# Балачак аланы

**Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия**

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән



Казан
РИЦ нәшрияты
2011

**УДК 373.167.1**
**ББК 74.200.53**
**Б 15**

Төзүчесе — **Закирова Кафия Вәлиевна**

Рецензентлары:
***Фәләхова Нелли Рифовна*** *— Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының укыту-методик эш белгече;*
***Шәйхетдинова Вәсилә Вәгыйзовна*** *— Казан шәһәре 153 нче балалар бакчасының югары категорияле тәрбиячесе;*
***Абдурахманова Әнүзә Вилдановна*** *— Тәтеш шәһәре «Әкият» балалар бакчасының беренче категорияле тәрбиячесе.*

**Б 15** **Балачак** аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011. — 560 б.
ISBN 978-5-4378-0030-0

«Балачак аланы» уку китабы бүгенге көн шартларына, заман таләпләренә яраклаштырып төзелде.

Китап балалар бакчаларында эшләүче педагогларга, әти-әниләргә юллана.

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**ISBN 978-5-4378-0030-0**

© РИЦ, 2011

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Туган телне саклау һәм үстерү — көнүзәк мәсьәлә, чөнки телнең яшәеше, үсеше халыкның аны көндәлек тормышта ни дәрәҗәдә куллануына бәйле.

Туган тел — бала тугач та үзләштерелә башлаган олы хәзинә.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Татар халкының мәшһүр шагыйре, бөек әдип Габдулла Тукай үзенең туган телгә булган ихтирамын әнә шулай матур итеп әйтеп биргән.

*Туган тел* төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул — *әти-әни, туган җир, Ватан* сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә бөек, изге сүз. Туган телгә баланы аның иң газиз, якын кешесе — әнисе өйрәтә, шул телдә аңа назлы бишек җырлары җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык *ана теле* дип атый. «Ана теле аша үзләштерелгән идеяләр, белем һәм күнекмәләр хәтергә көчлерәк сеңә. Чөнки ана теле — тою, сизү, йөрәк теле, рухи тамыр», — ди заманыбызның олпат педагогы Ш. Җәләлиев[1]. Баланың ана телен үзләштерүе һәм аны актив куллануы, шул телдә тәрбия һәм белем алуы аның һәрьяклы үсеше өчен уңай шарт булып тора.

Мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең тәрбия һәм белем бирү программасында, иң кечкенәләрнең беренче төркеменнән башлап (туганнан алып 1 яшькә кадәр), балаларның авазларны дөрес әйтеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә һәм бәйләнешле итеп сөйли белүләренә ирешү, туган телнең матурлыгын, аһәңлелеген тоя-күрә белергә өйрәтү бурычлары күрсәтелгән. Әлеге бурычларны тормышка ашыруда **әдәби әсәрләр, нәфис сүз, халык авыз иҗаты әсәрләренең** әһәмияте гаять зур. Әдәби мирасыбызның бер өлеше булган балалар әдәбияты әсәрләре, халык авыз иҗаты үрнәкләре нәниләрнең логик фикерләү сәләтен үстерә, тирә-юньне танып белергә өйрәтә, дөнья халыклары иҗаты белән кызыксынуларын арттыра.

[1] *Җәләлиев Ш.Ш.* Татар халык педагогикасы. — Казан: Мәгариф, 2000. — 57 б.

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11.2009) 655 нче номерлы боерык нигезендә расланган «Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре»нең (алга таба ФДТ. — *авт.*) «Матур әдәбият уку» бүлегендә (3,3,8) «балаларда китапка кызыксыну уяту һәм китап укуга ихтыяҗ формалаштыру максаты, матур әдәбиятны аңга алу-үзләштерү» зарурлыгы күрсәтелә.

«Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем стандарты»нда (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 нчы елның 6 нчы октябрендә 373 нче номерлы боерыгы нигезендә расланган) «әдәбиятның милли традицияләр һәм әхлакый кыйммәтләрне саклау, буыннарга тапшыру чарасы булганлыгы» («Филология» бүлеге 3,3,1) бәян ителә; әдәби әсәрләр укуның башлангыч этик күзаллаулар формалаштырудагы, Туган ил, Россия, дөнья тарихы һәм культурасы белән таныштырудагы әһәмияте ассызыклана.

Әдәбиятны юкка гына «тормыш дәреслеге» димиләр. Матур әдәбият әсәрләре, тәрбияви эчтәлекле китаплар белән танышу аша бала хыялланырга, иҗат итәргә, башкаларның борчу-шатлыкларын, рухи халәтен аңларга өйрәнә, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, тормыш тәҗрибәсен үзләштерә. Баланы китап белән таныштыру никадәр иртәрәк башланса, аның үсеше шулкадәр уңышлырак булу һәркемгә мәгълүм. Әмма, нәни бала әле үзе укый белмәгәнлектән, уку өчен матур әдәбият сайлау тулысы белән өлкәннәрдән тора. Нәниләргә кул астында булган теләсә нинди очраклы текстлар укырга ярамый. Әсәрнең бала өчен кызыклы, аңлаешлы (үз яшенә туры килүе), тәрбияви эчтәлекле булуы мөһим.

«Балачак аланы» хрестоматиясе өчен материал туплаганда да, иң элек әсәрнең баланы ни дәрәҗәдә кызыксындыра алуы, үзенең эчтәлеге белән балага якын, аңлаешлы булуы, сөйләм телен баетуга ярдәме, тәрбияви әһәмияте искә алынды. Шулай ук балаларның психологик үсеше һәм яшь үзенчәлекләренә зур игътибар бирелде.

«Балачак аланы» уку китабы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпкәчә

тәрбия буенча норматив документларын, педагогика һәм психология өлкәсендәге казанышларны искә алып; кече яшьтәге балалар өчен төзелгән барлык уку китапларында булган уңай тәҗрибәне саклап; бүгенге көн шартларына, заман таләпләренә яраклаштырып төзелде. Ул «Туганнан алып мәктәпкә кадәр» исемле тәрбия һәм белем бирү программасына (М.: Мозаика-Синтез, 2010), «Программаның милли-төбәк юнәлеше» (К.: Мәгариф, 2009) һәм Федераль дәүләт таләпләренә туры китереп иҗат ителде.

Хрестоматиянең төзелү принцибы, структурасы, эчтәлеге үзенчәлекле. Алдагы елларда нәшер ителгән хрестоматияләрдән аермалы буларак, җыентыкның төп өлешен ФДТда күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе («Сәламәтлек», «Физик культура», «Социальләштерү», «Хезмәт», «Куркынычсызлык», «Танып белү», «Аралашу», «Матур әдәбият уку», «Иҗат», «Музыка») буенча тупланган әсәрләр тәшкил итә.

Китап 2 кисәктән тора. **«Балдай татлы балачак»** дип исемләнгән **I кисәк** тулысы белән ФДТның «Матур әдәбият уку» белем бирү өлкәсен яктырта. Әлеге бүлекне «Программаның милли-төбәк юнәлеше» билгеләгән әсәрләр тәшкил итә. Әсәрләрнең тематикасы балаларның яше арта барган саен төрләнә, киңәя бара. Алар балаларның яшь үзенчәлекләре буенча тупланып, 6 төркемгә бүлеп бирелде: «Бәллүр бишек» (туганнан алып 2 яшькә кадәр), «Мин бит әле бик нәни...» (2—3 яшьлек балалар), «Үсә-үсә зур булам» (3—4 яшь), «Гөрләп үсәбез, без бәхетлеләр» (4—5 яшь), «Без инде хәзер зурлар» (5—6 яшь), «Мәктәпкә илтә юллар» (6—7 яшь). Билгеле, бу — шартлы бүленеш кенә. Чөнки балаларның әдәби әсәрләрне аңлау, кабул итү мөмкинлекләре төрле. Моңа аларның шәхси үзенчәлекләре дә, яшәү шартлары да, шулай ук матур әдәбият белән таныштыруның ни дәрәҗәдә эзлекле алып барылуы да йогынты ясый. Шуңа да теге яки бу әсәр белән баланы иртәрәк (мәсәлән, 3—4 яшьтә) яки үсә төшкәч (5—6 яшьтә) таныштырырга мөмкин. Димәк, балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр һәр балага индивидуаль якын килергә тиешләр. Балаларның әзерлек дәрәҗәләрен һәм шәхси мөмкинлекләрен искә алып, әсәрләр белән эшләү төрен дә (уку, эчтәлеген сөйләү) тәрбияче

үзе билгели. Ә инде ятлау, рольләргә бүлеп сөйләү өчен, әсәрләр исемлеге программада күрсәтелгән.

Балаларга ана телен өйрәтүдә төп алымнарның берсе — халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына таяну. Нәкъ менә шушы хакыйкатьне истә тотып, балаларның яшьләре буенча билгеләнгән бүлекләр *халык авыз иҗаты әсәрләре* белән башланып китә. 1—3 яшьлек балалар өчен ягымлы, назлы бишек җырлары, күңелле такмаклар, бала тугач әйтелә торган теләк-юраулар, бармак уеннары бирелсә, 4—7 яшьлек балалар өчен табигатькә, кош-кортка эндәшләр; календарь-йола җырлары; авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтен арттыру өчен, тел көрмәкләндергечләр өстәлде.

Халкыбызның рухи мәдәниятенә алып керүче тагын бер чыганак — ул *әкиятләр*. Хрестоматия кечерәк балаларны (1— 4 яшь) хайваннар һәм көнкүреш турындагы эчтәлекләре ягыннан катлаулы булмаган әкиятләр («Кәҗә бәтиләре һәм Бүре», «Калач», Аю белән бабай», «Ике ялкау» һ.б.) белән таныштыра. Ә зуррак балалар (5—7 яшь), мондый әкиятләрдән тыш, тылсымлы әкиятләр белән дә («Гөлчәчәк», «Зөһрә йолдыз», «Казлар-аккошлар» һ.б.) таныша алалар.

Язучыларыбыз тарафыннан иҗат ителгән серле әкиятләр һәм тәрбияви эчтәлекле хикәяләр дә сабыйларга олы бүләк булыр. А. Алиш, Җ. Тәрҗеманов, Р. Батулла, Р. Вәлиева, Ф. Яруллин, Ә. Гаффар, С. Сәүбәнова һ.б. язучыларның кызыклы һәм мавыктыргыч әкиятләрен тыңлап, балалар уңай һәм тискәре сыйфатларны аерырга, әкият геройларының уй-хисләренә, эш-гамәлләренә тиешле, дөрес бәя бирә белергә, мәрхәмәтле, рәхим-шәфкатьле, ярдәмчел булырга өйрәнерләр. Г. Бакир, Р. Гыйззәтуллин, Г. Лотфи, Ә. Хәсәнов, И. Туктар, Н. Каштан һ.б. язучыларның нәниләр тормышын, табигать дөньясын матур төсмерләр белән чагылдырган әсәрләре балаларда тереклек ияләрен яклау, аларны саклау, үзара ярдәмләшү, хезмәт сөючәнлек тәрбияләр.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга эстетик тәрбия бирү һәм аларда әхлак сыйфатлары булдыруда татар *балалар шигъриятенең* роле чиксез зур. Эчтәлеге белән сабыйлар күңеленә якын, аңлаешлы шигырьләрнең нинди тәрбияви көчкә ия булуы, баланың

сөйләмен баетуда, зиһенен үстерүдә иң тәэсирле тәрбия чарасы икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Шуны истә тотып, хрестоматиягә әдипләребезнең балалар яратып тыңлый, яттан сөйли торган шигырьләре кертелде. Алар программада күрсәтелгән тәртиптә берләштерелеп бирелде. Кызыклы, мавыктыргыч эчтәлекле шигырьләр балаларга, бер яктан, олы шатлык, сөенеч китерү чарасы дип каралса, икенчедән, нәниләрнең һәрьяклы үсешен тәэмин итүгә зур этәргеч тә була. Моннан тыш, балаларның тирә-як дөнья турындагы белемнәре арта. Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай, герой-шагыйрь М. Җәлил, табигать «җырчысы» Х. Халиков, нәниләр дөньясында «үз» кешегә әверелгән Ш. Галиев, Р. Мингалим, Р. Вәлиева, Р. Миңнуллин, М. Фәйзуллина һ.б.ның шигырьләре балаларда Туган ил, торган җир, туган телгә мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итә, аларда патриотлык һәм интернациональлек, үз илең белән горурлану хисләре тәрбияли.

Н. Думави, Дәрдемәнд, Р. Фәхреддин, К. Насыйри кебек олпат затларыбызның тирән эчтәлекле, тәрбияви кыйммәтле әсәрләре балаларны кечкенәдән инсафлы, гадел, әдәпле, өлкәннәргә ихтирамлы, мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Хәзерге заман татар шагыйрьләре Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Э. Шәрифуллина, Ф. Яруллин, Р. Корбан, Л. Лерон әсәрләре балаларның кеше белән табигать арасындагы төрле бәйләнешләр турындагы күзаллауларын киңәйтә, әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалашуга ярдәм итә.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законнарында «мәгарифнең гуманистик характерлы булуы, гомумкешелек кыйммәтләренең өстенлеге» (1 нче бүлек, 2 нче маддә) күрсәтелә. Бала хокуклары Декларациясендә баланың «халыклар арасындагы дуслык, түзүчәнлек, үзара аңлашу рухында тәрбияләнергә тиеш»леге ассызыклана. БМО Генераль Ассамблеясы кабул иткән «Бала хокуклары турындагы Конвенция»нең (20.11.1989) 28—31 нче маддәләрендә «белем бирү баланың туган теленә, үзе яшәгән илнең милли кыйммәтләренә хөрмәт тәрбияләү, башка милләт халыкларына ихтирамлы мөнәсәбәт булдыруга юнәлтелгән»леге күрсәтелә. Шушы бурычларны гамәлгә ашыру максатыннан,

җыентыкка, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, татар балалар шигърияте, бүгенге көн язучыларының максатка ярашлы эчтәлекле хикәяләре, серле әкиятләре белән беррәттән, *Россия һәм башка ил язучылары, дөнья халыклары фольклоры әсәрләре* кертелде. Әлеге әсәрләр балаларда кешелеклелек, башка милләт вәкилләренә, аларның теленә, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә карата уңай мөнәсәбәтләр тәрбияләүне, башкаларны ихтирам итү, янәшә тыныч яшәү һ.б. шундый матур әхлакый сыйфатлар тәрбияләүне күздә тота. Бөек рус язучысы Л. Толстойның хайваннар, кош-кортлар турында балалар күңеленә якын, аңлаешлы хикәяләре, әкиятләре («Варя белән Песнәк», «Өч аю», «Зирәк чәүкә» һ.б.); бөек педагог һәм психолог К. Д. Ушинскийның мавыктыргыч хикәяләре («Мияубикә», «Әтәч үзенең гаиләсе белән» ); нәниләр теле белән иҗат итүче А.Барто шигырьләре («Елга», «Катя», «Берүзем»); молдаван шагыйре Г. Виеру, грузин шагыйре Н.Думбадзе, литва шагыйре Ю.Некрошюс, чуваш шагыйрәсе Р.Сарби, мари шагыйре А.Тимиркаев, удмурт шагыйре В. Романовларның әсәрләре балаларда тереклек ияләрен яклау, аларны саклау, табигатькә, тирә-юньдәге предметларга сак караш, үзара ярдәмләшү, хезмәт сөючәнлек хисләре тәрбияли. Әлбәттә, бу бүлектә урын алган башкорт, украин, болгар, корея, венгр, филиппин һ.б. халык әкиятләре балаларга дөньяны танып белү серләрен өйрәтүдә, безнең илдә төрле милләт халыкларының тыныч, тату яшәүләре турында күзаллауларын ныгытуга ярдәм итәр.

Китапның **«Җирдә миңа ни кирәк?» II исемле кисәге** ФДТның калган 9 белем бирү өлкәсенә кагылышлы әсәрләрдән тора. Ул, ФДТда билгеләнгән 4 *төп тәрбия-үсеш юнәлешенә* (1 — «Физик үсеш», 2 — «Социаль-шәхси үсеш», 3 — «Танып белү-сөйләм үсеше», 4 — «Нәфис-нәфасәти үсеш») нигезләнеп, тематик принцип буенча төзелде. «Хәрәкәттә бәрәкәт», «Һәрвакыт булсын кояш!», «Дөнья матур, дөнья киң», «Салават күпере» исемле әлеге бүлекләрдә нәниләр тормышын чагылдыручы, үсемлек һәм тереклек дөньясына кагылышлы, экологик культура, табигатькә аңлы караш, туган җиргә, телгә мәхәббәт тәрбияләүгә булышлык итүче шигырьләр, әкият, хикәяләр урын алды; нәниләрдә кешелеклелек хисләре, үз-үзеңне культуралы тоту күнекмәләре,

өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләүгә, нәрсә — яхшы, нәрсә — начар, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә кагылышлы әсәрләр кертелде.

Һәр 4 бүлек тә темага кагылышлы, халкыбызның тормыш сынавы аша узган тәрбия җәүһәрләре — мәкаль-әйтемнәр, сынамышлар, табышмаклар белән башланып китә. Ана телебезнең матурлыгы, камиллеге һәм байлыгы гәүдәләнгән әлеге энҗе-мәрҗәннәр балаларның сөйләмен баетуда, тапкырлык-зирәклекләрен тирәнәйтүдә, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерүдә ышанычлы ярдәмлек булыр.

**«Хәрәкәттә — бәрәкәт» бүлеге** *«Сәламәтлек», «Физик культура» белем бирү өлкәләрен* чагылдыручы әсәрләрне үз эченә ала. Нәниләрнең сәламәтлеген саклау, ныгыту; аларда культура-гигиена күнекмәләре тәрбияләү; сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру (кеше организмының төзелеше, дөрес туклану, чыныктыру чараларының әһәмияте) турында шигырьләр, хикәяләр шушы бүлектә урын алды. Балалар тарафыннан яратып уйнала торган *уеннар*; уенны алып баручы (әйдәүче) сайлау өчен кулланыла торган *санамышлар*; шулай ук шөгыльләрдә файдалану өчен, *физкульминутлар* да әлеге бүлектә бирелде.

**«Һәрвакыт булсын кояш!» бүлеге** *«Социальләштерү», «Хезмәт», «Куркынычсызлык» белем бирү өлкәләренә* кагылышлы әсәрләрне берләштерә. Анда В. Хәйруллина, Йолдыз, Л. Шәех, Л. Әмирханова, А. Җамалиев кебек бүгенге көн балалар әдәбиятының талантлы шагыйрь-шагыйрәләре әсәрләренә зур урын бирелде. Бүлеккә шулай ук сабыйларның эчке кичерешләрен, теләк-хыялларын чагылдырган («Үсәсем килә минем», *Л. Әмирханова;* «Кечкенә», *Ш. Җиһангирова;* «Үстем», *Д. Гарифуллин* һ.б.); нәниләрдә *Мин* образын формалаштыру («Әни дә мин, бала да мин», *Ә. Габиди;* «Бу — мин!», *В. Ураксина*) һәм сөйләм культурасын үстерү («Тылсымлы сүзләр», *Йолдыз;* «Хәерле көн», *В. Хәйруллина*) буенча әсәрләр кертелде. Балаларның яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән үзара мөнәсәбәтләре («Йоклар алдыннан», *Р. Мәннан*; «Үпкәләп булмый әбигә», *Н. Мадьяров*; «Рамазан аенда», *Йолдыз*); әти-әни, гаилә әгъзаларын, туганнарны зурлау, олылау, аларга карата рәхмәтле, ихтирамлы булу («Иртә»,

*И. Иксанова*; «Энем бар», *Р. Мингалим*; «Иңнәремдә — фәрештә», *Э. Шәрифуллина*); Туган ил, безнең планета («Булатларга кунакка!», *Р. Миңнуллин*; «Хат», *Г. Юнысова*; «Сәлам, галәм!», *Йолдыз*); шулай ук өлкәннәр хезмәте, һөнәрләр, хезмәт итәсе килү теләге, балалар хезмәте турындагы әсәрләр дә («Безнең бабай», *М. Мазунов*; «Ялт иттерде бүлмәне», *Ф. Тарханова*; «Кем кем була?», *Л. Шәех*) шушы бүлектә тупланды. *Р. Мәннанның* «Булышам», *В. Хәйруллинаның* «Таяклы помидор», *Х. Халиковның* «Дәү әнием — бакчачы» исемле шигырьләре нәниләрнең ел фасыллары белән бәйле хезмәтләре турындагы белемнәрен арттыра, кеше тормышында хезмәтнең мөһимлеген аңларга ярдәм итә.

Тормыш куркынычсызлыгы нигезләре, юл хәвефсезлеге кагыйдәләре, табигатьтә үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләренә кагылышлы әсәрләр дә («Үрли дә үрли генә», *Ә. Бикчәнтәева*; «Гөмбәләр», *М. Фәйзуллина*; «Сансыз малай», *Б. Рәхимова*; «Светофор», *И. Иксанова*) әлеге бүлектә урын алды.

**«Дөнья матур, дөнья киң» дип исемләнгән зур күләмле бүлектә** *«Танып белү-сөйләм үсеше» юнәлеше* буенча әсәрләр тупланды. Табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары, тәүлек бүленеше турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экологик культура тәрбияләү бурычларын гамәлгә ашыруга ярдәм итүче әсәрләр («Җилкәй, исмә», *В. Ахунҗанов*; «Табигать кочагында», *Р. Фәйзуллин*; «Урманда», *З. Гомәрова*) белән беррәттән, әлеге бүлек балаларның *иң гади математик күзаллауларын формалаштыру, конструкцияләү эшчәнлеге*, предметлар дөньясы турындагы шигырьләрне берләштерә.

*«Аралашу» белем бирү өлкәс*е буенча тупланган әсәрләр («Яхшы бел», *Ш. Маннур*; «Туган тел», *Г. Морат*; «Әкиятләр ятатам», *Э. Шәрифуллина* һ.б.) нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруда ярдәм итәр.

Сабыйларның кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү максатыннан, әлеге бүлеккә *рольләргә бүлеп сөйләү өчен* дә шигырьләр кертелде. Аралашу,

кара-каршы сөйләшү сөйләм үсешенә зур йогынты ясый. Балалар шигырьләрне сәхнәләштереп уйнарга бик яраталар. Алар яңгырашлы рифмалы шигырьләрне тиз отып алалар, анда катнашучы персонажларның кичерешләренә бәйле рәвештә интонация үзгәртеп, сәнгатьле итеп сөйлиләр. Шигырьләрне укыганда, балаларның игътибарын сәнгатьле сурәтләү чараларына (чагыштырулар, тапкыр сүзләр, эпитетлар) юнәлтү, автор тарафыннан кулланылган образлы әйтелмәләр матурлыгын күрсәтү, төшендерү мөһим. Болай эшләгәндә, нәниләрдә матур әдәбият әсәрләрен күңелең белән тою, сиземләү хисләре туа, эстетик тойгылар уяна, матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләнә.

*«Күңелле шигырьләр»* дип исемләнгән шигырьләр бәйләмендәге Л. Лерон, Мөҗәһит, И. Солтан, И. Юзеев һ.б.ның юмористик әсәрләре, шигърият бәйрәмнәрендә, төрле конкурс-фестивальләрдә куллану өчен, балалар репертуарын баетырга ярдәм итәр.

**«Салават күпере» бүлегендә** тупланган шигырь-хикәяләр балаларны әйләнә-тирәдәге матурлыкны күрә белергә, халкыбызның милли мәдәниятенә, традицияләренә ихтирамлы булырга өйрәтер; декоратив-сәнгать үрнәкләре белән кызыксынуларын үстерер.

*«Музыка» белем бирү өлкәсе* буенча тупланган әсәрләр («Сәйдәш моңнары», *М. Хөсәен*; «Курай», *Р. Бәшәр*; «Әйлән-бәйлән», *Р. Миңнуллин*) нәниләрнең музыка өлкәсендәге белемнәрен үстерергә булышлык итәр, иҗади сәләтләрен үстерер. Бу бүлектә бирелгән халыкара, милли *бәйрәмнәргә багышланган шигырьләр* дә сабыйларның әлеге бәйрәмнәр турындагы күзаллауларын киңәйтер, эстетик зәвыгын үстерер, аларны милли традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасына өйрәтер.

Җыентыкта тупланган әдәби материал балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү һ.б. эшчәнлектә, иртән нәниләрне кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү, эксперимент эшләре, режим процессының башка вакытларында да файдалану өчен тәкъдим ителә.

...Балачак. Беркайчан да кабатланмас балачак иле — кеше гомерендәге серле, мавыктыргыч алан. Шул аланда — әниләрнең йөрәк җылысы белән сугарылган бишек җырлары моңы, беренче тапкыр әйтелгән *әннә*, *әттә* сүзләре, олы дөньяга атлап киткән тәүге адымнар... Шул аланда зур дулкынлану белән нәни кулларга алган беренче китап — балалар китабы.

«Балалар китабы ул — тормыш сабаклары да, гүзәллек, гаделлек, мәрхәмәтлелек дәресләре дә.

Балалар китабы ул — якын дус, акыллы киңәшче дә, турылыклы иптәш, ышанычлы фикердәш тә.

Балалар китабы ул вакытында чыккан якты кояш кебек, вакытында яуган шифалы яңгыр кебек, вакытында искән җылы җил кебек...» [2]

Танылган балалар язучысы, күренекле шагыйрь Р. Миңнуллин кеше тормышында балалар китабының әһәмиятле, кыйммәтле ролен әнә ничек матур итеп тасвирлый! Дөрестән дә, КИТАП — кешене һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле, әдәпле-әхлаклы булырга өйрәтүче тормыш дәреслеге бит ул.

«Балачак аланы» китабы да нәниләрне белемле, кешелекле, шәфкатьле итеп тәрбияләүдә, туган телен, халкын яратучы, рухи яктан бай, югары әхлаклы шәхес итеп үстерүдә балалар бакчасы педагогларына, әти-әниләргә ышанычлы ярдәмлек була алса иде.

---

[2] Балачак энциклопедиясе. I китап / Төзүчеләре: Т. Шакирова, Л. Шәех. — Казан: ТКН, 2009. — 3 б.

I КИСӘК

# Балдай татлы балачак



## Балдай татлы балачак

Балдан татлы бала чагым,
Күпме хисләрем синдә.
    Күпме иркәләү, сөелү,
Күпме җылы кул иңдә.

Балдай татлы балачакта
Җир җиләкләре тәме.
Тәмле балачак күгендә
Киләчәк көннәр гаме!

*Эльмира Шәрифуллина*

# «БӘЛЛҮР БИШЕК»

2 яшькә кадәрге балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Бишек җырлары, такмаклар

* Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Йокыларга киткәчтен,
Бик дәү булып үсәр бу.

* Салкын су, чиста су,
Баламның битләрен ю,
Баламның күзләрен ю.
Күзләре ялкынлансын,
Үзе нык, таза булсын.

* Әттә, әттә, әттәти,
Минем улым бик тәти.
Минем улым бик тәти дә,
Йөреп китәр ул тәпи.

* Биесен лә, биесен лә,
Биек тауга менсен лә.
Матур итек кисен лә,
Барысы моны сөйсен лә.

* Үчтеки, үчтеки,
Үсмәгәнгә кечтеки.
Үсә-үсә зур булыр,
Бигрәк матур кыз булыр
(кызларга).
Бик батыр егет булыр (малайларга).

* Әлли-бәлли бәү итә,
Кызым йокыга китә.
Кызым йокыга киткәч,
Әнисе кайтып җитә.

* Үсә-үсә бәбкәем,
Үсә-үсә зур була.
Кояш кебек сөйкемле,
Үзе сүзгә җор була.

* Минем кызым кечкенә,
Бик ошаган үземә.
Әкрен басып,
вак-вак атлап
Кил, алтыным, тиземә.

* Чәбәк-чәбәк әбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
— Каенлыкка җиләккә,
Кызыбызга бүләккә.

* Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң, мин басам.
Синең баскан эзләреңә
Мин дә китереп басам.

* Бу бармак — бабай,
Бу бармак — әби,
Бу бармак — әти,
Бу бармак — әни,
Бу бармак — бәби,
Аның исеме — Чәнти.

# ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР

## Кәҗә бәтиләре һәм Бүре

*(Татар халык әкияте)*

Урманда кечкенә генә бер өйдә үзенең бәтиләре белән бер Кәҗә яши. Кәҗә һәр көн саен урманга азык эзләргә китә. Үзе киткәндә балаларына: «Берәүгә дә ишек ачмагыз!» — дип әйтеп калдыра торган була.

Кәҗә, урманнан кайткач, мөгезләре белән ишекне шакылдата да җырлый:

Бәтиләрем, балакайларым!
Ачыгыз ишекне, ачыгыз!
Сезнең әнкәгез кайтты,
Сезгә сөт алып кайтты!

Кәҗә бәтиләре бик акыллы булалар. Алар әниләренең тавышын шундук танып алалар һәм ишекне ачалар. Әниләре аларны сөт белән сыйлый да тагын урманга китә. Ә бәтиләр ишекне бикләп калалар.

Кәҗәнең җырлаганын бервакыт Бүре ишетеп тора. Кәҗә урманга китү белән, ул өй янына килә дә җырлый башлый:

Әй кәҗә бәтиләре,
Ачыгыз ишекне!
Сезнең әнкәгез кайтты,
Сезгә сөт алып кайтты!

Кәҗә бәтиләре бик сизгер булалар:

— Ишетәбез, ишетәбез, бу әнкәбез тавышы түгел! — диләр. Бүрегә ишекне ачмый алар. Бүре ишек төбендә басып тора-тора да кайтып китә.

Бераздан Кәҗә үзе кайта. Балалары шунда ук әниләренең тавышын танып алалар да ишекне ачалар. Шуннан алар калын тавышлы берәүнең килгәнен сөйләп бирәләр.

Кәҗә үзенең балаларын тәмле сөт белән сыйлый да тагын урманга китә. Ишекне ныграк бикләргә куша. «Ачмагыз, Бүре килер дә үзегезне алып китәр!» — дип кисәтә балаларын.

Балалары әниләренең сүзен тыңлаганнар һәм ишекне берәүгә дә ачмаганнар.

## Шалкан

*(Рус халык әкияте)*

Бабай шалкан утыртты. Шалкан көн үсте, төн үсте, бик зур булды, күперде. Атналар, айлар үтте, җәй үтте, көз җитте. Бабай шалканны йолкырга кереште. Тарта, тарта — шалкан чыкмый.

Бабай, шалканны үзе генә тартып чыгара алмагач, ярдәмгә әбине дә чакырды. Әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан һаман чыкмый.

Әби булышырга кызын чакырды. Кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Тартырга керештеләр болар. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан чыкмый да чыкмый.

Әбинең кызы шалканны тартышырга Акбайны чакырды. Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан һаман чыкмый, селкенми дә.

Акбай ярдәмгә песине чакырып килде. Песи — Акбайга, Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Тартырга керештеләр. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан һаман да чыкмый.

Песи тычканны чакырып китерде. Тычкан — песигә, песи — Акбайга, Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга ябышты. Әй тарталар, әй тарталар. Җыйнаулашып тарта торгач, шалкан түзмәде — төбе-тамыры белән каерылып чыкты.

## Чуар тавык

*(Рус халык әкияте)*

Бер бабай белән әби яшәгән, ди. Аларның Чуар тавыклары бар икән. Беркөнне тавык йомырка салган, нинди диген әле, гади йомырка түгел, алтын йомырка. Бабай йомырканы ватып караган — вата алмаган. Әби ватып караган — вата алмаган. Бер тычкан үтеп бара икән — йомыркага койрыгы тиеп киткән. Йомырка тәгәрәп тә төшкән, урталайга ярылган да. Бабай да елый, әби дә елый икән. Ә Чуар тавык шунда болай дигән:

— Елама, бабай, елама, әби, сезгә әле мин тагын салырмын, алтынны түгел — гади йомырка!

## Зилә бакчага бара

— Кик-ри-кү-үү-үк! — дип кычкырды кызыл кикрикле Әтәч.— Бу өйдә ялкаулар ю-ю-юк!

Инде таң аткан икән, торыр вакыт та җиткән.

— Үс-үс, ү-ү-үс, кызым! — диде Зиләгә әнисе.

Зилә күлмәк кия, төймәләрен каптыра. Аннары битен юа, ә Песи карап тора.

Песи, песи, пескәем,
Уеннан һич туймыйсың,
Ник битеңне юмыйсың?
Тычканнарың күрерләр
Һәм үзеңнән көлерләр...

Песи бик тә оялды, кулына сабын алды…

Зилә бакчага китә, аны әтисе илтә. Зилә җәяүләп бара: ерак түгел ич ара.

Килеп җитә ул бик тиз.
Әтисе китеп бара,
Зилә бакчада кала.

Ә бакчада — бәбиләр, бик күп, бик күп тәтиләр.

*Зиннур Хөснияр буенча*

## Җиләккә барганда

Шулай беркөнне Рөстәм[3] исемле акыллы малай урманга җиләккә бармакчы булган. Аяк арасында сырпаланып йөрүче песи баласы аңа: «Мияу-мияу, мине дә үзең белән ал әле...» — дигән. «Әйдә,— дигән Рөстәм.— Бергә-бергә күңелле булыр».

Болар ишегалдына чыкканнар икән, каршыларына, койрыгын уйнаткалап, маэмай килгән: «Һау-һау, мин дә барам...»

Ә коймага кунган тавык малае, канатларын җилпеп: «Кикрикү-үк! Әйдә, киттек хәзер үк!» — дип кычкырган.

Иң алдан зур-зур атлап Рөстәм бара. Аннан — песи баласы Мияу, аннан — көчек Һауһау, аннан — тавык малае Кикрикүк. Баралар, баралар икән болар, шулчак каршыларына кызыл оек кигән каз бәбкәсе килеп чыккан: «Кыйгак-кыйгак, болай матур итеп тезелеп, кая киттегез?» Тегеләр: «Урманга җиләккә барабыз, дигәннәр. Әйдә син дә безнең белән. Бергә-бергә күңелле булыр».

Тагын кузгалып киткәннәр болар. Иң алдан, зур-зур атлап, Рөстәм бара. Аннан — Мияу, аннан — Һауһау, аннан — Кикрикүк, иң арттан — Кыйгак. Баралар, баралар икән болар, болында әнисе тирәсендә уйнаклап йөрүче колынны очратканнар һәм җиләккә барырга чакырганнар. «Миһа-һа-а!» — дип шатланып кешнәп җибәргән тай, әнисе аңа рөхсәт биргәч.

Болар тагын кузгалып киткәннәр. Иң алдан, зур-зур атлап, Рөстәм бара икән. Аннан — песи баласы Мияу, аннан — көчек Һауһау, аннан — тавык малае Кикрикүк, аннан — каз бәбкәсе Кыйгак, иң соңыннан — колын Миһаһа. Баралар, баралар икән, арттан кәҗә бәтие кычкырганны ишеткәннәр: «Мә-ә-ә-мә-ә-ә, мин дә барам...» Тегеләр: «Әйдә, бергә-бергә күңелле булыр»,— дигәннәр. Иң алдан, зур-зур атлап, Рөстәм бара. Аннан — Мияу, аннан — Һауһау, аннан — Кикрикүк, аннан —

[3] Һәркем үз улының яки кызының исемен әйтеп сөйли *(автор искәрмәсе)*.

Кыйгак, аннан — Миһаһа, иң соңыннан — бәти Мәәә. Шунда каршыларына...

Бу әкият менә шулай бала йоклап киткәнче дәвам итә. Дәвамын әкият сөйләүче үзе уйлап таба.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Мияубикә

Песи-пескәй, сары маңгай.

Мияубикә иркәлеккә бик иркә, ләкин хәйләкәр: тәпиләре аның хәтфә кебек йомшак, тырнаклары энә кебек, ай-яй үткен!

Мияубикәнең колаклары сизгер, мыеклары озын, ә туны хәтфә төсле.

Песи иркәләнә, сырпалана, койрыгын болгый, күзләрен йома, җыр көйли. Ә тычкан эләктереме — шәфкать көтмә инде! Күзләре зурая, тәпиләре корычтай ныгый, тешләре ыргак сыман була, тырнаклары тырпая.

*Константин Ушинскийдан*

## Настяның курчагы

Настяның курчагы бар. Настя аны кызым дип йөри. Әнисе, курчагына киертү өчен, Настяга киемнәр тегеп бирде. Хәзер инде курчакның күлмәге дә, яулыгы да, оеклары да, хәтта чәч тарагы белән теш щёткасы да, муенсасы да бар.

*Лев Толстойдан*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Без чәбәкәй итәбез

Чәп-чәп, чәбәкәй,
Безнең Солтан бәләкәй.
Ул акыллы, ул тәтәй,
Килмә монда, кәҗәкәй!
*Нурия Измайлова*

## Үчти-үчти

Үчти-үчти үчтеки,
үсте китте кечтеки.
Үсте, үсте, зур булды,
таза һәм матур булды,
Акыллы, зирәк булды,
һәркемгә кирәк булды.
*Ренат Харис*

## Бәллү

Кыйгач кашым,
Асыл ташым,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү
Алмакаем,
Аппаккаем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!
Кил, гөлкәем,
Сөмбелкәем,
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәлли-бәү!
*Дәрдемәнд*

## Булатны йоклатканда

Әлли итә бу Булат,
Бәлли итә бу Булат.
Кайчан тәпи йөреп китәр,
Үсеп җитәр бу Булат?

Челт-челт йома күзләрен,
Тырмап ала йөзләрен.
Әллә нәрсә әйтмәкче —
Аңлап булмый сүзләрен.

Әлли-бәлли ит, Булат,
Тизрәк йоклап кит, Булат.
Калсын әле бер мәлгә
Әниең иркен сулап.
Тизрәк йоклап кит, Булат...

*Мөҗәһит*

## Ай, нәни

Күк күгәрчен очадыр,
Зәңгәр күкне кочадыр.
Минем улым бәү-бәү итә,
Йолдызларда очадыр.

Әлли-бәлли-бәү, нәни,
Йоклап китәр бу бәби.
Җылы моңнар канатында
Үсеп җитәр бу нәни!

Күгәрченнәр күкләрдә
Очалар җим чүпләргә.
Үсеп җиткәч, минем улым
Үрнәк булыр күпләргә.

*Әхмәт Гадел*

## Бәлли-бәү

Акбай, Акбай, өрмә син,
өрмә син!
Тавышланып йөрмә син,
йөрмә син!

Кызым белән без икәү
Йоклыйк инде, бәлли-бәү.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Мияу!

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Йомшак синең йоннарың,
Җылы синең туннарың.

*Роберт Миңнуллин*

## Бәти

Бар белгәне — «Бә».
«Бә дә бә», — ди ул.
«Бу ни?» дисәгез, —
Безнең бәти ул.

*Рафис Корбан*

## Чебиләр

Өй алдында чебиләр:
«Чип-чип-чип!» — дип йөриләр.
Кечкенә канатлары,
Муеннары сап-сары.

*Мәхмүт Хөсәен*

## Туп

Әминә елый үкереп,
— Тубым суга төште, — дип.
— Чү, Әминә, елама:
Туп батмый ул елгада.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Тәп-тәп бас

Әйдә, улым,
Киттек тәп-тәп!
Атлап шәп-шәп,
Таза бас!

Тәп-тәп атла,
Йәт-йәт атла,
Ялгыш басма,
Иплəп бас!

*Хәлим Исмәгыйлев*

## Бии-бии үс, әйдә

*(Нәниләрне биетү такмагы)*

Ары да килеп биисең,
Бире дә килеп биисең,
Яңа гына тәпи йөреп
Киткәнеңне белмисең.

Бигрәк матур биисең шул
Кечкенә Гөлсинәбез,
Егылсаң да еламыйсың,
Сине шуңа сөябез.

Сиңа бер яшь тулганына
Өч ай гына бит әле,
Биеп кенә, җырлап кына,
Тизрәк үсеп җит әле.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Беренче адымнар

Илгиз нинди үскән бала:
Үзе торып баса ала!
Батыраеп атлап китә,
Аяклары тып-тып итә.

Әй күңелле була аңа!
«Тәпи йөрим!» — дип куана.

*Әнәс Кари*

## Минем кызым — курчагым

Әй акыллы курчагым,
Йом күзеңне, бәлли-бәү.
Башка бер сүз дә дәшмим,
Йоклап алыйк без икәү.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Чәбәкәй

Минем сеңлем Тәнзилә
Әлегә бик бәләкәй.
Ә шулай да инде ул
Итә беләчәбәкәй.
Менә шулай, менә шулай
Итә беләчәбәкәй.

Әллә инде шуңарга
Сеңлем бигрәк сөйкемле.
Чәбәк-чәбәк иткәндә
Очып китәр шикелле.
Менә шулай, менә шулай
Очып китәр шикелле.

Көн дә көтәм мин аның
Тып-тып йөреп киткәнен.
Ул чәбәкәй иткәндә,
Беркөн биеп киткәнмен.
Менә шулай, менә шулай
Үзем биеп киткәнмен.

*Хәкимҗан Халиков*

# «МИН БИТ ӘЛЕ БИК НӘНИ...»

2–3 яшьлек балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Җырлар, юаткычлар, эндәшләр

* Җиләк җыям, как коям
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

* Кәккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык.
Галиянең өстенә
Матур күлмәк биреп чык.

* Кәккүк, чыпчык,
Минем матур кызыма
Тәмле прәнник
Калдырып чык.

* Алтын, алтын, алтыным,
Минем йөрәк ялкыным.
Уян, бәбкәм, күз нурым,
Кояш булып балкырмын.

* Яңгыр, яу, яу, яу!
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен,
Тәти кашык базарда,
Майлы ботка казанда.

* Карга әйтә: «Кар, кар,
Мичтә бәлеш бар, бар,
Мичтән бәлеш алыр идем,
Өйдә кунак бар, бар».

* Үсеп буйга җитәр бу,
Галим булып китәр бу,
Туган-үскән иленә
Тырышып хезмәт итәр бу.

* Тор, тор, тургай,
Таң, таң ата бугай.
Тургай, кил, чыпчык, чык,
Чырык, чырык, чырык!

* Йә, сандугач, күзең ач,
Тәрәзәдән, тургай, кач!

* Тыпыр-тыпыр биидер,
Аягы җиргә тимидер,
Очкан коштай талпынып,
Канатларын кагынып,
Һәп, һәп, һәп!

* Кояш, чык!
Болыт, кач!
Без уйнарбыз,
Җылыткач.

* Тук, тук, тукран,
Тукылдатып утырам,
Мичтә бәлеш пешәме?
Шуны көтеп утырам.

* Песи-матур, нечкә бил,
Бала тирбәтергә кил.
Җылы җирдә яшәрсең,
Тәмле сөтләр эчәрсең,
Ап-ак күмәч ашарсың,
Ашап туйгач уйнарсың,
Уйнап туйгач йокларсың,
Бәлли-бәү! Бәлли-бәү!

* — Песи, кая барасың?
— Әбиләргә барамын.
— Анда сиңа ни тия?
— Ике калак май тия.

## Хайваннарны чакыру

Чакырабыз кәҗәне:
— Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Кәҗ-кәҗ-кәҗ!

Чакырабыз маэмайны:
— Маһ-маһ-маһ!
Маһ-маһ-маһ!

Чакырабыз аткайны:
— Бах-бах-бах!
— Бах-бах-бах!

## Паровоз

Алга таба барабыз:
Тик-так-так!
Тик-так-так!
Гөрләп чаба паровоз:
Юл тап-тап,
Юл тап-тап!
Ак төтен артта кала:
Пух-пах-пух!
Пух-пах-пух!
Вагоннар җырлап чаба:
Ах-ах-ух!
Ах-ах-ух!
Свисток яңгырап китә:
Ту-ту-ту!

Тавышы еракка җитә:
Уу-уу-уу!
Уу-уу-уу!
Бик күп җирләрне үттек:
Чың-чың-чың!
Чың-чың-чың!
Станциягә җиттек:
Дың-дың-дың!
Дың-дың-дың!
Зур паровоз уфылдый:
Пуф-пуф-пуф!
Пуф-пуф-пуф!
Бүген нинди ардым, ди:
Уф-уф-уф!

# ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР

## Калач

*(Татар халык әкияте)*

Карт белән карчык булган, ди. Ашарларына бетеп киткән, ди. Карчык чыга да бура төпләреннән онны себереп ала. Себереп ала да Калач пешерә. Калачны пешерә дә тәрәзә төбенә куя, караса, ул тәрәзә төбеннән тәгәрәп төшә дә китеп бара.

Бара торгач, Калачка Бүре очрый.

— Син кая барасың, Калач, — ди Бүре, — минем карыным ач, сине ашыйм, — ди.

— Син мине ашама, — ди Калач, — мин сиңа җыр җырлыйм, — ди.

— Йә, җырыңны җырла, — ди Бүре. Калач җырларга тотына:

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Синнән качам да качам, —

ди. Шулай булгач, Бүре моны ашамый узып китә. Шулай барганда, Калачка Аю очрый. Аю да шулай ук әйтә:

— Минем карыным ач, мин сине ашыйм, — ди.

— Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм, — ди Калач.

— Йә, җырыңны җырла, — ди Аю. Калач җырларга тотына:

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Бүредән дә качтым мин,
Синнән качам да качам, —

дип, тагын такмаклый бу. Аюга да бу җыр бик кызык булып күренә. Бу да ашамый узып китә.

Тагын китә бу. Бара торгач, моңарга Төлке очрый. Төлке хәйләкәр була инде.

— Кая барасың, Калач агай? — ди Төлке.

— Барам әле, — ди Калач.

— Мин сине ашыйм хәзер, — ди Төлке.

— Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм, — ди Калач.
— Йә, җырлап кара, — ди Төлке.

Әбиемнән дә качтым мин,
Бабамнан да качтым мин,
Бүредән дә качтым мин,
Аюдан да качтым мин,
Синнән качам да качам, —

ди Калач.

— Ярар, алай булгач, чалкан ятып кара әле, — ди Төлке.

Калач чалкан яткан иде, Төлке моны ашый да китә. Шуның белән әкият тә бетә.

## Теремкәй

*(Рус халык әкияте)*

Басуда терем-теремкәй урнашкан була.

Бер тычкан-Чыелдык шул теремкәй янына чабып килгән дә:

— Терем-теремкәй, теремдә кем яши? — дип сораган.

Аңа җавап бирүче булмый. Тычкан теремкәй эченә керә дә шунда яши башлый.

Көннәрдән бер көнне теремкәй яныннан бака-Бакылдык үтеп бара икән, ул туктаган да сораган:

— Терем-теремкәй! Теремдә кем яши? — дигән.

— Мин, тычкан-Чыелдык. Ә син үзең кем буласың?

— Мин бака-Бакылдык булам.

— Әйдә, кер, бергә торырбыз.

Бака-Бакылдык теремкәй эченә сикереп кергән, шул көннән алар теремкәйдә икәү бергә яши башлаганнар.

Бервакыт теремкәй янына куян-Куркак җан-фәрманга чабып килгән. Ул да сораган:

— Терем-теремкәй! Теремкәйдә кем яши? — дигән.

— Мин, тычкан-Чыелдык.

— Мин, бака-Бакылдык. Ә син кем буласың?

— Мин куян-Куркаккай булам.
— Әйдә, алайса, кер. Бергә-бергә яшәрбез.

Куян теремкәй эченә бер сикерүдә кереп тә киткән. Хәзер инде болар өчәү торалар, ди.

Төлке-Хәйләбайның да юлы теремкәй яныннан узган. Ул да, теремкәй янына туктап, тәрәзәгә шакыган да сораган:

— Терем-теремкәй! Теремкәйдә кем яши? — дигән.
— Мин, тычкан-Чыелдык.
— Мин, бака-Бакылдык.
— Мин, куян-Куркаккай. Ә син үзең кем буласың?
— Мин төлке-Хәйләбай булам.
— Әйдә, кер, бергә яшәрбез.

Төлке-Хәйләбай да теремкәйгә кереп урнашкан. Алар инде дүртәүләп бергә яши башлаганнар.

Яшь бүре-Сорыколак, теремкәй яныннан чабып барганда, тәрәзәдән караган да сораган:

— Әй терем-теремкәй! Теремдә кем яши? — дигән.
— Мин, тычкан-Чыелдык.
— Мин, бака-Бакылдык.
— Мин, куян-Куркаккай.
— Мин, төлке-Хәйләбай. Ә син үзең кем буласың?
— Мин бүре-Сорыколак булам.
— Әйдә, кер безнең янга!

Бүре дә теремкәйгә керә. Шулай итеп, алар теремкәйдә бишәү җырлый-җырлый яши башлыйлар.

Көтмәгәндә, теремкәй янына, лап-лап атлап, аю-Камытаяк килеп чыга.

Ул теремкәй эчендә җырлаганны ишеткәч туктый да бөтен көченә акырып җибәрә:

— Терем-теремкәй! Теремдә кемнәр бар? — ди.
— Мин, тычкан-Чыелдык.
— Мин, бака-Бакылдык.
— Мин, куян-Куркаккай.
— Мин, төлке-Хәйләбай.
— Мин, бүре-Сорыколак. Ә син үзең кем буласың?

— Мин аю-Камытаяк булам.

— Кер, алайса, бергә яшәрбез!

Аю теремкәйгә керергә бик озак азаплана, әмма сыя алмый.

— Мин сезнең түбәгездә генә яшәрмен инде, алайса, — ди Камытаяк.

— Син безне сытарсың бит!

— Юк, сытмыйм,— ди.

— Мен, алайса! — диләр.

Аю теремкәйнең түбәсенә үрмәли. Менеп җитүе була — шарт!

Теремкәй сытыла, шатыр-шотыр килеп, бер якка авыша, бөтенләй таралып китә.

Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак өйдән көчкә чыгып өлгерәләр.

Нишләмәк кирәк, алар шундук, бергәләшеп, бүрәнә ташырга, такта ярырга, яңа теремкәй салырга керешәләр һәм искесеннән дә яхшырак теремкәй салып өлгертәләр. Тагын бергә яши башлыйлар.

## Йокы бабай

*(Әкият)*

Йокларга яратмый торган бер бала булган, ди. Кичен караңгы төшкәч, әннәсе яки әттәсе, бабакае яки әбекәе аны караватка утыртуга, теге бала:

— Мин ятмыйм! Мендәр бә-әк! Йокы бә-әк! Бә-әк! — дип акыра-бакыра елый башлый икән.

Ә бер кичне аның бу ямьсез сүзләрен ап-ак сакаллы Йокы бабай үзе ишетеп торган һәм, бии-ик тә үпкәләп, тиз-тиз китеп барган.

Төн җиткән, ә берәү дә йоклый алмый икән. Мәчеләр мырылдаган. Кетәктәге әтәч-тавыклар, ишегалдына чыгып, арлы-бирле йөгерешә башлаган. Сарайдагы сыерлар өзлексез

мөгрәгән, ә атлар тибенә-тибенә кешнәгән. Дуңгызларның мыркылдавына хәтта трактор да чыдап тора алмаган: «Тыр-тыр-р-р...» — дип тыр-пыр килгән.

Йоклый алмый интеккән кешеләр, колак тондыргыч әлеге шау-шудан котылыр өчен, башларын мендәр астына тыкканнар. Моны күреп, теге бала да, үзенең йомшак мамык мендәрен кочаклап:

— Нәнәм... Йокы нәнәм... Нәннә! — дип әйтүен дә сизми калган.

Йокы бабай аның бу акыллы сүзен шундук ишетеп алган. Тылсымлы таягын нәзакәтле генә бер селтәп куюга, барча балалар, ә аннан соң әти-әниләр, әби-бабайлар, кош-кортлар һәм хайваннар иртәгесе көнгә кадәр тәмле йокыга чумганнар, ди.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Карлар ява

Тышта ап-ак кар ява. Агач ботакларына мамыктай йомшак бәс куна. Бакча аеруча ямьләнеп киткән.

Илгизәргә бу күренеш бик ошады. Ул, чанасын алып, урамга чыкты. Алар, күрше малайлары белән бергәләп, бакча артындагы куаклыкта туйганчы уйнадылар. Йомшак карны тәгәрәтеп, шар ясадылар. Ап-ак шар тәгәрәгән саен калыная, зурая барды. Балалар куандылар:

— Ай-яй, нинди матур булды!

— Әйдә, тагын тәгәрәтик әле!

— Әйдә, әйдә!

Балалар кардан ак аю һәм Кар бабай сыны ясап куйдылар. Аларның шатлыгы тагы да арта:

— Кулына таяк тоттырыйк!

— Күзенә күмер куйыйк!

— Борын да ясыйк! Борыны кып-кызыл булсын!

Балалар шулай эшләделәр дә. Берсе өйдән кишер алып чыкты. Шуннан Кар бабайга борын ясап куйдылар. Аннан соң үзләре читтән карап, рәхәтләнеп көлештеләр.

*Госман Бакир*

## Кар бабай

Көн җепшек иде. Балалар Кар бабай ясарга керештеләр. Кечкенә Ира да булышты. Ул өйдән кишер алып чыкты. Аны борын итеп куйдылар. Айдар күзләренә күмер ябыштырды. Кар бабайның кулына себерке тоттырдылар. Көлкеле килеп чыкты Кар бабай.

Кич булды, караңгы төште. Балалар өйгә кайтып киттеләр. Бары тик Ира гына китмәде. Ул Кар бабайны кызганды.

— Берүзе калгач куркыр, — дип уйлады ул.

Ира кардан эт баласы ясады.

— Икәү булгач курыкмаслар, — диде дә Ира өенә кереп китте.

*Светлана Летовадан*

## Нурбәк әкияте

Ике яшьлек Нурбәк әтисенә әйтә:

— Әти! Бака күрәсем килә, ди. Бака кайда тора ул?

Әтисе Нурбәккә әйтә:

— Бака су буенда була ул,— ди.

— Су буена барыйк, — ди Нурбәк.

Әтисе белән Нурбәк су буена төшеп барганда, аларга тыкрык башында бер оя Каз очрады.

— Ка-как-ка-ка-ка-как, — ди Казлар.

— Әти, Казлар ни әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Нурбәк, кая барасың?» — дип сорыйлар Казлар, — ди әтисе.

— Бака карарга барам,— ди Нурбәк.

— Ка-ка-ка-как, Бакага бездән сәлам әйт! — диләр Казлар.

Тыкрык уртасына җиткәч, Нурбәк белән әтисенә Бозау очрады.

— Му-у-у! — ди Бозау.

— Әти, Бозау ни әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Ну-ур-бә-әк, кая барасы-ың?» — дип сорый Бозау.

— Су буена, Бака карарга-а! — ди Нурбәк.

— Бакага миннән сәлам ә-әйт! — ди Бозау.

Нурбәк белән әтисе су буена төшеп җитте. Су буенда, сөзәк ярда бик матур, ямь-яшел бер Бака утыра. Үзенчә сайрап утыра.

— Курыйк-курыйк, бака-ка, курыйк-курыйк, бака-ка!

— Әти, Бака нәрсә әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Исән-саумы, Нурбәк!» — дип сорый Бака,— ди әтисе.

— Исәнме, Бака! — ди Нурбәк.— Бака-бака, Бакакай, Казлар сиңа сәлам әйтте.

— Бик рәхмәт, Нурбәк, — ди Бака.— Үзең дә Казларга миннән сәлам әйт.

— Бозау да сиңа сәлам әйтте, — ди Нурбәк.

— Бик рәхмәт, бик рәхмәт, — ди Бака.— Миннән дә Бозауга сәлам әйт.

Нурбәк белән әтисе Бака белән саубуллашып кайтып китә. Кайта торгач, алар Бозау янына җитә.

— Бозау, яшел Бака сиңа сәлам әйтте! — ди Нурбәк.

— Рәхмә-әт, — ди Бозау.

Казлар янына җиткәч, Нурбәк:

— Казлар, яшел Бака сезгә сәлам әйтте, — ди.

— Ка-как-ка-как, рәхмәт, — диләр Казлар.

*Батулла*

## Варя белән Песнәк

Варя исемле бер кызның Песнәге булган. Аның Песнәге читлектә яшәгән. Песнәк бер дә сайрамый икән. Көннәрдән бер көнне Варя читлек янына килгән дә: «Песнәк, бер генә сайрап күрсәт инде», — дигән.

Песнәк Варяга: «Син мине иреккә чыгар, иректә мин сайрармын», — дигән.

*Лев Толстойдан*

## Казлар

Хуҗа хатын чыкты да казларны йортка чакыра башлады:

— Дегә-дегә-дегәшкәй! Ак казлар, соры казлар, өйгә кайтыгыз!

Ә казлар озын муеннарын суздылар, кызыл тәпиләрен тырпайттылар, канатларын кактылар, авызларын ачтылар:

— Га-га-га! Өйгә кайтасыбыз килми безнең! Безгә монда да яхшы!

Хуҗа хатын, казларны яхшылык белән күндереп булмаганны күргәч, кулына озын тал чыбыгы алды да аларны куып алып кайтты.

*Константин Ушинский*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Әтәч

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!
Йә сузып кына,
Йә бик еш кына,
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!
Бакчага килдек,
Ашыга-ашыга:
— Кикрикүк,
Кикрикүк!

*Муса Җәлил*

## Лап-лап

Лап-лап, лап-лап,
аю килә атлап.
Бөтен төше тузан,
чәче-башы тузган.
Аюга ни булган?
Аюга ни булган?
Берни дә булмаган —
куян туп уйнаган,
тупка каты типкән,
туп очкан да киткән,
төшкән ул чокырга,
чокырда чытырман.
Аю тупны күргән,
алып менеп биргән.

*Ренат Харис*

## Чәбәк-чәбәк

Чәбәк-чәбәк-чәбәк,
күрдек алтын чабак.
Алтын чабак кайда?
Тыпырчына сайда.

Аны сайдан алдык,
тирән суга салдык.
Әй шатлана чабак —
чәбәк-чәбәк-чәбәк.

*Ренат Харис*

## Ул зу-у-у-ур үскән

— Кем утырткан бу гөлләрне,
Кем су сипкән?
— Ләлә утырткан, Ләлә су сипкән,
Ул зу-у-у-ур үскән.

*Зәкия Туфайлова*

## Туп-туп тубыбыз

Туп-туп тубыбыз,
Син — безнең матурыбыз,
Тишмәбез дә югалтмабыз,
Оста тота кулыбыз.

Рөстәм, сиңа да бирәбез,
Әйдә, уйныйбыз бергә,
Кирәк аны, чөеп-чөеп,
Тотып ала белергә.

Туп сикерә, син дә сикер,
Тыпыр-тыпыр тыпырда,
Дуслар белән уйна бергә,
Читтә генә утырма.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Аюым

Йом күзеңне,
Аюым,
Көтмә кояш
Баюын.
Әлли-бәлли
Бәлли-бәү,
Йом күзеңне,
Аюым.

Һаман ачык
Күзләрең,
Ник йоммыйсың
Үзләрен?
Әлли-бәү,
Бәлли-бәү,
Һаман ачык
Күзләрең.

Тыңламыйсың
Сүзләрем,
Күзлисең
Күк йөзләрен.
Җырлый-җырлый
Әлли-бәү
Йомылган
Үз күзләрем...

*Җәүдәт Дәрзаман*

## Беренче адым

Камил әле бик кечкенә,
Үрмәләп йөри инде,
Ә ёлкага бүген менә
Ул тәпи-тәпи килде.

Бүлмәсеннән залга хәтле
Килде берүзе генә,
Ул үзе дә бик куанды,
Куандырды безне дә.

— Әттәтә, әттәтә,
Камил йөри башлаган,
Яңа елны тәпи басып,
Зур үсеп каршылаган.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Бәлли-бәү

Әлли-бәлли-бәлли-бәү...
Куян кечтек, аю дәү!

Аюның бар юрганы,
ап-ак кардан сырганы.

Әлли-бәлли-бәлли-бәү...
Юрган җылы, юрган дәү!

Юрган астына сыя
Аю, Төлке һәм Куян.

Аю җылы, юрган дәү...
Әлли-бәлли-бәлли-бәү!

*Ренат Харис*

## Гөлдергү

Гөлдер, гөлдер, гөлдергү…
Күк күгәрчен көе бу.
Әнкәең дә, әткәең дә
Сөя сине, бәбкәем.
Гөлдер, гөлдер, гөлдергү…
Күк күгәрчен көе бу.
Күзләрең дә йомыла,
Күңелеңә нур тула.
Гөлдер, гөлдер, гөлдергү…
Күк күгәрчен көе бу.
Татлы төшең тәмләнсен,
Әкияткә әйләнсен.

*Нәкыйп Каштан*

## Син — минем нәнием

Син — минем нәнием,
Табигать җимеше.
Син — минем җирдәге
Йөрәгем тибеше.
Синдә ул кояшның
Яктысы, нурлары.
Син булсаң ямьләнә,
Яшәрә Җир шары.

Яңгырның шифасы,
Җылысы син, балам.
Җиремә гомерлек
Җыр булып кил, балам.
Күлләрдәй серле ул
Күзләрең карасы.
Күзеңә төбәлгән
Туган ил карашы.

*Эльмира Шәрифуллина*

## Йоклар алдыннан

... Көн киткән дә, төн җиткән,
Кояш йокыга киткән.
Аңа комачаулама,
Йокла, улым, шаулама!

Көлсәң, ашаган чакта,
Үсәлмәссең ашап та.
Еласаң, йоклар чакта,
Ошарсың ябалакка!

*Нурия Измайлова*

## Су

— Менә сиңа су,
Бит-кулыңны ю,
Ю, ю, ю, ю, ю!
— Туңдыра ич,
Салкын ич бу су.

— Ай-ай, ай, ай, ай!
Туңдырса да ю,
Әйбәт салкын су,
Ю, ю, ю, ю, ю!

*Бари Рәхмәт*

## Ике

Ике аягы Әнвәрнең,
Ике кулы.
Берсе кече, берсе олы
Ике тубы.
Ике колагы бар тагын,
Ике күзе.
Һич теленнән төшми торган
Ике сүзе:

— Әни, әти! —
Бар белгәне ике булды.
Аның үзенә дә инде
Ике тулды.

*Сажидә Сөләйманова*

## Йокла, курчак

Йокла, курчак, нәни курчак,
Йокласаң ял итәрсең.
Әлли-бәлли итәрсең.
Таза булып, матур булып,
Курчагым, зур үсәрсең.

Әлли-бәлли, бәү-бәү,
Нәни курчак, тыныч ят,

Мин дә йоклыйм, ял итәм,
Әлли-бәлли, бәү итәм.
Йоклап туйгач, таза булып,
Матур булып, зур үсәм.
Әлли-бәлли, бәү-бәү.

*Гыйльмия Таһирова*

## Гали белән кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

*Габдулла Тукай*

## Мыраубикә

Мыраубикә кызык та соң:
Мыр-мыр-мыр итә-итә,
Әбиемнең итәгендә
Гыр-гыр-гыр йоклап китә.

*Дамир Гарифуллин*

## Маэмай

Тешләмәсен Акбаем,
Сезгә өрә маэмаем:
«Ташлар ыргытмагыз, — ди, —
Мине котыртмагыз», — ди.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Кикрикүк

Күктә сүнде йолдызлар,
Уянды үрдәк-казлар,
Торсын малайлар, кызлар!
Кик-ри-кү-үк!
Кик-ри-кү-үк!

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Әтәчем

Әтәчем! Әтәчем!
Ник иртә ятасың?
Йокыдан син безне
Иртүк уятасың.

Торасың да иртүк,
Кычкырасың бик күп:
Кикри-күк, кикри-күк,
Кикри-күк, кикри-күк!

*Бари Рәхмәт*

## Чебиләр

Акыллы кыз Гөлфия
Чебиләрне бик сөя:
Әнисе эштә чагында
Ул аларга җим сибә.

Их чебиләр, чебиләр!
Һич тынычлык бирмиләр:
Гөлфиянең кул астында
Черелдәшеп йөриләр.

*Әнәс Кари*

## Тавык

Кытаклап чыкты тавык,
Кытаклый ул, мактанып.
Нәрсәгә бик шатланган?
Чөнки ул күкәй салган.
«Әби килеп алсын, — ди, —
Балалар куансын», — ди.

*Әнәс Кари*

## Кызыл Әтәч

Кызыл Әтәч
Торган иртүк.
Кычкырадыр:
— Кикрикүк!
Кикрикүк!
Торыйк иртүк —
Эшләр бик күп!

Гөлшат елап ятмасын,
Япсын елак капкасын.
Күз яшьләре тиз кипсен,
Тавыкларга җим сипсен.

*Саҗидә Сөләйманова*

## Безнең сыер

Безнең сыер өебезне яхшы белә,
Көтүдән ул мөгри-мөгри кайтып керә.
Әйтерсең лә: «Мине каршы алыгыз! — ди, —
Мул итеп сөт алып кайттым, савыгыз!» — ди.

*Әнәс Кари*

## Маэмай

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...

*Муса Җәлил*

## Йә, алар кемнәр икән?

Тезелешеп кайталар,
«Бак-бак-бак» дип әйтәләр.
— Йә, алар кемнәр икән?
— Алар үрдәкләр икән.
Сикерешеп уйныйлар,
Мәэлдәшеп туймыйлар.
— Йә, алар кемнәр икән?
— Алар бәрәннәр икән.
Юлны күктән сузалар,
Каркылдашып узалар.
— Йә, алар кемнәр икән?
— Алар каргалар икән.

*Дамир Гарифуллин*

## Яңгыр

— Яңгыр, нигә явасың,
Чәчләремә тамасың?
Көне буе яварга
Суны каян табасың?

*Вәсимә Хәйруллина*

## Беренче кар

Йомшак кына кар яуды,
Бөтен җирне каплады.
Ап-ак булды болыннар,
Ап-ак булды киң кырлар.

*Әхмәт Ерикәй*

## Яз

Туктап сана,
Тамчы тама:
Тып, тып, тып.

Төшә-төшә,
Бозны тишә:
Тып, тып, тып.

Яз бу, ишет,
Кага ишек:
Тып, тып, тып.

*Шәүкәт Галиев*

## Кәккүк

Яз килә. Кояш
Елмаеп тора.
Урман яңгыратып,
Кәккүк кычкыра:
Күк-кү, күк-кү,
Күк-кү, күк-кү.

*Әнәс Кари*

# «ҮСӘ-ҮСӘ ЗУР БУЛАМ...»

3–4 яшьлек балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Җырлар, такмаклар, эндәшләр

* Әлли-бәлли итәрсең,
Тыныч йоклап китәрсең.
Шулай тыныч йокласаң,
Бик тиз үсеп җитәрсең.

* Минем кызым бик иркә,
Башларында кәсинкә,
Аягында бәтинкә,
Күлмәге дә сәрпинкә,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле —
Коеп куйган кәртинкә.

* Әй Зөбәйдә, Зөбәйдә,
Бии-бии үс, әйдә,
Үсеп җит тә гүзәл җәйдә
Гөлләргә су сип, әйдә.

* Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Келәткә кермә, бал ашама;
Базга төшмә, май ашама,
Пресс, пресс, пресс!

* Тилгән, тилгән!
Бәбкә алырга килгән!
Бер аягы камырдан,
Бер аягы тимердән,
Кө-ш-ш-ш!..

* Минем кызым дәү кебек,
Бакчадагы гөл кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.

* Әтисе дә ярата,
Әнисе дә ярата,
Апалары, абыйлары —
Барысы да ярата.

* Там, там, тамчы, там,
Тамганыңны яратам.
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам.

* Суы сарыксын,
Үзе калыксын,
Тигез канатлы булсын,
Озын гомерле булсын,
Игелекле, шәфкатьле
булсын.

* Көзгегә карыйм әле,
Чәчемне тарыйм әле,
Әбиләргә бер атнага
Кунакка барыйм әле.

* Гөлдергү, гөлдергү,
Бигрәк чибәр, кемдер бу?
Тарап куйган чәчләре,
Өсте-башы бик ару.
Гөлдергү, гөлдергү,
Бик әдәпле кыздыр бу,
Мәктәп дигән бакчада
Чәчәктер бу, гөлдер бу!

* Чәбәк-чәбәк әткәсе,
Биетеп тора әнкәсе,
Такмак әйтә апасы,
Өзелеп тора тәтәсе,
Авызын-күзен
мимылдатып
Карап тора әбкәсе.

**Бармак уеннары**

*Бармак уенарында һәр бармакка исем кушыла. Чәнти бармак — баланың үз роле.*

* — Бармак, бармак,
Кайда булдың?
— Бу абый белән
Урманга бардым.
Бу абый белән
Кырда йөгердем.
Бу абый белән
Ботка ашадым.
Бу энем белән
Җыр җырладым.

* Олыга — утын ярырга,
Ә сиңа — чыгып алырга,
Уртага — мичкә ягарга,
Ә сиңа — казан асарга,
Чәнтигә — җырлый башларга,
Дусларның күңелен ачарга.

## ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР

### Аю белән Бабай

*(Татар халык әкияте)*

Борын заманда Аю белән Бабай яшәгән. Алар икәүләп шалкан чәчкәннәр. Шалкан бик мул булган, уңган.

Бабай Аюдан:

— Син шалканның кай җирен аласың: тамырынмы, яфрагынмы? — дип сораган.

Аю хайваннарның яфракны яратып ашаганнарын күргән дә яфракка кызыккан.

— Мин шалканның яфрагын алам! — дигән һәм яфрагын алган. Бабайга шалканы калган.

Икенче елны Аю белән Бабай бодай чәчкәннәр. Быел инде Бабайдан алдатмам, дип уйлаган Аю.

— Мин быел тамырын алам, ә син сабагын ал! — дигән ул Бабайга.

Бабай бодайны урып алган, ә Аюга камылы калган.

### Кыз һәм икмәк

Бер авылда Гөлназ исемле кыз яшәгән, ди. Бер начар гадәте булган аның: ул көйсезләнергә ярата икән. Бервакыт әбисе аны өстәл янына аш ашарга чакырган. Тәлинкә янына бер телем арыш ипие куйган. Шунда Гөлназ: «Мин сезнең бу ипиегезне ашамыйм, үзегез ашагыз, миңа конфет бирегез»,— дип киреләнә башлаган.

Шулвакыт бөтен өйне дер селкетеп, тәрәзә янына Трактор килеп туктаган:

— Мин басуны сөрдем, тырмаладым, орлык чәчтем. Ашлык куе, биек булып үсте, башаклар алтын-сары төскә керде. Ипи кирәкми дигәне өчен, Гөлназга мин бик ачулы! — дигән.

Аның артыннан Комбайн килеп кергән:

— Күрсәтегез әле миңа ул ипи яратмаган Гөлназ исемле кызны! Мин юкка гына ашлыкны урдым, суктыммы? Көннәр, төннәр буе басудан кайтмадым,— дип ачуланган.

Өй янына, тырылдап, Йөк машинасы якынлашкан һәм яңгыратып кычкырып җибәргән:

— Мин дә ипи яратмаган Гөлназ турында ишеттем, бик үпкәләдем. Без шофёр белән, ару-талуны белмичә, ашлыкны амбарга ташыдык. Бер дә юкка тырышканбыз икән!

Тәрәзә артында шакылдаган, гүләгән, шыгырдаган тавышлар килгән, өй дер селкенгән. Канатларын әйләндереп, Тегермән ашыгып килеп туктаган.

— Монда ничек шауламаска, ачуланмаска! Мин бер файдасызга ашлыктан он ясадыммы? Ә Гөлназ ипигә карамый да!

Мич тә капкачларын шалтыраткан:

— Мин дә аз эшләмәдем. Гөлназ өчен кабарып торган ипи пешердем, — дигән.

Әбисе, аңа шелтәле карап:

— Күрдеңме, кызым, сиңа өстәл өстендә ипи булсын өчен, барысы да күпме эш эшләгәннәр, тырышканнар,— дигән.

Гөлназга бик оят булган. Ул өстәл янына килгән дә:

— Әби, миңа аш ашарга ипи бирче,— дип пышылдаган.

Ашны ипи белән ялт итеп ашап та бетергән. Аннан соң ишегалдына чыккан. Трактор йөртүчегә, шофёрга, тегермәнчегә, комбайнчыга һәм әбисенә:

— Бик зур рәхмәт! Ипи бик тәмле! — дигән.

*Балалар матбугатыннан*

## Аю белән хатын

*(Татар халык әкияте)*

Әүвәлге заманда бер Хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ура башлагач ук, аның янына бер Аю килгән. Ул Аюның аягына шырпы кадалган икән, ди. Ул Хатынга аягын

күрсәтергә килгән булган. Хатын аның аягыннан шырпысын алган. Шуның өчен Аю Хатынга бер мичкә бал китереп биргән, ди.

## Мәче белән Аю

*(Татар халык әкияте)*

Бер Аю имән башына бал куйган икән. Аны Мәче сизгән дә имән башына менгән. Мәче бал ашап торган чакта, Аю килгән дә:

— Монда нишлисең? — дигән.

Мәче әйткән:

— Менә аюларны, бүреләрне зоопаркка җыярга килдем, — дигән.

Аю, бу сүзләрне ишеткәч, имән башыннан төшкән дә качкан. Мәче дә, Аюдан куркып, икенче якка йөгергән.

## Кем нәрсә ярата?

*(Татар халык әкияте)*

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» —дип бәхәсләшәләр икән.

— Иң тәмле сый — сөт, — ди Песи.— Сөттән соң бер Тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик Тычканны тотуы кыен.

— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң — менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.

— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай.— Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син? — дип каршы килә Кәҗә.— Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә! — ди ул.

Алар бәхәсләшәләр икән — әле һаман килешә алганнары юк, ди.

## Төлке белән Каз

*(Татар халык әкияте)*

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

— Каз, мин сине ашыйм! — дигән.

Каз боегып калган.

— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит, — дигән Каз.

— Әйдә, бие, — дигән Төлке. — Ашарга өлгерермен әле.

Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган.

Төлке:

— Әй оста биисең, Каз! — дип көлә икән.

Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очып киткән. Төлке авызын ачып калган.

## Төлке, Куян һәм Әтәч

*(Рус халык әкияте)*

Булган, ди, Төлке белән Куян. Төлке боздан, Куян кайрыдан өй салганнар.

Матур яз җиткән. Төлкенең өе эрегән дә аккан, ә Куянның өе һаман шул килеш калган.

Менә Төлке кунып чыгарга Куяннан рөхсәт сораган. Ә соңыннан Куянның үзен куып чыгарган. Куян елый-елый бара икән. Аңа Эт очраган:

— Һау-һау-һау! Куян, нигә елыйсың? — дигән аңа Эт.

— Нигә еламаска?! Минем өем кайрыдан, Төлкенең өе боздан салынган иде.Төлке миннән кунып чыгарга гына

рөхсәт сораган иде, соңыннан үземне куып чыгарды, — дигән Куян.

— Елама, Куян! Мин аны куып чыгарырмын, — дигән Эт.

Алар өй янына килгәннәр. Эт өрә башлаган:

— Һау-һау-һау! Төлке, чык, бар кит!

Ә Төлке аларга мич башыннан:

— Балта кайрыйм, пычак кайрыйм, сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын,— дигән.

Эт курыккан да чыгып качкан.

Куян, елый-елый, тагын юл буйлап китеп барган. Аңа Аю очраган һәм әйткән:

— Нигә елыйсың, Куян?

— Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, Төлкенең өе боздан салынган иде. Төлке миннән кунып чыгарга гына рөхсәт сорады, соңыннан үземне куып чыгарды, — дигән Куян.

— Елама, Куян, — дигән Аю, — мин аны куып чыгарырмын.

— Юк, куа алмассың шул! Эт барган иде — куып чыгара алмады, син дә куа алмассың, — дигән Куян.

— Юк, куармын! — дигән Аю.

Аю белән Куян кайры өйгә киткәннәр.

— Төлке, бар чыгып кит! — дип акырып җибәргән Аю.

Ә Төлке аларга мич башыннан:

— Мич башында балта кайрыйм, пычак кайрыйм, сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын! — ди икән.

Аю курыккан да китеп барган.

Куян, елый-елый, тагын киткән. Юлда аңа Үгез очраган.

— Нигә елыйсың, Куян? — дигән Үгез.

— Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, Төлкенең өе боздан салынган иде. Төлке миннән кунып чыгарга гына рөхсәт сораган иде, соңыннан үземне куып чыгарды,— дигән Куян.

— Әйдә, Куян, киттек, мин аны куып чыгарырмын,— дигән Үгез.

— Юк, Үгез, куа алмассың. Эт куды — чыгара алмады, Аю куды — чыгара алмады, син дә куып чыгара алмассың,— дигән Куян.

— Юк, куармын! — дигән Үгез.

Алар өй янына килгәннәр. Үгез үкереп җибәргән:

— Бар, Төлке, чыгып кит! — дигән.

Ә Төлке аларга мич башыннан:

— Мич башында балта кайрыйм, пычак кайрыйм, сикереп төшәрмен дә өзгәләп ташлармын! — дигән.

Үгез курыккан да йөгереп качып киткән. Куян, елый-елый, тагын киткән, элеккедән дә каты елый икән бу. Аңа җилкәсенә чалгы салган Әтәч очраган.

— Кикри-күк! Нигә елыйсың, Куян? — дигән Әтәч.

— Ничек еламаска?! Минем өем кайрыдан, Төлкенең өе боздан салынган иде. Төлке миннән кунып чыгарга гына рөхсәт сораган иде, соңыннан үземне куып чыгарды,— дигән Куян.

— Әйдә, киттек, мин аны куып чыгарырмын,— дигән Әтәч.

— Юк, Әтәч, куа алмассың! Эт барды — куа алмады, Аю барды — куа алмады, Үгез куды — куа алмады, син дә куа алмассың,— дигән Куян.

— Юк, куармын! — дигән Әтәч.

Алар өй янына барып җиткәннәр. Әтәч тәпиләре белән тибенгән, канатлары белән кагынган:

Кикри-кү-ү-к!
Җилкәмдә чалгы күтәрәм,
Төлкене чабып үтерәм!
Тиз төш, Төлке, мич башыннан,
Хәзер үк чыгып кит моннан! —

дигән Әтәч.

Төлке, моны ишеткәч, бик курыккан һәм:

— Хәзер, аягыма гына киям...— дигән.

Кикри-кү-ү-к!
Җилкәмдә чалгы күтәрәм,
Төлкене чабып үтерәм!

Тиз төш, Төлке, мич башыннан,
Хәзер үк чыгып кит моннан! —

дип, тагын да ныграк кычкырган Әтәч.

— Тунымны гына киям,— дигән Төлке.

Әтәч өченче тапкыр кычкырган:

Кикри-күү-к!
Җилкәмдә чалгы күтәрәм,
Төлкене чабып үтерәм!
Тиз төш, Төлке, мич башыннан,
Хәзер үк чыгып кит моннан!

Төлке өйдән чыгып качкан. Әтәч белән Куян өйдә бергә рәхәт-рәхәт тора башлаганнар. Әле дә булса торалар, ди, алар.

## Өч аю

Бер кыз, өйләреннән чыгып, урманга киткән. Урманда ул адашкан һәм кайтырга юл эзли башлаган. Ләкин таба алмаган. Урмандагы кечкенә генә бер өй янына килеп чыккан.

Өйнең ишеге ачык була. Кыз ишектән карый да, беркем дә юклыгын күргәч, эчкә керә.

Бу кечкенә өйдә өч аю яши икән. Аларның берсе — әтиләре, аны Михаил Иванович дип атаганнар. Ул тузгыган йонлы бик зур аю булган. Икенчесе — әниләре. Ул буйга бераз кечерәк. Аны Настасия Петровна дип йөрткәннәр. Өченчесе — кечкенә генә бер аю баласы. Аңа Мишутка дип дәшкәннәр. Аюлар өйдә юк икән, алар урманга йөрергә чыгып киткәннәр.

Бу кечкенә өйдә ике бүлмә булган: берсе — ашханә, икенчесе — йокы бүлмәсе. Кыз, аш бүлмәсенә кергәч, өстәлдә аш салынган өч савыт күрә. Беренчесе — бик зур савыт, Михаил Ивановичныкы. Икенчесе — кечерәк савыт, Настасия Петровнаныкы. Өченчесе — зәңгәрсу савыт, Мишутканыкы. Һәрбер савыт янында берәр кашык яткан: берсе зур, икенчесе уртача, өченчесе кечкенә.

Кыз башта иң зур кашыкны алган һәм иң зур савыттан ашап караган; аннан соң, уртача кашыкны алып, уртача савыттан ашап караган; соңыннан кечкенә кашыкны алган һәм зәңгәрсу савыттан ашап караган. Аңа Мишутканың ашы барысыннан да тәмлерәк булып тоелган.

Кызның утырасы килгән, һәм ул өстәл янында торган өч урындык күргән: берсе зур — Михаил Ивановичныкы, икенчесе кечерәк — Настасия Петровнаныкы, өченчесе кечкенә, анысы — Мишутканыкы. Кыз элек зур урындыкка менгән һәм аннан егылып төшкән; аннары уртача урындыкка утырып караган, анда җайсыз булган; аннары ул кечкенә урындыкка күчеп утырган. Һәм монда утыру шундый җайлы икән — кыз көлеп җибәргән. Ул зәңгәр савытны тез өстенә алып куйган да ашарга тотынган. Ашны бөтенләй ашап бетергән дә урындыкта утырган көйгә тирбәлә башлаган.

Урындык ватылып киткән, һәм кыз идәнгә егылып төшкән. Ул егылган урыныннан торган, урындыкны күтәреп куйган һәм икенче бүлмәгә кереп киткән. Анда өч карават тора икән: аның берсе зур — Михаил Ивановичныкы, икенчесе уртача — Настасия Петровнаныкы, өченчесе кечкенә — Мишутканыкы. Кыз башта зурысына ятып караган, ул артык киң булган; уртанчысына ятып караган, монысы артык биек икән; кечкенәсенә ятуы була һәм шунда ук йокыга китә.

Аюлар өйгә ачыгып кайтканнар һәм ашарга утырганнар.

Зур аю, үз савытын алып карагач, куркыныч тавыш белән үкереп җибәргән:

— Минем савытымнан кем ашаган?

Настасия Петровна, үз савытына карагач, йомшаграк тавыш белән:

— Минем савытымнан кем ашаган? — дип кычкырган.

Ә Мишутка, үзенең буш савытын күргәч, нечкә тавыш белән:

— Минем ашымны кем ашап бетергән? — дип чинаган.

Михаил Иванович үзенең урындыгына караган да куркыныч тавыш белән үкергән:

— Минем урындыкка кем утырган, аны урыныннан кем кузгаткан?

Настасия Петровна урындыгына күз төшергән дә, йомшак тавыш белән:

— Минем урындыкка кем утырган, аны урыныннан кем кузгаткан? — дип кычкырган.

Мишутка, үзенең ватык урындыгын күреп:

— Минем урындыкка кем утырган, кем аны ваткан? — дип чинаган.

Аюлар икенче бүлмәгә кергәннәр.

Михаил Иванович куркыныч тавыш белән үкергән:

— Минем урынга кем яткан, кем аны изгән?

Настасия Петровна, йомшаграк тавыш белән:

— Минем урынга кем яткан, аны кем изгән? — дип кычкырган.

Ә Мишутка, аяк астына кечкенә эскәмия куеп, караватына менгән дә нечкә генә тавыш белән чинап җибәргән:

— Минем урында кем ята?

Ул анда яткан кызны кинәт күреп алган һәм чыелдый башлаган:

— Менә ул! Тот, тот!

— Менә ул! Менә ул! Ай-ай! Тот!

Ул кызны тешләргә теләгән. Кыз, күзләрен ачып җибәрүгә, аюларны күргән һәм тәрәзәгә ташланган. Тәрәзә ачык булган. Кыз тәрәзәдән сикереп төшкән дә урман буйлап йөгергән. Аюлар аны куып җитә алмаганнар.

*Лев Толстойдан*

## Кызыл калфак

*(Әкияттән өзек)*

Борын-борын заманда бер авылда кечкенә генә бер кыз яшәгән. Бу кыз шундый матур икән, аңардан да матуррак кыз бөтен дөньяда булмаган. Анасы кызын үлеп яраткан, ә әбисе аны тагын да ныграк яраткан.

Әбисе кызга туган көнендә бик матур кызыл калфак бүләк иткән. Шул көннән башлап, ул бөтен җиргә яңа, матур кызыл калфагын киеп йөри башлаган. Күршеләре, аны күргәндә:

— Әнә Кызыл калфак килә! — диешәләр икән.

Беркөнне шулай бу кызның әнисе бәлеш пешергән дә:

— Кызыл калфаккаем, бар, әбиең янына барып кайт. Менә шушы бәлеш белән бер чүлмәк майны илтеп бир, хәлен дә белеп кайтырсың, авырып ятмыймы икән? — дигән.

Кызыл калфак җыенган да әбисенә дип, икенче авылга чыгып киткән…

*Шарль Перро*

## Рөстәм

Беркөн мин улым Рөстәм белән әбиләрдә кунакта булдым. Самовар, җырлый-җырлый, өстәлгә килеп басты. Самовар артыннан ит сумсалары, алма, карбызлар, конфетлар килеп тулдылар өстәлгә. Алмалары: «Мине ал, мине ал!»; конфетлары: «Кулыңны суз! Ах, тәмле без, ах, тәмле!»; карбызлары: «Ал-кызыл без! Ал-кызыл! Кап авызыңа, эрербез», — диешә сыман, алдыбызда кызыктырып яталар.

Рөстәм кулын сузарга ашыкмады. Башта миңа карады ул. Аннан әбисенә карады.

Әбисе аның тәлинкәсенә өч сумса салды. Мин бер алма алып бирдем. Апасы аның алдына конфет, бер телем карбыз куйды.

Улым үзен бик әдәпле тотты. Ашыкмый гына ашады, авызын чапылдатмады. Ашъяулыкка карбыз суын агызмады.

*Дәрҗия Аппакова*

## Сания инде зур үсте...
*(Өзек)*

Сания әле бик кечкенә, ләкин аның дәү үсәсе килә. Әнисе аңа: «Син зур булдың инде, уенчыкларыңны ватма», — ди. Кая әле аңа зур булырга! Өстәл биеклеге дә юк ич, өстәл астыннан ул башын имичә дә үтеп чыга. «Кайчан дәү үсәрмен икән, кайчан өстәл өстендәге әйберләрне күрә алырмын икән?» — ди торгандыр инде ул.

Кайчакта Сания әнисе белән күрше кибеткә керә. Кибеттән чыкканда, әнисенең сумкасы әйбер белән тулы була. «Әни, мин дәү үстем инде, сумканы үзем күтәрим, миңа бир!» — ди ул. Кая әле аңа сумка күтәрергә! Ул үзе дә сумка хәтле генә диярлек! Шулай да әнисе: «Әйдә, алайса, икәү күтәреп барыйк!» — ди. Сумканы икәү күтәрәләр. Билгеле инде, ул әле сумканы күтәреп бара алмый, тик әнисе күтәргән сумкага асылынып кына бара. Урамдагы кешеләр, моны күреп:

— Ай-яй, нинди зур үскән бу кыз! Әнисенә ничек булыша! — дигән шикелле елмаеп калалар.

*Госман Бакир*

## Бәби әйтә

Иртәгә Яңа ел дигән көн иде. Айгөл исемле кечкенә кыз үзенең әнисе белән бергә Яңа елны күңелле итеп каршы алырга әзерләнә. Менә аның әнисе, Айгөл белән бергәләп, идән уртасына зур итеп чыршы әзерли. Яңа елда Айгөл янына үзе кебек кечкенә кунаклар киләчәк. Әй кызык булыр! Алар шул чыршы әйләнәсендә биерләр, җырларлар, белгән шигырьләрен сөйләрләр. Ә соңыннан чыршыга эленгән бүләкләрне алырлар. Әй кызык булыр!

Айгөл шуларны уйлап, кычкырып көлеп җибәрде. Зур бүлмәнең бер почмагында торган тәгәрмәчле карават өстендә кечкенә бәбиләре йоклап ята иде. Айгөл кычкырып көлгән тавышка бәби уянды. Әнисе әйтте Айгөлгә:

— Айгөл, кызым, тавышланмыйча гына, бәбине селкет әле, тагын әзрәк йокласын. Минем эшем бар.

Айгөл тәгәрмәчле караватны бер алга, бер артка йөртә башлады. Ә бәби йокламый. Әллә йокысы туйган, әллә Айгөл селкетә белми. Бәби нәрсәдер әйтергә тырышкан кебек, мыгыр-мыгыр килә. Ул арада кычкырып та җибәрде:

— Үә, үә!

Бәби шулай кычкыргач, Айгөл әнисенә әйтте:

— Әни, бәби әйтә, әни, ал, ди.

Әнисе бәбине кулына алды. Әнисе кулына кергәч, бәби тешсез авызы белән кызык итеп көлде. Нәрсәдер әйткән төсле:

— Анна… Илл!.. — диде

— Яңа ел шул, улым, Яңа ел! — диде әнисе.

Айгөл аптырап китте. Ул бәбине сөйләшә алмый дип белә иде.

— Әни, — диде ул,— бәби «Яңа ел» дип әйтә беләмени? Сөйләшә белми бит ул.

— Нигә белмәсен, белә.

— Бәбичә сөйләшә белгән кеше дә буламы? — дип сорады Айгөл.

— Зур кешеләр бәби белән сөйләшә беләләр. Менә син дә, бәбине яратсаң, аның белән сөйләшергә өйрәнерсең, — диде әнисе Айгөлгә.

*Мирсәй Әмир*

## Кечкенә Ринат

Ринатның әнисе китапханәче булып эшли. Еш кына әнисе белән кечкенә Ринат та китапханәгә бара. Ул анда китаплар карый. Әнисе аңа әкиятләр укый. Әкият тыңларга бик ярата шул малай.

— Үскәч, дәү булгач, мин дә сиңа укырмын, әнием, яме, ул чакта син тыңлап кына утырырсың! — ди.

— Ярар, улым, — ди әнисе, улының маңгаеннан үбеп.

Ринат янә китаплар карый башлый. Бер дә ертмый ул аларны. Бу хакта — китапны ертырга ярамаганны — дусларына да әйтә.

— Китапны ертмагыз! — ди.

Кайберәүләр кебек түгел шул ул, кечкенә булса да, китапны ертырга ярамаганын, синнән соң башкаларның да аны укыйсын белә ул.

*Рафис Гыйззәтуллин*

## Айсылу

Әтисе Гүзәлгә курчак алып кайтты. Исеме дә бар — Айсылу исемле.

— Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз, — диде әтисе.

Әй сөенде, әй шатланды соң Гүзәл! Җитен чәчле, зәңгәр күзле курчагын бер генә дә кулыннан төшермәде. Җайсызрак тотканда, Айсылу:

— Ән-нә, ән-нәү-ү... — дип тавыш та бирә белә иде.

Бүген ял көне. Гүзәлне бакчага илтмәделәр. Ул, сөенеп, Айсылу белән уйный гына башлаган иде, урам яктан күрше кызы Рәйханәнең тавышы ишетелде:

— Гүзәл, әйдә, уйнарга!

Кыз, тиз-тиз киенде дә урамга йөгерде. Айсылуның:

— Мине дә алып чык, бергә-бергә уйнарбыз, — дип, курчагының ялварып карап калуын да күрмәмешкә салышты.

— Әйем лә, синең белән үзем генә уйнармын, — дип, ашыгып, ишекне япты. Чөнки Рәйханәнең курчак белән уйнавын теләмәде ул. Урамда комнан әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр ясап бетерделәр. Тора-бара Гүзәл курчагы турында тәмам онытты. Өйгә кергәч кенә, янә хәтеренә төшерде, йөгереп килеп, Айсылуны кулына алды.Чү! Ни булган аңа? Кулга алуга:

— Ән-нәү-ү, тимәү-ү! — дигән сыман ыңгырашты да күзләрен йомды.

— Әни, әнием, — дип, алгы бүлмәгә йөгереп керде Гүзәл. — Айсылу минем белән уйнарга теләми.

Әнисе, сынап, кызына карады.

— Әллә үпкәләттеңме үзен?

Гүзәл ни дияргә белмәде. Бары шунда гына әтисе әйткән сүзләрне исенә төшерде. «Иптәшләрең белән бергәләп уйнарсыз...» — дигән иде бит.

Гүзәл курчагының чәченнән йомшак кына сыйпап алды:

— Син ачуланма инде, икенче тапкыр сине дә дусларым янына алып чыгармын... — диде.

Айсылу әйтерсең лә шуны гына көтеп торган, ул зәңгәр күк йөзе төсле күзләрен ачып җибәрде.

*Рафис Гыйззәтуллин*

## Яңа чана

Раиләләрнең ишегалдында балалар бик күп. Алар бер-берсен яраталар, бергәләп, төрле-төрле уеннар уйныйлар. Быел кыш тау ясадылар.

Һәркайсының чанасы бар. Тик Раиләнең генә чанасы юк. Ул уйнарга чыккач, Фирая белән Гүзәл йөгереп киләләр дә:

— Раилә, кил, чанада шу,— дип, үз чаналарын биреп торалар.

Беркөнне Раиләнең әтисе дә чана алып кайтты. Раилә шатлыгыннан нишләргә белмәде. Биеп тә алды, сикергәләп тә. Әтисе Раиләгә:

— Чанаңны саклап кына шу, ватма, — диде.

— Ярар, — диде Раилә. Ул, чанасын тартып, ишегалдына чыкты. Аны балалар чолгап алды. Алар: «Раиләгә дә чана алганнар!» — дип шатландылар. Раилә горурланып шуды да шуды чанада. Үз чанасы булгач, тагын да күңеллерәк икән аңа. Бераздан аның янына күрше малае Илдар килде.

— Раилә, чанаңны биреп тор әле, мин дә шуып карыйм әле, — диде ул. Кыз аңа кулын гына селтәде:

— Кит, кит, бирмим, йә ватарсың, — диде дә Илдар яныннан выжылдап шуып китте. Фирая белән Гүзәл, бу сүзләрне ишеткәч:

— Ул чанасын кызгана, саран, саран, — дип, Раиләне үрти башладылар. Раилә, чанасын өстерәп, Илдар янына килде. Аңа чанасын бирергә теләде. Тик Илдар аңа әйләнеп тә карамады. Раиләгә бик күңелсез булып китте. Аны хәзер яңа чана шатландырмый иде инде.

*Рәисә Ишморатова*

## Песнәк белән Әнисә

Кыш көне иде. Көннәр үтә салкынаеп китте. Суык бабай стеналарга китереп суга, шарт-шарт итә. Тышка чыксаң, борынны чеметә.

Кошларның хәле бик авырайды. Аларга ашарга табу кыенлашты.

Беркөнне Әнисәләрнең тәрәзәсенә сары түшле песнәк килеп кунды. Тәрәзә пыяласын чукырга тотынды.

— Әни, песнәк нигә тәрәзәне чукый? — дип сорады Әнисә.

— Күрәсең ич тышта нинди салкын. Аның ашыйсы килгән, — диде әнисе.

— Алайса, мин аны ашатыйм, — диде Әнисә, форточканы ачты да бер кисәк туңмай куйды. Песнәк бик шатланды. Канат кагып, Әнисәгә рәхмәт әйтте. Күз ачып йомганчы майны ашап та бетерде.

Шул көннән алып, песнәк бик иялəшеп китте. Көн саен бер вакытта тәрәзәгә килеп куна торган булды. Тора-бара ул ачык тәрәзәдән өйгә дә керә башлады.

*Гасыйм Лотфи*

## Сания бакчага бара

Сания инде бакчага үзе бара, үзе кайта. Ул һәр эшне үзе эшләргә ярата. Иртә торгач, үзе киенә. Тик менә аның оегы бик тискәре. Кигәндә, үкчә ягына башы, баш ягына үкчәсе килеп йөдәтә. Ботинкалары да шулайрак. Кайчакта уң аягы-

на сулныкы, сул аягына уңныкы килеп тора. Җитмәсә тагы, шулвакыт аның ботинка баулары белән шаян мәче баласы уйный башлый.

— Кит, юләр, шаярма, минем бакчага барасым бар ич! — ди аңа Сания.

Бүген ял көне. Урамда матур кыш. Әтисе Санияне кечкенә чанага утыртып, урамга алып чыкты.

Чана йомшак кар өстеннән выжлап кына бара. Үрдән төшкәндә, чана үзе шуа. Әтисе чана артыннан тотып кына бара. Ә менә үргә каршы менүе авыррак икән. Әтисе дә көчкә генә тарта чананы. Шулвакыт Сания әтисенә: «Тукта, әти, хәзер син утыр, мин тартыйм!» — ди.

*Госман Бакир*

## Минеке, тимә!

Гөлгенәнең уенчыклары бик күп. Тик бергә уйнарга иптәше генә юк. Бүген әбисе аның белән уйнарга күрше малае Фәритне чакырды. Алар башта бик тату уйнадылар.

Шунда матур бер уенчыкка Фәритнең күзе төште. Аны кулына алды. Ә Гөлгенә чырылдап кычкырып җибәрде:

— Минеке, тимә!

Аш бүлмәсеннән әбисе килеп чыкты.

— Алай ярамый, Гөлгенә! Бергә уйнагыз. Уенчыкларыңны бир, — диде ул.

Гөлгенә, теләмичә генә, бер кулы чыккан, бер аягы сынган курчакны Фәриткә сузды. Тик кулсыз курчак Фәритне тиз туйдырды. Ул икенче уенчыкка үрелде. Гөлгенә яңадан чырылдый башлады:

— Минеке, тимә! Үзем уйныйм!

Гөлгенәнең әбисе тагын килде.

— Алай ярамый, кызым. Бергә уйнагыз дим бит инде! Һай, кемгә охшап болай комсыз соң син? — диде ул.

Көтмәгәндә Гөлгенә уенчыкларын җыеп алды да кочаклап күтәрә башлады.

— Әйдә, теге бүлмәгә чыгып уйныйк, — диде ул.

Фәрит әйбәт малай икән. Гөлгенәгә булышам дип, берничә уенчыкны ала башлады.

Гөлгенәнең чырае сытылды.

— Минеке, тимә! Үзем күтәрәм!

Ул бөтен уенчыкларын да үзе күтәреп китәргә азапланды. Шулай кылана торгач, әнисе бүләк иткән алтын тоткалы бәләкәй чәйнеген төшереп ватты. Ватты да бик ямьсез итеп еларга кереште.

Тагы әбисе килеп җитте.

— Һай, харап иттең ич! Үзең генә уйнагач, үзең генә күтәргәч, шулай була инде ул! — диде.

*Абдулла Әхмәт*

## Куян кызы

Бер соры Куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән.

Көннәрдән бер көнне Куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

— Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, — дигән.

Кызы бу бүләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул яңа киез итекләрен киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин Куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнисе тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе баласына аларны эзләп табып кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә, ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул салып ташлаган. Кар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде, аксый-аксый, әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта! — дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

— Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, дигән. Инде ни эшләргә? — дип уйга баткан Куян. —

Бу баланы кая алып барырга, ничек дәваларга? — дип кайгырган.

Шулвакыт нәрсәдер кычкырган. Куян агач башына күтәрелеп караган икән — Тиенне күргән. Ул Куянга болай дигән:

— Кайгырма, туганкай, йомшак Куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен Доктор Айболитка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк, — дигән.

Тиен Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, Доктор Айболитның өенә үзе илтергә булган.

Куян да кызын күтәргән һәм Доктор Айболитка киткән. Тиен, агачтан агачка сикереп, аңа юл өйрәткән.

Барып җитсәләр, Доктор Айболитның эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр икән. «Балаларны чиратсыз карыйм мин»,— дигән Доктор Айболит. Куян кызын доктор бүлмәсенә алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. Доктор Айболит Куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм аңа болай дигән:

— Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма, — дигән.

Доктор Айболитка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып, өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, Куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.

*Абдулла Алиш*

## Елак Өтәч

Бер Өтәч очрады миңа бүген. Акырыплар елап утырган көне.

— Нигә елыйсың, Өтәчкәй? — дип сорадым. Өтәч томшыгын ачып күрсәтте. Тешләре коелып беткән икән мескеннең.

Өтәч һаман елый:

— И-и-и, томшыгым авырта-та. Йоклый алмыйм. Ашый алмыйм. Чукый алмыйм.

— Кем койды соң синең тешләреңне, Әтәчкәй? — дим.

— Конфет күп ашадым. Шоколад яратам мин. Менә хәзер ашый алмыйм, йоклый алмыйм, томшыгым сызлы-ы-ый, — дип елый Әтәч.

— Син бит Әтәч түгел, улым, елама. Алайса, тавыклар көлер үзеңнән. Әнә Әтәчкәйдән бөтен тавыклар көлә икән хәзер.

Елак-елак, елтын колак,
Карама таяк, карт әтәч.
Гарьлек, хурлык,
Бер түбәтәй орлык, —

дип, җыр чыгарганнар тавыклар Әтәч турында.

Син бит Әтәч түгел, конфет күп ашама, шоколад сорама. Йә елак Әтәч сыман тешсез калырсың, аннары йоклый алмассың.

*Батулла*

## Юынмый торган Балык

Яшәгән, ди, бер Балык. Юынырга бер дә яратмаган икән ул. Юынмагач, бите дә каралган, муены да каралган, койрыгы да каралган. Әнисе юындыра башласа, кычкырып елый икән бу. Имеш, әле күзенә сабын керә, әле борынына су керә! Шулай итеп, бер дә юынмыйча йөри, ди. Ашар алдыннан, канатларын юмаган, йоклар алдыннан, койрыгын юмаган. Танырлыгы да калмагач, Балык адашкан. Ә адашкан, танырлыгы да калмаган Балыкның кемнеке икәнен кем белсен? Шулай итеп, юынырга яратмаган Балык бөтенләй югалган.

*Әхәт Гаффар*

## Чукмар белән Тукмар

Бер әбинең ике әтәче булган. Аларның берсе ак, икенчесе кара булган. Әтәчләр күп вакытларын сугышып үткәрәләр икән.

Әби ак әтәчкә Чукмар дип, карасына Тукмар дип исем кушкан. Чукмар чукырга бик оста, ә Тукмар бик нык тукмый икән.

Әби аларны ашатырга тотынса, «Җимне миңа әзрәк бирдең!», «Ник минем өлешемә кердең?» — дип кычкырыша башлыйлар икән әтәчләр. Әйтешеп кенә калмыйлар, шунда ук сугыша да башлыйлар икән. Чукмары канга батырганчы чукырга, Тукмары күгәргәнче тукмарга тотына икән.

Әби килеп җитсә, Чукмар исемле ак әтәч:

— Әби, Әби, кара әле, Тукмарың, тукмый-тукмый, бөтенләй күгәртеп бетерде, — дип әләкли икән.

Тукмар исемле кара әтәч тә энесеннән калышмый:

— Башымны кара әле, Әби. Чукмарың чукый-чукый канатып бетерде.

Әби аларның әләкләшүләреннән дә туйган булган. Ул бер сүз дә әйтмәгән. Тукмарны култыгына кыстырган да каядыр күтәреп алып киткән. Тукмар бик курыккан. Әби аны күршеләренә кертеп торган. Тукмар анда өч кич кунган.

Ялгыз калгач, Чукмарга бик күңелсез булган. Юньләп ашый да, эчә дә алмаган.

Әбигә ул:

— Тукмарны алып кайт, башка сугышмабыз! — дип ялынган.

— Ярый, — дигән Әби, — алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне бөтенләй юк итәм! — дип куркытып та куйган. Шуннан Тукмарны алып кайткан.

Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган. Алар кочаклашып исәнләшкәннәр.

Хәзер инде алар бик тату яшиләр икән. Тик исемнәре генә һаман шулай Тукмар белән Чукмар булып калган.

*Абдулла Алиш*

## Мактанчык бака

Түгәрәк күл буенда, камышлыклар төбендә яшәгән, ди, бер бакылдык бака. Үзе кечкенә булса да, тавышы бик еракларга

ишетелгән, ди. Көн димәгән, төн димәгән, һаман мактанган. «Бакка-как-как. Мине эзләп тап! Миннән оста җырчы юк. Исемем — Бакылдык, үзем бер батам, бер калкам», — ди икән.

Шулай беркөнне бу бака су астыннан өскә күтәрелгән һәм тирәякны яңгыратып бакылдарга керешкән: «Бакка-как-как», — ди икән бу. Шулвакыт камышлар арасында йөзеп йөргән үрдәк, баканың тавышын ишетеп, аның янына ашыккан.

Үрдәк баканың бакылдавын мактарга тотынган. Бака бик шатланган, тагын да күбрәк бакылдаган.

«Кил әле, борыным өстенә мен әле. Колакларым катырак, җырыңны бик тансыкладым», — дигән үрдәк. Бака бик шатланган. Үрдәкнең борынына менеп атланган. Җырларга дип авызын ачуы булган — Үрдәк баканы капкан да йоткан.

*Идрис Шәймөхәммәтов*

## Дару

Таняның әнкәсе авырып китә дә, доктор аңа әче дару эчәргә куша. Әнкәсенең әче даруны көч-хәл белән генә эчкәнен күргәч, Таня:

— Әнекәем! Синең өчен үзем генә эчимче шул даруны! — дип куя.

*Константин Ушинский*

## Әтәч үзенең гаиләсе белән

Ишегалдында әтәч йөри. Башында — кызыл кикрик, ияк астында — кызыл сакал. Әтәчнең борыны өтерге сыман, бизәкле койрыгы түгәрәкләнеп тора, аягында — типкеләр. Әтәч көчле аяклары белән чүп өемен тарата, чебешләрне, тавыкларны чакыра:

Тавыкларым, җан кисәкләрем!
Чуаркайлар! Матуркайлар!
Каракайлар! Сарыкайлар!

Чебешләрегез белән бергә җыелыгыз,
мин сезгә җим әзерләп куйдым!

Тавыклар чебешкәйләре белән бергә җыелышалар, кытаклашалар да җимне бүлешә алмыйча сугыша башлыйлар.

Әтәч тәртипсезлекне бер дә яратмый. Ул шунда ук гаиләсен килештерергә тотына. Берсенең башыннан чукып ала, икенчесенең маңгай йонынннан йолкый, ә үзе шул арада җимне ашап та куя. Ә аннары читәнгә кунып, канатларын кагып, бар тавышына кычкырып җибәрә:

— Кикрикүк!

*Константин Ушинскийдан*

## Бергә җайсыз, аерым күңелсез

Бер малай сеңлесенә:

— Минем бөтерчегемә тимә! — ди.

Ә сеңлесе аңа:

— Син дә минем курчакларыма кагылма! — дип җавап бирә.

Балалар икесе ике почмакка утырып уйный башлыйлар, әмма тиздән аларның икесенә дә күңелсез булып китә.

Нигә күңелсез була соң аларга?

*Константин Ушинскийдан*

## ШИГЫРЬЛӘР

### Көз

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

*Әхмәт Ерикәй*

### Яратам

Яратам мин үземне,
Әти белән әнине,
Абый белән энемне,
Бишектәге сеңлемне.

*Шәйхи Маннур*

### Минем бакчам

Иркен һәм матур да
Безнең Туган илебез.
Урманга бай, суга бай
Гөлбакчалы җиребез.

*Әминә Бикчәнтәева*

### Көзге яңгыр

— Апа, безгә артыбыздан
Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
— Кем дә дәшми, көзге яңгыр
Зонтик белән сөйләшә.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Бәтиләр

Үсә безнең фермада
Бик күп нәни бәтиләр.
— Бә! — диләр. —
Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Ничек исемнәрегез? —
Дип сорагач, бәтиләр:
— Бә! — диләр. —
Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Сезгә ничә яшь? — дигәч,
Аңламыйлар бәтиләр:
— Бә! — диләр. —
Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Шәл бәйләргә йон безгә
Бирегезче, бәтиләр!
— Мә! — диләр. —
Мә! — диләр
Бөдрә тунлы бәтиләр.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Чишмә

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

*Әхмәт Исхак*

## Безнең сыер

— Әби, әби, әйт әле:
Сыер нигә мөгери?
— Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер, — ди.

— Ашап туйгач, ник сыер
Сузып-сузып «му-у» ди ул?
— Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! — ди ул.

*Нәкыйп Каштан*

## Беренче рәхмәт

Алсу хәзер зур кыз инде —
Аңа өч тулган.
Алсу бүген абыйсының
Яулыгын юган.

Сабынлаган да яулыкны
Чиләккә тыгып,
Чайкаган да элеп куйган,
Тормыйча сыгып.

Шатлыктан нәни Алсуның
Күзләре яна:
Рәхмәт әйткән моның өчен
Абыйсы аңа.

Мөмкин түгел шатланмаска:
Бит шундый рәхәт
Чын күңелдән эшләп алган
Беренче рәхмәт.

*Әхмәт Исхак*

## Шофёр булам

Мин дә, әтием шикелле,
Шофёр булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт
Машинам белән уйныйм.

Тизрәк үсеп шофёр булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем.

*Зәкия Туфайлова*

## Ул шуңа кечкенә

Әнием гел миңа:
—Үскәнем минем, — ди.
Ник минем курчакның
Үскәне күренми?

Әй, минем курчагым
Ашамый һич кенә.
Ул шуңа үсми шул,
Ул шуңа кечкенә.

*Заһирә Гомәрова*

## Үз телендә сөйләшә

Әтисе дә сөйләшә,
Әнисе дә сөйләшә.
Шулай булгач, нигә әле
Айдарга сөйләшмәскә?! —
Теле бар бит аның да!
Кара-каршы сөйләшергә
Әбисе бар янында.
— Әт-тә, ән-нә, тәт-тәт-тәт!..
Әб-бә, баб-ба, тәт-тәт-тә!.. —
Айдар шулай матур итеп
Үз телендә сөйләшә.

*Энҗе Мөэминова*

## Ботка

Газлы зәп-зәңгәр утта
әни пешерә ботка.
Юган ярмасы сары,
исеме була тары.
Ярманы суга салды,
суны кайнатып алды.
Сөт өстәде аннары,
тоз өстәде аннары,
май өстәде аннары,
һәм ботка булды тары.

*Ренат Харис*

## Минем сеңлем

Һап, һап, һап кына,
Очар коштай талпына.
— Үчти-үчти итәм, ди,
Тәпи атлап китәм, — ди.

Тәпи-тәпи, тәпи-тәпи...
Минем сеңлем бик тәти.
Бер утыра, бер баса,
Биетим лә, булмаса.

Тып-тып килә ул,
Ничек кенә белә ул!
Бәләкәч кулларын җәеп,
Чарык-чарык көлә ул.

Тыпыр-тыпыр биесен,
Тик куансын, тик көлсен.
Көлсә көлер эше бар,
Ике бөртек теше бар...
Һап, һап, һап!

*Резеда Вәлиева*

## Энесенә ул апа

Җырлый-җырлый, кыз бала
Энекәшен йоклата.
Биштә генә булса да,
Энесенә ул — апа.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Йоклатканга энемне,
Әнкәй мине пәп итә.

Кошлар кунган тирәккә,
Аларны җил тибрәтә.
Тышта җилләр искәндә,
Бәби йоклый мендәрдә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә,
Энем йокыга киткәч,
Әнкәй бераз ял итә.

Йоклый бала, төш күрә,
Көлә, күккә сикерә,
Имеш, аны әтисе
Үсти-үсти иттерә.
Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Әнкәй, мәми пешереп,
Әткәйне эштән көтә.

*Мөнир Мазунов*

## Түз инде

Куянымның бер колагын,
Белмим, кайсы өзгәндер.
Бик тә авырткандыр инде,
Белмим, ничек түзгәндер...

Түзүен дә түзгәндер ул,
Инде менә моннан соң
Минсөйләгәншигырьләрне
Ничек итеп тыңлар соң?

Әни эштән кайтсын инде,
Түз, куяным, түз генә,
Әниемнән яңа колак
Тектерермен үзеңә!

*Рафис Корбан*

## Ләлә чана шуа

Ләлә чана шуа,
Шуа, шуа, шуа,
Егылып чанасыннан
Төшеп кала шунда.

Чана тауга менми,
«Әйдә, тартып мен», — ди.
Ләлә: «Менә кызык!
Ничек тартыйм мин?» — ди.

Шуып китә чана
Тау астына таба.
Йөгереп төшеп, Ләлә
Эләктереп ала.

Тауга таба, Ләлә,
Тартып булмый мәллә?
Шуа белгәч өйрән
Тартып менәргә дә.

*Бари Рәхмәт*

## Ләйлә

Урамнар бүген сөенгән,
Ап-ак кардан киенгән.
Ләйлә чанасын өстерәп
Чыгып китте өеннән.

*Һади Такташ*

## Салкын, саф һава

Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.

Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Кыш бабай

Кыш бабай килгән,
Ап-ак тун кигән.
Көтә: кем генә
Чыгар дип өйдән.

Чыксаң чеметә,
Битне өшетә,
Менә шул аның
Бөтен эше дә.

*Бари Рәхмәт*

## Кыш бабай

Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай;
Сакал-мыек ап-актан,
Килгән безгә ерактан.

Бүләкләр алып килгән,
Бүреген кыңгыр кигән.
Әйлән-бәйлән уйната,
Биетә һәм җырлата.

*Әхмәт Рәшит*

## Минем бүләк

Сигезенче март —
Әни бәйрәме.
Бүләк итәрмен
Чәчәк бәйләме.

Ничек табарга,
Кайда чәчәк бар?
Кая карама —
Каплаган ак кар.

Әнигә шигырь
Бирдем бүләккә.
«Гомергә, — ди ул, —
Калыр йөрәктә».

*Заһирә Гомәрова*

## Куянкай

Әй куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына,
Бик куркак кына.

Ике колагы
Озынкай гына.
Аягы җиңел —
Мамыктай гына.

*Нәкый Исәнбәт*

## Үзен бик чиста йөртә

Күрәсезме песине,
Юына, чистарына.
Ул кунакка барамы?
Ник юына, арына?

Йомшак тәпие белән
Битен әйбәтләп сөртә.
Ул шулай һәрвакытта
Үзен бик чиста йөртә

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Әтәч

Иртән бик иртә тора,
Канат кагып кычкыра:
— Кикрикүк! Кикрикүк!
Тор иртәрәк: эшең күп...

*Гасыйм Лотфи*

## Кәҗә

Кәҗә безгә йон бирә,
Кәҗә безгә сөт бирә.
Тик шунысын яратмыйм:
Җәен бакчага керә.

*Мөнир Мазунов*

## Яз

Яз килә! Яз килә!
Сыерчыклар килә,
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.

*Бари Рәхмәт*

## Тышта яз

Тышта яз әле
Яңа башлана:
Тамчылар тып-тып
Түбәдән тама.

*Әхмәт Ерикәй*

## «Әни» сүзе

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

*Зәкия Туфайлова*

## Уңган сыерчык

Ак буяулы бер оя бар
Бакчада зур агачта,
Очып килә шул ояга
Сыерчык, яз булгач та.

Шунда тора, шунда йоклый,
Шунда бала үстерә,
Матур итеп сузып сайрый,
Басып оя өстенә.

*Хәй Вахит*

## Тавыклар белән Таһир

Тавыклар йөри:
— Кыт-кыт та кыт-кыт!
Син, Таһир, безнең
Тамакны тук тот!

Таһир җим бирә:
Сүзсез дә аңлый —
Алар бит җимсез
Бер күкәй салмый.

*Дамир Гарифуллин*

## Зиләнең курчагы

Зиләнең бер курчагы бар,
Сузып кына: «Ән-нә», — ди.
Сеңлем аңа: «Әттәбезне
Яратмыйсыңмы әллә?» — ди.

Сөеп кенә тора безне,
Беләсең бит әтине...
Йә үпкәләр, аңа да бер
Әт-тә» диеп әйт инде.

*Хәкимҗан Халиков*

## Йокла инде, курчагым

Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле,
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле.

Аргансың инде, җаным,
Йокла, минем матурым,
Мин дә синең яныңа
Ял итәргә ятармын.

Йокла инде, курчагым,
Йомылмаса да күзең,
Сине йоклата торгач,
Йоклап китәм бит үзем.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Тәти кул

Уң кул була, сул кул була,
Ә уң кул була тәти.
Тәти кул белән ашарга
Өйрәтте мине әти.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Алмаз

Бер итеге уңга карый,
Берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч
Кыендыр ул аякка.

Бияләй — ишле-сыңарлы,
Бүрек каплаган күзен.
Әллә малай, әллә кыз ул —
Танып та булмый үзен.

Танымаса танымаслар,
Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн
Үзе киенә менә.

*Җәүдәт Дәрзаман*

## Сүз тыңлаучан булыгыз

Курчакларым, килегез,
Яңа йортны күрегез.
Менә бусы — ишеге,
Рәхим итеп керегез!

Шаулашмагыз, елашмагыз,
Тату гына торыгыз.
Сез бит инде дәү курчаклар,
Сүз тыңлаучан булыгыз.

*Резеда Вәлиева*

## Башмак кигәндә

Менә безнең уң башмак,
менә безнең сул башмак.
Уңын киябез башта,
аннан киябез сулын…

Уңын алдан кигәннең
уңа икән, ди, юлы.
Уң аяк безнең әзер.
Сулын киябез хәзер.

*Ренат Харис*

## Курчак

Кичә Ләйлә көйсезләнеп
Атып бәрде курчагын.
Уйныйсы килгәч, ул аны
Эзли башлады тагын.

Әнисе әйтә аңарга:
— Курчагың синнән бизгән,
Ләйлә мине гел кыйный дип,
Ул чыгып киткән бездән.

Өстәл асларын карады,
Шкаф артын капшады,
Сандык яннары калмады,
Тик курчагын тапмады.

*Әнәс Кари*

## Ике кыз

Ай, начар кыз Әнвәрә,
Көн дә елый: «Вә-вә-вә!»
Кичен елый куркудан,
Елап тора йокыдан.

Уенчыкларын вата,
Энесен дә елата.
Шуңа аны сөймиләр —
«Елак Әнвәрә» диләр…

Күрше кызы Әминә
Шундый акыллы менә:
Егылса да еламый,
Сеңлесен дә кыйнамый.
Елаганда юата,
Курчак биреп уйната.

*Әнәс Кари*

## Әнигә булышам

Бик зур үстем инде мин,
Әнигә булышам.
Үз ботинкамны үзем
Кияргә тырышам.

Әниемнең эше күп:
Бәйли миңа оек.
Бүген бөтен уенчыкны
Үзем куйдым җыеп.

Башка-башка эштә дә
Файдам бар әнигә.
Уйнап кайткач, пальтомны
Үзем эләм чөйгә.

Әнием китә эшенә,
Ә мин чебеш карыйм.
Ипи турап ашатам,
Мин дә эшкә ярыйм.

*Газиз Нәбиуллин*

## Ап-ак иткән

Чисталыкны бик ярата
Гөлгенә.
Битен-күзен юып тора
Гел генә.
Өс-башына тузан-туфрак
Тидерми.
Курчакка да керле күлмәк
Кидерми.

Ә беркөн ул артыграк
Тырышкан:
Мех бүреген суга салган
Берочтан.
Кара киез итеген дә
Юган ул.
Бар әйберен «ап-ак» итеп
Куйган ул.

*Фәнис Яруллин*

## Әни белән сөйләшү

Улы дәшә: «Уа, уа!» —
Кил янына, янәсе.
— Килә алмыйм, савыт юам, —
Ди улына әннәсе.

Үрсәләнә, ярсулана:
— Уа, уа! — ди улы.
— Киләм, җаным, ачуланма! —
Ди әнкәсе бу юлы.

*А. Барто*

# «ГӨРЛӘП ҮСӘБЕЗ, БЕЗ БӘХЕТЛЕЛӘР...»

4—5 яшьлек балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Җырлар, такмаклар, мавыктыргычлар, эндәшләр, бармак уеннары

* Кояшкаем, чык, чык,
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.

* Утыр, балам, ашарга,
Түгеп-чәчеп ашама.
Матур утыр табында,
Алдыңа күл ясама.
Ипи валчыгыңны койма,
Аяк астына ташлама.

* Кәк-күк, кәк-күк,
Монда гөмбә бик күп.
Бик күп, бик күп,
Кәк-күк, кәк-күк.

* Әтисенә ай кебек,
Әнисенә көн кебек,
Апасына гөл кебек,
Бабасына туп кебек,
Килеп киткән кешеләргә
Чүп кадәр дә юк кебек.

* Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул,
Тирән күлне ярата,
Әлфирә үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул,
Белмим, кемне ярата.
Сәвияне ярата шул, ярата.

* Әй чулпысы, чулпысы,
Бигрәк матур тәңкәсе.
Аккош микән, былбыл микән
Моны тапкан әнкәсе.

* Болыт, болыт, килмә син,
Безнең юлны бүлмә син,
Син килгәч, без куркабыз,
Өйгә кайтып китәбез.

* Әби коймак пешерә,
Бабай кабык төшерә.
Мин дә коймак сорасам,
Кабык белән төшерә:
— Көтеп тор, ди, пешкәнче,
Табасыннан төшкәнче.

* Яңгыркаем, яу, яу,
Игеннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын —
Безгә катык, сөт булсын,
Яңгыр, яу, яу, яу!

* Бас, кызым, эзенә,
Күз тимәсен үзеңә;
Асыл гөлләр үсеп тора,
Синең баскан эзеңә.

* Баш бармак,
Балан ияк,
Урта тияк,
Әби-чәби,
Нәни бәби.

* Ай, диләр, вай, диләр,
Бу абзый бик бай, диләр.
Бу абзыйның капчыгында
Баллы прәннек бар, диләр.

* Булатның туган көненә
Без пешердек ак калач;
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк,
Менә шундый киңлеге,
Менә шундый тарлыгы;
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне ал да кач!

* Ябалак, ябалак,
Йөрмә, чеби сагалап.
Чебиемне бирмәм,
Күземә күренмә, көш!

* Камка түти, кач, кач,
Алтын капкаң ач, ач.
Анаң салма пешерә,
Атаң ашап бетерә.

* Карга килер — казан асар,
Торна килер — тоз салыр,
Саескан килер — салма салыр,
Песнәк килер — пешерер,
Чыпчык килер — төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер...

# ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР

## Йомры күмәч

*(Рус халык әкияте)*

Борын-борын заманда бер әби белән бабай бик тату гомер кичергәннәр.

Бервакыт бабай, әбигә карап:

— Карчык, күмәч пешерер идең, — дигән.

— Нәрсәдән пешерим соң? Он юк бит.

— Их, карчык, әрҗә төбеннән кырып, бура почмакларыннан себереп кара, бераз җыймассыңмы?

Әби, кечкенә генә канат белән әрҗә төбеннән, бура почмакларыннан себереп, бер-ике уч он җыйган. Шул оннан күмәч пешергән һәм тәрәзә төбенә суытырга куйган.

Күмәч, тәрәзә төбендә тора торгач, кинәт сәке өстенә тәгәрәп төшкән. Сәке өстеннән идәнгә, идән буенча ишеккә, аннан, бусага аша сикереп, өй алдына, өй алдыннан тышкы баскычка, тышкы баскычтан ишегалдына, ишегалдыннан урамга чыгып, юл буйлап тәгәрәп киткән.

Күмәч шулай тәгәрәп барганда, каршысына бер Куян килеп чыккан:

— Күмәч, Йомры күмәч, мин сине ашыйм!— дигән аңа Куян.

— Син мине ашама, кылый, мин сиңа җыр җырлармын,— дигән дә күмәч, шундук җырларга тотынган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч,
Әрҗә төбеннән себерелгән,
Каймакта басылган.
Мин әбидән дә киттем,
Мин бабайдан киттем,
Синнән дә, Куян, кыен булмас качуы, —

дигән дә тәгәрәп китеп барган, Куян аны күреп кенә калган...

Йоры күмәч һаман тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Менә бервакыт аның каршына Аю килеп чыккан:

— Йомры күмәч, Йомры күмәч, мин сине ашыйм! — дигән аңа Аю.

— Син мине ашама, Аю дус, мин сиңа җыр җырлармын, — дигән дә күмәч, шундук җырларга тотынган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч,
Әрҗә төбеннән себерелгән,
Каймакта басылган.
Мин әбидән дә киттем,
Мин бабайдан киттем,
Мин Куяннан да качтым,
Синнән дә, Аю, кыен булмас качуы, —

дигән дә тәгәрәп китеп барган, Аю аны күреп кенә калган...

Йомры күмәч һаман тәгәрәгән дә тәгәрәгән, аның каршына Төлке килеп чыккан.

— Исәнме Йомры күмәч, син нинди гүзәлсең! — дигән Төлке.

Аңа каршы Йомры күмәч җырлый башлаган:

Мин — Йомры күмәч, Йомры күмәч,
Әрҗә төбеннән себерелгән,
Каймакта басылган.
Мин әбидән дә киттем,
Мин бабайдан киттем,
Мин Куяннан да качтым,
Мин Аюдан да качтым,
Синнән дә, Төлке, кыен түгел китүе!

— Һай, нинди матур җырлыйсың икән! — дигән Төлке. — Тик мин картайдым инде, бик начар ишетәм: яле, якынрак килеп, минем борыным өстенә утырып, тагын бер генә тапкыр җырлап күрсәт әле. Кычкырыбрак җырла.

Күмәч Төлкенең борын өстенә менеп утырган да шул ук җырны кабатлаган.

— Рәхмәт, бик әйбәт җыр икән. Мин тагын да тыңлар идем. Минем телем өстенә утырып, соңгы тапкыр җырлачы! — дигән Төлке һәм телен чыгарган.

Йомры күмәч Төлкенең тел өстенә сикереп менгән икән, Төлке аны капкан да йоткан.

## Торна белән Төлке

*(Әкият)*

Бервакыт Төлке Торна белән дуслашкан һәм аны үзенә кунакка чакырган: «Кил, дустым, кил, кадерлем! Мин сине сыйлармын», — дигән.

Торна кунакка килгән. Төлке ботка пешергән дә сай тәлинкәгә салып куйган һәм Торнаны кыстый икән: «Аша, дустым, аша, иркәм! Үзем пешердем», — дигән.

Торна борыны белән тәлинкәне тук-тук чукыган да чукыган, ләкин авызына ботка эләкмәгән. Ә Төлке ботканы ялый биргән. Шулай итеп, ботканы берүзе ашап бетергән. Ахырдан Төлке: «Гаеп итмә инде, дустым, башка сыем юк», — дигән.

«Монысына да бик рәхмәт, дускаем, — дигән Торна. — Иртәгә үзең миңа кил».

Икенче көнне Төлке Торнага кунакка килгән. Торна тар муенлы озын чүлмәккә борчак салган да: «Аша, дустым, аша, сөеклем!» — дип, Төлкене кыстый икән. Төлке чүлмәк тирәсендә әйләнә дә тулгана, чүлмәккә башы белән тыгылмакчы да була, иснәп тә карый, ләкин бернәсә дә ала алмый икән. Ә Торна озын борыны белән чүлмәктән борчакны чүпли бирә икән. Ул, шулай итеп, борчакны ашап та бетергән. «Гаеп итмә инде, дустым, башка сыем юк», — дигән Торна.

Төлке ач көе өенә кайтып киткән. Шуннан бирле Төлке белән Торнаның дуслыгы да беткән, ди.

## Ата каз

*(Татар халык әкияте)*

Казлар елга буенда йөриләр икән. Куе таллыктан Төлке килеп чыккан да казларга таба бара башлаган.

— Төлке бар, сак булыгыз, — дигән Ата каз. Казлар дошманга каршы торырга әзерләнгәннәр.

Төлке бөтенесен дә күреп торган һәм хәйләгә керешкән. Казлар алдына килеп, түбәнчелек белән генә башын игән:

— Кадерле казлар, — дигән ул, тавышын нык калтыратып. — Мин — төлкеләр патшалыгының илчесе, аюлар патшалыгына китеп барам. Бик арыдым. Сездә ял итәргә мөмкин булмасмы?

— Була, берсүзсез була, — дигән Ата каз. — Тик безнең сезгә бер үтенечебез бар иде.

— Сөйләгез, — дигән Төлке, үзенең кипкән иреннәрен ялап.

— Сүз шул, — дигән Ата каз. — «Илче Идел кичә» дигәннәр. Безнең беребез елга аръягында калды. Шуны алып чыгарга ярдәм итмәссезме икән?

Төлке шатланып киткән, ялтыр күзләрендә очкыннар күренгән.

— Мин моңа күнәм, — дигән ул. — Ләкин кайсыгыз булса да берегез иптәш булып барыр бит?

— Барыр, барыр, — дигән Ата каз.

Елга тирән һәм бик киң икән. Ата каз ары караган, бире караган, яр буенда яткан бүрәнәләрне күргән. Борыны белән сөйрәп, берсен суга төшергән дә:

— Әйдәгез, киттек, — дигән Төлкегә.

— Ә кайсыгыз минем белән чыга? — дип сораган Төлке.

— Мин, — дигән Ата каз һәм, йөзеп килеп, бүрәнә өстенә менгән.

Төлке, моны күреп: «Аргы якта берсе бар, ә монысы — икенчесе, мин сезнең икегезне дә исән калдырмам», — дип уйлаган. Бүрәнәнең өстенә менеп утыруы булган, бүрәнә әйләнеп киткән дә Төлке суга чумган, ә Ата каз очып киткән.

Казлар бик шатланганнар. Аның хөрмәтенә бәйрәм ясап, биш көн буена аны сыйлаганнар.

## Балыкчы Аю

*(Татар халык әкияте)*

Бер көнне Аю Төлкенең балык ашаганың күргән дә бик кызыккан.

— И Төлке дус, балык тотарга мине дә өйрәтсәнә! — дигән. Төлке Аюга әйткән:

— Ярар, Аю дус, өйрәтермен, — дигән. Аюның койрыгына бер кәрзин бәйләгән дә аны бәкегә төшергән. Аюга әйткән:

— Шунда кузгалмый гына утыр, кузгалсаң, кәрзингә балык кермәс, — дигән. Шулай дигән дә үзе качкан.

Әй утыра, ди, Аю, әй утыра, ди, балыклар качып бетмәсен тагын дип, бер дә селкенеп карамый, ди. Шулай төне буе утырган, ди. Утыра торгач, койрыгы бәке кырыена ябышып каткан, ди.

Иртә белән хатыннар суга килсәләр, бәке өстендә Аю утыра.

— Ник монда килеп утырдың? — дип, менә тотынганнар Аюны кыйнарга. Аю, бичара, куркуыннан сикереп торган икән, койрыгы шарт итеп өзелгән, ди. Аюның койрыгы шул вакыттан кыскарып калган, ди.

## Ябалак

*(Әкият)*

Ябалак Чыпчыкны тотты, ди. Чыпчык Ябалактан сорады, ди:

— Үлгәнче синең исемеңне белеп калыймчы, син кем буласың? — дип әйтте, ди.

Ябалак, авызын зур ачып:

— Ябалак! — дип кычкырган иде, ди, Чыпчык чыкты да ычкынды, ди.

— Аһ, — дип әйтте, ди, Ябалак, — авызымны ачмыйча, «ябәләк» дип кенә әйтәсе калган, ул чагында ычкына алмаган булыр иде, — дип әйтте, ди.

## Ике ялкау

*(Татар халык әкияте)*

Әүвәлге заманда булган, ди, ике ялкау кеше. Болар бер тапкыр барганнар, ди, урманга. Ул урманда бик тәмле җимешләр бирә торган алма агачы үскән, ди. Болар, бара торгач, шул алма агачын күргәннәр. Олырагы әйткән, ди:

— Әйдә, без бу алма агачын селкетик тә алмасын коеп ашыйк, — дигән. Кечерәге әйткән:

— Иренмичә аны селкеткәнче, әйдә, ичмаса, астына кереп ятыйк, — дигән. Болар шулай дип, алма агачының күләгәсенә кереп ятканнар, ди. Байтак яткач, олысы, карыны ачканга чыдый алмагач, тагын әйткән, ди:

— Ай, авызыма бер генә алма төшсәче! — дигән, ди. Кечесе әйткән, ди:

— Авызга төшсә, аны иренмичә ашыйсы да бар бит әле, мин булсам, авызыма төшсә дә чәйнәмәс идем, — дигән, ди.

Шулай итеп, алар ач көе өйләренә кайтып киткәннәр, ди.

## Тавык, Тычкан һәм Көртлек

*(Татар халык әкияте)*

Тавык, Тычкан һәм Көртлек бергә торалар икән.

Көннәрдән бер көнне Тавык арпа бөртеге тапты, шатлыгыннан кытаклап җибәрде:

— Арпа таптым, арпа таптым! Аны тарттырырга кирәк. Арпаны тегермәнгә кем алып бара?

— Мин бармыйм, — диде Тычкан.

— Мин дә бармыйм, — диде Көртлек.

Ни эшләргә? Тавык арпаны тегермәнгә үзе алып барды да он итеп тарттырып куйды.

— Өйгә онны кем алып кайта? — дип сорады Тавык.

— Мин алып кайтмыйм, — диде Тычкан.

— Мин дә алып кайтмыйм, — диде Көртлек.

Яхшы. Тавык онны үзе үк алып та кайтты.

— Ипине кем изә? — дип сорады Тавык.

— Мин измим, — диде Көртлек.

— Мин дә измим, — диде Тычкан.

Тавык ипине дә үзе изде.

— Мичкә кем яга? — дип сорады Тавык.

— Мин якмыйм, — диде Тычкан.

— Мин дә якмыйм, — диде Көртлек.

Тавык мичне дә үзе якты.

— Мичкә икмәкне кем куя? — дип сорады Тавык.

— Мин куймыйм, — диде Тычкан.

— Мин дә куймыйм, — диде Көртлек.

Тавык икмәкләрне дә үзе куйды. Икмәкләр бик уңдылар — кабарып, кызарып пештеләр.

Тавык аларны чыгарып өстәлгә куйды да:

— Ә икмәкне кем ашар? — дип сорады.

— Мин ашыйм, — диде Тычкан һәм өстәл янына килеп утырды.

— Мин дә ашыйм, — диде Көртлек, ул да килеп утырды.

## Карт белән Төлке

*(Татар халык әкияте)*

Борын заманда бер авылда бер карт белән бер карчык торган. Карт карчыгына: «Карчык, син ипи пешереп куй, мин балык тотарга барып кайтыйм», — дигән. Шуннан соң карт, бер күлгә барып, балык тоткан. Карт балыкларны чанага төягән дә өенә кайтырга чыккан. Юлда ул бөгәрләнеп яткан бер Төлке күргән... Төлке үлгән кебек ята икән. Карт бик шатланган. «Менә карчыкның тунына яхшы якалык та булды бит!» — дигән. Шуннан соң ул Төлкене чанасына салган да алга таба китеп барган.

Бу Төлке тере булган. Ул як-ягына каранган да чанадагы балыкларны берәм-берәм ташлап калдырган. Балыкларны ташлап бетергәч, үзе дә төшеп калган. Карт моны сизмәгән.

Балыкчы йортына кайтып җиткән. Чанасын карамыйча, өенә ашыгып кергән дә:

— Карчык, мин сиңа бик шәп якалык алып кайттым. Бар, чыгып кара: чанада балык та күп, якалык та бар, — дигән.

Карчык чыгып караса, балык та, якалык та булмаган.

Төлке юл буе ташлап калдырылган балыкларны җыеп алган да утырып ашый башлаган. Шул чагында аның янына бер Бүре килеп чыккан.

— Исәнме, дускай? — дигән.

— Бик яхшы, — дигән Төлке.

— Миңа да балык бирче!

— Үзең тот!

— Мин тота белмим шул.

— Су буена бар да койрыгыңны бәкегә тыгып тор. Балык үзе койрыгыңа ябышыр. Ләкин бик озак утыр, яме! — дигән Төлке.

Бүре, елга буена барып, бәкегә койрыгын тыгып, төн буе утырган.

Кышның бик салкын көннәре була. Бүренең койрыгы бәкегә ябышып ката. Ул урыныннан кузгалып китмәкче булып карый, әмма койрыгын боздан кубарып ала алмый. Ул эченнән генә: «Уй-уй, бик күп балык эләккән икән», — дип уйлый.

Таң аткач, хатыннар суга килә башлаганнар. Алар, Бүрене күреп: «Бүре бар, Бүре!» — дип кычкырырга тотынганнар. Алар, барысы бергә җыелып, кайсы көянтә, кайсы таяк, кайсы башка нәрсә белән Бүрене кыйнарга керешкәннәр.

Бүре, сикергәли торгач, койрыгын өзеп, артына да карамыйча, урманга чапкан.

## Конфет ашап, тамак туямы?

*(Корея халык әкияте)*

Көннәрдән бер көнне ярлы агай базарга юл тоткан. Тамагы бик тә ачыккан икән моның. Базарга килеп җитүгә үк, ул дөге көлчәсе сатып алган. Көлчәне ике капкан да бер йоткан, ә тамагы һаман ач икән.

Аннары агай пешкән бәрәңге сатып алган. Әмма аны ашагач та тамагы туймаган. Инде нишләргә? Уйлаган-уйлаган да калган акчасына шикәр белән дөгедән ясалган иң очсызлы конфет сатып алган. Шуны ашавы булган, кинәт кенә тамагы туйган, ди, моның. Шулчак аптыраудан ул, шап итеп, учы белән маңгаена суккан да болай дигән:

— Әй, ахмак та инде мин! Әллә нинди көлчәләр, пешкән бәрәңгеләр ашап бетердем. Юкка акча әрәм иттем. Башта ук конфет алсам, тамагым шундук туйган булыр иде!

Көлчә белән бәрәңге ашап корсагы тулганны һич кенә дә аңламый икән бит бу ахмак бәндә.

Конфет ашап, тамак туймаганны аңламаган кеше тагын кайда бар икән, ә?

## Комсызлык бәласе

*(Венгр халык әкияте)*

Ике аю баласы бер баш сыр тапканнар. Алар бу сырны бүлә алмый аптырап беткәннәр. Ничек сындырсалар да, сыр тигез булмас төсле күренгән аларга.

— Бирегез, үзем бүлеп бирим, — дигән Төлке аю балаларына һәм сырны икегә сындырган.

— Берсе зур, берсе зур! — дип кычкырышканнар аю балалары.

Төлке аларны тынычландырган: хәзер тигезлим, янәсе.

Ул сырның зур ягыннан беркадәр сындырып кабып җибәргән. Сырның тегесе зуррак күренгән. Аю балалары, ризасызлык белдереп, тагын шаулашканнар: тагын тигез түгел, диешкәннәр.

Төлке аптырап калмаган. Зуррак дигәнен тагын сындырып капкан. Сыр кисәгенең әле берсен, әле икенчесен ашый-ашый, Төлке тәмам сырдан туйган. Ә баш чаклы зур сырдан тора-бара кеп-кечкенә кисәкләр генә калган.

— Кечкенә булса да тигезләр! — дигән Төлке, шаркылдап көлеп. — Ашагыз, тәмле булсын!

Шулай дигән дә чабып киткән. Аю балалары авызларын ачып карап калганнар.

Комсызлансаң, һәрвакыт шулай була икән.

## Күбәләкләр ничек килеп чыккан?

*(Филиппин халык әкияте)*

Яр буенда зур бакча үскән. Мондагыдай гаҗәеп чәчәкләр Җир йөзендә башка булмаган. Аның хуҗасы киң күңеллелеге һәм юмартлыгы белән дан тоткан, килгән кешеләргә чәчәкләр бүләк итәргә яраткан. Ләкин бер шарт белән: чәчәкне ул үзе өзеп бирергә тиеш.

Бервакыт бакчага чит кешеләр кергән. Алар, бик матур киенгән чибәр кешеләр булса да, игелекле булмаганнар. Матур чәчәкләрне күреп өзә башлаганнар. Өзәләр-өзәләр, туктала алмыйлар икән...

Моны күреп, бакча хуҗасының ачуы чыккан. Кесәсеннән бамбук таягы чыгарып, әлеге тәкәббер кешеләргә орынган. Ул тылсымчы булган һәм могҗиза барлыкка клгән. Бу кешеләр кимегәннән-кими башлаганннар.

— Моннан соң сез күбәләкләр булырсыз. Сез матур киемнәр яратасыз. Сезнең канатларыгыз сезне бизәп торыр. Сезгә минем чәчәкләр ошый бит. Алар өстендә очып йөрсәгез, беркайчан да өзә алмассыз, — дигән ул.

## Әтәч һәм Бөркет

*(Тибет халкы әкияте)*

Элек Әтәч һәм Бөркет дуслар булалар. Ничектер шулай кич алар трактирга керәләр, тәмле ашап-эчәләр. Инде китәргә җыенгач кына, ашаган өчен түләргә акчалары булмавы ачыклана. Бөркет, акча алу өчен очып кайтып килгәнче, Әтәчкә калып торырга киңәш итә.

— Ярый, әмма тизрәк әйләнеп кайт, — ди аңа Әтәч. — Югыйсә ачуланырмын. Әгәр өч мәртәбә «кикрикүк» дип кычкыруымны ишетсәң, бу минем ачулана башлавымны аңлатыр.

Әтәч Бөркетне озак көтә, инде таң да атып килә, ә Бөркет һаман юк та юк. Әтәч өч тапкыр «кикрикүк» дип кычкыра, әмма

Бөркет пәйда булмый. Шул көннән башлап, Әтәч кешеләр янында кала һәм һәр иртәдә өч мәртәбә кычкыра — Бөркетне чакыра.

## Бөдрә чәчле кыз

*(Чукот халык әкияте)*

Аю белән Төлке яр буенда балык тотып утыралар икән. Болар янына тузган чәчле бер кызчык килеп туктаган. Төлке:

— Һай, балыкларны качырып бетерә инде бу, — ди һәм кызчыкны үзләре яныннан куып җибәрмәкче була.

— Чәчеңне дә тарамагансың, кит моннан! Шапшак!

— Курыкма. Бөдрә чәчле бу кызчык бик акыллы!

Уйнап йөри торгач, кызчык туңа башлый. Аю, өстеннән тунын салып, кызга киерткән дә:

— Ах, нинди матур! Нәкъ тә минем кызым кебек! — дип сок-ланып бетә алмый икән.

Бераздан кызчык өенә кайтып китә һәм әнисенә барысын да сөйләп бирә. Аюны кунакка чакыралар. Кунак озак көттерми, килеп тә җитә. Түр башына утырып, чәй эчә, туйганчы балык ашый, өстәвенә тәмле-томлыны биреп тә җибәрәләр моңа.

Менә Аю алпан-тилпән кунактан кайтып килә. Берзаман күтәрелеп караса, каршысында Төлке тора.

— Шулкадәр балыкны кайдан алдың? — ди ул.

— Бөдрә чәчле кызчык бирде.

Төлке шунда йөгерә. Килсә — ишек бикле.

— Бөдрә чәч, ач ишегеңне! Балык бир миңа! — дип ялына Төлке. Бөдрә чәчле кызчык эндәшми дә икән. Төлкенең, кычкыра-кычкыра, тамагы карлыгып бетә. Нишләсен, ишек төбендә тора-тора да кире китәргә мәҗбүр була ул. Аңа балыкның койрыгы да эләкми.

## Тавык белән Сарык

*(Болгар халык әкияте)*

Бер Тавык беркөнне күкәй салып төшкән дә кытакларга, мактанырга тотынган:

— Һәммәгез дә тизрәк минем янга килегез! Карагыз нинди матур, нинди ак күкәй салдым! — дигән.

Ә аның янында кечкенә кара бәрәне белән тыйнак кына бер Сарык ята икән. Ул бернәрсә дә дәшмәгән. Тавык аның яныннан горур гына үтеп киткән һәм:

— Нигә син минем матур ак күкәемне килеп карамыйсың? Син андый күкәйне сала да алмыйсың бит! — дигән.

— Хуҗаларга һәркем үзе булдыра алганча файда итә, Тавык сеңелкәш. Син аңа күкәй салып бирдең, ә мин бәрән китердем. Ләкин мин моның белән бер дә мактанмыйм.

— Сөйләдең сүз, минем күкәем кыйбатмы да, синең бәрәнең кыйбатмы! — дигән Тавык.

— Әнә безнең хуҗа килә — аннан сорыйк.

Хуҗа бәхәснең нәрсә турында барганын аңлап алган да Тавыкка:

— Нигә син дөнья бетереп кытаклыйсың? — дигән. — Күкәй салдым дип мактанасыңмы? Бер бәрәнгә синеке шикелле ике йөз күкәй алып була! Үзең уйлап кара: әгәр син бер күкәй өчен шулкадәр зур тавыш куптаргач, бәрән кадәр бәрән китергән Сарыкка нишләргә кала?

## Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау

*(Абхаз халык әкияте)*

Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау көтүдән аерылып калдылар һәм урманда адаштылар. Алар агачта төн үткәрергә уйладылар. Кәҗә бәтие һәм Бәрән агачка тиз үрмәләп менделәр һәм Бозауны да сөйрәделәр. Алар арасында иң ипсезе булган Бозау агач ботагында көчкә-көчкә генә тотынып торды.

Шул вакытта Аю, Бүре һәм Төлке аларның эзләрен иснәнеп таптылар һәм агачка кадәр килеп җиттеләр. Шулчак Бозау ычкынып китте һәм аска таба очты. Ләкин Кәҗә бәтие югалып калмады һәм:

— Әйдәле, Аюны тот, мин Бүренең кирәген бирермен, ә Төлкене исә безнең кече туганыбыз өзгәләп ыргытыр, — дип кычкырды.

Һәм Кәҗә бәтие бөтен көченә мөгезләре һәм тояклары белән агачка бәрә башлады. Җәнлекләр агач башына куркыныч ерткычлар утырганнар дип куркуга төштеләр һәм качып киттеләр.

## Керпе туны

Борын-борын заманда Җир йөзендә бөтенләй кыш булмаган, гел җәй генә патшалык иткән. Болыннар шау чәчәккә чумып, агачлар мул җимештән сыгылып утыра икән. Кояш туры карагач, җәнлек-җанварлар да көлмәкчән генә йөргән, ди.

Бервакыт «Кыш килә!» дигән хәбәр таралган. Кыш үзе дә озак көттермәгән, суык җилләр исә башлаган, кар төшкән. Җәнлек-җанвар бик аптыраган — нишләргә? Урман хуҗасы Аюхан күп уйлап тормаган, ерак таныш-белешләреннән барлык җәнлекләргә дә тун тектерергә җитәрлек тире кайтарткан.

Ул чакта Керпе тегүче булып эшләгән, ди. Аның бик күп энәләре булган. Тотынган бу менә шул энәләре белән җәнлекләргә тун тегәргә. Кыш килеп җиткәнче, һәммәсен дә тунлы иткән бит! Караса, үзенә тун тегеп киярлек тире дә калмаган. Шуннан соң Керпе күлмәгенә энәләр кадап чыккан да тунлы булган. Әмма аның туны салкын җилләрдән саклamaган шул...

Керпе, салкынга түзә алмыйча, җирне тишеп, өн ясаган да шунда кереп яткан. Салкын кыш үтеп киткәнче, өнендә йоклаган.

Бу хәлдән соң күпме заманнар узган инде. Әмма Керпе әле һаман да салкын кышларны өнендә үткәрә, ди.

*Хәйдәр*

## Шифалы сөт

Куян баласы кичкә таба авырып киткән. Әнисе табиб Керпегә йөгергән.

— Керпекәем, апакаем, балама әллә нәрсә булды, нишләргә дә белмим, — дигән.

Керпе, Куян баласын карагач, болай дигән:

— Терелсен дисәң, кайнаган сөт эчер.

Куян шөбһәгә төшкән. «Кайнаганы түгел, кайнамаганы да юк бит әле аның», — дип уйлаган.

Киткән бу, елый-елый, урман буйлап. Каршысына Саескан очраган.

— Нигә елыйсың, берәр кайгың бармы әллә? — дип сораган.

— Ничек инде еламыйсың? Сабыем үләргә ята. Табиб Керпе кайнаган сөт эчерергә кушты, каян табарга да белмим, — дигән Куян.

— Бар өеңә кайт, сабыең янында утыр, мин сиңа сөтне үзем табармын, — дигән Саескан.

Куян кайтып киткән. Саескан Сыер янына килгән.

— Сыеркаем, матуркаем, бераз гына сөт бир әле, — дигән.

Сыер әйткән:

— Бик бирер идем дә, хуҗа хатын әле генә сөтемне базарга чыгарып сатты, иртән кил, — дигән.

— Иртәгә кадәр Куян баласының үлүе бар шул, — дигән Саескан.

— Ярар, алайса, — дигән Сыер. — Хәзер сөт җыеп карыйм.

Шуннан болынга чыккан, күп итеп үлән ашаган, җилененә сөт төшкән. Саескан җитәрлек кадәрле сөт савып алган һәм Куян янына кайтып киткән. Куян сөтне кайнаткан, баласына эчергән, баласы терелгән.

*Сәмига Сәүбәнова*

## Кыңгырау чәчәк

Яшел нарат урманында, аның иркен аланында бик нәфис, бик назлы бер Кыңгырау чәчәк үсеп чыккан.

— Абау ла, бигрәк матурсың! Исәнме, Кыңгырау чәчәк! Бик тә ошыйсың син миңа. Әйдә, икәү дус булабыз! — дигән Куян баласы.

— Дус булабыз? Ә ничек була соң ул дус булу? — дип сораган Кыңгырау чәчәк.

Ул бит әле яңа гына туган булган, шуңа күрә дуслыкның нәрсә икәнен белмәгән.

Урман ягыннан бер Малай килеп чыккан. Килеп чыгуга ук, ул:

— Күр инде, нинди матур чәчәк! — дип, Кыңгырау чәчәкне өзәргә кулын сузган.

Әмма кулын сузуы булган, шунда ук ялт иттереп тартып алган. Кемдер авырттырып тешләп алган икән аның кулын. Караса, кечкенә генә Куян баласы.

— Тимә Кыңгырау чәчәккә! Ул — минем дустым! — дигән Куян баласы, малайга ачу белән карап. — Кит, кагылма аңа! Кыңгырау чәчәкне өзәргә ярамый.

— Ә! Мин белдем! Белдем дуслыкның нәрсә икәнен! — дип, шатланып чыңлап куйган шулчак Кыңгырау чәчәк һәм талгын җилдә әкрен генә зәңгәр башын чайкый-чайкый җырлап җибәргән:

Дуслык ул — яхшылык,
Дуслык ул — яктылык.
Дуслык ул кояштай нур чәчә.
Син мине саклаучы,
Яшәүне яклаучы,
Яшә син, Куян дус,
Мең яшә!

*Резеда Вәлиева*

## Чуар тавык

Чуар тавык оясыннан җиргә сикереп төште дә:

— Коорт-корт! Әйдәгез, киттек, киттек! — дип, чебешләрен йөрергә чакырды. Аның сап-сары мамык йонлы чебешләре, бәләкәй генә канатларын җилпи-җилпи, башта оя читенә очып менделәр, аннан җиргә төштеләр. Очып төштеләр дә, тәгәрәп йөргән яшел туп кебек, үлән арасына сибелделәр.

— Пи-пи! Пи-пи! — дип, йөгерешеп уйнарга керештеләр. Йомшак үлән очларын нәни томшыклары белән керт-керт иттереп өзеп алдылар.

— Корт-корт!.. Миннән ерак китмәгез, ерак китмәгез! — диде аларның әнкәләре Чуар тавык. Шулвакыт аның янына кызыл кикрикле Әтәч килде дә исәнләште:

— Ко-око-ко! Исән генә тордыңмы, кодача? Ничә чебеш чыгардың? — диде.

— Корт-корт! Ундүрт, ундүрт! — диде Чуар тавык.

Әтәч моңа бик шатланды. Ул, канатларын җилпеп, койма башына сикереп менде дә башын югары күтәреп, кагына-кагына кычкырды:

— Кикрикүк! Кикрикүк!

Чуар тавык, аның тавышына сокланып:

— Корт-коооорррт! Ко-ко-ко-ко! — дип торганда, аның чебешләре:

— Чи-и-и-и-и, чи-и-и-и! — дип чыелдаштылар. Оялары янына йөгерделәр, ләкин анда да тынычлана алмадылар. Алар янына усал песи Мырмыр килгән иде. Ул чебешләр өстенә ташланырга әзерләнеп, яшел күзләрен ут кебек ялтыратып тора иде. Чуар тавык, канатларын кабартып, очына-очына барып, аның өстенә ташланды:

— Куррр, куррр! Кит моннан, юньсез Мырмыр! — диде ул. Песи, сыртын дугаландырып, арт тәпиләренә басты да алгы тәпиләрен югары күтәреп, без кебек очлы тырнакларын тырпайтып, әче итеп кычкырды:

— Мыррау-мырррауууу!

Ул тавыкка таба сикерде. Чуар тавык аның мыраулавыннан бер дә курыкмады:

— Син миңа каршы торасыңмы әле, Мырмыр? Мин сиңа кирәгеңне бирим әле менә! — диде дә, канатларын җилпи-җилпи очып барып, үткен томшыгы белән аның колак төбен чукып алды, башына канатлары белән уңлы-суллы сукты... Песи моңа чыдамады, үртәлә-үртәлә качып китте. Ә Чуар тавык, усал песине җиңеп, үзенең газиз балаларын саклап калгач, бик шатланып җырлап җибәрде:

— Куррр, куррр!

Чебешләре, сары туп кебек тәгәрәшеп, аның янына йөгереп килделәр. Алар:

— Пи-пи-пи-пи-пии! — дип, чәрелдәшеп, әнкәләренең җылы канаты астына җыелыштылар һәм тынычлап йоклап киттеләр.

*Гариф Гомәр*

## Аю Әппәс

Бер бәләкәй аю баласы яши икән урманда. Бәләкәй генә булса да, бу аю баласы бик эшчән булган, ди. Бу аю баласының исеме Әппәс булган. Әппәс яз көне бакча казыган. Бер түтәлгә кишер чәчкән. Кәбестә дә утырткан. Бер түтәлдә чөгендер үстермәкче булган Әппәс. Кыяр да утырткан. Помидор белән шалкан да үстергән ул.

Көз җиткән. Яшелчәләр өлгергән. Бәләкәй аю кишерне дә алган, кәбестәне дә, чөгендерне дә алган, кыярны да җыйган, шалканны да йолыккан. Йолкып алган да чишмә суында юып ашый да башлаган.

— Мәм-мәм-мәм, баллы, тәмле, татлы мәми! — дип сөйләнә икән үзе.

Шулчак Куян узып бара икән. Куянның шулкадәр ашыйсы килә икән.

— Аю Әппәс, бир әле миңа да тәмле әйбер! — дигән Куян.
— Мә! — дигән аю баласы.
Куянга бер кишер, бер кәбестә, бер чөгендер, бер кыяр, бер помидор, бер шалкан биргән.
— Мәм-мәм, баллы икән болар! — дигән Куян. — Рәхмәт, синңа, Әппәс, рәхмәт.
Шулчак Керпе килеп чыккан.
— Мә! Син дә авыз ит! — дип, Әппәс Керпегә дә яшелчә биргән.
— Мәм-мәм, татлы икән болар! — дигән Керпе. — Рәхмәт синңа, Әппәс!
Шулчак Тиен килеп чыккан.
— Тиен, син дә аша баллы яшелчә! — дигән аю баласы.
Аю урмандагы барлык киек-җәнлекләрне сыйлаган. Барысы да Әппәскә рәхмәт укыганнар.

*Батулла*

## Бикбатыр белән Биккуркак

Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, агач кайрысы кимергән, песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән. Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа теге бала Бикбатыр дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрли икән, аны ул Биккуркак дип атаган.
Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән. Куркуыннан куян нишләргә дә белмәгән, баскан урыныннан кузгала да алмаган. Ярый әле, Бикбатыр килеп җиткән һәм Биккуркакка бераз көч кергән: «Әй юләр, юләр, дигән, үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич», — дигән. Биккуркактан бик көлгән. «Ярый әле, син килдең, Бикбатыр, куркуымнан мин үлгән булыр идем», — дигән куян.
Икенче бервакытны куян тагын куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп итеп типкән, нәрсәдер бик нык кыштырдый

икән. «Хәзер идән астыннан чыга да инде кыштырдаучы. мине кабып йота», — дип уйлый икән куян. Песи дә колакларын торгызган. «Ул да курка, ахры», — дип уйлаган куян. Шулчак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян хушсыз була язган. Ә песи, авызына нәрсәдер кабып, куян янына килгән. Килгән дә: «Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде», — дигән, бер кечкенә генә кара әйберне куянга күрсәткән. «Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы?» — дип, Тычканга куян гаҗәпләнеп караган.

Өченче тапкыр ачык ишектән өйгә бер Эт килеп кергән һәм каты итеп өрергә керешкән. Куян карават астына кереп качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан да, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан, Эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган. Билгеле, Эт аңа кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган. Ә Бикбатыр үзенең батырлыгы аркасында бу бәладән бик оста котылган.

*Абдулла Алиш*

## Койрык

Яшәгән, ди, бер тычкан малае, исеме Пи-пи икән моның. Шул тычкан малае көннәрдән бер көнне бакчада шалкан тапкан. Шалканның койрыгы бар икән. Ул койрык бик озын, матур, сыгылмалы булган.

— Менә ичмаса бу койрык дисәң дә койрык! Мондый койрыгым булса, мин бөтен тычкан малайларыннан уздырыр идем. Минеке шикелле койрык бүтән беркемдә дә булмас иде! — дигән Пи-пи.

Тычкан малае үз койрыгын ташлаган да, аның урынына шалкан койрыгын тагып, урамга чыккан. И-и мактана, ди, бу яңа койрыгы белән! Койрыгын, чыбыркы шикелле шарт та шорт китереп, уңга да селки, сулга да селки икән.

Башка тычкан малайлары аннан:

— Каян алдың мондый тәмле исле койрыкны? — дип сораганнар.

— Бу тәмле исле койрык түгел, бу — иң яхшы койрык! — дигән Пи-пи һәм өйләренә кайтып киткән дә, кояш чыккач, йокларга яткан.

Төн җиткәч, Пи-пи уянган. Уянгач ашыйсы килгән. Шунда борынына шалкан исе кергән. Караса, янында гына бик тәмле шалкан койрыгы ятканын күргән. Түзмәгән, бик рәхәтләнеп, тамагы туйганчы ашаган да ашаган.

Бервакыт караса, шалкан койрыгы да юкка чыккан, үз койрыгы да калмаган.

*Әхәт Гаффар*

## Җил белән Кояш

Бервакыт Җил белән Кояш икәү бәхәсләшкәннәр. «Кайсыбыз кешенең киемен салдыра ала?» — дигәннәр.

Җил, бар көченә исеп, кешенең киемен салдырырга теләгән. Җил ныграк искән саен, кешенең киеме тәненә ныграк ябыша бара икән. Җил булдыра алмаган.

Менә бервакыт Кояш күтәрелгән. Баягы кеше Кояшның кыздыруына чыдый алмыйча чишенгән дә, киемнәрен култык астына кыстырып, ялангач китеп барган.

*Габдулла Тукай*

## Комсыз эт
*(Мәсәл)*

Авызына сөяк капкан бер эт, күпердән чыкканда, суда үзенең шәүләсен күрде. Үзе кебек, ул эт тә авызына сөяк кабып йөгереп бара икән. Ләкин аңа судагы этнең сөяге зуррак кебек күренде. Шунлыктан үзенең авызындагы сөякне суга төшерде, үзе дә, суда күренгән эт авызындагы сөякне алмакчы булып, суга сикерде. Ләкин ул арада инде авызындагы сөяге дә су төбенә киткән иде.

*Каюм Насыйри*

## Кырмыска белән күгәрчен

*(Мәсәл)*

Кырмыска, су эчәргә дип, чишмәгә килә. Дулкын аны, эләктереп алып, суга чак батырмый кала. Күгәрчен бер чыбык күтәреп бара икән, кырмысканың батканын күреп, ул чыбыкны чишмәгә ташлый. Кырмыска чыбыкка менеп утыра һәм котылып кала.

Моннан соң бер аучы, күгәрченне тотам дип, җәтмә кора. Кырмыска үрмәләп килә дә аның аягын тешләп ала — аучы, «эх» дип куя һәм җәтмәсен ташлый. Күгәрчен канат кагып очып китә.

*Лев Толстойдан*

## Зирәк чәүкә

Бер чәүкәнең эчәсе килгән. Ул бер ишегалдында тар авызлы чүлмәк белән су күргән. Су чүлмәкнең төбендә генә икән. Чәүкәнең суга буе җитмәгән. Шуннан ул чүлмәк эченә вак ташлар тутыра башлаган. Таш тутыргач, чүлмәк төбендәге су өскә күтәрелгәч, чәүкәгә эчәргә уңайлы булган.

*Лев Толстойдан*

## Төлке белән Кысла

Төлке Кыслага әйтә:

— Әйдә, чабышабыз! — ди.

— Әйдә, чабышабыз! — ди Кысла да.

Чабышып китәләр.

Төлке алдан чабып китә, ә Кысла аның койрыгына ябыша.

Төлке билгеләнгән урынга барып җитә дә борылып карый, койрыгын селкеп куя, ә Кысла койрыктан ычкынып төшә дә Төлкегә әйтә:

— Мин сине монда күптән көтәм инде, — ди.

*Лев Толстой*

## Куян белән Керпе

Ап-ак шоп-шома йонлы Куян бервакыт Керпегә болай дигән:

— Ай-һай, ямьсез дә соң синең кадала торган туның, энекәш.

— Дөрес, — дигән Керпе, — ләкин минем энәләр мине этләрдән дә, бүреләрдән дә коткара. Синең матур тирең сине дә шулай дошманнарыңнан саклый аламы соң?

Куян җавап урынына тирән итеп сулап кына куйган.

*Константин Ушинский*

## Хайваннар бәхәсе

Сыер, Ат һәм Эт, хуҗа кайсыбызны ныграк ярата дип, үзара бәхәсләшеп киткәннәр.

— Билгеле, мине ярата, — дигән Ат, — мин аның җирен сукалыйм, тырмалыйм, урманнан утын ташыйм, миңа утырып, шәһәргә бара. Миннән башка әллә кайчан харап булыр иде инде ул.

— Юк, хуҗа мине ныграк ярата, — дигән Сыер, — мин аның бөтен семьясын сөт белән туйдырам.

— Юк, мине, — дигән Эт, — мин аның йортын саклыйм.

Хуҗа бу бәхәсне тыңлап торган да шулай дигән: «Юкка бәхәсләшеп тормагыз, сезнең барыгыз да миңа кирәк, сезнең һәрберегез үз урынында яхшы».

*Константин Ушинский*

## Тавык һәм үрдәк бәбкәләре

Бер хатын үрдәк асрамакчы булган. Үрдәк йомыркалары сатып алган да аларны тавык астына куйган һәм үрдәк бәбкәләре чыгуын көтә башлаган.

Тавык йомыркалар өстендә утырган да утырган, җим чүпләргә генә чыккан да тагын тизрәк оясына кереп урнашкан.

Менә бервакыт тавык үрдәк бәбкәләре утырып чыгарган, бик шатланган һәм, кырт-кырт килеп, ишегалды буенча бәбкәләрне ияртеп йөри башлаган, җирне тырнап, аларга азык эзләгән.

Бервакыт тавык, ничектер, үзенең бәбкәләре белән ишегалдыннан чыгып киткән дә буа янына килеп чыккан. Бәбкәләр, суны күрү белән, берсе артыннан берсе, йөгерешә-йөгерешә, буага кереп киткәннәр һәм йөзә башлаганнар. Мескен тавык яр буенда әрле-бирле йөгергән, кычкырып караган, батарлар дип куркып, бәбкәләрне үз янына чакырган.

Ә бәбкәләр рәхәтләнеп суда йөзгәннәр, чумганнар, яр буена чыгарга уйлап та карамаганнар. Теге хатын тавыкны су буеннан көчкә генә куып җибәрә алган.

*Константин Ушинский*

## Шапшакларны бака ялый

Мөбарәкша манный боткасы ашап утыра икән. Үзе алак-ялак карана. Күке кычкырса, сәгатькә карый. Песи мияулап урындыктан сикереп төшсә, Мөбарәкша песигә карый. Абыйсы телевизор кабызса, Мөбарәкша телевизордан күзен алмый.

— Алдыңа гына карап аша, улым! — диде әнисе Мөбарәкшага. — Әнә тагын түшеңә тамызгансың. Эчкән сөтең дә, ашаган боткаң да күлмәгеңә җыела бит.

Мөбарәкша түшенә тамган сөтне, ботканы кулы белән сыпыра. Сыпырган саен, күлмәк карала бара.

— Һи-и, Мөбарәкша улым, — диде әнисе. — Күлмәгеңне пычратып бетергәнсең бит. Әнә түшең каткан. Битең пычранган. Алай ярамый.

— Нигә алай ярамый? — ди Мөбарәкша.

— Түше каткан малайлар, бите шапшаклар янына төнлә бака килә икән. Бака килә икән дә пычранган җирләрне ялый икән. Йоклаганда, синең дә битеңне бака ялап китәр инде.

Мөбарәкша ашап туйгач, әнисе аның өстен алыштырды, чиста күлмәк кигезеп, битен-кулын юдырып, йокларга яткызды. Мөбарәкша, йокламаска тырышып, төн уртасына чаклы бака килгәнне көтте. Күпме генә көтсә дә, аның битен яларга бака килмәде. Белгәндер ул бака, Мөбарәкшаның бите чиста икәнен белгәндер. Шуңа килмәгәндер.

*Батулла*

## Балалар бакчасында

Наилә әле мәктәпкә йөрми. Балалар бакчасына гына бара. Аны бакчага иртән әтисе илтеп куя, кичен әнисе алып кайта. Кайтканда, алар бик матур итеп сөйләшеп кайталар. Әни белән кыз бик дуслар, бер-берсеннән берни яшермиләр. Көннәрдән бер көнне әнисе Наиләдән сорап куйды:

— Кызым, тәтием, син бүген бакчада матур апалар биргән ризыкларның барын да ашадыңмы соң?

— Әйе, ашадым.

— Берни дә калдырмадыңмы, кызым?

— Юк, юк, әнием.

— Ярар, матурым. Син алдашмыйсың бит. Ә шулай да иртәгә тәрбияче апаңнан сорармын әле.

— Сора, сора, әнием, — диде Наилә. — Тик ашны гына сорама, яме.

*Әнәс Хәсәнов*

## Эшче абый

Люция бар нәрсәне дә белергә тырыша. Аның бер белгән соравы бар: «Кем ясаган да, кем ясаган?»

Менә бүген дә, киез итекләрен кия-кия, әтисеннән сорады:

— Әти, киез итекләрне кем ясаган?

— Эшче абыең баскан, кызым. Балаларның аяклары туңмасын, дигән.

— Ә бүрекне кем ясаган?

— Эшче абыең теккән, кызым. Салкында балаларның колаклары өшемәсен, дигән.

— Бияләйләрне дә ул ясаганмы, әти?

— Әйе, бияләйләрне дә ул бәйләгән.

Менә алар урамга чыктылар. Люция бу вакыт һәрнәрсәне дә эшли белә торган эшче абый турында уйлый. Әнә бит ул бар нәрсәне дә балалар өчен эшли. Балалар эшче абыйны бик ярата торганнардыр. Люция дә аны бик ярата.

Люция уйланып барганда, чеңгел-чеңгел итеп, трамвай үтеп китте.

— Трамвайны да ясаганмы? — дип сорады Люция.

— Әйе, трамвайны да эшче абыең ясаган, менә бу зур йортларны да ул салган, юлларны да ул төзегән.

— Әти, минем эшче абыйны күрәсем килә. Ул кайда була?

— Һәркайда бар ул, кызым, — диде әтисе.

— Юк, ул бер генә була, — диде Люция.

— Эшче абыйлар бик күбәү, — диде әтисе. — Мин үзем дә эшче.

Кечкенә кыз рәхәтләнеп көлде.

— Юк, эшче абый мондый булмый, син әти ич! — диде ул.

Люция, зур булгач, эшче абый кебек булу, бар нәрсәне дә эшли белә торган кеше булу турында уйлана иде.

*Абдулла Алиш*

## Ботка

Кичә Фәрит КамАЗ машинасы белән балчык ташып уйнады. Бик нык арыган иде, аяк-кулларын юып тормады, шул килеш ятып йоклады. Төшендә карабодай боткасы күрде. Ул зур табакта иде. Уртасындагы чокырына сап-сары май салынган, өстеннән хуш исле бу күтәрелә. Фәрит карабодай боткасын бик ярата, әнисе аны пешереп кенә тора. Аның авызыннан сулар килде. Капмакчы гына булган иде — кашыгы юк икән.

Шкафтан кашык алып килгәнче, боткадан җилләр искән. «Их, кул белән генә ашыйсы калган икән», — дип кайгырып торганда уянып та китте.

Бүген Фәрит караңгы төшкәнне түземсезлек белән көтте. Кич җиткәч, әбисенең чәйгә сөт сала торган зур агач кашыгын алды. Ул шундый матур, сарылы-кызыллы бизәкләре елык-елык килеп тора. Фәрит кашыкны, беркемгә дә күрсәтмичә, күлмәк эченә тыкты да караватына барып ятты. Өстенә юрган ябынды, күзләрен йомды.

Ул унбиш минут, ярты сәгать, бер сәгать ятты — күзенә йокы кермәде. Күпме генә ятса да йоклый алмады. Түзде, түзде дә, ахырда ялынып:

— Ботка, кил, минем тәти кашыгым бар! — диде.

Шулчак әнисе йомшак куллары белән аның аркасыннан сөйде һәм, шундый ягымлы, шундый тәмле итеп:

— Йокла, улым, йокла, — диде.

Фәрит ничек йоклап киткәнен дә сизмәде.

Иртән торгач, шатлыгыннан ул чак кычкырып җибәрмәде: өстәл уртасында, буларын бөркеп, карабодай боткасы тора иде. Фәрит күлмәк эченнән тәти кашыкны алды да боткага үрелде.

— Улым, юынмыйча ашарга утырган кешене ризык яратмый, — диде әнисе.

Фәрит кичә кул-аякларын юмый ятканлыгын исенә төшерде. Һәм төшендә ботканың ни өчен үзеннән качуын аңлады.

Ул кашыгын куйды да яхшылап юынды, тешләрен чистартты, ботканы, тагын кача күрмәсен дип, ике мәртәбә карап килде. Әнисе тәти кашыкны да юып куйды. Ул арада әбисе белән бабасы, әтисе белән әнисе, абыйсы белән сеңлесе дә өстәл янына тезелешеп утырдылар. Һәммәсе дә, Фәриткә карап, серле елмайды. Күрәсең, бөтенесен дә тәти кашык кызыктырды. Карабодай боткасы бик тәмле булды.

*Фоат Садриев*

## Бер әби

Урамнан бер кыз белән бер малай узып бара. Ә бераз алдарак бер әби бара. Аяк асты бик тайгак. Әби таеп китә дә егыла.

— Китапларымны тотып тор әле! — ди малай һәм кызга сумкасын бирә дә әбигә ярдәмгә ашыга.

Ул кире борылып килгәч, кыз аңардан:

— Әллә ул синең әбиеңме? — дип сорый.

— Юк, — дип җавап бирә малай.

— Әллә әниеңме? — дип гаҗәпләнеп сорый иптәш кызы.

— Юк!

— Алайса, апаңдыр? Я булмаса берәр танышыгызмы?

— Юк ла инде, юк! — дип елмая малай. — Бер әби шунда!

*В. Осеева*

## Тәмле сүз

Минем әбиемнең һаман әйтә торган сүзе бар. Ул безгә һәрвакыт:

— Балакайларым, тәмле телле, тәмле сүзле булмасагыз, үзегезне беркем дә яратмас, — ди.

Тик мин башта бу сүзне бер дә аңлап җиткерми идем. Ничек инде сүз тәмле була ала икән?.. Ул бит конфет та, прәннек тә түгел. Аны ашап карап булмый ич. Мин үзем белгән сүзләрне әйтеп карыйм: «Әти, әни, күмәч, ипи, бир, кил, кит, матур, кечкенә, зур, акыллы, ал, кызыл, зәңгәр, ат, сыер, кәҗә...» Сүзләр бик күп инде ул. Зур үскән саен, сүзләрне дә күбрәк беләсең. Тик менә әбием әйткән сүз нинди була икән соң?

Менә беркөнне безгә кунак апа килде. Ул миңа бик матур курчак алып килгән. Мин, курчакны алгач: «Рәхмәт, апа», — дидем. Ул миңа: «Дәү үс», — диде. Шул арада минем янга иптәш кызым Рәйсә килеп керде. Минем кулымдагы курчакның матурлыгын күреп, Рәйсәнең исе китте. Чыннан да, курчагым бик матур. Күзләре зәп-зәңгәр, үзләре миңа карап торган шикел-

ле! Чәчләрен укучы кызлар кебек артка бәйләп куйган. Зәңгәр ефәк күлмәк кигән!

— Абау, Гөлкәй, курчагың бигрәк матур икән, — ди Рәйсә. Ә мин аңа:

— Матур шул, кунак апа китерде, әйдә, бергә уйныйбыз, — дидем. Шуннан соң без минем уенчыкларым торган почмакка бардык та уйный башладык. Ә бездән ерак түгел диванда әни белән кунак апа сөйләшеп утыралар. Үзләре, сокланып, безнең уйнаганны карыйлар.

— Кызың нинди үскән инде, — ди кунак апа. Әнием дә миңа елмаеп карый.

— Әйе, зур үсте. Бакчада өлкән группага йөри хәзер, — ди. Иптәш кызым Рәйсә минем курчакны алды да кечкенә урындыкка утыртты.

— Кит әле, шулай утырталармыни, юләр. Бир үзем утыртам, — дип, мин курчакны тартып алдым. Кунак апа да, әни дә ялт итеп безгә карадылар. Әйтерсең лә берәү матур чынаякны төшереп ватты. Аларның йөзләре шундый күңелсез булып китте. Кояш батып, болыт каплаган шикелле, йөзләрендәге елмаю бөтенләй юкка чыкты.

— Абау, нинди сөйләшү бу?! Иптәш кызларың белән шулай тупас сөйләшергә ярыймыни? Кит әле, юләр, имеш. Ә син миңа курчак өчен рәхмәт әйткәч, мин сине тәмле телле дип уйлаган идем, — ди кунак апа. — Ә син шундый тәмсез телле дә буласың икән.

Әнием дә минем өчен оялды, ахры. Ул тиз генә минем ике кулымнан тотып алды да:

— Хәзер үк дустыңнан гафу үтен, — диде.

Мин иптәш кызымнан:

— Гафу ит, Рәйсә! — дип гафу үтендем. Хәзер инде мин тәмле телнең нәрсә икәнен беләм. Моннан соң беркем белән дә болай тупас сөйләшмәм.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Куян күчтәнәче, яки тешсез малай

Биш яшьлек Булат, әтисе белән әнисе эштән кайтып керүгә:

— Миңа бүген нәрсә алып кайттыгыз? — дип тинтерәтә.

Гадәттә, аңа чит ил сагызы яки конфет кирәк инде. Әтисе аны «куян күчтәнәче» дип атый. Ышанасызмы, юкмы — көн саен конфет суыра торгач, берзаман Булатның тешләре коела башлады!

Аны бар кеше дә: «Тешсез малай! Тешсез бабай!» — дип үчекли. Булат моңа бик тә гарьләнә, хурлана. Ә үзе һаман конфет сорый.

Шуннан соң Булатка көн саен «куян күчтәнәче» итеп кишер алып кайта башладылар. «Куян күчтәнәче» булгач, малай кишерне бик тәмләп ашый инде.

Берзаман, күпмедер вакыт узгач, Булатка яңа тешләр чыга башламасынмы! Ап-ак, энҗе кебек матур тешләр инде менә! Ә куяннар бик хәйләкәр икән бит ләбаса! Тешләре матур булсын дип ашый икән бит алар кишерне!..

Булатны хәзер бер кеше дә: «Тешсез малай! Тешсез бабай!» — дип үчекләми инде...

*Зиннур Хөснияр*

## Әби белән онык

Бер әбинең оныгы булган. Кечкенә кызчык йоклаган да йоклаган. Әбисе бөтен эшне үзе эшләгән: кызчык өчен икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

Тора-бара әбисе картайган. Ул мич башына менеп яткан. Инде хәзер әби йоклаган да йоклаган. Ул арада оныгы үсеп җиткән. Әбисенә ул икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

*Мәҗит Гафури*

## Начарлык

Эт ал аякларына чүгеп, котырынып-котырынып өрә. Аның алдында ук, коймага сыенып, йоннарын тырпайткан кечкенә песи баласы утыра. Ул авызын зур итеп ачып җибәрде дә кызганыч итеп мияулый башлады. Шунда, якында гына, нәрсә буласын көтеп, ике малай басып торалар иде.

Шул вакытта бер хатын тәрәзәдән башын тыгып карады һәм ашыгып, баскычка йөгереп чыкты. Ул этне куып җибәрде дә, малайларга ачуланып:

— Оят түгелме сезгә! — дип кычкырды.

— Ә нигә оят булсын безгә? Без бит тик кенә торабыз, — дип гаҗәпсенделәр малайлар.

— Менә бусы инде үзе начарлык! — диде хатын, ярсып.

*В. Осеева*

## ШИГЫРЬЛӘР

### Көз

Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

*Габдулла Тукай*

### Бу кайчак була?

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, —
Бу кайчак була?

*Габдулла Тукай*

### Көз

Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

*Кави Нәҗми*

### Яфрак бәйрәме

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыймын мин —
Кушыл син яңа җырга.

Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Көзнең матур чаклары.

Оча яфрак, уйный яфрак,
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

*Ләбиб Лерон*

## Бу кайчак, туган?

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран, —
Бу кайчак, туган?

*Габдулла Тукай*

## Кыш

Уянып бүген иртән
Карасам тәрәзәгә,
Ак сакаллы Кыш бабай
Кар алып килгән безгә.

Әйдәгез, тауга барыйк,
Чанада шуып калыйк.
Бер тузан юк, саф һава,
Җиргә ап-ак кар ява.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Кыш

Юеш көннәрдә
Зарыгып беттек.
Кыш бабабызны
Сагынып көттек.

Без нәниләрне
Кыш та сагынган,
Төнлә килеп ул
Карлар яудырган.

Кар яуган! Яуган
Мамык кебек кар,
Ап-ак булганнар
Урамнар, кырлар.

Бәскә төренгән
Агач башлары...
Бүгеннән безгә
Бәйрәм башланды!

Җыелып бергә,
Тауга чыгабыз,
Шаулашып, анда
Чана шуабыз.

Кычкырабыз без
Бергәләп: «На-на!»
Курыкмыйбыз һич
Чанабыз яңа.

*Әнәс Кари*

## Буран

Урамда буран,
Мин өйдә торам.
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам.

Әй, җил выжылдый,
Буран дуылдый.
Ачулы песи
Кебек мырылдый.

Җиңдем, ди, бугай,
Дуланып шулай.
Әй бичаракай,
Кыланма болай.

*Гомәр Толымбай*

## Шуабыз

Чанада да шуабыз,
Чаңгыда да шуабыз.
Тимераякта очабыз,
Чыңлап тора шома боз.

Тауларга да барабыз,
Кырларга да чыгабыз.
Кар-буран дип тормыйбыз,
Шуабыз да шуабыз.

*Нәҗип Мадьяров*

## Кошлар туйдырам

Җимлек ясап бирде миңа
Абыем Сәлим.
Шунда хәзер кошлар өчен
Җимнәр сибәм мин.

Ашап туйгач китә алар
Төрле якка.
Тик күгәрчен генә кала
Иң азакка.

Бире килә күк күгәрчен,
Песнәк һәм чыпчык.
Җыелалар бер-бер артлы,
Пыр-пыр очынып.

Ул да туйган, биегән күк
Уйнап йөри.
Миңа рәхмәт әйткән сыман:
«Гөлдергү», — ди.

*Әнәс Кари*

## Кыш бабай

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабай
тыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында —
Безнең апа башмагы.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Солдатлар

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

*Клара Булатова*

## Туган илнең улы мин

Бабайның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый
Ярамый —
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

*Роберт Миңнуллин*

## Бу кайсы вакыт?

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде;
Елап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт? —
Йә, әйтеп кара.

*Габдулла Тукай*

## Яз җитә

Кояш көлеп карый безгә,
Күзләр чагыла.
Елгалардан бозлар ага
Диңгез ягына.
Агачка кунып, чыпчыклар
Чыелдашалар,
Яшькелт-кара сыерчыклар
Әйй җырлашалар.

Яз, яз, яз җитә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып-тып итә
Эре-эре тамчылар.
Тиздән шаулап яфрак ярыр
Озын ак каен,
Ал чәчәкләр алып килер
Безгә май ае.

*Фатих Кәрим*

## Яз килә

Гөрләвек ага,
Кояш елмая,
Торналар үтте
Тезелеп бая.

Гөрләвекләрдә
Уйный үрдәк, каз.
Илне яшәртеп,
Шаулап килә яз.

*Нур Гайсин*

## Яз

Яз килде, кояш көлде,
Дөньяга нур бөркелде.
Уянды бар агачлар,
Куанды алмагачлар.

*Резеда Вәлиева*

## Апрель

— Апрель, апрель җитте, — дип,
Тамчы бии тып та тып.

Гөрләп ага гөрләвекләр,
Юлга тула күлдәвекләр.
Салкын кышлар үтеп китте,
Кырмыскалар чыгып җитәр.

Аю юлын эзли һаман
Урман-куак арасыннан.
Кошлар сайрый тирә-якта,
Умырзая чәчәк ата.

*Самуил Маршактан*

## Сыерчыклар

Сыерчыклар: «Чык-чык!» —
дип
Чакыргач чыктым әле,
Мин аларның дусты бит,
Әниемнең Дилбәре.

Абау, җаным, күр әле,
Нәни генә үзләре,
— Чик-чирик тә чык-чык! —
икән
Бөтен белгән сүзләре.

Безне бик дус итәләр,
Кортларны юк итәләр,
Чик-чирик дип кайталар да
Чик-чирик дип китәләр.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Минем әнием

Мине әнием көн саен
Бакчага үзе илтә,
Мин бакчада уйнап калам,
Әнием эшкә китә.

Оста тегүче булып
Танылган ул эшендә,
Аның теккән киеме
Бик килешә кешегә.

Без, нәниләр, яратабыз
Матур күлмәк кияргә,
Рәхмәт безнең апаларга,
Тегүче әниләргә.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Әниләр бәйрәме

Кояш көлә, мин елмаям,
8 нче Март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакь булсын.

— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

*Саҗидә Сөләйманова*

## Дәү әнигә күчтәнәч

Тутырдык без тартмага
Өрек, йөзем, алманы,
Салдык чәй дә, конфет та —
Буш урыннар калмады.

Әй сөенер дәү әни,
Килеп төшкәч күчтәнәч.
Кызык булыр ул аңа,
Алдан белеп көтмәгәч.

*Шәүкәт Галиев*

## Оекбаш

Кыш көне салкын булса да,
Һич туңмый минем аяк.
Җылыта аны дәү әни
Бәйләп биргән йон оек.

Сарык йоны җылы була.
Бар бит тагын шунысы —
Күчкән аңа дәү әнием
Кулларының җылысы.

*Рафис Корбан*

## Кишер суы

Үсми утыра борчак —
Комачаулый чүп үлән,
Кишер күренә чак-чак —
Эшләр начар, гомумән.

Маринада ике кул,
Светада да ике.
Чүп үлән, хәзер сак бул,
Сиңа инде көн бетте.

Үсмәс кишер бу хәлдә,
Чыкмас болай бер эш тә!
Ике апа түтәлдә
Чүп утарга керешә.

Бер сәгатьтән беркайда
Чүп калмый — бетә эшләр!
Энеләре бер айдан
Кишернең суын эчәр.

*Агния Барто*

## Бакчага килгәч

...Безне бик яраталар
Бакчадагы апалар:
Килгәч тә елмаеп,
Кулларын киң җәеп
Кочаклап алалар, —
Әниләр күк алар...

*Бари Рәхмәт*

## Йомшак су, йөгерек су

Йомшак су, йөгерек су!
Син мине чиста ю!

Бер тап та калмасын,
Битләрем аллансын,
Кулларым агарсын,
Тешләрем тазарсын...

Авызым елмайсын,
Колагым тыңласын,
Йомшак су, йөгерек су!
Һәммәсен чиста ю!

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Уенчыклар

Без уйныйбыз залда,
Ни генә юк анда:

Тун кигән аюлар,
Кыланчык маймыллар,
Тиеннәр, керпеләр,
Куяннар, төлкеләр,
Мөгезле пошилар,
Мыеклы песиләр,

Әтәчләр, тавыклар,
Кәҗәләр, сарыклар.
Батыр без — курыкмыйбыз
Аюдан, маймылдан,
Кочаклап алабыз
Маймылның муеныннан.

*Бари Рәхмәт*

## Гөлсия

Гөлсиянең курчагы бар:
Кечкенә бала төсле.
Көн дә иртән киендерә
Бик матур итеп өстен.

Гөлсия ул — акыллы кыз,
Һич борчымас әнисен.
Елый башласа юата
Бишектәге энесен.

Әтисе дә бик ярата,
Әнисе дә бик сөя.
Битен юа, чиста йөри
Акыллы кыз Гөлсия.

*Нур Гайсин*

## Һаҗирә апа

Ә менә минем апа
Конфет-перәнник сата.
Ул эшләгән кибеттә
Бар ак күмәч тә, сөт тә.

Әйбер ала күп кеше —
Олысы һәм кечесе.
Һәммәсе мактап китә,
Апамны хөрмәт итә.

*Мөхәммәт Садри*

## Аның өчен оялам

Таһир ботка ашаса,
Бөтен бите буяла.
Карап-карап торам да
Аның өчен оялам.
Аннан шулай уйланам:
Әллә авызы кыекмы,
Әллә ботка сыекмы?

Әллә ашыймы ашыгып,
Тишелгәнме кашыгы?!
Ни булса да булгандыр,
Берүк, маэмай килмәсен,
Таһир битен күрмәсен.
Йә тотыныр яларга,
Барыбер ич аңарга.

*Зәкия Туфайлова*

## Уяталар

Кояш чыккан да көлеп,
Алтын түбәтәй киеп,
Уята мине килеп:
— Тор, малай, әй, тор! —
диеп.

Әтәч тә йокы бирми,
Һич тыныч кына йөрми,
— Кикрикүк! — дип, —
Кикрикүк! —
Уята мине иртүк.

Сандугач та уята,
Гел үртәп аптырата.
— Чут, чут, чут, — ди, —
кем анда
Төшкәчә йоклап ята?

Уяталар һәрьяклап,
Әби сөя кочаклап,
— Сине яраталар, — ди, —
Шуңа уяталар, — ди.

*Резеда Вәлиева*

## Юмартлар

Апамның зур курчагы
күзләрен йома белә.
Минем шаян маймылым
эченә төртсәң көлә.

Апамның телефоны —
өреп тутыра торган.
Минем автомобилем —
ачкычын бора торган.

Апам белән без дуслар,
уенчык алмашабыз.
Икебез дә без юмарт —
беркайчан талашмабыз.

*Ренат Харис*

## Нәни ташчылар

Кызыл, сары, яшел, зәңгәр
Бик күп шакмаклар алып,
Зөфәр белән Гөлшат икәү
Куйдылар зур йорт салып.

Зөфәр кирпеч биреп торды,
Гөлшат тезде матурлап,
Ишек, тәрәзә башларын,
Тигезләп, сырлап-сырлап.

Гөлшат әйтә: «Яңа йортка
Курчакларым күчәр, ди,
Ләлә курчакларына да
Монда урын җитәр», — ди.

*Зәкия Туфайлова*

## Светофор — тәмлетамак?!

Светофордан
Сорадым бүген:
– Нигә кып-кызыл
Синең бер күзең?

Елмаеп, миңа
Ул болай диде:
– Кызыл помидор
Ашаган идем...

Светофордан
Сорадым тагы:
– Икенче күзең
Нигә сап-сары?

Елмаеп, янә
Ул болай диде:
– Иртән лимонлап
Чәй эчкән идем...

Сорамый тагы
Буламы түзеп:
– Нигә ямь-яшел
Өченче күзең?

Балкып елмайды
Һәм әйтте аннан:
– Ашаган идем
Ямь-яшел алма...

Шаярта ла ул –
Беләм ич инде!
...Шулай да торам
Ялмап иренемне.

*Ләбиб Лерон*

## Пескәем

Бар кечкенә пескәем,
Бик акыллы дускаем.
Ап-ак йонлач күлмәге...
Бизи безнең бүлмәне.

Күзләре ялт-йолт итә,
Мыегы җиргә җитә.
Үзен бик яратам мин,
Аннан алда ятам мин.

Тик ул бик иртә тора,
Битен юып утыра...
«Мияу, мияу, мияу! — ди, —
Мин бик күптән уяу!» — ди.
*Мәхмүт Хөсәен*

## Светофор

Бу ни хикмәт, тамаша?
Янып тора кызыл ут,
Малай чыга юл аша.

Ачуланды светофор.
Үрелде дә малайның
Алма кебек кызартып

Борып алды колагын:
— Йөри-йөри кыланып,
Машинаны ек тагын!

Нәрсә булды, туктале —
Кызыл колакны күреп,
Машиналар туктады.
*Рәшит Бәшәр*

## Чебиләр сөенделәр

Ишегалдында иртән
Сап-сары күлмәк кигән
Нәни генә бер чеби
Аптырап елап йөри.

Корт эзләп бара-бара,
Еракка рак киткән ул.
Иптәшләрен югалткан
Һәм адашкан икән ул.

Бик жәлләдем мин аны,
Аннан тотып сак кына,
Илтеп куйдым чебине
Башкалары янына.

Иптәшләре табылгач,
Бар да бик сөенделәр.
Һәм чебиләр телендә:
«Рәхмәт сиңа!» — диделәр.
*Ямаш Игәнәй*

## Тиен

Урманда бер зур койрыклы
Җитез тиен
Агач башларында яши
Кышын-җәен.

Агачлардан агачларга
Сикереп үтә,
Чикләвекләр ашап шунда
Гомер итә.

*Әнәс Кари*

## Бәләкәй көчек

Бәләкәй генә
Соры бер көчек
Үз оясында
Утыра өшеп.

Чатнама суык!
Буран котыра!
Түзәрлек түгел!
Ә ул утыра.

Чапса, уйнаса
Курыкмас кыштан.
Тик утырырга
Аңа кем кушкан?!

*Мозаффар Әлимбаев, казах шагыйре*

## Бу кайчак була?

Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә, —
Бу кайчак була?

*Габдулла Тукай*

## Хәерле иртә

Иртән торып чыгуга
Урап алды чебиләр.
Әй сөйлиләр, сөйлиләр:
— Чи-чи, чи-чи-чи... —
диләр.

Казлар әйтә: — Ка-га-га,
Ә үрдәкләр: — Бак-бак-бак.
Нәни бәбкәләре дә:
— Пип-пи, — диләр,
такмаклап.

Берсен тотып иркәлим,
Икенчесен иркәлим...
Алар: «Пип-пип-пип», —
дисә,
Мин: «Хәерле иртә!» — дим.

Тукта, тукта! Нишләргә?
Әле төште хәтергә:
Әнигә бит шулай дип
Онытканмын әйтергә.

*Хәкимҗан Халиков*

## Тыныч йокы!

Тыныч йокы әнкәйгә!
Тыныч йокы әткәйгә!
Тыныч йокы абыема!
Тыныч йокы радиога!
Тыныч йокы үземә!
Тыныч йокы күземә!
Тыныч йокы курчакларыма,
Куяннарыма — куркакларыма!
Тыныч йокы сәгать күкесенә дә,
Тыныч йокы бөтенесенә дә!
Юк, юк, күке ятмасын,
Иртән безне уятсын.

*Шәүкәт Галиев*

## Кояшлы ил

Кояшлы ил — безнең ил,
Күге анның гел аяз.
Кыш китерсә Кыш бабай,
Чәчәк алып килә Яз.

Сандугачлы урманы,
Ашлык тулы кырлары,
Бөтен җирдә яңгырый
Безнең бәхет җырлары.

Һавасы да, җире дә,
Салават күпере дә,
Яңгыры да, кары да —
Безгә якын бары да...

*Әхмәт Рәшит*

# «БЕЗ ИНДЕ ХӘЗЕР ЗУРЛАР»

5–6 яшьлек балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләр, әйтешләр

* Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатырыйм дигәнсең.

Түп-түп, түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

* Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз;
Кулны кулга чаба-чаба
Көләбез дә җырлыйбыз.

* Барыр идем урманга,
Соңга калсам кунарга,
Таба алмасам бер җир дә,
Куып китеп ач бүре,
Кайта алмасам кире?..
Юк, мин урманга бармыйм,
Лучше урында ауныйм.
Утыным бетсә бетәр,
Тиздән җәе дә җитәр.

* Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.

* Исәнмесез, саумысез,
Нигә кәҗә саумыйсыз?
Әтәчегез күкәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?

* Бака, бака, бакырган,
Бака кунак чакырган.
Кунаклары килмәгәч,
Тышка чыгып акырган.

* Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар;
Кунакларны сыйларга
Салдык майлы коймаклар.

* Карга килде — казан асты,
Торна килде — тоз салды.
Саескан килде — салма салды,
Күгәрчен килде — күп ашады,
Кетеки бәби туймый калды.
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер.

* Саескан сары май китерә,
Тургай туң май китерә,
Бүдәнә килә — бүлеп бирә,
Чыпчык килеп өләшә,
Миңа бир дә миңа бир!

* Там, там, тамчы, там,
Тамганыңны яратам.
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам.

* Яңгыр ява, томан төшә,
Кура җиләге пешә,
Ипи, пәрәмәч пешә.

* Әйт әле, чикерткә,
Сине нәрсә сикертә?
Сайрый белми сайрыйсың
Бертуктамый кич-иртә.
Бер сикердең — котылдың,
Ике сикердең — котылдың,
Өченчесендә — тотылдың!
Һап!

* Яңгыр, яу, яңгыр, яу,
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчтән, коймактан,
Арпадан, бодайдан,
Эшләр китәр уңайдан!

* Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада, Миңлебай,
Син нишләсәң,
ни кылансаң,
Без кыланырбыз шулай.

* Карга әйтә: «Кар, кар!
Тиздән эреп бетәр кар,
Канатымда хатым бар,
Буең җитсә, тартып ал».

* Торыгыз, тор, хуҗалар!
Нәүрүз җитте, беләмсез?
Нәүрүзчеләр килде сезгә,
Ни сөенче бирәсез?

* Абагага бага-бага
Башым бәрдем баганага.

# ӘКИЯТЛӘР, ХИКӘЯЛӘР, ЛЕГЕНДАЛАР

## Кем көчле?

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер кеше. Бу кешенең исеме Нарый булган, ди.

Көннәрән бер көнне Нарый чыгып киткән, ди, юлга. Бара да бара, ди, бу. Бара торгач барып кергән, ди, бу ялтырап торган боз өстенә. Боз өстенә барып керүе булган, аягы таеп, әйләнеп төшүе булган.

— Боз, син нидән болай көчле?

— Көчле булсам, — ди Боз, — мине Кояш эретә алмас иде, — ди.

— Кояш, син нидән көчле? — ди Нарый.

— Көчле булсам, мине Болыт капламас иде.

— Болыт, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Яңгыр тишеп чыкмас иде.

— Яңгыр, син нидән көчле?

— Көчле булсам, — ди Яңгыр, — мине Җир сеңдермәс иде.

— Җир, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Үлән тишеп чыкмас иде.

— Үлән, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Сыер ашамас иде.

— Сыер, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Пычак кисмәс иде.

Хәзер пычактан сорый инде Нарый.

— Пычак, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Ут эретмәс иде.

— Ут, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Су сүндермәс иде.

— Су, син нидән көчле?

— Көчле булсам, мине Кеше җиңмәс иде, ә ул мине җиңә, тегермәннәр әйләндерергә җигә! — ди Су.

Шуннан соң Нарый, кешедән дә көчле нәрсә юк икән дип, үз юлына китә, шуның белән әкият тә бетә.

## Батыр этәч

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманнарда бер авылда яшәгән икән, ди, бер Бабай. Бу Бабайның бер кызы һәм бер Кәҗәсеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, ди. Бик ярлы булган бу.

Көннәрдән бер көнне Бабай үзенең Кызын болынга Кәҗәсен көтәргә җибәргән. Кыз Кәҗәне көн буена болында көтеп йөргән дә кичкырын гына алып кайтып, ишегалдына кертеп япкан, ди.

Бабай, Кәҗә янына чыгып:

— Йә, Кәҗәкәем, көне буена болында булып, ни ашадың, ни эчтең? — дип сорый икән.

Кәҗә моңа:

— Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем,— дип җавап биргән, ди.

Карт, моңа ачуы килеп:

— Бер Кәҗәне дә туйганчы ашатып кайта алмагансың, — дип, Кызын бик каты ачуланган, ди.

Икенче көнне Карт болынга Кәҗәне үзе алып киткән. Кәҗә көне буе болында йөреп туйганчы ашаган, ял иткәләп алган да, ди, тагын торып ашарга тотынган. Бабай моны күреп бик шатланган. «Ярый, үзем алып килгәч, бик рәхәтләнеп, туйганчы ашады әле бу», — дип уйлый икән Бабай. Шулай дип уйлаган да теге Бабай, кич булганны да көтеп тормаган, Кәҗәсен калдырып, өенә кайтып киткән, ди.

Кич булып караңгы төшүгә, Кәҗә дә болыннан кайтып кергән, ди. Бабай сорый инде бу Кәҗәдән:

— Нихәл, Кәҗәкәем, көне буена болында йөрдең, ни ашадың, ни эчтең? — ди.

Кәҗә аңа:

— Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем, — дип җавап биргән, ди.

Картның моңа бик ачуы килә. «Гаеп Кызда түгел, бу Кәҗә үзе бик ялганчы хайван икән», — ди. Шуннан соң Бабай: «Бу

ялганчы Кәҗәдән барыбер бер рәхәт тә күрмәссең», — дип уйлый да Кәҗәсен суеп ашарга була. Икенче көнне Бабай Кәҗәнең ике мөгезеннән тотып алып, аякларын бәйләп сала. Бабай пычак алырга дип өенә кереп киткән арада, Кәҗә аякларын ычкындыра да чыгып сыза.

Китә бу. Бара-бара барып җитә бу кечкенә генә бер өйгә. Бу Куян йорты икән. Барып керә. Өй эчендә беркем дә юк. Бу барып кергәндә, Куянның чыгып киткән вакыты булган икән, ди.

Кояш баеп караңгы төшә башлауга, Куян үзенең өенә кайтып керә. Керсә, ни күзе белән күрсен, теге Кәҗә түр башына менеп, мөгезләрен тырпайтып, сакалын селкетеп утыра икән, ди. Куян, моны күреп, бик каты курыккан да, алдына-артына карамастан, урманга таба торып чапкан, ди.

Урманга барып керүгә, бу Куянга очраган, ди, бер Бүре. Бүрене күрү белән, Куян акырып елый башлаган. Моны күреп, Бүре:

— Нигә елыйсың, сиңа ни булды? — дип сорый икән.

Куян моңа:

— Нигә еламаска, көне буена урманда йөреп, өемә әйләнеп кайтсам, түр башында бик куркыныч бернәрсә утыра, күрү белән, йөрәгем ярыла язды, — ди.

Моны ишетү белән, Бүре, батырланып:

— Әйдә, киттек, без аны хәзер куып чыгарабыз, — ди.

Китәләр. Куян өенә барып җитү белән, Бүре үзе дә, курка-курка гына, ишекне ача. Караңгы өйдә зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗә башын күрү белән, Бүренең дә коты оча. Бүре тиз генә өй ишеген яба да урманга карап сыза. Куян аның артыннан китә. Куянның урманга барып керүе була, моның каршысына лап-лап басып килә икән, ди, бер Аю. Аюны күрүгә, Куян тагын кычкырып елап җибәрә:

— Коткарыгыз, харап булдым, өемә куркыныч бернәрсә кергән, — ди.

Аю, бик батырланып:

— Ташла әле, юкка-барга елап, күз яшеңне әрәм итмә, без аны хәзер куып чыгарырбыз, — ди икән.

Китәләр. Караңгы төшүгә, Куян өенә барып җитәләр. Аю, бик батырланып өй ишеген ачып җибәрүгә, сәке өстенә менеп утырган зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗәне күрү белән, бик каты куркуга төшә. Аю да куркуыннан алдына-артына карамый урманга чаба. Куян — аның артыннан.

Куянның урманга барып керүе була, очрый инде моңа бер Төлке. Төлке дә бик батырланып бара. Караңгы бүлмәдә кукраеп утырган Кәҗәне күрү белән, Төлкенең дә коты оча — кача бу.

Куян нишләсен, йорт-җирен калдырып чыгып китә урманга.

Таң атып яктыра башлауга, барып җитә бу бер урман каравылчысының йортына. Бу йортның койма башында утыра икән, ди, бер Әтәч. Әтәчне күрү белән, Куян, гадәтенчә, тагын да кычкырып елап җибәрә, ди.

— Нигә елыйсың соң син, Куянкай? — ди Әтәч, моннан сорый инде.

— Нигә еламаска? — ди Куян, — минә минем өемә бер куркыныч нәрсә кереп утырды, аны үзем дә, Бүре белән Аю да, хәтта Төлке дә куып чыгара алмады, — ди.

— Юкка елама, Куянкай, әйдә, киттек, минә мин үзем сиңа ярдәм итәрмен, — ди Әтәч.

Китәләр. Куян өенә барып җитүгә, Әтәч әйтә инде Куянга:

— Миңа өй ишеген ачу гына кыен булыр, син, ишекне ачып, мине кертеп җибәрерсең, калганын үзем белермен, ди.

Өй янына барып җитү белән, Куянның ишекне ачып җибәрүе була, Әтәчнең, өй эченә кереп, Кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була. Кәҗә башына куна да бу, чукый башлый Кәҗәнең күзләрен. Кәҗә бернәрсә эшли алмый. Чыгып кача Куян өеннән. Әтәч аны бик еракка хәтле куып бара. Шулай итеп, батыр Әтәч Куянны ялганчы Кәҗәдән коткарган, ди.

## Күгәрченнәр ни өчен гөрләшеп яшиләр, һәм гөрләмеш уены каян килеп чыккан?
*(Легенда )*

Борын-борын заманда бер җирдә бик тату бер пар күгәрчен булган, ди. Күгәрченнәрнең иң тәүге әби белән бабасы да шушылар булган, ди, имеш. Аларның нәни генә ике баласы булган. Болар да, әти-әнисе кебек, үзара бик тату булганнар, имеш. Кызык уеннар уйлап чыгарып уйнаулар дисеңме — әйтәсе дә юк.

Менә болар бервакыт бик кызык шундый бер яңа уен уйлап чыгарганнар: берсе канатлары белән күзләрен каплый да, гөр-гөр дип, шулай гөрли тора, икенчесе шул арада каядыр кача. Беренче аны эзләп тапканчы, икенчесе ояга килеп басып өлгерә. Анысын эзләп тапкач, хәзер ул шулай күзләрен каплый да гөр-гөр килеп гөрләп тора. (Шунлыктан бу уенны гөрләмеш уйнау дип атаганнар.)

Шулай итеп, бу күгәрчен балалары, гөр-гөр килеп уйнап, тиз генә арада бик матур булып үсеп тә җиткәннәр. Үскәч, инде беркөнне ояларыннан бөтенләйгә үк очып та киткәннәр.

Ояда калган пар күгәрчен, аларны бик сагынып, ничек-ничек гөрләмеш уйнаганнарын исләренә төшереп сөйли-сөйли, үзләре дә һаман гөрләшеп утыра башлаганнар.

Башка күгәрченнәр дә, бу пар күгәрченнәрнең гөрләшүен отып алып, әнә хәзер әле булса гөлдер-гөлдер килеп, матур итеп гөрләшеп яшиләр, ди, шул.

Күк күгәрчен ояда,
Оялары пыяла,
Күгәрчен кебек гөрләшеп
Торсаң иде дөньяда.

## Куркак юлдаш

*(Татар халык әкияте)*

Элекке заманда ике иптәш юлга чыкканнар. Боларга зур урман аркылы үтәргә туры килгән. Урманга кергәннәр икән, боларның каршысына кинәт кенә бер аю килеп чыккан. Моны күргәч, боларның берсе, бик куркып, агач башына менеп качкан. Икенчесе, үлгән булып, тиз генә сузылып яткан.

Аю, бу юлда яткан кешенең янында әйләнә-әйләнә, башларын, аякларын иснәгән дә, ди, бер дә тимичә, үз юлына киткән, ди.

Аю киткәннән соң, әлеге кеше, агач башыннан төшеп, иптәшеннән сораган:

— Аю синең колагыңа шыпырт кына нәрсә әйтте? — дигән.

Бу кеше әйткән:

— Аю миңа, моннан соң шушындый куркак кеше белән юлга чыкма, дип әйтте, — дигән.

## Ике кыз

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Аларның ике кызы булган. Олы кызлары усал да, ялкау да, саран да икән. Шуның өчен аны беркем дә яратмаган. Кече кызы үги булган. Аның уңганлыгына, аның булганлыгына кешеләр сокланып туя алмаганнар. Үги ананың моңа бик эче поша икән.

Көннәрдән бер көнне карчык иренә әйткән: «Урманга алып барып адаштыр ул кызыңны!» — дигән. Карт, ат җигеп, кызын урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин бераз утын әзерлим», — дигән. Кыз, җырлый-җырлый, җиләк җыярга керешкән:

Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән?

Җыйган-җыйган да кыз, тырысы тулгач, әлеге урынга килсә, атасы юк, ди. Ары сугылып, бире сугылып йөри торгач, бик арыган, бик талчыккан кыз һәм бер каен төбенә тамак ялгарга утырган. Үги әнисе биреп җибәргән бер телем икмәкне чыгарып ашыйм гына дисә, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Куян.

Кыз аңа икмәген бүлеп биргән. Куян икмәк сыныгын тәмләп кенә ашап куйган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, аңа куян бүреге китереп биргән.

Куян киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Төлке.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Төлке икмәк сыныгын тәмләп кенә ашап куйган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, аңа төлке туны китереп биргән.

Төлке киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Бүре.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Бүре икмәк сыныгын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, кызга бүре туны китереп биргән.

Бүре киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Аю килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Аю.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Аю икмәк сыныгын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, бер тәпән бал китереп биргән.

Аю киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Көтүче килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Көтүче.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Көтүче икмәк сыныгын тәмләп ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, бер көтү мал куып китергән.

Көтүче киткәч, калган икмәк сыныкларын кабып җибәрим генә дисә, моның кулбашына Сандугач килеп кунган.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Сандугач.

Кыз учыннан аңа калган икмәк валчыкларын чүпләткән. Сандугач икмәк валчыкларын тәмләп кенә чүпләп бетергән дә: «Яхшылыкка — яхшылык, нинди теләгең бар, түтекәй, хәзер үтим», — дигән.

Кыз әйткән: «Минем өйгә кайтасым килә, әткәемә генә барып хәбәр салчы, Сандугачым», — дигән.

Кош очып киткән. Ул, авылга җитеп, аларның өй каршындагы агачка кунып:

Чут, чут, чут,
Түтәйнең маллары күп,
Килеп алучы юк, юк, —

дип сайрарга тотынган.

Атасы моны ишеткән һәм, атын җигеп, урманга киткән. Кызның бөтен байлыкларын төяп, көтүләрне куып алып кайтканнар. Үги әни, моны күреп, ачуыннан нишләргә белми, ди. «Үз кызыңны баеттың, инде минем кызымны да бает, урманга алып барып адаштыр!» — дип, картына бәйләнә икән.

Карт ат җигеп, бу кызны да урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор. Мин бераз утын әзерлим,» — дигән. Кыз җиләк җыярга тотынган. Бер җиләкне савытка, өч җиләкне авызга салып йөри-йөри, тырыс төбе каплангач, әлеге урынга килсә, атасы юк, ди. «Әйдә, ярар, монда гынадыр әле, мине ташлап әллә кая китә алмас, югыйсә әнием аның кирәген бирер», — дип уйлаган кыз һәм каен төбенә ашарга утырган. Әнисе җибәргән төргәкне чишеп, нигъмәтләрне җәеп куюы булган, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Куян.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм таяк белән башына суккан. Куян ачу итеп, кызның күлмәген ертып, җиләген түгеп киткән.

«Их, котылдым бу арык Куяннан!» — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Төлке.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән Кыз һәм Төлкенең башына таяк белән суккан. Төлке ачу итеп, кызның яулыгын ертып, тырысын тетеп киткән.

«Их! Котылдым бу ач Төлкедән! — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, —

дигән Бүре.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм Бүренең башына таяк белән суккан. Бүренең моңа бик каты ачуы килгән һәм кызны кабып йоткан, ди.

Бу вакытта карт өйдә икән. Карчыгы: «Бар инде, кызым баегандыр, тизрәк алып кайт!»— дип әрләшә, ди. Карт атын җигеп урманга барса, кызы юк. Тетелгән тырысы гына җирдә аунап ята, ди. Карт шуны арбасына салып кайтып киткән. Ишегалдына килеп кергәч, карчыгы йөгереп чыккан. Арбада кызының тетелгән тырысын күргән һәм хурлыгыннан егылып үлгән, ди.

Үги кыз әле дә булса матур гына гомер итә, ди.

## Ни өчен Эт белән Песи бер-берсенә дошман булганнар?

*(Легенда)*

Элекке заманда бер Этне хуҗасы бик начар карый башлаган. Эт, бичара, бик ябыгып, арыкланып, эченнән кылыч күренерлек булып калган, ди. Менә бервакыт аны шул авылның Старостасы күргән дә бик кызганган, аны үз янына чакырып алып әйткән, ди:

— Син, төннәр йокламыйча, хуҗаның йортын саклыйсың, көндез аның терлекләрен көтәсең, быелгы ачлыкта, улап-улап, яңгыр китердең. Бар, әйт хуҗаңа, сине, карамыйча, болай ач йөртмәсен; инде ул ашлыгым уңмаган дисә, менә мин синең кулыңа шушы кәгазьне бирәм, яңа ашлык өлгергәч тә, сине ул яхшылап ашатып симертсен, анда да начар ашатса, аңа шушы фәрманны күрсәтерсең! — дип, Староста аңа печать суккан кәгазь тоттырып җибәргән, ди. Эт шул кәгазьне алып киткән, авызында тотып та караган, кулында тотып та караган, кая куярга да белмәгән.

— Авызымда йөртсәм чылана, өрсәм, авызымнан төшә, кулымда йөртсәм ертыла, тукта, мин моны Мәчегә биреп саклатыйм, — дигән дә аны чакырып чыгарган. Чыгарган да кәгазен күрсәтеп әйткән, ди:

— Мәче дус, менә бу миңа югарыдан төшкән зур кәгазь, минем аны саклар урыным юк, син өйдә торасың, шуңа күрә мин

аны сиңа әманәт итеп куеп торам, көз хуҗабыз әвен суккач, мин аны үзем синнән сорап алырмын, син яхшы сакла, — дигән.

Мәче кәгазьне «ярый» дип алган да өйгә шома гына кереп киткән. Ләкин Мәчедә Эт кайгысы бармыни? Шул төнне салкын булгач, ул җылынырга дип, мичкә кереп яткан икән, Этнең боерыгын шунда онытып та калдырган. Иртән торуга мич яксалар, Этнең кәгазе дә шунда янып көл булган, ди.

Менә җәй үткән. Яңгырлар явып, игеннәр уңып киткән. Өйдә икмәк тә, аш-су да пешеп тора, ди. Адәмнәр дә тук, Мәче дә тук. Тик хуҗасы бу карт Этне һаман да карамый, ул һаман да ач кала икән. Ник дисәң, аның хуҗасыннан икмәк дәгъва итәргә кулында кәгазе юк. Хыянәтче Мәчедән сора-сорама, хәзер юньләп җавап та бирми, тыр-мыр итә дә, үтә дә китә.

Шуннан бирле хәзер Эт, Мәчене күрсә, бердән аңа ташланып:

— Ыр-р, ыр-р! Безне ач калдыручылар! — ди икән.

Мәче:

— Пырых, пырых!.. Без бит тук!.. — дип, йоннарын торгызып, өйгә таба чаба бирә, ди.

Һәм шуннан бирле араларында дуслык та беткән, әле дә булса гомер буе ырлы-мырлы, этле-мәчеле булып яшәргә калганнар, ди.

## Өч кыз

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер Хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу Хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, дип, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар үсеп буйга да җиткәннәр. Алар берсеннән-берсе матур, ди, бер битләре ай, бер битләре кояш, буй сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, Олы кыз җиз ләгәннәр чистартып торадыр иде, ди.

— Һай, — дип әйткән, ди, Олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне чистартып бетерәсем бар иде шул, — дигән, ди.

Тиен моңа бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар.

Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән.

Тиен Уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай, — дигән, ди, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомерең буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, Кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен Кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.

## Шүрәле
*(Татар халык әкияте)*

Әүвәле берәү урманда утын кисә икән, аның янына бер Шүрәле килеп чыккан, ди. Шүрәле аңа:

— Син ни атлы? — дигән. Ул кеше:

— Мин Былтыр атлы, — дигән.

— Әйдә, кети-кети уйныйк әле, — дигән.

— Ярар, элгәре менә бу тумранны ярыйк әле, аннары уйнарбыз, — дигән кеше.

Кеше тумранга балта белән чапкан икән, тумран азрак ярылган. Шуннан соң бу кеше Шүрәлегә әйткән:

— Мин икенче чапканчы, син шунда бармагыңны кыстырып торсана, — дигән. Шүрәле бармагын ярыкка куйган икән, кеше балтасын алгач, ул шунда кысылган да калган. Кеше балтасын алган да качкан. Шүрәле шыр-шыр кычкыра башлаган, ди.

— Бармагымны Былтыр кысты, Былтыр кысты! — дип.

Менә аның янына бүтән шүрәлеләр җыелган, аннан:

— Кем кысты? — дип сорыйлар икән, ул:

— Былтыр кысты, — дип әйткән, ди. Алар аңа әйткәннәр, ди:

— Быел кысса табар идек, былтыр кыскач, каян табасың, — дигәннәр, ди.

— Соң син былтырдан бирле ник кычкырмый тордың? — дигәннәр, ди. Шүрәле аларга авыртуыннан юньләп аңлата да алмаган, ди.

## Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми?
*(Башкорт халык әкияте)*

Бердәнбер көнне Карга Күке белән очраша. Алар берберсенең хәл-әхвәлен сорашканнар. Күке, Карга белән хушлашып, үз юлына китә. Очып барып, бер агачка куна да, бик матур итеп:

— Күк-кү, күк-кү, — дип кычкыра башлый.

Карга моны ишетеп көнләшеп куя.

— Мин Күке кебек үз исемемне әйтеп бетерә алмаммыни? Минем тавышым да көр, сыным да матур, — ди ул.

Шуннан соң Карга: «Кар-га, Кар-га», — дип кычкырып йөри башлаган.

Бервакыт Карга, азык эзләп йөргәндә, бер Тургайны эләктереп ала да авызына каба. Шулчак Тургай Каргадан болай дип үтенә башлый:

— Агай, мин барыбер үләм инде. Шулай да исемеңне белеп үләсем килә. Син миңа үз исемеңне әйтә күр инде, — ди. Моңа Карга, томшыгын кысып кына:

— Карр, каррр, — дигән.

Тургай:

— Минем колакларым бик бәләкәй, ишетмиләр, кычкырыбрак әйтә күр, — дигәч, Карга, авызын зур ачып:

— Кар-га, Кар-га, — дип кычкырган. Шуны гына көтеп торган Тургай Карга авызыннан очып чыгып та китә. Карга Тургайны куып караган, әмма яңадан эләктерә алмаган.

Шулай итеп, Тургай үлемнән котылып калган. Карга үз исемен әйткәнгә бик үкенгән. Шуннан соң ул үз исемен бервакытта да тулысынча әйтми икән. «Карр, карр», — дип кенә кычкыра икән.

## Башак

*(Украин халык әкияте)*

Борын заманда яшәгән, ди, ике тычкан баласы. Аларның берсе — Әйләнчек, икенчесе Бөтерчек исемле булган, ди. Тычканнар иртәдән кичкә кадәр җырлаганар, биегәннәр, әйләнгәннәр, бөтерелгәннәр — башка нәрсә эшли белмәгәннәр. Әтәч исә, яктыра башлау белән, җырын сузып, бөтен кешене йокысыннан уята, аннан соң эшкә тотына торган булган.

Менә беркөнне Әтәч, ишегалды себергәндә, җирдә бодай башагы тапкан.

— Әйләнчек, Бөтерчек, карагыз әле, мин нәрсә таптым, — дип, Әтәч аларны үз янына чакырган. Тычканнар йөгереп килгәннәр дә: «Аны суктырырга кирәк», — дигәннәр.

— Ә кем суктыра? — дигән Әтәч.

— Мин түгел, мин түгел, — дип чыелдашканнар тычкан балалары.

— Ярар, үзем суктырырмын, — дип, Әтәч эшкә керешкән. Ә тычканнар, мәтәлчек ата-ата, куышлы уйнарга тотынганнар. Әтәч бодай башагын сугып бетергән дә: «Әй Әйләнчек, әй Бөтерчек, карагыз әле, мин күпме бөртек суктырдым», — дип кычкырган. Тычканнар йөгерешеп килгәннәр дә: «Хәзер бодайны тегермәнгә алып барырга кирәк», — дип кычкырганнар.

— Ә кем алып бара? — дип сораган Әтәч.

Тычкан балалары: «Мин түгел, мин түгел!» — диеп, уйнарга чыгып йөгергәннәр. Әтәч аркасына капчык аскан да тегермәнгә китеп барган. Тегермәннән кайткач, Әтәч тычканнарга: «Әй Бөтерчек, әй Әйләнчек, карагыз әле, мин он алып кайттым», — дигән. Тычканнар йөгерешеп килгәннәр дә Әтәчне мактарга тотынганнар: «Әй Әтәчкәй, әй булдыклы Әтәчкәй, әй уңган Әтәчкәй! Инде хәзер, камыр басып, күмәч пешерергә кирәк», — дигәннәр.

— Кем камыр баса? — дип сораган Әтәч.

— Мин түгел! — дигән Әйләнчек.

— Мин түгел! — дигән Бөтерчек.

Әтәч, бер сүз дә әйтмичә, эшкә тотынган. Ул камыр баскан, утын ташыган, мичкә яккан, күмәчне мичкә тыккан. Тычканнар да вакытларын бушка уздырмаганнар: биегәннәр, җырлаганнар, әйләнгәннәр, бөтерелгәннәр.

Пешеп чыккач, Әтәч күмәчне, мичтән алып, өстәлгә куйган. Ә тычкан балалары, чакырганны да көтмичә, өстәл янына килеп утырганнар.

— Һай, ничек ашыйсы килә! — дигән Әйләнчек.

— Минем дә бик-бик ашыйсы килә! — дигән Бөтерчек.

— Туктагыз, туктагыз, — дигән Әтәч. — Сез миңа элек әйтегез әле: башакны кем тапты?

— Син таптың! — дип кычкырганнар тычканнар.
— Ә башакны кем суктырды?
— Син суктырдың, — дигәннәр тычканнар, әкрен генә.
— Ә кем башакны тегермәнгә алып барды?
— Анысын да син, — дигәннәр болар икәүләшеп.
— Ә кем камыр басты? Кем утын ташыды? Кем мичкә якты? Күмәчне кем пешерде?
— Барсын да син, барсын да син, — дигән тычканнар, пышылдап кына.
— Ә сез нәрсә эшләдегез?
Ничек дип җавап бирергә дә белмичә, Әйләнчек белән Бөтерчек өстәл яныннан кузгалып киткәннәр.

## Итагатьле мәче

*(Литва халкы әкияте)*

Шулай беркөнне Чыпчык малае ишегалдына очып төшкән дә бодай чүпләргә тотынган, ди. Чыпчык, сикерә-сикерә, бодай бөртеге чүпли, ә хәйләкәр Мәче бер читтән моны күзәтеп тора икән. Шулай карап-карап торган да Мәче, ялт сикереп,Чыпчыкны канатларыннан эләктереп алган.
— Менә хәзер рәхәтләнеп тамак ялгыйм! — дип мырлаган Мәче.
— Нишлисез, Мәче әфәндем? Әллә чынлап та мине ашамакчы буласызмы? — дип чыркылдаган Чыпчык.
— Ашамыйча, тагын нишлим мин синең белән? Хәзер кабам да йотам! — дигән дә Мәче Чыпчыкның муенын авызына капкан.
— Оятыгыз бармы сезнең, Мәче әфәнде? — дип өзгәләнә-өзгәләнә чыркылдаган Чыпчык. — Юынмаган килеш кем ашарга утыра инде? Хуҗагызның юынмыйча ашаганын күргәнегез бармы?
— Монысы дөрес инде, — дип, Мәче йомшак тәпие белән битен юарга тотынган.

Мәче тырнагыннан ычкынган Чыпчык канатларын җилпегән дә очып киткән. Мәченең моңа бик тә ачуы килгән, билгеле.

— Болай булмый бу. Бүтән мине алдый алмассың! — дип, тешләрен шыгырдаткан ул. — Кешеләр теләсә нишләсен, ә мин башта ашыйм, аннары гына битемне юам.

Шушы көннән башлап, мәчеләр ашап туйгач кына битләрен юалар, ди.

## Бүре аларны нигә ашаган?

*(Болгар халык әкияте)*

Бүре, яшеренеп кенә, абзарга килеп кергән. Сарыклар, куркып, бер почмакка сыенганнар. Бүре зур Тәкәне бугазыннан алган да, аркасына салып, урманга чапкан.

Сарык Бүре артыннан киткән. Үзе бара, үзе елый икән. Аңа Кәҗә очраган. Ул Сарыктан сораган:

— Нигә бик өзелеп елыйсың әле, Сарык дускай? — дигән.

— Ничек еламыйм ди, Бүре әтиемне алып китте. Аңардан тик муенындагы кыңгыравы гына калды. Бүрене табам да тукмап үтерәм.

Кәҗә аңа:

— Мин дә синең белән барам, дигән. Минем мөгезләрем шундый үткен!

Сарык кайгыдан Бүренең усаллыгын да оныткан.

— Кирәкми, — дигән ул Кәҗәгә. — Үземнең дә көчем җитә минем.

Шулай дигән дә, китеп тә барган. Аңа юлда Эт очраган. Сарыкның кайгысын уртаклашып, ул:

— Мин дә синең белән барам, — дип белдергән. — Бүре минем ике туганымны ашады. Син Бүре белән сугыша башлауга, мин аның аркасына сикереп менәрмен дә бугазыннан эләктереп алырмын.

Сарык әйткән Эткә:

— Синең эшең түгел ул. Мин бер сугуда аны үзем дә юк итәм.

Сарык әнә шулай Бүре янына берүзе барып җиткән икән. Бүре моны шундук тотып ашаган.

Сарык өчен Бүредән үч алырга дип, Кәҗә дә урманга киткән. Әмма үзе әйләнеп кайтмаган.

Бүренең кирәген бирергә дип, Эт тә урманга барган икән. Бүре авызына эләгүен үзе дә сизми калган.

Ә Бүре: «Менә юләрләр, — дип, алардан көлгән. — Әгәр җыйнаулап бергә килгән булсалар, нишләр идем?! Мөгаен, мине җиңгән булырлар иде алар. Берәм-берәм килгәнлектән, барысын да тотып ашадым», — дип шатланган.

## Хәйләкәр Әтәч

*(Болгар халык әкияте)*

Әтәч киртә өстенә менеп баскан да, канатларын җәеп, бар көченә «кик-ри-күк» дип кычкырып җибәргән. Шулчак янәшәдәге куаклар арасыннан Төлке килеп чыккан.

— Хәерле көн! — дип сәлам биргән Төлке. — Тавышың бигрәк матур икән! Сине ишеткәч, мәрхүм әтиең искә төште... Менә ул җырлый иде ичмасам!

— Әти ничек җырлый иде? — дип авызын ачкан Әтәч.

— Бер аягы белән киртәгә баса да икенче аягын канат астына кыстыра. Аннары бер күзен йомып җырларга тотына.

— Мин дә алай җырлый беләм! — дигән дә яшь Әтәч бер күзен чытырдатып йомган, бер тәпиен канат астына яшергән. — Кик-ри-күк!

— Ә син бер аякта торган килеш ике күзеңне дә йомып җырлый беләсеңме соң? — дип елмайган Төлке.

— Беләм! — дип масаеп кычкырган Әтәч.

Яшь Әтәч ике күзен тиң йомуга, Төлке киртәгә сикереп менгән дә аны муеныннан эләктереп алган. Аннары, урман эченә кереп, Әтәчне ашарга җыена башлаган.

— И-и-их! — дип авыр итеп көрсенгән Әтәч. — Синең мәрхүмә әниең болай итми торган иде...

— Ә ничек итә иде ? — дип, башын күтәргән Төлке.

— Әтәч ашар алдыннан, әниең мәрхүм һәрчак дога укый торган иде. Бигрәкләр диндар иде шул мәрхүмә...

— Мин дә дога укый беләм! — дип мактанып кычкырган Төлке һәм, алгы тәпиләрен җиргә куеп, күзләрен йомган да дога пышылдый башлаган.

Әтәчкә шул гына кирәк! Ул, Төлкенең тәпиләреннән ычкынуга, канатларын кага-кага, «кик-ри-күк» дип кычкырган да кетәклек ягына элдергән.

Шул көннән башлап, Төлкеләр дога укымый башлаганнар, ди.

## Күңелле Чыпчык белән күңелсез Карга

*(Калмык халык әкияте)*

— Чыр-чыр, чыр-чыр! — иртәдән кичкә кадәр пырхылдап оча да оча бу Чыпчык. Шулай күңел ача. Үзе кечкенә, аруталуны белми. Монда бөртек каба, тегендә суалчан таба. Шулай яши дә яши. Күңеле көр, кайгыра белми.

Агачта бер Карга утыра. Төсе кара, чырае сытылган, үзе тәкәббер. Бер күзен кыйшайтып кына, Чыпчыкның шаяруын күзәтә, аның шат күңелле булуына ачуы килә, көнләшә. Чыпчык очып китә дә яңадан килеп куна. Чыр-чыр итә. Чыр-чыр! «Кыланчык, — дип уйлый Карга, — түзәрлек түгел».

— Чыпчык, әй Чыпчык, хәлләрең ничек? Ашарга ничек табасың? — дип, Чыпчыкка сүз куша Карга. Ә Чыпчык бер минут та тик утыра алмый. Йә очып китә, йә бер урыннан икенче урынга сикерә.

— Менә шулай камыш чукыйм, — ди Чыпчык, очып барганда.

— Әгәр тамагыңа тыгылса нишләрсең, үләрсең бит? — ди Карга.

— Нигә үләргә? Тырнакларым белән тартам да чыгарам, — ди Чыпчык.

— Әгәр канаса нишләрсең?

— Су эчәрмен, су белән юармын. Шулай итсәң, кан туктый ул.

— Аякларыңны чылатсаң туңарсың, салкын тидерерсең бит. Аякларың авырта башласа нишләрсең?

— Чыр-чыр, чыр-чыр! Учак ягармын, аякларымны утта җылытырмын. Шулай итсәм терелермен.

— Әгәр янгын чыгарсаң нишләрсең?

— Канатларымны җилпермен. Шулай итсәң, ут сүнә ул.

— Әгәр канатларыңны яндырсаң, ничек очарсың?

— Табиб чакырырмын, ул мине дәвалар.

Карга сорый да сорый.

— Әгәр табиб килмәсә нишләрсең? — ди.

— Чыр-чыр, чыр-чыр! Бөртек табармын, суалчан ашармын, оя ясарга җайлы урын эзләрмен, кояшта кызынырмын, җиләс җил исәр. Табибның кирәге дә булмас, терелермен!

Чыпчык шулай ди дә оча да китә. Карга аның койрыгын гына күреп кала. Карт Карга көнләшүдән каурыйларын тырпайта, күзләрен акайта, томшыгын шакылдата.

Тормыш бик күңелле, гаҗәп матур ул! Тик борыныңны гына Карга кебек салындырма. Чыпчык кебек шат күңелле бул!

## Суалчан кунакка бара

Булган, ди, бер Суалчан.

Яңгыр аны кунакка дәшкән. Бик озаклап җыенгач киткән бу Яңгыр янына кунакка. Бик, би-и-ик, би-и-и-и-ик озак барган, ди. Барган да барган икән. Бер дә ашыкмаган. Барып җитсә, ни күрсен: Яңгыр, моны көтә-көтә, Карга әйләнгән.

— Кунакка кем янына барсаң да ярый. Кар, син мине кунак ит, — дигән Суалчан.

Ләкин Кар аңа ишеген ачмаган. Суалчан ач килеш үз өенә кайтып киткән.

Кунакка вакытында барырга кирәк. Югыйсә, көтә-көтә, хуҗаның ашы суынып бетә.

*Әхәт Гаффар*

## Каз белән Аккош

Очы-кырые күренмәгән болын уртасында зур бер күл булган. Тирәләре аның яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган икән.

Бу күл буена кеше аягы бер дә басмаган, ул тирәләрдә аучыларның мылтыклары да шартламаган.

Шул тыныч күлдә Аккош белән Каз яшәгәннәр. Дус булып, тату булып гомер кичергәннәр. Балык ашаганнар, су эчкәннәр, йомырка салганнар, бала чыгарганнар.

Җәйнең матур бер көнендә бу ике күрше балалары турында сөйләшкәннәр. Киек Каз әйткән:

— Улым ашны аз ашый, суны гына күп эчә, — дигән.

Аккош әйткән:

— Минем балам бик яхшы ашый, зур үсә, — дигән.

Каз үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле балыклар, яшел бакалар, тәмле кыслалар тотып китерә икән. Баласы, үзе зур булса да, кулына кашык тотып ашамаган, әнисенең ашатуын көткән. Ашау аңа бик зур эш булган. Ашарга-эчәргә тотынса, ул тәмам йөдәп беткән. Ә дуга муен, аккош баласы, кыстатып та тормый, кашыкны үзе тотып, азыкны кат-кат чәйнәп, тәмле итеп ашый икән.

Көннәрдән бер көнне, киек Каз белән Аккош баласы әниләренә килгәннәр дә:

— Әни, безгә велосипед алыйкчы! — дип үтенгәннәр.

— Ярый, барсак барыйк, алсак алыйк, — дигәннәр әниләре. Улларын ияртkәннәр дә велосипед сатыла торган кибеткә киткәннәр. Анда барып кергәннәр дә әниләре:

— Иптәшләр, безнең сөекле улларыбызга велосипед бирегезче! — дигәннәр.

Шунда сатучылар йөгереп килгәннәр дә:

— Рәхим итегез, рәхим итегез! — дип, көмеш төсле ялтырап торган велосипедлар китереп биргәннәр. Шунда Аккошның улына:

— Теләгәнеңне сайлап ал, акыллым! — дигәннәр.

Аккош баласы велосипедка менеп атланган да, йөгерткән дә киткән. Аңа карап, сатучылар:

— Менә егет икән бу малай, тамагына шәп ашый, ахры, — дигәннәр, ә Аккош, үз баласының булдыклылыгын күреп, елмаеп, кәефләнеп, карап тора икән, ә малай велосипедны йөгертә дә йөгертә икән.

Киек Каз бәбкәсенә дә чират җиткән. Ул, Аккош бәбкәсе белән бер яшьтә булса да, аңа караганда бик ябык, буйга да бик кечкенә икән.

Аңа да велосипедның көмеш төслесен биргәннәр:

— Яле, акыллым, син дә йөгереп кара! — дигәннәр.

Каз бәбкәсе бер атланып караган — булдыра алмаган, икенче атланырга уйлаган — егыла язган, өченче тапкыр атланырга теләгән икән, — егылып ук киткән, әйләндермәгәч, велосипед та тәгәрәмәгән. Кибеттә эшләүче абыйлар шунда ук йөгереп килеп җиткәннәр, киек Каз бәбкәсенә менә шушы сүзләрне әйткәннәр:

— Син, акыллым, ашны аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың. Һавада уйнамыйсың, ахры, шуңа күрә бик ябык, буең да кечкенә, шунлыктан велосипедка да аягың җитми, хәзергә өеңә кайтып тор, зур үскәч килерсең, — дигәннәр һәм велосипедны да алып киткәннәр.

Каз бәбкәсе бик күңелсезләнеп кайтып киткән, ә Аккош бәбкәсе велосипедка атланып җилдергән.

Хәзер инде, «велосипедка аягым җитсен, аягым җитсен» дип, Каз бәбкәсе азыкны да ашый, вакытында йоклый да, саф һавада да уйный икән.

*Абдулла Алиш*

## Мактанчык алма

Бакчада бер алмагач үсеп утырган. Аның әле бер генә тапкыр да алма биргәне булмаган. Яз җиткәч, бер генә бөртек чәчәк аткан да алмага бөреләнгән. Олы агачлар бик сөенгәннәр, кортлар ияләшмәсен өчен, көндез дә, төнлә дә аны саклаганнар.

Алма көзгә бик матур булып кызарып пешкән. Уңыш җыяр вакыт җиткәч, аны да агачыннан өзәргә булганнар. Ләкин Алма:

— Мин, матур алма, өзеп ашар өчен түгел! — дигән дә яфраклар арасына кереп качкан.

Шулай берзаман бөтен бакчага бер Алма булып калган. Шуннан соң ул:

— Күрдегезме инде, куркаклар, мин матур гына түгел, батыр Алма да бит әле! — дигән. — Курыкмыйча, шундый зур бакчада минем кебек батырлар гына кала!

Бүтәннәр аның соңгы сүзләрен ишетмәгәннәр. Аларның кышка әзерлек эшләре башланган: яфракларын коясы, ботакларын корткыч бөҗәкләрдән чистартасы булган.

Шул арада күптән инде җай гына чыкканын көтеп торган алма корты сиздермичә генә менгән дә Алманы тешләп алган. Алма, авыртуына чыдый алмыйча, үрле-кырлы сикергән дә, агачыннан өзелеп, җиргә төшкән. Бер генә түгел, әллә нихәтле корт кимереп бетергән үзен.

*Сәмига Сәүбәнова*

## Ялкау карга баласы

Текә ярның каршында,
Карт карагай башында,
Карга оя корган, ди,
Балалар чыгарган, ди.
Балаларының берсе,
Өлкәне, эшлеклесе,
Энеләрен карашкан,
Каурыйларын тарашкан.
Уртанчысы, матуры,
Бар эшне дә белгән, ди.
Пар чиләкләрен асып,
Су китереп йөргән, ди.

Ә төпчеге, иркәсе,
Эш кушсалар, баш тарткан.
Иртәсен дә, кичен дә
Гел уйнарга яраткан.
Беркөнне әнкәләре
Таң белән ауга киткән,
(Ул бөтен тирә-якта
Кодрәтле аучы икән.)
Үзе киткән чагында
Әйткән икән тагын да:
— Өй эшләрен, улларым, сез
Эшләрсез, — дип, —
барын да.

Төпчегенә аерып әйткән:
— Сүземне тыңла, — дигән.—
Оя ямарга чыбык җый,
Эшсез утырма! —
дигән.
Балкып кояш чыгуга,
Каргалар торганнар, ди.
Җиң сызганып,
Җырлый-җырлый,
Эшкә тотынганнар, ди.
Иң өлкәне, назлап сөеп,
Энеләрен караган.
Ак май сөртеп, ялтыратып,
Каурыйларын тараган.
Уртанчысы да тырышкан,
Кыймаган тик ятарга,
Чиләк-чиләк су ташыган,
Әниләре кайтуга.
Тик ялкау Төпчекнең генә
Эшкә кулы ятмаган.
Чыбык та ташымаган ул,
Су да алып кайтмаган.
Ташламаган ялкаулыгын,
Һаман үз сүзен иткән:
— Кир-рәкми,
мин эшләмим! — дип,
Урманга очып киткән.
Шул урманда уйнаган ул,
Өйгә кайтмый көн буе,
Күнел ачып тик йөрегән —
Эштә булмаган уе.
Төн яшел урман өстенә
Кара юрган каплаган.
Караңгыда нәни карга
Кайтыр юлын тапмаган.
Өстәвенә яңгыр килгән,
Уйнап торган яшене.
— Курр-кам! — дип
Кычкырган Төпчек,
Буылып күз яшенә.
...Урман шаулый,
Җил сызгыра,
Яңгыр һаман котыра.
Карт карагай ботагында
Төпчек елап утыра.
Аяклары дерелди,
Канатлары калтырый,
Күшеккән шул мескенкәй,
Оча алмый аптырый.
Җитмәсә, шунда бер Аю
Аны тотмакчы була.
Ялкаулыгын белгән, ахры,
Кабып йотмакчы була.
Ябалак күзен уйната,
Төлке теш шыкылдата,
Ялкау карга, калтыранып,
Яңгыр астында ята...
...Иртәгесен абыйлары
Аны эзләп тапканнар.
Канатларыннан өстерәп,
Өйгә алып кайтканнар.
Шул чагында бу карганы
Барча кошлар күргәннәр,
— Ялкау кайта, ялкау!— диеп
Кычкырышып көлгәннәр.
Авыр булган бу каргага,
Бик үкенгән бичара.
Тик беләсез, эш узгачтын
Үкенүдән ни чара?!

*Резеда Вәлиева*

## Әбү булган аягы

Яз җиткәч, аю баласы Әппәс йокысыннан уянган. Уянгач та, өненнән чыккан. Иртәрәк чыккан аю баласы өненнән.

Шул чакта урман буйлап аучы узып бара икән. Аучы аю баласы Әппәсне күреп алган. Мылтыгын төзәп:

— Тукта, аю баласы, мин сине хәзер атам! — дип кычкырган аучы.

Аю баласы Әппәс куаклар арасына кереп качкан. Аучы аны куа башлаган. Әппәс качкан җиреннән чыккан да и йөгерә, и йөгерә икән. Аучы һаман куа икән аю баласын. Үзе йөгерә, үзе шатыр-шотыр мылтыктан ата, ди. Барыбер аучы Әппәскә тидерә алмаган. Аучы артта калган. Аю баласы, куркуыннан туктый алмыйча, әллә кая чаклы йөгергән. Шулай йөгерә торгач, сукмакка аркылы ауган агачка абынып егылган. Егылганда, аягын авыртырган.

Авырткан аягына өрә-өрә:

— У-у, аягым каерылды. Өемә кайта алмам инде! — дип кайгыра икән Әппәс.

Аю баласының аягы нык имгәнгән булган шул. Ул кишер дә, шалкан да утырта алмаган. Куян, керпе, тиен аю баласы Әппәсне бергәләп караганнар, күмәкләп ашатканнар. Гөмбә, чикләвек, шомырт, җиләк, карлыган, тагын әллә ниләр белән сыйлаганнар.

— Йокла, Әппәс, тиз терел! — дип, үзләренчә җырулар җырлаганнар җәнлекләр.

Аю баласы Әппәс терелеп җиткән. Ул терелгәнче, җәй дә үтеп киткән. Ул терелгәч, җәйләр үтеп киткәч, кыш та килеп җиткән. Кыш җитүгә, аюлар йокларга ята. Аю баласы Әппәс тагын өненә кереп яткан. Җәнлекләр аңа тагын бишек җыры җырлаганнар:

— Һилай-һилай, һилалай,
Һила-ла-лай, һилалай!.. — дип җырлаганнар алар.

*Батулла*

## Алпамыш шәһәргә килде

Бер карурманда Алпамыш исемле аю малае яши иде. Беркөнне ул шәһәрдә яшәүче абыйсыннан хат алды. Ул хатта «Алпамыш! Мин циркта чыгыш ясыйм. Кил, әйдә!» дигән сүзләр язылган иде.

Әлеге хәбәрне алгач, Алпамыш бик сөенде. Моңарчы аның циркта гына түгел, шәһәрнең үзендә дә булганы юк иде. Ул тиз генә киенде дә юлга чыкты.

Шәһәрдә аны бик күп машиналар һәм җәяүлеләр каршы алды. Шулхәтле халыкны, шулхәтле машиналарны күреп, Алпамыш югалып калды хәтта!

— Әй син! Нишләп торасың монда?

Алпамыш сискәнеп куйды. Бер көчек аңа дәшә икән.

— Мин... мин... циркка... абый янына бара идем, — диде Алпамыш.

— Циркка бара беләсеңме соң? — дип сорады көчек.

— Юк шу-ул...

— Әйдә, алайса, үзем озатып куям, — диде көчек. — Таныш булыйк: мин Зирәк булам.

— Ә мин — Алпамыш.

Менә алар, икәүләп, тротуар буйлап киттеләр.

— Исеңдә тот, Алпамыш: тротуардан барганда, һәрвакыт уң яктан барырга кирәк! — диде Зирәк. Бара торгач, болар бер чатка килеп җиттеләр. Алпамыш юлдагы машиналарның әле туктап торуларын, әле китеп баруларын күрде дә:

— Бу машиналар нигә алай итәләр? — дип сорады.

Зирәк каршыдагы өч күзле баганага төртеп күрсәтте:

— Күрәсеңме аны? Светофор дип атала ул. Әнә кызыл ут яна. Бу «Туктап тор!» дигәнне аңлата. Хәзер сары ут яначак. Анысы «Игътибарлы бул! Юлыңны дәвам итәргә әзерлән» дигәнне белгертә. Сары уттан соң яшел ут кабыначак. Менә шул чагында инде юлны дәвам итәргә ярый. Аңладыңмы?

— Аңладым, аңладым, — диде Алпамыш. — Ә менә бу төстәге сызыклар нинди сызыклар?

— Болар — юл сызыклары. Светофорда яшел ут янгач, җәяүлеләр шушы сызыклы юл аша теге якка чыга алалар...

Алпамыш белән Зирәк юлларын дәвам иттеләр. Трамвайга утырдылар. Трамвай тәрәзәсе аша урамны күзәтеп барганда, Алпамыш ерактагы бер матур биннаны күреп алды. Ул бина оча торган тәлинкәгә бик тә, бик тә ошаган иде.

— Менә шушы була инде цирк! — диде Зирәк, әлеге бинага ишарәләп. — Әйдә, хәзер трамвайдан төшәбез...

Трамвайдан төшүгә, Алпамыш тиз генә трамвай артыннан юлның икенче ягына чыкмакчы иде, Зирәк аны туктатты.

— Ашыкма, Алпамыш. Трамвай артыннан чыгарга ярамый! Каршыдан килүче трамвай астында калуың бар. Трамвай киткәнне көтик, — диде ул.

— Әнә теге кешеләр нишләп арттан чыга соң? — диде Алпамыш, ерак түгел генә туктаган троллейбуска таба ишарәләп.

— Ул бит — троллейбус. Троллейбус белән автобусның артыннан чыгарга ярый. Анда да юлдан килүче машиналарга бик игътибарлы булырга кирәк.

Алар урам аша чыга башладылар.

— Урам аша чыканда, башта сулга, аннары уңга карарга онытма. Якынлашып килүче машиналар булмаса, юлны дәвам итәргә була, — дип аңлатты Зирәк.

— Барысы өчен дә рәхмәт сиңа! — диде Алпамыш.

— Кабат очрашканга кадәр! — диде Зирәк һәм үз юлы белән китеп барды.

— Сау бул! — диде Алпамыш. Ул Зирәк артыннан бераз карап торды да циркка кереп китте.

*Илнур Дәүләтша*

## Керпе

Элек Керпе хәзерге кебек чәнечкеле түгел, ә шәп-шәрә, бәләкәй генә бер бөҗәк булган. Урманда үләннәр белән тукланган, иртәләрен чык тамчысында коенырга яраткан. Тамчы аңа зур, тирән күл булып тоелган.

Шулай беркөнне, чыкта коенып ятканда, аның янына бер Сыерчык килгән. Бөҗәкне йотмакчы булып авызын ачкан икән, теге аның телен тешләгән. Сыерчык бик гаҗәпләнгән, чөнки моңа кадәр аны тешләгәннәре булмаган. Бөҗәкне капкан да биек агач башына менеп утырган. Шулчак көчле җил искән дә бөҗәкне әллә кая очыртып алып киткән. Очырта торгач, Гөлҗимеш куагының чәнечкеләре арасына элеп калдырган. Бөҗәк чәнечкеләрдән ычкыныр өчен чәбәләнә икән. Чәбәләнгән саен, Гөлҗимеш энәләре аның тәненә кадала, бөҗәкне кабарта икән. Берзаман бөҗәк гел энә белән капланган һәм Керпегә әйләнгән. Бөҗәк, үзенең энәдән генә торганын белеп, тагын да ныграк кабарынган, кабарына торгач, энәләре үзенә дә ошап киткән.

Гөлҗимеш чәнечкеләрен үзенә кире аласы бик килгән, Керпе аңа бирмәгән. Нишләп бирсен, хәзер аны бәләкәй генә кош түгел, Арыслан да күтәреп китә алмаган. Чәнечкеле йомгак шул ул хәзер.

Ә Гөлҗимешнең үзенә калган энәләре дә бик җиткән.

*Сәмига Сәүбәнова*

## Ак песи

Төзүче абыйлар һәм апалар бик матур урамда биш катлы йорт җиткерделәр. Шул матур йортның беренче подъездына өч малай, өч кыз күчеп килде. Алар бик тиз танышып, дуслашып киттеләр. Кыш көннәрен дә, яз көннәрен дә, җәй көннәрен дә гел бергә уйнап үткәрделәр.

Менә көз җитте. Агач яфраклары саргайды. Яңгырлар ява башлады. Кошлар җылы якларга очып киттеләр.

Яңгырлы бер көндә Айдар балалар бакчасына бармады... Киенеп, урамга чыгып китте.

Урамда кояш юк иде. Һавадагы болытларны һәм җирдәге яфракларны куып, салкын җил генә исә иде. Айдар урамда кызык тапмады... Колаклары туңгач, өйләренә кереп китте.

Ишекне ачкан иде, кемдер, нечкә тавыш белән:

— Мияу-у! — дип кычкырып куйды. Почмакта ап-ак песи утыра иде. Айдарны күргәч, тагын нечкә генә итеп:

— Мияу-у! — дип куйды.

— Туңып беткәнсең бит. Әйдә, безгә керәбез, пескәй, мин сиңа сөт белән күмәч бирермен. Җылынырсың да, тамагың да туяр, — диде Айдар. Ләкин песи урыныннан кузгалмады.

Айдар, тәлинкә белән җылы сөт һәм йомшак күмәч кисәге алып чыгып, аның алдына куйды. Песи юка кызыл теле белән, челт-челт итеп, сөт эчә башлады. Аны бетергәч, күмәчне дә ашап куйды. Тамагы туйгач, ал аякларына башын куеп, күзләрен йомды да тәмләп йокыга талды.

Айдар, аны тизрәк дусларына күрсәтү өчен, Галимнең, Рәзинә белән Рәзимәнең, Тимер белән Карачәчнең бакчадан кайтуларын көтә-көтә аптырап бетте. Кайтып керүләренә:

— Безгә песи килде! — дип сөенче алды.

Дуслары да песине бик яраттылар.

— Ура! Ура! — дип шатландылар.

Соңыннан, җыелышып утырып, аңа исем эзли башладылар.

*Газиз Мөхәммәтшин*

## Ялкау өчен ботка суынган

Җиңнәребезне сызганып, без эшкә киттек.

Кашык кадәр генә көрәгенә таянып, Ялкау очрады.

— Болай ашыгып кая барасыз? — дип сорады ул бездән.

— Эшкә барабыз, — дидек.

— Мин дә сезнең белән барыйммы, әллә ботка пешкәнне генә көтимме? — диде Ялкау.

— Төш җиткәнче, ботка пешкәнче эшләп алыйк, син дә бездән калышма, — дидек Ялкауга.

— Сез эшкә барып җитеп, әйләнеп кайтып та өлгермәссез, мин дә сезнең артыгыздан куып җитәрмен, — дип, Ялкау баскан урынында йокымсырап калды.

Эшләдек. Арыдык. Ботка ашарга дип кайттык. Көрәк кадәр зур кашыгын күтәреп, Ялкау тагын очрады

— Ботка суынмас борын, мин дә ашыктым, — диде Ялкау.

— Ялкау өчен ботка күптән суынган, — дип, без ботканы үзебез генә ашап бетердек.

*Идрис Туктар*

## Әбиләрдә кунакта

Беркөнне әни миңа:

— Кызым, Гөлгенә, яратканым син генә, кил, әйдә, киен, әйдә, әбиләреңә барабыз, бүләк илтеп кайтабыз, — диде.

Мин бик шатландым. Шатлыгымнан җырлый да башладым.

— Барабыз, барабыз, әбиләргә кунакка!

Әни дә мин, без икәү, киттек әбиләргә, әбиләр бездән еракта торалар.

Безнең капканы чыгасың — бер, Маратлар капкасы — ике, Хәлимнәрнеке — өч, Гарифларныкы — дүрт, Асияләрнеке — биш. Ә аннан соң бик күп, бик күп капкалар бар.

Безнең урам белән туп-туры барасың, барасың да сулга борыласың. Аннары тагын барасың-барасың да уңга борыласың. Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала, икенчесен дә үтәсең, өченчесенә дә кермисең, дүртенчесен дә узып китәсең, ә бишенче йорт — әбиләрнеке.

Беркөнне мин бик яхшы билгеләп кайттым. Аларның йорты каршында гына трамвай туктый. Бик билгеле урында безнең әбиләр йорты!

Әбиләр тора торган йорт бик зур. Түбәндә бер тәрәзә бар, аның өстендә тагын бер, аның өстендә тагын. Кул бармакларының барысын да берәм-берәм бөгеп бетерәсең: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тәрәзәләрнең очына чыга алмассың.

Әни әйтә:

— Әбиләрең бишенче катта торалар, — ди.

Без баскычлар буйлап шул бишенче катка атлыйбыз.

Берне менәбез, икене, өчне менәбез, дүртне, бишне. Бик күп баскычлар менсәк тә, әле без беренче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Ял итәбез дә тагын менәбез: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тагын бик күп баскычлар менәбез. Бу әле бары икенче кат кына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Тагын баскычның бер басмасы артта кала, ике басмасы, өч басмасы, дүрт, биш басмасы. Без әле бары өченче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Без тагын менәбез, тагын менәбез. Беренче катны менгәч ял итәбез, икенчене, өченчене, дүртенчене менгәч ял итәбез дә, бишенче катка менеп җитәбез. Безнең әбиләр менә шушы бишенче катта торалар.

Анда ишекләр бик күп: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...

Ә ишек яңагында бер түм-түгәрәк әйбер бар, аның уртасында бер төймә дә бар, әни шул төймәне бармагы белән басарга тотынды. Бер мәртәбә басты, эчтә «чылтыр!» итте. Икенче мәртәбә басты — тагын «чылтыр!» итте, өченче мәртәбә баскан иде, берәү:

— Кем бар? — дип сорады.

Әни әйтте:

— Кызым Гөлгенә дә мин генә.

Ишек ачылды. Аннан әби килеп чыкты, ул көлә иде. Ул мине күтәреп алды.

— Ай, кызым Гөлгенәм килгән, бик сагындырдың, бер атна бит инде сине күргәнем юк, — диде.

Без өйгә кердек.

Мин әнидән әкрен генә сорадым:

— Әни, атна нәрсә соң ул? — дидем.

Әни әйтте:

— Җиде көн, — диде. — Дүрткә берне кушсаң, биш була бит. Бишкә берне кушкач, алты көн була, алты көнгә тагын берне кушсаң, җиде көн була. Менә шул бер атна инде.

Әби безгә чәй эчертте. Безне коймак белән сыйлады. Мин биш коймак ашадым. Әни биштән дә күбрәкне ашады.

Мин бер чынаяк чәй эчтем, әни өчне эчте, ә әби биштән дә күбрәк, җидедән дә күбрәкне эчте.

Без әбигә бүләгебезне бирдек. Алар кып-кызыл алмалар иде. Әби ике кулына икешәр алма тоткач та, өстәлдә әле тагын биш алма калды. Барысы күпме булгандыр, мин белмәдем. Биштән дә күп, җидедән дә күбрәк.

Аннары без өебезгә кайтып киттек, әби безне озатып калды.

*Абдулла Алиш*

## Ирек, Алмас һәм Җәлил

Ирек комлыкта уйнап ята. Үзе генә уйный. Аның кечкенә автомашинасы бар. Автомашинага ком тутыра да бер җирдән икенче җиргә илтеп аудара. Комны бушаткач, кире килә, тагын ком тутыра, тагын илтеп аудара. Ул үзенчә чокырлар казый, юллар сала, буалар буа. Ул шулай уйнап ятканда, аның янына Алмас белән Җәлил килде. Ирекнең күңелле итеп уйнавын күрделәр дә кызыктылар болар. Аларның да юллар салып, чокырлар казып уйныйсылары килде.

— Ирек, әйдә, бергә уйныйбыз, — диде Алмас.

— Мин синең машинаңа ком төярмен, ә син шофёр булырсың, — диде Җәлил.

Ләкин Ирекнең аларны уенга катыштырасы килмәде.

— Кирәкми, мин үзем генә уйныйм, — диде ул.

Малайлар аның сүзенә карамадылар, шунда комлыкта уйнарга да керештеләр. Комнан юллар салдылар, буалар будылар, таулар өйделәр. Ләкин алар комны куллары белән ташыдылар, чөнки аларның машиналары юк иде.

Ирек машинасын аларга бирмәде. Һаман үзе генә уйнады. Алай гына да түгел, Алмас белән Җәлил килгәч, аңа комлыкта урын тар булып күренә башлады.

— Минем комны алмагыз! — диде ул, шыңшып.

— Синекен алмыйбыз бит! — диле Алмас. Ирек барыбер тынычланмады.

— Минем юлны таптамагыз! Минем чокырны бозмагыз! — диде ул, бәйләнчекләнеп.

— Синеке түгел, үзебезнеке! — диде Җәлил.

— Юк, минеке! Бу — минем юл! Бу — минем буа! — диде Ирек.

Шулай диде дә иптәшләре ясаган юлны аягы белән бозып ташлады. Алмас белән Җәлилнең моңа ачулары килде. Шулай итеп, малайлар ачуланыштылар да киттеләр.

Ирек еларга тотынды. Автомашинасын күтәрде дә, «әни!» дип кычкыра-кычкыра, үзләренә йөгерде.

Ләкин Ирек өйләренә кайтып җитә алмады. Тыкрыкта аңа кара эт очрады.

Чыннан да, Ирекнең коты алынды. Ул шундый курыкты, куркуыннан хәтта елавыннан да туктады.

Нишләргә хәзер? Эт янына барып булмый. Барсаң кабар да йотар! Шулай ук аны читләтеп үтәргә дә мөмкин түгел — ике якта бөек коймалар.

Малай нишләргә белми карап торды-торды да кире йөгерергә тотынды. Ул, тыны бетеп, Алмас белән Җәлил янына килде.

— Ник килдең, елак? — диде Алмас.

Ирек рәтләп сүзен дә сөйли алмады.

— Э-эт... э-эт бар! — диде ул, тотлыгып.

Җәлил белән Алмас уйнауларыннан туктап калдылар. Ирек янынарак килделәр.

— Кайда ул? Кайда? — диделәр алар.

— Те... те... тегендә... тыкрыкта, — диде Ирек.

— Әйдәле! — диде Алмас, Ирекне үз артыннан ияртеп.

Малайлар тыкрыкка таба китеп бардылар. Карасалар, кара эт һаман шунда басып тора. Юл уртасында, эттән читтәрәк, Ирекнең автомашинасы аунап ята.

Батыр Алмас кулына таяк алды, кыюланып, эткә таба атлады. Хәзер инде Ирек курыкмады. Өчәү булгач, нишләп куркып торырга?

Эткә якынлашкач, Алмас таягын ыргытты. Ирек белән Җәлил этне куркытып кычкырырга тотындылар.

Кара эт малайларга гаҗәпләнеп бер карады да койрыгын болгап алды, башын иде һәм иренеп кенә китеп барды. Тыкрык бушап калды.

— Кайтасыңмыни? Бар инде,— диде Алмас Иреккә.

— Юк, мин сезнең белән уйныйм, — диде Ирек.

*Нурихан Фәттах*

## Велосипедлы Мөнир

Мөниргә әтисе магазиннан өр-яңа велосипед сатып алды. Мөнир велосипедын җитәкләде дә урамга чыкты. Аның тирәсенә шундук иптәш малайлары җыелды.

— Мөнир, йөреп торырга миңа да бирерсең әле велосипедыңны? — диде Илдус. Бүтән малайлар да:

— Эх, нинди ялтырап тора!

— Бер генә тотып карыйм әле, — диештеләр

Мөнир велосипедын бик кызганды. Аның үз әйберсенә беркемне дә кагылдырасы килмәде.

— Теләнмәгез дә, берегезгә дә бирмим, — диде ул, кырт кисеп.

Ләкин Мөнир велосипедта йөри белми иде. Шуңа күрә аны, велосипедка утыргач аумас өчен, арттан кем дә булса тотып барырга тиеш иде.

— Ярар инде, алайса, син генә йөреп карарсың, — диде ул Илдуска. — Тик мин утыргач, син велосипедны тотарсың... ычкындыра күрмә... Басуга чыгып, әнә теге чыршы турысына җиткәч, мин төшәрмен дә син китәрсең.

Илдус бик шатланып риза булды. Мөнир киртә янына килде дә велосипедның ияренә атланып утырды. Илдус велосипедны тотып торды.

Менә алар әкрен генә кузгалып киттеләр. Велосипед баштарак әле бер якка, әле икенче якка кыйшайды. Әгәр Илдус ныгытып тотмаган булса, Мөнир шундук егылып төшкән булыр

иде. Шулай да ул бераздан тигезлеген саклый ала башлады, һәм велосипед такыр юлдан җиңел генә тәгәрәп китте.

Тиздән иптәшләре дә, авыл да артта калды. Алар юл буендагы чыршы турысына да якынлаштылар. Илдус бик кызу йөгерүдән тирләп чыкты, кызарды.

— Тукта инде, Мөнир... — диде Илдус, ялгыз чыршыны узып киткәч.

Мөнир туктамады, киресенчә, тагын да кызурак бара башлады.

— Мөнир, йөрерсең дип үзең әйттең ич... тукта инде, — диде Илдус, кызганыч тавыш белән. — Туктамасаң ычкындырам. Кит үзең генә.

— Ычкындырсаң әллә! Бар, китә бир, — диде Мөнир, бер дә исе китмичә. — Мин инде синнән башка да йөри алам.

Илдус бик хурланды. Мөнирнең велосипедын ычкындырды да, кире борылып, авылга таба йөгерде. Мөнир, иптәшеннән котылуына сөенеп, тагын да кызурак китте.

Бара торгач, юл кисәк кенә түбәнәя башлады. Велосипед, тигезсез юлда дыңгырдап, һаман шәбрәк тәгәрәде. Хәзер инде педальгә басарга да кирәкмәде. Мөнирнең колак төбендә җил сызгырды, йөрәге куркудан жу итеп китте: велосипедның йөрешен әкренәйтү өчен, тормозга басарга кирәклеген ул белми иде.

Велосипед очты гына. Мөнир үз алдында берни дә күрмәде, куллары, аяклары тыңламас булды. Һәм коты алынган малай, үзе дә сизмәстән:

— Илдус! Тот, ычкындырма! — дип кычкырып җибәрде.

Зырылдап әйләнеп барган алгы тәгәрмәч кинәт читкә кереп китте, һәм Мөнир велосипеды-ние белән юл читендәге чокырга мәтәлеп төште.

Аның янында беркем дә юк иде.

*Нурихан Фәттах*

## Иртәнге нурлар

Күк йөзенә кып-кызыл булып Кояш килеп чыкты да төрле якка үзенең алтын нурларын сибәргә, җирне уятырга кереште.

Беренче нур сызылып үтте дә Тургай өстенә төште. Тургай талпынып куйды, оясыннан пырхылдап очып чыкты һәм биеккә-биеккә күтәрелде дә көмештәй тавышы белән өздереп сайрап җибәрде: «Ах, иртәнге саф һавада нинди рәхәт! Нинди рәхәт! Нинди иркен!»

Икенче нур Куянкайга төште. Куянкай колакларын селкетеп куйды да, шатланып сикерә-сикерә, чыклы болын буйлап чабып китте. Үзенә иртәнге ашка сусыл үлән эзләп китте ул.

Өченче нур тавык кетәгенә төште. Әтәч канатларын җилпеде дә: «Кикрикү-ү-үк!» — дип кычкырып җибәрде. Тавыклар, кытаклый-кытаклый, куначаларыннан сикереп төштеләр һәм, чүп-чарда тибенә-тибенә, суалчан-кортлар чүпли башладылар.

Дүртенче нур умарталарга төште. Бер корт кәрәз өеннән чыкты да ояның ишек төбенә кунды, канатларын җәеп җибәрде һәм, хуш исле чәчәкләргә куна-куна, бал җыярга дип очып китте: «бз-з-з-з!»

Бишенче нур балалар бүлмәсенә, йоклап яткан бәләкәй ялкау өстенә төште, аның күзләрен чагылдырып җибәрде. Ә ул икенче ягына борылды да тагын йокыга китте.

*Константин Ушинский*

## Сыер

Сыер ул үзе бик матур түгел түгелен, ә сөт бирә. Маңгае киң, колаклары як-якка киткән, тешләре күп түгел, аның урынына мөгезләре бик зур, койрыгы пумала кебек, корсагы бүлтәйгән, тояклары икегә аерылган. Ул үлән йолка, күши, башак болгаган су эчә, мөгри һәм кычкыра, хуҗа хатынын чакыра:

— Хуҗакаем, бирегә чык, сөт саварга чиләк алып чык, сөртергә чүпрәк алып чык! Мин кайттым, балакайларга сөт тә, куе каймак та алып кайттым, — ди.

*Константин Ушинский*

## Сөт елгасы

Безнең Маша ботка яратмый. Әнисе ботка пешереп китердеме, елый ук башлый: «Әйем, әйем, ашамыйм, ашамыйм», — ди.

Беркөнне Машаның әнисе кашык алды да ботка эчендә елга ясады. Шул елгага сөт салды. Тәлинкә эчендә сөт елгасы ага башлады.

— Йә, кызым, сөт елгасын ашап кара әле, — диде әнисе.

Маша, куана-куана, сөт елгасын ашый башлады. Елганың ярын каба да сөт эчеп җибәрә, ярын каба да сөт эчеп җибәрә.

Менә кызык!

Караса, тәлинкәдәге ботканы ашап та бетергән ич!

*Я. Тайц*

## Канатларың булса...

Бер кыз кошларның канатлы булуларына кызыгып яшәгән.

— Ник минем канатларым юк икән? — дигән бу кыз әнисенә.

— Кошларның канатына кызыгасыңмы? — дигән әнисе.

— Әйе, бик кызыгам, — дигән кыз.

— Канатың булса нишләр идең, балам? — дигән әнисе. — Әллә очып китәр идеңме? Мине калдырып?

— Очып китәр идем дә... Очып кайтып җитәр идем, сине сагынып, — дигән кызы.

Әнисе кызын кочагына алган. Кыз да әнисен кочаклаган.

— Канатларың булса, кулларың булмас иде. Син мине болай кочаклый алмас идең, кызым, — дигән әнисе.

Кыз шунда әнисен тагын да кысыбрак кочаклаган.

Моннан соң ул кошларның канатлы булуына да кызыкмаган. Аларга ул бик яратып карый, кызганып та куя... Үзенең бердәнбер әнисе, әнисен кочакларга ике кулы булган өчен шатланып яши икән.

*Рөстәм Мингалим*

## Агачлар да авырый

Яз башлануга, Рәмиләнең әтисе көн дә бакчада була. Ул агач төпләрен йомшарта, корыган ботакларны кисә. Рәмилә әтисе янында йөрергә ярата.

— Әти, агач төбен нигә казыйсың?

— Агач төбен йомшартам, кызым, — ди әтисе.

— Нигә йомшартасың аны? — дип сорый Рәмилә.

— Йомшартмаган агачка су сипкәч, аның төбе катып кала. Су агач тамырларына кадәр үтә алмый. Тамырлар һава сулый алмыйлар.

— Агачлар да сулыймы?

— Сулый, кызым. Алар өчен дә һава кирәк.

Беркөнне кемдер бакча ишеген ачык калдырган. Шуны гына көткән кәҗә бакчага кереп тә китә. Рәмиләнең әтисе, тиз генә чыбык алып, кәҗәне куып чыгара.

Рәмилә:

— Әти, нигә кәҗәне куасың? — дип сорый.

Әтисе Рәмиләне бакчага алып керә, кәҗә кимерә башлаган агачны күрсәтә.

— Кимерсә ни була?

— Агачларыбыз авырый, яфраклары саргая, үзе корып кала. Аннан соң ул алма бирми башлый.

— Агач та авырыймы?

— Авырый, кызым, хәтта корып, үлеп тә китә.

— Бу алмагач та корыймы инде, әти? — дип сорый ул, еламсырап.

— Бәлки, корымас, — ди әтисе. — Без бу агачны дарулап, бәйләп куярбыз.

Шуннан соң Рәмилә авыру агач янына көн дә килеп йөри башлый. Ул әлеге агачның бөтерелә, яшеллеген югалта башлаган яфраклары яңадан яшәрә башлавын күреп куана. Ә беркөнне ул, шатлыгыннан сикерә-сикерә, бакчадан әнисе янына йөгереп керә.

— Әнием, агач терелгән, яфраклары көлеп тора, — ди ул.

*Зәкәрия Әхмәров*

## Йорт салалар

Тышта тагын кар яуган. Койма буйларында шундый матур, шундый тигез, йомшак булып ята ул: күз камашырлык! Азат киенеп чыкканчы, таптап, бозып китмәсәләр генә ярар иде. Әнә күршеләрнең Акбае юл читенә баскан да уңга-сулга карап, эреләнеп тора. Койма буендагы карны таптыйсы булмагыз, ботыгызны тешләрмен, янәсе! Хәзер Азат чыгар, аның белән карга бата-чума уйнарбыз дип көтәдер әле.

Азат көрәген тотып ишегалдына чыгуга, Акбай аны койрыгын болгый-болгый каршылады:

— Һам-һам!

Бу аның: «Мин кайчаннан бирле сине көтеп торам!» — дигән сүзе инде.

Азат, иркәләп, аның башыннан сыйпады:

— Әйдә, Акбай, кардан өй ясыйк. Бик зурны, әнә теге безнең каршыдагы биш катлы йорт хәтлене! — диде.

Акбай, аңлаган кебек, койрыгын селкеп куйды:

— Һам-һам!

«Бик шәп, әйдә, мин дә булышырмын», — ди Акбай үзенчә.

Кеше аягы тимәгән кар, койма буенда ятып, шактый басылган икән. Азатның көрәге тиз генә батып китмәде. Шулай да ул бер шакмак кар кисеп алды. Алды да бераз аптырап торды...

Азат берүзе. Күңелсез болай. Ул зур эшкә keреште бит: йорт сала! Карны шакмаклап ала да берсе өстенә икенчесен өя бара.

Шулвакыт  Гөлшат килеп чыкты. Аның кулында кечкенә генә тимер көрәге бар, бик матур кызыл көрәк!

Гөлшат кардан ясалган стенага карап торды да:

— И-и, нинди матур йорт булыр бу, Азат! — диде. — Тик менә тәрәзәләре юк икән...

— Әйдә, алайса, бергәләп ясыйк!.. — диде Азат.

Тәрәзәләр ясалды, түбәсен дә әйбәтләп яптылар. Инде эш бетте дигәндә генә, Вова килеп җитте.

— Әбәү, моның морҗасы кайда? Морҗасыз йорт буламыни?

— Була шул, — диде Гөлшат, аңа каршы төшеп. — Хәзер йортларны газ белән җылыталар, беләсең килсә!..

Шулвакыт ишекгалдында Илгизәр күренде. Ул:

— Ай-һай, нинди матур йорт! Нәкъ чын шикелле, — диде. — Ә... ишекләре?

—  Нәрсә, нәрсә? — диделәр балалар.

— Ишекләре кайда? Бер ишеге дә булмагач... Түбәсеннән төшеп йөрерсезме?!

Балалар аптырап калдылар. Чыннан да, ишек ясарга онытканнар ич алар!..

Дуслар, дәррәү эшкә тотынып, бер-ике ишек тә ясап куйдылар. Хәтта ишекләрнең берсенә Акбай башын да тыгып карады. Янәсе, кирәк-ни булса, бу ишектән  эчкә кереп булырмы икән!

— И-и, нинди матур!

Карасалар — күрше йорттагы Гөлчәчәк килеп җиткән икән. Эш белән мавыгып күрми калганнар аны балалар.

...Дуслар йортның шундый матур булып чыгуына үзләре дә исләре китеп карап торалар. Азат кул чабарга тотынды, Гөлшат иптәшләрен җитәкләп җырлап җибәрде:

И-и, карагыз, күрегез,
Нинди матур өебез!

Балалар йорт тирәсендә әйлән-бәйлән уйный башладылар. Акбай да алардан калышмады, ул да булышты ич йорт салырга!

*Госман Бакир*

## Актырнак белән Назбикә

Минем Актырнак исемле көчегем белән Назбикә исемле песи балам бар. Икесе дә шундый матур! Икесе дә йомгак шикелле инде менә. Бергәләшеп уйный башласак — чыдап кына тор! Өйнең асты өскә килми торып туктау юк. Мин кайчакларда бик арыйм. Актырнак белән Назбикә уйный бирә. Ничек арымый торганнардыр инде. Алар өйне туздыра, мин җыештырам... Назбикә түгәрәк әйберләр белән уйнарга ярата. Уйнап, хикмәтләр күрсәтә инде! Сыртын кабарта, усал итеп мырылдый ук башлый. Актырнакка да кызык бит, аның уенчыгын иснәп карыйсы килә. Тик кая ул иснәү, якын да җибәрми Назбикә. Тырнакларын батырырга гына тора. Нәкъ күрше Гөлгенә төсле инде менә. Ул да шул: кеше курчаклары белән уйнарга ярата. Ә үзенең курчагын тотып карарга да ярамый. Йә тырный, йә тешли, йә елый ук башлый...

Тиз дә үсә Актырнак белән Назбикә! Үсүен үсәләр дә... Үскән саен, әллә нишлиләр шунда. Белмим инде, ни җитмидер. Көненә ике-өч тапкыр ызгышалар. Назбикә бигрәк тә усалланды. Әле беркөн генә Актырнакның борынын тырнап канаткан. Жәлләп куйдым мескен маэмаемны. Әти дә: «Актырнак инде үсте, оясында торсын», — ди.

Хәзер Актырнак тышта, Назбикә өйдә яши. Назбикә мамык түшәктә йоклый, Актырнак — салам өстендә. Без йокларга ятуга, Назбикә, мыр-мыр итеп, карават янына килеп җитә. Юрган асты Актырнак оясы түгел. Монда җылы... Назбикә төне буе мырлавын гына белә. Актырнак исә ләң-ләң итеп өргәләп алырга да онытмый. Шук малайлар, кереп, бакчадагы чәчәкләрне өзмәсен, диптер инде...

Хәзер мин Актырнакны ныграк яратам. Нигә икәнен үзем дә белмим...

*Җәүдәт Дәрзаман*

## Көн җылынды

Әтисе белән әнисе, әйбәтләп киендереп, Хәйдәрне дә үзләре белән ишегалдына алып чыктылар. Тышта салкын. Кар ява.

Әтисе белән әнисе утын кисәргә кереште. Ә Хәйдәр бер читтә басып карап торды. Бераздан аның бүрек түбәсен, җилкәләрен кар каплап китте.

Әтисе Хәйдәргә таба борылды да, елмаеп:

— Улым, кар күмеп китә күрмәсен үзеңне, — диде.

Ә бераздан әнисе:

— Улым, туңмыйсыңмы? — дип сорап куйды.

Хәйдәр ни дияргә дә белмәде. «Туңам» дисә, өйгә кертеп җибәрүләре бар, ә аның өйдә утырасы килми. «Туңмыйм» дияр иде, — суык. Әнә бит суык, шаярган кебек кенә итеп, борынны, бит очларын чеметеп алды. Аннары бияләй эчендәге бармакларга, итекләр эчендәге тәпиләргә үк барып җитте...

Әтисе белән әнисе эшлиләр дә эшлиләр. Кая ул туңу! Тирләп чыкканнар. Бераздан әтисе Хәйдәр янына килде.

— Улым, туңасың ич, — диде ул. — Яле, шушыларны утынлыкка илтеп куй, суык синең янда тора алмасын.

Хәйдәр ярып ташлаган утын агачларын берәм-берәм утынлыкка ташый башлады.

— Менә улыбыз да эшкә ярый хәзер, — дип куаныштылар әтисе белән әнисе.

Бераздан Хәйдәр, әнисе янына килеп, бүрек колакчыннарын чишәргә кушты.

— Әни, көн җылынды! — диде ул.

Әтисе белән әнисе рәхәтләнеп көлештеләр. Аннары әтисе, Хәйдәрнең аркасыннан сөеп:

— Көн җылынмады, улым, эш җылытты сине, — диде.

*Мәхмүт Хәсәнов*

## Кое чыпчыгы

Минем апам зур шәһәрдә яши. Әни әйтә, анда өйләр шундый зур, кемнәр яшәгәнен дә белеп бетереп булмый, ди. Ничек инде ул үзең яшәгән өйдә кем торганын белмисең, ди? Әгәр моны Диләрәгә сөйләсәң ышанмый да. Аннары тагын ялганчы булып калам. Каян белсен инде Диләрә, аның апасы да бик бәләкәй бит әле, читкә китәрлек түгел. Югыйсә ул сөйләр иде Диләрәгә зур өйләр турында.

Чынлап та, менә безнең өйдә, кыр куянын, песине чутламаганда, әти, әни, абый, мин, сеңлем Әлфия. Әле мин безнең өйдәге кешеләрне генә түгел, авылдагы барлык кешеләрне беләм. Кушаматларын да. Безнең авылда Наилләр генә җидәү. Каян белеп бетерәсең аларны, кушаматларын белмәсәң!

Кемдер кереп килә, ахрысы, капка тавышы ишетелүгә, тәрәзәгә карасам... урам кар белән тулган.

— Әни, әни, кар ява икән бит, нишләп әйтмичә торасың? — дип, чөйдә эленеп торган бишмәтем янына атылдым.

Беренче кар! Ур-ра! Әллә кайчаннан мине көтеп яткан чанамны эләктердем дә Диләрәгә йөгердем.

— Диләрә, чык кар ява! Диләрә, дим, чык инде, кар ява бит.

Диләрә чыкты.

— Нигә шулхәтле кычкырасың?

— Кар яуганын күрми каласың бит.

— Нәрсә дисең?

— Һи, шушының бер! Мактанчык! — дидем мин, аның янына ук килеп. — Харап икән, яңа чаналы булган икән. Ишетмәгән булып кылана! Бик беләсең килсә, былтыр минем чанам да өр-яңа иде, шуа-шуа искерде.

— Ә минем өр-яңа!

— Булса ни!

— Ә минем буявы да уңмаган! — диде Диләрә, чанасын бавыннан күтәреп.

— Ярар, алайса, карап тор шул яңа чанаңа! — дидем дә, иске чанамны тартып, тауга йөгердем.

— Тукта инде, мин дә барам бит, — дип, мышный-мышный, Диләрә дә минем арттан йөгерде.

Без килүгә, абыйлар зур итеп кар бабай ясаганнар, борынына кызыл кишер, күзләренә кара күмер куйганнар иде.

— Әйдә, без дә үзебезнең кар бабайны ясыйбыз!

Кулларыбызның туңуларын да онытып, зур кар бабай янына кечкенә кар бабайлар ясап куйдык. Алар шулхәтле кечкенә булып чыктылар, без аларга кар малайлары дип исем куштык.

Ә абыйлар һаман тәгәрәтәләр дә тәгәрәтәләр карны. Күп яуса да, беренче кар бит әле ул.

— Малайлар! Әйдәгез, безнең коега кар тутырабыз. Ну, шапылдап төшә дә ул кое төбенә, — диде Мансур.

Безгә кызык. Карның кое төбенә төшкәнен карыйсы килә. Алар безне коега якын да җибәрмиләр. Аларның коелары тирән, ләкин анда бер тамчы да су юк. Җәй көне олы кешеләр, күмәргә кирәк дип йөрсәләр дә, тагы калды шул көе. Өч малай, карны зур итеп тәгәрәтеп, коега капладылар. Кар кысылды да калды.

— Менә шапылдады сиңа, — диде Рифат, — әйттем мин сезгә, зур итмәгез дип.

— Һәй, куркаклар, — диде Мансур, кое авызындагы кар өстенә менеп тә басты. Менеп басты да: «Күрдегезме абзагызны?!» — дип, кое кырыендагы баганага тотынып, тыпырдатып та алды.

— Баганага тотынма син, тотынгач, кем дә сикерә аны, — диде Илнур.

— Әйе, әйе, тотынмыйча сикер, бик батыр булсаң, — диештеләр малайлар.

— Тотынмыйчамы? Һи! Әллә сикермәс дип беләсезме? Бер, ике, өч...

Өч дигән тавыш инде кое астыннан килде. Кары-ние белән Мансур кое төбенә очты.

Безнең тавышка чыккан олылар да, без дә яңадан кое янына җыелдык.

— Кар коймагыз, — диде Мансур кое эченнән, тонык кына тавыш белән.

— Әй яшьти, — диде Рифат, — нәрсәләр бар анда кое төбендә?

— Монда әйбер күп. Нурсамат абыйның югалган мотоциклы да монда икән, малайлар!

Мансурның коега төшү хәбәре бик тиз таралып өлгерде, кое янына халык җыелды. Озын бау тоткан Мансурның әтисе кое баганасына тотынып басып торган Мансурның әнисенә инде ничәнче мәртәбә:

— Нигә безнең балалар гына коега төшә? — дип сорый.

Ә әнисе кулын гына болгый, тизрәк чыгарыгыз, янәсе.

Ул арада Мансурны тартып чыгардылар. Менә, бәхетле булгач, бер җире дә сыдырылмаган. Шул көннән башлап, Мансурга «Кое чыпчыгы» дигән кушамат тагылды да калды. Үзе гаепле. Мактанмасын иде.

*Нәзифә Кәримова*

## Татлы җәй

Төлке баласы Шаян кошлар сайравына уянды. Күл буена барып, битен юды. Әйләнеп кайтканда, әнисе өстәлгә тәмле-татлы ризыклар куйган иде. Тамагын туйдыргач, Шаян әнисенә рәхмәт әйтте.

— Улым, Җәйгә дә рәхмәт әйт. Бу — Җәй нигъмәтләре, — диде әнисе, Шаянның башыннан сыйпап.

— Әнием, ә Җәйне кайдан табармын соң мин? — дип сорады Шаян.

— Җәй җиләкле урман аланында яши. Әмма ул акыллы балаларга гына күренә.

— Ә акыллы бала нинди була соң, әнием?

— Акыллы бала агач һәм куак ботакларын сындырмый, чәчәкләрне өзми, суны пычратмый, улым. Гомумән, башкаларга гел игелек кенә кыла.

Шаян, Җәйне күрү өчен, урман аланына юнәлде. Барганда, урман сукмагында бер Кырмыскага чак кына басмый калды.

— Гафу ит, зинһар, Кырмыска дус, — диде Шаян һәм әдәп белән аның яныннан сак кына үтеп китте. Ул ерак китәргә өлгермәде, куаклар арасында чырылдашкан тавышлар ишетте. Шәүлегән баласы оядан егылып төшкән икән. Әнисе, ни эшләргә белми, аның янында бөтерелә, елый.

Шулчак кинәт каяндыр Карга атылып чыкты. Шаян, сикереп, Шәүлегән баласын гәүдәсе белән каплады. Төлке баласына бәрелгәч, Карга усал каркылдап очып китте. Шаян бәләкәчне оясына салды.

— Рәхмәт сиңа, акыллы малай, — диде Шәүлегән. — Син минем баламны үлемнән йолып калдың. Мин, батырлыгыңны җырга салып, башкаларга да сөйләрмен.

Һәм Шәүлегән, биеккә күтәрелеп, өздереп сайрый башлады.

Шаян алга атлады. Кинәт урман ачыклыгындагы агач ботаклары шартлап сына башлады. Якынрак килеп караса, Аю балалары икән.

— Нигә ботакларны сындырасыз?! — диде Шаян, аларны шелтәләп.

— Без бит көй чыгарабыз, — дип аклана башладылар нәни йөнтәскәйләр, уңайсызланып.

— Сез шулай көй чыгарсагыз, кичкә урманда бер исән агач та калмас, — диде Шаян һәм аларга корыган агач чырасыннан кубыз ясап бирде.

Шулай урман аланына җитүен сизми дә калды Шаян. «Инде ничек Җәйне табармын», — дип, күл буендагы агач төбенә утырып кайгыга чумды.

Шулчак гаҗәеп ягымлы тавыш ишетелде.

— Кайгырма, Шаян, мин монда. Күрәсеңме, кызарып җиләкләр пешә. Кылган игелекләреңөчен алар сиңа бүләгем булсын. Кояш җылы нурын сипкәндә, кошлар сайраганда, чәчәкләр хуш ис таратып, өсләрендә күбәләкләр очканда, мин һәрчак янында булырмын.

Шаян җиләк өзеп алды да, күзләрен йомып, авызына капты. Кара син аны, Җәй нинди татлы икән, ә?!

*Фирдәвес Зариф*

## Бал дәвалый

Исмәгыйльнең тамагы шеште. Температурасы күтәрелде, хәтта колак яфракларына хәтле уттай яна. Исмәгыйльнең үзеннән бигрәк, әнисе хафага төште. Чөнки алар атна башыннан Чаллыга кунакка барырга тиешләр. Инде билетларны да алып куйганнар иде.

Ә хәзер менә Исмәгыйльне хастаханәгә үк салып куймагайлары. Исмәгыйльнең анда ятып чыкканы бар. Утыргыч битенә энә кадап, тәмам җәфалап бетерделәр.

Әнисе бу юлы да табибә апаны дәште. Озаклап тыңлап карагач, табибә апа: «Бал белән дәвалагыз, ике көннән сихәтләнер», — диде.

Әнисе, җылы сөткә бал туглап, Исмәгыйльгә эчертә башлады. Гаҗәп! Малайның хәле кичкә үк яхшырды. Әнә нинди тылсымлы көчкә ия икән ул бал!

Хәзер Исмәгыйль һәр чәчәк таҗына кунган бал кортына чын күңелдән сокланып, яратып карый. Аны кулына алып сөясе килә Исмәгыйльнең.

*Альберт Хәсәнов*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Көз

Алтын-сары
Яфракларны
Җилләр саный.
Иртә-кичен
Суык бабай
Бармак яный.
— Ник гомергә
Килми икән
Шушы язлар?! —
Дигән кебек,
Моңсу гына
Китә казлар.

Әнә инде
Юлга чыккан
Торналар да...
Бер үк сүзне
Кабатлыйлар
Гүя бар да:
— Суык бабай
Арттан җитеп
Харап булмыйк,
Оча торыйк,
Тор-рыйк,
Тор-рыйк!

*Хәкимҗан Халиков*

## Көзге табын

Көзге табын — бай табын,
Кыяр, карбыз һәм кавын
Телем-телем теленгән,
Өем-өем өелгән.

Алмалары ал төсле,
Балкып туган таң төсле.
Капсаң эри авызда,
Һәр кисәге бал төсле.

Ә җимеше, җимеше, —
Ачысы бар, төчесе!
Яңа пешкән күмәчтер
Кайнар кояш төслесе.

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.
Көзләр юмарт булганга,
Бик бәхетле, бик шат без.

*Фәнис Яруллин*

## Без игенчеләр булдык

Әти дә эшкә китә,
Әни дә эшкә китә,
Абый мине һәр көнне
Иртүк бакчага илтә.
Бакчабыздагы апалар
Безне бик яраталар.
Төрле-төрле, кызык-кызык
Уеннар уйнаталар.
Әйтте бүген Алсу апа:
— «Очучылар» күп бездә,
«Капитаннар» күп бездә.
Ә ник әле «сабанчылар»,
«Игенчеләр» юк бездә?..
Игенчеләр булмаса,
Ак күмәчне кем бирер?
Ботка, бәлеш кем бирер?
Ипине кем үстерер?
Яле, кемнең шәп игенче
Буласы килә икән?
Бездә бүген «игенчеләр»,
«Сабанчылар» бар
микән? —
Йөгереп янына килдем,
Иң беренче өлгердем:
— Бар, апа, бар! Үзем, үзем
Игенче булам! — дидем.
Апа көлеп карады:
—Шулаймыни? Ярар, — ди.—
Әйдәле, Зирәк, алайса,
Иген игеп карале...
Ә мин комлык янына
Килдем шундук туп-туры:
— Комлык түгел бүген бу,
Бу бүген — «иген кыры!»
Апа әйтте:
— Йә, Зирәк,
Башта нишләргә кирәк?
Озак уйлап тормадым:
— Бирегез, — дидем, —
көрәк!
«Җирне» казый башладым.
Ике-өч көрәк ташладым...
Тик әллә җире бик каты,
Әллә көрәк сынатты,
Әллә көч җитми шунда...
Апа әйтте:
— Көрәк түгел,
Трактор кирәк монда! —
Тракторын тырылдатып,
Наил килеп тә җитте.
Сүз әйтергә өлгермәдем,
Җирне сөреп тә китте.
Тырма тагып артына,
Китереп бар шартына,
Тагын әйләнеп килде.
Шәпләп тырмалап бирде.
Менә ничек булышты,
Трактор — шәп булышчы.
Килдек апа каршына:
— Инде чәчәргә кирәк... —
Иңгә тагып зур чиләк,
Ары да үткән булам,
Бире дә үткән булам,
Бик тырышып бураznага
«Орлыклар» сипкән булам.
Тик, чәчелми матур итеп,
Чәчелә әллә ничек:
Әле еш, әле сирәк...

Апа әйтте:
— Чиләк түгел,
Монда шул чәчкеч кирәк! —
Нил чәчкеч алып килде,
Шундый да кызу йөрде,
Шундук чәчеп тә бирде.
Минә ничек булышты
Чәчкеч дигән булышчы!
— Инде, ашлама кертеп,
Туклындырыйк мул
итеп... —
Тик
Мин шул җир ашлый
белмим,
Җилкә кашып тик йөрим.
Ә вакыт һаман үтә,
«Туфрак» ашлама көтә...
Апа әйтте:
— Безгә хәзер
Самолёт ярдәм итәр... —
Самолёт килеп җитте,
Гүелдәп очып үтте,
Җирне «ашлап» та китте.
Минә ничек булышты,
Самолёт — шәп булышчы!
Апа әйтте:
— Инде менә
Яңгыр сибәләп алса,
Әйбәт булыр иде, аннан
Кояш көлеп караса... —
Ник яумасын, «явар шул»,
Айгөл «яңгыр яудырды».
Уңган кыз ул, булдырды.
Аннан кояш карады,
Йомшак җилләр
«игеннәр»не
Иркәләде, тарады...
Нурлар йотты, дым эчте,
«Иген» өлгереп җитте...
Күрегез, ничек алар
Чайкалып утыралар...
Апа хәйләле карый:
— Бусы булды, ди.
Ярый.
Инде менә көз җитте,
Әллә безгә эш бетте?!
— Юк. Хәзер кирәк кырга
Комбайн чакыртырга! —
Комбайнын гөрләтеп,
Камил килеп тә җиткән.
Комбайны шәп икән,
Әллә тылсымлы микән?
Үзе ура, үзе суга,
Үзе җилгәрә икән!
Бик тырышып булышты,
Комбайн — шәп булышчы!
Шундук МАЗ килде
«кыр»га,
Игенәрне ташырга,
Ташырга амбарларга,
Исәпләргә, барларга...
— Апа, дидем, менә
хәзер
КамАЗ да булса икән! —
Карасам, КамАЗы
белән

Алмаз килеп тә җиткән.
Чыж да выж килеп
йөрде,
Игенне ташып бирде.
Бар көченә булышты,
КамАЗ — әйбәт булышчы!
Апа әйтте:
— Аңлатсагызчы безгә:
Мондый уңыш үстерергә
Кем ярдәм итте сезгә? —
Кабалана-ашыга:
— Апа, апа, безгә, дидек,
Ярдәм итте машина!
Машиналар ярдәм итте,
Әнә нинди күп алар.
Тракторлар, комбайннар...
Тезелешеп торалар.
Без булдык бүген аларның
Механизаторлары.
Ә Нил белән Наил булды
Машина докторлары...
Менә нинди кешеләр.
Без — нәни игенчеләр!
Ә аннары килде безгә
«Көзге уңыш бәйрәме.
Табын-табын сый-
хөрмәт,
Гөл-чәчәкләр бәйләме...
— Ягез әле, — диде апа, —
Хөрмәтле «игенчеләр» —
«Чирәм-җир сөрүчеләр»,
«Икмәк үстерүчеләр»,
Ягез, рәхим итегез,
Түрдән, түрдән үтегез!..—
Бар да тезелеп беткәч,
Апа зурлап баш иде:
— Рәхмәт, «уңган
игенчеләр»,
Зур рәхмәт сезгә! — диде.
Аннан әтиләр үстергән
Күмәчне алып килде.
Һәм әйтте ул: — Балалар,
Онытмагыз икенче:
Ипекәй ул — менә
шундый
Тырыш хезмәт җимеше.
Берүк, кадерен белегез,
Хөрмәт итә күрегез...

*Резеда Вәлиева*

## Октябрь

Октябрьдә, октябрьдә
Яңгырлар бик еш ява,
Бар үләннәр дә саргая,
Чикерткә тынып кала.

Яфракларны үзә-үзә,
Көчле җил уйный тышта,
Бик күп утын хәзерләнә
Мичкә ягарга кышта.

*Мөнир Мазунов*

## Банан тәмле буламы?

Яратканы Искәндәрнең —
Карбыз, компот һәм... банан.
Шундый тәмле-томлы гына
Ашамакчы ул һаман.

Ярый әле, компотлар күп,
Карбызын да табарсың,
Әмма гел генә банан дип,
Кая чыгып чабарсың?!

Кыяр, кишер, кәбестәләр
Тулып ятса да монда,
Банан кибетләре фәкать
Банастанда гына.

Ә анда — Банастанда,
Малайлар үсмиләр, ди,
Бөтенесе кәрләләр, ди,
Лилипут төслеләр, ди.

Алар ит, икмәк, бәрәңге
Гомер буе күрми, ди,
Банан, бик тәмле булса да,
Тамакны туйдырмый, ди.

Банан үстергән әтиләр
Бары газап чигә, ди —
Өйдә малае ач булгач,
Банан нигә, ди...

Сөйләдем дә Искәндәргә
Шундый-шундый хәлләрне,
Ул андагы үсми калган
Малайларны жәлләде.

Банандамыни соң хикмәт:
Бөтен хикмәт — икмәктә!
Таза малай булыйм дисәң,
Аш та аша, икмәк тә...

*Әхмәт Рәшит*

## Кар яуды

Менә нинди кар яуды:
Ап-ак булды җир өсте.
Чаналарга, чаңгыларга
Җиткереп булмый эшне.

Бөтен дөнья чаж да чож,
Тауда — тау шуучылар.
Тау асты да чуп-чуар,
Тау өсте дә чуп-чуар.

Тау башыннан төшкәндә
Мәтәлеп тә китәләр.
Ничек итсә итәләр,
Барыбер төшеп җитәләр.

Гел шома гына булмый шул,
Кайчакта егылалар.
Егылсалар егылалар,
Алар бит чыныгалар.

*Галимҗан Латыйп*

## Кыш килде

Ап-ак тун киеп, кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава.

Чормадан сикереп төште
Чаңгылар һәм чаналар.
Ак мамыктай ап-ак кышны
Сагынып көткән алар.

Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк —
Безнең иң якын дуслар.

*Гөлшат Зәйнашева*

## Балалар ярдәм итә

Кышын бездә яшиләр
Песнәкләр һәм чыпчыклар,
Күгәрченнәр, чәүкәләр,
Тагын башка кошчыклар.

Шундый салкын кышларда
Бу сөекле кошларга
Балалар ярдәм итә
Рәхәт, тыныч кышларга.

Кыен була аларга,
Кышын салкыннар җиткәч,
Ачыгалар, туңалар,
Ашарга җимнәр беткәч.

Җим сибәләр аларга,
Оя ясый балалар,
Шатланышып, кошкайлар
Канатларын кагалар.

*Гасыйм Лотфи*

## Кыш бабай бүләкләре

Матур бәйрәм җырыбыз
Яңгырагач еракка,
Кыш бабабыз ишетеп
Килде безгә кунакка.

Елмаеп, ул эндәшә:
«Исәнмесез, дусларым!
Ямьле бәйрәм кичендә
Яусын сезгә котлавым.

Нинди әйбәт уйныйсыз
Яшел чыршы янында.
Бүләк бирep, мин сезне
Шатландырыйм тагын да.»

*Әнәс Кари*

## Бүләк

Кыш бабайдан быел бүләк
күп булды.
Тәмле-тәмле конфет белән
кесәләр тулды.

Матур-матур уенчыклар
бүләк итте ул.
Һәммәбезне сөендерде,
инде китте ул.

Бүләкләрнең куанычы
озакка җитте.
Дәү бүләк энемә булды —
Ул тәпи китте.

*Йолдыз*

## Яшел чыршы, яшь чыршы

Әй чыршы, яшел чыршы,
Безнең өйгә кердең син,
Кергәч, әллә шатландың,
Әллә үксеп көлдең син.

Бер генә көн сиптең дә
Тәмле ылыс исеңне,
Коелды ылысларың —
Үзгәрттең син төсеңне.

Әй чыршы, нәни чыршы,
Сине кайчан аңларбыз?
Бер көнлек бәйрәм өчен
Сине кисеп алабыз.
Уенчык шарлар асып,
Түргә куеп бизибез.
Аннан урын — чүплектә,
Аннан сине белмибез,
Хәтта сәлам бирмибез.
Их, безне...

*Эльмира Шәрифуллина*

## Почмакта торам

Әни почмакка
Бастыра мине,
Нигә икәнен
Беләсез инде!

Торам төз генә,
Телләшми генә,
Сер бирми генә,
Сөйләшми генә.

Чыкмый тыным да,
Еламыйм хәтта.
Елау турында
Уйламыйм хәтта.

Әзер мин монда
Көн дә торырга —
Өйрәнәм бит мин
Солдат булырга!

Солдат булырга —
Сакта торырга!

*Роберт Миңнуллин*

## Яз килә

Яз килә! Яз килә!
Сыерчыклар килә.
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.

Бик күңелле тышта:
Кар эри, боз китә.
Чабышып йөриләр
Малайлар бер читтә.

*Бари Рәхмәт*

## Яз

Су буенда җем-җем итә
Май чәчәкләре.
Иркәләнеп оча майның
Күбәләкләре.

Күк йөзеннән бакчаларга
Кояш нур сибә.
Яфрак яра бакчаларда
Шомырт һәм чия.

*Нур Баян*

## Минем кунагым

Зур бер бүләк алган сыман,
Чын күңелдән куандым:
Сыерчык килде, сыерчык,
Сагынып көткән кунагым.

Хәзерләнеп тордым күптән,
Каршыларга дип аны.
Әнә ничек яраткан ул
Мин ясаган ояны.

Тирәсендә очып йөргәч,
Кереп эчен карады:
Яңа өен котлагандай,
Матур итеп сайрады.

*Әнәс Кари*

## Бәйрәм бүген

Күтәренке күңелле,
Бар да көләч, шат бүген.
Күктә кояш елмая,
Яшералмый шатлыгын.

Тып-тып тама тамчылар,
Җырлап бәйрәм көенә.
«Бәйрәм бүген!» дип, гүя
Тамчылар да сөенә.

Җырлыйсы килеп кенә
Тора бүген безнең дә,
Көтеп алган бәйрәме
Бүген һәммәбезнең дә.

Җыр күтәрә күңелне,
Бар да көләч, шат бүген.
Бүген әни бәйрәме,
Сигезенче март бүген.

*Рафис Корбан*

## Нәүрүз

Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз! —
Язгы яңа елыбыз,
Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!
Еракларга яңгырасын
Бүген дәртле җырыбыз.

*Роберт Миңнуллин*

## Тукай абый

Әле укый белмәсәк тә,
«Туган тел»не җырлыйбыз.
Бу — Тукай абый бүләге,
Иң гүзәл бер җыр, дибез.

Әкиятләр сөйләп, тыңлап,
Телләребез ачыла.
«Су анасы», «Шүрәле»ләр —
Безнең дуслар барсы да.

*Зәкия Туфайлова*

## Бала белән Күбәләк

Б а л а:
Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?

Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

К ү б ә л ә к:
Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын,
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, —
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

*Габдулла Тукай*

## Бал корты

Апам безнең бакчабызда
Матур бер гөл үстерде,
Ул гөл ап-ак чәчәк атты,
Бик матур төскә керде.

Апам лагерьга киткәч, мин
Шуны өзәргә булдым.
«Алам!» — диеп, гөлгә таба
Тиз генә кулым суздым.

Шулчак бал корты, безелдәп:
«Чәчәкне ө...з...ззз...мә! — диде. —
Сезгә тәмле бал җыярга
Кирәк ул безззгә», — диде.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Ыграк авыртыр иде

Бакчага кергәч беркөнне,
Өзеп алырга теләп
Үрелүгә чәчәгенә,
Чәнчеде кулны гөләп.

Авыртса да еламадым.
Гөләпне бит аннан да
Ыграк авырттырыр идем,
Гөлен өзеп алганда.

*Рафис Корбан*

## Оныткан

— Ашарга да утыргансың,
Юындыңмы әле син?
— Әллә минем юынганны
Күрмәдеңме, әни, син?

Колакны да юдым бүген.
— Ә битеңне, битеңне?..
— Бәби түгел лә мин хәзер,
Юдым, дидем бит инде.

— Алай булса кулың нигә
Буялган соң буяуга?
— Онытылып калгандыр ул
Бит юганда юарга.

*Хәкимҗан Халиков*

## Керпе белән Бала

— Керпе, Керпе, күр инде,
Энәләрең никадәр!
Уйнар идем синең белән,
Шундый булмасаң әгәр.

— Әй Бала, Бала, Бала,
Соң үзең уйлап кара:
Мин бит яшим урманда,
Кемнәр генә юк анда!

*Резеда Вәлиева*

## Безнең дусларыбыз

— Яле, безгә әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз. —
Зур мыеклы үзе,
Аннан курка күсе!
— Ул бит песи, ул бит песи!
Мияу! — ди, —
Курыкмагыз, мин һәрвакыт
Уяу, — ди.
— Яле, тагын әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
— Койрык болгый үзе,
Ялт-йолт итә күзе.
— Ул бит маэмай, ул бит
маэмай:
Һау-һау! — ди, —
Минем эшем — сезнең өйне
Саклау, — ди.

— Яле, тагын әйтеп карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
— Чип-чип-чип! — ди алар,
Кортлар чүпли алар.
— Ул чебиләр, ул чебиләр
чүплиләр:
Сезгә файда китерәбез күп,
диләр.
— Тагын, тагын әйтеп
карагыз,
Нәрсә икәнен хәзер табабыз.
— Башындагы бүрек
Кып-кызыл ут кебек.
— Ул бит әтәч, ул бит әтәч:
Кикрикүк!
Безне йокыдан уята бик
иртүк!
Безнең әле дусларыбыз
бик-бик күп!

*Мәхмүт Хөсәен*

## Авыл малае белән шәһәр малае

— Ипекәйне минем әни
Пешерә үзе мичтә.
— Ә без завод пешергәнне
Ашыйбыз иртә-кич тә.

— Без авылда үзебезнең
Сыер сөтен эчәбез.
— Ә без «С Ө Т»
кибетендәге
Сөтне эчеп үсәбез.

— Безнең авылда татарча
Сөйләшә песиләр дә.
— Казанда гел русча гына
Сөйләшә кешеләр дә.

— Ишегалды чирәм бездә,
Ул зурлыгы дисеңме?!
— Ә андый ишегаллары
Бездә «балкон» исемле.

— Ял көне куян куарга
Барабыз без урманга.
— Без дә куабыз ла аны...
«Ну, погоди!» булганда.

— Зәп-зәңгәр бездә күк
йөзе,
Китәр иде исең дә!
— Безнең шәһәребез үзе
Зәңгәр төтен эчендә...

*Ярый, малайлар сөйләшсен,*
*Миңа кирәк китәргә.*
*Бу шигырьне булыр иде*
*Чиксез дәвам итәргә.*

*Роберт Миңнуллин*

## Энә

Кайчаннан бирле менә
Әбием саплый энә.
Энәгә ул җеп саплый,
Ә үзе
Энәнең күзен тапмый.
Күзе бигрәк кечкенә,
Җебе керми һич кенә.
Карап торам тын алмый:
Әллә энә тыңламый,
Әллә җебе тыңламый,
Әллә кулы тыңламый?!
Әбинең күзе күрми,
Энәнең күзен күрми,
Җеп, ахры, шуңа керми.
Әбием шуны белми.
Энәне миңа бирми.

*Нодар Думбадзе*

## Якшәмбе көн балыкта

Әле иртә, хәтта көн дә
Уйламый яктырырга.
Энем белән төшеп киттек
Без балык каптырырга.

И каптырдык, и каптырдык,
И утырдык шым гына…
Бер балык та каптыралмый
Кайтып киттек соң гына.

Болытлы иде көне дә,
Начар иде җиме дә.
Җитмәсә, көн буе исте
Салкын, усал җиле дә.

Балыксыз чагы туры килде
Бүген таллыкларның да.
Ял көннәре булды бугай
Бүген балыкларның да.

*Анатолий Тимиркаев, мари шагыйре*

## Елга

Коры урын бер дә юк
Безнең капка төбендә.
Ярсып ага гөрләвек
Бик киң булып бүген дә.

Кояш карагач аңа,
Без уйнарга чыгабыз.
Көмештәй балкып ага
Җырлый-җырлый елгабыз.

Һәрбер күлнең, елганың
Үз исеме була бит,
Ә без үз елгабызны
Йөртик Көмеш елга дип.

Карлар бетәр һәр якта,
Чокырлар кибәр менә...
Безнең елга ул чакта
Йөрер исемсез генә!

*Агния Барто*

## Миннән дә зур үсәрсез

Кишер суы күп эчтем,
Шуңа быел бик үстем.
Кайсын кырып ашадым,
Кайсын тешләп ашадым.
Ялкауланып тормадым,

Үзем эшләп ашадым.
Сез дә кишер кырыгыз,
Баллы суын эчәрсез.
Күрегез дә торыгыз:
Миннән дә зур үсәрсез.

*Зәкия Туфайлова*

## Кунаклар

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын:
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына чәкчәк.

Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.

Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш!
— Җитешегез, кунаклар,
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

*Шәүкәт Галиев*

## Берүзем

Ишекне үзем ачтым,
Түргә үк кереп бастым.
Ышанмый хәтта күзем:
Бөтен өйгә берүзем!

Ачуланучы булмас,
Берәү дә килеп тыймас.
Әй, рәхмәт, ачкыч, сиңа,
Ирек ачтың син миңа!

Хәзер радио тыңлыйм,
Үзем кушылып җырлыйм.
Чүкечне шакылдатам,
Ишекне шапылдатам,
Аннан сызгырып ятам.

Тик ник җырлыйсым килми?
Нигә уйныйсым килми?..
Бернигә төшми күзем:
Мин өйдә шул берүзем...

*Агния Барто*

## Ярый әле

Беркемне тыңламый торган
Бер малай булган, имеш.
Шырпы алып уйный икән
Шул бәп-бәләкәй килеш...

Өй эченә утын өеп,
Учак ягып маташа.
И сикереп уйный икән
Дөрләп янган ут аша!..

Уйный-уйный, күлмәгенә,
Чәчләренә ут капкан.
Үрле-кырлы сикерә, ди,
Үкерә, ди, газаптан...

«Ни булган, дип
сорыйсызмы,
Бу тәртипсез малайга?»
Бөтен хикмәт тә
шунда шул:
Исән калган алай да.

Чөнки уйнаганы аның
Уенчык йорты булган.
Өстәвенә шырпысы да
Уенчык шырпы булган.
Ярый әле, ярый әле,
Уенчык шырпы булган!

*Галимҗан Гыйльманов*

## Шофёр буласым килә

Үскәч кем буласың дип
Сорыйлар да сорыйлар.
Әллә нинди һөнәрләр
Саныйлар да юрыйлар.
Теләгем шундый минем:
Шофёр буласым килә.
Капка төбенә кайтып,
«Җырлап» торасым килә:

Пип, пип, пип,
Мин бу, мин...

Кем бар анда, кайсыгыз?
Чыгып капка ачыгыз.
Юл өстендә тормагыз,
Юлдан читкә качыгыз.
Юллар үтәсем килә,
Ерак китәсем килә.
Сөт, суганын калага
Төяп илтәсем килә.

Авыл күчтәнәче бу
Әби, бабай, малайга.

Юлда тыз-быз йөрсәләр
Кычкыртамын алай да:

Пип, пип, пип,
Кит, син, кит...

Кычкыртам ипләп кенә,
Атлагыз читләп кенә,

Олы юлга кермәгез,
Карамыйча йөрмәгез!

*Эльмира Шәрифуллина*

## Өлкән группага күчкәч

Ятканда әйттем әнигә:
— Мине иртәрәк уят!
Өлкән группага күчкәч,
Соңга калуы оят.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Туган тел

Туган тел — иң татлы тел,
Туган тел — иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма —
Туган телне онытма!

*Шәүкәт Галиев*

## Якын дус

Бар минем дускаем,
Иң якын сердәшем.
Һәр җирдә, һәр эштә
Киңәшчем, иптәшем.

Күргәнен, белгәнен —
Барын да аңлата,
Көлдерә, җылата,
Уйлата, юата.

Син аны беләмсең?
Кем соң ул ? Уйлап тап!
Иң якын дускаем,
Киңәшчем,
Ул — китап.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Кадерлә син китапны

Китап — киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең,
Ул хөрмәткә бик хаклы —
Кадерлә син китапны.
Почмакларын бөкләмә,
Битләрен дә ертма син,
Керле кул белән аны
Беркайчан да тотма син.

Ул яратмый пычракны —
Керне, тузанны, тапны,
Саф, керсез куңелең белән
Бик чиста тот китапны.
Көн дә укы син аны:
Китап — якын дустың ул,
Синең сорауларыңа
Җавап биреп торсын ул!

*Хәсән Шабанов*

## Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай,
Әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү:
Безнең песи — җиденчесе.

*Габдулла Тукай*

## Иң матур сүз

— Син яраткан иң матур сүз
Нинди сүз, әйт, бәбкәем?
— Иң назлы сүз, иң якын сүз,
ул матур сүз — әнкәем!
— Бар тагын бер иң матур сүз:
Һәрвакыт син әйткәнең.
Анысы нәрсә?
— Ул матур сүз,
ул якын сүз — әткәем!
— Үскәнем, йә инде син әйт!
— Иң матур сүз — Илкәем.
Анда мин, син — һәммәбез дә,
анда әткәй-әнкәем!

*Нәкый Исәнбәт*

# «МӘКТӘПКӘ ИЛТӘ ЮЛЛАР...»

6–7 яшьлек балалар өчен

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## Җырлар, такмаклар, әйтенүләр

* Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

* Наза, Наза,
Наза — матур кыз бала.
Наза — тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.

* Сания апа суга бара,
Зәңгәр чиләген асып,
Сандугачлар чут-чут сайрый,
Көянтәсенә басып.

* Кәҗә, кәҗә, мәкәрҗә,
Кермә минем бакчага.
Минем бакча бик тирән,
Сакалың җиргә тигән.

* Исәнлеккә-саулыкка,
Тазалыкка-байлыкка.
Бакаларга ярлыкка,
Үзебезгә байлыкка.

* Тилгән, тилгән,
Бәбкә күрсә тилергән,
Бер бәбкәне алалмыйча,
Көне буе тилмергән.

* Их, төймә, төймә, төймә,
Төймә була егерме.
Бергә җырлыйк,
бергә уйныйк,
Бергә яшәү күнелле.

* Роза, Роза,
Роза гөлләре матур.
Кызларыбыз бигрәк уңган,
Егетләребез батыр.

* Бер аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.
Әминә, Гөлфия,
Әйдә әле биергә.

* Сип, сип суганга,
Тимә безнең туганга,
Безнең туган бигрәк матур —
Зифа буйлы булганга.

* Тфү-тфү дияем,
Җиргә байлык,
Үземә саулык теләем.

* Саескан, саескан,
Бүрәнәгә ябышкан.
Бер аягы тимердән,
Бер аягы камырдан,
Шу, шу!

* Үрмәкүч, күч, күч,
Атаң-анаң янына
Кызыл туның ки дә оч.

## Санамышлар

* Җепсез орчык,
Чәүкә, чыпчык,
Кара балчык,
Син кал, бу — чык!

* Каенда — карга,
Имәндә — чыпчык,
Җирдә — елан,
Һавада — кош,
Бар син оч!

* Чар, чар чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

* Әлчи, бәлчи,
Әни күлмәк үлчи.
Әнә тора чыпчык,
Монда торма, тиз чык.

* Чәйнеккә акча салдым.
— Ничә булды?
— Йөз булды.
Әтәлчек, мәтәлчек,
Сиңа туры килде, чык!

* Әти китте базарга
Алтын-көмеш сайларга.
Ал чук, зәңгәр чук,
Монда торма, тизрәк чык!

## Календарь йола җырлары

* Нардуган, нардуган,
Нардуган, хуҗалар,
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын.

* Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез, нардуган,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Мин дә шуны булдырам!

* Нәүрүз әйттек без сезгә,
Хакын бирегез безгә.
Яшегез җитсен йөзгә,
Малыгыз артсын көзгә,
Нәүрүз мөбарәк булсын!

* Карга әйтә: «Кар, кар,
Туем җитте — бар, бар!
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт-маеңны тагын ал!
Бар, бар, бар!»

## Тел көрмәкләндергечләр

* Ваттым мичкә, яктым мичкә,
Бер мичкәне бер мичкә.
Ярый сыйды мичкә мичкә,
Ул да җитте бер кичкә.
* Күпер башында күп күркә, күп күркәгә кирәк күп көрпә.
* Казандагы суны кайнарландыралсаң кайнарландыр.

## Алдавыч әкиятләр

* Әүвәл заманда булган бик зур бер тау,
Шул тау башында — бер зур төлке.
Бу әкиятне сөйләр идем,
Шул сөйләве бик көлке.

* Борын-борын заманда
Булган, ди, бер мичкә.
Ярар инде, сораган әкиятеңне
Сөйләрмен иртәгә кичкә.

## Ай белән Кояш

*(Татар халык әкияте)*

Ай белән Кояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Шуннан соң, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Бөтен кошлар, боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңар кул куйганнар.

Болар арасында бары бер генә кош кул куймыйча калган, ди. Ул булган Ярканат. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:

— Бөтен кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — дигәннәр.

— Кулны мин, — дигән Ярканат, — шул сәбәпле куймадым, дигән: — Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, җил бер яктан гына исәр, агачлар кәкре булып үсәрләр, игеннәр дә Кояш төшкән җирдә генә үсәр. Кояш төшмәгән җирдә үсмәс, — дигән.

Шуннан соң бүтән кошлар әйткәннәр:

— Дөрес әйтә шул, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми инде ул, — дигәннәр.

Ай белән Кояшның икесенә дә бер җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә дип карар чыгарганнар, ди.

Шуннан соң Кояш әйткән Ярканатка:

— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәм, — дигән.

Шунлыктан Ярканат көн яктысына чыгып йөри алмый икән.

Аңа Ай сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул Ай яктысында бик әйбәт йөри, ди.

Ай белән Кояшның болай әйләнеп йөрүен бөтен кошкортлар, бөтен халыклар бик дөрес дип кабул иткәннәр, ди. Шуннан соң игеннәр дә яхшы була башлаган, ди.

## Ялкау малай

*(Татар халык әкияте )*

Бер кеше, улын ияртеп, шәһәргә барырга чыккан икән, ди. Баралар, баралар икән, юл өстендә бик яхшы бер ат дагасы ятканлыгын күргәннәр.

Бу кеше, улына күрсәтеп:

— Улым, әнә бер бик яхшы дага ята. Файдасы тияр иде, ал аны! — дигәч, малай:

— Юлда очраган бар тимер-томырны җыя китсәң... Иренмичә, аны иелеп аласым юк әле, — дип әйтте, ди.

Ул алмагач, бу кеше үзе алып, куенына кыстырып киттеләр, ди. Барып җиттеләр, ди, бер тимерчелеккә. Әлеге кеше, тимерчегә кереп, даганы егерме биш тиенгә сатты, ди, һәм шул акчага чия җимеше сатып алды, ди. Киттеләр, ди. Малай арттан, әтисе алдан бара, ди. Ә әтисе, малайга сиздермичә генә, чияләрне юлга берәм-берәм ташлап бара башлаган. Малай юлда яткан чияләрне берәм-берәм чүпләп бара, ди.

Инде әтисе, чияләрне ташлап бетергәч һәм малае иң соңгы чияне дә үрелеп юлдан алгач, артына борылып, улына:

— Менә шулай, улым, акылны хезмәт түкмичә генә алып булмый аны. Әгәр дә даганы үрелеп алырга иренмәсәң, бер үрелүдә эш беткән булыр иде. Менә син бер дага бәһасенә сатып алынган чияләрне ике йөз дә егерме биш тапкыр үрелеп алдың инде. Бер иелергә иренсәң, ике йөз егерме биш мәртәбә иелергә туры килер, — дип әйткәч, малайның йөзе чия кебек кызарды, ди.

## Зөһрә йолдыз

*( Легенда )*

Заманында Зөһрә исемле бик матур, бик акыллы, бик эшчән кыз булган. Аның булдыклылыгына, уңганлыгына, һәр эшне белүенә, кешеләргә карата игелекле булуына бөтен

тирә-як исләре китеп сөйли икән. Ләкин ул үзенең матурлыгы, уңганлыгы белән бер дә мактанмаган, эреләнмәгән. Аның бик усал үги анасы булып, ул, Зөһрәдән бик көнләшеп, һәрвакыт юк сәбәпләр белән аны тирги, ачулана, кыен эшләр куша икән. Иртәдән кичкә кадәр эшләгән Зөһрә. Кешеләрнең елан, ерткыч күп дип сөйли торган куркыныч урманнарга Зөһрәне коры утыннар җыярга юри җибәрә икән үги анасы. Зөһрә бер дә карышмый, үзенә кушкан эшләрне эшли, аңар һични булмый икән. Ничаклы ачуланса да, ничаклы эшләтсә дә, Зөһрә үги анасына бер дә усаллык кылмый икән. Күңеле һәрвакыт изгелектә генә булган. Кулыннан килгән эшләрне көн димәгән, төн димәгән эшләгән, ничек тә үги анасын ризалатырга тырышкан. Зөһрәнең шундый сабырлыгы, шундый түземлеге үги ананың бигрәк тә ачуын чыгарткан.

Шулай беркөнне, иртәдән кичкә кадәр эшләп бик арып кайткач, Зөһрәне үги анасы төпсез савытка су ташырга кушкан, үзе, бик ачуланып:

— Әгәр дә таң атканчы тутырмасаң, йортыма аяк басачак булма, бик нык кыйнармын, — дигән.

Зөһрә, бер сүз дә әйтмичә, көянтәсе белән чиләкләрен күтәреп, суга киткән. Көн буе эшләүдән куллары талган, аяклары йөрүдән көчкә-көчкә генә атлыйлар, җилкәләре буш чиләкләр күтәргәнгә дә сызлана икән. Бик матур айлы кич булган. Ай күктән көмештәй ак, якты нурларын җиргә коя, бөтен җир йөзе, нурга чумып, иркәләнеп, тын гына ята икән.

Яр буенда Зөһрә, бер аккан суга, бер күктәге айга, бер тирәягына карап, тирән уйга чумган. Туган әнисенең ягымлы сүзләре, җылы сүзләре исенә төшкән. Шунда үзенең бәхетсезлеген уйлап, кайнар яшьләре бит буеннан җиргә тәгәрәгәннәр. Ул ялгыз үксеп-үксеп елаган да, «уф...» дип сулап, чиләкләре белән су алган. Сулы авыр чиләкләр аның җилкәләрен тагын да авыррак басалар икән. Ул тагын айга караган. Ай һаман нурланып йөзә икән. Үзенең бәхетсезлегенә кызның җаны әрнегән, ләкин бәхетсезлеге өчен берәүне дә гаепләмәгән. Күңелендә үги анасына бер усал уе юк, тик аңар миһербанлык кына

тели икән. Шунда, бер йолдыз атылып, дөнья тагын да нурланыбрак киткәндәй булган. Зөһрәнең күңеленә дә әллә нишләп җиңел була башлаган. Күңеле һәрвакыт яхшылыкта булганга, Зөһрәне бер якты йолдыз һәрвакыт күзәтеп торган икән, менә шул йолдыз, җиргә атылып, аны нурларына чолгап күтәрә башлаган. Зөһрә үзе дә каядыр күтәрелгәнен сизгән, чиләкләре җиңеләйгәндәй булган. Аның йөрәгендәге авыр төен беткән, күңеленә бик йомшак, бик җиңел, бик рәхәт булган. Шунда озын керфекле күзләрен ачып җибәрсә, үзен ай уртасында күргән.

Сез әгәр дә тулган айга игътибар белән күзләрегезне текәп карасагыз, ай уртасында көянтәсенә чиләкләрен аскан Зөһрә кызның басып торганын әле дә күрерсез. Ә ай янында ялтырап яна торган йолдыз булыр, бусы инде — Зөһрәне күккә күтәргән йолдыз. Аны Зөһрә йолдызы дип йөртәләр.

## Кәкре каенга терәткән

*(Татар халык әкияте)*

Борын заманда бер алдакчы кеше булган, ди, теләсә кемне алдалый ала икән ул, ди. Үзен бик акыллыга санап йөргән тагын бер бай кеше бар икән, ди. Шул кеше әйтә икән:

— Мин шул Алдарга очрасам, аны һич тә алдатмас идем, — ди икән.

Бервакыт бу кеше юл буйлап барганда күрә: юл буенда әлеге Алдар бер кәкре каенны терәтеп тора, имеш. Бу аның янына барып сораган:

— Йә дус, сине алдарга бик оста дип әйтәләр, мине дә алдый алырсыңмы икән, йә, алдап кара әле, — ди. Алдар әйткән:

— Нигә сине алдый алмам икән? Бик тиз алдар идем дә, янымда алдар капчыгым юк шул, өйдә калды, — дигән. Бу кеше, үзенең уяулыгына ышанып, Алдарга әйткән:

— Бар, өеңнән капчыгыңны алып кил, мин монда көтеп торырмын, — дигән. Алдар аңа әйткән:

— Өйгә бик кайтыр идем дә, менә бу каен аварга тора, китәргә ярамый бит, — дигән. Бу кеше, бик үрсәләнеп:

— Барсана, зинһар, капчыгыңны китерсәнә, син килгәнче, каенны үзем терәтеп торырмын, — дип, кәкре каенны терәп калган.

Алдар шул китүдән кире әйләнеп килмәгән, ди, бу кеше әле дә булса кәкре каенны терәп тора, ди.

## Алтын бөртекләр

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманда бер ир белән хатын яшәгәннәр. Аларның биш уллары булган. Бердәнбер көнне боларның әтиләре, Туган илне яклап, яуга киткән. Ул кире әйләнеп кайтмаган, сугыш кырында үлеп калган. Ялгыз ана биш малайны үзе генә тәрбияләп үстергән.

— Улларым, — дигән ана, егетләрне үз янына чакырып алган да. — Мин сезне үстердем, хәзер үз көнегезне үзегез күрегез, — дигән.

— Без, — дигәннәр егетләр, — үз көнебезне үзебез күрер идек, акчабыз юк бит. Син, әни, безгә берәр генә бөртек булса да алтын бир.

— Алтын бирәм, — дигән ана. — Бер бөртек түгел, мең бөртек. Тик ул алтыннарны әтиегез җыеп куйган иде. Аны үзегез эзләп табыгыз!

— Табабыз, табабыз! — дигәннәр егетләр.

— Ә-әнә, — дигән ана, — Ташлытау белән Карлытауны күрәсезме? Шул ике тау арасындагы киң басуны күрәсезме? Шул басуга әтиегез алтын бөртекләре күмгән иде. Эзләп табыгыз шуны. Басуның җирен казыгыз. Җиң сызганып, тир сыпырып эшләгез.

Биш егет биш сабан белән күз күреме кадәр җирне сөреп чыкканнар. Аннары кәсләрне ваклап, тырма белән тырмала-

ганнар. Ә алтын бөртекләрен тапмаганнар. Шуннан егетләр, бик күңелсезләнеп, әниләре янына кайтканнар.

— Бер генә бөртек тә алтын тапмадык, әни! — дигәннәр.

— Борчылмагыз, улларым! — дигән ана. — Табарсыз алтыннарны! Әнә бурадагы бодайны илтеп чәчегез шул җиргә, көз көне бодайны ургач, камылын йолкырсыз, бодай тамырына алтын бөртекләре эләгеп чыгар.

Егетләр әниләре әйткәнчә эшләгәннәр. Бодай мул уңган, аны урганнар, сукканнар.

— Китерегез миңа үзегез иккән игенне! — дигән ана.

Егетләр әниләре алдына капчык-капчык игенне китереп өйгәннәр. Ана кызгылт-сары бөртекләрне учына алып караган да улларына әйткән:

— Әтиегезнең җиргә күмгән алтын бөртекләре менә шулар инде, улларым. Сез менә аларны эзләп таптыгыз. Инде хәзер үзегез көн итә алырсыз! — дигән.

Егетләр бер-берсенә караганнар да бәхетле елмайганнар.

## Ни өчен бакалар бакылдык булып калганнар?

*(Легенда)*

Иң элек дөньяда өч төрле җан иясе булган, ди. Теллеләр, Телсезләр, аннан тагын Бакылдыклар. Өчесе дә суда яшәгән, имеш, болар.

Теллеләр беркөнне судан башларын чыгарып әйткәннәр:

— Телебез булгач, нигә суда торабыз? Сөйләшик дисәк, авызыбызга су тула. Әйдәгез, коры җиргә чыгабыз! — дигәннәр дә, судан чыгып, коры җиргә күчкәннәр.

Телсезләр:

— Безгә суда да ярый. Без сөйләшми дә тора алабыз! — дип, бер-берсенә койрыклары белән ымлашканнар да, балык булып, суда калганнар.

Ә Бакылдыклар менә берзаман су өстендә тавыш күтәргәннәр:

— Бак сана тегеләрне, бак, бак! Теллеләре, халык булып, коры җиргә күчеп китте. Телсезләре, балык булып, суда калды. Ә без соң, без? Безнең телебез дә бар, үзебез дә шәп: суда да яши, корыда да сикерә! Шулай булгачтын? Безгә кайда торырга, ди, соң? — дип, бик каты бакылдашырга тотынганнар, ди.

Берләре:

— Без кемнән ким? Без дә корыга китәбез! — ди.

Икенчеләре:

— Юк, юк, суда торуга ни җитә? Суда калабыз! — ди.

Һәр көнне күл өстендә шушы тавыш. Хәтта төннәр буена шул бәхәсне хәл итә алмыйча бакылдашып чыгалар икән.

Шулай бу Бакылдыклар, ни коры җиргә бармыйча, ни тыныч кына суда калмыйча, әле булса яр буенда бака булып бакылдап яталар, имеш.

## Ни өчен, Чәберчек килмичә, боз китми икән?

*(Легенда )*

Кайсыбер елны елгаларда боз бик иртә — апрель башларында ук китә башлый, әмма кайбер язны апрель буена да кузгалмый ята. Ул шулай боз җибәрүче Чәберчек дигән кошны көтеп ята, ник дисәң, боз җибәрү аның эше икән, ди.

Иртәме, соңмы, язның ничек килүенә карап, менә берзаман Чәберчек кайтып төшә. Килү белән, ул иң элек боз өстенә куна, куна да үзенең бер учка сыеп бетәрлек кечкенә гәүдәсе, сыгылмалы тәпиләре белән көяз-көяз сикереп басып йөри, ул шулай бозның калынмы, нечкәме икәнлеген чамалый икән. Йөргәндә, аның сиртмә кебек озын койрыгы бозга тияр-тимәс кенә селкенеп бара. Шуннан ул, бозның чамасын-ниен белгәч, менә берзаман кинәт кенә алга бер сикереп куна да койрыгы белән бозга суга, сугу белән, боз шатырдап буйга ярыла да китә. Та-

гын суга — аркылыга ярыла. Өченче сугуда боз бөтенләй калшаеп чыга да кузгалып та китә.

Шуңа күрә Чәберчек үзе дә мактанып әйтә икән, ди:

— Үзем кечкенә булсам да, койрыгым алтмыш пот! — ди икән.

Булса да булыр. Ул хәтле елгаларның шулхәтле калын бозларын сугып ярырлык булгач, авырлыгы шуннан ким булмас та шул.

## Бүләк кемгә?

*(Татар халык әкияте)*

Бервакыт Кояш елның дүрт фасылын — Көзне, Кышны, Язны һәм Җәйне — үзенә чакырып алган.

— Сезнең кайсыгыз матуррак, кайсыгыз эштә батыррак? Шуңа бүләк бирәм, — дигән.

Ә бүләк бик затлы икән — уч тутырып, йолдыз бирергә уйлаган Кояш.

Сүзне башлый Көз:

— Үзегез яхшы беләсез: мин бөтен басуларның уңышын җыйдым, бар дөньяны алтынга күмдем. Кошларны җылы якка озаттым, балаларны мәктәпкә җыйдым. Бүләк миңа тиеш!

— Әллә мин эшләдемме аз? — дип сикереп тора Яз. — Мин барлык карларны эреттем, басуларга иген чәчтем, кошларны чакырып кайтардым, агачларны яфрак ярдырдым, болыннарны чәчәккә күмдем. Арада иң матуры да, иң булдыклысы да мин! — дигән ул.

— Ай-яй, — дигән Җәй, — мине тыңлагыз әле: мин дөньяны яшеллеккә күмәм, чәчәкләр үстерәм, игеннәрне өлгертәм, җимешләрне пешерәм. Әллә мин иң матурыгыз түгелме?

— Артык күп түгел минем эш, — ди тыйнак кына Кыш. — Мин җирне ял иттерәм, киләсе уңыш өчен карлар ташыйм, дөньяны ап-акка буйыйм, балаларны чана, чаңгы шуарга ча-

кырам. Мин дә ямьсез түгел. Минем чыршыларымны, кар бөртекләремне, мамык бәсләремне яраталар.

Тыңлап-тыңлап торган да Кояш, бүләкне бу дүртәүнең берсенә дә бирә алмаган. Йолдызларны ул күккә сипкән. «Әнә барыгызга да!» — дигән.

Йолдызларны елның бер фасылы да үзенә ала алмаган. Алар һәрвакыт — яз да, җәй дә, көз дә, кыш та балкып яналар.

## Кола ат

*(Әкият)*

Яшәгән, ди, булган, ди, карт белән карчык. Аларның булган, ди, бер Кола атлары. Яхшы ат инде — көчле дә, матур да. Бервакыт карт бу атны кырга утларга чыгарып җибәргән. Кырда йөргәндә, берзаман күрә Кола ат: аның каршысына бер барс йөгереп килә. Кола ат куркып кала инде, әмма сиздерми — барстан сорый:

— Син кем буласың? — ди.

— Мин — Ала барс, барлык җәнлекләрнең башлыгы булам, — ди ул. — Ә син кем буласың?

— Мин — Кола ат, — ди бу, — барлык терлекләрнең башлыгы булам.

Ала барс бүтән башлыкны очраткач куркып кала һәм әйтә моңа:

— Ә шулай да мин — синнән зуррак башлык, — ди.

— Юк, мин синнән зуррак! — ди ат.

Алар шулай озак кына бәхәсләшкәч, ниһаять, Кола ат әйтә:

— Әйдә, синең белән көч сынашыйк, — ди.

— Әйдә, — ди Ала барс. — Ләкин без көчебезне ничек сынашырбыз соң?

— Менә ничек, — ди Кола ат, — кем дә кем таштан очкын чыгара, шул көчлерәк була.

Барс килешә һәм, беренче булып, көчен күрсәтә башлый. Ташка ул аяклары белән бәрә-тибә, әмма файдасыз: очкын чыкмый да чыкмый.

Шуннан соң Кола ат ташка үзенең дагаланган тояклары белән китереп типкән икән, таштан бер көлтә очкын чәчелеп киткән.

Барс, очкыннарны күргәч, элеккедән дә катырак куркып, бар көченә йөгереп, качып киткән, ди.

## Казлар-аккошлар

*(Рус халык әкияте)*

Бер Карт белән бер  Карчык торганнар, ди. Аларның бер Кызы белән бер бәләкәй Малайлары булган, ди. Бервакыт Карт белән Карчык базарга барырга җыенганнар.

— Кызым, Кызым! Без базарга барабыз, син өйдә утыр, кечкенә энеңне кара, ул беркая да китеп йөрмәсен. Без сиңа яңа күлмәк алып кайтырбыз, —  дигәннәр.

Тиздән Кызның әтисе белән әнисе чыгып киткән, ә Кыз, әнисенең әйткәннәрен онытып, энесен тәрәзә каршындагы чирәмгә утырткан  да, үзе урамга чыгып киткән. Уен белән мавыгып, ул энесен бөтенләй исеннән чыгарган. Шулчак, көтмәгәндә, әллә кайдан казлар-аккошлар килеп чыкканнар, малайны канатларына утыртканнар да алып киткәннәр.

Кыз өйгә кайтса, энесе юк! Кычкырып та карый, әле тегендә, әле монда йөгерә, ә энесе юк та юк!

Шуннан ул басуга йөгереп чыга; еракта, бик еракта казлар-аккошлар очып барганын күрә. Кошлар тиздән кара урман артына кереп юк булалар. Кыз, минем энемне шулар алып  киткәннәрдер әле дип, алар артыннан китә. Казлар-аккошларның бәләкәй балаларны алып киткәләүләрен ишеткәне була аның.

Кыз бик озак йөгерә, йөгерә торгач, басуда бер Мич очрата.

— Мич,  Мич, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Минем арыш кабартмамны ашасаң әйтәм.

— О, өйдә мин бодайныкын да ашамыйм әле.

Мич кызга берни әйтми.

Кыз тагын йөгерә башлый, шулчак бер Алмагачны күрә.

— Алмагач, Алмагач, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Минем кыргый алмамны ашасаң әйтәм.

— О, өйдә мин бакчада үскәнне дә ашамыйм әле.

Алмагач бер сүз дә әйтми.

Кыз тагын йөгерә башлый, Сөт елгасына килеп чыга, елганың ярлары кесәлдән ясалган була.

— Елга, Елга, әйт әле: казлар кайсы якка очтылар?

— Кесәл белән минем сөтемне ашасаң әйтәм.

— Юк, өйдә мин каймак та ашамыйм әле.

Елга бер сүз дә әйтми.

Кыз тагын йөгерә башлый. Аңа басулар буенча бик күп йөгерергә, урманнарда бик күп адашып йөрергә туры килгән булыр иде, бәхеткә, Керпе очрый. Ул аны тибеп җибәрмәкче була, ләкин энәләре кадалудан курка, шуннан соң:

— Керпе, Керпе, күрмәдеңме син казларның кайсы якка очканын? — ди.

— Мин күрүен күрмәдем, — ди Керпе, — Шулай да мин сиңа бер йомгак бирәм, ул кая тәгәрәсә, син шунда бар, казлар-аккошларны табарсың.

Кыз, Керпегә рәхмәт әйтеп, йомгакны ала да аны тәгәрәтеп җибәрә, ул бик тиз тәгәрәп китә, Кыз аның артыннан йөгерә башлый.

Йомгак, тәгәри-тәгәри, урманга килеп керә.

Урманда тавык аяклары өстендә, төрле якка борылгалап, бер йорт тора. Йорт эчендә Убырлы карчык — сөяк аяк утыра. Ә Кызның энесе тәрәзә каршында сәкедә алтын йомыркалар белән уйнап утыра. Апасы бәләкәй энесен күреп ала, посып кына килә дә күтәреп алып китә.

Убырлы карчык башын күтәреп караса — малайдан җилләр искән! Ул алар артыннан куарга казларны җибәрә. Казлар-аккошлар очып китәләр, Кыз артыннан куалар болар.

Инде кая барырга?Алда Сөт елгасы агып тора, ярлары гел кесәл генә. Кыз аңа:

— Елга, Елга, яшер мине! — ди.

— Аша минем кесәлне!

Башка чара юк, Кыз ашый.

Елга аны яры астына яшерә, казлар күрмичә очып узалар.

Кыз, качкан җиреннән чыгып, Елгага рәхмәт әйтә дә энесе белән алга таба китә. Ә казлар кире очып киләләр, тагын боларны очраталар. Инде нәрсә эшләргә? Кыз Алмагачны күреп ала.

— Алмагач, Алмагач, яшер мине! — ди.

— Минем кыргый алмамны аша!

Кыз тиз генә алманы да ашый.

Шунда Алмагач аны ботаклары белән ышыклый, яфраклары белән каплый, казлар аны күрмичә очып китәләр.

Кыз моннан чыга да энесе белән тагын алга йөгерә башлый, казлар аны тагын күреп алалар, тагын артларыннан куа башлыйлар.

Шул арада Кыз юлда бер Мич күреп ала.

— Мич, Мич, яшер мине!

— Минем арыш кабартмамны аша!

Кыз тиз генә кабартманы ашый да энесе белән Мичкә кереп утыра, һәм Мичнең капкачы ябыла да.

Казлар кычкыра-кычкыра очып йөриләр-йөриләр дә, бернәрсә таба алмагач, кире очып китәләр.

Ә Кыз, энесен алып, өйгә йөгерә. Тиздән әтисе белән әнисе дә базардан кайтып керәләр.

## Куянның ирене нигә ярык?

*(Эстон халык әкияте)*

Көннәрдән бер көнне куяннар карт нарат төбенә җыелганнар да тормыш авырлыгыннан зарланыша башлаганнар. Иң карт куян боларны тыңлап-тыңлап торган да, алга чыгып, болай дигән:

— Кадерле туганнарым минем! Мескен куяннарга җирдә яшәү бик авыр. Куаклыкта берәр җәнлек кыштырдап куйса — куян дер-дер килә, агачтан яфрак өзелеп төшсә — куянның коты оча. Үзебез бөтен нәрсәдән куркабыз, ә безгә хәтта черкинең дә исе китми. Болай яшәү туйдырды, әйдәгез, диңгезгә барабыз да бөтенебез шунда батып үләбез. Иртәме-соңмы, барыбер үләсе бит.

Куяннар өлкән туганнарының сүзенә каршы килмәгәннәр. Уйлап-нитеп тормыйча, барысы да дәррәү диңгезгә таба юл тотканнар. Ә диңгез буендагы болында сарык көтүе утлап йөри икән. Бер сарык, шулхәтле куян килүен күргәч, куркудан бәэлдәп куйган һәм чабып киткән. Аның артыннан бөтен көтү ияргән. Чабалар, ди, сарыклар, ә үзләре кая чапканнарын да, нигә чапканнарын да белмиләр, ди.

Ә сарыклар артыннан, шартларга җитеп өрә-өрә, этләр куа икән. Көтүчеләр кычкырыша, таяк болгый... тирә-юньдә ыгы-зыгы, шау-шу! Куяннарга бик көлке тоелган бу. Шуннан алар арткы тәпиләренә утырганнар да көләргә тотынганнар. Шулхәтле шаркылдап көлгән болар — хәтта иреннәре ярылган.

— Юк, куяннарның тормышы ул кадәр үк начар түгел икән! Бергә чакта — без дә көчле! — дип уйлаган алар.

Һәм диңгездә батып үлмәскә карар кылганнар. Ләкин, шул көннән башлап, бар куяннарның өске иреннәре ярык булып калган.

## Сандугач

*(Украин халык әкияте)*

Берзаман бер бай Сандугач тоткан да аны читлеккә ябарга теләгән.

Ә кошчык аңа әйтә икән:

— Җибәр мине, мин сиңа яхшы киңәшләр әйтәм, бәлки, ярап куяр.

Шуннан Сандугачны бай җибәрергә булган.

Менә Сандугач киңәшләрен биргә башлаган:

— Беренчесе: үткән эшкә, бай, беркайчан да үкенмә. Икенчесе: акылга сыймас сүзгә ышанма.

Бай әфәнде, бу киңәшләрне ишеткәч, Сандугачны коткарган. Сандугач очып киткәндә әйткән, ди:

— Их, мине җибәреп начар эшләдең бит, бай. Белсәң иде миндә нинди хәзинә барын. Минем эчемдә зур асылташ бар. Син аны алсаң, тагын да баер идең.

Бай, моны ишетеп, бик нык үкенгән, хәтта Сандугачны тотарга тырышып та караган.

Сандугач байга әйткән:

— Мин хәзер, бай, синең саранлыгыңа да, наданлыгыңа да төшендем. Үткәнне кире кайтарып булмавына үкендең. Минем ахмак сүзләремә дә ышандың! Кара: нинди кечкенә бит мин. Мин кечкенә кошның эчендә ничек зур таш булсын, ди?

Сандугач шулай дип әйткән дә очып та киткән.

## Тату туганнар

*(Корея халкы әкияте)*

Борын-борын заманда бер патшалыкта абыйлы-энеле ике туган яшәгән. Өйләре арасында зур биек тау торса да, бик дус, тату булганнар, бер-берләренә ярдәм иткәннәр.

Бервакыт көз көне ике туган иген җыеп алган да тип-тигез итеп бүлгән.

Шул төнне туганнарның өлкәне уйланып ята икән.

— Без ашлыкны урталай бүлдек. Болай гадел булмады. Энем яңа гына аерым яши башлады. Миңа караганда аңа күбрәк тиеш.

Өлкән туган торган да энесенә бер капчык ашлык илтеп куйган.

Бу вакытта туганнарның кечесе дә шулай уйланып ята икән.

— Юк, бу уңышны дөрес бүлмәдек. Абыйның гаиләсе зур. Аннан соң ул миннән өлкәнрәк тә. Миңа караганда аңа күбрәк тиеш.

Таң алдыннан, сиздермичә генә, энесе абыйсына бер капчык ашлык илтеп куйган.

Иртән абыйсы да, энесе дә үзенең амбарларын кереп караган. Бу ни хәл? Төнлә һәркайсы туганына берәр капчык илткән, ә икмәк кимемәгән. Капчыкларын кат-кат санаганнар — барысы да урынында. Менә могъҗиза!

Төн җиткән. Ике туган, аркаларына капчыкларын салып, тагын юлга чыкканнар. Тау өстендә тулган ай балкып торган. Карт нарат янында ике туган очрашкан. Абыйсы сораган:

— Ә-ә, бу син икән, болай бик соң кая барасың?

Энесе:

— Ә-ә, бу сез икән, сез кая барасыз? — дигән.

Ике туган уйланып калган. Һәм эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган. Бу хәлдән соң бер-берсен тагын да ныграк ярата башлаганнар, ди.

## Икмәк

*(Төрекмән халык әкияте)*

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер егет. Ул бик ярлы булган. Картайган әнисеннән башка беркеме дә — сеңелләре дә, энеләре дә булмаган. Егет бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр байга эшләгән, ләкин бай аңа хезмәт хакы түләмәгән, ашарына да бик аз биргән.

Беркөнне әнисе улына әйткән:

— Бай сине ачка үтерергә тели. Эшкә чыкма. Тауга утынга бар. Мин утынны ярлыларга сатармын. Аларның да акчалары аз, билгеле. Ләкин бу эштән килгән акчага без ничек тә яши алырбыз.

— Синеңчә булсын, — дигән егет.

Ул иртән иртүк, кояш чыкканчы торган да бау, балта асып, әнисе белән саубуллашып, өйдән чыгып китәргә җыенган.

— Улым, — дигән карчык, — менә бу ипи кисәген дә ал әле. Башка бернәрсәбез дә юк безнең. Ләкин син аның балга әйләнгәнен көтер тор. Шуннан соң гына ашарсың.

Егет ипи телемен яулыкка төреп алган да тауларга таба киткән.

Егет төш җиткәнче эшләгән дә эшләгән. Арыган. Бик нык ашыйсы килгән. Кичтән үк авызына бернәрсә капмаган булган. Төенчекне алган да чишеп караган: ипи балга әйләнмәгәнме, янәсе. Ләкин ипи һаман да ипи булып калган. Бик ашыйсы килсә дә, әнисенең үтенечен бозарга теләмәгән егет.

Ипине күкрәгенә яшергән дә яңадан эшли башлаган. Караңгы төшкәнче, утын кисүен дәвам иткән.

— Хәзер ипи балга әйләнгәндер инде, — дип әйткән ул үз-үзенә һәм төенчекне тагын чишкән.

— Әни мине алдаган, — дип уйлаган һәм ипине ашый башлаган. Кабуы булган, балдан да тәмлерәк булып тоелган ипи. Егет әнисеннәен оялган:

— Кичер мине, әни. Ипи тәмле, бал кебек татлы, — дигән ул.

## Пингвин баласы

*(Инглиз халык әкияте)*

Шулай берзаман король пингвиннары нәселеннән Принц атлы бәби йомырка эчендә утыра икән. Тизрәк дөньяга чыгып, үз ишләре белән уйныйсы килә, ди, моның. Менә ул томшыгы белән йомырка кабыгына бәргән, аннан аягы белән китереп типкән, һәм, кабык ярылып, пингвин баласы якты дөньяга чыккан.

Әни пингвин бәбиенә караган да шаккаткан. «Менә гаҗәп, бөтен пингвиннарның аркалары кара, түшләре ак, ә минем

бәбием көрән төстә, — дип уйлаган ул. — Әгәр әйбәтләп юсаң, ул да шулар кебек булмас микән?»

Ләкин Әни пингвин томшыгы белән күпме генә кырса да, Принц һаман көрән булып кала биргән.

— Белдем! Нишләсен белдем! — Әни пингвин, бер чүлмәк бал алып, бәбиенең бөтен җиренә бал сылаган. Аннары Ак аюны чакырып китергән дә балны яларга кушкан. Шулай иткәч, Принцның көрән төсе бетәр, дип уйлаган ул.

— Ай, кытыгым килә! — дип көлгән Принц.

Ак аю, тырыша-тырыша, балны ялаган. Ләкин, күпме генә яласа да, пингвин көрән килеш калган.

— Принц кар тавына менсен дә шуннан аска тәгәрәп төшсен, бәлки, кар көрән төсен алыр, — дип акыл биргән Ак аю.

Ләкин, таудан тәгәрәп төшкәч тә, Принц аклы-каралыга әйләнмәгән.

— Әйдәгез, Ябалак белән киңәшләшеп карыйк, ул — дөньядагы кошларның иң акыллысы, — дигән Әни пингвин.

Ябалак боларга караган да елмаеп куйган:

— И-и, кызык та соң! Үзең Әни пингвин, үзең бәби пингвиннарның туган чакта көрән булуын, ә бераз үскәч, аклы-каралыга әйләнүен дә белмисеңмени?

— Аһ, әйе шул! — дип шатланган Әни пингвин. — Бөтенләй истән чыккан!

Һәм шулай булган да... Озакламый Принц ябага койган һәм кара аркалы, ак түшле король пингвинына әйләнгән.

## Тычкан белән Чыпчык

*(Удмурт халык әкияте)*

Яшәгән, ди, Тычкан белән Чыпчык. Талашмаганнар, әрләшмәгәннәр, киңәшсез бер эшкә дә тотынмаганнар, кыскасы, бик дус яшәгәннәр болар.

Шулай берчак алар юлда өч бөртек арыш тапканнар. Уйлаганнар-уйлаганнар да бу өч бөртекне басуга чәчәргә бул-

ганнар. Тычкан, сукага җигелеп, җир сөргән, ә Чыпчык тырмалаган.

Көзен арыш каерылып уңган. Тычкан үткен тешләре белән игенне урып та алган, Чыпчык җитез канатлары белән көлтәләрне җәһәт кенә сугып та куйган. Уңышны бөртекләп җыйгач, бүләргә тотынганнар болар. Бер бөртек — Тычканга, икенчесе — Чыпчыкка, өченчесе — тагын Тычканга, дүртенчесе — Чыпчыкка...

Шулай тигезләп бүлә торгач, бер бөртек артып калган. Тычкан болай дигән:

— Җир сөргәндә, тәпиләремне, борынымны канатып бетердем, бу бөртек миңа тиештер инде...

— Юк, бу бөртек миңа тиеш. Җир тырмалаганда, бөтен канатларым эштән чыкты, — дигән Чыпчык.

Озак бәхәсләшкәннәрдерме, белмим, ләкин ахырда Чыпчык теге арыш бөртеген томшыгына алган да очып киткән.

Тычкан аның артыннан куа чыкмаган. Ул үзенә тигән өлешне ипләп кенә өненә ташып куйган. Аннары Чыпчыкның кайтуын көтә башлаган. Бер бөртегенә дә тимичә, аның өлешен саклаган. Ләкин, күпме көтсә дә, Чыпчык кире очып кайтмаган.

Кыш буе муллыкта яшәсә дә, Тычкан үз өлешен дә ашап бетерә алмаган. Ә Чыпчык, салкында туңа-туңа, ишегалды саен ризык эзләп йөргән.

Әле һаман Чыпчык ишегалды саен теләнеп йөри, ә Тычкан үз өнендә аның өлешен саклап утыра, ди.

## Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар

Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәп үләннәр үскән. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш исләр таратканнар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар.

Менә шундый матур болында ат көтүе йөргән. Дугадай муенлы, стакан тояклы аргамаклар болын үләнен ашаганнар. Туйганчы, салкын чишмә суын эчкәннәр.

Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән. Ул, муенындагы кыңгыравын шалтыратып, башкаларны үз артыннан ияртә, барысын бергә туплап йөртә икән.

Җирән Кашка беркөнне бик арыган, кичен аның йокысы калган булган. Ул, ятып, бераз хәл җыйнарга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барсын бергә җыйган да әйткән:

— Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез, — дигән.

Атлар башта гел бергә йөргәннәр. Кичкә таба берничәсе бик начар иткән, көтүдән аерылып киткән. Алар Җирән Кашканың сүзләрен онытканнар. Аның файдалы киңәшен тотмаганнар.

Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер Аюга очраганнар, куркуларыннан һушсыз була язганнар, кайту юлына бик тиз борылганнар. Ләкин Аю алар артыннан калмаган. Әй куган, әй куган, хәер, тота алмаган. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар, юлларында тау очраган — йөгереп менгәннәр, урман очраган — ерып чыкканнар, чокырдан сикерергә уйлаганнар — булдыра алмаганнар. Тирән чокыр эченә егылганнар, аякларын сындырганнар.

Тагын өчесе көтүдән бүленеп киткән булган. Күп тә үтмәгән, алар да Җирән Кашканың туры сүзләрен исләренә төшергәннәр, үзләренең бүленеп китүләренә үкенгәннәр, ләкин инде соң булган. Каршыларына, тешләрен шакылдатып, күзләрен акайтып, бер соры Бүре килеп чыккан. Алар бу явыз дошманны күргәч каушап калганнар, үзләрен үзләре белештерми, ярсып, кайсы кая таралганнар. Бүре шунда ук бер Атның бугазына ябышкан, буып алган, егып та салган. Калганнары качып котылганнар. Җирән Кашка муенындагы кыңгырауның матур шалтыравын ишеткәннәр һәм туп-туры шунда киткәннәр.

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәннәр, аның туры сүзен тотмауларына

бик үкенгәннәр. Ә Җирән Кашка башын чайкаган, көчле итеп бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан да сөйләргә тотынган:

— Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар Аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр Бүрегә очрадылар, — дигән дә кыңгыравын өченче мәртәбә шалтыраткан һәм барлык аргамакларын болынга җыйган.

*Абдулла Алиш*

## Тузганак

Яшәгән, ди, бер Тузганак. Аягы аның бик төз һәм бик озын булган, ди. Башы хәйран да купшы, сырлы-сырлы ямь-яшел яфраклары, җилпәзәдәй булып, җиргә үк җәелгәннәр, ди.

Тузганакның матурлыгына барысы да соклана икән.

Бервакыт Каз үләне:

— Бигрәк күркәм инде сезнең бүрегегез! — дип куйган.

Тузганак үзенең матурлыгын үзе дә белә икән, бу сүзләргә исе дә китмәгән аның. Берни дәшмәгән.

Каз үләне исә аның купшы бүрегенә тагын бер генә мәртәбә күтәрелеп караган да җиргә иелгән. Гарьлегеннән елыйсылары килгән аның. Бигрәк инде, сөйләшмәгән дә була...

Якында үсеп утырган Әрекмән дә, үзенең олы-олы яфракларын рәтли-рәтли, Тузганакка сокланып карап торган.

— Әйе, бүрегегез бик килешле, — дигән ул, калын тавышы белән.

Карт Әрекмәнне кем генә белми икән! Аның турында бик зирәк дигән фикер таралган, һәм күпләр аны олылыйлар икән. Шуңа күрә Тузганак та аның сүзләрен илтифатсыз калдырырга батырчылык итмәгән.

— Әйе шул! Бүрегем бик матур шул! — дигән. — Ансыз яши дә алмас идем мин, — дип тә өстәгән.

Бу сүзне ишеткәч, Әрекмән елмаеп әйткән:

— Юкка кайгырасыз. Бүрексез яшәве читен түгел, менә башсыз яшәве кыенрак.

Тузганакның моңа хәтере калган калуын, тик озын-озак сүз көрәштереп тормаган. «Әйдә, лыгырдасын шунда», — дип кенә куйган. Әрекмәннең сүзен санга сукмаган.

Нәкъ шулчакны Җил күтәрелгән. Һәммә үлән куркудан күзен йомган. Бераздан керфекләрен ачып карасалар... ни күрсеннәр — һавада җиңел-җиңел парашютлар очып йөри, ә Тузганак яланбаш калган. Аның шәрә башы майлы кабартма төсле ялтырап тора, баш тирәли ямь-яшел сакаллар салынган. Тузганак үзенең матур бүрегеннән күтәрелгән парашютларга моңсуланып карап тора, ләкин бу хәлнең ничек булганын, ни рәвешле бүрексез калуын аңларга башы җитми аның. Бик тә инде кызганыч булып калган Тузганак. Каз үләне аңа берәр җылырак сүз әйтмәкче, күңелен күтәрмәкче булган.

— Бер дә кайгырмагыз. Без сезгә икенче бүрек табарбыз, — дигән ул.

Карт Әрекмән генә дәшмәгән.

*Светлана Гыйльметдинова*

## Һәркемнең үз эше

Көннәрдән бер көнне Куян белән Маймыл очрашканнар да бер-берсе белән дус булышканнар. Аннан соң, бер-берсенең начар гадәтләрен бетерү өчен, Куян як-якка карамаска, Маймыл бер дә кашынмаска дип, үзара сүз куешканнар. Куян, як-якка карамыйча, ярты көн түзгән, артык чыдый алмагач хәйләгә сабышкан:

— Мин шулай-шулай урта яшьләрдә вакытта куян халкы белән бүре халкы арасында бик каты сугыш булды, дошман безгә бу яктан да, теге яктан да килә иде... — дип, тиз генә як-якка каранып алган.

Маймыл да шунда ук аңа ияреп, болай дип хәйләләшергә керешкән:

— Мин кечкенә вакытта да бер бик каты сугыш булды, шул сугыш вакытында минем бу төшем дә, теге төшем дә тишелде, — дип, тәненең кычыткан җирләрен тиз генә кашып алган, имеш, ди.

Шулай итеп, Куян да, Маймыл да бер-берсенә биргән вәгъдәләрен тыштан гына үтәгәннәр. Куян як-якка карамаган, Маймыл да кашынмаган исемен алып, үзләре һаман шунда каранып та, кашынып та әле дә булса бергә торалар, ди.

*Нәкый Исәнбәт*

## Кыш бабай бүләк өләшә

Зәңгәр урманга Кыш бабай килгән көннең кичендәге тынлыкны койрыксыз Саескан чәлпәрәмә китерде:

— А-һа-һай! Ишеттегезме әле? Күрдегезме әле?

— Ни булды? Сөйлә инде тизрәк! — дип чыелдады Тычкан.

— Әллә... Әллә урманга аучы килгәнме? — дип калтыранды Тиен.

— Карчыга күренмәгәндер бит? — дип чыркылдады Чыпчык.

Куяннар, куркынып, ялт-йолт карандылар.

— Кыш бабай килә, Суык бабай! — дип кычкырды Саескан.

— Кыш бабай? Бик куркынычмы ул? Усалмы? Тешләмиме? — дип шаулаштылар җанварлар.

— Хи-хи-хи! — дип көлде Саескан, белдекле кыланып. — Бик шаян ул Кыш бабай. Дәү капчыгына салып, төрле бүләкләр алып килә. Минем ише акыллы кошларга бушлай өләшә. Ә сиңа, Чыпчык, бүләк эләкмәячәк, чөнки син аңгыра, тинтәк. Кыяфәтең дә каракныкына охшаган.

— Ә миңа? Миңа? — дип кызыксынды Тиен.

— Сиңа да юк, — дип көлде Саескан. — Синең дә акылың керделе дә чыктылы. Гомумән, сезнең арада акыллы җан иясе

юк. Бер Тукран бераз уйларга сәләтле дисәң, анысы да шыр тиле! Бер мин генә акыллы кош, зирәк кош!

— Ә... Ә нәрсә бүләк итәчәк соң сиңа Кыш бабай? — дип сорады Тычкан.

— Маш-шина! — дип күкрәк киерде Саескан.

Шулвакыт урман өстендә: «Кар-р-р!» дигән аваз яңгырады. Күтәрелеп карасалар, имән башына Ала карга килеп кунган икән.

— Кыш бабай килде! — дип каркылдады ул.

Әйе, зәңгәр урманга Кыш бабай килде. Салкын ак томан булып килде ул, көмеш бәс булып, агач ботакларына сарылды. Аннары ак сакаллы, ак тунлы, зур гәүдәле мөлаем бабайга әверелде.

— Йә җәнлекләрем, кошларым, ничек яшисез? — дип елмайды ул, урман халкына карап.

Кыш бабай, дәү капчыгын чишеп, бүләкләрен чыгара башлады.

Шунда ук әрсез Саескан очып килеп җитте.

— Миңа! Миңа! — дип кычкырды ул, Кыш бабай кулындагы сыбызгыны күргәч. Әмма Кыш бабай сыбызгыны Чыпчыкка бирде.

— Ә миңа? Миңа нәрсә? — дип үрсәләнде Саескан.

Ә Кыш бабай әйтерсең аны күрми дә, уңга-сулга бүләкләр өләшә: Куянга барабан, Тукранга пәке, Тиенгә курчак, Тычканга быргы...

Үзенә өлеш чыкмагач, Саескан, тәмам нәүмиз булып, бер читкә барып кунды. Хурланудан аның күзенә яшь бәреп чыкты.

Шунда нәни Куян түзмәде, кыяр-кыймас кына Кыш бабайның тун җиңенә кагылды:

— Бабай! Бабакай, ә Саесканга нәрсә?

— Ә, Саескан өлешсез калдымыни әле? — дип, хәйләкәр генә елмайды Кыш бабай. — Сезнеңчә ничек, балалар, бүләк тиешме Саесканга?

— Мин аңа үземнең сыбызгыны бирәм, — дип чыркылдады Тычкан.

— Мин барабанымны...
— Мин пәкемне...
Шунда Саескан башын тагын да түбәнрәк иде.
— Йә, ярый, монда аңа да бүләк калган икән әле, — диде Кыш бабай һәм капчыгыннан искиткеч матур зәңгәр шар чыгарып бирде.
Саескан шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Ул үзенең зәңгәр шарын бөтен халык күз алдына — каен ботагына элеп куйды. Урман өстенә сыек зәңгәр яктылык таралды.

*Аяз Хәсән*

## Кар кызы

Бер карт белән карчыкның ни балалары, ни оныклары юк икән, ди, ялгызлыкта гомер итәләр, ди.
Кышкы матур көннәрнең берсендә алар урамга чыкканнар. Ә анда балалалар шау-гөр килә: кар тәгәрәтәләр икән. Карт кулына кар йомарламы алган да:
— Эх, карчыгым, шушы кардай ап-ак, түп-түгәрәк бер кызыбыз булса иде! — дигән.
— Нишлисең бит, булмады шул, картым, булмады, — дип көрсенгән карчык та, кар йомарламына карап.
Шулай да бабай йомарламны өенә алып кайта. Чүлмәккә сала да, өстен каплап, тәрәзә төбенә куя. Кояш җылысыннан чүлмәктәге кар эри башлый. Шулчак карт белән карчыкка тәрәзә төбеннән бала тавышы ишетелгәндәй була. Чүлмәкне ачып карасалар — ни хикмәт, ап-ак, түп-түгәрәк, бик матур бер кыз ята.
— Мин — Кар кызы. Ап-ак йөзле, алсу битле Кар кызы. Мин сезнең кызыгыз булырмын, — ди ул.
Карт белән карчык, бик куанып, Кар кызын чүлмәктән алалар. Карчык тиз генә аңа кием-салым тегә башлый, карт бишек җыры көйли:

Йокла, кызым-йолдызым,
Йокла, нәни Кар кызы.
Кадерлебез, диярбез,
Яратырбыз-сөярбез.

Карт белән карчыкны сөендереп, кыз ай үсәсен көн үсә. Матурлыгы, акылы ягыннан тирә-якта тиңнәр булмый. Булса да, әкияттә генә булыр.

Картларның эшләре майлаган кебек бара: өй җылы, йортта тәртип.

Тик кайгы белән шатлык янәшә йөри икән шул. Күңелсез хәлләр, кыш узып, кош-кортны өйдән абзарга чыгаргач башлана.

Болай була. Беркөнне картның тугрылыклы йорт сакчысы Жучка янына Төлке килә. Авыруга сабышып, хәлсез тавыш белән ялвара башлый бу:

— Жучка дустым, ак тәпием, ефәк койрыгым, абзарыңа җылынырга кертсәнә.

Көне буе урманда хуҗасы артыннан чабып йөргән эт әбинең тавыкларны абзарга чыгарганын белми, әлбәттә. Кертә бу Төлкене. Ә ач Төлкегә шул гына кирәк: ике тавыкны буып ала да чыгып кача.

Карт, моны белгәч, Жучканы урамга куа.

— Теләсәң кая кит! — ди ул аңа. — Миңа мондый сакчының кирәге юк!

Карчык белән Кар кызы, этне бик кызгансалар да, йорт хуҗасына каршы сүз әйтә алмыйлар.

Ямьле җәй җитә. Урманда тәмле-татлы җиләкләр пешә башлый. Күрше кызлары җиләккә барырга җыена. Үзләре белән Кар кызын да чакыралар...

Кызлар, җитәкләшеп, урманга йөгерәләр. Андагы җиләкләрне күрүгә, бар дөньяларын онытып, төрле якка сибелүләрен сизми дә калалар.

Менә бервакыт Кар кызының кәрзине тула. Башын күтәреп караса, янында берәү дә юк. «Ауу-ауу-ауу!!» — дип, иптәшләренә кычкырып карый — каршы җавап ишетелми. Кар кызы ары йөгерә, бире йөгерә, бөтенләй адаша. Аптырагач, агач башына менеп кычкыра башлый...

Шунда кинәт эт өргән тавыш ишетелә.

— Аууу, Жучка, аууу! Мин монда, агач башында. Ап-ак йөзле, алсу битле Кар кызы мин. Дусларым урманга алып килделәр дә ташлап калдырдылар...

Кар кызы агач башыннан төшә. Жучка сөенеченнән аның битләрен ялап бетерә. Аннары кызны өйләренә алып кайтып китә.

Карт белән карчык, боларны күргәч, куанычларыннан елап җибәрәләр.

Сөекле кызларын, ашатып-эчертеп, ефәк юрганнарга төреп, мамык түшәккә йокларга яткыралар.

Жучканы да кичерәләр, яңа сауган җылы сөт эчерәләр.

*Владимир Даль*

## Чыбык ашату

Аю баласы Әппәс гел киреләнә. Өйдәгеләр ашарга утыра башласа көйсезләнә, елый, ди. Әнисе дә, әтисе дә аптырап беткәннәр.

— Миңа бал кирәк, миңа конфет кирәк, миңа туңдырма-маружный кирәк! — дип, Әппәс әти-әнисенең теңкәсенә тиеп беткән.

— Балыбыз юк бит, балам, әнә кәбестә аша! — ди әтисе.

— Мин кәбестә яратмый-йм! — ди Әппәс.

Башка аю балалары белән әти-әнисе кәбестәне ашап бетергәннәр, ди.

— Миңа кәбестә калдырмагансыз! — дип, Әппәс тагын елый башлаган.

— Әнә кишер аша, ул да баллы бит! — дигән әнисе.

— Мин кишер яратмыйм! — дигән Әппәс.

Шуннан кишерне дә ашап бетергәннәр.

— Миңа кишер калдырмагансыз! — дип, тагын елый башлаган Әппәс.

— Алайса, шалкан аша! — дигән абыйсы Әппәскә.

— Мин шалкан яратмыйм! — дигән Әппәс.

Шуннан шалканны да ашап бетергәннәр өйдәгеләр.

— Миңа шалкан калдырмагансыз! — дип акыра башлаган Әппәс.

Шуннан әтисе белән әнисе базарга чыгып бал, конфет, кәбестә, кишер, шалкан, тагын әллә никадәр яшелчә, баллы нәмәстәләр алып кайтканнар да:

— Мә, киребеткән Әппәс, җаның ни теләсә, шуны аша! — дигәннәр.

— Хәзер инде ашыйсым килми-и! — дигән Әппәс.

— Мә, алайса, чыбык аша! — дип, әтисе Әппәсне бик каты ачуланып йокларга яткырган.

Син дә аю баласы Әппәс кебек кире булма инде. Аның хәленә калма, бәбкәем, безнең белән аша. Ашаганнан соң, битеңне юарсың, авызыңны чайкарсың, аннан соң йокларга ятарсың, яме!

*Батулла*

## Иң бәхетле көн

Ялгандырмы-чындырмы, булгандырмы-юктырмы, авылда түгел, шәһәрдә шушы безнең көннәрдә яшәгән, ди, бер юаш малай. Бик оялчан, бик юаш булганга, аны малайлар дус итмәгән, кызлар иш итмәгән. Ул, килеп, уенга кушылса, читкә сибелгәннәр, сүз башласа, егыла-егыла көлгәннәр...

Юаш малайның моңа бик-бик хәтере калган, әмма үзен рәнҗетүчеләргә каршы чыгарга кыюлыгы җитмәгән. Чөнки ул кешеләрне рәнҗетүдән бик-бик курка торган булган.

Таң артыннан таңнар аткан, җилләр искән, сулар аккан. Ә бу вакыт эчендә ишегалды малайлары бер-берләре белән утыз тапкыр ачуланышырга, кырык тапкыр дуслашырга өлгергәннәр, тик әлеге юаш малай гына үзенә иптәш таба алмаган.

Көннәрнең берендә ишегалдының усал малайлары, черелдек кызлары уйный-уйный арып өйләренә таралышкач, күктә йолдызлар кабынгач, болытларны аралап, ай калыккач, бөркет җанлы юаш малай чыккан да җепшек кардан бик матур итеп

Кар кызы ясап куйган. «Без синең белән мәңге дуслар булырбыз, бергә-бергә тау шуарбыз, тәгәри-тәгәри уйнарбыз, яме», — дигән ул Кар кызына.

— Мин риза, — дигән Кар кызы. Һәм алар җитәкләшеп, тауга менеп киткәннәр. Итекләрен чана иткәннәр. Чаналарына төнге җилләрне җиккәннәр. Егылсалар, бер-берсен тартып торгызганнар, арысалар, иңгә-иң куеп ял иткәннәр, күктәге йолдызларга карап сокланганнар. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып, тәгәри-тәгәри көлгәннәр. Шатлыктан күңелләре тулып ташыса — җырлап җибәргәннәр. Куеннарына суык кереп, тәннәрен чеметкәли башласа — рәхәтләнеп биегәннәр.

— Их! — дигән юаш малай, хискә бирелеп. — Дөньяда дустың булу нинди рәхәт!

— Әйе, — дигән Кар кызы, — синең кебек батыр малай белән дус булуыма мин бик шат.

— Юк шул, — дип кире каккан малай аны, — мин батыр түгел.

— Син батыр! — дигән Кар кызы. — Чөнки син, кара төннән курыкмыйча, берүзең урамга чыктың. Аннары, әле генә минем күзләремә карап: «Мин батыр түгел», — дип әйтә алдың. Үзеңә карата мондый сүзне әйтер өчен дә, батырлык кирәк.

Шушы минуттан башлап, юаш малай бернидән дә курыкмый башлаган.

— Әйдә, синең белән шәһәр әйләнәбез, — дигән Кар кызына.

— Әйдә. Минем төнге шәһәрне бик-бик күрәсем килә.

...Төнге шәһәр буйлап алар озак йөргәннәр. Шаярганнар, көлгәннәр. Йөреп туйгач, иңгә-иң куеп, сүзсез генә утырганнар.

— Бәхетле төн үтеп тә китте! — дигән малай, көрсенеп. — Яңадан бервакытта да мин болай бәхетле булалмам инде.

— Булырсың, — дигән Кар кызы, — чөнки синең күңелең бай. Ә күңел байлыгы — зур бәхет ул.

Һәм, чынннан да, шушы көннән башлап, бөркет җанлы юаш малай батырларның батырына әйләнгән. Көчсезләрне рәнҗетсәләр, яклашыр өчен, араларына атылып кергән, уенда иң беренче үзе башлап йөргән. Әти-әниләре: «Безнең ма-

лаебызга ни булды соң?» — дип сокланып та, аптырап та карап куялар икән. Ә бөркет җанлы юаш малай, үзенең тугры дусты Кар кызына тәрәзә аша күз кысып: «Рәхмәт, дустым, син мине көчлелегемә, үземнең бүтәннәрдән ким түгеллегемә ышандырдың. Мин бик-бик бәхетле, чөнки синең кебек әйбәт дусты булган кеше бәхетсез дә, кыюсыз да, куркак та була алмый», — дип эндәшә икән.

*Фәнис Яруллин буенча*

## Ташбака белән Куян

*(Мәсәл)*

Ташбака белән Куян, узышмакчы булып, бер тауга таба йөгерешә башладылар.

Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.

Куян берзаман йокысыннан уянып караса, Ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән!

Инде безнең Куян артка калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?

*Габдулла Тукай*

## Җил белән Кояш

Бервакыт мөлаем Кояш белән кырыс Җил бәхәсләшә башлаганнар. Кайсыбыз көчлерәк, янәсе. Озак бәхәсләшкәннәр, әмма барыбер бер фикергә килә алмаганнар.

Юлдан атлы сәяхәтче узып бара икән.

— Күр дә тор, — дип гайрәтләнгән Җил, шуңа күрсәтеп. — Күз ачып йомганчы өс киемен салдырам мин аның.

Шулай дип, Җил бар көченә тузына башлый. Ләкин, күпме генә тырышмасын, сәяхәтченең киемен салдыра алмый. Тегесе, киресенчә, аның саен ныграк төренә бара. Җилнең ачуы кабара: котырганнан-котыра, карлы-бозлы яңгыр яудыра башлый.

Юлчы бирешми, бишмәтен төймәләп, билен ныгытып буып куя. Шунда Җил бу кешенең киемен салдыра алмаячагын аңлый.

Кояш Җилнең көчсезлеген күреп елмаеп җибәрә. Болытлар арасыннан килеп чыга да нурлары белән җирне дә киптерә, юлчыны да җылыта. Анысы, Кояшка рәхмәт укый-укый, артык киемнәрен ияргә үк бәйләп куя.

— Менә күрәсеңме, — ди Кояш пырдымсыз Җилгә, — усаллыкка караганда яхшылык белән күбрәк нәрсәгә ирешеп була икән бит.

*Константин Ушинский*

## Сабыр итә бел

Агалы-сеңелле ике туган — Әтәч белән Тавык яшәгән, ди. Бервакыт Әтәч бакчага йөгереп кергән дә пешмәгән карлыган чүпли башлаган икән, Тавык аңа:

— Ашама, Әтәч. Карлыганның пешкәнен көт, сабыр ит, — дигән.

Әтәч аның сүзен тыңламаган: чүпләгән дә чүпләгән, ул шулчаклы күп ашаган, хәтта өенә дә көчкә кайтып җиткән, ди.

— Уф! — дип кычкырып җибәргән Әтәч. — Харап булдым! Авырыйм, сеңлем, авырыйм!

Тавык Әтәчкә дару эчергән, горчичник куйган, һәм Әтәч терелгән.

Әтәч, тәмам сәламәтләнгәннән соң гына, кырга киткән; ул анда уйнаган, сикергән. Тирләп-пешкән килеш, салкын чишмәгә су эчәргә килгән, ә Тавык, аны күреп:

— Тирең кипкәнче эчми тор, Әтәчкәй, сабыр ит, — дип кычкырган.

Әтәч тыңламаган, салкын суны туйганчы эчкән һәм шундук аны бизгәк калтырата башлаган; Тавык аны көч-хәл белән өйгә алып кайткан. Тавык тиз генә доктор чакырып китергән, доктор Әтәчкә ачы дару эчергән, Әтәч бик озак авырып яткан.

Кыш җиткәндә, Әтәч терелгән һәм, боз белән капланган елганы күргәч, аның боз өстендә тимераякта шуасы килгән, ә Тавык аңа:

— Эх, сабыр ит, Әтәчкәй! Елга катып җитсен, хәзергә әле боз бик юка, батарсың, — дигән.

Әтәч үзенең сеңлесе Тавыкның сүзен тыңламаган: боз өстендә шуа да башлаган, шундук боз ватылып та киткән, ә Әтәч — чулт! — боз астына. Кешеләр Әтәчне күреп кенә калганнар.

*Константин Ушинскийдан*

## Дуслар

Кич якынлашып килә иде. Алан әйләнәсендәге агачларның күләгәләре озыная барды. Менә алан өстендәге кояш, агачлар артына тәгәрәгәндәй булып, күздән югалды. Күләгәләр барысы да бергә тоташып җәелделәр, урман эче караңгылана башлады.

Көне буе, кич җиткәнне көтеп, куак астында яткан ана Куян урманда йөреп кайтмакчы булды. Киткән чакта, ул үзенең балалары Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Сез шунда гына уйнагыз. Ерак китмәгез! Чирәм үсеп куелана төшкәч, мин сезне үзем урман белән таныштырырга алып чыгармын. Аңарчы сез тиз йөгерергә дә өйрәнерсез.

Урыныннан кузгалып, бер-ике сикергәч, ул тагы, артына әйләнеп:

— Шалпан колак, син Кечкенәне кыерсытма, — дип кычкырды. Аннан агач арасына кереп югалды.

Бу Куян балалары яз көне икесе бервакытта туган булсалар да, берсе никтер нәни иде. Шуңа күрә дә аңа әнисе Кечкенә дип исем кушты.

Әниләре киткәч, Шалпан колак белән Кечкенә ду килеп куышып йөгерергә тотындылар. Түгәрәк алан әйләнәсендә йөгереп арыгач, алар кайчандыр яшен сугып аударган имән агачы төбе янына барып ял иттеләр. Ауган агачның үзен инде

күптән кешеләр ягарга алып киткән. Ә төбе алан уртасында кара утыргыч төсле булып торып калган иде.

— Әйдә, шул төп аша сикереп уйныйбыз! — диде Шалпан колак, бераз ял иткәннән соң.

— Әйдә-ә! — диде Кечкенә.

Алар сикереп уйнарга керештеләр. Йөгереп-йөгереп киләләр дә шул агач төбе аша һоп!

Шуннан ерак түгел ямь-яшел яфраклы каен агачы үсеп утыра. Анда бер ана Песнәк, оя ясап, йомырка салган да шул йомыркалардан нәни песнәкләр борынлап чыкканны көтеп утыра иде.

Песнәк Куян балаларының йөгереп, сикереп уйнаганнарын оясыннан күреп, сокланып утырды.

— Менә озакламый минем дә нәни кошчыкларым булыр. Канат чыккач, алар очарга өйрәнерләр, — дип уйлап куйды.

Шулвакыт Шалпан колак еракта йөгереп килеп сикерим дигәндә генә, агач төбе өстендә кәкре коры чыбык, кинәт кузгалып, яртылаш үрә торды. Шалпан колак, куркып, колакларын торгызып, кырыйга сикерде.

Башта әле ул бернәрсә дә аңлый алмый аптырап торган иде. Аның коры чыбык дип уйлаган әйбере, ысылдап, чирәмгә төшкәч аңлады.Ул чыбык түгел, агулы кара Елан икән.

Ул арада кара Елан, чирәм өстеннән шуышып, туп-туры әлеге Песнәк оялаган каенга таба китте.

Өстән аны күреп торган бичара Песнәкнең йөрәге ярылырга җитеште. Ул, акыллы кош, еланнарның гадәтен белә иде. Менә хәзер Елан аның оясына үрмәләп менәр дә йомыркаларын ватып эчәр!

Песнәк бик борчылып чыелдап кычкырды:

— Коткарыгыз!

Шалпан колак белән Кечкенә эшнең нәрсәдә икәнен аңлап җиткермәделәр җиткерүен. Шулай да ысылдаган кара Еланның берәүгә дә зарары тимәгән кошка явызлык эшләргә җыенуын сизенделәр.

— Ничек коткарырга соң ул кошчыкны? — диде Шалпан колак.

Кечкенә:

— Тукта! Әни кайтып килмиме икән? Мин барып карыйм әле. Ул кайтса, берәр нәрсә уйлап табар, — дип, әнисе киткән якка чапты.

— Ярый, син ул якка бар. Мин бу яктан карап килим! — дип, аланның икенче ягына йөгерде.

Кечкенә сикерә-сикерә йөгереп, агачлар арасына барып керүгә, тәпиенә нәрсәдер кадалып кычкырып җибәрде:

— Ой, ой, ой!

Караса, анда Керпе йомарланып яткан икән.

— Нәрсә шулчаклы, күзеңә ак-кара күренми, мәтәлә-кадала чабасың? — диде Керпе, Кечкенәгә ачуланып.

Йөгереп килеп сулышы беткән Кечкенә аңа:

— Елан! Елан! — дип кенә әйтә алды.

Керпе:

— Фу-фу! Төлке куа икән дип торам тагын! Кайда ул Елан, күрсәт, — дигәч, Кечкенә, шатланып, аны ияртеп китте.

Алар бик вакытлы барып өлгерделәр.

Керпе, аланда каен агачына үрмәләп менәргә җыенган Еланны күрүгә, йөгерүен кызулатты һәм, вак-вак атлап, тиз генә барды да, Елан өстенә ташланып, башының арт ягына тешләрен батырды. Арттарак калып, бу хәлне карап торган Кечкенә, Керпе өчен куркып, күзләрен йомды хәтта. Ул күзен ачканда, Керпе еланны буып салган иде инде.

Ул арада Шалпан колак та, әнисен эзләп таба алмыйча, әлсерәп кайткан иде. Еланның кузгалмый сузылып ятканын күргәч, ул да иреннәрен кыймыл-кыймыл иттереп, шаккатып торды.

— Фу! Шулмы курыккан еланыгыз? Фу! — диде Керпе эре генә.

Оясында тынын алырга да куркып утырган Песнәк шатлыгыннан ни эшләргә белми чутылдады:

— Рәхмәт, сиңа, Керпе. Бу яхшылыгыңны гомердә дә онытмам. Бәлки, кайчан да булса минем дә сиңа файдам тияр.

Керпе аңа бернинди дә җавап бирмәде.

— И мескен кошчык! Син кемгә ярдәм итә аласың соң? — дип, авыз эченнән генә пырхылдап көлеп, үз юлына китте.

Озакламый Песнәкнең нәни кошчыклары булды. Алар әле бернәрсә дә эшли белмиләр. Әниләре азык алып кайтканны көтеп, авызларын ачып, тик чыелдашып яталар иде.

Беркөнне Песнәк, гадәтенчә азык эзләргә чыгарга җыенгач, аланда уйнап йөргән Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Куянкайлар! Мин юкта, сез минем кошчыкларга күз-колак булсагыз иде. Алар бик тынгысызлар. Егылып төшеп имгәнмәгәйләре дип куркам. Сез аларга кычкыргалап торыгыз, оядан башларын чыгарып сузылмасыннар, — диде.

Шалпан колак белән Кечкенә:

— Ярый, ярый. Без шунда каен төбендә генә уйнарбыз. Кошчыкларың егылып төшә башласа, йомшак тәпиләребез белән тотып алырбыз. Җиргә төшеп имгәнергә ирек бирмәбез! — диделәр.

Песнәк тынычланып очып китте. Бераз очып, азык алып кайтып килешли, ул бер Төлкенең шыпырт кына куак артына яшеренгәнен күреп алды.

— Кемне сагалап посты икән бу явыз? — дип борчылып, як-якка каранса, текер-текер атлап килеп яткан таныш Керпене күрде.

Керпе сусаган булган, күрәсең, яңгырдан соң тирән чокырга җыелган суга таба бара иде. Төлке шуны сагалап поскан икән. Коры җирдә Керпе, йомарланып ятып, Төлкегә бирешмәсә дә, су аның өчен куркыныч. Төлке аны суга тәгәрәтеп төшерә дә, Керпе җәелеп йөзә башлау белән, буып ашый ала.

Песнәкнең шундый хәлне күргәне бар иде. Ул, шунда ук түбән төшеп, акрын гына:

— Төлкедән саклан! Төлке сагалый! — дип чыелдап, Керпенең өстеннән очып үтте.

Керпе, кире борылып, бөтен көче белән йөгерергә тотынды. Төлке эшне аңлаганчы, ул әллә кая, чытырман арасына качып өлгергән иде инде. Бераз бөгәрләнеп ятканнан соң,

ул чирәм арасыннан башын чыгарып карады һәм Төлкенең, бик кәефсезләнеп, борынын салындырып, икенче якка ауга киткәнен күреп тынычланды.

— Фу! Менә сиңа кечкенә кошчык! Тукта, барып хәлләрен белим әле үзләренең, — дип, аланга таба тәпиләп китте.

Көннәр үтте. Песнәкнең балалары да үстеләр. Канат чыгарып очарга өйрәнделәр. Үз-үзләренә көн күрә башладылар. Шалпан колак белән Кечкенә дә зур куян булдылар. Тик аларның берсенең дә шул аланнан китәселәре килмәде. Керпе дә башка җирдә ямь тапмады, һаман кыштыр-кыштыр шул тирәдә йөрде.

Кышын песнәкләргә урманда туенып тору читен булачак иде. Шуңа күрә, көз җитү белән, алар кая булса да кешеләр тора торган җиргә китәргә җыендылар.

Керпе, Шалпан колак һәм Кечкенә шул алан тирәсендә кышларга булдылар. Алар песнәкләрне:

— Яз җиткәч, тагын шунда килегез! Без сезне көтәрбез! — дип озатып калдылар.

*Сәрвәр Әдһәмова*

## Чишмә

Аны ачкан кеше дөньяда юк инде. Ә ул менә тау астында инде ничә гасыр челтер-челтер ага бирә. Иртән аның суларында әрәмәлектә оя корган сайрар кошлар су коена, күбәләкләр, бал кортлары сусауларын баса. Чишмәне барысы да ярата, үз итә. Тик кешеләр генә аңа карата мәрхәмәтсез була башладылар. Чишмә ярында учак ягып ял иткәч, алар чүп-чарны шунда ук ташлап калдыралар. Хәтта гомергомергә изге саналган су юлын да, көтүдән таптатып, батгомергә изге саналган су юлын да, көтүдән таптатып, баткаклыкка әйләндерделәр. Әгәр болай дәвам итсә, сайрар кошлар да урманга китәр. Юк, моңа юл куярга ярамый. Кешеләрнең үзләре белән сөйләшеп карарга кирәк. Бәлки, оялырлар, иманга килерләр.

Шулай дип фикер йөртә Чишмә.

Беренче булып Чишмә буена карт бабай төште.

— Йә Аллам, нишләттеләр сине? — диде ул, Чишмәне күргәч. — Көчемдә вакытта мин сине карап, чистартып тордым. Их, яшьрәк чагым булса... Болай интектерер идемме соң мин сине?! Гаепле мин синең алда, изге Чишмә. Балаларымны игелекле, иманлы итеп тәрбияли алмадым... Шулай да мин улларым белән сөйләшеп карыйм әле.

Карт, авырлык белән генә торып, өенә юл тотты. Кичен механизатор улы эштән кайткач, Чишмә хакында сүз кузгатты. Тик ул елмаеп кына куйды.

— Әй әти, Чишмә кайгысымы соң башта?.. Үзең беләсең бит: көндез вакыт эштә уза. Ә иртә-кичен малларны карыйсы бар.

Шәһәрдә яшәүче уллары белән сөйләшү дә нәтиҗә бирмәде. Берсе ялын дача төзеп, ә икенчесе, акча җитмәгәнгә, төшемле эштә эшләп уздырырга уйлый икән. Имеш, аның хәлен белергә дә юк вакытны бар итеп кайтканнар.

Аптырагач, бабай оныгы белән сөйләшеп карарга булды. Бәхеткә, Инсаф аны аңлады. Күрәсең, бала вакыттан догалар өйрәтеп, игелеккә өндәп үстерү файдасыз калмагандыр.

Икенче көнне иртән Инсаф, көрәк тотып, чишмә буена төште. Барлык чүп-чарны җыеп, җиргә күмде. Чишмә юлын чистартып тирәнәйтте.

Хәлсезләнгән Чишмә җиңел сулап куйды.

— Рәхмәт сиңа, Инсаф, — диде ул, ягымлы челтерәү белән. — Инде суымны авыз ит. Шифасы тисен.

Инсаф, учларын тутырып, су алды. Чишмә суы бик тәмле, тирә-якта кошлар сайрый, дөнья да ямьле иде.

*Фирдәвес Зариф*

## Чәчәк

Булган, ди, бер Чәчәк. Сабагында утырган-утырган да әйтеп куйган бу:

— Җил мине төрле якка селкетә, Кояш кыздыра, ул кыздырганда, күләгәгә дә кереп яшеренеп булмый, туйдым бу сабакта гына утырудан, — дигән.

Бүтәннәр аның белән бәхәсләшмәгәннәр. Аларга сабакта утыру да, Җил искәндә чайкалу да, Кояшта кызыну да, кичке җиләс һавада таҗларны йомып йокыга талу да бик рәхәт булган.

Шул арада болынга бер Кыз йөгереп килгән дә әлеге Чәчәкне, өзеп, түшенә кадаган. Чәчәк куанычыннан нишләргә дә белмәгән.

— Күрдегезме, мин хәзер барыгыздан да өстәрәк, биектәрәк! Мин Кояшка да, Җилгә дә якынрак, хәзер мин аларның үзләренең кирәген бирәм! — дигән.

Тик Җилне туктата, Кояшны суыта алмаган, үзе генә сулган. Кызның түшеннән чүп үләннәре арасына төшеп калгач, Җил аны очыртып алып киткән дә кире болынга илтеп ташлаган.

Чәчәкнең күзләреннән яшьләр тамган. Сабагына кире кайтып утырыр иде дә, соң булган шул. Бүтән гөлләр аңа:

— Кояш һәм Җил белән кем көрәшә соң? — дигәннәр. — Кояш белән Җил булмаса, без беребез дә үсмәс идек. Җил безнең орлыкларны тирә-якка тарата, Кояш безнең таҗларыбызны кирәк чагында ачтыра, кирәк чагында йомдыра.

Кояш та, Җил дә Чәчәкне ачуланмаганнар. Җир аны үз кочагына алган, Җил Яңгыр чакырган. Яңгыр явып үткәч, бу урында бер генә түгел, әллә ничаклы чәчәкләр үсеп чыккан. Әлеге Чәчәкнең орлыкларыннан үсеп чыкканнар алар.

*Сәмига Сәүбәнова*

## Гөлгүзәл

Борын-борын заманда булган, ди, бик матур бер гөлбакча. Бу бакчага әле кеше аягы басмаган икән. Анда бик күп чәчәкләр үскән. Аларның иң матуры, иң нәфисе, ханбикәсе Гөлгүзәл исемле гөлчәчәк булган.

Бу гөлбакчада бертуктаусыз сандугачлар сайраган, чәчәкләр вальс биегәннәр, аллы-гөлле асыл күбәләкләр очып йөргән. Гөлчәчәкләр тирә-юньне хуш искә күмгәннәр.

Гөлгүзәл зифа буйлы нарат астында үскән. Бакчадагы бар чәчәкләр аның янында биегәннәр, сандугачлар да аңа атап җырлаганнар. Гөлгүзәл дә алар белән җырлаган, биегән. Ай, бигрәк гүзәл булган, ди, шул Гөлгүзәл! Ул җырласа, сандугачлар тынып калган, биесә, чәчәкләр аннан күзләрен ала алмаганнар. Бакчада иң гүзәл чәчәк булганга күрә, аны өлкән чәчәкләр Гөлгүзәлкәй дип йөрткәннәр.

Кешеләр, Гөлгүзәлдән рөхсәт алып, гөлбакчага керә башлаганнар. Гөлгүзәл кешеләрне гөлләр белән таныштырган. Аларны гөлҗимешләр белән сыйлаган, чәчәкләр биюен карарга рөхсәт иткән. Кешеләр гөлбакчада бер генә агачны да сындырмаганнар, бер генә чәчәкне дә өзмәгәннәр. Ә үләннәрдән дарулар ясарга өйрәнгәннәр, үлән төпләрендәге җиләкләрне җыеп ашаганнар.

Ләкин берзаман кешеләр гөлбакчада йөрергә шулкадәр күнегеп киткәннәр, ди. Алар гөлбакчага инде рөхсәтсез генә керә, чәчәкләрне дә иркенләп өзә башлаганнар. Гөлгүзәл моңа түзгән. Ул кешеләр аңнарына килерләр, бу матурлыкны бетермәсләр дип ышанган. Ләкин кешеләр үзләренең ни эшләгәннәрен уйлап та карамаганнар.

Инде кешеләрнең бу гөлбакчаны үзләренеке итәселәре килгән. Алар гөлбакча патшалыгының иң гүзәл чәчәген — Гөлгүзәлне өзеп алганнар. Шулчак урман шомлы итеп шаулый башлаган, агач ботаклары чайкалган, кошлар сайраудан туктаган, каргалар каркылдаган, өзгәләнеп, күке кычкырган, коеп,

яңгыр ява башлаган. Чәчәкләр, куркып, күзләрен яфраклары белән каплаганнар. Гөлбакчада ямь беткән.

Кешеләр гөлбакчадан чыгып киткәннәр, ләкин инде анда бернәрсә дә калмаган. Гөлчәчәкләр, кешеләр явызланганны күреп, үзләрен өзмәсеннәр дип, Гөлгүзәл утырган җиргә барып, нарат төбендәге коелган энәләрне үзләренә алып кадаганнар. Шул көннән башлап, гөлчәчәкләр чәнечкеле булып үсә башлаганнар.

Ә синең шул гөлбакчага барып керәсең килсә, иң элек кешеләргә яхшылык эшлә, аларга шатлык китер, кешеләр белән тату яшә. Менә шундый була алсаң, син, һичшиксез, бу гөлбакчага эләгерсең.

*Сөмбел Гаффарова*

## Кыңгырау чәчәкләр

Яшәгән, ди, бер колын. Ул Йолдызкай атлы икән. Ә әнкәсенең исеме Алмачуар булган.

Көннәрдән бер көнне Йолдызкайның әнисе Алмачуарның туган көне килеп җиткән. Туган көн җиткәч котларга кирәк бит инде. Ә котлар өчен, бүләк кирәк. Йолдызкай әнкәсен туган көне белән котларга нинди бүләк алып кайтыйм икән дип уйлаган да уйлаган.

«Чәчәктән дә яхшысы булмас», — дигән бу, озак кына баш вата торгач. Йолдызкайның әнкәсе бигрәк тә шәмәхә төстәге кыңгырау чәчәкләрен ярата икән. Муенындагы җиз кыңгыравы да шул чәчәккә охшап тора икән. Ул аны матурлык өчен генә түгел, адашканда колынкае шул кыңгырау тавышына килсен дип йөрткән.

Шулай итеп, Йолдызкай әнкәсенең туган көненә бүләккә кыңгырау чәчәкләр җыярга киткән.

Кыңгырау чәчәкләр болында үскән. Ә болын елганың аргы ягында, ди. Әллә кайдагы күперне эзләп йөрмәгән Йолдызкай.

Елганы йөзеп кенә чыккан да күп итеп шәмәхә кыңгырау чәчәкләр җыйган.

Йолдызкай өенә кайтырга чыккан. Кочагындагы кыңгырау чәчәкләре ул атлаган көйгә чең дә чең, зең дә зең, челтер дә челтер килеп барган. Колынкай түзмәгән, чәчәкләр көенә кушылып, үзе дә җырлап җибәргән:

Иhа-hа, иhа-hа!
Бүген әни туган көн.
Әниләрнең туган көне —
Чәчәкләр күп булган көн.

Кайта торгач, теге елга янына килеп җиткән. Йолдызкайның чәчәкләрне әнисенә тизрәк бүләк итәсе килгән. Шуңа күрә күперне эзләп йөрмәгән, туп-туры йөзеп чыгарга уйлаган. Чәчәкләрне башына куеп, суга кергән дә йөзеп киткән. Йөзә икән, йөзә икән бу... Йөзә торгач арый башлаган. Арый башлагач бата башлаган. Бата башлагач кычкыра башлаган.

Әмма аны беркем ишетмәгән. Чөнки су буенда беркем булмаган. Дөрес, чәчәкләрне ташласа, ул батмас, җиңелрәк йөзәр иде. Тик ул: «Әнинең туган көненә кыңгырау чәчәкләремне алып кайта алмасам, бик күңелсез булыр инде», — дип уйлаган.

Шулчак су буена зәңгәр канатлы Күбәләк килеп чыккан. Ул, гадәтенчә, елганың аргы ягында үскән кыңгырау чәчәкләргә кунып, баллы су эчәргә теләгән. Караса, суда бер кочак кыңгырау чәчәк бәйләме йөзеп бара икән. Күбәләк озак уйлап тормаган, канатларын ки-и-иң иттереп җәйгән дә, чәчәкләрне күтәреп, югары күтәрелгән. Шулай итеп, зәңгәр канатлы Күбәләк шәмәхә кыңгырау чәчәкләрен яр буена чыгарып та куйган. Ә Йолдызкай чәчәкләргә ябышкан икән. Күбәләк кыңгырау чәчәкләр белән бергә колынны да җиргә чыгарып бастырган.

— Рәхмәт сиңа, зәңгәр канатлы Күбәләк! Син коткармасаң, бүген минем әнием туган көнсез кала иде бит, — дигән колынкай. Ул бер чәчәкне Күбәләкнең чәченә кыстырган да кушаяклап чабып, өйләренә кайтып киткән. Әнкәсенең туган көненә, зәңгәр канатлы кызын ияртеп, теге Күбәләк тә килгән.

*Әхәт Гаффар*

## Кояштагы тап

Еракта, еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер төзәткән, нидер яңарткан. Ә улы аңардан юри дә: «Әнием, син көннәр буе бил турайтмыйча ниләр эшлисең соң?» — дип сорамаган, гел уйнаган да уйнаган.

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе, авырып, түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең: хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай, үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит, кичләрен уеннан арып кайткач, салкын су эчәргә яратасың, — дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым, — дигән әнисе аңарга, — суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы да тәмле, салкын да, шифалы да.

Малай, чиләген күтәреп, урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле», — дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга

тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне, тирләп-пешеп, судан кайтып кергән. Әнисе, аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт», — дигән. Һәм, йотлыгып-йотлыгып, суны эчә башлаган. Эчкән саен, күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай, сөенә-сөенә, урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде», — дип уйлаган ул. Шулай дип әйтүе булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар, куркышып, ояларына качканнар. Шомлы итеп, елап-елап, этләр өрергә тотынган. Малай, ни уйларга белмичә, курка-курка, өенә чапкан.

— Әни, — дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып, — нишләптер кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни, — дигән малай, башын түбән иеп, — мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар, кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар. Этләр елый-елый өрүләреннән туктаганнар. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы кара тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

*Фәнис Яруллин*

## Өч угыл [4]

Бер кешенең өч улы бар иде. Иң кечкенәләре Гали атлы икән. Аталары базардан өчесенә дә берәр алма алып кайтты. Алмалар бик пешкән, татлы, сусыл җимешләр иде.

Берничә сәгатьтән соң аталары, балаларын янына чакырып: «Алмаларны нишләттегез?» — дип сорады.

Өлкән угълы әйтте:

— Әти! Мин алмамны ашадым. Эчендәге орлыкларны җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп, алма агачы үстермәк буламын.

— Яхшы иткәнсең, угълым! — диде ата.

Уртанчы угълы әйтте:

— Мин алманы ашадым. Бик тәмле, татлы җимеш икән. Әтиемә Хак Тәгалә исәнлек бирсен дип дога кылдым.

Атасы янә: «Яхшы иткәнсең, угълым!» — диде.

Өченче угълы Гали атасына карап әйтте:

— Алманың яртысын ашадым.

Атасы әйтте:

— Яртысын нишләттең?

Гали куркып, кызарып әйтте:

— Күршебезнең угълы Вәли авырып ята. Барып, яртысын аңа бирдем. Бик куанды, дога кылды.

— Бәрәкалла, угълым! Син бигрәк тә яхшы иткәнсең! — дип, атасы Галинең битеннән, күзләреннән үпте.

*Дәрдемәнд*

## Тәрбияле бала
*(Өзекләр)*

Тәрбияле баланың кешегә күренә торган яхшы һөнәре зурлар һәм кечкенәләр белән тереклек итүләрендә булыр. Мәсәлән, тәрбияле бала үзеннән кечкенәләргә бик шәфкатьле булыр, аларны кызганыр, һәрвакыт «туганым» дип кенә эндәшер, шулай ук үзеннән зурларга, бигрәк тә ата-анасына,

---
[4] *Угыл* — ул.

үзен тәрбияләүче тәрбиячеләренә, хәтта ки үзеннән олы яшьтәгеләрнең барысына да һәрвакыт хөрмәт күрсәтер...

Баланың тәрбияле булуы ашарга утырганда беленер. Тәрбияле бала зурлар күрсәткән урынга туры китереп утырыр. Терсәкләре белән таянмас, ашарга бирүләрен көтәр һәм, бүлеп бирсәләр, шуны ашар. Аз гына кабып, яхшылап чәйнәп ашар...

Тәрбияле бала ашаганда һич ашыкмас, икмәк валчыкларын читкә төшермәс, ашны ашъяулыкка һәм үзенең киемнәренә түкмәс...

Тәрбияле бала үзенә хәзерләп бирелгән чәйне яхшы гына утырып эчәр, икмәкне дә кадерләп кенә ашар. Аяк өстендә ашап йөргән кешенең икмәк валчыклары, җиргә төшеп, аяк белән тапталыр да гөнаһ булыр. Шуның өчен тәрбияле бала һичбер вакытта аяк өстендә ашап йөрмәс.

Тәрбияле бала, аш яныннан торгач, майлы кулы белән әйбер тотмас, кулын киемнәренә сөртмәс, бәлки, яхшылап сабын белән юар. Авызын чайкар, зурлар бар вакытта, алар юынып бетергәнне көтәр, үзенә чират җиткәч юар.

Тәрбияле бала үз эшен үзе эшләр. Көндез кия торган киемнәрен урыныннан алып, пычраклары күренсә, үзе чистартыр. Әгәр дә үзенең көче җитмәслек эшләр булса, ул вакытта зурлардан үтенер...

Мондый балаларны һәркем яратыр.

*Ризаэддин Фәхреддин*

## Хәрәмләшү

Көз. Апалы-энеле Айнур белән Рафис, йөгерешеп, урамга чыктылар да тау итәгендә үскән агачлар арасына ашыктылар. Исәпләре төрле-төрле агач яфракларын, җыеп, альбомнарына беркетү иде. Ул яфраклар шундый матур: сары, кызыл, куе кызыл, көрән, тагын әллә нинди төслеләр... «Мине ал!», «Мин менә монда!» дигәндәй кызыктырып чакыралар, җилгә ияреп, аяк астына түшәләләр.

Айнур бик ашыгып җыя, хәтта энесе күреп алган яфракларны да аның кул астыннан ук тартып алырга өлгерә. Энесе, кулын сузган килеш, авызын гына ачып кала һәм тагын тырышатырыша җыярга керешә. Матуррак яфрак тапкан саен, апасы:

— Кара әле, Рафис, мин ниндиен таптым! — дип мактана. Тик үзе, Рафис күреп өлгергәнче, күзләрен елтыратып, тапкан яфрагын тиз генә артка яшерә.

Менә Рафис та, бик матур каен яфрагы табып, шатлыгыннан:

— Әй апа, мин синекеннән дә матуррак яфрак таптым! — дип кычкырып җибәрде.

Апасы шунда ук, йөгереп килеп:

— Бу миңа, — диде һәм энесе кулындагы яфракны эләктереп алып, үзенекеләре арасына яшереп тә куйды. Рафис гарьлегеннән чүт кенә еламыйча калды. Ул, апасы ягына ачулы күз ташлап:

— Үзеңнеке генә җитмимени? — дип куйды да янәдән җиргә иелде. Бераздан соң Айнур энесен өйгә чакырды.

— Күп булды инде, әйдә, өйгә кайтабыз, — диде.

Рафис апасы кочагындагы яфракларга карап көрсенде, ләкин калып җыясы итмәде. Алар куыша-куыша йөгереп киттеләр.

Менә кинәт көчле җил, кузгалып, башта Рафисны йолкыптalкып үтте, аннан соң, бөтерелә-бөтерелә, Айнурга килеп җитеп, кызның куенындагы яфракларны очыртып та китте. Айнур, нишләргә дә белмичә, яфракларга ымсынып карап калды.

Рафис, йөгергән җиреннән туктап:

— Апа-а-а-а, ни булды? — дип, кире борылып килде.

Айнур, яшь аралаш:

— Җил алып китте... — дип кенә әйтә алды. Рафис караса, күктә апасы хәрәмләшеп җыйган берсеннән-берсе матур яфраклар талпына иде.

*Нәкыйп Каштан*

## Кадерле бүләк

Менә инде ярты сәгать Зөлфия ванна бүлмәсендә бикләнеп утыра. Абыйсы Айдар, ике мәртәбә килеп, ишек шакыды, ә Зөлфия һаман ачмый да ачмый. Ак тәпиле мәче баласын күкрәгенә кыскан да, тыела алмыйча, сулыгып елый.

— Нишләдең син, Актәпи, нишләдең?! — дип сулкылдый ул. — Әнигә нәрсә бүләк итәрмен инде хәзер? Әллә белмисеңме, әниемнең туган көне бит бүген. Шундый матур рәсемемне әрәм иткәнсең!

Аның әнисенә бүләккә дип ясаган рәсеме, чыннан да, искиткеч матур чыккан иде... Бөтен дәфтәр битен алып торган роза чәчәге. Чәчәк таҗына сары сандугач баласы кунган. Һавада өем-өем ак болытлар. Алар арасыннан кояш алтын нурларын сибә. Ә сандугач шул нурларда коена-коена, өздереп сайрый.

Рәсемне күргәч, Зөлфиянең әтисе белән абыйсы да ах иттеләр.

— Кара инде, бөтенләй тере чәчәк бит! Хәтта хуш исе дә бөркелеп тора кебек! — диде әтисе.

— Ә мин сандугачның сайравын ишетәм, — диде абыйсы, сокланып.

Зөлфиянең шатлыгы эченә сыймады.

Ә менә бүген, музыка мәктәбеннән кайтып керсә, ни күрсен!... Ертылып, туракланып беткән рәсемнең вак-вак кисәкләре идәндә аунап ята. Тиктормас Актәпи кәгазь кисәкләре белән уйнап, тере йомгактай тәгәрәп йөри. Бөтенләй өзгәләп бетергән. Ничек табып алган диген! Китап арасына яшереп куйган иде ләбаса! Инде яңасын ясарга вакыт та калмады.

Шул арада, шау-гөр килеп, әтисе белән әнисе кайтып керделәр. Зөлфия, ашыга-ашыга, битен-күзен юган арада, кунаклар да килеп җитте. Кәшиф абый белән Фәния апа. Һәр ел шулай алар. Бу көнне, эштән кайтышлый, өйләренә дә кереп тормастан, Зөлфияләргә киләләр. Быел да гади генә, ләкин бик матур бүләкләр алып килгәннәр. Як-яктан әнисенең колагын тарта-тарта, көлешә-көлешә котладылар, бүләкләрен бирделәр.

Абыйсы агач тамырыннан юнып ясалган су анасы сынын бүләк итте. Әтисе күлмәклек алган. Тик Зөлфиянең генә бүләге юк. Ул нәрсә эшләргә белмичә, пианино кырына сөялеп, боегып утыра.

Бу арада әтисе аңа сәер генә күз төшереп алды. Хәлен аңлады, күрәсең.

— Ә син... син, кызым, әниеңә берәр матур көй уйна әле, — диде ул, пианино капкачын ачып.

Зөлфиядә җыр, музыка кайгысы юк иде бу вакытта. Ләкин «әниеңә» дигәч карышып тормады. Тик нинди көй уйнарга?

Зөлфия әкрен генә пианино телләренә басты. Бармаклары ничектер үзеннән-үзе «Һәрвакыт булсын кояш!» көен уйный башладылар. Әмма бу көйне ул әле ныклап өйрәнергә өлгермәгән иде. Музыка укытучысы Хәмдия апа бүген генә уйнап күрсәтте. Әни өчен булгач... Аның бармаклары торган саен җитезрәк йөгерделәр. Музыка ышанычлырак, матуррак агылган саен, йөрәге ашкыныбрак типте.

Көй тынарга өлгермәде, барысы да шаулатып кул чаптылар.

— Кара инде, кайчан син болай уйнарга өйрәндең әле? — дип гаҗәпләнде Кәшиф абый.

— Сандугачлар сайраган кебек! — диде Фәния апа.

— Рәхмәт сиңа, кызым! — дип кочып үпте әнисе Зөлфияне. — Синең бу бүләгең миңа — иң кадерле, иң кыйммәтле бүләк.

Кинәт кенә Зөлфиянең күз алдында кояш балкыгандай булды. Шундый якты, шундый нурлы, шундый олы кояш! Ул кояшның нурлары, назлап-иркәләп, биттән, маңгайдан сыйпый. Ул нурлар күңелне җылыта, күзләрне чагылдыра.

*Габделхәй Сабитов*

## Ай-һай

Кыш килде. Урамнарга ак юрган җәйде. Бакчаларга кар тулды, агачлар ак «чәчәк» аттылар.

Рәшитнең әнисенә эш артты. Ул тротуар чистартырга урамга чыкты. Рәшит тә тик торырга яратмый. Ул үзе кебек бәләкәй

көрәк күтәрде дә кар көри башлады. Көрәге аның фанердан эшләнгән — җиңел.

Әй, рәхәт тә соң кышкы саф һавада кар көрәве! Эш һәм кыш Рәшитнең битен әнис алмасыдай кызарткан. Бәләкәй борын бераз гына җебеп киткәләсә дә, аңа исе китми Рәшитнең. Бер тартып куя да җиңе белән сөртеп ала. Көрәвен белә.

Тротуардан кешеләр өзлексез агылып тора: берәүләр бу якка, икенчеләр теге якка. Нишләптер, барысы да ашыгалар: эшләргә комачаулыйлар. Кайберсе Рәшиткә бәрелеп китә, кайберләре хәтта көрәккә басып узалар. Баштарак Рәшитнең аларга бик үк исе китмәде. Эшендә булды, көри бирде. Менә бервакыт Рәшит көрәген күтәрә алмады. Караса, ни күрсен, бер абый аның көрәгенә баскан! Ачуы килде Рәшитнең. Аны-моны уйлап тормады:

— Йөрмәгез әле эш вакытында, аяк астында чуалып! — дип кычкырды. Абый дигәне бабай булып чыкты. Рәшит аның күзлеген күреп алды да: — Күзлек киеп тә күзең күрми икән, әй! — дип өстәп куйды.

Бабай бер генә сүз әйтте:

— Ай-һай!

Әйтте дә, кулындагы таягын селки-селки, китеп тә барды. Бабайның таягы Рәшитнең башына суккан кебек булды. Ә сүзе, бер генә булса да, күңелен әллә нишләтеп җибәрде: «Ай-һай!..»

Эш беткәч тә әле, ул сүз Рәшитнең колак төбендә яңгырап, эчен пошырып торды: «Ай-һай!..»

— Әни, нәрсә дигән сүз ул «ай-һай»?

Әнисе аз гына уйлап торды да болай диде:

— «Ай-һай»мы? Син, малай, эш яратасың икән, — әйбәт! Әниеңә булышуың да матур! Тик олыларга тупас мөгамәләң әйбәт түгел дигән сүз ул «ай-һай!»

*Абдулла Әхмәт*

## Куян

Көзнең соңгы көннәре җитте, кышка да ерак калмады. Куян кыска соры йонын койган, аңа озын ак йон үсә башлаган. Башта аның койрыгы, арт аяклары агара, һәм ул ак итек кигән кебек күренә. Аркасының да арт өлеше ак. Озын колаклары да ак. Бары тик колак очлары гына кара. «Декабрь кергәч, бөтенләй агарырмын әле, колак очларым гына кара килеш калыр», — ди Куян.

Менә декабрь узып та китте. Гыйнвар ае башланды. Куян өчен иң авыр вакыт инде бу. Суык. Ә шушы үзәк өзгеч суыкка ачлык та килеп өстәлә. Ерткыч җәнлекләр дә тынычлык бирми. Әле ярый Куянның аяклары йөгерек, артыннан берәрсе җитә башласа, ул тизрәк олы юлга чыгу җаен карый. Такыр юлдан бик тиз элдертә ул. Ау этләренә дә тоттырмый, төлкеләргә дә исе китми аның. Олы юлда ашарга табыла. Салам, печән учмалары очраштыргалый. Туңса, юл буйлап арлы-бирле чабып йөри шунда, үз ишләрен очратып, шаяртып, уйнап та ала. Йокларга да шул тирәдәрәк кала. Ятар алдыннан, эзләрен яшермәкче булып чуалтып бетерә. Аннары якындагы куак төбенә сикерә дә посып ята бирә.

Куянның тагын бер кызык гадәте бар: йоклаганда, күзләрен йомып бетерми. Ул-бу була калса, шундук табан ялтыратырга әзер тора.

*Гарәфи Хәсәнов*

## Песнәк

Идриснең Песнәге бар. Койрыгы кап-кара, түшләре сары, яңаклары ап-ак, битен гел юып йөри ул. Түбәтәен томшыгына ук төшереп кигән.

Алар инде әллә кайчан дуслаштылар. Кар яуганчы ук. Идрисләрнең ян тәрәзә каршында сәрби агачы үсә. Ул хәзер ап-ак. Кыш бабай кар бөртекләрен җепкә тезгән дә шулар

белән аның ботакларын чорнап куйган. Салкын тимәсен өчен инде. Бер ботак очында нәни генә ачык урын калган. Идриснең дусты гел шунда куна. Әнисе белән әтисе эшкә киткәч, Идрис өйдә берүзе кала. Калса да курыкмый, янында дусты булгач, бер дә куркыныч түгел.

Песнәк Идриснең тәрәзә янына килүен көтеп кенә тора. Шунда ук тәрәзә рамына килеп куна да, кара төймәдәй күзләрен ялтыратып, дустына карый. Теле юк шул аның, сөйләшә белми. Шуңа күрә бөтен әйтәсе сүзен күзләре белән генә аңлата. Идрис бик яхшы аңлый аны. «Хәерле көн, Идрис дус. Тордыңмы, чырык-чырык», — ди ул аңа. Идрис, форточканы ачып, икмәк валчыклары ыргыткач, тиз генә алар артыннан очып төшә. Кар өстеннән валчык чүпләгәндә, башын ияия, Идрискә рәхмәт әйтә. Аның рәхмәт әйтүен дә Идрис кенә аңлый.

*Роза Хафизова*

## Ак песи

Идел-елга буенда, ямьле яр тугаенда зәңгәр тәрәзәле, зәңгәр болдырлы, зәңгәр капкалы бик матур бер йорт утырган. Шушы йортта бик тә матур, кеп-кечкенә ике песи баласы торган. Аларның берсе ап-ак мамыктай күперенке туннлы, үзе күк күзле, үзе бик тә үзсүзле булган. Икенчесе аклы-сорылы, күзе дә соры, әмма үзе бик тә акыллы, тыйнак һәм тыңлаучан икән.

Шушы ике песи баласыннан кала, бу матур йортта тагын апак чәчле, йомшак сүзле, ягымлы йөзле Әби дә яшәгән. Янында бик җитез, бик шаян бер оныгы да бар икән.

Бу Кызчык үзе дә тузгып торган сап-сары чәченә күбәләк кебек итеп зәңгәр тасма тагып йөри, Ак песинең муенына да зәңгәр тасма бәйләп куя икән. Барыннан да бигрәк, Кызчык Ак песине ярата, аны кочаклап кына йоклата, үзе ашаганны гына ашата, кәгазь күбәләкләр ясап уйната икән. Аның каравы, Әби

үзе Соры песине артыграк күрә, аны һаман «акыллым» — дип кенә йөртә икән.

Шуңа да бу ике песи, тормышларыннан бик канәгать булып, тыныч кына, рәхәт кенә яшәп яталар, тәмле-татлы ризыклар ашыйлар, йомшак урыннарда гына йоклыйлар, матур яшел бакчада йөреп-уйнап кайталар икән.

Бервакытны бу песиләр икесе бергә зәңгәр болдырның зәңгәр баскычында зәңгәр чынаяктан сөт эчеп торганда, баскыч төбендә кечкенә генә кап-кара бер Көчекне күреп алганнар. Бу Көчек, бик тә нәүмизләнеп, боегып кына, песи балаларының сөтләренә карап тора, ә үзе, сөт эчәсе килүен белгертергә теләгәндәй, еш-еш койрыгын болгый икән.

Ак песи баласы, Көчекне күрүгә, ап-ак сыртын кабартып җибәргән, тешләрен ыржайткан да, күк күзләрендә зәңгәр очкыннар уйнатып:

— Кит моннан! — дип ысылдаган. Соры песи, аптырап, Ак песигә караган.

— Бу нишләвең, Аппагым?! Күрмисеңмени, безнең кунагыбызның да сөт эчәсе килгән бит! — дигән ул, иреннәрен ялап торган кара Көчеккә күрсәтеп.

— Килсә соң! Минем анда ни эшем бар? Безнең зәңгәр баскычтан хәзер үк китсен! Югыйсә менә шушы тырнакларым белән күзләрен тырнап бетерәм мин аның! — дигән Ак песи һәм, кечкенә генә йомшак тәпиен күтәреп, үзенең бик тә очлы, бик тә үткен тырнакларын күрсәткән.

— Алай ярамый, сеңлем! Бәлки, аның сыеныр урыны юктыр, хәлен белергә, ярдәм итәргә кирәк үзенә! — дигән Соры песи.

— Сыеныр урыны, имеш! Шул гына җитмәгән иде, Сыеныр урынсыз Көчек була димени? Минем андыйларны күргәнем дә юк, күрәсем дә килми, — дигән Ак песи бик эре генә.

Соры песи туганының бу сүзләре өчен бик оялган һәм зәңгәр баскычтан сикереп төшкән дә кара Көчекне, әйдәп, үзе белән сөтле чынаяк янына алып килгән.

— Курыкма син аннан, курыкма, эч сөтне, эч! Үсмәгән әле ул, дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми, — дигән Соры песи һәм, тынычландырырга тырышып, кара Көчекнең борын очын ялап алган. Шуннан кара Көчек, курка-курка гына булса да, сөтне эчә башлаган.

*Резеда Вәлиева*

## Солтания белән күбәләк

Көн бик эссе. Солтаниянең бик тә, бик тә тәмле туңдырма ашыйсы килә. Ул әле бик кечкенә, аңа бары дүрт яшь кенә. Кечкенә булса да, урамга берүзе генә чыкты әле менә.

Солтания тирә-якка күз салды, ләкин ул якын-тирәдә туңдырма сатучы күрмәде. Инде кая барырга дип торганда гына, Солтания һавада бөтерелеп очкан бер матур күбәләкне шәйләп алды. Туңдырма ашыйсы килүен онытып, Солтания әлеге күбәләк артыннан китте. Матур күбәләк аның үз артыннан ияргәнен сизде, ахры, тиз генә юлның теге ягына очты. Солтания янә аның артыннан иярде...

Шулвакыт әллә ни булды. Машиналарның кинәт кычкырткан тавышларын ишетеп, юл уртасында тукталып калган Солтания чүт кенә егылып китмәде. Бер машина хәтта аңа терәлеп диярлек туктады.

Солтания кая барырга белмичә басып торганда, аның янына бер дәү абый килде дә җәһәт кенә аны читкә алып китте. Тротуарга чыгып баскач, әлеге дәү абый Солтаниядән:

— Курыктыңмы, үскәнем? — дип сорады.

— Әйе, — диде Солтания.

— Башка вакытта урамга үзең генә чыкма, яме, — диде аңа дәү абый. — Әниең йә әтиең белән генә чык. Өегезгә үзең генә кайта беләсеңме?

— Беләм, беләм, — диде Солтания. — Менә ич безнең өебез!

Ул янәшәдәге йортка ишарәләде.

— Бар, кайт инде тизрәк. Әти-әниең эзли чыкканнардыр... — диде дәү абый.

— Рәхмәт, абый! Мин киттем, — диде Солтания һәм, туңдырма ашыйсы килүен дә, әле генә күбәләк кууын да онытып, өенә таба йөгерде.

*Нәкыйп Каштан*

## Витаминлы аш

Мәктәптән кайтып керүгә:

— Нәрсә пешердең, дәү әни? Өйгә тәмле ис чыккан, — диде Тәнзилә.

— Витаминлы аш пешердем, кызым. Яз көне витаминнар җитми безгә, — диде дәү әнисе Сәхипкамал әби.

— Витаминны кайдан алдың соң? Даруханәгә бармагансыңдыр ич?

— Бакча рәшәткәсе буенда мине үзе көтеп торган.

— Кызык, мин аны даруханәдә генә була дип уйлаган идем.

Тәнзилә кулын тиз генә сабынлап юды да өстәл янына килеп утырды. Дәү әнисе тәлинкәгә аш салып бирде. Аңа бер кашык каймак өстәп болгатты да:

— Йә, ашап кара инде, — диде.

Тәнзилә тәлинкәне бик тиз ялт иттерде:

— Рәхмәт, дәү әни, тәмле аш пешергәнсең. Тагын пешер, яме.

— Пешерермен, кызым, пешерермен. Кычыткан җитәрлек, — диде Сәхипкамал әби, кет-кет көлеп.

Тәнзилә шаккатты:

— Кычыткан чага бит ул! Ә мин сизмәдем дә.

— Пешергәч юашлана ул шулай.

Сәхипкамал әби андый витаминлы ашларны кузгалак, сәрдә, балтырган кебек үләннәрдән дә пешерде. Тузганак яфрагыннан салат та ясаштыргалады. Тәнзилә аларның һәркайсын бик яратып ашады. Тузганак тамырыннан әзерләнгән төнәтмәне дә мактый-мактый эчте. Сөтле кофе дип уйлады. Сулышы кысыла башласа, дәү әнисе шуны гына эчә.

Менә ямьле җәй дә җитте. Су буйлары, болыннар шау чәчәккә төренде. Дәү әнисе кебек, Тәнзилә дә аларны бик ярата. Шулай беркөнне йөгереп кайтып керде дә:

— Дәү әни, хуш исле ромашка да чәчәк аткан! Инешкә төшә торган сукмак буенда бик күп икән ул, — диде.

— Алайса, аны да җыяр вакыт җиткән, — диде Сәхипкамал әби. — Әйдә, мал-туар таптаганчы җыеп керик, кызым.

Алар бер кулларына кайчы, икенче кулларына кәрзин күтәреп чыктылар да ромашка чәчәкләрен кисә башладылар. Ул арада Тәнзиләнең иптәш кызлары да килеп җитте. Әй китте эш, китте кызып, кызларның куллары кулга йокмый. Һәркемнең күбрәк җыясы, күршесеннән уздырасы килә. Тырышлык бушка китәме соң! Төш җиткәндә, барысының да кәрзиннәре хуш исле ромашка чәчәкләре белән тулган иде инде.

Сәхипкамал әби икенче көнне Тәнзиләне елга буена алып төште. Яр буендагы дымлы урыннарны эт тигәнәге үләне каплап алган иде. Чәчәккә бөреләнгән генә вакытлары. Аларның очларын нәкъ шундый чакта җыярга кирәк.

Дымлы урыннарда песи үләне дә шактый күп иде. Әмма Сәхипкамал әби аларга кагылмады.

— Орлыклары өлгереп коелсын әле, — диде. — Тамырларын көз көне казып алырбыз. Йөрәк авыртканда эчә торган валериан тамчыларын шулардан ясыйлар инде.

— Аны ни өчен песи үләне диләр соң?

— Тамырын песиләр яратканга.

Эт тигәнәге белән тулган кәрзиннәрен күтәреп кайтырга гына чыкканнар иде, Тәнзилә тышкы күренеше белән курайга охшаган үсемлек күреп алды.

— Дәү әни, әнә балтырган да бар икән монда.

— Без аш пешерә торган балтырган түгел ул, кызым, су балтырганы. Аның агуы шулкадәр зәһәр, хәтта кешене дә үтерә, — диде Сәхипкамал әби. — Исеңдә тот: әнә вак кына ак чәчәкләре бергә җыелып, зонт сыман булып тора. Яфраклары саплы, өч-

дүрт өлешкә телгәләнгән. Әгәр аны, уч төбенә салып, бармак белән изсәң, тәмсез ис чыга.

Чүплектә үскән миңгерәткеч белән тилебәрән орлыгын күргәч, оныгын тагын кисәтте Сәхипкамал әби:

— Бу үләннәрнең дә тартмачыктагы орлыклары бик агулы. Мәк дип, аларны ашаган кайбер балаларның үлү очраклары да бар.

Ә менә шунда ук үскән сукыр кычыткан чәчәкләрен күпләп җыйдылар алар. Бу чәчәктән аптекада йөрәк даруы ясыйлар. Сәхипкамал әби исә аннан төнәтмә әзерли.

Тәнзилә дәү әнисе белән урманда да еш була. Алар анда җиләк тә, көрән мәтрүшкә дә җыялар. Аны да кайчы белән генә кисеп алалар. Иң зурларын орлыкка калдыралар.

Шулай бервакыт Тәнзилә, кечкенә генә куак күреп, кинәт туктап калды. Аның кып-кызыл җиләкләре сабак буйлап тезелеп төшкән иде. Берсен алып кабыйм гына дигәндә, бәхетенә, дәү әнисе күреп алды:

— Чү, нишлисең, кызым?! Бүре җиләге бит ул. Аның хәтта кабыгы да агулы.

— Ә монысы нинди җиләк? — диде Тәнзилә. — Дүрт яфрак уртасыннан үсеп чыккан сабак очында кара җимеше дә бар. Кош күзе сыман ялтырап тора.

— Шуңа күрә дә карга күзе дип атала. Ул да бик агулы.

Тау битләрендә үскән сары мәтрүшкәне дә, сап-сары гөлбадран чәчәген дә шактый күп җыйдылар алар. Көчкә күтәреп кайттылар. Һәр үләнне күләгәдә аерым-аерым яхшылап киптерделәр. Сәхипкамал әби аларның һәркайсын кечкенә янчыкка яки кәгазь капчыкка салып куйды. Үзләреннән артканын Тәнзилә даруханәгә илтеп тапшырды.

*Хәкимҗан Халиков*

## Тылсымлы сүз

Озын ак сакаллы, кечкенә буйлы бер карт, зонтигының очы белән комга нәрсәдер сызгалап, эскәмиядә утыра иде.

— Тегендәрәк китегез, — диде аңа Павлик һәм эскәмия кырыена утырды.

Карт күчеп утырды һәм, малайның ачулы кызыл йөзенә карап:

— Нәрсә булды сиңа? — диде.

— Булса соң! Ә сезгә нигә ул? — дип, кырын карап куйды аңа Павлик.

— Миңа берни дә түгел. Ә менә син хәзер генә кычкырындың, еладың, кем беләндер ызгыштың...

— Шулай булмыйча! — диде малай, ачулы мыгырдап. — Мин тиздән өйдән чыгып китәм инде.

— Качасың?

— Качам! Шул Ленка аркасында качам. — Павлик йодрыкларын кысты. — Мин әле аны тукмап ташлый яздым. Бер буявын да бирми! Ә үзенең нихәтле буявы бар!

— Бирми? Кит сәнә, моның өчен генә качарга кирәкми.

— Аның өчен генә түгел. Әби мине бер кишер өчен дә кухнядан куып чыгарды... тастымал белән суккалап, тастымал белән...

Павлик, ачуыннан мышнап, борынын тартып куйды.

— Юк нәрсә! — диде карт. — Берсе ачуланса, икенчесе кызганыр үзеңне.

— Мине берсе дә кызганмый! — дип кычкырды Павлик. — Абый көймәдә йөрергә чыга, ә мине үзе белән алып чыкмый. Мин аңа: «Яхшылык белән ал, мин барыбер артыңнан калмыйм, ишкәкләреңне яшереп куям, көймәгә кереп утырам», — дим.

Павлик йодрыгы белән эскәмиягә сугып куйды да кинәт тынып калды.

— Нигә соң абыең сине үзе белән алып чыкмый?

— Ә нигә сез барысын да сорашасыз?

Карт озын сакалын сыйпап куйды.

— Мин сиңа ярдәм итәргә телим. Шундый бер тылсымлы сүз бар...

Павлик, авызын ачып, картка карап торды.

— Мин сиңа ул сүзне әйтәм. Ләкин исеңдә тот: аны, кем белән сөйләшсәң, шуның күзләренә туп-туры карап, йомшак тавыш белән әйтергә кирәк. Онытма: йомшак җавыш белән, күзләренә туп-туры карап...

— Ә нинди сүз соң ул?

Карт малайның колагына ук иелде. Аның йомшак сакалы Павликның яңакларын кытыклады. Карт нәрсәдер пышылдады да кычкырып өстәп куйды:

— Бу — тылсымлы сүз. Ләкин аны ничек әйтергә икәнен онытма.

— Сынап карыйм әле, — дип көлемсерәде Павлик, — хәзер үк сынап карыйм.

Ул сикереп торды да өйләренә йөгерде.

Лена өстәл янында рәсем ясап утыра иде. Аның алдында: яшел, зәңгәр, кызыл буяулар. Ул, Павликны күрү белән, аларны тиз генә сыпырып алды да кулы белән каплады.

«Карт алдаган! — дип үкенеп куйды малай. — Аңамы соң тылсымлы сүзне аңларга!»

Павлик, апасы янына килеп, аны җиңеннән тартты. Апасы борылып карады. Шул вакытта Павлик, аның күзенә туп-туры карап, йомшак тавыш белән:

— Лена, миңа бер буявыңны биреп торчы... зинһар, — диде.

Лена гаҗәпсенеп, күзләрен акайтып карады. Аның бармаклары ачылып китте һәм ул, кулын өстәлдән ала-ала, аптырабрак, авыз эченнән генә сорап куйды:

— Ниндиен?

— Зәңгәрен, — диде Павлик, кыюсыз гына.

Ул буяуны алып, кулында тотып торды, бүлмә буйлап бераз йөрде дә апасына кире бирде. Аңа буяу кирәк түгел иде. Хәзер ул бары тик тылсымлы сүз турында гына уйлады.

«Әби янына барыйм әле. Аның пешеренгән вакыты. Куармы икән, юкмы икән?»

Павлик кухня ишеген ачты. Карчык табадан кайнар пәрәмәчләр ала иде.

Павлик йөгереп килде дә ике кулы белән әбисенең кызарган, җыерчыклы йөзен үзенә таба борды һәм, туп-туры аның күзләренә карап:

— Бер пәрәмәч бирче... зинһар, — дип пышылдады.

Әбисе тураеп куйды.

Аның һәрбер җыерчыгында, күзләрендә, елмаюында тылсымлы сүз балкып китте.

— Кайнарынмы... кайнарны ашыйсың киләме, күгәрченкәем! — дип сөйләнде әбисе, кызарып пешкән иң яхшы пәрәмәчне сайлап.

Павлик шатлыгыннан сикеренде дә әбисенең ике яңагыннан үбеп алды.

«Тылсымчы! Тылсымчы!» — дип кабатлады ул үз-үзенә, картны искә төшереп.

Павлик аш янында басынкы гына утырды һәм абыйсының һәрбер сөйләгән сүзен игътибар белән тыңлады. Абыйсы көймәдә йөрергә чыгачагын әйтү белән, Павлик, аның җилкәсенә кулын салып, акрын гына:

— Мине дә үзең белән алып чыкчы... зинһар, — дип сорады.

Өстәл янындагылар бар да кинәт тынып калдылар. Көтмәгәндә, апасы:

— Алып чык инде аны үзең белән, сиңа берни дә тормый бит, — диде.

— Ә нигә алмаска? — дип елмайды әбисе. — Әлбәттә, ал.

— Зинһар, — дип кабатлады Павлик.

Абыйсы кычкырып көлеп җибәрде дә, аны җилкәсеннән кагып, чәчен кирегә сыпырып кабартып куйды:

— Эх, син, сәяхәтче! Йә, ярар, җыен! — диде ул.

«Ярдәм итте! Тагын ярдәм итте!»

Павлик, өстәл яныннан торып, урамга йөгерде. Ләкин бакчада инде карт юк иде. Эскәмия буш, бары тик комда зонтик очы белән сызгалаган билгесез тамгалар гына калган иде.

*В. Осеева*

## Кем хуҗа?

Зур кара эт Жук исемле иде. Ике малай, Коля белән Ваня, Жукны урамнан табып алып кайттылар. Аның аягы яраланган иде. Коля белән Ваня аны бергә тәрбияләделәр, ә Жук тереләп җиткәч, малайларның икесе дә аны үзенеке итмәкче булды. Ләкин Жукның хуҗасы кем соң — моны алар һич кенә дә хәл итә алмадылар. Шуның өчен дә аларның бәхәсе һәрвакыт ызгыш белән бетә иде.

Менә бервакыт алар урман эченнән баралар. Жук алдан йөгерә. Малайлар кызып бәхәсләшәләр.

— Эт минеке, — ди Коля. — Жукны, беренче күреп, мин алып кайттым!

— Юк, минеке, — ди ачуланып Ваня. — Мин аның яралы аягын бәйләдем, аңа тәмле әйберләр ашаттым!

Берсенең дә юл куясы килми. Ахырында малайлар бик нык ызгыштылар.

— Минеке! Минеке! — дип кычкырдылар икесе дә.

Кинәт урман каравылчысы йортыннан ике бик зур овчарка килеп чыкты. Алар Жукка ташландылар, аны җиргә ектылар. Ваня, кабаланып, агачка үрмәләде һәм иптәшенә:

— Кач тизрәк! — дип кычкырды.

Ләкин Коля бер таяк эләктереп алды да Жукка ярдәмгә ташланды. Тавышка урман каравылчысы йөгереп килде һәм үз овчаркаларын куып җибәрде. Ул, ачуланып:

— Кем эте бу? — дип кычкырды.

— Минеке, — диде Коля.

Ваня эндәшмәде.

*В. Осеева*

## Туган көндә

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә төрле-төрле тәмле-татлы сыйхөрмәт тезде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәриdәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, бар да елмаепкөлеп кенә торгандай күренә.

Фәридә, куана-куана, тирә-якка күз йөртеп чыкты. Күр инде, хәтта өстәлдәге чәчәкләргә кадәр елмая. Әле бүген генә алып кайткан, күрәсең, аларны әнисе!

Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары да килеп җитәр...

Фәридә әнисе янына аш бүлмәсенә керде.

— Әни, әни, дим, әйдә, әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына чыкмасын, ә? Югыйсә бүген анда бөтен нәрсә шундый матур, шундый яңа, ә әби шундый иске, әйем лә, шундый карт... бер дә килешми.

Әнисе башта аңышмыйчарак торды. Аннары, кинәт кенә хәлсезләнеп киткәндәй, кулларын салындырып, урындыкка сеңде. Кулларын тезләренә куйган килеш, байтак вакыт шулай сүзсез утырды ул. Аның йөзе бөтенләй үзгәргән, зур күзләре тирәнәеп, каралып киткәндәй булган иде.

— Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менә шулай, уздырмыйбыз... — диде ул.

*Резеда Вәлиева*

## Җанлы эшләпә

Песи малае Васька идәндә чебен аулап утыра иде. Комод өстендә кырыйда гына яткан эшләпәгә бер чебен килеп кунды. Васька кинәт кенә комодка сикерде дә, тырнакларына эшләпәне эләктереп, идәнгә очты. Ә эшләпә — шалт! — Васька өстенә төшеп капланды. Бүлмәдә рәсем ясап утырган Володя белән Вадик песинең эшләпә астында калуын күрмәделәр дә. Бары ниндидер тавыш кына ишеттеләр.

Борылып карасалар — идәндә эшләпә ята.

— Ә-ә, эшләпә төшкән икән.

Володя эшләпәне алырга дип иелгән иде, куркуыннан кычкырып җибәрде.

— Нәрсә булды?

— Ул те-те-ре!

— Нәрсә тере?

— Эш-эш-эшләпә.

— Син нәрсә! Эшләпә тере буламыни?

— Ы-ы-ышанмасаң килеп кара.

Вадик эшләпәгә якынрак килде. Килеп иелүгә, эшләпә аңа таба шуыша башлады.

— Ай! — дип, Вадик диванга сикерде. Аның артыннан — Володя.

Эшләпә бүлмә уртасына кадәр шуышып килде дә туктады. Аннары куркуларыннан дер-дер калтыранган малайлар ягына — диванга таба килә башлады.

— Ай! Ой! — Володя белән Вадик диваннан сикереп төштеләр дә бүлмәдән үк чыгып сыздылар.

Аш бүлмәсенә чабышып кереп, ишекне дә ябып куйдылар.

— Мин ки-ки-китәм! — диде Володя.

— Кая китәсең?

— Өйгә кайтып китәм.

— Нигә?

— Эшләпәдән ку-куркам. Йөри торган эшләпәне беренче тапкыр күрүем.

— Ә бәлки, берәрсе аны бавыннан тартадыр?

— Бар соң, кара.

— Әйдә, икәү карыйбыз. Мин кисәү агачы алам. Безгә таба килә башласа, кисәү агачы белән тондырырмын.

— Алайса, мин дә алыйм.

— Бездә бүтән кисәү агачы юк шул.

— Булмаса, мин чаңгы таягы алам.

Малайлар, кисәү агачы һәм чаңгы таягы белән коралланып, бүлмәгә башларын тыктылар.

— Кайда соң ул?

— Әнә тегендә, өстәл янында.

— Хәзер тондырам мин аңа, — дип батырайды Вадик, — килеп кенә карасын.

Әмма эшләпә кузгалмады, өстәл аягы янында ята бирде.

— Әһә-ә, курыкты! — дип шатланышты малайлар.

Эшләпәне кузгатырга тырышып, Вадик кисәү агачы белән идәнгә бәрә башлады:

— Әй эшләпә!

Юк, селкенми эшләпә.

Малайлар аңа, идәндәге кәрзиннән алып, бәрәңге тондыра башладылар. Ниһаять, берсе эләкте бугай, эшләпә өскә атылды:

— Мияу!

Эшләпә астыннан башта соры койрык күренде, аннары — тәпиләр, соңыннан песи баласы үзе килеп чыкты.

Вадик аны кочаклап алды.

— Васька, йомшагым, син ничек эшләпә астына кердең?

Васька аңлатып торуны кирәк санамады бугай, яктыдан күзләрен кыскалап утыруын белде.

*Николай Носов*

## Туган илем

*(Истәлекләрдән)*

Минем әнием йокыдан бик иртә, кояш чыкканчы ук торучан иде. Беркөнне мин дә шулай иртә тордым... Әни миңа сөтле чәй эчерде. Балчык чүлмәктә кайнаган сөт өстенә кызгылт каймак утыра. Каймак астындагы сөт гаҗәп тәмле, чәе дә эчеп туймаслык була торган иде.

Шушы чәй минем тормышымны уңай якка хәл итте: мин, кояш чыкканчы торып, әни белән тәмле чәй эчә торган булдым. Иртә торырга шулхәтле күнектем, кояш чыкканда йоклап ята алмый башладым.

Соңрак, шәһәрдә яши башлагач та, иртә тора идем. Хәзер дә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы уянып үзенчә эшкә керешкәндә, мин инде язарга утырган булам.

Еш кына башыма мондый уй килә: көн саен шулай кояш белән торсак! Күпме сәламәтлек, шатлык, бәхет өстәлер иде кешеләргә!

Чәйдән соң мин ауга киттем...

Авым минем, һәрвакыттагыча, табышлардан гыйбарәт.

Табигатьтә әле үзем күрмәгән, ихтимал, моңа кадәр беркем дә юлыкмаган нәрсәләрне табарга кирәк миңа...

Яшь дусларым! Без — табигатьнең хуҗалары. Табигать — безнең өчен кояш хәзинәсе. Без аны сакларга, алай гына да түгел, яңадан-яңа байлыкларын табып, өйрәнеп, серенә төшенергә тиеш.

Балыкка чиста су кирәк — сулыкларны саклрбыз. Урманнарда, кыр-далаларда, тауларда кыйммәтле, сирәк җәнлекләр яши — урман-кырларыбызны, тауларыбызны сакларбыз. Балыкка — су, кошка — һава, җәнлекләргә урман-кырлар, далатаулар кирәк. Ә кешегә Туган иле кирәк. Табигатьне саклау — Туган илеңне саклау дигән сүз ул.

*Михаил Пришвин*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Мәктәп

Җәй үтеп, көз җиткәч үк,
Мәктәп күзен ачты тагын;
Ялтырап китте урамнар,
Басты нур төрле ягын...

Инде башланды дәресләр,
Инде мәктәп җанлана;
Нинди шат, нинди бәхетле
Монда кергән һәр бала!

*Нәҗип Думави*

## Көз җитте

Киң болыннарда,
Урман-кырларда
Агачлар, гөлләр
Кибеп сулдылар.
Уйсу җирләрдә,
Елга, күлләрдә
Көзге салкыннан
Сулар туңдылар.

Көннәр суынды,
Чишмәләр тынды.
Безне калдырып,
Кошлар да китте.
Кошлар шикелле
Бергә гөр килеп,
Мәктәптә укыр
Вакытлар җитте.

*Муса Җәлил*

## Чыршы

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртмичә саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

*Габдулла Тукай*

## Күңелсез көз

Көннәр суынды,
Яфраклар сулды.
Көз җиттеме әллә —
Кошлар юк булды.

Кыйблага таба
Торналар оча.
Тауларны кара —
Болытлар коча.

Нинди салкын көз,
Тышта күңелсез!
Ничек яшәрбез
Чәчәксез, гөлсез?

*Сәгыйть Сүнчәләй*

## Ашлар солтаны

Зурлап уңыш бәйрәмен,
Җыелды татлы ашлар:
Катламалар, ләвәшләр,
Өчпочмаклар, токмачлар.
Игенченең өенә
Җыелдылар, күп булып.
Утыралар, тезелеп,
Кабарып, өстәл тулып.

Менә табын түрендә
Гөбәдия күренде.
Йөзе шат, көлеп тора,
Хуш ис бөркелеп тора.

— Уз, әйдә, Гөбәдия,
Йөзембай! — дия-дия
Зурлады Ләвәш аны:
— Саумы, ашлар солтаны!

Шулчак Чәкчәк күренде,
Йөзе кинәт сүрелде:
— «Табын яме — Чәкчәк» дигән
Сүзләр йөри түгелме?..

Кош теле, уйлап кына,
Сүз катты тыйнак кына:
— Кара инде, Ләвәш, син
Әллә мине белмисең?
«Кош теле — кунак ашы» дип
Әйтәләр түгелме соң?

Аннан Бәлеш кузгалды,
Тирән итеп тын алды,
Сулышыннан табынга
Татлы исләр таралды.

— Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә,
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән...

Пәрәмәч әйтте:
— Беләм,
Иттән генә торсам да,
Майга чумып чыксам да
Мактанмыйм мин дә, түзәм.

Сүз сорады Бөккән дә:
— Менә мине әйткәндә,
мин бит төрлечә булам,
Бер пешкәндә ит белән,
Бер — алма белән тулам.
Мине дә тәмле диләр,
Табынның яме, диләр...

— Мине тыңлагыз башта,
Минсез узмый бер аш та!..

Игенче хәйран калды,
Бәхәскә колак салды.

Әйтте ул: «Аңламыймын
Асылын сүзегезнең,
Сез һәммәгез ләззәтле
Кунак ашлары безнең.
Тик шулай да бу бәхәс
Борчый әле күңелне:
Иң кадерле ризыкны
Оныттыгыз түгелме?
Иркен кырларның исен,
Кояшның тәмен, төсен,
Җир-әнкәбезнең көчен
Үзенә җыйган өчен,
Дөньяның тиңсез ашы,
Табыннарның кояшы —
Ипекәй диләр аны.
Улдыр — Ашлар солтаны!

Ипекәй һәр көн кирәк,
Ул тәмледән тәмлерәк.
Ризыкка тәм биргән — ул,
Дөньяга ямь биргән — ул.
Ул тыйнак, ләкин көчле,
Онытмагыз икенче», —
Диде, кисеп, Игенче.

Татлы ашлар аптырап,
Тып-тын булып калдылар.
Бер-берсенең йөзенә
Карарга оялдылар...

Шулчак аналар кебек
Ягымлы гына көлеп,
Ипекәй килеп җитте,
Табын ямьләнеп китте.

Хөрмәт белән баш иеп,
— Түргә үт, түргә, — диеп
Каршы алдылар аны:
— Саумы, Ашлар солтаны!

*Резеда Вәлиева*

## Уңыш җыелды

Уңыш җыелды,
Аккошлар китте,
Матур көз ае —
Сентябрь җитте.

Урамнар тулып
Йөкләр үтәләр,
Алар дәүләткә
Ашлык илтәләр.

Бар да ашыга,
Тизрәк илтик дип,
Илебезне бай,
Матур итик  дип.

*Нур Гайсин*

## Кырдан кайткач

Бүген бер дә кыстатып
Утырмадым табында.
Әни нәрсә китерсә —
Ялт иттердем барын да.

Бәрәңгесе дә бүген
Шундый тәмле, ярмалы...
Тик бер кабым ипине
Кабар җирем калмады.

Киткән чакта табыннан,
Әни шундый мактады,
Ә дәү әти нигәдер
Мактарга сүз тапмады.

Авыр сулап куйды да:
Улым, диде, их сине!..
Китәләрме калдырып
Бер кабымлык ипине?

*Хәкимҗан Халиков*

## Беренче кар

Төн буенча туктамастан,
Тышта ап-ак кар ява,
Капланып кырлар, болыннар,
Җир йөзе ап-аклана.

«Кар явадыр, кыш була!» —
дип
Кычкыра бер яшь бала;
Үз-үзен белми куана,
Кул чаба да шатлана.

*Нәҗип Думави*

## Кыш килде

Килеп җитте кыш та.
Ай-яй, салкын тышта...
Өч ай торыр торса, —
Аның гомере кыска...

Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән;

Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.

Саф һавага чыгып,
Таудан чана шуып,
Кышның салкыннарын
Җибәрәбез, куып.

Ә кыш, көлә-көлә,
Битебездән үбә.

Алсу була безнең
Битләр шуңа күрә.

*Бари Рәхмәт*

## Кыш килде

Урамнарга, бакчаларга,
Урман, кырлар өстенә
Ак мамыктай күбәләк кар
Төшә дә төшә генә.

Яңа яуган кар шыгырдый,
Өстенә баскан саен,
Курыкмыйча каршылыйбыз
Салкын кыш аен.

Урамга чыктык шаулашып,
Йортлардан чана тартып;
Уйныйбыз, учта йомарлап,
Юеш кар тубы атып.

Һава саф — рәхәт суларга,
Яп-якты бөтен урын.
Кыш бабай килде кунакка,
Җир киде йомшак тунын.

*Галимҗан Латыйп*

## Җепшек көндә

Бүген иртән көн җепшеткән,
Кар явып үткән иде.
Без, малайлар, мондый көнне
Зарыгып көткән идек.

Йөгереп чыктык урамга,—
Кар атышып уйнадык.
И уйнадык, и уйнадык,
Тик барыбер туймадык.

Әйдә, — диде шунда кемдер, —
Кар бабай ясыйк бергә!
Вил чапты кишер алырга,
Нил йөгерде күмергә.

Ә дигәнче үсте бабай —
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз —
Киттек тирәли биеп.

Күмер күзләр янып тора,
Тап-таман чиләк бүрек.
Кар бабабыз җанлы кебек,
Китеп бармасын берүк.

*Җәүдәт Дәрзаман*

## Ак бабай

Бөтен дөнья аппак булып кар яуганда,
Ишегалды, урам, түбә агарганда,
Аппак булып кайтып килә безнең бабай,
Безгә төрле-төрле уенчык алган да.

Шатланышып, без әйтәбез: «Рәхмәт, бабай,
Сиңа тагын күп ел гомер бирсен Ходай!»
Бабай, мескен, кар-яңгырга карамыйча,
Безне шатландырмак өчен йөри шулай.

*Габдулла Тукай*

## Һай, Кыш бабай

Кемнең кигән киемнәре
Энҗе кар бөртекләре?
Кемнең көмеш күк сакалы,
Чәчләре, керфекләре?

Кем соң безгә шундый ямьле
Яңа ел алып килә?
Матур-матур капчыкларга
Күчтәнәч салып килә?

Чаңгы-чанада шуарга
Булды шома тавыбыз.
Кем безгә аны ясаган,
Кем икән ул, табыгыз...

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Бер яшькә үстем

Көн салкын, тышта
Уйный кар-буран,
Ак төскә керде —
Бизәлде урам.

Тагын ямьлерәк
Итәргә илне,
Иске ел үтеп,
Яңа ел килде.

Ямьле Кыш бабай,
Килдең син безгә,
Кунак булырсың,
Кер өебезгә.

Кыш бабай, мине
Бүген син макта,
Бер яшькә үстем,
Син килгән чакта.

*Нур Гайсин*

## Җәлил турында җыр

Әлифбадан укып беләм
Муса Җәлил турында.
Фашистлар белән көрәшкән
Дошманның үз тылында.

Туган илгә биргән антын
Тап төшерми саклаган.
Палач башын кискәндә дә,
Туган илен сатмаган.

Җырлар язган Муса Җәлил,
Каләм булган коралы.
Дошман килгәч, автоматка
Алмаштырган ул аны.

Муса Җәлил, Муса Җәлил,
Халкыбыз каһарманы!
Үлемсез аның исеме,
Мәңгелек аның даны.

*Рафис Корбан*

## Яз килә

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп, кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы —
Сагынып көткән яз килә.

Әйтегезче: кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк.

Көннәр җылы, күктә алсу
Нур сибеп, кояш көлә, —
Җәйге шатлык, көзге бәхет
Яз белән бергә килә.

*Мөнир Мазунов*

## Әниләр бәйрәмендә

Әй ачу чыкты абыйга —
Шундый иртә торган ул.
Мин торганчы, бөтен эшне
Бетергән дә куйган ул.

Әнием мактый абыйны:
— Әй уңган улым, син, ди.
Бөтен эшкә өлгергәнсең,
Минем уң кулым син, — ди.

Утыннар да кисеп керткән,
Ишегалдын көрәгән.
Аның күпме эшләгәнен
Әнием дә күрмәгән.

Ә абыем рәхәтләнеп
Көлеп тора бер читтә.
Көл, әйдә, көл, синнән әле
Үч алырмын ничек тә.

Әниләр бәйрәме тагын
Килеп җитәр бер елдан.
Шулчакта күрерсез менә —
Кем өлгер дә, кем уңган.

*Фәнис Яруллин*

## Иң матур җыр

Күгәрченнәр гөрләшәләр
Якты кояш нурында.
Алар җырлый иң матур җыр
Минем әни турында.

Нинди булган, нинди уңган —
Ул һәр эштә, һәркайда!
Йомшак сүзе, күркәм үзе,
Нурлы йөзе елмая.

Күрәсезме букет итеп
Алсу нурлар бәйләмен.
Кояш котлый март аенда
Минем әни бәйрәмен.

Йөрәгемнең иң түрендә
Иң кадерлем — әнием.
Яхшылыкта, матурлыкта
Үрнәк миңа әнием.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Әти кайтыр эштән...

Һәммәсе дә әзер:
Чәй кайнаган күптән,
Мичтә бәлеш пешкән...
Тик әтинең кайтып
Җитәсе бар эштән.

Тынлык. Сәгать кенә
Тек-тек килә өйдә.
Барыбыз да көтә:
Әни, мин, кечкенә
Миләүшә бишектә.

Кайтып керер әти,
Әниемне үбәр,
Мине күккә чөяр.
Бишегеннән алып,
Миләүшәне сөяр.

Идән юганымны,
Су китергәнемне
Әни аңа сөйләр.
И сөенер әти,
Улым уңган, дияр!

Сагынып, зарыгып,
Барыбыздан битәр
Әтине мин көтәм:
Ул кайтудан да зур
Шатлык бармы икән
Бу дөньяда бүтән?..

*Ямаш Игәнәй*

## Кайгырту

Бакчага бара Гөлназ,
Киенгән, җылы итеп:
Өстендә калын пәлтә,
Аякта киез итек.

— Әнием, ди, — кара әле:
Агачлар бит өшегән;
Җәй көне киенгән иде,
Кышка кергәч чишенгән.

Әнә бит ничек туңганнар,
Калтыранып торалар.
Минеке шикелле күлмәк
Бәйләп бир син аларга.

Бияләй дә, оекбаш та
Бәйләрсең бер тотынгач —
Аларның бит әнисе юк
Җәлләргә кызын, туңгач...

*Шәмсия Җиһангирова*

## Энҗе-мәрҗән калфагым

Дәү әнием энҗе калфак
Бүләк итте үземә,
Энҗе калфак, үзе ап-ак,
Бик килешә йөземә.

Энҗе-мәрҗән калфагыма
Йөрим сөенеп кенә,
Сәхнәләргә чыгып җырлыйм,
Калфаклар киеп кенә.

Әй калфагым, калфагым,
Калфаклар кияр чагым.
Күңелемә ямь бирүче
Нур булды шул калфагым.

Көзгеләргә күзем салсам
Хәйран калам үзем дә:
Җем-җем энҗе-мәрҗән-
нәрнең
Нуры уйный йөземдә.

Калфагымның матурлыгын
Һәммәсе дә күрсеннәр.
Энҗе калфак кигән кыз ул —
Татар кызы, дисеннәр.

*Резеда Вәлиева*

## Тылсымлы түбәтәй

Әбиемә нәрсә бүләк
Итим туган көненә?
Бүләк итеп шигырь сөйлим
Аңа туган телемдә.

Әбиемә минем бүләк
Бик тә ошаган икән.
Ул үзе дә бүләк бирде —
Бәрхет түбәтәй, чиккән.

Серле булды бу түбәтәй,
Тылсымлы булды әллә?
Тәртиплегә әйләнәм мин,
Башыма кигән мәлдә.

Әниемне дә тыңлыймын.
Шаярмыймын, йөгермим,
Энемне дә елатмыймын,
Елап, кеше көлдермим.

Түбәтәйле башым белән
Сугышып йөриммени?
Түбәтәйле башым белән
Буялып кериммени?

Ләкин менә кайчакта
Кияргә гел онытам.
Кәҗәләнәм, сугышам,
Ватам, бозам, ыргытам.

Тик даруын да беләм,
Дәвасы үзем белән.
Каплап куям башымны
Бүләк түбәтәй белән.

Аннары инде минем
Түбәтәйле башыма
Усаллык та килелек
Керми чаба-ашыга.

Мин яңадан әйләнәмен
Тәртиплегә, әйбәткә.
Әби биргән түбәтәйнең
Тылсымы бу, әлбәттә.

Инде беләм бабайның да
Ник тәртипле икәнен.
Бабаем бит беркайчан да
Салмый шул түбәтәен.

*Йолдыз*

## Бүген

Алсу җил таң нурларын
Сибеп китте тәрәзгә.
Урынымнан торалмый
Яттым әле беразга.
Нәрсәдер чаж-чож итә,
Әй исләре, исләре!
Искә төшерә өйдә
Бәлеш пешкән кичләрне.

Тордым, кердем кухняга.
Камыр шулай, чыжылдап,
Табага төшә икән,
Кетер-кетер кетердәп,
Коймаклар пешә икән.

Миңа карап елмая
Матур йөзле әбием.
Сөлгегә кулын сөртә
Ак яулыкны әнием:
— Юын, чистарт тешеңне,
Матур итеп киен! — ди, —
Бүген татар бәйрәме —
Гает көне бүген! — ди.

Йөгердем юынгычка.
Мин бәләкәй татарга
Ярамый мондый көнне
Озак йоклап ятарга.

*Рәшит Бәшәр*

## Намаз

«Бисмилләһир-рахмәнир-
рахим!» диеп кенә,
Намазлыгын идәнгә
Пөхтәләп җәеп кенә,
Бабам укый намазны,
Кәләпүш киеп кенә.

Тып-тын калган өй эче:
Сәгать тә келт-келт йөрми,
Самовар да гөрләми,
Мәчебез дә мырламый,
Радио да җырламый.

Ишегалды да тыныч:
Сыерлар мөгрәми,
Тавыклар кытакламый,
Үрдәкләр бакылдамый,
Казлар да каңгылдамый,
Хәтта Алабай өрми,

Бәрәннәр бәэлдәми —
Намаз вакыты икәнне
Алар да белгәнмени?

*Рәшит Бәшәр*

## Бәйрәм бүген

Бар күңеллек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкаддәс[5] хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын:
«Ул киенгәндер!» — дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
«Ислемай сөрткән икән дөнья!» — дидем: бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын;
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

*Габдулла Тукай*

## Китап һәм балалар

Дүрт-биш бала җыелганнар бер урынга,
Нәкъ уртада берсе китап тоткан кулга.
Һәммәсе дә колакларын торгызганнар:
Берсе укый, башкалары тыңлый шунда.
Утыралар, китап укып, күңел ачып,
Шатлыкларын бергә-бергә уртаклашып.
Кайвакытта тыңлый болар тып-тын гына,
Кайчагында көлешәләр шаркылдашып.

*Мәҗит Гафури*

---

[5] *мөкаддәс* — изге

## Әлифбам

Китап кибетенә без
Әтием белән барып,
Матур тышлы өр-яңа
Әлифба сатып алдык.

Ачып карагач аны,
Мин шатландым тагын да,
Андагы хәрефләрнең
Өйрәнермен барын да.

Сумкага салып аны,
Мин мәктәпкә барырмын.
Дөрес итеп сүзләрен
Тезеп укый алырмын.

Рәсеме дә күп икән,
Шундый кызык карарга.
Саклап кына тотармын,
Яңа торыр һаман да.

Күп нәрсәләр белермен
Туган илем турында.
Мин бит инде зур булдым,
Әлифбам бар кулымда.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Кояш — безнең дустыбыз

Иртән торып юлга чыксак,
Кояш озатып килә.
Көне буе юлда кояш,
Көн буе безнең белән.

Суга керсәк, ул да керә,
Чыныктыра нурлары.
Безнең белән уйный кояш,
Без — кояшның дуслары.

Җәй буе озатып барды
Болыннар буе безне.
Тәмле җиләкләр пешереп
Сыйлады һәммәбезне.

Көнгә чыксак каршы ала,
Сибеп җылы нурларын.
Кояш һаман безнең белән,
Без — кояшның дуслары!

*Рафис Корбан*

## Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл[6], дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

*Габдулла Тукай*

## Туган телем

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул — минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул — минем туган телем.

«Балам!» — диеп, туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
«Әнием!» — дип, әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.

Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин туган илдә.
«Туган ил» дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

*Энҗе Мөэминова*

## Татар теле

Мин бала чактук «әти, әни»
дидем шул тел белән,
Һәм дә әнкәм дә миңа
«бәбкәм» дигән шул тел белән.

[6] *Ярлыкагыл* – кичер

Әле дә шул тел белән
укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән
көйлим, берәр көй көйләсәм.

*Мәҗит Гафури*

## Нәүрүз килә

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Нәүрүзне зурлыйк әле.
Гөрләвекләр челтерәвенә
Кушылып җырлыйк әле.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Илләр, көннәр ямьләнә.
Бергәләшеп биергә дип,
Куллар кулга бәйләнә.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Күктән нурлар сибелә.
Туган илем, туган җирем
Язны күреп сөенә.

*Роза Хафизова*

## Тукай көне

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Йөздә кояш, күздә кояш.
Көндәгечә көлә кояш,
Әмма бүген үзгә кояш.

Бүген аның каршысына
Канатланып чыккан бөре...
Аваз сала томшыклары:
Тукай көне!
Тукай көне!

Килә язлар, китә язлар,
Һәр ел саен үзгәрелә...
Үзгәрелә...
Һәр ел саен Тукай гына
 Япь-яшь хәлдә килә безгә.

Киңлекләрдә язгы аваз —
Чыр-чу килә кошлар иле,
Чыңлап тора аһәңнәре:
Тукай көне!
Тукай көне!

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне —
Безнең бәйрәм!

*Мөдәррис Әгъләмов*

## Моңсу бәйрәм

Бәйрәмнең тагын да
Матуры, олысы,
Кояшлы май кебек
Яктысы, җылысы —

Бабамның сугышта
Кан коеп алганы —
«Зур Җиңү бәйрәме»
Дигәне бар әле.

Өр-яңа күлмәген,
Иң матур костюмын
Кия дә бабаем
Ул көнне өстенә,

Сандыктан ала да
Күп төрле орденнар,
Медальләр тага ул
Пиджагы түшенә.

Урамнар бәйрәмчә
Бизәлгән булса да,
Кояш гел һавадан
Нур чәчеп торса да,

Кешеләр ул көнне
Кайгылы тоела.
Елыйсын китереп
Яңгырый җыры да.

Ул көнне кешеләр
Һәйкәлләр каршында,
Баш иеп, тын гына
Торалар барысы да.

Һәйкәлләр тирәсе
Чәчәккә күмелә.
Шулчакта минем дә
Яшь килә күземә.

*Энҗе Мөэминова*

## Татарстан байрагы

Җилфер-җилфер итә байрагыбыз,
Ниләр сөйли соң ул җилләргә? —
Көрәшүче татар халкыннан ул
Сәлам әйтә азат илләргә...

Өч төс балкый безнең бу байракта:
Ак төс — безнең намус төсебез.
Яшел төсе — безнең яшәү төсе,
Кызылында чагыла көчебез.

Җилфер-җилфер итә безнең байрак,
Элеп куйдык аны биеккә.
Дөнья безнең шушы байрак аша
Омтылышны күрсен иреккә.

*Фәнис Яруллин*

## Туган җир

Сандугачкай, сайра, сайра,
Котлап язгы таңнарны.
Туган җирдәй гүзәл җирләр
Дөньяда тагын бармы?

Күрче, дөнья нинди матур,
Тирә-ягың гөл генә.
Гөлбакчадай ямьле була
Бары туган җир генә.

*Резеда Вәлиева*

## Карга бичара

Тормаган бер дә аяп,
Ыргыткан кемдер таяк.

Хәтта таш белән аткан,
Канатларын канаткан.

Яраларын карадым
Яраланган карганың.

Су эчердем, ашаттым.
Ә син аңа таш аттың.

Әй усал уйлы малай,
Ник иттең инде алай?

Бар иде нинди үчең?
Оялам синең өчен!

*Юозас Некрошюс, литва шагыйре*

## Сандугачлы Ак инеш

Исәнме, Ак инеш!
Аптырап калдың мәллә
Бу, дип, нинди кунаклар.
Ярыңа утыртырга
Алып килдек куаклар.

Юкса, тирә-ягыңда
Агачлар бетеп бара,
Сазлыклар кибеп бара,
Сулыклар кимеп бара.

Казларың бөтенләйгә
Очып китсә, нишләрсең?
Балыкларың диңгезгә
Качып китсә, нишләрсең?

Сандугачлар кунарга
Яшел талың калмаса,
Керәшәле ярларга
Ак дулкының какмаса,
Син дә кибеп бетәрсең,

Кешегә үпкәләрсең.
Ә син агарга тиеш,
Ә син чабарга тиеш
Сабантуйлар каршына,

Бары тик ап-ак килеш.
Сандугачлы Ак инеш!

*Рәшит Бәшәр*

## Кызыл китап

Яшел китап... Бәрхет китап...
Чыкты Кызыл китап та!
Югалуы мөмкин төрләр
анда барсы хисапта.

Җәнлеге дә, киеге дә,
үләне дә, бөҗәге дә...
«Саклап калыйк!» дип куелган
игътибар үзәгенә.

Китаплар күп. Бусы — кызыл.
Кызыл төс юкка димә!
Кызыл төс сискәндерә дә,
кызыл төс: «Тукта!» — ди дә!

Димәк, яшәр Җиребездә
хәлләр бар шомланырлык.
Табигатьтән ни алдык та
аңарда ни калдырдык?

Бар соңгы кат очкан кошлар...
Соңгы чәчәкле гөлләр...
Килер буынга калырмы
алар рәсемдә генә?

Димәк, иртәгә бер аваз,
бер төс-ямь җитмәячәк...
Беркөн үзенең хөкемен
әйтер бит ул Киләчәк!

*Равил Фәйзуллин*

## Дуслашасым килә!

«Ул малай бик тәртипсез,
Сугыш чукмары!» — дисез.
Димәк, әле сез аны
Бөтенләй дә белмисез.

Беләм, әйтмәсәгез дә,
Бар аның сугышканы.
Дөресрәге, кызларга
Бар аның булышканы.

Бәйләнде бер әзмәвер
Күрше кызына беркөн.
Әмма кызны якларга
Якын килмәде беркем.

Ә малайлар — гарьлекләр
Курыктылар якларга.
Курыктылар… качтылар…
Аларны ник якларга?

Ә ул менә килде дә
Яклашты күрше кызын.
Гарьлектән йодрыкларын
Төйнәде теге озын.

Көлгән булды әзмәвер:
— Яле, сыздыр тиз генә!
Әһә, курыкмыйсыңмы?
Ул чагында түз генә!

Качып китмәде малай,
Бик китмәде исе дә.
Үзенең, минсиңайтим,
Бар икән, әй, көче дә!

Егып салды тегене,
Шундый җилле иттереп —
Чын көрәшче шикелле
Бөтен шартын китереп.

Ә шуннан соң әзмәвер…
Сөйләп тормыйм барысын.
Шундый хәл булган иде,
Бик хәтерлим анысын.

Ә сез: «Сугыша!» — дисез…
Сугышканын да беләм.
Тик дуслашасым килә
Нәкъ шундый малай белән.

*Владимир Романов, удмурт шагыйре*

## Мин җырларга яратам

Мин җырларга яратам,
Тыңларга да яратам.
Җырларымны яңгыратам,
Бар дөньяга таратам.

Җырлыйм кояш турында да,
Тургайларга кушылып.
Җырларым канат кага да
Очып китә кош булып!

Җырларымда Туган илне,
Туган җирне зурлыйм мин.
Без бу җирдә дус һәм туган —
Рәхәтләнеп җырлыйм мин!

Рус малае, татар кызы —
Дусларымның барчасы,
Кушыла миңа… Гөр килә
Безнең дуслык бакчасы!

*Раиса Сарби, чуваш шагыйрәсе*

## Май

Беренче май бәйрәменә
Чәчәк ата ландышлар.
Аннан, чәчәкләргә күмеп,
Майны сирень алкышлар.

*Самуил Маршактан*

## Июнь

Июнь килде.
«Июнь! Июнь!» —
Бакчада кошлар сайрый...
Тузганакка өрсәң әгәр —
Бер бөртеге дә калмый**.**

*Самуил Маршактан*

## Катя

Без бакчабызга килдек,
Иртә таңнан ук торып.

Без үз кулларыбыз белән
Үрентеләр утырттык.

Без, әби белән бергәләп,
Шытымнар күмдек җиргә.

Ә Катя дус кызы белән
Бакчада йөрде бергә.

Көрәшеп маташкан булды
Безнең белән чүп үлән.

Без аларны йолкып алдык
Үз кулларыбыз белән.

Әби белән су ташыдык,
Лейкаларга тутырып,

Ә Катя көнен уздырды,
Скамьяда утырып.

— Син нәрсә, ят кеше кебек,
Карап торасың читтән?

Ә Катя җавап кайтарды:
— Мин дә мул уңыш көтәм.

*Агния Барто*

## Кабырчык

Мин бу кабырчыгымны
Саклыйм тартма эчендә.
Элек аунап яткан ул
Ярдагы ком өстендә.

Алып кайтты миңа бабай
Ерак Кавказдан аны.
Куйсаң әгәр колакка,
Ишетәсең шулчакта
Дулкыннар шаулаганны.

Хәзер безнең бүлмәдә
Тыңлап була диңгезне.
Кавказ килгән, әйтерсең,
Безнең бүлмәгә үзе.

*Агния Барто*

## Казлар, казлар

— Казлар, казлар, га-га-га,
Әйдә, киттек елгага.
Чумып-чумып йөзәрбез,
Чиста булдык, диярбез.

— Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Без бармыйбыз елгага.
Без болай да ап-аклар,
Кызыл тәпи ак казлар.

— Казлар, казлар, га-га-га,
Кермәгез сез бакчага!
Елга буе чирәмлек —
Сезгә азык җитәрлек.

— Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Без бармыйбыз бакчага.
— Кыйгак-кыйгак, га-га-га,
Әйдә, киттек елгага!

*Касыйм Тәхау*

## Песи һәм Чыпчык

*(Инглиз фольклорыннан)*

— И син, Чыпчык, нәнием,
Кайда соң синең өең?

— Хөрмәтле Песи агай,
Минем йортым юк бугай...

— Әйдә минем йортыма —
Рәхим ит курортыма!

— Хөрмәтле Мәче агай,
Миңа килешмәс алай:
Сез бит мине ашарсыз!

— Ах, сез, Чыпчык, начарсыз!

*Афзал Нигъмәтуллин*

## Карак песи

— Песи, кая барасың?
— Кырда тычкан ауларга.
— Барма әллә кайларга,
Кер дә утыр амбарга.
— Куркам шул мин хуҗамнан.
— Ник куркасың син аннан?
— Мыегы бик кабарган.
— Ник кабарган мыегы?
— Харап итте койрыгым:
Ялгыш тиеп, өстәлдән
Май савытын төшерде,
Хуҗам мине пешерде.
— Яле, ничек иттереп?
— Менә болай иттереп,
Башка берне шак итте,
Корсагыма шап итте.
Чак-чак качып котылдым,
Тышта елап утырдым.
— Алайса, бар, кайт та син:
«Хуҗам, гафу ит», — диген.
Бәлки, хуҗаң кичерер.
Хәзергә хуш! Киттем мин.

*Хәкимҗан Халиков*

## Светофор

Карап-карап торам да мин,
Уйлап-уйлап торам да,
Куркып куям: ай-һай кыен
Йөрүләре урамда!

Урамның теге ягына
Мөмкин түгел үтүе:
Урам тулы троллейбуслар,
Машиналар көтүе.

Әллә кайсы җирдән генә
Трамвай йә машина,
Йә булмаса, мотороллер
Килә чыга каршыңа!

Йә сызгырта сыбызгысын
Милиционер абый.
Йөри белмәсәң урамда,
Ул әллә каян таный!

Ялт чыгасың тротуарга —
Сизелми дә калына.
Бигрәк авыр шул шәһәрдә
Авыл малайларына!

Алмаз исә уйламый да —
Ят түгел аңа кала.
Машиналы урамда ул
Туйганчы йөри ала.

Бу шау-шулы урамнарда
Алмаз да йөрми тормый.
Тик урам аша чыгулар
Алмазга берни тормый.

Башта сул якка карый ул,
Аннан уң якка карый.
Аннары миңа борыла:
— Хәзер чыксаң да ярый!

Ни булды соң «Волга»ларга,
«ГАЗ»га, «МАЗ»га, «КамАЗ»га?
Выжлап килеп туктыйлар да
Юл бирәләр Алмазга.

Баксаң, алда светофор
Тора икән лә сакта.
Чыгалар икән урамнан,
Яшел ут янган чакта.

КЫЗЫЛ, САРЫ УТ ЯНГАНДА
ЯРАМЫЙ, ДИ, ЧЫГАРГА.
ЯНГАН ЧАКТА ЯШЕЛЕ
КИРӘК ИКӘН ЧЫГАРГА...

*Роберт Миңнуллин*

## Малайлар сөйләшә

— Мин үскәч абый булам!
Аннары бабай булам!
— Ә мин, бабай булгач та,
Гел әйбәт малай булам.
— Мин үзем әти булам!
— Ә мин дәү әти булам!
— Үскәч кем буласымны
Мин әле әйтми торам.
— Мин батыр солдат булам!
— Ә мин космонавт булам!
— Ә мин Третьяк булам!
Капкада сакта торам!..

— Ә мин бик озын булам,
Үсәм әле тагы да!
— Ә мин начальник булам,
Йөрим «Волга»да гына!
— Ә мин кибетче булам
Яисә итче булам!
— Ә мин бик көчле булам,
Әтием төсле булам!
— Мин комбайнчы булам,
Кырда иген урырга!
— Ә миңа әни, үскәч,
Куша кеше булырга!

*Роберт Миңнуллин*

## Сөембикә манарасы

Кремльнең эчендә
Биек, биек, биеккә
Ашкан бер манара бар,
Исеме — Сөембикә...

Балкып тора алтын ай
Шул манара очында.
Карыйсы килә кереп —
Ни бар икән эчендә?

Их, бер күрәсе иде,
Очып менәсе иде!
Шул биек манараның
Серен беләсе иде!..

Бик борынгы манара,
Исеме — Сөембикә.
Беләсебез бик килә:
Кем икән ул, кем икән?..

Хәзер үк әйтим микән,
Хәзер үк сөйлим микән? —
Патшабикә-ханбикә
Булган ул Сөембикә...

Сөекле бикә булган,
Сөйкемле бикә булган.
Җырларымда җырланган,
Бәет итеп укылган...

Аннан тагын ни булган?
Бик тә беләсе килә...
Шул манара очына
Очып менәсе килә!..

*Лена Шагыйрьҗан*

## Казан

И нурлы Казан —
Туган ил төсе,
Синең ташларда
Бабайлар эзе.

И якты Казан,
Синең нурларың
Кыйбласы безнең
Озын юлларның...

Еракта да син
Йөрәккә якын;
Торган җир — алтын.
Туган җир якын!
Туган тел якын!

*Хәсән Туфан*

## Биктырыш «Әлифба» укый

...Җитез малай Биктырыш,
Бүлмәсен яңгыратып,
Хәрефләр белән серләшә,
Тәм табып, ләззәт табып.

Һавада йөзә аваз...
Әйтә ул, сузып-сузып.
Авазларны бергә кушсаң,
Сүз туа — менә кызык!

Алларында — «Әлифба»,
Аллы-гөлле хәрефләр;
Мәктәпкә син хәрефләрнең
Һәммәсен дә танып бар!
Һәммәсен дә алып бар,
Төшереп калдырсаң берсен
Табалмассың, күрерсең!

— Ал-су су са-ла,
Ал-су су-са-ган...
Күзләреннән нур тама,
Дулкынланып тын ала,
Китап белән мәш килә,
Укый бала шәп кенә!

*Айдар Хәлим*

## Хуш, сөекле бакчабыз

Хуш, сөекле бакчабыз,
Сау булыгыз, апалар!
Кала курчакларыбыз,
Безне көтә парталар.


Мәктәпләр дә матурлана,
Нурлар сибеп таң аткач,
Бик күңелле була икән,
Китапларны яраткач.

Мәктәпләрне бәйрәмнәрдә
Гөлләр белән бизәрбез,
Түгәрәктә әйләнербез,
Илгә рәхмәт диярбез.

*Әминә Бикчәнтәева*

## II КИСӘК

# Җирдә миңа ни кирәк?



**Җирдә миңа ни кирәк?**

Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк!
Әллүкиле көй кирәк!
Тукай туган тел кирәк!

Җирдә миңа ни кирәк?
Туган-үскән ил кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Мәңге имин Җир кирәк!
Туган-үскән ил кирәк!
Мәңге имин Җир кирәк!

*Шәүкәт Галиев*

# I БҮЛЕК

## ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

*(«Физик үсеш» юнәлеше)*

### «СӘЛАМӘТЛЕК» БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Саф һава — тәнгә дәва.
* Таза тәндә — таза рух.
* Сәламәт тәндә — сәламәт акыл.
* Шапшак — ялкауның юлдашы.
* Чисталык — сәламәтлек билгесе.

## ТАБЫШМАКЛАР

* Исе юк, төсе юк,
* Аннан башка тормыш юк.
*(Су)*

* Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел.
*(Һава)*

* Ничек коеныр идең соң
Бу дөньяда син минсез?
Рәхәт җылы суым белән
Бүлмәдә мин — ак диңгез.
*(Ванна)*

* Иртә торгач, кулыңа ал,
Миннән башла эшеңне.
Паста белән мин чистартам,
Ап-ак итеп тешеңне.
*(Теш щёткасы)*

* Лампа түгел — яктырта,
Мич түгел — җылыта.
*(Кояш)*

* Берсе көнне ярата,
Берсе төнне ярата.
Икесе дә дөньяга
Якты нурлар тарата.
*(Кояш, ай)*

* Бит-кулыңны югач,
Сиңа мин кирәк.
Мин нәрсә булам,
Әйт син тизрәк.
*(Сөлге)*

* Юеш чакта кулдан
* ычкынмакчы,
Шуып китә, җаны бар кебек.
Мин ваннада шулай утыра
торгач,
Күмеп китмәсенме ак күбек!
*(Сабын)*

* Һәр көн авызына капса,
Яратса аны кеше,
Беркайчан да сызламас һәм
Ялтырап торыр теше.
*(Теш щёткасы)*

* Тешләре күп — ашамый,
Минсез эшен башламый.
*(Тарак)*

* Ике туган рәттән торсалар да,
Берсен берсе күрә алмыйлар.
*(Күзләр)*

* Авыз эчендә үзе,
Тик йотып булмый.
*(Тел)*

* Таралгач — биш,
Җыелгач — бер.
*(Бармаклар, йодрык)*

* Мин йөримен, ул тибә,
Эчемдә дөп-дөп итә.
*(Йөрәк)*

* Эскәтердән алдым,
Тегермәнгә салдым,
Капчыгымны тутырдым.
Капчыгымны тутыргачтын,
Ах-вах итеп утырдым.
*(Ашау)*

* Кечкенә генә җил капка
Ачыла да ябыла.
*(Авыз)*

* Хуш исле, шома,
Үзе чисталап юа.
*(Сабын)*

* Кечкенә генә сарай,
Эчендә бии утыз ике малай.
*(Авыз һәм тешләр)*

* Аны күрмисең дә,
Ансыз күрмисең дә.
*(Күзләр)*

* Минем ике тәрәзәм бар,
Һәр көнне иртән ачам,
Кич җиткәч ябып куям.
*(Күзләр)*

* Бер агачта ике яфрак.
*(Колаклар)*

* Тигез җирдә тай эзе.
*(Кендек)*

***

## Армыйм да мин, талмыйм да!
*(Спортчы җыры)*

Иртә торып күз ачуга,
Тышка атылам.
Кулларымны канат итеп,
Коштай талпынам.

Физзарядка, физзарядка!
Тәнгә көч тула.
Армыйм да мин,
Талмыйм да мин
Көн буе шуңа!

Көз дип тормыйм,
Кыш дип тормыйм,
Чабам юлларда.
Туктата алмый юлымнан
Кар да, буран да.

Чыныкканны корыч белән
Дөрес тиңлиләр.
Таза тәндә — таза рух дип,
Дөрес сөйлиләр.

*Мәхмүт Хөсәен*

## Хәрәкәттә — бәрәкәт

Куркып ятмый ачарга
Өстендәге юрганын,
Сизмисең дә Илгизнең
Йокысыннан торганын.

Тынгы бирми безгә дә:
— Тәмле булыр ашарга!
Барыгыз да, әйдәгез,
Физзарядка ясарга!..

Без торганчы, кайвакыт
Йөгереп тә кайта ул...
Йөри белә кул белән,
Мәтәлчек тә ата ул.

Илгиз зыр-зыр әйләнсә,
Җитә кала Ләйләгә:
— Зинһар, тукта, абыем,
Минем башым әйләнә.

— Беләсеңме, алайса,
Өйрән аны, Ләйлә, син:
Минем кебек зыр да зыр
Менә шулай әйлән син.

Әни тора шаккатып:
— Нишли соң бу? Бәрәкәт!
Әти көлә: «Әйләнсен,
Хәрәкәттә — бәрәкәт».

*Хәкимҗан Халиков*

## Зарядкага бас

Урыныңнан сикереп тор да
Зарядкага бас!
Чыныгып үсеп булмый бит,
Иренеп яткач.

Тәрәзне ачып җибәрдем —
Зарядкага бас!
Их, нинди саф һава керә —
Югал, йокы, кач!

Бер, ике, өч, бер, ике, өч —
Тик ялгышмый бас!
Елмай, кояш, ис, җиләс җил,
Күңелләрне ач!

*Гөлфия Юнысова*

## Хәрәкәттә — бәрәкәт

Әбием намаз укый —
Мин читтән карап торам;
Аның һәр ым-хәрәкәтен
Искәреп, барлап торам.

Иелә дә турая ул,
Турая да иелә —
Шуңа, ахры, әбекәйнең
Сызламыйдыр биле дә.

Өч тә түгел, дүрт тә түгел —
Нәкъ биш мәртәбә көнгә
Әбекәем намаз укый
Мин аңламаган телдә.

Хәрәкәттә — бәрәкәт, ди,
Минемәбитапкырул,
Көн дә физзарядка ясый —
Шуңа көләч, матур ул.

*Газинур Морат*

## Физкультура

Көн дә күнегүләр ясыйм,
Гер күтәрәм, туп тибәм...
Шаккатмассыз, әгәр мәшһүр
Чемпион чыкса миннән.

Көч-җитезлек бәйгесендә
Эшләрем уңмаса да,
Шаккатмассыз, димен, хәер,
Чемпион булмасам да.

Көчле, нык булып, чыныгып
Үсәсем килә тизрәк.
...Туган илне сакларга да,
Туган телне якларга да
Сәламәт акыл кирәк.

*Газинур Морат*

## Ял ит инде

Күргәнем юк дәү әнинең
Тик утырып торганын.
— Ял ит инде, арыгандыр
Аякларың, кулларың...

Дәү әнием, кет-кет көлеп:
— Бетсен инде эшем, — ди. —
Беләсеңме, тиз картая
Эшсез торган кеше, — ди. —
Эш ул — миңа физзәрядке,
Һич тынгылык бирми, — ди. —

Эшсез торып, минем тизрәк
Картаясым килми, — ди.

*Хәкимҗан Халиков*

## Тот яхшы тәрбиядә

Яңгырларга бирешми,
Пычрак йөртү килешми,
Бернинди дым сеңдерми,
Тузганлыгын сиздерми.

Бөгәрләнми бөртек тә,
Ә һава яхшы үтә.
Йөз ел яшә, барыбер
Гомер буена җитә.

Ләкин онытма шуны:
Бик ярата ул суны,
Кояшны һәм сабынны,
Чыныкканда, салкынны.

Аннан башка беркем дә
Яши алмый бер көн дә.
Тот яхшы тәрбиядә,
Нәрсә соң ул, әйт, әйдә?!

*(Тән тиресе)*

*Заһирә Гомәрова*

## Көмеш чишмә

Челтер-челтер көмеш чишмә
Яр астыннан агадыр.
Әби көн дә тәмле чәйгә
Суны шуннан аладыр.

Көрәк тотып, чишмәне мин
Чистартып кына торам.
Кыр-кырына ташлар түшим,
Аннан ерганак ерам.

Әби әйтә:— Чишмә суы
Гади түгел, серле, — ди, —
Ул кешегә көч бирә, — ди, —
Ямьли туган җирне, — ди.

*Дамир Гарифуллин*

## Чишмәгә бардык

Чишмә суын мактый әби:
«Тәнгә бик шифалы, — ди.
Самавырга җитми инде,
Кирәкми «Тифаль»е, — ди.

Бүген дә әбиебезгә
Чишмәдән су китердек.
Кайткан чакта, чалбарларга
Түгеп-чәчеп бетердек.

Очраган бөтен кешегә
Әбидән сәлам әйттек.
...Бер чиләк су алып кайттык,
Бер чиләк — сәламәтлек!

*Галимҗан Гыйльманов*

## Чисталык яратабыз

Су буенда, ком өстендә
Уйныйбыз төрле уен.
Уйнап туйгач, чүп-чарлардан
Чистартабыз яр буен.

Дулкыннар да чүпне судан
Күтәреп ярга ата.
Димәк, алар да, безнең күк,
Чисталыкны ярата.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Песине дә юабыз

Безнең песи аклы-кара,
Барыбыз да ярата.
Ай-һай, бик тә шаян шул,
Гел үзенә карата.

Безнең белән бергәләп,
Уйный-уйный тәгәрәп,
Үзе бетә каралып,
Йоны оча таралып.

«Песи белән уйнагач,
Кулыгызны юыгыз.
Бер, ике, өч! Туп-туры
Юынгычка юлыгыз!»

Песине дә юабыз,
Иркәләп, сыйпап кына.
Тырышуыбыз хак кына,
Түзә шуның хакына.

Төреп кенә, сак кына
Куйгач аны, җылына.
Без юганга өстәп, ул
Үзе тагын юына.

*Бикә Рәхимова*

## Бармаклар

Уң кулда биш бармак бар,
Сулында да биш бармак.
Ике кулдагын да кушсаң,
Ничәү була, уйлап тап!

Аяк саен бишәр бармак —
Аларын да саныйк без.
Ә соңыннан бөтенесен
Бергә кушып карыйк без.

*Гөлфия Юнысова*

## Муен

Теләсәм, сулга карыймын
Йә карыймын мин уңга,
Кирәк якка бора башны,
Рәхмәт инде муенга.

*Гөлфия Юнысова*

## Тешләр

Энҗекәйнең ике теше
Төште бүген, кит инде.
«Тешсез әби» диеп, үзен
Йөртәчәкләр бит инде.

Сөйләшүе дә көлкеле:
Уйнаным, — ди, — мин кишә,
Абыем чәй эчә, дисә,
Килеп чыга «шәй эшә».

Ярый әле, Ирхан көлми,
Тәҗрибә бар малайның.
Энҗекәй ышанып тыңлый
Сүзен өлкән абыйның:

— Алты-җиде яшьтә тешләр
Һәр кешенең төшә ул.
Елама, борчылма, сеңлем,
Озакламый үсә ул.

Яңа тешләр әйбәт була:
Үзе үткер, үзе ак.
Син елмаеп көлгән саен
Елтырар, энҗе сымак.

*Гөлфия Юнысова*

## Чисталык сөябез

Иртә белән торабыз,
Битебезне юабыз.
Сабын белән юынгач,
Бигрәк матур булабыз.

Муеныбызны юабыз,
Тешләрне чистартабыз.
Пөхтәлекне, чисталыкны
Һәрвакыт яратабыз.

Аш алдыннан һәрвакыт
Кулыбызны юабыз.
Ап-ак итеп кулны юып,
Ашарга утырабыз.

Аякларны кичкырын
Сабын белән юабыз.
Юынырга яратабыз, —
Без бик чиста торабыз.

*Әхмәт Ерикәй*

## Аш вакыты

...Тәртипне беләбез:
Кул юып керәбез.
Әйбәтләп кенә без
Ашыйбыз, эчәбез,
Бер сүз дә дәшмибез,
Түкмибез, чәчмибез.

«Апа, бик рәхмәт!» — дип,
Урыннан торабыз,
Авызны чайкыйбыз,
Кулларны юабыз,
Ә урындыкларны
Урынына куябыз.

*Бари Рәхмәт*

## Сөт эчәбез

Кояш инде кичкә ята,
Урам тулып, көтү кайта.
Сөтбикәләр сөт апкайта,
Сөт апкайта! Сөт апкайта!

Сөт ярата бөтен кеше:
Сөттә ак томаннар төсе,
Болыннарның татлы исе,
Туган җирнең сихри көче.

Сөт ярата әтиләр дә,
Сөт ярата әниләр дә,
Бабайлар да, әбиләр дә,
Сөт ярата бәбиләр дә,

Көтәбез көтү кайтканын,
Сөтбикә сөт апкайтканын.
Куанышып, сөт эчәбез,
Сөт эчәбез! Сөт эчәбез!

Без көчле булып үсәбез!

*Резеда Вәлиева*

## Чәчәкләр ясыйм

Бик чиста безнең Фоат,
Кулларын үзе юа.
Ашаганда, түшенә
Кулъяулык элеп куя.

— Карагыз әле монда
Мин ничек ашыймын, ди,
Ашыймын да савытта
Чәчәкләр ясыймын, — ди.

Алдына куйган ашын
Ашый бит ул, бетереп.
Тәлинкә төбендәге
Чәчәкләргә җиткереп.

*Саҗидә Сөләйманова*

## Без ашыйбыз бишбармак

Таудан кояш кызарды —
Алып кайттым бозауны.
Чебешләрем мең бөртек —
Эзләп таптым йөгертеп.
Әни сыер савуга,
Әти кайтты басудан.
Эш тә бетте, туктадык —
Ашъяулыкка тупландык.
Һә-һә-һә!
Уңда — әти, сулда — әни,
Без ашыйбыз бишбармак!

Асыл палас тупсада —
Әни ашны мул сала.
Әтием көлеп карый:
— Эшеңә күрә ярый!
Биш бармакта бер калак —
Селкенә ике колак.
Кояш киткән, ай чыккан,
Төш монда, ай, ачыксаң!
Һә-һә-һә!
Уңда — әти, сулда — әни,
Без ашыйбыз бишбармак!

Утырабыз түргә без,
Көн дә шулай бергә без!
Көндез тирләп эшлибез,
«Биш»ледән һич төшмибез.
Күршеләр һәм күләннәр,
Үткәннәр һәм сүткәннәр,
Кереп безне күрегез,
Ашның тәмен белегез!
Һә-һә-һә!
Уңда — әти, сулда — әни,
Без ашыйбыз бишбармак!

*Айдар Хәлим*

## Шифа чәе

Мунча яккан көнне әни
Шифа чәе пешерә.
Шифа чәе җәй көннәрен
Исебезгә төшерә.

Әнием аларны җәен
Урман, болыннан җыйган.
Кышын кечкенә чәйнеккә
Бөтен җәй үзе сыйган.

Ничә төрле яфрак, җимеш,
Җир җиләге, карлыган.
Исле үлән, бөтнек, чия,
Мәтрүшкә дә калмаган.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Аппетиты юк

«Аппетит юк», — ди Рөстәм.
Инде кылыйк ни чара?
Аш та, ит тә, ботка да
Ашый алмый, бичара.

Иртәнге ашка бары:
6 банан, 10 киви,
5 әфлисун, конфетлар,
Алган соклар да кими.

Әбәткә — торт, чикләвек,
Грушалар, алмалар.
Кәбестә ашын Рөстәм
Тагын ашый алмаган.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Әбиләрдә кунакта

Коймагы да коймагы,
Агып тора каймагы!
Табада пешеп тора,
Табынга төшеп тора.
Кайнар! —
яланкул тотма,

Тәмле! —
    телеңне йотма.
Син телең йотсаң, Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?!

*Шәүкәт Галиев*

## Табиблар яныбызда

Күздән яшь агып тора,
Борыннан тамып тора.
Тамак ачытып тора,
Кытыклап кырып тора.

Салкын тиюдән туйдым,
Әнигә әйтеп куйдым:
— Бирмә дару, уколлар,
Мин чыныгырга булдым.

Иң яхшы микстура
Булыр ул физкультура.
Кирәкми таблетка,
Күтәреләм турникта.

Уколлар урынына
Чыгам ишегалдына.
Салкын су коям баштан,
Бик авыр булды башта.

Иң шәп табиб — витамин,
Җәй авылга кайтам мин.
Ашыйм какы, балтырган,
Кишер, җиләк, карлыган.

Их, шәп авыл җәйләре,
Җыям үлән чәйләре.
Эшлим бакча, ындырда,
Чөгендер утыйм кырда.

Җәй үтә дә, көз җитә,
Минем китәр көн җитә.
Буйга үстем, ябыктым,
Чирләмәдем, савыктым.
Бирә дарулар табып,
Табигать — үзе табиб.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Татлы чир

Татлы әйберләр яратам —
Киндер, Натс, Милке-вей,
Сникерс, Марс, Нестле
Бигрәкләр дә тәмле, әй.

Кайсының эчендә суфле,
Ә кайсында чикләвек.
Бүләк аласыгыз булса
Тормагыз, һич шикләнеп.

Кибетләрдә мин яраткан
Тәм-томнар тулып ята...
Авызны ачып карасам,
Тешләрем тузып ята.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Ватмасын

Ай үтмәде, ике теше
Төште Зиләнең кинәт.
Алып бардым больницага,
Бер көйләп тә бер чөйләп.

Доктор әйтә: «Бала бик яшь,
Тешләрен, ди, сакласын,
Капмасын конфет, шоколад,
Чикләвек тә ватмасын».

*Вил Казыйханов*

## Чама бел

Йокыдан торгач та Айдар
Алды кулына көзге.
Күрә: алма төсле булып
Кызарган ике күзе.

Әнисе аны җитәкләп
Алып барды докторга.
Доктор әйтә: «Больницада
Туры килер ятарга.

Дәвалыйбыз бер шарт белән:
Кирәк булу түземле.
Чамадан тыш телевизор
Карау бозган күзеңне».

*Вил Казыйханов*

## Яшьтән өйрән тәртипкә!

Син, курчагым, киемеңне
Кадерсезләп аунатма,
Китапларыңны буяма,
Уенчыгыңны ватма,

Әйберләреңне ташлама,
Бөтен җирне туздырып;
Бүлмә буйлап чабып йөрмә,
Атлардан да уздырып.

Бар нәрсәң урынлы булсын —
Уйнап туйгач җыештыр,
Үз артыңнан эш ясама,
Әнием дә орышыр.

Үскәч кенә әдәп кермәс,
Күп мәртәбә әйтеп тә;
Мактаулы кыз булыйм дисәң,
Яшьтән өйрән тәртипкә!

*Флёра Тарханова*

## Курчагымны өйрәтәм

Курчагымның күлмәге гел
Буяла да буяла.
Тукта, өйрәтимче әле
Үзен керләр юарга.

Башта аңардан юдырмыйм,
Янда гына утырсын.
Ни эшләргә кирәклеген
Хәтергә салып торсын.

*Ямаш Игәнәй*

## Ләйсән инде зур булган

Ләйсән инде зур булган:
Әгәр килсә көенә,
Үзе торып юына,
Хәтта үзе киенә.

Әле менә бүген дә,
Тик күз генә тимәсен.
Үзе кигән күлмәгенең
Ә күлмәккә өч кенә.

Ләкин тора аптырап:
Күлмәге бик тә кыска,
Иңнәре дә тар гына,
Җиңнәре дә бик кыска.

Тик Ләйсән телгә оста:
— Ул,— ди,— шуңа кечкенә:
Миңа инде биш яшь,— ди, —
Төймәләгән төймәсен.

*Зиннур Насыйбуллин*

## Йомшак кыш яратабыз

Бигрәк йомшак кыш килде,
Күңелемә хуш килде.
Юраганым юш килде.

Көне буе тышта без.
Кар бабайлар, аюлар
Әвәләргә оста без.

Чаңгыда да шуабыз,
Чанада да шуабыз. —
Шулай чирне куабыз.

Тыштан арып керәбез.
«Әлли-бәлли бәү»не дә
Төштә генә күрәбез.

*Мөҗәһит*

## Бер дә ял итми калам

Төшке ашны ашагач,
Ял итәргә ятабыз.
«Тәннәрегез, күзләрегез
Ял алсын», — ди апабыз.

Ял итәргә дип ятам да
Мин ялгыш йоклап алам.
Шулай итеп, әз генә дә
Ял итә алмый калам.

*Мәрзия Фәйзуллина*

***

## Өстәл янында

Без энем Равил белән бик тату уйныйбыз. Ат-ат уйнаганда энем ат була, мин дилбегә тотам. Энем чапканда егылмасын дип, дилбегәне каты тартмыйм. Равил бик каты йөгерергә ярата. Ул башын артка чайкалдырып чаба, гел яхшы ат кебек.

Без чирәмле җирдә генә уйныйбыз, юл уртасында бер дә уйнамыйбыз. Әнием анда уйнарга кушмый. Анда машиналар йөри, ди. Йөгереп уйнап арыгач, өйгә ашарга керәбез. Бик әйбәтләп кулны юабыз. Кул сөртергә икебезнең дә кечкенә сөлгебез бар. Равил сөлгесендә чия, минекендә алма рәсеме чигелгән. Кечкенә апам чигеп бирде.

Без урамнан пычранып кайтсак, түргә дә уздырмый ул. Юынып керегез, ди. Безнең зур апабыз да бар әле. Ул инде сигезенчедә укый. Кечкенә апабыз — Сәлимә исемле. Дәү апабыз — Хәлимә. Дәү апа һәрвакыт аш өстәлен әзерли. Кечкенә апа безнең өстәл янында ничек утыруыбызны тикшереп кенә тора. Әнием белән әтием өйдә булганда, безнең барыбызны да күзәтеп торалар.

— Өстәл янында тыныч кына утырып ашагыз, дәү үсәрсез, — ди әтием. Әнием дә шулай ди. Дәү апа белән кечкенә апа да шулай әйтергә өйрәнеп беткәннәр. Равил дә, мин дә аларның сүзен бик тыңлыйсыбыз килә. Тик кайчагында тик кенә утырып булмый. Шул чагында дәү апа кара чия төсле күзләре белән безгә туп-туры карый. Кечкенә апабыз тиз генә җиңебездән тартып куя.

— Тик кенә утырыгыз инде, — ди. Үзе әле әтигә, әле әнигә карый. Апаларым бөтенләй тәртипкә өйрәнеп беткәннәр. Әти дә, әни дә аларны ачуланмый. Без дә кечкенә түгел бит инде. Равил дүрттә, мин алтыда. Ә безнең шаярасы гына килеп тора. Мин Равилнең кашыгын алам да әкрен генә аның башына сугам. Дәү апам урыныннан тора да минем кашыкны алып куя.

— Авырттырмадым ич, уйнап кына, әкертен генә, — дим. Равил дә үпкәләми, елмая. Ә шулай да мине шелтәлиләр.

— Кашык ашар өчен куелган, аның белән чәч тарамыйлар, — ди әнием.

Кайвакыт Равил өстәл астыннан минем аякка төртә. Мин дә аңар тибеп куям. Шаяра торгач, өстәлдә тәлинкәләр селкенә башлый.

— Болай шаярсагыз, мин сезне циркка алып бармам, — ди әтием.

Без бер вакытта туктап калабыз, шаярмаска сүз бирәбез. Менә аш артыннан әнием өстәлгә карбыз китерә. Карбыз утлы күмер кебек кып-кызыл. Үзе бер дә эссе түгел, сап- салкын, үзе шикәрле.

Безнең алдыбызга әнием карбыз телемнәре куя. Мин Равилнең карбызына карыйм да:

— Минем кечкенә, Равилнеке зур, — дим. Равил кулындагы карбыз телемен миңа бирә.

— Мә, апам, дәүрәге сиңа булсын. Минем карбызым кечкенә булса да, үзем зур буласым килә. Ә сиңа зур карбыз булсын. Үзең кечкенә булып калырсың, — ди Равил.

Миңа бик-бик оят була. Әтием дә, әнием дә, апаларым да Равилне мактап башыннан сөяләр.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Табын әдәпләре

Әй угыл, ризыкны уң кулың белән аша. Авызыңны тотып капма. Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булыр. Табынга ашны китергәч, шунда ук ашарга утыр, көттермә. Ашап бетергәч, өстәлдән ашны алмас борын торып китмә. Күп кеше килгән булып, бер генә кеше килеп җитмәгән булса, бер кеше өчен күп кешене көттермә.

*Каюм Насыйри*

## Ашау әдәпләре

Ашарга утырган вакытыгызда, иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез.

Үзегездән олы кешеләр булганда, өстәл янына алардан элек утырмагыз.

Аш янында берни белән дә уйнамагыз.

Аш янында борыныгызны тартмагыз, чөмереп ашамагыз.

Ризыкны зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз. Бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнлеген үзегез дә белерсез.

Чәй янында каймак вә майлы ашлар булса, киемнәрегезгә тамызмагыз, кулларыгызны майламагыз, майлы кулларыгызны киемнәрегезгә сөртмәгез.

Аштан соң кул вә авызларыгызны юыгыз, теш арасында бернәрсә калдырмагыз.

*Ризаэддин Фәхреддин*

## Ботка нигә тәмле?

Булган, ди, бер кыз. Ул әнисе пешергән рызыкларны ашарга бер дә яратмаган. Кәнфит-прәннек кебек татлыдан-татлыны гына сораган. Әнисе тегеләй әйтеп караган, болай әйтеп караган, кызый:

Моны ашагач эчем авырта! — дип ялганлый икән.

Әнисе аны врачка алып барган. Врач әйткән:

— Сезнең кызыгыз тап-таза, — дигән.

Кыз тагын хәйләгә сабышкан.

— Күзем авырта! — дигән.

Әнисе тагын врачка алып барган. Врач:

— Кызыгызның күзләре сау-сәламәт, — дигән.

Әнисе алдына тагын ашарга куйган. Кыз тәлинкәне эткән дә:

— Колагым авырта! — дип акырып еларга тотынган.

Әнисе аны тагын врачка алып барган. Врач:

— Кызыгыз бик әйбәт ишетә, — дигән.

Шулай булса да әнисе кызына татлыдан-татлы ризык кына ашатырга мәҗбүр булган. Шулай итә торгач, әнисенең ипи алырга да акчасы калмаган. Шуннан әнисе манный боткасы пешереп биргән. Кыз:

— Манный боткасын песнәкләр ашасын! — дип акырып-бакырып еларга тотынган.

Әнисенең ачуы килгән.

— Мин пешергән ризыкларны яратмагач, корт чүпли торган песнәккә әверел! — дигән.

Кыз песнәккә әверелгән, очып киткән, песнәкләр көтүенә кушылган.

Тик ул чын песнәк булмаган шул. Песнәкләр яратып ашаган бөҗәкне авызына да каба алмаган.

Шулай йөри торгач, ачыккан һәм үзләренең өенә кайтып җиткән. Ачык тәрәзәдән очып кергән, өстәлдә үзе ашамый калдырган ботканы күргән. Тәлинкәгә очып кунган да ботканы ашарга тотынган. Үзе ашый икән, ә үзе:

— Тәмле, тәмле, нишләп мин моңарчы шулхәтле тәмле икәнен белмәдем икән, — дип сайраган.

Ашый торгач, корсагы шартлап ярылырдай булып тулган. Һәм шуннан кемгә әйләнгән дип уйлыйсыз? Билгеле инде, үзенә?

Шуннан соң әнисе нәрсә пешереп бирсә, шуны ашаган, аны бүтән бимазаламаган.

*Сәмига Сәүбәнова*

## Киемнәр кая киткән?

*(Әкият)*

Мин төн уртасында күрше бүлмәдә мәзәк тавышлар ишеттем. Бу бүлмәдә Әхмәт йоклый иде. Мин аптырап калдым. Нинди тавыш булыр бу вакытта? Кемнәр килгән икән Әхмәт янына? Акрын гына килдем дә тыңлый башладым. Ишек ярыгыннан караган идем, — исем китте.

Бүлмә уртасында киемнәр. Әйе, Әхмәтнең Чалбары, Күлмәге, Бүреге, ботинкалары һәм оеклары. Алар җыелганнар да гөр килеп бәхәсләшәләр. Ә Әхмәт үзе йоклап ята. Берни дә ишетми, күрми.

Уртада Күлмәк. Аның якасы бөгәрләнгән, җиңе ертылган, бер генә төймәсе калган. Ул да бер генә җептә асылынып тора. Шул ертык җиңен селки-селки, Күлмәк сөйли:

— Кичә малайлар белән сугышып, менә бер җиңемне чак өзеп чыгармады. Уң җиңемне карагыз: менә бит ул гармун кебек җыерылган. Әхмәт бу җиңгә борынын сөртеп йөри. Төймәләремне карагыз: биштән тик берәү генә калган ич. Ул да иртәгә өзелеп төшәчәк. Ә яка? Юк, карамагыз аңа...

— Мине күрегез, мине! — дип, кыек-мыек атлап, уртага Чалбар чыкты. — Мине теккәнгә бер генә атна, ә тезләрем сүсәрде дә. Балак очларыма балчык ябышып каткан. Кесәмне күрегез бер генә. Анда ни генә юк: таш, тимер-томыр, ватык уенчыклар... Күтәрә дә алмыйм.

Караватастыннан сыңар Ботинка килеп чыкты.

— Минем хәлем аннан да начар! — диде ул. — Менә бауларым юк. Мине Әхмәт киндерә белән генә бәйләп йөри. Бауларым өстерәлеп йөрде-йөрде дә ишеккә кысылып өзелеп калды.

— Кайда соң сезнең икенчегез, уң аяк Ботинкагыз кайда? — дип сорады Чалбар.

Почмактан тавыш килде. «Мин монда! — диде кемдер, елак тавыш белән. — Җылыткыч батарея астында. Мине салган чакта, Әхмәт шушында кыстыра да аягын тыга. Мин кысылып калам. Хәзер сезгә күренергә оят, олтаным купты. Чөнки Әхмәт теләсә нинди кәнсир калайларын футбол итеп тибеп йөртә» .

Ботинканы бары да кызганды.

— Мине күрегез әле, мине! — диде кемдер. Карасам, уртада Бүрек тора. Аның бер колагы салынган, икенчесе күтәрелгән, түбәсеннән мамыгы бүлтәеп чыккан.

— Мине сатып алганга бер ай да юк, — диде Бүрек. — Менә үзегез күреп торасыз, мин нинди хәлдә! Менә бәйли торган бавым да юк бит. Ул аны чәйнәп өзде. Ә кичә? Кичә ул мине шундый җәберләде! Мәктәптән кайтканда, мине туп итеп типкәләде.

Бүрекне кызганып, бары да авыр сулап куйды. «Ай-яйяй!» — диделәр.

— Нишлибез? Болай яшәп булмый! — диде үкчәсе тапталган Оек. — Бүрек, син нәрсә уйлыйсың?

Бүрек уйга калды. Аннан әйтте: «Болай яшәп булмый, без башка берәр акыллы малайны эзләп китик!» — диде.

Бүрек белән бары да килеште.

— Китәбез, китәбез! — диде шунда ук Ботинка. — Үзенә үпкәләсен!

Шунда ишек ачылды. Алдан авызын ачкан Ботинка атлады, аның артыннан үкчәләре тапталган оеклар киттеләр, алар артыннан мамыгы чыккан Бүрек тәгәрәде, Чалбар да озын-озын атлап килеп чыкты. Иң азактан, ертык җиңен селки-селки, Күлмәк ашыкты.

Тик алар урам ишеге төбендә туктап калдылар.

— Минем башыма бер фикер килде, — диде Чалбар, — мондый хәлдә безне беркем дә үзенә алмас. Без кием төсенә керик башта!

Киемнәр борылдылар да Әхмәтнең Әбисе бүлмәсенә юл тоттылар. Әби бүлмәсендә дә бик озак сөйләшү, зарлану булды. Икенче көнне Әхмәт, киемнәрен эзләп, елый-елый, Әбисе янына килеп керде. «Мин аларны каян табам инде хәзер, мәктәпкә соңга калам ич!» — дип зарланды.

— Әгәр минем сүземне тотсаң, киемнәрең табылыр! — диде Әбисе.

— Әйт, Әбекәй, сүзеңне тотам, — диде Әхмәт.

— Мин сезне кадерләп кенә, чиста итеп, саклап кына киярмен. Кайтыгыз, киемкәйләрем, дип әйт! — диде Әбисе Әхмәткә.

— Күлмәккәем, Чалбаркаем, Бүреккәем, Оеккаем, ботинкаларым, мин сезне кадерләп кенә, саклап кына киярмен, чиста гына, пөхтә генә йөрермен! — диде Әхмәт. — Кайтыгыз миңа!

Шуннан почмактагы шкаф ачылып китте, аннан Чалбар, Күлмәк, Бүрек, оеклар һәм ботинкалар килеп чыкты. Алар бары да чисталар, әйбәтләр иде. Аларны Әби кием төсенә керткән.

Әхмәтне шуннан соң киемнәре бервакытта да ташлап китмәде. Ни өчен? Анысын сез әйтегез!

## Әкияттәге кебек

Равил — әйбәт малай. Ә менә ашау мәсьәләсенә килгәндә... Хәлләр кыен, хәлләр тәмам аптыраш.

— Улым, бер генә чүмеч аш салдым. Ашап куй, — ди Равилгә дәү әнисе.

— Ашыйсым килми, дәү әнием, рәхмәт, — дип җавап бирә Равил, ипле генә итеп.

— Менә бу бәрәңге боламыгы да бик тәмле...

— Юк, юк. Минем тамагым тук, дәү әнием.

— Кишер юып биримме?

— Кишерне дә яратмыйм.

— Ала-ай! Бу кишерләр, чөгендерләр еларлар инде.

— Еларлар? Нигә еларлар?..

— Үзләрен ашамаганга хурланып еларлар.

— Ашамагач, шатланырга тиеш бит алар, дәү әнием.

— Киресенчә. Алар бит безне Равил яратсын, безне Равил ашасын дип, тырыша үскәннәр. Кояш нурларын эчкәннәр, яңгыр суларын буыннарына күчергәннәр. Зур-зур яфраклар чыгарганнар, көч җыйганнар. Ә син аларны яратмыйм дисең. Менә шул син яратмаганга елый да инде алар.

— Ашау ярату буламыни?

— Ярату була. Аларның вазифасы шундый, улым. Сезнең кебек малайларга һәм кызларга көч бирәсе килә аларның. Йөзләрегезне көләч, алсу итәсе килә.

— Ашагач бетә ич алар, дәү әнием, юк була, — ди Равил, кулларын җәеп.

— Кешеләргә файда биреп юкка чыгу — аларның яшәү мәгънәсе! Синең кебек малайлар һәм кызлар яратып ашаса, кишер дә, чөгендер дә, кәбестә дә, суган да, башка җиләк-җимешләр дә шатлана гына.

— Кызык.

— Иң кызыгы тагын шунда: ай үсәсен атна эчендә үстерә алар үзләрен яраткан балаларны.

— Әкиттәге кебекме?

— Әкият тормыштан алына инде ул, улым.

Равилнең, билгеле инде, әкияттәге кебек бик тиз үсәсе килә. Шуңа күрә, күзләрен очкынландырып:

— Дәү әнием, син ясаган чөгендер салатын ашап куйыйммы? — дип сорый.

— Рәхим ит, улым, — ди дәү әнисе.

Шул көннән соң Равил бөтен яшелчә, җиләк-җимешләрне яратып ашый башлаган. Һәм, чынлап та, ел үсәсен — ай, ай үсәсен атна үсә икән бу.

*Эльмира Шәрифуллина*

## Шифалы табиблар

— Ромашка, Ромашка! Кая болай чабасың?

— Чапмый хәлем юк! Гыйләҗ бабайга салкын тигән, тамагы авырткан. Шуны дәваларга чабам!

— Әрем, Әрем! Кая болай йөгерәсең?

— Йөгерми хәлем юк! Сәрби әбинең ашказаны бозылган. Шуны төзәтергә йөгерәм.

— Ланыш, ландыш! Туктале, кая болай чабыш?

— Гафу, гафу! Туктап торырлык вакытым юк! Мөнәвәрә апаның нервылары какшаган, шуны тергезергә ашыгам!

— Бака яфрагы! Бака яфрагы!..

— Соңыннан, соңыннан! Вакытым юк! Хәйрүш абыйның күзенә арпа чыккан! Шуны дәваларга кирәк!

— Кычыткан! Кычыткан! Ә син кая?..

— Искәндәр дигән малай янына! Арт сабагын укытырга! Бүген тагын «ике»ле эләктергән! Юньсез!

*Вахит Монасыйпов*

# «ФИЗКУЛЬТУРА»
# БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

# ТАБЫШМАКЛАР

* Типтем — очты, биеп-биеп,
Суга төште, батмады.
Әни әйтә: «Шуны чөеп,
Тәрәзәне ватма!» — ди.
*(Туп)*

* Ике көпчәкле арба,
Атсыз да алга чаба.
*(Велосипед)*

* Аяклары түгәрәк,
Куышалар, тәгәрәп.
Үзем утырам, үзем чабам
Теләсә кая табан.
*(Велосипед)*

* Елгада су акканда
Эшсез без — ял итәбез.
Елга бозга әйләнгәч,
Без йөгереп китәбез.
*(Тимераяклар)*

* Йөртәләр аны һәрвакыт,
Каты-каты типкәләп,
Җан-фәрманга йөгерә ул,
Тормый бер дә үпкәләп.
*(Футбол тубы)*

* Кышын таудан шуабыз,
Җәен җыеп куябыз.
*(Чана, чаңгы)*

* Шома табанлы чана,
Атсыз да алга чаба —
Кулда булса таяклар,
Җитез булса аяклар.
*(Чаңгы)*

* Агач атлар
Кардан баралар.
Карда батмыйлар,
Матур эз салалар.
*(Чаңгы)*

# САНАМЫШЛАР

* Бер, ике, өч,
Сиңа көч,
Син моннан күч.

* Әлчи-бәлчи,
Әни күлмәк үлчи.
Чәүкә, чыпчык,
Син кал, бу чык!

* Җепсез орчык,
Чәүкә, чыпчык,
Кара балчык,
Син кал, бу чык!

* Каенда — карга,
Имәндә — чыпчык,
Җирдә — елан,
Һавада — кош,
Бар син дә оч!

* Бер, ике, өч,
Әнә тегендә күч.

* Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң, очып чык!

* Бер тай, ике тай,
Өч тай, дүрт тай,
Монда торма, чыгып тай.

* Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

* Кулда —уймак,
Табада — коймак,
Мичтә — бәлеш,
Ал да ябыш.

* Әке, бәке,
Кыек сәке,
Эремчек.
Син калып тор,
Ә син чык.

* Карга, чыпчык,
Берең кал да,
Берең чык.

* Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык
— Чык әле, ди, чык!

* Саескандай чикаклап,
Мин йөримен, өй саклап.
Син йокыңнан уян,
Озын колаклы куян.

* Ыргадан, мыргадан,
Песи бара елгадан,
Песи түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!

* Ялкау, чытык, мактанчык,
Мактанчыкка — буш капчык.
Буш капчык, уеннан чык!

* — Зәйни, Зәйни, Зәйнәбем,
Атны кайда бәйләдең?
— Алмагачка бәйләдем. —
Алма төште, шап итеп,
Зәйнәп чыкты, ялт итеп.

* Саесканның койрыгын
Саный китсәң — унике.
Сыңар аяк, сыңар, чык,
Син калып тор,
Ә син чык.

* Мин барамын базарга
Алтын-көмеш сайларга.
Ал чук, зәңгәр чук,
Монда торма, тизрәк чык.

* Тор, тор, тургай,
Таң ата бугай.
Тургай түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!

* Аладай, каладай,
Чистай, Чикәнәй,
Алабуга — ак балык,
Син кал, бу чык.

* Алма, шикәр, бавыр,агач,
Тик торма син ал да кач.

* Чәйнеккә акча салдым,
— Ничә булды?
— Йөз булды.
— Әтәлчек, мәтәлчек,
Сиңа туры килде, чык!

* Әлчи, бәлчи,
Әни миңа күлмәк үлчи,
Әнә тора бер чыпчык,
Менә тора бер чыпчык,
Артык булсаң очып чык!

* Алатыр, булатыр,
Тау ягыннан таң атыр,
Аны көтеп торганчы,
Алга таба бара тор.

* * *

* Алсу алма алланган,
Алты алма торып калган,
Алты, биш, дүрт, өч, ике, бер,
Монда торма, бар, йөгер!

* Рәшит, Рәшит, рәшәткә,
Рәшәткәдә пирчәткә,
Пирчәткәгә сук та сук,
Монда торма, торма, чык.

* Утын, утын, утыннар,
Утыннарга урын тар,
Утта янар утынга
Урман буйлап урап бар!

* Эчем, эчем, эчемкәй,
Эчемкәйгә тәмлекәй,
Эчемкәйне тәмләп ал,
Син чыгасың, ә син кал.

*Вәсимә Ураксина, башкортстан шагыйрәсе*

# УЕННАР

## Кояш һәм яңгыр

Урындыкларны (балагызга кечкенә урындык бирегез) арты белән үзегезгә каратып куегыз. Балагыз да, үзегез дә урындык артына чүгәләп утырыгыз. Урындык аркасының ачык урыныннан — «тәрәзәдән» карагыз. Түбәндәге шигырь юлларын әйтегез:

Тәрәзәдән кояш карый,
Алсу нурларын сибеп.
Сөенеп, кул чәбәклибез,
Уйныйбыз, матур итеп!

«Әйдә, шундый матур кояшлы көндә уйнарга чыгыйк!» — дип, балагыз белән бүлмә буйлап, биеп-сикереп, уйнап йөрегез, кулларыгызны чәбәкләгез. «Яңгыр килә!» — диюгә, урыннарыгызга йөгерегез (урындык артына чүгәләгез).

Уенны берничә тапкыр кабатлагыз.

## Куышу

Бер бала урындыкта утырып тора. Калган балалар белән тәрбияче, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, әлеге бала янына киләләр:

Без — күңелле, шат балалар, —
Яратабыз уйнарга.
Без качабыз, син, әйдә, ку,
Тырыш куып тотарга.

Соңгы сүзләрдән соң балалар йөгереп китәләр, утырып торган бала аларны куа. Тотылган бала урындыкка утыра.

Уен шулай дәвам итә.

## Йонлач көчек

Уенга берничә баланы чакырыгыз. Бер баланы көчек итеп билгеләгез. Ул, алга сузылган кулларына башын куеп, идәндәге паласка ята. Балалар әкрен генә аның янына килә башлыйлар, ә сез бу вакытта түбәндәге сүзләрне әйтәсез:

Йонлач көчек йоклап ята,
Җиргә төртеп борынын.
Йокламасын, уянсын,
Безнең белән уйнасын.

«Көчек» сикереп тора, балаларны куа башлый. Балалар төрлесе төрле якка йөгереп китәләр һәм «көчек»тән качалар. Барлык балалар да качып беткәч, «көчек» кире паласка барып ята.

Уен кабат уйнала.

## Төлке һәм куяннар

Идәнгә зур түгәрәк сызыла. Ул — «куян балаларының оясы». Бер читтә «төлке» утыра. Балалар ояларыннан чыгып сикерәләр, уйныйлар, бииләр. Тәрбияче: «Төлке килә!» — диюгә, балалар ояларына йөгерәләр. «Төлке» аларны куа. Уен шулай дәвам итә.

## Черки

Балалар урындыкларда утырып торалар. Алар — «черкиләр». Тәрбияче сөйли:

Яфракка черки кунган,
Ял итәргә уйлаган.
Аякларын селки-селки,
Аннан «качыш» уйнаган.

Балалар шигырьнең беренче ике юлында як-якка чайкалып утыралар, өченче юлында аякларын селкиләр, дүртенче

юлда качалар (куллары белән күзләрен каплыйлар). Бу вакытта тәрбияче бака маскасы кия һәм: «Кайда ул черкиләр? Мин аларны хәзер табам!» — ди. «Черкиләр»не эзли. «Менә алар кайда икән!» дигән сүзләрдән соң балалар як-якка йөгереп китәләр, «бака» аларны куа.

## Коңгызлар

Уйнаучы балалар коңгызлар итеп билгеләнә. Тәрбияченең «Коңгызлар очалар» дигән сүзләреннән соң уйнаучылар «жу-жу-жу» дип жуылдап, бүлмә буйлап төрле юнәлештә йөгереп китәләр. Бу вакытта тәрбияче сөйли:

Коңгызлар оча жуылдап,
Бж-бж, бж-бж быжылдап.
Оча торгач ардылар,
Идәнгә егылдылар.

«Егылдылар» сүзеннән соң балалар аркаларына яталар һәм аяк-куллары белән төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

Коңгызлар ял иттеләр,
Тагын очып киттеләр.

Балалар, торып, тагын очу хәрәкәтләре ясыйлар.

.

## Кечкенә туплар

Балалар, түгәрәк ясап, урындыкларда утырып торалар. Рәттән утырган 2 балага тәрбияче берәр кечкенә туп бирә. Бер бала тупны уң якка, икенчесе сул якка җибәрә (балалар тупларны бер-берләренә бирәләр). Ике туп «очрашкач», туплы балалар икесе ике якка йөгереп китәләр. Калган балалар бу вакытта «йөгердек, йөгердек» дип кабатлыйлар, кулларын чәбәклиләр. Ике бала, кара-каршы очрашкач, тупларын тәрбиячегә тапшыралар. Ул аларны башка балаларга бирә һәм уен дәвам итә.

## Атлар һәм көтүче

Балалар атлар итеп билгеләнәләр, тәрбияче — көтүче. Ул, курай уйнаган хәрәкәтләр ясый-ясый, түбәндәге шигырь юлларын сөйли:

Курай уйныйм: та-ра-ра!
Атлар кай якка таба бара?
Атлар бара болынга,
Яшел чирәм ашарга.

Бу вакытта балалар, бер аякларын алга, икенчесен артка куеп, атлар кебек сикергәләп, мәйданчык буйлап йөриләр. Курай уйнаудан туктагач, «атлар» да туктап калалар, башларын селкеп торалар. Тәрбияче кабат курайда уйный һәм уен кабатлана.

## Курыкмыйм

Балалар түгәрәк ясап басып торалар. Бер бала әбәкләүче итеп билгеләнә. Ул түгәрәк уртасына баса. Балалар, «курыкмыйм! Курыкмыйм!» дия-дия, бер урында ике аякта сикерәләр. Бу вакытта алар кулларын әле як-якка җәяләр, әле артларына яшерәләр. Әбәкләүче, балалар кулларын як-якка җәйгәндә, аларны әбәкләп өлгерергә (кулы белән кагылырга) тырыша. Әбәкләнгән бала уеннан чыгарыла.

## Бүләкләр

Балалар кулга-кул тотынып, түгәрәк ясап басалар. Бер баланы уртага бастыралар. Калганнары, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, түгәрәк буйлап йөриләр:

Алып килдек бүләкләр —
Курчак, очкыч һәм атлар,
Аю, куян — бар да бар —
Теләгәнеңне сайлап ал!

Шигырь ахырында балалар туктап калалар, ә уртадагы бала уенчыкларның берсен аласы килүен әйтә. Әгәр дә ул «ат ки-рәк» дисә, балалар, атлар кебек сикергәләп, хәрәкәтләр ясыйлар: кулларын алга сузып, аякларын югары күтәреп, бер-бер артлы түгәрәк буйлап йөриләр; әгәр дә «курчак» дисә, бию көенә пар-лашып бииләр; «аю» сүзенә — алпан-тилпән килеп, авыр басып йөриләр, «куян» сүзенә — бер урында ике аякта сикерәләр һ.б.

Уен уртага икенче баланы бастырып дәвам итә.

## Такыя үрәм

Балалар түгәрәк ясап баса, алып баручы уртада кала.

Алып баручы:

Мин йөримен болында,
Чәчәкләр бик күп монда.
Чәчәкләр җыям,
Такыя үрәм.

Алдан балаларның һәрберсенә чәчәк исеме кушылган була.

Алып баручы:

Кыңгырау чәчәк, кил әле,
Бер елмаеп көл әле,
Кочагыма кер әле.

«Кыңгырау чәчәк» уртага чыга. Алып баручы белән «кыңгырау чәчәк» икесе ике якка йөгереп китә, буш урынны алырга тырышалар. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.

## Тургай, чыпчык

Бер бала күзен йомып тора. Калган балалар, бергәләп:

Тор, тор, тургай,
Таң-таң ата бугай,
Тургай, кил, чыпчык, чык,
Чырык-чырык-чырык, —

диләр дә төрлесе төрле җиргә качып бетәләр. Күзен йомган бала «уяна», һәм «тургай» «чыпчыклар»ны эзләп китә. Кемне беренче булып тапса, шул күзен йома, һәм уен яңадан башлана.

## Мин качам, син тот

Уйнаучылар кулга-кул тотынышып, парлап басалар. Алда, аларга каршы, уенны алып баручы баса. Балалар, бергәләп:

Без, балалар, яратабыз качыш-тотыш уйнарга.
Әйдә, безне тотып кара, көчең җитсә тотарга, —

дип әйтүгә, беренче булып басып торган пар кулларын ычкындыра, һәм икесе ике якка йөгереп китә. Уенны алып баручы аларның берсен тотарга тиеш. Тотылган кеше уенны алып баручы була.

## Ачкычлар

Мәйданчыкта (яисә идәндә) түгәрәкләр сызыла. Уйнаучылар шул түгәрәкләргә кереп басалар. Арадан берсе уенны алып баручы була. Ул уенчыларның берәрсе янына килеп сорый: «Ачкыч кайда?» Тегесе җавап бирә: «Алсудан сора, ул әйтер сиңа». Алар сөйләшкән арада, калган балалар бер-берсе белән урыннарын алыштыралар (бер түгәрәктән икенче түгәрәккә күчәләр). Алып баручы да тиз генә берәр буш түгәрәк эченә кереп өлгерергә тырыша. Түгәрәксез калган бала уенны алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.

## Тилгән һәм тавык

Уен мәйданчыгының бер башында җиргә түгәрәк сызыла. Ул — «тилгән оясы». Уенда катнашучыларның берсе — «тилгән», икенчесе «тавык» итеп билгеләнә. Калган балалар «чебиләр» булалар. «Чебиләр» бер-берләренә тотынып, «тавык» артына тезелеп басалар (алда торучы «чеби» «тавыкка» тотына).

Уенны алып баручы «тилгән килә» дип сигнал бирә. «Тилгән» оясыннан чыга да колоннада соңгы булып басып торучы «чеби»не тотарга тырыша. «Тавык», «канатларын җәеп» (кулларын як-якка сузып), балаларын саклый. Ул «тилгән» кайсы якка ташланса, шунда «тилгән»гә каршы чыга. Бу вакытта «чебиләр», бер-берләреннән аерылмыйча, «тавык» артыннан ияреп йөриләр, соңгы булып басып торучы «чеби»не тоттырмаска тырышалар. Әгәр «тилгән» иң арттагы баланы тартып ала алса, ул аны үз оясына алып китә.

Уен вакытында балалар чылбырны ычкындырмаска, «тавык»тан аерылмаска тырышалар.

## Аю

Уенчылар бер-берсенә карап, түгәрәкләнеп басалар. Бер уенчы, кулына ярты метр чамасындагы бау тотып, түгәрәк тышында йөри. Ул: «Аю китте, күрдеңме?» — дип, иптәшләренең берсенә бау белән сугып ала, һәм үзе йөгерә. Сугылган кеше, аны куып җитеп, бауны алырга тиеш. Тота алмаса, ул уеннан чыга, һәм киресенчә, тота алса, бауны алдырган кеше уеннан чыга. Уен түгәрәктә бер генә кеше калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.

## Чәчәкләр, җилләр

Бер-берсеннән 2 м ераклыкта ике сызык сызыла. Шул сызыклардан 10—15 м ераклыкта тагын ике сызык сызарга. Уенда катнашучылар ике төркемгә: «чәчәкләр» һәм «җилләр»гә бүленәләр һәм эчке сызыклар артына бер-берсенә йөзләре белән тезелешеп басалар. Уенны «чәчәкләр» башлый. Алар һәрберсе үзләренә берәр чәчәк исеме алалар. «Җилләр, җилләр. Безнең исемнәребезне беләсезме?» — диләр алар. «Җилләр» чәчәк исемнәрен әйтә башлыйлар. Исеме аталган «чәчәк», йөгереп килеп, «җилләр» төркеменә күчә бара. Уен шулай дәвам итә.

## Сикергечләр

Сикергечләр белән төрле уеннар оештырырга була. Мәсәлән, «Кем тизрәк?» уены. Берничә бала сикергечләр тотып, бер-берләреннән ара калдырып, бер рәткә тезелеп басалар һәм тәрбияче сигналыннан соң алдан билгеләнгән урынга кадәр сикергечләр аша сикереп баралар.

«Кем озаграк?» уенында балалар бер урында сикереп торалар. Кем озаграк ялгышмыйча сикерә, шул җиңүче була. «Кем ничек булдыра?» уенында һәр уйнаучы сикергечләр белән хәрәкәтләрне үзе уйлап чыгара һ.б.

Әлеге уеннарны уйнау өчен, алдан балаларны сикергечләр аша яхшы итеп, хәрәкәтләрне катлауландырып сикерергә өйрәтергә кирәк.

## Тырыш кырмыскалар

Эстафета өчен һәр командага бер гимнастика таягы кирәк булачак. Командалар старт сызыгы артына басалар да, беренче уенчы, гимнастика таягын алып, билгеләнгән урынга йөгерә. Кире йөгереп килеп, «ярдәмгә» бер иптәшен чакыра. Таякка икенче уенчы тотынып, алар эстафетаны дәвам итәләр. Алары да шулай йөгереп килеп, өченче уенчыны «ярдәмгә» чакыралар. Иң ахырдан таякка барлык уйнаучылар да ябыша. Әлеге «авыр йөкне» иң беренче булып финиш сызыгына кадәр китергән команда җиңүче була.

## Әйт, күгәрчен

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Ике бала уртага чыгып баса. Алар уенны алып баручылар һәм җыр башлаучылар булалар. Салмак көйгә балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр. Җыр эчтәлегендә нәрсә турында сүз барса, шул хәрәкәтне бергәләп башкаралар.

Әйт, күгәрчен, син генә:
Яшь кызлар ничек йөри? *балалар яулык очларын*
Ул болай да, ул шулай, *тотып йөриләр*
Яшь кызлар йөри шулай.

Әйт, күгәрчен, син генә:
Куяннар ничек йөри? *куян кебек*
Ул болай да, ул шулай, *сикереп йөриләр*
Куяннар шулай йөри.

Әйт, күгәрчен, син генә: *әле бер якка,*
Үрдәкләр ничек йөри? *әле икенче якка янтаеп,*
Ул болай да, ул шулай, *алпан-тилпән*
Үрдәкләр шулай йөри. *йөриләр*

## Яулык алыш

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык, —

дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

## Башмакчы

Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (уйнаучы балаларның аяк размерыннан башмак зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез;
Асыл төсле җепләр белән
Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы,
Үзең — оста такмакчы.
Син җырлама такмагың,
Бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны 2 бала арасына куя һәм аларның иңнәренә кагыла. 2 бала икесе ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул «башмакчы» була. Уен яңадан башлана.

## Бүген кемнең туган көне?

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала (туган көне булган бала) уртага чыга. Уйнаучылар, җырлый-җырлый, бер якка таба әйләнәләр, ә уртадагы бала түгәрәк эчендә каршы якка йөри. Тәрбияче балалар белән бергә җырлый:

Бүген кемнең туган көне?
Нигә кояш елмая?
Белдек, белдек: Гөлсинәгә
Бүген 7 (3, 4, 5, 6) яшь тула.

Гөлсинәгә карагыз:
Ничек матур киенгән!
Сәламәтлек, бәхет, шатлык
Телибез чын күңелдән.

Икенче куплетка балалар туктап, кул чабып торалар, ә Гөлсинә бии.

# ФИЗКУЛЬТМИНУТЛАР

## Кечкенәләр төркеме

### Яңгыр

Яңгыр, яңгыр, яңгыр, яу! *сикергәлиләр,*
Яңгыр безгә бик кирәк. *әйләнәләр,*
Яңгырдан соң агачлар, *кулларын як-якка җәяләр,*
Гөлләр үсә тизрәк. *кулларын өскә күтәрәләр*

### Там, там, тамчы, там!

Там, там, тамчы, там! *бер бармак белән уч төпләренә сугалар, кул чәбәклиләр*
Тамганыңны яратам.

Тамган тамчыларга карап, *башларын як-якка чайкыйлар*
Мин җырларга яратам.

### Чәбәк-чәбәк

Чәп-чәп, чәбәкәй, *нәниләр кулларын күтәреп чәбәклиләр*
Кулларыбыз бәләкәй,

Ә хәзер тизрәк-тизрәк *кулларны җиңелчә генә тезләргә сугалар*
Чәбәклик күңеллерәк.

### Үсеп китте

Үчтеки, үчтеки, *балалар алга таба иеләләр, чүгәлиләр*
Үсмәгәнгә кечтеки.

Үсә-үсә зур булыр, *акрын гына күтәреләләр, бармакларын бит уртасына куеп,*
Бигрәк матур кыз булыр.

| | |
|---|---|
| Бик батыр егет булыр. | *башларын як-якка чайкыйлар* |
| Үчти, үчти, үчтеки, | *аяк очларына басып,* |
| Үсеп китте кечтеки. | *кулларын өскә күтәрәләр* |

## Нәниләр

| | |
|---|---|
| Әй нәниләр, нәниләр, | *балалар бер рәткә тезелеп,* |
| Ардык без, дип әйтмиләр. | *чүгәләп утыралар, әкрен* |
| | *генә торалар* |
| Аякларын күтәреп, | *йөрү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Матур итеп атлыйлар. | |
| | |
| Хәзер барабыз артка, | *артка таба йөрү* |
| Егылмыйча, син атла. | *хәрәкәтләре ясыйлар* |
| | |
| Бер, ике, бер, ике! | *алга таба киләләр* |
| Егылмыйча, син атла. | |

## Матур тубым

| | |
|---|---|
| Минем тубым бигрәк җитез: | *кулларын чәбәклиләр,* |
| Матур итеп сикерә. | *сикерәләр,* |
| Әгәр тотып өлгермәсәң, | *кулларын өскә күтәрәләр,* |
| Әллә кая йөгерә. | *бер урында йөгерәләр* |

## Тигез юл буйлап…

| | |
|---|---|
| Нәниләр бара | |
| Тигез юл буйлап, | *атлап баралар* |
| Тигез юл буйлап, | |
| Ашыкмый атлап. | |
| | |
| Зур-зур ташларны | *алга таба ике аякта* |
| Сикереп үтәләр. | *сикереп баралар* |
| Һәм көтмәгәндә | |
| Егылып китәләр… | *туктап калалар,* |
| Бух! | *чүгәлиләр* |

## Курчакны йоклату

| | |
|---|---|
| Курчагымны юам мин, | *баланың өстенә су сибү* |
| Күлмәкләрен уам мин. | *хәрәкәтләре ясыйлар, «кер» уалар* |
| Зинһар өчен, берегез | *кулларын алга сузып, уч төпләрен* |
| Булышырга килегез. | *өскә каратып, бармаклары белән* |
| | *чакыралар* |
| Юындыргач, без аңа | *кашык белән ашату хәрәкәтләре* |
| Тәмле мәми ашатыйк. | *ясыйлар* |
| Көне буе арыгандыр, | *баш алдында кулларны бергә куеп,* |
| Инде аны йоклатыйк. | *башны шул кулларга салып, әкрен* |
| Бәлли-бәлли-бәү! | *генә чайкалалар* |

## Кошлар

*Балалар идәндә чүгәләп утыралар.*

| | |
|---|---|
| Нәни кошлар уяндылар, | *әкрен генә торалар* |
| Канатларын кагындылар. | *кулларын як-якка селкиләр* |
| Чырык-чырык чыркылдап, | *чәбәклиләр* |
| Төрле якка таралдылар. | *төрле якка таралышалар* |

## Нәни аяклар

| | |
|---|---|
| Безнең нәни аяклар | *балалар бер урында йөгерәләр* |
| Шәп итеп йөгерәләр. | |
| Юлдагы ташлар өстеннән | *ике аякта сикереп баралар* |
| Сикерә-сикерә үтәләр. | |
| Озак сикерә торгач, | *«бух!» сүзеннән соң чүгәлиләр* |
| Зур чокырга төшәләр. | |
| Бух! | |

## Чебиләр

| | |
|---|---|
| Өй алдында чебиләр:<br>«Чип-чип-чип!» — дип йөриләр. | *кулларны артка җәеп, як-якка борылалар* |
| Кечкенә канатлары,<br>Муеннары сап-сары. | *кулларын як-якка җәяләр, бармаклары «бии», башларын чайкыйлар* |

## Уңган балалар

| | |
|---|---|
| Безнең нәни аяклар<br>Шәп итеп йөгерәләр. | *балалар йөгерү хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Куллар да калышмыйлар,<br>Чәп-чәп итеп бииләр. | *кулларны чәбәклиләр* |
| Шушы нәни балалар<br>Уенчыкларны җыя. | *чүгәләп, уенчык җыю хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Уенчыклар җыялар да<br>Урыннарга куялар. | *басып, «уенчыкларны куялар»* |
| Апа әйткәч, балалар<br>Беркая да бармыйлар. | *урыннарга бараลар* |
| Тыныч кына утырып,<br>Әкиятләр тыңлыйлар. | *әкрен генә утыралар* |

## Уртанчылар төркеме

### Без атлап барабыз

Без атлап та барабыз, — *атлап баралар,*
Йөгереп тә барабыз, — *йөгерәләр*

Арып китсәк утырып, — *туктап, бер урында*
Аякларны язабыз. — *тыпырдыйлар*

### Карагыз

Менә минем уң кулым, — *уң кулларын күрсәтәләр,*
Менә минем сул кулым, — *сул кулларын күрсәтәләр*

Менә идән, менә түшәм, — *өскә-аска карыйлар,*
Менә шулай зур үсәм. — *аяк очларына күтәреләләр*

### Аю

Тау башында ята кар, — *балалар, кулларын җәеп,*
Тау башында бик күп кар! — *әкрен генә өскә күтәреләләр*

Урманда чыршы төбендә — *гәүдәне алга таба ия төшеп,*
Йокыга талган аю бар. — *әкрен генә алга баралар*

Шыпырт, тавышланмагыз, — *бармак яныйлар, «йоклыйлар»*
Аюны уятмагыз!

### Без инде хәзер зурлар

Без инде хәзер зурлар, — *аяк очларына басып,*
Күп эшли безнең куллар. — *кулларын югары күтәрәләр,*
*кулларын төрле якка*
*хәрәкәтләндерәләр*

| | |
|---|---|
| Без идән дә юабыз,<br>Без керләр дә уабыз,<br>Гөлләргә су сибәбез. | *иелеп, идән юу хәрәкәтләре ясыйлар, куллар белән кер «уалар», гөлгә су сибү хәрәкәте күрсәтәләр* |
| Менә шундый уңган без,<br>Менә шундый булган без. | *аяк очларына басып, түгәрәктә әйләнәләр* |

## Бака, бака, бакырган...

| | |
|---|---|
| Бака, бака, бакырган,<br>Бака кунак чакырган,<br>Кунаклары килмәгәч,<br>Тышка чыгып акырган:<br>Ба-ка-ка-ка!<br>Ба-ка-ка-ка! | *кулларын як-якка җәеп сикерәләр, бер-берсенең каршысына килеп, баш ияләр, сикергәлиләр, як-якка карыйлар, сикергәләп торалар, бергә кычкыралар* |

## Энебез тәпи китә

| | |
|---|---|
| Атлап-атлап килә ул,<br>Алпан-тилпән килә ул. | *алпан-тилпән баралар* |
| Бер чүгә дә бер тора,<br>Лып итә дә утыра... | *чүгәлиләр, торалар, идәнгә утыралар* |
| Ничек итсә дә итә,<br>Энебез тәпи йөри, | *бер урында атлап торалар* |
| Үзенчә тәти йөри,<br>Егыла, тәки йөри. | *кулларын чәбәклиләр* |

*(А. Нигъмәтуллин )*

## Тавыклар

| | |
|---|---|
| Уяндылар тавыклар,<br>Канатларын кактылар. | *балалар чүгәләп утыралар,*<br>*әкрен генә торып басалар,*<br>*кулларын як-якка җәеп*<br>*селкиләр* |
| Савыттагы ярманы<br>Чүпли дә башладылар.<br>Тук-тук-тук! Тук-тук-тук! | *чүгәлиләр,*<br>*идәнгә бармаклары белән*<br>*бәргәлиләр* |
| Килеп чыкты машина:<br>— Би-би-биип!<br>Йөгерешәләр тавыклар<br>Тиз, тиз, тиз! | *торып, куллары белән*<br>*«рульне» боргалыйлар,*<br>*бер урында йөгерәләр* |

## Аю килә, лап-лап

| | |
|---|---|
| Аю килә, лап-лап,<br>Үләннәрне таптап. | *әкрен генә аю сымак атлап*<br>*баралар* |
| — Аю, алай итмә син,<br>Безнең белән уйна син. | *аюга бармак яныйлар,*<br>*аны уйнарга чакыралар* |
| Урыныңда тик торма,<br>Тыпыр-тыпыр тыпырда. | *урыннарында тыпырдыйлар* |
| Аю бик арыган икән,<br>Тәмләп йокыга киткән. | *чүгәләп, башларын тез*<br>*өстенә куялар, «йоклыйлар»* |
| — Аю, әйдә, тор инде,<br>Тагын бер уйныйк инде. | *басып,*<br>*кулларын чәбәклиләр* |

## Түгәрәктә

*Балалар урындыкларда утырып торалар.*

| | |
|---|---|
| Бергәләп басыйк әле,<br>Түгәрәк ясыйк әле. | *басалар, түгәрәк ясыйлар* |
| Менә нинди түгәрәк!<br>Бик кечкенә түгәрәк! | *уртага керәләр* |
| Кулны кулга тотышып,<br>Артка таба барабыз. | *артка чигенәләр* |
| Менә нинди түгәрәк!<br>Бик зур түгәрәк! | *зур түгәрәк ясап басып тора-<br>лар* |
| Түгәрәктә йөрибез,<br>Бик тырышып биибез. | *тыпырдый-тыпырдый,<br>уртага керәләр* |
| Менә шулай ял иттек,<br>Вакыт күңелле үтте. | *урыннарына утыралар* |

## Зурлар төркеме

### Курчагым

Менә минем курчагым, — *күзләрен күрсәтәләр*
Ике күзе бар аның.

Ә менә бу — борыны, — *барысын да шулай*
Бу, — билгеле, муены. — *күрсәтеп баралар*

Колакларын күрсәтим,
Чәчен сыйпап иркәлим.

Бигрәк матур битләре,
Авызында тешләре.

Ә менә болар — куллар, — *кулларын чәбәклиләр*
Чәбәк-чәбәк уйныйлар.

Кечкенә аяклары — *тыпырдыйлар*
Бик матур тыпырдыйлар.
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр!

### Бик арыдык

*Балалар түгәрәккә тезелеп басалар, тәрбияче — уртада. Ул шигырь юллары укыганда, балалар тиешле хәрәкәтләр ясыйлар.*

Бакчада саф һава суладык, — *тирән итеп сулыйлар,*
Бик арыдык! — *туктап, ял итәләр*
Шакмаклар, тартмалар, — *кирпеч өю хәрәкәтләре*
өйгәләп, — *ясыйлар*
Биналар ясадык, бергәләп.
Бик арыдык!

Ашадык тәмле аш, күмәчләп, — *«ашыйлар»,*
Чәй эчтек, шикәрләп һәм сөтләп, — *«эчәләр»,*
Бик арыдык! — *ял итәләр*

## Уң кул кайда?

— Уң кул кайда? — *уң кулны уң якка сузалар,*
— Ул монда. — *кулларны чәбәклиләр,*
— Сул кул кайда? — *сул кулны сул якка сузалар,*
— Ул монда. — *кулларны чәбәклиләр,*
— Куллар алда, — *алга сузалар,*
Куллар артта, — *артка,*
Куллар өстә — *өскә*
Һәм янда. — *төшерәләр*

## Аю бара...

Аю бара урманнан, — *бер-бер артлы баралар,*
Утын җыя учакка. — *иеләләр,*
Усак артында куян — — *торалар,*
Курка икән аюдан. — *як-якка карыйлар,*
— Куян, куян, курыкма, — *сикерәләр*
Аю тими ул сиңа.

## Кошлар ашату

Менә кошлар очып килде — *очу хәрәкәтләре ясыйлар*
Җимлеккә.
Әй, сөенде алар анда — *сикергәлиләр*
Җим күпкә.
Әй, чукыйлар алар җимне — *башлары белән чукыган*
Җимлектән. — *хәрәкәтләр ясыйлар*
Сөенешеп тыпырдыйлар — *тыпырдыйлар*
Җимлектә.

## Куллар

*Балалар, парлашып, бер-берләренә карап басалар.*

| | |
|---|---|
| Менә сиңа уң кулым, | *икесе дә үзләренең кулларын шапылдаталар, уң кулларын бер-берсенә сугалар,* |
| Менә сиңа сул кулым. | *кул чабалар, сул куллар сугыла* |
| Уң кулым, сул кулым, | *кул чабалар, уң кул, сул кул чиратлашып чабыла,* |
| Менә сиңа куш кулым. | *кул чабалар, ике кул да бер-берләренә сугыла* |

## Бармаклар

| | |
|---|---|
| Менә минем бармаклар, | *кулларын сузып, кул чукларын* |
| Шаян алар, шук алар. | *әйләндерәләр* |
| Бармаклар гел уйныйлар, | *бармакка бармак сугалар* |
| Уйный-уйный туймыйлар. | |
| Менә минем бармаклар: | *кулларын күрсәтеп, уң куллары* |
| Баш бармак, имән бармак, | *белән сул кулның бармакларын* |
| Урта, атсыз һәм чәнчә — | *берәм-берәм тотып чыгалар,* |
| Бик дус алар, гел бергә. | *кул чабалар* |

## Заводлар

| | |
|---|---|
| Эре-эре заводлар, | *аяк очларына басып,* |
| Заводта станоклар. | *куллар янга сузыла, кулларны төшерәләр* |

| | |
|---|---|
| Тиздән үсеп җитәрбез, | *аяк очларына басып,* |
| Шунда эшкә китәрбез. | *кулларны өскә күтәрәләр,* |
| | *бер урында атлыйлар* |

## Булышу

| | |
|---|---|
| Бергәләшеп тышка чыктык, | *баралар,* |
| Ике кулга пычкы тоттык. | *утын кисү хәрәкәтләре* |
| Утын кистек: | *ясыйлар* |
| Зиң-зиң, зиң-зиң. | |

| | |
|---|---|
| Кулыбызга балта алдык, | *утын яру хәрәкәтләре* |
| Утын ярдык: | *күрсәтәләр* |
| Дак-док, дак-док. | |

| | |
|---|---|
| Бераз арыдык, өйгә кайттык. | *урыннарына утыралар* |
| Уф-уф, уф-уф! | |

## Яңгыр

| | |
|---|---|
| Яңгыр, яңгыр юлларда | *баралар* |
| Аякларны чылата. | |
| Аякларны күтәреп | |
| Сикерәбез күл аша. | *сикергәләп баралар* |
| Чыланмасын аяклар, | *кию хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Киик әле итекләр. | |
| Яңгырдан без курыкмыйбыз, | *аякларын күрсәтәләр* |
| Аякта бит итек бар. | |

| | |
|---|---|
| Матур яңгыр явып үтте, | *кулларын өскә күтәрәләр* |
| Кояш җылы нур сипте. | |

## Без шулай ял итәбез

Без әле бераз арыдык, *басып торалар*
Ял итәргә уйладык.

Башны иябез алга, *хәрәкәтләр сүзләргә туры*
Ә аннары — артка. *китереп ясала*
Уңга, сулга борабыз,
Аннан карап торабыз.

Иң өсләрен сикертәбез,
Кулларны биетәбез.
Бер алга, бер артка сузып,
Күңелле ял итәбез.

## Утырып арыдык

Утырып инде арыдык,
Бераз ял итеп алыйк. *хәрәкәтләр сүзләргә туры*
Кулларны билгә куеп, *китереп ясала*
Башларны чайкап карыйк.
Куллар билгә, өскә, янга.
Утырып-торып алыйк.
Кушаяклап сикерик тә
Урыныбызга утырыйк.

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

### Шаян балалар

*Балалар иректе басалар. Сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.*

Бигрәк шаян инде без,
Тик тормыйбыз бер дә без:
Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Чүгәлибез, торабыз,
Башны уңга борабыз.

Аннан сулга карыйбыз
Һәм сикерә башлыйбыз.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез.
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.

### Бу дустың белән көреш

*Балалар, кулга-кул тотынып, түгәрәккә басалар.*

| | |
|---|---|
| Аякларың тыпырдат, | *аякларын тыпырдаталар,* |
| Кулларыңны чәбәклә, | *кул чәбәклиләр,* |
| Бер анда, бер монда, | *кулларын бер уңга, бер сулга* |
| Кыен эш түгел бер дә. | *чәбәклиләр* |
| | |
| Башың аска иеп ал, | *башларын аска иеп алалар,* |
| Кул бармагың янап ал, | *бармак яныйлар,* |
| Бер анда, бер монда, | *уңга, сулга бармак яныйлар,* |
| Кыен эш түгел бер дә. | *әйләнеп алалар* |
| | |
| Бу дустың белән көреш, | *уң яктагы дусты белән көрешәләр* |
| Бу дустың белән көреш, | *сулдагы дусты белән көрешәләр,* |
| Йә иптәш, йә, әйлән, | *әйләнәләр,* |
| Бик кыен түгел бу эш. | *баш ияләр* |

## Көчегем

Бар минем көчегем,
Шаяным, бөтерчегем.
Сикергәли ул, уйный, *хәрәкәтләр белән күрсәтәләр*
Койрыгын болгап туймый.
Йөзә белә ул суда.
Чупырдый ул йә чума.
«Бергәләп йөзик!» — диеп,
Минем артымнан куа!

## Аю килгән

Аю килгән урманнан, *баралар*
Ерак диеп тормаган.
Уйный балалар белән: *сикергәлиләр,*
Тәпиләрен күтәрә, *хәрәкәтләр белән күрсәтәләр*
Аннан кире төшерә,
Урында биеп ала,
Ә балалар кул чаба.

## Куяннар һәм бүре

Йом-йомшак куяннар *киереләләр*
Йокыдан уянганнар,
Нинди рәхәт аланда, *сикергәлиләр*
Шатланалар алар да.

Тик бүрене күрмиләр, *як-якка караналар*
Читтәнрәк йөрмиләр,
Бүре — бик явыз нәрсә, *кулларын, йодрыклап,*
Уйлап тормый һичнәрсә, *күкрәк турысында*
Аланга килеп җитә, *әйләндерәләр,*
Куянны алып китә. *йөгерәләр*

## Кышкы урманда

| | |
|---|---|
| Кышкы урманга килдек, | *бүлмә буйлап йөриләр,* |
| Матур урыннар күрдек: | *кулларын як-якка җәяләр,* |
| Тун кигән каен — уңда, | *уңга күрсәтәләр,* |
| Ямь-яшел чыршы — сулда, | *сулга күрсәтәләр,* |
| Кар бөртекләре оча, | *кул чукларын әйләндерәләр,* |
| Әйләнеп, җирне коча. | *әйләнәләр* |

## Һәркайсының үз эше

*Исеме әйтелгән һәр бармак бөкләнә бара.*

| | |
|---|---|
| Баш бармак бау ишә, | *бау ишү хәрәкәте,* |
| Имән бармак имән кисә, | *агач кисү хәрәкәте,* |
| Урта бармак ут кабыза, | *шырпы сызу хәрәкәте,* |
| Атсыз бармак ат җигә, | *атта йөрү хәрәкәте,* |
| Чәнти бармак чәй эчә. | *чәй эчү хәрәкәте* |

## Без рәсем ясадык

| | |
|---|---|
| Без рәсемнәр ясадык, | *йодрыктагы бармаклар* |
| Безнең бармаклар арыды. | *бер ачыла, бер ябыла,* |
| Без хәзер ял итәбез, | *кулларны аска төшереп,* |
| Аннан тагын ясыйбыз. | *бармакларын селкетәләр,* |
| | *рәсем ясау хәрәкәтләре* |
| | *ясыйлар* |

## Кар бөртекләре

| | |
|---|---|
| Йомшак карны алабыз, | *кар әвәләү хәрәкәтләре* |
| Аннан туплар ясыйбыз. | *ясыйлар* |
| Кар атышып уйныйбыз, | |
| Бик күңелле яшибез. | *«кар атышалар»* |

| | |
|---|---|
| Суыктан без курыкмыйбыз, | *кулларын як-якка җәеп* |
| Рәхәтләнеп уйныйбыз. | *йөриләр* |
| | |
| Кар бөртекләрен куып | *йөгерәләр* |
| Уйнаудан һич туймыйбыз. | |

## Тамчылар

| | |
|---|---|
| Кара каргалар килә, | *очу хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Түбәдән тамчы тама, | |
| Көндез көн җылы була, | *кулларны өстә болгыйлар,* |
| Суыта кичкә таба. | *чүгәлиләр* |
| | |
| Тамчылар бии тып та тып, | *бииләр,* |
| Тамчылар сикерәләр, | *сикерәләр,* |
| Аларны булмый туктатып, | *кул чабалар* |
| Алар яз китерәләр. | |

## Апрель

| | |
|---|---|
| Гөрләвекләр агалар, | *утырган килеш,* |
| Күктән кояш елмая. | *кулларын як-якка җәяләр* |
| | |
| Каңгылдашып, торналар | *очу хәрәкәтләре ясыйлар* |
| Тезелеп үтте бая. | |
| | |
| Инешләрдә коена | *чуму, йөзү хәрәкәтләре* |
| Канатланып үрдәк, каз. | *күрсәтәләр* |
| | |
| Җирне яшәртеп, безгә | *кул чабалар* |
| Гөлләр алып килә яз. | |

# II БҮЛЕК

# ҺӘРВАКЫТ БУЛСЫН КОЯШ

*(«Социаль-шәхси үсеш» юнәлеше)*

## «СОЦИАЛЬЛӘШТЕРҮ»
## БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Рәхмәт кемгә дә рәхәт.
* Кош — канаты белән, кеше дуслары белән көчле.
* Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма.
* Кешегә иң кирәге — ягымлы чырай, җылы сүз.
* Татлы тел аюны да биетә.
* Теле татлының дусты күп.
* Тыйнаклык кешене бизи.
* Бер ялганласаң, икенче дөрес сүзеңә дә ышанмаслар.
* Үзеңне үзең мактама, кеше сине мактасын.
* Өлкәннәргә хөрмәт — үзеңә дә хөрмәт.
* Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.
* Әти-әни — чын дустым, дус-ишләрем — юлдашым.
* Ата-анасына игелек күрсәтмәгән,
  олыгайгач, үзе дә игелек күрмәс.
* Әткәй — шикәр, әнкәй — бал.
* Бердәм өйдә бәрәкәт була.
* Яктылык — кояш янында, яхшылык — ана янында.
* Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.
* Туган илем — туган өем.
* Иленнән аерылган — канаты каерылган.

# ТАБЫШМАКЛАР

* Туган илнең нуры булып,
Зәңгәр күктә җилферди.
Яшел, кызыл, ак төсләре
Күз карашын иркәли.
*(Татарстан флагы)*

* Акчасыз керәсең,
Хәзинә алып чыгасың.
*(Мәктәп)*

* Күлләре бар — суы юк,
Чүлләре бар — комы юк.
Таулары бар — кар ятмый,
Аны белгән адашмый.
*(Карта)*

* Эче тулы балалар,
Парталар һәм такталар.
Бик тырышып белем бирә
Абыйлар һәм апалар.
*(Мәктәп)*

* Бабай бүреге йөз ямау.
*(Глобус)*

* Мине алып йөрсәгез,
Карурманга керсәгез,
Диңгезләрдә йөзсәгез,
Онытмагыз сез шуны:
Белмәссез адашуны.
*(Компас)*

## Әссәламегаләйкем!

Таң ата да, кояш чыга,
Кояшны сәламли көн.
— Саумы, кояш, сүнмәс учак!
Әссәламегаләйкем!

Тел ачкычы иман биргән
Сөекле туган телем!
Үзебезчә сиңа сәлам,
Әссәламегаләйкем!

Әй игенче, күкрәп үссен
Кырларда синең иген.
Икмәк тотып сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

Ачыйк бәхет ишекләрен,
Бәхетле булсын һәркем.
Әй кардәшләр,
миллəттәшләр,
Әссәламегаләйкем!

Таң ата да, кояш чыга,
Кояшлы бездә һәр көн.
Кояш белән сәлам юллыйм,
Әссәламегаләйкем!

*Госман Садә*

## Тылсымлы сүзләр

Иртән әни уята:
— Улым, хәерле иртә! —
Шул тылсымлы сүз мине
Көн буе саклап йөртә.

Әби мәктәпкә озата:
— Улым,— дип,— хәерле юл!
Әбием изге күңелле,
Гел хәерле була юл.

Бакчага килеп кергәч тә
Телимен: «Хәерле көн!»
Әллә шуңа әйбәт кенә
Хәерле уза бу көн.

Кичен әти каршы ала:
— Хәерле кич, улым, — дип.
Бергәләшеп уйнаганда,
Хәерле уза кич бик.

Гап-гади инде үзләре,
— Катлаулы түгел һични.
Әмма хәерле итәләр
Иртәне, көнне, кичне.

Мин шушындый сүзләр.
беләм
Син дә беләсең микән?
Хәерле юл! Хәерле көн! —
Тылсымлы сүзләр икән.

*Йолдыз*

## Якты сүз

Һәммәбезгә
Иң кадерле
Олы сүз ул.
Күңелләргә
Нур бөркүче
Җылы сүз ул.

Көлеп торган
Кояш кебек
Якты сүз ул.
Витамин күк
Шифалы һәм
Татлы сүз ул.

Әйтергә дә
Шулкадәрле
Рәхәт сүз ул!..
Сез ничектер?
Яратам мин
«Рәхмәт» сүзен.

*Хәкимҗан Халиков*

## Хәерле көн

Саумы, кояш! Саумы, елга!
Саумысыз, урманнарым!
Саумысыз, кошлар, чишмәләр,
Авылым урамнары.

Исәнмесез, таулар, кырлар,
Күлләрем, камышларым.
Саумысыз, җәнлек, бөҗәкләр,
Дусларым, танышларым.

Хәерле көн, туган ягым!
Яңа көнем, бул изге!
Алып кил җиргә бәрәкәт,
Куандыр әле безне.

Исән булыйк һәркайсыбыз,
Таң туды, сәламләшик.
Табигатьнең җаны бит без,
Бербөтен булып яшик.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Әйдә, танышабыз

Йә, әйдә, танышабыз,
Кулга-кул бирешәбез,
Исемне әйтешәбез,
Кул кысып күрешәбез.

Киң итеп елмай миңа,
Мин дә елмаям сиңа.
Туры итеп караштык,
Менә шулай таныштык.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Үсәсем килә минем

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү —
Бик озак шул көтәсе.
Минем дә бит сезнең кебек
Килә тизрәк үсәсе.

Эх, тизрәк үссәмче,
Дәү кыз булып җитсәмче.
Ничек тизрәк үсәсе,
Дәү кыз булып җитәсе?..

Табак-савыт юар идем,
Урындыкка басмыйча.
Кибеткә дә йөрер идем,
Юл аша курыкмыйча.

Уенчык, курчакларымны
Калдырып торыр идем.
Китап-дәфтәрләрне алып,
Мәктәпкә барыр идем.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү —
Бик озак шул көтәсе.
Берәр серен әйтегезче,
Килә тизрәк үсәсе.

*Лиана Әмирханова*

## Үсәсем бар

Минем әни шундый әйбәт —
Мактап кына тора ул:
«Улым бигрәк уңган!» — диеп,
Миңа канат куя ул.

Әни мине мактаганда,
Очып китәрдәй булам.
Бер талпынсам, йолдызга да
Менеп җитәрдәй булам!

«Эшчән кеше тиз үсә», — ди,
Белми әйтмәс әнием!
Үсәсем бар — мин бит әле
Төпчек улы әнинең.

Кушканны да көтми эшлим —
Бик үсәсем килә ич!
Көн дә үсәм, әниемә
Зур-зур егет кирәк ич!

*Фирая Зыятдинова*

## Кечкенә

— Әни, нигә безнең Гөлназ
Шулкадәрле кечкенә?
Минем егерме тешем бар,
Ә аныкы өч кенә.

Ә нигә соң аягында
Басып тора ул көчкә?
— Үсәр, улым! Синең кебек
Җитсен әле ул өчкә.

Бөтен бәбиләр дә шулай
Кечкенә була башта.
Син дә бик кечкенә идең,
Без алып кайткан чакта.

— Мин аны күтәреп йөрим!
Үсмәсен, шулай торсын!
Әни! Син кечкенә чакта
Кечкенә идеңме соң?!

*Шәмсия Җиһангирова*

## Үстем

Мин хәзер бәләкәй түгел,
Мин олы булып үстем.
Бакчабызда да олылар
Группасына күчтем.

Кичә әле самавырдан
Үзем чәй ясап эчтем.
Әбиләрдә кер юышып,
Бөтенләй тирләп пештем.

Әнием белән бүген мин
Инешкә суга төштем.
Мин хәзер бәләкәй түгел,
Мин инде бик зур үстем!

*Дамир Гарифуллин*

## Иртә

Бер ягымда — кызыл Кояш,
Бер ягымда — ап-ак Ай.
Мине озата баралар,
Адашмасын дип бугай.

Бер кулымнан әни тоткан,
Бер кулымнан — әтием.
Шыпырт кына уйлап барам,
Үзләренә әйтмимен.

Әни минем Кояш инде,
Әти Ай дип ышанам.
Уң якта — Ай,
Сулда — Кояш,
Ә мин кемгә охшаган?

*Илсөяр Иксанова*

## Әни дә мин, бала да мин

Әнием өчен
Мин газиз бала.
Курчаклар өчен
Мин үзем ана.

Курчакларымны
Сөям, уйнатам.
Кич җитү белән,
Кочып йоклатам.

*Әзһәр Габиди*

## Бу — мин!

Менә борыным,
Бу — минем кашым.
Күзем, колагым,
Ә менә башым.

Авызым ачсам,
Телем күренә.
Тезелгән тешем
Биш бөртек кенә.

Кулым күтәрәм,
Аяк тыпырдый.
Үзеннән-үзе
Биергә сорый.

*Вәсимә Ураксина*

## Туган

Мин әниемнән туган,
Әни әбидән туган.
Шулай булгач, бу өйдә
Без барыбыз бертуган.

Бу өй — минем туган йорт,
Шушы нигездә үсәм.
Туган як чишмәсенең
Челтер суларын эчәм.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Минем гаиләм

Аш кашыгы — агачтан,
Чәй кашыгы — көмештән.
Җиз самавыр кайнап тора —
Суы — изге инештән.
Әбием һәм әнием
Безгә бәлеш пешергән.

Бәлеш уңган, күрәсең,
Өйгә тәмле ис тулган.
Әби-бабай, әти-әни,
Мин, нәни кыз, Наилә.
Менә нинди сокландыргыч
Безнең матур гаилә!

*Зәкия Туфайлова*

## Әтием белән бергә

Әтием белән икәү
Без гел бергә йөрибез,
Бергә утын кисәбез,
Бергә карлар көрибез.

Язлар җиткәч, балыкка
Таң аткач ук барабыз,
Тота алсак, әнигә дип
Сатып кына алабыз.

Әгәр барсак урманга,
Бергә җырлап алабыз,
Яшеренгән гөмбәне
Икәү эзләп табабыз.

Бергә ишкәк ишәбез
Бергә кәрзин үрәбез.
Бик күңелле яшибез
Менә шуңа күрә без.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Хәзер инде өчәү без

Энем дә бар, сеңлем дә,
Хәзер инде өчәү без.
Шау-гөр килеп үсәбез,
Сокланырсыз, күрсәгез.

Әти-әни юк чакта,
Өйгә хуҗа өчебез.
Җиткән кадәр көчебез
Бөтен эшне эшлибез.

Энем белән сеңлемә
Торасы юк әйтеп тә:
Курчакларын үзләре
Өйрәтәләр тәртипкә.

*Хәкимҗан Халиков*

## Олы кунаклар

Безгә бүген кем килә?
Саескан күптән белә.
Өйдә пешә пәрәмәч,
Бәлеш исләре килә.

Өстәлебез дә әзер,
Мунча куйган ягылып.
Килә олы кунаклар,
Көтәм күптән, сагынып.

Килә ике әбием,
Килә ике бабам.
Мин аларны яратам,
Һәрвакыт көтеп алам.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Энем бар

Шатлыгым бар — өем бар,
Әтием-әнием бар.
Минем гармуным да бар,
Гармун кадәр энем бар.
Энем мине ярата,
Мине күрсә — гел көлә.
Еласамы?
Еласа ул —
Сызып кына җибәрә
Гармун тавышы белән.

*Рөстәм Мингалим*

## Энемә

Әйдә, энем, елмай әле,
Инде ела әзрәк.
Ни әйтсәң дә, бүген син
Кичәгедән дәүрәк.

Ә инде дәү кешегә
Елап тору килешми.
Синдәй егет кешегә
Елап тору ул эшме?!

Әйдә, үс, үс тизрәк —
Миңа әйбәт дус кирәк.
*Йолдыз*

## Мин бит татар егете

Һаваның да ае бар,
Мәчетнең дә бар ае,
Үземнең дә аем бар.
Айнур минем исемем —
Мин бит татар малае.

Кул юабыз, сөендереп
Баскычтагы комганны.
Чәй эчәргә керәбез,
«Бисмилла»сыз ашамыйм —
Мин бит татар малае.

Хәлсезләнгән песине
Һәм хуҗасыз маэмайны
Ишегалдына дәшеп,
«Бисмилла» әйтеп сыйлыйм —
Мин бит татар малае.

Шәмаил тора түрдә,
Шәмаилнең бар ае.
Әни килә, елмаеп,
Үбеп алам мин аны —
Мин бит татар малае.

Ялкауларны гел сөймим,
Әти түбә япканда
Тотып торам калайны,
Әти кадак какканда
Биреп торам кадакны —
Мин бит татар малае.

Догалар да beләм мин,
Түбәтәй дә киям мин,
Очратсагыз урамда
Әгәр минем кебекне,
Белеп торыгыз, яме —
Ул бит татар егете!
*Рәшит Бәшәр*

## Дәү әнием

Әниемнең әнисе
Әбием була минем,
Әби генә түгел әле
Ул — минем дәү әнием.

Мин бакчага киткәндә
Озатып кала мине,
Кайтканда каршы ала,
Бигрәк тә әйбәт инде!

*Әминә Бикчәнтәева*

## Зиратка бардык

Дәү әтием зиратка
Алып бара мине дә.
— Менә, улым, һәркемнең
Төп йорты, — ди, — бирелә.

Каберләрне чистартып,
Ромашкалар утырттык.
Сулар сибеп шунда ук,
Эшебезне тиз тоттык.

Бусы — әниемнеке,
Әтинеке — монысы.
Чиста тоту аларны —
Исәннәрнең бурычы.

Кошлар безгә аннары
Концерт куеп алдылар.
Ә ташландык каберләр
Гүя елап калдылар.

*Хәкимҗан Халиков*

## Гөлсия

Гөлсиянең курчагы бар:
Кечкенә бала төсле.
Көн дә иртән киендерә,
Бик матур итеп өстен.

Гөлсия ул — акыллы кыз,
Һич борчымас әнисен,
Елый башласа юата
Бишектәге энесен.

Әтисе дә бик ярата,
Әнисе дә бик сөя.
Битен юа, чиста йөри
Акыллы кыз Гөлсия.

*Нур Гайсин*

## Йоклар алдыннан

Бабай белән Әхтәм кебек
Бар микән дуслар тагын?..
Уенда да алар бергә,
Өстәлдә — зур бер табын.

Бер кичне бабай сөйләнә:
«Бетердемме эшемне?
Оныттым әле, — дигән ул, —
Чистарттыммы тешемне?»

— Юк, бабаем, оныткансың! —
Әйтеп салган ул туры.
— Каян белдең, улым, әйтче?
— Теш щёткаң синең коры!

*Ринат Мәннан*

## Үпкәләп булмый әбигә

Әби миңа дәшә беркөн:
— Рамил, Гамил, Данил, ди.
И-и-и, саташып ялгыш әйттем,
Наил, Камил, Рамил... ни...

Ә ул көлә: — «Әбиегез
Менә шундый инде, — ди.
Азат улым, картайдым шул,
Гаепләмә мине», — ди.

— Әби, — димен мин, елмаеп, —
Тагын дөрес булмады.
Алар бит олы һәм кече
Кызларыңның уллары.

Үпкәләп булмый әбигә,
Бик дөрес әйткән сүзе.
Без бит аның оныклары —
Унау, ә ул — берүзе.

*Нәҗип Мадьяров*

## Иңнәремдә — фәрештә

— Иңнәреңдә — фәрештәләр, —
Ди миңа ак әбием.
— Оҗмах кошым, — дип сөяләр
Әтием һәм әнием.

Үзе тарих, тере тарих —
Безнең әби-бабабыз.
Зурласак кына аларны,
Олы булып калабыз.

*Эльмира Шәрифуллина*

## Рамазан аенда

Кояш баер вакыт җитсә
Йөгерәбез тыз да быз.
Тизрәк авыз ачсын диеп,
Әбигә эзлибез тоз.

Әби рамазан аенда
Көн буе ризык капмый.
Ничек ачтан үлмидер ул?
Шуңарга җавап тапмыйм.

Чәйне бик тә яратса да
Түзә, эчмичә тора,
Ашамый-эчми, гел укый
Авыз эченнән дога.

Шуңа кояш баеганны
Без бергәләп көтәбез.
Әби ничектер, ә без
Көтеп арып бетәбез.

Тозны алып бирү белән,
Әби аркадан сөя.
— Рәхмәтләр яусын, савабы
Сезгә дә булсын, — дия.

Әбием авыз ачканда,
Җанда рәхәт тоябыз.
Әби белән бергәләшеп,
Без дә савап җыябыз.

*Йолдыз*

## Булышабыз

Минем тешем чыга гына,
Бабамныкы — коела.
Коелган теш урынына
Яңалары куела.

Минем чәчем каралганда,
Бабамныкы — агара.
Ап-ак чәчләр бигрәк матур,
Килешеп тора аңарга.

Бабам машина да йөртми,
Матайга да утырмый.
Ишегалдында, бакчада
Бер минут та тик тормый.

Мин аңа булышып йөрим,
Ул булыша әбигә.
Әбием дә шундый уңган:
Ярдәм итә әнигә.

*Мөҗәһит*

## Курчаклар

Бар бик күп курчаклар.
Аларны без саклап,
Кадерләп йөртәбез,
Битләрен сөртәбез,

Буялсалар-нитсәләр,
Мунчага кертәбез.
Бәрмибез, атмыйбыз,
Ватмыйбыз — саклыйбыз...

*Бари Рәхмәт*

## Минем эш

Әни белән бик рәхәт тә,
Бакчага барасы бар.
Ул киткәндә, тәрәзәдән
Кул болгап каласы бар.

Мин дә иртән эшкә китәм —
Бакчада минем эшем.
Барам, кичен әниемне
Сагынып кайтыр өчен.

*Йолдыз*

## Сөйләшсәләр безнеңчә...

Җирдә нинди илләр юк,
Нинди генә телләр юк...
Һәркем сөйли үзенчә,
Сөйләшсәләр безнеңчә
Эреп китәм, май кебек,
Йөзем тулган ай кебек
Яктырганнан-яктыра.
Күңелдә таң аттыра
Балдан да татлы телем,
Нәфис һәм затлы телем.

*Хәкимҗан Халиков*

## Ул бакчаны ярата

Көн саен Ләйлә
Бакчага килә.
Соң гына кайта
Кич белән өйгә.

Төрле уенчыклар,
Курчаклар монда.
Кайтасы килми
Ләйләнең шуңа.

Ярата Ләйлә
Көн үткәрергә
Иптәшләр белән
Бакчада бергә.

— Әнием, — ди ул, —
Ашыгып йөрмә.
Мине алырга
Бик иртә килмә.

*Гасыйм Лотфи*

## Кунакка килегез!

Кунакларны бик яраткан
Электән безнең халык.
Юмарт, диеп, уңган, диеп,
Килгән, күптән мактальп.

Татар кызы — Таңсылу мин,
Уңган буласым килә.
Чәем кайнар, чәкчәк әзер,
Йә, кем кунакка килә?!

*Йолдыз*

## Татарстан җирләре

Самолётта очып барам,
Якынлашкандай айга.
Тәрәзәдән җиргә карыйм:
Әй кызык икән анда!

Кама заводлары артта,
Идел дәрьясы уңда.
Әнә Зәйдә су керәләр,
Мин һаман юлда, юлда.

Әнә Бөгелмәм, Казаным —
Күренә минем Ватаным!
Факеллар нурланып яна,
Күрәм нефть фонтанын.

Тагын нефть вышкалары
Әлмәттә, Азнакайда.
Кырларда иген өлгергән —
Шатлык кына һәркайда!

*Әдхәт Синегулов*

## Мин яратам сине, Татарстан

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам.
Күк күкерәп, яшен яшьнәп
яуган
Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,
Горур халкың өчен яратам.
Җан эретә торган
әнкәм теле —
Татар телең өчен яратам.

Арыш кырың, урманнарың өчен,
Тугайларың өчен яратам.
Тукайларың, Сәйдәшләрең өчен,
Җәлилләрең өчен яратам.

*Роберт Рәкыйпов*

## Казанда гына калам

Чакырып хат язганга
Барган идем Казанга,
Инде хәзер нишлисе,
Килми кайтып китәсе.

Кердем бакчаларына,
Йөрдем урамнарында.
Басып тордым, шаккатып,
Казансу ярларында.

Төнге Казан искиткеч,
Әкияткә биргесез.
Күрсәгез, ул фикергә
Үзегез дә килерсез.

Казан бит гомер буе
Дан-шөһрәт казанган.
Сихерләде мине дә:
Юк, киталмам Казаннан.

Казан, Казан — башкалам,
Мин синдә генә калам.

*Мөҗәһит*

## Сәлам, Галәм!

— Алло, алло, Марсмы бу?
Хәбәр бирәм мин Җирдән.
Бу мин — Айнур атлы малай,
Татарстан дигән илдән.
Бездә инде көзләр җитте,
Ә сездә анда ничек?
Салкын җилләр исәләрме,
Яңгыр явамы ишеп?

Марс малайларының да
Борыннары кызылмы?
Ә буйлары минем күкме?
Йә азрак озынмы?
Бик күрәсем килә сезне,
Төшегез әле, әйдә!
Ара ерак булса да
Яшибез бер Галәмдә.

*Йолдыз*

## Дусларың гына булсын

Егылсаң торып була,
Торсаң йөгереп була,
Йөгерсәң җитеп була —
Дусларың гына булсын!

Сөйләшеп, уйнап була,
Күп нәрсә белеп була,
Шаярып-көлеп була —
Дусларың гына булсын!

*Рөстәм Мингалим*

## Хат

Үзбәк дустым хат җибәргән,
Җавап язам аңа хәзер.
Әйтеләчәк сүзләрем дә,
Серләрем дә күптән әзер.

Дустым кунакка чакырган,
Бездә өрек пеште, дигән.
Ул да әле хәреф белми —
Сөйләшәбез сурәт белән.

*Гөлфия Юнысова*

## Дуслык җыры

Кайларда яшәсә, торса да,
Бер уйда, теләктә балалар.
Бәхеткә юл ярып, дусларча,
Салават күпере салалар.

Сабыйлар күңелендә һәрвакыт
Очрашу, бәйрәмнәр еш булсын.
Һәр илдә, һәр җирдә балалар
Бәхеттән, шатлыктан елмайсын.

Әйдәгез, бергәләп,
Куллардан тотышыйк.
Җир шары — уртак йорт,
Шул йортта дус яшик.

Бу җирдә һәркемнең
Бәхеткә хакы бар.
Ятимлек күрмәсен
Дөньяда балалар.

*Лиана Әмирханова*

## Булатларга кунакка!

Булат яши Әстерханда,
Алмаз яши Казанда.
Булатка ай-яй әйбәттер —
Күптән инде яз анда...

Хатлар килә ерактан —
Алмазга ул, Булаттан:

«Сездә һаман кыш әле,
Җимешләр әздер анда.
Кавын, карбыз, йөземнең
Оясы — Әстерханда!

Бездә Идел киң, — дигән, —
Кунак булып кил! — дигән. —
Сиңа бик уңай, — дигән. —

Әгәр дә булса көймәң,
Булмый хәтта ишәсең:
Иделдән агып кына,
Җырлап кына төшәсең!»

Алмаз шушы хаттан соң
Көн саен хәзер әнә
Кунакка әзерләнә.
«Язны гына көтәм, — ди, —

Әстерханга китәм, — ди, —
Казанда яз җитүгә,

Иделдән боз китүгә,
Мин бит үсеп җитәм,— ди, —
Бәләкәй малай булып
Бик күп йөрдем, җитәр! — ди...»

Язлар җитте, җәй булды —
Алмазга да җай булды!
Теплоходта бара ул:

Бүләкләре — Булатка!
Үзе белән әтисен дә,
Үзе белән әнисен дә
Ияркән ул кунакка!

*Роберт Миңнуллин*

***

## Хикмәтле чиләк

Фоат Африкада яшәүче Боаб исемле малай белән хат алыша. Хат саен аны кунакка чакыра: «Бездә хәзер кыш. Кар күреп китәрсең, чанада шуарбыз», — ди.

Боаб озак уйлый торганнардан түгел. Дустына күчтәнәчкә дип, уенчык чиләгенә Нил елгасының суын алды да аэропланга утырып, төньякка карап очты. Аэропланның ап-ак кырга килеп төшүе булды, Боаб җиргә сикерде. Ялан аягы тездән карга батты. Боабның кар күргәне юк иде. Шуңа күрә аны туңдырма дип уйлады. Монда бөтен җирне ап-ак туңдырма каплаган икән бит.

Туңдырманы алып кабыйм дигәндә генә, шатлыгыннан авызын ерып, Фоат килеп җитте. Үзе белән алып килгән колакчынлы бүрекне, киез итекне, кайры тунны, йон бияләйне дустына кигертте. Боаб исә Фоатка уенчык чиләкне сузды.

— Күчтәнәчкә Нил суы алып килдем сиңа. — Чиләкне ачып карасалар, су юк, чиләк төбендә түгәрәк көзге генә җемелди.

— Нәрсә бу?

— Боз бу, Боаб. Кыш көне су боз булып ката. Нил суы да боз булган.

Дуслар, туйганчы, кар атышып уйнадылар, чанада шудылар, кар тәгәрәтеп, Кар бабай ясадылар. Кар бабайның күзләре урынына Нил бозын ватып куйдылар.

Уйнап арыгач, Боаб кайтырга булды. Истәлеккә дип, чиләккә кар тутырып алды да аэропланга менеп утырды.

— Иртәгә безгә кунакка кил, Фоат. Җирафка атланып йөрербез, — дип, кул изәде ул.

Боабны әти-әнисе сагынып өлгергән иде инде. Саваннага төшеп, кызулыгын киметкән аэроплан артыннан йөгерделәр. Колакчынлы бүрек, киез итек кигән улларын танымый тордылар башта. Малайлары тешләрен җемелдәтеп елмайгач кына, «Боаб!» дип сөенешеп күтәреп үк алдылар.

Боаб әтисенә уенчык чиләген сузды.

— Сюрприз алып кайттым сезгә!

Әти кеше чиләк капкачын ачты.

— Тамак кибеп тора иде, әйбәт булды әле бу, рәхмәт сиңа, улым, — диде.

— Карны ашарга ярамый, — диде Боаб. — Тамакка салкын тия икән.

— Шушы буламыни инде ул кар?! — дип гаҗәпләнде әти-әнисе, чиләк төбендәге суга карап.

— Әйе, шушы була!

— Аның белән нишлиләр соң?

— Чанада шуалар, Кар бабай ясыйлар. Менә хәзер, йомарлап, кар атышып уйныйбыз. — Боаб чиләккә тыгылды. Кулын алган иде — бияләеннән, тып-тып, су тама. Малай, аптырап, чиләккә карады. Карның бөртеге дә юк иде анда.

— Кызы-ы-ык, — дип гаҗәпләнде Боаб. — Су алып бардым — боз булды, кар алып кайттым — су булды...

Әти кеше чиләкне күтәреп йотлыгып эчеп куйды.

— Бигрәк тә тәмле икән кар дигәннәре. Фоатка әйт әле, кунакка килгәндә, карны күбрәк алып килсен. Әниеңә дә җитәрлек итеп...

*Нәкыйп Каштан*

## Кечкенә Миләш

Кечкенә Миләш үзен ялгыз тойды. «Минем яныма беркем дә килми», — дип уйлады ул. Күңеле йомшарып, хәтта елап ук җибәрде.

Сары Күбәләк аның елавын ишетте дә:

— Ник елыйсың, Миләш? — дип сорады.

Миләш аңа:

— Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми... — диде, үкси-үкси.

— И елак, син бит әле кечкенә, синең чәчәгең дә юк, — диде гамьсез Күбәләк һәм очып та китте.

Күбәләкнең сүзенә Миләшнең хәтере калды. Ул тагын да ныграк үкси башлады.

Шулчакны кайдандыр Сыерчык килеп чыкты.

— Ник елыйсың, Миләш? — дип сорады ул да, ягымлы тавыш белән.

— Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми, — диде Миләш.

— Син кечкенә бит әле, сине борчырга ярамый, — диде Сыерчык, аны юатып. Синең әле ботакларың да аз, кошлар кунар урының юк. Зур үскәч, сиңа күбәләкләр дә, кошлар да килер. Син безне кызыл җимешләрең белән сыйларсың. Елама, шат күңелле бул. Озакламый син дә зур үсәрсең!

Миләшнең күңеле күтәрелде. Елаудан туктап, ул елмаеп җибәрде.

*Гыйльмия Таһирова*

## Ярдәм

Бер әби урам буйлап килә. Атлый да туктый, атлый да туктый. Туктый да, ярдәм итәр кеше юк микән дигәндәй, як-ягына карана: кулындагы төенчеге бик авыр бугай... Аруы йөзенә чыккан. Үч иткәндәй, урам буп-буш. Бер малай гына туп куып йөри.

Менә малай әбине күреп туктап калды. Әбинең көч-хәл белән төенчек күтәреп барганын шәйләп алды. Уенны ташлап, әби каршына йөгерде.

— Булышыйммы, әби? — дип, рөхсәт иткәнче үк, төенчеккә ябышты.

Карчык бераз тын алыр өчен туктады, мөлаем елмайды.

— Исемең ничек синең, бәбкәм?

— Сөләйман...

— Матур исем. Пәйгамбәрләр исеме. Ә мин Галия әби булам.

— Галия әби, әйдә, булышам, — дип кабатлады Сөләйман.

— И Алланың рәхмәте төшкере. Бигрәк итагатьле бала икәнсең. Икебез күтәргәч, төенчек тә җиңел тоелыр, миңа да күңелле булыр.

Сөләйман елмайды, төенчекне катырак итеп тотты.

Менә алар икәүләп, төенчек күтәреп, урам буйлап киләләр. Күптәнге танышлар кебек сөйләшәләр, көлешәләр. Әби кызык нәрсә сөйли, ахры. Адымнары җиңел — кулларында авыр төенчек димәссең.

Сөйләшә-сөйләшә, тугыз катлы йорт каршына килеп җитүләрен сизми дә калдылар. Әбисенең тавышын ишетеп, подъезддан оныгы атылып чыкты һәм бар тавышка:

— Әбекәй, тәмле әйбер бир! — дип кычкырды.

Үз яшендәге ят малайны күреп туктап калды. Ник ярдәм итә ул әбигә?

Мөгаен, тәмле әйбер алыр өчен күтәрешкән булгандыр. Әбисе юмарт бит аның: кибеткә барып килгәнче оныгын карап торган өчен дә, күршесенә акча бирә. Авызын чалшайтып, усал итеп, ят малайга эндәште:

— «Киндер сюрприз» кирәк булдымыни? Әбием синнән башка да күтәрер иде әле.

Карчык белән Сөләйманның кәефе китте. Көтелмәгән бу сүздән аптырап калдылар. Оныкның сүзе камчы белән ягргандай тәэсир итте. Үпкәләде Сөләйман. Ачуы чыгып, йодрыкларын каты итеп йомарлады. Ләкин әбигә хөрмәт йөзеннән тавыш күтәрмәде, тыныч кына:

— Синнән сорамадылар... — дип әйтеп куйды.

Оныгы өчен оят булып китте карчыкка, йөрәге сызлап куйды:

— Яхшы малай ул — Сөләйман. — Ярдәмчесен иркәләп, башыннан сыйпады. — Зур рәхмәт сиңа. — Аннары оныгына таба борылып, әйтеп куйды: — Менә кем белән дуслашырга кирәк!

Малай сандалие белән җирне чокый башлады, борынын мышкылдатты. Кешеләргә рәхмәт өчен генә дә ярдәм итәргә мөмкин икәнен аңлады микән ул?

Ул арада Сөләйман, тубын куа-куа, кайту ягына элдертте.

Дорфа малай исенә килде, булышырга теләп, әбисе кулындагы төенчеккә ябышты...

*Нәкыйп Каштан*

## Гап-гади Инсаф

Җир йөзендәге барлык малайларның да исемнәре була. Җирән чәчлеме ул, кара чәчлеме, чебен тимәс чер итәрме, каты йодрыклы сугыш чукмарымы — барыбер. Сиңа исемең, туганчы ук, әллә кайчан табылган. Табылган гына да түгел — тагылып ук куелган була.

Мине тотканнар да Инсаф дип йөртә башлаганнар. Миңа барыбер. Хет әллә кем дип атаган булсыннар иде. Исемнәр күп бит. Дөнья тулы малайлар, дөнья тулы исем. Шулай булса да берсе дә ялгышмый, буталышып бетми. Хәбир дисәң, Хәбире «ә» ди, Җәмиле тик тора. Җәмил дисәң, анысы «җә» ди, Хәбире тик тора. Бу әти-әниләр шулкадәр исемне кайдан гына уйлап бетерәләрдер — аптырарсың.

Башка малайлар беләләр микән, юк микән, мин үземә нишләп Инсаф диюләрен әллә кайчаннан бирле беләм. Бер елны, мин салкын тидереп авырып ятканда, авылыннан әби килгән иде. Ул шунда миңа, көчли-көчли, әрли-әрли, кипкән җиләк кайнатып эчерде. Инсафның ни икәнен дә ул әйтте. Әбисенең сүзен тыңлап, әче җиләк суын күбрәк, әмма тәрәзә бозын яламый торган әдәпле малайларны Инсаф дип йөртәләр икән.

*Газиз Мөхәммәтшин*

## Бүләк

Илдар быел Әниләр бәйрәмендә әнисенә башка беркем дә уйлап таба алмаган әйбер бүләк итәргә булды. Ул инде белә: Хәлим абыйсы, әнисенә дип, матур сәгать алып куйды. Нәсимә апасы әллә нинди тәмле исләр аңкытып торучы хушбуй алып кайтып яшерде. Илдар аның тәмледән-тәмле исләрен каян беләме?

Апасы өйдә юк чакта, ике мәртәбә алып иснәп карады инде ул бу бүләк-хушбуйны.

Беркөнне тәрәзәдән тышка карап утырганда, Илдарның башына шундый уй килде: әгәр дә ул, кардан әнисенең сынын ясап, 8 Март көнне шуны алып кереп бүләк итсә? Әй шаккатыр, әй сөенер иде әнисе!

Илдар шулай итте дә. Әниләр бәйрәменә бер көн кала, ул кич буе ындыр артында кар тәгәрәтте, өч йомарлам кар кисәгеннән бер кеше сыны әмәлләп тә куйды. Бу сын әнисенә бик тә охшаган кебек тоелды.

Шул ук кичтә Илдар үзенең бүләген качырып кына алып кереп, бүлмәсенең бер почмагына бастырып куйды. Җәймә белән капларга да онытмады.

Иртән барысы да гадәттәгедән иртәрәк уянды. Ел саен шулай: иртәнге ашка кадәр үк Илдар әтисе, абыйсы һәм апасының котлау сүзләрен, бүләк бирүләрен түземсезлек белән көтте. Чират җиткәч, Илдар әнисе янына килде дә: «Хәзер мин үз бүләгемне күрсәтәм», — дип, түрдәге бүлмәсенә йөгерде. Әмма, бүлмә ишегеннән атлап керүгә, ниндидер юешкә басуын тоеп алды Илдар.

Идәнгә күз салса аһ итте: аның «кар әнисе» җылы өйдә бөтенләй эреп беткән, ә кар суы бөтен бүлмә буенча җәелеп киткән!

Илдар нишләргә дә белмичә каушап калды. Әнисенә нинди бүләк бирә инде ул хәзер? Җитмәсә, бүлмә идәненә җәелгән кар суына әнисенең бик тә кәефе китәчәк... Менә сиңа бәйрәм!..

Илдар су эчендә яткан җәймәгә барып ябышуын сизми дә калды. Әнисе күреп орышканчы, тизрәк сөртеп алырга кирәк. Югыйсә бөтенләй оятка калачак ул. Аннары ел буе үзеннән көлеп йөрерләр иде бугай... Әле ярый түр почмактагы зур агач савытта гөл үсеп утыра. Илдар җәймәгә җыеп алган бөтен суны шул гөл төбенә агыза торды. Инде идәнне сөртеп бетерәм дигәндә генә, зал яктан әнисенең: «Илдар, балам, бүләгеңне карарга чыгыйкмы инде?» — дигән мөлаем тавышы ишетелде.

Илдар соңгы мәртәбә идәнне сыпырып алды да, гөл төбенә соңгы тамчы суны агызып, чүпрәкне карават астына яшереп куйды. Шулвакыт аның янына әнисе, әтисе, абыйсы, апасы килеп керде. Килеп керүгә, юеш идән уртасында мыштым гына басып торган Илдарга карап телсез калдылар...

Тынлыкны әнисе бозды:

— И-и-и улым, менә нинди зур бүләк әзерләгәнсең икән син миңа! Идәнне ялт иттереп юып куйгансың лабаса! Миңа бер эш тә калдырмагансың. Рәхмәт, улым, мең рәхмәт сиңа!.. Кил әле, шуның өчен бер сөйим үзеңне!

Шулвакыт еларга җитешеп басып торган Илдарның күзләрендә ниндидер тылсымлы нур балкышы чагылып китте. Һәм ул, дөньядагы иң бәхетле бер малай булып, әнисенең кочагына атылды...

*Галимҗан Гыйльманов*

«ХЕЗМӘТ»

БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Хезмәт төбе — хәзинә.
* Эше барның ашы бар.
* Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.
* Бакча ясамый, алма булмый.
* Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.
* Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.
* Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
* Биш әйткәнче, бер эшлә.
* Сүзең белән мактанма — эшең белән мактан.
* Башлый белсәң — бетерә бел, эшеңне җиренә җиткерә бел.
* Бетми калган эш — пешми калган җимеш.
* Бүгенге эшне иртәгә калдырган кешенең һич эше бетмәс.
* Ялкаулык — хурлык, тырышлык — зурлык.
* Эш беткәч уйнарга ярый.
* Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
* Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.

***

# ТАБЫШМАКЛАР

* Чүп-чар, тузан йота ул,
Өйне чиста тота ул.
*(Тузан суырткыч)*

* Ары йөгерде — сыйпады,
Бире йөгерде — сыйпады.
Ары килеп, бире килеп,
Бер почмакка утырды.
*(Себерке)*

* Табаным утлы булса да,
Тукымадан йөрим мин.
Җыерык кына йөзләрне дә
Матурлап тигезлим мин.
*(Үтүк)*

* Ат түгел, кешнәми,
Йөз аттан ким эшләми.
Үзе тыр да тыр.
Йә, бу нәрсә, кем әйтер?
*(Трактор)*

* Ду-ду итеп үкерә,
Басу иңләп йөгерә.
Бөтен кырда игенне
Урып, сугып бетерә.
*(Комбайн)*

* Армый, талмый,
Ат артыннан калмый.
*(Арба, чана)*

* Ике божра, ике аяк,
Уртасында — бер таяк.
*(Кайчы)*

* Озайган саен юлы —
Кыскарадыр койрыгы.
*(Энә, җеп)*

* Бурычым бик кечкенә,
Кечкенә дә төш кенә.
Нечкә баудан төшмим мин,
Чиста керләр тешлим мин.
*(Кер каптыргычы)*

* Колагыннан борган чакта
Чукый бер үк ояны.
Кешеләрне сөендерә,
Тими аның зыяны.
*(Тегү машинасы)*

* Ул үзе шундый көчле,
Тешле-тешле чүмечле.
Берүзе эшли ала
Йөз кешелек эшне.
*(Экскаватор)*

* Кызу табанлы чана,
Ат җигелгән аңа.
Бер чигенә, бер бара,
Юлы шомарып кала.
*(Үтүк)*

* Тимер ат җир сөрә,
Ашарга сорамый.
*(Трактор)*

* Тик бер генә һөнәр беләм:
Кыям, турыйм, юнам, теләм.
*(Балта)*

* Тимер жираф, башы күктә,
Күп күтәрә көче күпкә,
Тонна-тонна йөкләрне
Эләктереп ала ул,
Балконнарны балкытып,
Биек өйләр сала ул.
*(Күтәрү краны)*

* Борыны озын үзеннән,
Үзе минем теземнән.
Шыбыр-шыбыр
шыбырдап,
Яңгыр ява эзеннән.
*(Су сипкеч)*

* Бер ягымнан тоталар,
Бер ягымнан куркалар;
Теләләр дә юналар,
Чәнчиләр дә кыркалар.
*(Пычак)*

* Тешләре бар, авызы юк,
Үзе чәйни, үзе йотмый,
Ашаганы — агач он.
*(Пычкы)*

* Укырга да өйрәтә,
Язарга да өйрәтә.
Аны белә һәр кеше.
Ул була... *(укытучы)*

* Матур яңа күлмәкне
Тиз табыла киюче.
Ә аларны кемнәр тегә?
Әйтегезче... *(Тегүче)*

* Көн дә нидер сата ул,
Булсын гына алучы.
Үлчәп бирә, төреп бирә
Кем соң безгә?.. *(Сатучы)*

* Диварларда — бизәкләр,
Кем икән соң аларны
Болай матур ясаучы?
Әйтегезче... *(Буяучы)*.

***

## Бармак уены

Баш бармагым — биюче,
Имән бармак — итекче.
Урта бармак — укытучы,
Атсыз бармак — аучы.
Чәнти бармак кем була?
Читек чигүче була.

*Фәрсия Зиннурова*

***

## Эшкә өндәү

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

*Габдулла Тукай*

## Кызыклы шәкерт

— Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

— Ах, юләр маэмай! тырыш яшьләй, — зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!

*Габдулла Тукай*

## Игенчеләр гаиләсе

Әти ипи
Үстерә,
Әни ипи
Пешерә.
Ә мин... мин ипи
Ашыйм.
Ә аннары
Ипине
Үзем үстерә
Башлыйм.

*Роберт Миңнуллин*

## Безнең бабай

Исем китә: безнең бабай
Җитмеш төрле һөнәр белә.
— Каян болай, ничек алай?
Дисәң әгәр, көлә генә.

— Без, оланнар, яшь чагында
Тырай тибеп йөрмәдек, — ди,
Әти нәрсә кушса, шуны
Иренмичә эшләдек, — ди.

Җитмеш төрле һөнәр белү —
Зур тырышлык хикмәте, — ди,—
—Һөнәре юк кешеләрнең
Булмый иде икмәге, — ди. —

Әйтсәм әйтим, — диде бабай, —
— Гомер буе гел эшле бул.
Иң-иң татлы, затлы җимеш —
Тырыш хезмәт җимеше ул.

*Мөнир Мазунов*

## Иртәнге кояш

Иртәнге кояш
Нурларын чәчә.
Битемнән сөеп,
Миңа эндәшә:

«Иртәрәк уян,
Кызым Зилә, ди,
Йоклап ятуны
Кем дә белә, ди.

Карап көчеңә,
Тотын эшеңә.
Хезмәт батырлык
Өсти кешегә».

*Зәкия Туфайлова*

## Ике көрәк

Түтәлләр казырга чыккач
Күрдек без ике көрәк,
Белмим, кемнәрдер аларны
Коймага куйган сөяп.

Апа безгә сорау бирде,
Берсен кулына тотып:
— Ник монсы көмештәй балкый,
Ә монсын баскан тутык?

— Берсе аның күп эшләгән,
Көмеш төсле шунлыктан.
Икенчесе гел тик яткан,
Ялкаулыктан тутыккан!

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Таяклы помидор

Язын тәрәзә төбенә
Әни үсенте тезә.
Балчык өсти йә күчерә,
Әле тамырын өзә.

Кыраулар үтеп бетүгә
Чыгарабыз түтәлгә.
Мин дә әзер әбиемнең
Һәр кушканын үтәргә.

Су китерәм, көл китерәм,
Биреп торам черемә.
Помидорның әле аның
Була икән чире дә.

Ботаклары җиргә ятса
Чирли дә чери икән.
Әбием шуңа аларга
Таяклар тери икән.

Көче җитмәгәч, үзенең
Сыңар аягы белән
Басып тора помидорлар,
Култык таягы белән.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Булышам

Түтәлләргә чиләк-чиләк
Су сибәм әле менә.
Тизрәк җиләк өлгерсен дип
Булышам әбиемә.

— Җиләкләрнең иң зурысы
Булыр, — дим, — әби, сиңа.
Җиде яшьлек егет ич мин,
Гел зуры булмас миңа.

*Ринат Мәннан*

## Кишер чәчтек

Өй артындагы бакчага
Ясадык та түтәлне,
Кишер чәчтек. Ә карауны
Әни миңа йөкләде.

Ягъни мин чүп үләннәрне
Көн дә утарга тиеш.
Йомшартырга түтәлне,
Чиста тотарга тиеш.
Йолкып ата барам, шытып
Чыгу белән һәр үлән.

Үзем китереп инештән
Чиләк-чиләк су сибәм.
Әби әйтә:
— Тырышлыгың,

Улым, һич бушка китмәс.
Хезмәтеңнең җимешләре
Өлгерер, көзләр җиткәч.
Өстәвенә беләкләрең
Чыныгыр, эшләп үскәч...

*Ямаш Игәнәй*

## Әниемә булышам

Мин әнигә булышам,
Табак-савыт юышам.
Чистарган савыт-сабаны
Шүрлекләргә куешам.

Мин әнигә булышам,
Урын-җирләр җыешам.
Иртән гөлләргә су сибәм,
Керләрне дә уышам.

Мин әнигә булышам,
Идәннәрне юышам.
Әни кебек эш остасы
Булу өчен тырышам.

*Нәҗип Мадьяров*

## Ялт иттерде бүлмәне

Ләгәнгә җылы су салып,
Чүпрәк алып кулына,
Диана өй җыештыра —
Ярдәмләшеп тор гына.

Башта дымлы чүпрәк белән
Сөртеп чыкты тузанны.
Аннары келәм чистартты,
Кәнәфи дә кузгалды.

Өстәл астына да керде,
Җитез генә үрмәләп,
Ә идәнне иң соңыннан
Юып чыктык, бергәләп.

Тырышып эшли Диана,
Әнисеннән күрмәле:
Коймак өлгергән арада
Ялт иттерде бүлмәне.

*Флёра Тарханова*

## Теләсәң, эш табыла

Иртән торгач, гөлләремә
Сулар сибәм һәр көнне.
Аның матур чәчәкләре
Сокландыра һәркемне.
Курчаклар чиста булсын дип,
Аларның керен уам.

Ашап эчкәч, һәрвакытта
Чынаягымны юам.
Оста кулларга һәрвакыт,
Теләсәң, эш табыла.
Эш эшләгәч, тәмле була
Аш та, чәй дә табында.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Кем кем була?

Илшат мөгаллим була,
Илдар зур галим була.
«Кибет ачам берүзем!» —
Диеп куйды Гөлйөзем.

«Бизнесмен!» — диде Марат,
Хәйләкәр генә карап.
Депутат була Таһир,
Ул күп сөйләргә маһир...

Үскәнен көтә-көтә,
Илгиз автобус «йөртә».
Айгөл билет сатачак...
Йолдыз өйдә ятачак...

Ник эндәшмисең? Нигә?..
Озак уйлый бу Динә...
Менә ул телгә килде:
«Мин Динә булам!» — диде...

*Ленар Шәех*

## Эш табыла кемгә дә

Бөтен кеше эштә бүген,
Бөтен кеше өмәдә.
Өмә булгач өмә инде,
Эш табыла кемгә дә.

Гөр-гөр килеп, күгәрчен
Биеп йөри тирәдә.
Алсу белән Гүзәлия
Аларга җим сибәләр.

Әтиләр түтәл күтәрә,
Гөл утырта әниләр.
Арбадагы бәбиләрне
Тирбәтәләр әбиләр.

Бабайлар өйрәтеп тора,
Чокыр казый малайлар.
Агач утырта урамга
Олы-олы агайлар.

Бөтен кеше эштә бүген,
Бөтен кеше өмәдә.
Өмә булгач өмә инде,
Эш табыла кемгә дә.

Өмәне көтеп алалар,
Көткән кебек бәйрәмне.
Нинди көн соң өмә көне?
Эш көнеме? Бәйрәмме?

*Энҗе Мөэминова*

## Мин әтигә охшаган

Әтигә йомышы
Төшмәгән кеше юк.
Аның бит кулыннан
Килмәгән эше юк.

Бура да бурый ул,
Чыгара белә мич.
Терлекче, игенче,
Гармунчы, итекче,
Комбайнчы, шофёр...

Кемгәдер булышсам,
Эшләсәм игелек,
Әйтәләр: «Гел инде
Әтисе бу егет!»

Әйтәләр ихластан,
Мин моңа ышанам.
Әти бит үзе дә
Гел миңа охшаган!..

*Ямаш Игәнәй*

## Кем булырга?

Серләшәләр, язгы урман
Бөреләр ярган чакта.
Кем нинди һөнәрне сайлый? —
Сүз менә шушы хакта.

Айрат сөйли: «Иң алдынгы
Тракторчы — әтием.
Тракторчы булудан да
Әйбәт һөнәр тапмыймын.

Бәхет эзләп, туган җирдән
Китмәм әллә кайларга.
Уйлыймын, мәктәп бетергәч,
Аның юлын сайларга.»

«Доктордан да шәп һөнәр юк, —
Кешегә өсти гомер.
Мин доктор булачакмын!» — дип,
Өзеп әйтә Биктимер.

Әсма: «Савымчы булам», — ди,
Гөлнур очучы булмакчы,
Айбулатны урман тарта,
Абыйсы да — урманчы.

*Гөлфия Юнысова*

## Әтием — җир докторы

Минем әти — басуларның
Һәм кырларның докторы.
Аның кебек хезмәт сөйгән
Бер кеше дә юктыр ул.

Агроном да диләр үзен
Олылар, хөрмәт итеп.
Ул үстергән игеннәргә
Карыйм исләрем китеп.

Мин тоганчы, басу, кырның
Хәлен белеп кайта ул.

Әти аркасында инде
Безнең шундый бай авыл.
Җир кадерен белә әти,
Аны да ял иттерә.

Вакытын белеп кенә,
Ашламалар керттерә.
Ял иткән җир уңыш белән
Сөендерә әтине.

Сөендерә бар халыкны,
Әлбәттә инде, мине!..

*Мөҗәһит*

## Гөлсем апа

Гөлсем апаны күрерсез,
Бакчабызга килсәгез,
— Менә безнең тәрбияче
Гөлсем апа, — диярбез.

— Кайнамаган салкын суны
Эчмәгез! — ди ул безгә,
Аның сүзен онытмыйбыз,
Кайткач та өебезгә.

— Үскәннәрем, — ди ул безгә, —
Чиста булсын сөлгегез.
Бервакытта да авырмас
Сезнең матур күзегез.

Порошок белән юабыз,
Тешебезне агартып,
— Шикәр төсле булган ич, — ди
Гөлсем апа, яратып.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Минем әнием — тегүче

Өстемдәге күлмәгемә
Күпләр карый сокланып.
«Кем текте?» — дип, кайберләре
Сорап куя, тукталып.

«Әнием, дим,
әнием минем —
Фабрикада тегүче».
Бер мин генә түгел әле
Ул теккәнне киюче.

*Әнәс Кари*

## Архитектор

Архитекторның алдында
Хыялдан туган урам.
Мәһабәт сарайларында
Баскычы урау-урау.

Яшел гөмбәзле мәчетләр,
Айлы манаралары.
Балконлы шәп өйләр белән
Бизәлә калалары.

Архитектор шәһәр төзи
Кәгазьдә еллар буе.
Хыялы һәм оста кулы
Бүләк итә өй туе.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Әти йорт төзи

Минем әти — йорт төзүче,
Ул сала биек йортлар.
Ул салган яңа йортларда
Балкып торалар утлар.

Югарыда көчле кран
Әйләнеп, йөреп тора.
Шушы машина әтигә
Кирпечләр биреп тора.

Минем әти кирпеч түши,
Нык итеп, тыгыз итеп,
Матурлап, сырлап, шомартып,
Турылап, тигез итеп.

Көн саен йорт үсә бара,
Биеккә күтәрелә.
Әтием дә күтәрелә
Шушы йорт белән бергә.

Хәзер инде ул йортны мин
Тәрәзәдән дә күрәм.
Хәтта аның рәсемен дә
Дәфтәремә төшерәм.

*Әхмәт Ерикәй*

## Доктор апа

Ничек алай була икән
Доктор апаның кулы:
Эсселәсәң — салкынча күк,
Ә туңсаң — шундый җылы.

Ап-ак бүлмәгә керә ул.
Ап-ак халатын кия ул.
Чирең булса, «И тәмле», — дип,
И әче дару бирә ул.

Эчкәндә чырай сытыла,
Ә терелгәч көләсең.
«Тәмле» дигән сүзнең серен
Шулвакытта беләсең.

*Газиз Нәбиуллин*

## Дәү әнием — бакчачы

Дәү әнием — бакчачы,
Бакчасы да бакча соң:
Ачып керсәң капкасын,
Җәйгә аяк басасың.

Гөлләре дә гөлләре,
Пыяладан өйләре.
Менә һөнәр ичмасам
Дәү әнинең һөнәре:
Чәчәк арасында үтә
Аның бөтен көннәре.

Буш вакытым булганда,
Мин дә аңа булышам:
Помидорлар, кыярлар,
Яшел суган җыешам.

Аның эшен, дәү булгач,
Үзем дәвам итәм мин.
Аннан сезгә ел буе
Ашатырмын витамин.

*Хәкимҗан Халиков*

## Чирле кран

Томаулаган борыны,
Чирләгән су краны:
Тып-тып,
Чуп-чуп
Тора тамып,
Борсаң-бормасаң аны.

Килде кран докторы,
Карый үрмәләп, ятып.
Шалт-шолт,
Шарт-шорт
Сүтә, җыя,
Куймаса ярый ватып!

Кай төшендер майлады,
Төрле ачкыч сайлады.
Әллә компресс куйды,
Кранның чирен куды.
Чаң-чоң, ур-ра!
Ачсаң — ачыла,
Япсаң — ябыла!

*Вәсимә Хәйруллина*

## Фокусчы

Фокусчы фокус күрсәтә,
Карап тора бар кеше.
Ышанмастай эшләрне ул
Ышандырырлык эшли:

Юк нәрсәне бар итә ул,
Салкын суны ут итә.
Таяк белән бер селтәнсә,
Күгәрчен очып китә.

Авызыннан ут бөрки ул,
Аждаһа дип белерсең.
«Мин хәйләли белмим, — ди ул, —
Күрсәтәм, — ди, — дөресен...»

*Энҗе Мөэминовадан*

## Нәни чакта һәм зур үскәч

Бик яраткан гөлләрне
Нәни чакта Гөләндәм,
Хәзер күзләр камаша
Ул үстергән гөлләрдән.

Кечкенәдән машиналар
Ясап уйнаган Рөстәм,
Укыган да тырышып,
Инженер булып үскән.

Нәни чакта Айтуган
Чанада гына шуган,
Хәзер батыр йөрәкле,
Данлы очучы булган.
Алмагачлар, чияләрне
Яшьтән сөйгән Кәбирә,
Данлы бакчачы хәзер,
Илгә җимешләр бирә.

Врач булып уйнаган
Нәни чакта Гөлбикә,
Хәзер өлкән врач ул,
Халыкка хезмәт итә.
Урамдагы суларда
Көймә йөздергән Марат.
Хәзер инде корабта
Диңгез гизүче моряк.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Фотомодель булам

— Фотомодель булам бүген!
— Ничек итеп, әйт әле.
— Матур көлмәктән фотога
Төшәм дә төшәм, яме!

*Вәсимә Ураксина*

## Теш табибында

Әллә конфет күп ашадым,
Әллә юмадым микән?..
Беркөн бик нык тешем сызлап
Уянып киттем иртән.
Әни бераз җәлләде дә
Табибка алып барды.
Авызымны дәү ачтырып,
Табиб тешне карады.
Утырам, котым очып,
Без-без итә әллә ни.
Тишә, тешне җәлләми.
Шөпшә безләгән кебек,
Нидер эзләгән кебек.
Утырам батыр гына,
Берни сизмәгән кебек.
Табиб апа алдында
Төшмәм бит инде җебеп,
Мин бит биш яшьлек егет!
Авырта, суккан шикелле
Дәү чүкеч белән башка.
Хәтта килә елыйсы,
Ничек кенә чыдыйсы?
Бераз гына еларга да
Уйлаган идем башта,
Тик курыктым, күз яшьләре
Миннән сорап тормас дип,
Түздем инде шуңа күрә,
Елыйсы килсә дә бик.
Шөпшә инде безләми,
Тештә нидер эзләми.
Апа бетерде эшен —
Авыртмый хәзер тешем.
Чыгам менә ишектән,
Пәһлеван батыр кебек.
Чираттагылар көнләшә.
Әниләре эндәшә:
«Менә ичмасам егет!»

*Йолдыз*

***

## Һәркем эштә

Борһанетдин: «Мин бүген сабакка бармыйм, анда барганчы, кырларга чыгып уйнармын», — дип, басу капкасыннан йөгереп чыгып китте.

Борһанетдин кырда бер Атны күрде. Ул тиз генә Ат янына барды да: «Әйдә, бахбай, икәү уйныйк, күңел ачыйк», — диде.

Ат: «Юк, җаным, минем уйнарга вакытым юк, минем сабан сөрәсем бар. Хуҗама хезмәт итеп, ризык табасым бар, син үзең генә уйнарсың», — дип җавап бирде.

Бала, моннан киткәч, Умарта кортын күрде.

Ул аның янына барды.

— Әй Умарта корты! Әйдә, икәү уйныйк, күңел ачыйк, — диде.

Умарта корты да җавабында: «Юк шул, минем эшем бар, җәй көннәре тиз үтеп китә. Минем көзгә кадәр төрле чәчәкләрдән бал җыеп каласым бар, үзең генә уйна», — диде.

Борһанетдин, аптырагач, бер Кош янына барып, аның да үзе берлә уйнавын үтенде.

Кош та, Борһанетдиннең үтенечен кабул итмичә: «Юк, бала, минем уйнарга вакытым юк, кечкенә балаларыма ашатырга чебен-черки аулыйсым бар», — диде.

Болай да булмагач, Борһанетдин тирән уйга чумды да тиз генә мәктәпкә таба йөгерде.

*Габдулла Тукай*

## Кем тизрәк үскән?

Матур, кояшлы яз. Кечкенә Фәритнең әтисе — бакчачы. Ул бакчасына помидор, кыяр, шалкан, кәбестә һәм тагын әллә нинди яшелчәләр утырта.

Менә кәбестә үсентеләре. Әтисе аларны рәт-рәт итеп утыртып бара, әнисе аңа ярдәм итә, Фәрит кечкенә чиләк белән кәбестә утыртасы чокырларга су сибә. Әтисе моңа бик шат.

Алар кәбестәне кичке якта утырталар — кояш көйдереп алмасын үзләрен.

Эшләрен бетергәч, күтәрелеп карасалар, кәбестә үсентеләре матур булып, рәт-рәт тезелеп утыра! Аларның үсәселәре килә.

Әнисе шунда:

— Улым, кем тизрәк үсәр икән: синме, әллә кәбестәләрме? — дип шаярта. Фәритнең дә, тиздән үсеп, әтисе кебек бакчачы булырга теләвен белә ул.

Фәрит, әти-әнисенә карап:

— Кәбестә, — дип елмая.

— Көз килер, күрербез диген, улым, — ди әтисе. — Алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди халык.

Фәрит кәбестәләргә көн дә су сибә. Көндез кәбестәләр кояшка елмаеп карыйлар, һаман кояш нурларына сузылалар. Кояш аларны алтын нурлары белән иркәли.

Кайчак болытлар да Фәриткә ярдәмгә килә, кәбестәләрне шифалы тамчылары белән сыйлый. Яңгырдан соң көн тагын да ямьләнә, үсентеләр дә яшелләнеп, матураеп китә.

Көн артыннан көн үтә, көз килеп җитә. Кәбестәләр баш кадәрле булып үскән. Кул белән кыскаласаң шыгырдап торалар. Үзләре катлы-катлы, сусыл, тәмле. Аларга күзләр, борын, авыз ясап куйсаң, «Без инде үсеп җиттек!» — дияр кебек.

Әти-әнисе белән бергә Фәрит тә шатлана. Әнисе, кәбестә үсентеләрен утырткандагы сүзләрне искә төшереп:

— Улым, йә, кем тизрәк үскән? — дип елмая.

Фәрит зур булып үскән кәбестәләрне күтәрергә тырышып карый да:

— Кәбестәләр! — ди. Аннан соң, җәй буе аларга су сибәсибә, үзенең дә буйга сузылганын, күлмәк җиңнәренең кыскарып калганын күреп:

— Мин дә! — дип өсти.

*Нәкыйп Каштан*

## Супермалай

Ул — супермалай.

Ул, теләсә, әлләниләр эшли, әллә нәрсәләр майтара ала...

Теләсә, кибеткә барып, ипи-сөт алып кайта ала.

Чишмәдән «ә» дигәнче су алып кайта ала. Теләсә.

Утын кисә ала.

Елап яткан энесен юата ала. Әгәр теләсә.

Буш вакытында (ә аның буш вакыты күп!) китаплар укый ала. Урындыкны төзәтә ала. Идәнне себерә-юа ала...

Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр эшли ала...

Әгәр теләсә....

*Ләбиб Лерон*

## Ничек аңларга?

Бүген Рөстәмнең эше бик күп булды. Иртән иртүк әбисе аны: «Шәмсениса, Әдибә, Галимә, Сәрбиҗиһан, Гөлҗамал әбиләреңне ашка чакырып кайт, Коръән укытабыз», — дип, аркасыннан сөя-сөя, капкадан чыгарып җибәрде. Авылның бер очыннан икенче очына кадәр йөреп, кире әйләнеп кайтканда, әбисе белән әнисе әллә никадәр тәмле әйберләр пешергәннәр иде.

— Булдырдың, улым, рәхмәт, — дип мактады аны әбисе.

Мактау килеште Рөстәмгә. Ул, кунаклар килгәнче дип, җырлый-җырлый, ишегалдын себерергә тотынды.

— Эшне үзең белеп башкару бик шәп тә, тик иртәнге сәгатьтә үк җырлап йөргән кешенең бәхете булмас, диләр, улым. Авызыңа тузан да тула, — дип кисәтү ясады ишегалдына суга чыккан әбисе.

— Иртәнге сәгатьтә җырлаган кешенең ник бәхете булмый? — дип сорады Рөстәм.

— Соң, иртә таңнан җырлап йөри башлагач — ялкау инде ул, улым. Ялкауга акча бирмиләр. Акчасыз кеше ач була, — дип, кыскача гына аңлатты әбисе.

Бераздан кунак әбиләр, килеп, аш өстәле янына утырыштылар.

— Чакырган кешеләрем килеп бетте, башларга рөхсәт, Мәчтүрә абыстай, — диде Рөстәмнең әбисе. Мәчтүрә абыстай, әмер булуга, көйләп, моңлы гына итеп җырлый башлады. Җырлап бетергәч, һәммәсе дә аңа акча бирергә тотынды. Иң сәере һәм Рөстәм өчен иң аңлашылмаганы — Мәчтүрә абыстайга иң беренче булып Рөстәмнең әбисе сузды.

— Алланың рәхмәте яусын, Мәчтүрә абыстай, тавышыңның мәкаме кимемәсен, — диде.

Рөстәмгә дә акча бирделәр. Минем дә, җырлый-җырлый, ишегалды себергәнемне ишетте микән әллә болар, дип уйлады Рөстәм. Акча булгач яшәргә була! Ә соң әбисенең «Иртә таңнан җырлаган кеше ач була, ялкау, бәхетсез була» дигәнен ничек аңларга?

Чынлап та, ничек аңларга икән? Бәлки, хикәянең дәвамын сез язарсыз, дусларым?

*Эльмира Шәрифуллина*

# «ИМИНЛЕК»
# БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Аюдан курыксаң, урманга барма,
Бүредән курыксаң, сарык асрама.
* Ике куянны берьюлы кумыйлар.
* Юлда йөрергә дә акыл кирәк.
* Урау булса да, юл яхшы.
* Юлга чыксаң, азыгың үзең белән булсын.

## ТАБЫШМАКЛАР

* Башы белән кабына,
Кагылдымы — кабына.
*(Шырпы)*

* Пожар турында ишеткәч,
Сигнал бирергә ашык.
Янгын гел көчәя бара,
Туктатып булмый ич һич.
Су гына сүндермәс аны,
Кирәк шул... *(ут сүндергеч)*.

* Автомобиль, трамвайдан
Саклан, димен, бик сак бул!
Уйный торган урын түгел
Машиналар йөргән... *(юл)*.

* Авызы юк, борыны юк,
Тик бар аның өч күзе.
Урамдагы хәрәкәтне
Көйләп торадыр үзе.
*(Светофор)*

* Төймәсе челт итә,
Үзе гөлт итә.
*(Лампочка)*

* Башыбыз бар, гәүдәбез бар,
Юк кул, аякларыбыз.
Балалар тотса куркабыз —
Яман шул якларыбыз.
*(Шырпы)*

* Җәен, кышын, яз, көзен,
Иртән, кичен, көндезен
Телсез әйтәдер сүзен —
Ача-йома өч күзен.
*(Светофор)*

* Сукмактан да чыгалмыйлар,
Бер-берсен дә уздырмыйлар,
Кызыл күзле ябалактан
Рөхсәт алмый кузгалмыйлар.
*(Трамвай, светофор)*

* Тәрәзәле һәр ягы,
Җиргә тими аягы.
Сыртында бар дугасы,
Йә, бу нинди юрга соң?
*Мотоцикл)*

* Аяклары түгәрәк,
Куышалар, тәгәрәп.
Үзем утырам, үзем чабам
Теләсә кая табан.
*(Велосипед)*

* Ияремә менәләр,
Өзәнгемә тибәләр.
Йөгертәләр, чаптыралар,
Кирәк җиргә китәләр.
*(Трамвай)*

* Маңгаенда мөгезе бар,
Боргаласаң — үкерә.
Менеп атлансаң биленә,
Җилдән җитез йөгерә.
*(Мотоцикл)*

***

## Үрли дә үрли генә

Рәис белән Хәдичә
Ялгыз калдылар кичә,
Уйнадылар ут белән,
Ни буласын белмичә.

Ул бит берни дә белми,
Үрли дә үрли генә,
Әниләре, ичмасам,
Керми дә керми генә.

Мич алдында чырага
Рәис утны элдерде,
Ялкын кинәт чырадан
Күлмәгенә үрелде.

Нишләргә дә белмиләр,
Рәиснең тәне пешә,
Ярый, югары өйдән,
Бәхеткә, апа төшә.

Апа утны сүндерә,
Коткарырга өлгерә,
Рәис үзе исән калды,
Янды күлмәге генә.

*Әминә Бикчәнтәева*

## Гөмбәләр

Әйтерсең лә качыш уйный
Гөмбәләр безнең белән.
Мин ул шаян гөмбәләрне
Бик оста эзли беләм.

Ак, ал, кызыл гөмбәләрне
Табам да кисеп алам,
Мин аларны һич бутамыйм,
Җайлап, кәрзингә салам.

Тик чебен гөмбәсе кебек
Агулысын өзмимен.
Нәкъ апабыз әйткәннәрен —
Яхшыларын эзлимен.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Кошларга

Курыкмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңелегезгә Тәңре нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим;
Әллә иркендә торуның кадерен белмимме мин?!

Курыкмагыз — яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.

*Габдулла Тукай*

## Песи, песи, пескәем...

Песи, песи, пескәем,
Нигә качкан төскәең?
Тычкан тотмадыңмыни,
Озак йокладыңмыни?

Сөт бирмәделәрмени,
Нык тиргәделәрмени?

Ә песи әйтә: «Мияу,
Мин һәрвакытта уяу,
Тычканнар миннән поса,
Күсенең коты оча.
Олылар шуңа күрә
Миңа тәмле сөт бирә.

Тик менә Айрат кына
Кылана харап кына:
Йә аягыма баса,
Йә ул койрыктан аса.

Шуңа качкан төскәем,
Шуңа яшьле күзкәем.

Тик Айратка әйтегез:
Ул зур дип тормыйм әле.
Тагын миңа тисә ул,
Борынын тырныйм әле».

*Дамир Гарифуллин*

## Батыр кызчык

Күрче, әнә бер кызчык
Песиен ничек тоткан —
Маэмай аңа тимәсен,
Яклаучысыз димәсен.

Һау-һаулап маэмай өрә,
Уенда ни — кем белә?..
Йә эләктереп алса?
Йә селтәп җиргә салса?

Ә кызчык бер курыкмый,
Тып итеп аяк тибә,
Бармак яный маэмайга:
— Син минем дуска тимә!

Бигрәк тә нәни кызчык,
Ә үзе батыр ничек!
Яздым әле шул хакта,
Улым, дим, син дә ишет.

*Бикә Рәхимова*

## Сансыз малай

Чабып килеп, бер малай
Ак каенга атылды:
Ботагына ябышып,
Әй, атынды, атынды.

Һаман атынды малай,
Әлләниләр кыланды...
Шарт итеп сынган ботак
Җиргә төшеп сыланды.

Әй, елады ак каен,
Әй, елады ботагы...
Малай — ялт — икенчегә
Асылынды бит тагы...

Бу елауны ишетеп,
Көтү-көтү чыпчыклар
Куаклар арасыннан
Очып килеп чыктылар.

Аяусыз малай, диләр,
Бик сансыз малай, диләр.
Алты яшькә җитсә дә,
Тәртипсез малай, диләр.

Аңлыймы соң бу малай
Ни кылганын чын-чынлап?
Әлегә баш очында
Чыпчыклар оча, чырлап.

*Бикә Рәхимова*

## Акбай шулай ди...

Акбай белән бик дуслар без.
Мин аның телен беләм.
Ул үзе дә нәкъ кешечә
Сөйләшә минем белән.

Ул миннән берни яшерми,
Сиңа бер сер сөйлим, ди.
Мин бит безнең урамдагы
Малайларны сөймим, ди.

Урамга да чыгып булмый,
Мине рәнҗетәләр, ди.
Йә миңа таш аталар, ди,
Йә үртәп үтәләр, ди.

Үртәсеннәр әле, әйдә,
Мин әлегә түзәм, ди.
Әгәр тагын үртәсәләр,
Чабуларын өзәм, ди.

Анда да туктамасалар,
Аякларын тешлим, ди.
Алар миңа нишләсәләр,
Мин дә шуны эшлим, ди.

Урамга да чыгармыйм, ди.
Тагын усаллансагыз!
Әнә үзеннән сорагыз,
Әгәр ышанмасагыз!

*Роберт Миңнуллин*

## Авыру урман

— Кермәгез, дип, урманга! —
Үрмәкүчләр агачка
Пәрәвез дә суздылар,
Ә кешеләр аларны
Өзеп кенә уздылар.

Яфрак астына гөмбә
Качып-качып карады,
Ә кешеләр таптап кына
Китеп барды аларны.

Бүреләр дә сукмакка
Чыгып басканнар икән,
Кешеләрне күрүгә
Куркып качканнар икән.
Әллә миңа ышанмыйсыз?

Сез үзегез килегез,
Килегез дә күрерсез:
Җиләксез һәм чәчәксез,
Гөмбәсез һәм бүресез

Моңаеп тора урман.
Ә сез, бәлки, якында
Көлешеп йөрисездер?
Мин менә елап торам.

*Рәшит Бәшәр*

## Тәкый һәм пәке

Тәкый беркөн
Алтын саплы
Пәке тапты,
Өйгә кайтып

Мактанды да
Чыгып чапты.
Шуннан бирле
Һәр агачка
Тамга куя.

Әнә ничек
Алмагачка
Чокыр уя.
Пәке түзми,

Шунда кинәт
Йомыла да
Тамга сала
Тәкыйнең үз
Кулына да.

*Хәкимҗан Халиков*

## Песинең зары

Мансур — тәртипсез бала,
Төрле уеннар таба.

Баса минем койрыкка,
Буйсын, имеш, бойрыкка.

Кычкыр, имеш, мыраула,
Сикер артка йә алга.

Мөмкинме сикерергә
Койрык кысылган көйгә?

Мияу-мияу-мияу, дим,
Биткә сөртмә буя, дим.
Ә ул һаман үчегә,
Масаямы көченә?

Күтәрә сырттан тотып —
Ала йонымны йолкып.

Башы җитми уйларга:
Ничек болай уйнарга?

Кыланса һаман шулай,
Мин дә тик кенә калмам!

Аңа соңгы сүз менә:
Үпкәләсен үзенә.

Үткен минем тырнагым,
Тотармын да тырнармын.
Тартма, дим, мыегымны,
Киертмә оегыңны!

*Самат Шакир*

## Ятим тургай

— Тургай, нигә моңлы син?
Нигә болай елыйсың?
— Инде елап арыдым мин:
Япа-ялгыз калдым мин.
— Абау, шулай укмыни?
Балаларың юкмыни?
— Аждаһадай коточкыч
Мәрхәмәтсез бер очкыч
Агу сипте басуга:
Балаларым барсы да
Шундук үлеп беттеләр...
Мине ятим иттеләр.
Әле безнең кадерне
Тора-тора белерсез.
Тургайларны бервакыт
Төштә генә күрерсез...
Белмим, нинди кеше сез?
Нишлисез?!

*Хәкимҗан Халиков*

## Машинада балалар

Машинада балалар
Җырлый-җырлый баралар.
Машинада чәчәкләр,
Кайдан өзеп алганнар?
Әй көләләр балалар,
Чәчәкләре булганга.
Тик калган, ди, моңаеп,
Шомырт кына урманда.

Матур төсе югалган,
Чәчәкләре урланган.
Шомырт шуңа моңайган,
Шомырт шуңа хурланган!

*Заһирә Гомәрова*

## Светофор

Бервакытны әти белән
Машинада барабыз.
Дәште безгә Светофор:
— Туктагыз, ди, карагыз.
Кызыл утым янган чакта,
Юл бирегез барына.
Әзерләнә торыгыз, ди,
Сары янган чагында.
Ә карасак, шул арада
Яшел уты да янган.
Әйтте безгә:
— Кузгалыгыз, рәхим итегез, мадам!

*Илсөяр Иксанова*

## Светофорның өч сүзе

Урамнарны
Күзәтеп,
Ваемсызны
Кисәтеп,
Чатта тора
Светофор,
Сакта тора
Светофор.

Янып тора
Өч күзе,
Күреп тора
Ич безне,
Әйтеп тора
Өч сүзне:
— Кузгалма! — ди
Кызыл күз.
— Сабыр! — дия
Сары күз.
— Ярый! — дия
Яшел күз.

Без дә аңа
Карыйбыз,
Күзебезне
Алмыйбыз,
Ни әйткәнен
Аңлыйбыз:
— Кузгалма! — ди
Кызыл күз.
— Сабыр! — дия
Сары күз.
— Ярый! — дия
Яшел күз.

*Шәүкәт Галиев*

## Светофор

Озын агайның өч күзе:
Кызыл, сары, яшел ут.
Икесе сүнеп торганда,
Берсе яна шунда ук.

Юл аша чыкканда, һәркем
Карый шушы күзләргә.
Һәрбер күзнең — үз фәрманы,
Һич кирәкми сүзләр дә.

Сары күз янса — «Көтеп тор!»
«Тукта!» — кызыл янганда.
«Тизрәк бул, алга атла!» —
Яшел күз елмайганда.

*Гөлфия Юнысова*

## Велосипедыңа өйрәт

Абыйсы велосипеды
Зур булса да Булатка,
Көне буе чабып йөри,
Атлана да шул атка.

Велосипедта әбисе
Йөртмәскә бик тырыша:
— Егылырсың әле, — дип,
Булатны гел орыша.

— Машиналар йөргән юлга
Чыгарга ярамый, — дип, —
Инспектор алып китәр,
Бернигә карамый, — ди.

Инспектор Наил абый
Безнең күршедә тора.
— Сорыйм әле шуңардан, — дип,
Булат та план кора.

— Әйе, — ди Наил абыйсы, —
Бик сак булырга кирәк,
Велосипедыңа башта
Юл кагыйдәсе өйрәт.

*К. Низамова*

## Алга утырсаң...

Нәкыйп керде трамвайга,
Алда бар бер буш урын.
Тиз генә барып утырды,
Кепкасын киеп кырын.

Малай горур, утыра ул,
Күрмәмешкә салышып.
Ә әби, нидер эзләпме,
Аска карый тырышып.

Бераз баргач, әби керде,
Таягы да кулында.
Трамвай селкетә-чаба,
Юк әбигә урын да.

— Әби, анда ни эзлисең? —
Дип сорап куйды Нәкыйп.
— Карыйм: синең аякларың
Бармы, әллә юкмы дип...

*Ринат Мәннан*

## Светофор

Без бакчага барабыз
Иртән, ашыга-ашыга.
Машиналар ашыга,
Килеп чыга каршыга.

Ярый әле, шул чакта
Светофор тора чатта.
Җемелдәтеп өч күзен
Әйтеп сала өч сүзен.

Кызыл әйтә: «Туктап кал!»
Сары әйтә: «Игътибар!»
Яшел әйтә: «Юл ачык!
Карап кына атлап чык».

Без бергәләп җырлыйбыз
Бүген сезгә шул хакта.
Урамнарда һәр чатта
Светофор торсын сакта.

Әмма ләкин бар чатта
Светофор тормый сакта.
Юл аркылы чыгулар
Мең газап ла бу чакта.

Җемелдәсен өч күзе,
Әйтеп салсын өч сүзне.
Кызыл әйтсен: «Туктап кал!»
Сары әйтсен: «Игътибар!»

Яшел әйтсен: «Юл ачык!
Карап кына атлап чык».
Әй сез, өлкән абыйлар,
Безнең хәлгә керегез.
Олы юллар чыкканда
Имгәнмәсен беребез.

*Йолдыз*

***

**Уйныйсы килә**

Нәни Айрат әтисе белән саф һавада йөреп керде.

— Әтиең белән кая бардыгыз? — дип сорады әнисе.

— Урамда йөрдек. Эт күрдек.

— Нинди эт?

— Менә шундый зур эт, — дип, Айрат кулларын җәеп җибәрде. — Йонлач башы телевизордагы аюныкы төсле үк иде.

— Дөрес әйтә, — диде әтисе. — Бик матур эт иде.

— Әти аны миңа сыйпарга кушмады.

— Дөрес эшләгән, ул сине тешләгән булыр иде.

— Юк, аның күзләре шундый матур иде. Гел миңа гына карап торды.

— Ни өчен икән? — дип гаҗәпләнгән булды әнисе.

— Аның да минем белән уйныйсы килә иде, тик аны җибәрмәделәр генә.

— Кем җибәрмәде?

— Аны бауга бәйләп тоткан әтисе инде.

Әнисе көлеп җибәрде. Әтисе дә көлде. Алар көлделәр, Айрат кына берни дә төшенмәде.

*Заһирә Гомәрова*

## Кызык итте...

Соңгы вакытта Айгөлне ишегалдына бик чыгармаска тырышалар. Әле «әтәч талый» диләр, әле «ата каз» дип куркыталар. Чебиләр, каз бибиләре анда. Айгөлнең аларны бик тә күрәсе, кулына тотып карыйсы, алар белән уйныйсы килә. Ә чыгармагач, аксыл йомгак чебиләрне дә, сары йомшак бибиләрне дә кулга алып булмый инде ул.

Бүген аңа уйнап керергә рөхсәт иттеләр. Әнисе өй җыештыра, Айгөлнең җиң сызганып чиләккә таба килүен күргәч, аны уйнап керергә чыгарып җибәрде.

Койма буендагы челтәр тәрәзәле читлектә чебиләр ярма бөртекләре чемченеп йөргән булалар. Аларны читлектән бик чыгарыр иде Айгөл, ишек келәсенә буе җитми. Ярый, челтәр тәрәзәдән карап торсаң да кызык икән.

Ул арада бакча артыннан кайтып килүче Мәликә әбисе күренде. Алъяпкыч итәген кайтарып тоткан. Айгөлнең күргәне бар: әбисе чебиләргә үлән йолкып алып кайта шулай. Алып кайткан үләнне ләгәнгә салды да, Айгөлгә һичнигә кагылмаска кушып, нәрсәдер алып чыгарга өйгә кереп китте әби. Айгөлгә шул гына кирәк тә. Ничек инде кулга тотып карамый түзәсең үләннәрне? Кызыктыра бит.

Мондый эре, тере яфраклы үләнне бер дә күргәне юк иде Айгөлнең. Соклanudан йөзенә яктылык җәелде. Тиз генә барып, бер бәйләм үләнне кулына алган иде, нәни бармакларын кайнар су пешекләп алдымыни! Яндыра, әчеттерә. Айгөл чыр итеп кычкырып елап җибәрде.

Ишектән берьюлы диярлек әнисе белән әбисе йөгереп килеп чыктылар.

— Ни булды тагын? — диде әнисе, куркынган тавыш белән.

— Әтәч явыз кетәклектән чыкмагандыр бит? — диде әбисе. — Югыйсә ныклап ябып куйган идем...

Айгөл әрнегән кулын өскә күтәрде.

— Ай-ай... — дип такмаклады ул. — Авырта-а...

— Кычыткан бәласе икән бу, — диде әбисе, хәлгә төшенеп. — Әйттем, бернәрсәгә дә кагылма, дидем...

— Кычытмый, авырта-а, — дип үксүен белде Айгөл.

— Кычыткан... — Әбисе сүзен әйтеп бетермәде, Айгөл тагын да ныграк үкси башлады:

— Кычытмый, авырта-а...

— Аңладым, аңладым, — диде әбисе, көлемсерәп. « Өф-өф» итеп кызчыкның бармагына өреп алган иде, бармакның әрнеп сулкылдавы басыла төште.

— Менә бу тешләде... — диде Айгөл, әбисенә сыенган килеш, эре яфраклы үләнгә ачулы карап.

— Бу үлән кычыткан дип атала да инде, кызым. Тешләми ул, чага. Мин яшь кычытканнарны бакча артыннан алып кайтам да чебиләргә турап бирәм. Яраталар аны наныйлар. Кычытканны ашагач, алар авырмый, тиз үсәләр. Менә шундый бик файдалы үсемлек булгач, аны өзеп алучылар да күп була. Ул үзенә кагылган кешеләрне куркытам дип чагып ала.

Әбисе файдалы дип бик мактаса да, Айгөл кычытканга яңадан кагылмаска булды. Үсә бирсен койма буенда. Әбисе белән дуслашканнардыр алар, аны бер дә чакмыйлар ич.

*Факил Сафин*

## Шомырт нигә елый?..

Без ел саен шомырт агачыбыз янына кунакка киләбез. Бу килүебездә без аның моңаеп, боегып утырганын күрдек һәм дустыбыз каршында башларыбызны иеп, сүзсез басып калдык... Аны талаганнар иде. Ботагы-ботагы белән сындырып

алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр. Кул җитәрдәй, урлар чәчәк калмагач, кайсыдыр тагын да өскәрәк үрмәләгән һәм шомыртның югарыдагы бер канатын-ботагын сындырып ук төшергәннәр. Ул ботакның яфраклары, әрнеп, йөзләрен җыерганнар. Сынган урындагы кызгылт-сары җәрәхәттән, дымланып, кан саркый сыман...

— Әти, шомырт безгә нигә тагын чәчәк бүләк итми?

— Үпкәләгән ул кешеләргә, рәнҗегән. Әнә бит, ботакларын бик авырттырып сындыра-сындыра, аның чәчәкләрен урлап киткәннәр. Бер канатын каерганнар. «Арагыздагы ул рәхимсез җаннарны нигә акылга утырта белмисез соң сез?!» — ди ул безгә.

— Инде бер дә, бер дә чәчәк бүләк итмәсмени ул безгә? Җимешләре белән дә сыйламасмы?

Икенче көнне без, янәдән килеп, шомыртыбызның җәрәхәтенә сагыз сыман бакча мае сөртеп, аны чиста чүпрәк белән бәйләдек. Сындырылган ботакларын тигезләп кисеп, ул урыннарга да бакча даруы сыладык.

Җәйләр үтте. Беркөнне улым:

— Әти!.. Шомырт безне гафу итте микән әле?

— Бәлки, гафу иткәндер, — дидем мин, яралы шомыртыбызның хәлен белергә яздан бирле бара алмавыбызга уңайсызланып.

Иртәгесен аланлыкка юнәлдек. Хозурланып кына атлыйбыз. Һәм кинәт... тукталып калдык. Бу юлы шомыртның канатын каерып кына калмаганнар, бугазына ук ябышканнар. Өске ботакларында сакланып калган чәчәкләр җимеш өлгерткәннәр, күрәсең. Шуларга комсызланып, шомыртның өске ботакларын чәрдәкли-чәрдәкли каерып төшергәннәр. Инде ике канаты да каерылган, бөтен тәне әрнүле җәрәхәтләнгән шомыртның. Без акрын гына шомыртыбыз янына килеп җиттек.

— Шомырт... елый, — диде улым, агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчыларга карап һәм үзенең дә күзләреннән мөлдерәп чыккан яшьләрен кул аркасы белән сөрткәләп.

Әйе, елый иде шомырт...

*Рафаил Төхфәтуллин буенча*

# III БҮЛЕК

# «ДӨНЬЯ МАТУР, ДӨНЬЯ КИҢ»

*(«Танып белү-сөйләм үсеше» юнәлеше)*

## «ТАНЫП БЕЛҮ» БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Табигатьне саклаган — үз яшәвен аклаган.
* Язның байлыгы — кояш, көзнең байлыгы — уңыш.
* Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле елый.
* Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.
* Кышкы кар — көзгә икмәк.
* Яңгыр яуса — җиргә май.
* Бер карлыгач килеп, яз булмый, бер саескан килеп, кыш булмый.
* Малың мал булсын дисәң, азыгың мул булсын.
* Терлекне кул белән генә сөймә, азык белән дә сөй.
* Кошның да туган оясы бар.

***

## ТАБЫШМАКЛАР

### Табигать күренешләре

* Берсе яшел келәм тукый,
Берсе сарыга мана.
Берсе ак мамыгын түши,
Ә берсе җыеп ала.
*(Ел фасыллары)*

* Беркемгә дә күренмичә,
Җыр көйләргә ярата.
Көзге сары яфракларны
Тирә-якка тарата.
*(Җил)*

* Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.
Бу кайчак?
*(Кыш)*

* Һәр көн диярлек
Елап яшь коя.
Килгән кошларны
Көньякка куа.
Бу кайчак?
*(Көз)*

* Ул булса, көн була;
Ул булмаса, төн була.
*(Кояш)*

* Төнлә баксаң — күк тулган,
Иртә баксаң — юк булган.
*(Йолдызлар)*

* Ишегалдында таш була,
Өйгә керсә, су була.
*(Боз)*

* Колак, борынны уып,
Өеңә кертә, куып.
*(Салкын)*

* Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,
Кайчак кара төстә мин.
*(Болыт*

* Җәйге эссе көннәрдә
Мине сагынып көтәләр.
Мин аз гына күренсәм,
Качып-посып бетәләр.
*(Яңгыр)*

## Үсемлекләр

* Җәй киенә,
Кышын чишенә.
*(Агач)*

* Язын дөньяга килә,
Көзен саргаеп үлә.
*(Яфрак)*

* Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар,
Кем аны сөртеп йөргән?
*(Чәчәкләр)*

* Кигән ап-ак эшләпә,
Төшереп кашына ук.
Эшләпәсен салдырсаң,
Каш түгел, башы да юк.
*(Гөмбә)*

* Нечкә яшел сабакта
Юл буенда шар үскән.
Кай арада җил искән,
Ак шар очкан да киткән.
*(Тузганак)*

* Ялгыш кына тисәгез дә
Елатабыз, чагабыз.
Безгә үпкәли күрмәгез,
Шул — саклану чарабыз.
*(Кычыткан)*

* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
Җәй башында җиләгемне
Авыз итәрсез, дигән.
*(Каен)*

* Сары эшләпә кигәннәр,
Җем-җем итә күзләре,
Гел кояшка караганга
Кояш төсле йөзләре.
*(Көнбагыш)*

## Җәнлекләр, кош-корт, бөҗәкләр...

* Үзе кардай ап-ак ул,
Озын колак бик сак ул.
Дошман күрсә элдертә,
Кем аны куып җитә?
*(Куян)*

* Ул өстенә җәй дә, кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе
«Йомшагым» диеп сөя.
*(Керпе)*

* Кош түгел — оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне бик ярата,
Сызгырса, урман яңгырата.
*(Тиен)*

* Язын килә, көзен китә,
Оя ясасаң, үз итә.
*(Сыерчык)*

* Гөлдер-гөлдер-гөлдергү,
Кызыл тәпи — кемдер бу?
*(Күгәрчен)*

* Бигрәк инде иләс кош,
Үз оясы булмас кош.
Үз оясы булмаса да,
Күкәй сала торган кош.
Бу нинди кош? — Исем куш!
*(Күке)*

* Асрамый да умарта,
Балны бик, бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята.
*(Аю)*

* Үзе ялагай,
Үзе хәйләкәр.
Ул нәрсә булыр,
Йә, әйтеп җибәр.
*(Төлке)*

* Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Бозаулар күзли.
*(Бүре)*

* Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый.
*(Карлыгач)*

* Җәй шакылдый бу чүкеч,
Кыш шакылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч?
*(Тукран)*

* Борыны озын, боты озын,
Камышлыкта көнозын,
Сазлык җирләрдә йөри,
«Тату торыйк», — дип сөйли.
*(Торна)*

* Үзе бәләкәй генә булса да,
Үзеннән зур күтәрә.
*(Кырмыска)*

* Аллы-гөлле очкалак,
Оча, гөлләр кочкалап.
*(Күбәләк)*

* Чырр, чырр, чырр, ди ул,
Канат белән җырлый ул,
Аяк белән тыңлый ул.
*(Чикерткә)*

* Аллы-гөлле чәчәкләрне
Кетер-кетер ашый ул.
Шуннан ап-ак сөт ясап,
Көн дә безгә ташый ул.
*(Сыер)*

* Сакаллы килеш туа —
Берәү дә гаҗәпләнми.
*(Кәҗә)*

* Мырк-мырк мырылы,
Бик каты икән борыны.
*(Дуңгыз)*

* Кешенең дусты,
Йортның сакчысы.
*(Эт)*

* Үзе суфи, үзе урлаша,
Тотсаң әле, тырнаша.
*(Песи)*

* Тызлый да бызлый,
Үпкән җире сызлый.
*(Бал корты)*

* Аягын, башын яшерә
Таш күлмәге эченә.
*(Ташбака)*

* Канаты бар — каурыйсыз,
Күзе дә бар — керфексез.
Күлмәге тулы ак тәңкә,
Ул да тагылган җепсез.
*(Балык)*

* Сабан туенда узыша,
Кешеләргә булыша,
Утырдым исә биленә,
Илтә кирәк җиремә.
*(Ат)*

* Табышмак әйтәм мин сезгә:
Йон бирә нәрсә безгә?
*(Сарык)*

* Соскы борын — бакылдык,
Күп сөйләшә — такылдык.
*(Үрдәк)*

* Иртән бик иртә тора,
Матур итеп кычкыра.
*(Әтәч)*

* Суда юынып алды,
Өсте коры калды.
*(Каз)*

* Канаты бар — очалмый,
Аягы бар — йөзалмый.
*(Тавык)*

* Ап-ак йомгак ярылды —
Сары йомгак яралды.
*(Чеби)*

* Йон йомгагым бөдрә,
Су күрдеме йөгерә.
*(Үрдәк бәбкәсе)*

* Яшел палас өстендә
Сары йомгак тәгәри.
*(Каз бәбкәсе)*

## Үсемлекләр дөньясы

* Кышын да, җәен дә
бертөсле.
*(Чыршы, нарат)*

* Нинди агач җилсез шаулый?
*(Усак)*

* Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
*(Каен)*

* Алсу битле кыз үсте,
Кызарып, җиргә төште.
*(Алма)*

* Озын, яшел — түтәлдә,
Сары, тозлы — кисмәктә.
*(Кыяр)*

* Җир астында җиз бүкән,
Һәр көн ашыйсың, иркәм.
*(Бәрәңге)*

* Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк.
*(Кәбестә)*

* Туп түгел — түгәрәк,
Күсе түгел — койрыклы.
*(Чөгендер)*

* Кызыл төймә таптым,
Авызыма каптым.
*(Җиләк)*

## Йорт-җир, көнкүреш әйберләре, кием-салым, савыт-саба, аш-су

* Көн-төн йөри,
Урыныннан китә алмый.
*(Сәгать)*

* Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән,
Юлы агач башында.
*(Телефон)*

* Үзе бер әрҗә,
Бөтен дөньяны
Күрсәтә.
*(Телевизор)*

* Чүп-чар, тузан йота ул,
Өйне чиста тота ул
*(Тузан суырткыч)*

* Берсе сулдан, берсе уңнан,
Урам таптый ике туган:
Бер-береннән калышмыйлар,
Урыннарын ялгышмыйлар.
*(Аяк киемнәре)*

* Үзе бер дә ашамый,
Ашаганда бушамый.
*(Кашык)*

* Бәләкәй генә ак тана,
Борыным бар, дип мактана.
*(Чәйнек)*

* Почмакта бер суык кыш,
Исеме аның... *(суыткыч)*.

* Төймәсенә басу белән
Бәйли зәңгәр яулыгын.
Аш пешерә, чәй кайната —
Күрсәтә уңганлыгын.
*(Газ плитәсе)*

* Аяксыз, кулсыз
Өй саклый.
*(Йозак)*

* Айрат кия, Гөлназ бәйли —
Икесен дә салалар.
Нәрсә кигән икән алар,
Беләсезме, балалар?
*(Бүрек, яулык)*

* Колагы бар, башы юк,
Ашамаган ашы юк.
*(Кәстрүл)*

* Колаклы ябалак
Кыштан саклый..
*(Бүрек)*

* Үзе түгәрәк,
Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк;
Әчкелтем дә төчкелтем,
Бар нәрсәдән дә кадерлерәк.
*(Икмәк)*

* Башы да тишек,
Төбе дә тишек,
Уртасында — ут,
Читендә — су.
*(Самавыр)*

* Тоз түгел — ак,
Бал түгел — татлы.
*(Шикәр, шикәр комы)*

* Бер чынаяк эчендә
Ике төрле сөт тора.
*(Йомырка)*

* Мине тотып ашамыйлар,
Миннән башка туй да ясамыйлар.
*(Тоз)*

***

## Табигать кочагында

Гөл-чәчәкләр өзмәдек без.
Куаклар сындырмадык.
Яшел урман аланында
Уйнадык та җырладык.

Кояшка карап елмайдык.
Җилләргә сәлам әйттек.
Һәркем өйгә алып кайтты
Бер кочак сәламәтлек!

*Равил Фәйзуллин*

## Яз

Инде яз җитте,
Җирдә кар эреп бетте.
Салкын буранлы көннәр
Кыш белән узып китте.

Иртән тәрәзәләрдән
Кояш яктысы төшкән.
Нинди матур сайрыйлар —
Кошлар да килеп җиткән.

Җылы һавада йөреп,
Агымсуларны күреп,
Күңелләрем хушлана,
Язның рәхәтен белеп.

*Габделмәннан Рәхманколый*

**Фасыллар**

Ел эчендә дүрт фасыл,
Дүртесе дә бик асыл.

Елгалар ярына кайтты.
Ташулар басылдылар.
Кояшка карап, елмаеп,
Бөреләр ачылдылар.
Печән үсте, җиләк пеште,
Өзелеп, җиргә төште.
Кош баласы, җиләк кабып,
Үрелеп, сулар эчте.

Сайрар кошлар очып китте,
Болытлар яшен түкте.
Таң алдыннан чәчәкләрне
Кыраулар төшеп үпте.
Урамнарга ак мамыктан
Юрган сыра бураннар.
Ай-һай җылы юрган, диеп
Сөенәләр урамнар.

*Галиәхмәт Шаһиев*

**Булмагандыр буявы**

Көз килде дә тирә-юньне
Сары төскә буяды.
Яшелгә буяр иде дә —
Юктыр, ахры, буявы.

Тик сары төс агачларда
Бик озакка булмады.
Кыш килде дә бөтен җирне
Ап-ак төскә буяды.

*Вәкил Ахунҗанов*

## Кар астыннан чыкты яз

Иртә белән уянсак,
Бөтен дөнья агарган.
Түбәләргә, урамнарга
Актан да ак кар яуган.

Әбиебез: «Балалар,
Күрәмсез, кыш килде, — ди.
Көзне бөтенләе белән
Кар астына күмде», — ди.

Инде салкын кыш үтте,
Нурга чумды дөньялар.
Киң ярларын тарсынышып
Ташый инеш, елгалар.

Әбиебез: «Балалар,
— Күлләрдә боз купты, — ди. —
Без сагынган шау-шулы яз
Кар астыннан чыкты», — ди.

*Нәҗип Мадьяров*

## Җилкәй, исмә

Җилкәй, исмә, тукта син,
Төнгә давыл чыкмасын.
Бишегендә тынычлап,
Курчакларым йокласын.
Болыт, күкне каплама,
Балкып торсын кояшым.
Йокысыннан бары да
Шат елмаеп уянсын.

*Вәкил Ахунҗанов*

## Нәрсә ул җил?

— Кояшны, күкне, болытны
Күреп була, — ди Җәмил, —
Ә җилне бит күреп булмый,
Нәрсә соң ул, әни, җил?

—Соравың,улым,бикҗитди,
Җил — күзгә күренмәс кул!
Ботка ашамаганнарны
Этеп кенә ега ул!

*Ринат Мәннан*

## Яңгыр ява

Яңгыр ява! Яңгыр ява
Шыбыр-шыбыр.
Йөгереп чыга бала-чага,
Ыбыр-чыбыр.

Яшен яшьни, күкләр тетри
Дөбер-шатыр!
Курыкмыйлар, кулларында
Зонтик-чатыр...

*Илдар Юзеев*

## Яшенле яңгыр

Болыт килә үкереп,
Дөбер-дөбер иттереп.
Яшеннәрен уйната,
Шомлы уйлар уйлата.

Авыл турына җитә,
Яңгыр тетепме-тетә!
Без почмакка посабыз,
Бер-беребезне кочабыз.

Яшен гөлт итеп куя,
Йөрәк дерт итеп куя.
Күк күкри, дөбердәп,
Без ятабыз, дерелдәп.

Сөйләшәбез тын гына,
Тын гына, мыштым гына:
«Яңгыр бер узып китәр,
Болыт таралып бетәр.

Менә инде шулчакта
Без дә җаен табарбыз,
Күк күкрәгән кебек итеп
Дөбер-шатыр чабарбыз!»

*Гәрәй Рәхим*

## Кырау

Кичә генә бакчабыз
Шау чәчәк иле иде.
Иртән уянып баксам
Каралган барча гөле.

— Кырау суккан, — ди әни, —
Хараплар булган инде!
Ул тәртипсез кырауга
Яман ачуым килде.

Бакчаны ямьләп торган
Гөлләрем бик кызганыч.
Кырауның гүзәллекне
Аңламавы аяныч.

*Резеда Шәрипова*

## Томан

— Әтием, әйдә, бергәләп,
Балыкка төшик инде?
— Улым, су буена күз сал:
Томан бераз таралсын.
Балык тотарга, әлбәттә,
Төшәрбез без аннан соң.

— Әти, әти, әйдә, киттек.
Мин бит эшне яратам.
Су буеннан ул томанны
Үзем куып таратам.

*Нәҗип Мадьяров*

## Давыл

Юаш кына җил булып
Килеп керде авылга.
Әйләнде дә куйды ул
Коточарлык давылга.

Кубарды өй түбәсен,
Мунчаның кыекларын.
Бабам да гаҗизләнеп
Сыйпады мыекларын.

Әби йөрде, пошынып:
— Яңгырга бу, явымга...
...Килеп кергәч авылга,
Әйләнде җил давылга.

*Фирүзә Җамалетдинова*

**Өермә**

Урамда —
Өермә.
Син анда
Бик йөрмә,
Син анда
Тик йөрмә:

Кара син
Артыңа,
Карале
Як-якка,
Аннары аякка.

Кинәт җил
Өрмәсен,
Якында
Йөрмәсен
Һәм күрә
Күрмәсен.

Күрсәме —
Күтәрер,
Мең чакрым
Үтәлер.
Һавада
Бөтерер,
Башыңны
Бетерер.
Болытка
Эләрме,
Кояшка терәрме,
Йолдызга
Ташлармы, —
Аннары
Качармы?..
Калырсың,
Эленеп,
Җирдән үк
Күренеп —
Булмас һич
Үрелеп.
Меналмас
Әниең,
Меналмас
Әтиең...
Менә шул,
Тәтием...
Өермә
Булганда
Йөрмә син
Урамда!

*Ленар Шәех*

## Ай белән кояш очрашкач

Менә сиңа тамаша,
Күрсәң күзләр камаша —
Ай белән кояш күктә
Очрашканнар лабаса!

Бу нәрсә була инде:
Көнме соң, әллә төнме?
Саташып алар шулай
Йөзәрләр икән күпме?

Мин борчылганны сизеп
Карады кояш, көлеп,
Аңлады бугай ай да,
Юк булды шундук, эреп.

Тынычлап калдым мин дә —
Тәртип кирәк һәр җирдә!

*Резеда Шәрипова*

## Саташкан табигать

Әллә кайчан тау битләре
Кардан ачылган иде,
Елгалар да ярдан чыгып,
Ташу ташыган иде.

Кошлар, җылы яктан
кайтып,
Оялар корган иде,
Көннәр дә кояшлы, матур,
Бик җылы торган иде.

Кайдан купты бу ак буран?
Кыш кабаттан килгәнме?
Китмәс борын ук, балалар
Сагынган дип белгәнме?

Юк инде, кыш,
син ялгышма,
Язга бир тулы ирек!
Күңелләрне без бит язга
Ачтык инде, киереп.

*Резеда Шәрипова*

## Чүмеч йолдыз

Чүмеч йолдыз яши күктә, —
Төнлә чыгып карагыз.
Балкып җемелди башласа,
Гел яхшыга юрагыз!

Бу йолдызның күк йөзендә
Эше җайлы көйләнгән.
Ул һәр таңда сихри суын
Сибеп чыга үләнгә.

«Чык» диләр аны кешеләр,
Чык — суның иң чистасы.
Чүмеч йолдыз — йолдызларның
Иң шәбе, иң остасы!

*Галимҗан Гыйльманов*

## Яңа һәм иске ай

Кискән кабак телеменә
Охшап тора үзе бик.
Кайсы якка каравыннан
Исеме үзгәрә тик:

Уңга таба кырын ятса,
Яңа туган ай була.
«Иске ай» диеп йөртәләр,
Кырынайганда сулга.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Алмалар ничек кызарган?

— Әни, — дип йөгереп керде
Тыштан Вәсилә.
— Нәрсә булды? Ни бар, кызым?
Тыңлыйм, йә, сөйлә.

— Әни, безнең алмаларның
Бите кызарган,
Элек алай түгел иде,
Кемдер буяган.

— И кызым, — диде әнисе,
Иркәләп аны. —
Кешеләр бакчада буяп
Йөрмиләр аны.

Сиңа ашарга бик тәмле
Булсыннар диеп.
Кояш кызарта аларны,
Нурларын сибеп.

— Әни, кояш кызыл төсне
Кайдан ала соң?
— Анысын, кызым, укырга
Кергәч аңларсың.

Әнисен тыңлап, Вәсилә
Елмаеп куя.
Хәзер үк үзен укучы
Иттереп тоя.

*Нәҗип Мадьяров*

## Балан

Җимеш кирәк бәлешкә,
Барыйк икән кай төшкә?
— Җимеш-җимеш, син кайда?
— Баланда мин, баланда.
— Балан-балан, син кайда?
— Болында мин, болында.
— Болын-болын, син кайда?
— Түгәрәк күл буенда.
— Түгәрәк күл, син кайда?
— Тугайда, кил, мин монда!
Тугайда күлне күреп,
Болын эченә кереп,
Баланның иң кызылын
Җыеп йөрдек көнозын.
Балан-балан бал гына,
Тәмле икән җимеше.
Әнигә — туган көнгә
Бүләк булды бәлеше.

*Нәҗип Мадьяров*

## Чыршының күлмәкләре

Яшь чыршылар киң итәкле
Күлмәкләрен кигәннәр.
Җитәкләшеп, бергәләшеп,
Юл буена килгәннәр.

Энәле күлмәкләренә
Карап тордык, сокланып.
Тик Равил берничә энә
Өзеп алды, шукланып.

Апа әйтте: «Болай эшләү —
Начар гадәт, бел менә:
Һәр чыршы күлмәк алыша
Җиде елга бер генә.

Без энәләрен йолкысак,
Чыршы күлмәксез калыр,
Җиде ел буена ничек
Күлмәксез яши алыр?»

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Ап-ак икән эзләрем

Ап-ак кардан да аграк
Яңа бияләйләрем.
Салкын була кышын дип,
Дәү әнием бәйләде.

Ап-ак куян кебек ак
Башлыгым да, туным да.
Бик җылы һәм бик йомшак,
Шуңа күрә туңмыйм да.

Итекләрем... кап-кара.
Куркып торам кияргә...
Үпкәләр, дим, Кыш бабай,
Карны буйый, дияр дә...

Чыгып чаптым шулай да,
Таудан чана шуарга.
Юлга төшсә күзләрем —
Ап-ак икән эзләрем...

*Лена Шагыйрьҗан*

## Маратка нәрсә җитми?

Аквариумда су тынчу...
Балыкларга һава җитми!
Корылыктан чүлмәкләрдә
Гөлләр сула, су-дым җитми!

Маратның җитеш һәммәсе!
Уйный-чаба, чаба-уйный!
Урамда саф һава сулый.
Тәмләп чишмә суы эчә...

Шулай да аңа бер бик кирәк
Нәрсә җитми, безнеңчә!
Ул ни икән, сезнеңчә?

*Равил Фәйзуллин*

## Җәнлекләр

Куркак куян, болан, поши,
Төлке, аю һәм бүре —
Кышкы туннарын салалар
Яз җитүгә һәрберсе.

Җәнлекләрнең йон койганын
Кызылтүш күзләп тора
Һәм, аларны ваклап ташып,
Бик матур оя кора.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Кәгазь

Без укый торган китаплар,
без яза торган дәфтәрләр,
без карый торган альбомнар
башта — агач булганнар.
Яфрак ярып, җилдә шаулап,
Җирдә басып торганнар.

Аннан аларны екканнар,
чапканнар да кискәннәр...
Машиналардан үткәреп,
юка кәгазь иткәннәр.
Алдымда — чиста ак кәгазь, —
Нинди агачтан икән?

Каеннанмы, нараттанмы,
әллә усактан микән?
Аның урынына яңаны
кемдер утырткан микән?..
...Уйлап тордым да ясадым
кәгазьгә бер имәнне.

Ясадым мин имәннең
шәбен — менә дигәнне!
Очы күккә тигәнне,
мәңге үсеп торырлыкны.
Кош оя корырлыкны.
Күргән кеше шатлансын.

Кәгазьдә генә булса да,
тагын бер агач артсын!

*Равил Фәйзуллин*

## Күгәрчен

Безнең тәрәзә башына
Көн дә куна күгәрчен.
Мин аңарга ярма сибәм,
Матур гөрләсен өчен.

Кечкенә тәпиләренә
Кигән ул кызыл оек.
Мин ярма сипмәгән көнне
Күгәрчен була боек.

Боекма син, күгәрченкәй,
Үз өең, гөрлә, кагын.
Энҗедәй ярма сибәрмен,
Иртәгә килсәң тагын.

*Нур Гайсин*

## Сыерчыклар

Җылы яктан очып килде
Сыерчыклар-кошкайлар.
— Исәнмесез, малайлар! — дип
Дәшә безгә дускайлар.

Куанышып сайрашалар
Кояшлы, аяз күктә.
Без аларга кул болгыйбыз:
— Оябыз әзер күптән.

*Ләбиб Лерон*

## Файдалы чәүкәләр

Апрельдә һәрчак
Тормыш җанлана,
Тынлык югала:
Безнең чәүкәләр
Оялар кора,
Чыгара бала.

Бәләкәчләргә
Көл-көрән кошлар
Корт-бөҗәк ташый.
«Пи-пи-пи, рәхмәт!» —
Кошчыклар тәмләп,
Яратып ашый.

Чәүкәләр, үскәч,
Гаскәрләр булып,
Кырларны яулый:
Бөҗәкләр ашый.
Көзен басуда
Әрәмгә, тиккә
Бөртекләр калмый.

*Айдар Җамалиев*

## Чыпчык

Тәрәз каршына
Килгән бер чыпчык.
Миңа кычкыра:
— Чык әле, ди, чык.

Алдый ул, беләм,
Гел шулай итә.
Йөгереп чыксам
Оча да китә.

*Фәнис Яруллин*

## Нәни дусларым

Чырык-чырык килеп янда,
Чыпчыклар серләшәләр.
Җим сипсәнә диеп, миңа
Әйтерсең эндәшәләр.

Кулымдагы икмәгемне
Бүлешәм алар белән.
Канатларын җилпи-җилпи,
Рәхмәт әйтәләр, беләм.

*Лиана Әмирханова*

## Беләсезме?

Урманда «тр-р-р!» ди саескан,
«Кар-кар!» ди кара карга.
«Кар-кар-кар!» суга тукран кош —
Билгеле болар бар да.

Ә менә бер кош «күк-кү!» дип
Кычкыра, бер дә талмый.
Тик мин ул кошның исемен
Искә төшерә алмыйм.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Яу-яу

Кызу чагы көннәрнең.
Яңгыр көтә гөлләрем:
— Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!

Яңгыр көтә
Бакчабыз,
Яңгыр көтә
Барчабыз:
— Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!

Яңгыр килде,
Яңгырап,
Каршы алдык
Без, җырлап:
— Кил, яңгыр, яу-яу!
Яу, яңгыр, яу-яу!

*Рөстәм Мингалим*

## Гүзәл

Гүзәл беркөнне
Бакчага керде,
Агачта матур
Ак чәчәк күрде.

Нәни кулларын
Тырышып сузды,
Чәчәкне өзеп
Алмакчы булды.

Чәчәк елмаеп
Әйтте Гүзәлгә:
— Ярамый, Гүзәл,
Мине өзәргә.

Өзмә син мине,
Өзмә, Гүзәлем,
Өзсәң, мин сиңа
Алма бирмәмен.

*Максуд Сөндекле*

## Урманда

Кояш көлеп торганда
Килеп кердек урманга.
Урман безне кумады,
Без бит аның кунагы.
Җиләк белән сыйлады,
Шатлык эчкә сыймады.

*Заһирә Гомәрова*

## Миләш

Кызыл болыт кунганмыни
безнең бакча түренә!
Минем яраткан миләшем
быел шулай күренә.

Теләсәң, как итеп кой!
Теләсәң, әчетеп кой!
Теләсәң, тәлгәше белән
киптерергә элеп куй!

Әй быел миләш, миләш!
Күзнең явын алырлык!
Очларына кул җитмәде,
чыпчыкларга калдырдык.

*Равил Фәйзуллин*

## Әбием сүзләре

Исеме балан булса да,
Баллы түгел ул балан.
Менә сиңа шул баланнан
Бәлеш салам мин, балам.

Пешеп чыккач, бәлеш йөзе
Алма кебек алланыр.
Татлы булыр баланы да —
Шикәр кебек балланыр.

*Җәүдәт Дәрзаман*

## Мәк чәчәге

Мәк чәчәге — кызыл ефәк,
Сокланып карыйм аңа.
Әни әйтә: «Мәк чәчәге
Күзләрен ача таңда».

Көндезге ике тулганда,
Күзләрен йома икән.
Кичләрен бөрешеп тора,
Салкында туңа икән.

*Самат Шакир*

## Күбәләк

Кызым, синең эшең бик күп:
Бакчага барасың да
Күбәләк куып йөрисең
Чәчәкләр арасында.

Чәчәккә кунган күбәләк
Күзен йомып утырмый,
Канат җәеп очып китә,
Еласаң да тоттырмый.

Кума, кызым, күбәләкне,
Бакчабызда йөрсен ул,
Кунсын йомшак чәчләреңә,
Бантик булыр торсын ул.

*Фатих Кәрим*

## Бездән үрнәк алыгыз

Кырмыскалар, мескенкәйләр,
Зур итеп тау өйгәннәр.
— Безнең йортыбыз була бу,
Туздырмагыз, — дигәннәр. —

Ерактан күренеп торсын
Өчен, шулай төзибез.
Әгәр сез борчымасагыз,
Без дә сезгә тимибез.

Әле сезгә булышабыз,
Сезгә файда итәбез.
Урманнарны чистартабыз,
Ерак юллар үтәбез.

Бик сирәк кенә булса да,
Безнең яннан узыгыз.
Безгә карап торыгыз да
Матур тормыш корыгыз».

*Мөҗәһит*

## Сыер

Сыер әйтә: «Мин кайттым,
Сөткә чиләк алып чык,
Имчәкләремне сөртергә
Чиста чүпрәк салып чык.

Чиләк шыбыр-шыбыр яуган
Җылы сөт белән тулыр.
Пары чыгып торган сөтем
Эчәргә тәмле булыр».

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Замана бозавы

Шундый кызык
Бозау бу.
Бар бозауны
Уза бу.

Башкалар:
— Му-у-зыка! — дисә,
— Му-у-льтфильм! — дип
Кыза бу!

*Афзал Нигъмәтуллин*

## Танышмак өчен табышмак

«Үти-үти!» — дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«Кыйгак-кыйгак», — дип
килерме,
Кем җавап бирер?
«Ти-ти-ти-ти!» — дип чакырсам,
Миңа кем килер —
«Бак-бак, бак-бак», — дип
килерме,
Кем тавыш бирер?
«Дөгә-дөгә, дөгә!» — дисәм,
Миңа кем килер —
«Кыт-кыт, кытыйк», — дип
килерме,
Кем җавап бирер?

«Маh-маh, маh-маh!» — дип
чакырсам,
Миңа кем килер —
«Мияу-мияу», — дип килерме,
Кем тавыш бирер?
«Пес-пес, пес-пес!» — дип
чакырсам,
Миңа кем килер —
«Һау-һау, һау-һау!» — дип
килерме,
Кем җавап бирер?
Кайчан да кайчан барсы да
Дөп-дөрес килер,
Әнием шулчак аларга
Ашарга бирер:

Үрдәккә — ботка салыр,
Тавыкка — тары сибәр,
Казга — бәрәңге изәр,
Маэмайга — шулпа куяр,
Ә песигә — сөт кояр!

*Шәүкәт Галиев*

## Ат

Аттан башлыйк без сүзне:
Ат була ике күзле,
Ике колак, дүрт аяк,
Һәр аяк саен тояк.
Тоякка каксаң дага,
Бахбай таймыйча чаба.

*Эдуард Мостафин*

## Безнең ишегалдында

### Әтәч

«Кикрикүк!» — дип, таң белән
Йокыдан уятучы.
Ул — иң иртә торучы
Һәм иң иртә ятучы.

### Үрдәк

Күлгә таба йөгерә,
Җиргә басып лап та лоп.
Күпләп су эчә, ашый,
«Бак-бак», — диеп мактанып.

### Каз

«Кыйгак-кыйгак» килә дә
Бермәлгә уйга кала.
Шәп итеп суда йөзә
Һәм бераз оча ала.

### Дуңгыз

Дуңгыз рәхәткә чыккан:
Һаман җирне актара.
«Мырык-мырык» сөйләнә,
Ә борыны кап-кара.

### Сарык

«Бә-ә-ә!» — ди сарык.
Әтием
Аңа печән, он бирә.
Оекбаш, бияләйгә
Сарыгыбыз йон бирә.

### Ат

«Иһа-һа-һай», — дип кешни,
Арба тарта, йөк ташый.
Чабышка да чыга ул,
Аннары солы ашый.

*Ленар Шәех*

## Куяннарым

Хуш исле үләннәр салсам
Әгәр дә алларына,
Куяннарым йөгерешеп
Киләләр яннарыма.

Бары да озын колаклы,
Барысы да йомшаклар.
Беләсезме? Миннән генә
Курыкмый бу куркаклар.

*Нәҗип Мадьяров*

## Песи

Ал тасмадай теле белән
Чип-чиста итеп ялап,
Песиебез битен юа,
Ишеккә таба карап.

Шомарта йомшак күлмәген,
Койрыгы буйлап үтә.
Үзен тәртипкә китереп,
Песи кунаклар көтә.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Атна

Бер-ике, бер-ике,
Өч, дүрт, биш, алты, җиде.
Дүшәмбе һәм сишәмбе,
Чәршәмбе, пәнҗешәмбе,
Аннары килә җомга —
Без йөрибез бакчага.
Шимбә һәм якшәмбедә
Бар да булабыз өйдә.
Әни бәлеш пешерә,
Канәгать бар кеше дә!

*Рафис Корбан*

## Бер атнада ничә көн?

Бер атнада ничә көн?
Бер атнада җиде көн.
Җиде төрле исеме —
Җидесен дә яттан бел.

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе
Пәнҗешәмбе, җомга,
Шимбә, якшәмбе —
Онытма мәңге!..

Шимбә белән якшәмбе —
Икесе — ял көннәре.
Ял көннәре — атнаның
Чәчәкләре, гөлләре.

Ял көннәре — атнаның
Чәчәкләре, гөлләре.
Атнаның яфраклары, —
Димәк, калган көннәре.

*Гөлшат Зәйнашева*

## Тәүлек

**Иртә**

Ал таң ата, нурлы кояш
Балкып чыга.
Бөтен халык кузгала да
Эшкә чума.

**Көндез**

Йөзә кояш зәңгәр күктә,
Кайный эшләр.
Бераз гына туктый ялга
Бар кешеләр.

**Кич**

Ялыккандай талгын гына
Кояш бата.
Шунда һәркем, эштән туктап,
Өйгә кайта.

**Төн**

Бөтен дөнья төренеп ята
Караңгыга.
Арыган халык чума шунда
Тын йокыга.

*Әнәс Кари*

## Бу кайвакыт? Әйт, балам!

Күз төпләрен угалап,
Кояш уянып килә...
«Кик-ри-күк!
Торыгыз!» — дип,
Әтәч куанып көлә.
Кеше эшкә кузгала —
Бу кайвакыт? Әйт, балам!
*(Иртә)*

Сайрар кошлар «чут» та «чут»
Гөрләшә дә серләшә.
Агачларның яфраклары
Лепер-лепер сөйләшә...
Күктә кояш чайкала —
Бу кайвакыт? Әйт, балам!
*(Көндез)*

Ак болытлар, кызарып,
Еракларга юл ала.
Биек таулар артына
Кояш кереп югала...
Көн сүрелә кай ара —
Бу кайвакыт? Әйт, балам!
*(Кич)*

Тәрәзәдән ай карый,
Йолдызлар җем-җем яна.
Акрын гына, талгын гына
Тынлык иңә дөньяга...
Кеше йокыга тала —
Бу кайвакыт? Әйт, балам!
*(Төн)*

*Ләбиб Лерон*

## Көн һәм төн

Өйләрдә ут алынгач,
Күктә йолдыз кабынгач,
Көн инде үткән була,
Төн килеп җиткән була.

Диванда күптән инде
Курчагым көтә мине.
Менеп ятам сак кына,
Күзне йомам чак кына.

Ә карасам бераздан,
Күз чагыла нурлардан.
Төн инде үткән була,
Көн килеп җиткән була.

*Гөлфия Юнысова*

## Кайсы ай бу?

Яңа елда яңа кар
Җемелдәр дә елкылдар.
Агачлар көмеш кенә —
Торсын шул килеш кенә!
Коры суык урамда
Кайсы айда? *Гыйнварда.*

Юлда — җәяүле буран,
Көрткә күмелә урам.
Кояш толыбын сала,
Бераз кар көрәп ала.
Бетми кар көрәп кенә
Кайсы айда? *Февральдә.*

***

Тамчы тама кыектан,
Турылап та кыеклап.
Тамчы тама тып та тып:
«Булмый язны туктатып!»
Төнлә суык шарт та шарт.
Кайсы ай бу?
Әйе*, март!*

Ага юлдан гөрләвек,
Кар эчендә күлдәвек.
Агачларда бөреләр
Җиләк кебек эреләр.
Тауда үлән терелә
Кайсы айда? *Апрельдә.*

***

Шау чәчәктә агачлар —
Чияләр, алмагачлар.
Ак болыт төшкән кебек,
Шомыртлар ап-ак күбек.
Тынмый кошлар сайравы.
Кайсы ай бу? *Май ае.*

Сабантуй колгасыдай
Көннәре бик озын ай.
Гөрләп тора су буе,
Болында — Сабан туе.
Беркем ятмый өендә
Кайсы айда? *Июньдә.*

***

Иртән чык төшкән вакыт,
Җиләкләр пешкән вакыт.
Әзерләп әйрән-катык,
Печәнгә төшкән вакыт.
Чаң-чоң чалгы чүкелә
Кайсы айда? *Июльдә.*

Кырларны һаман уйлап,
Чормада ята урак.
Болытлар йөри урап,
Кырларда йөри кораб.
Яңа икмәк сала оста
Кайсы айда? *Августта.*

***

Кошлар оча, төркемләп,
Яңгыр ява, иркенләп.
Кояш чыгып алгалый,
Моңсу караш салгалый.
Агач сары төстәдер.
Кайсы ай бу? *Сентябрь.*

Иртәләрен туң төшә.
Күңелләргә моң төшә.
Көн яктысы карала.
Яңгыр катыш кар ява.
Кояш кайсы яктадыр?..
Кайсы ай бу? *Октябрь.*

***

Болытлар — кара шәлдә,
Агачлар — кара шәүлә.
Карлар ява китмәскә,
Җирне шәрә итмәскә.
Көз югалды каядыр.
Кайсы ай бу? *Ноябрь.*

Соңлап кына көн туа.
Чәй эчкәнче, төн туа.
Ай яктысы астында
Балалар чана шуа.
Ел ахыры икәндер.
Кайсы ай бу? *Декабрь.*

*Нәкыйп Каштан*

## Нигә кирәк шкафлар?

Нигә кирәк шкафлар? —
Киемнәрне эләргә.
Киштәсенә күп китаплар,
Сувенирлар тезәргә.

Нигә кирәк шкафлар? —
Савыт-саба куярга.
Тартмасына төрле әйбер,
Ашамлык тутырырга.

Нигә кирәк шкафлар? —
Капкачларын ачарга...
Качышлы уйнаганда,
Эчкә кереп качарга.

*Гөлфия Юнысова*

## Пешкән, әллә пешмәгән

Мин йомыркалар пешерәм
Кухняда әни белән,
Аларның пешеп җиткәнен
Тикшереп карый беләм.

Моның өчен әйләндерәм
Алып йомыркаларны.
Кайсылары шәп әйләнә —
Пешкән була алары.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Куркыныч уй

Интернетка керсәк тә без
Йә уен уйнасак та,
Тычканны ычкындырмыйбыз,
Без песи булмасак та.

Олысы да, кечесе дә
Шул тычканга тотынган.
Күзләр экранга төбәлгән,
Китап кына онтылган.

Элек тычканнарны тоткан
Уңган песиләр генә.
Ә бүген тычканны тота
Һәммә кешеләр менә.

Кеше тычкан тотып кына
Китапларны оныпса,
Гаҗәп түгел, беркөн аңа
Койрык һәм.. мыек чыкса...

*Йолдыз*

## Минем дусларым

Дусларым — уенчыкларым,
Менә алар, күрегез.
Таныштырып чыгыйм әле,
Һәммәсен дә белегез.
Бу менә — минем атым,
Атым — минем канатым,
Акыллы да, матур да,
Кыю да ул, батыр да.
Аюым бакчада тора,
Карурманда туса да,
Уйнарга бик ярата,
Үзе ялкау булса да.

Зәңгәр күзле курчакларым
Сөйләшә дә беләләр.
Үчти-үчти иттергәндә,
Чырык-чырык көләләр.
Паровозым гудок бирә,
«Төялегез, китәм! — ди. —
Барыгызны да, утыртып,
Сабантуйга илтәм», — ди.
Шау-гөр килеп төялешеп,
Сабантуйга барабыз.
Мин киләм, атка атланып,
Алдан чаба паровоз...

Менә шулай уйныйбыз без,
Дусларым белән бергә,
Янда дусларым булганда,
Күңелсез түгел бер дә.

*Резеда Вәлиева*

## Тылсымчы

Тылсымчы бар һәр өйдә,
Изгелектә — бар эше.
Аның тылсымнарына
Өйрәнеп беткән кеше.

Кич җитсә дә, кайгы юк,
Балкып тора өй эче.
Урамда да яп-якты,
Йөри бир теләгәнчә.

Утынсыз да, газсыз да
Шәп җылыта бит миче.
Плитәсе аш пешерә,
Юк төтене, юк исе.

Кер юа. Идәннәрне
Чүп-тузаннан тазарта.
Кайчан теләсәк, шунда
Телевизор карата.

Үтүкләрне кыздыра,
Магнитофон җырлата...
Тылсымчының эшләрен
Чыгып булмый санап та.

Тылсымчы бар һәр өйдә,
Изгелектә — бар эше.
Белмәсәгез белегез:
Ул бит электр көче.

*Гөлфия Юнысова*

## Без — төзүчеләр

Шакмаклардан өй салабыз
Тырышып барыбыз да:
Рәхәтләнеп яшәсеннәр
Курчак дусларыбыз да.

Бүлмәләре шундый якты,
Кояш балкыган сыман,
Кәгазь чәчәк-гөлләреннән
Хуш ис аңкыган сыман.

Үсеп җиткәнебезне дә
Сизми калырбыз әле.
Түбәләре күккә тигән
Йортлар салырбыз әле.

*Хәкимҗан Халиков*

## Тегермән

Әбинең туган көненә
Бүләк иттек тегермән.
«Хәзер кофе тарттырырга
Кибеткә барып йөрмәм, —

Дип сөенә әбиебез, —
Мәшәкатьтән котылдым».
Әби күршегә кергәч,
Тегермәнгә тотындым.

Әй тарттырам чикләвекне
Кабыгы-ние белән.
Әйләнеп тора тегермән,
Мин шатлыгымнан көләм.

Тарттырдым мин бәрәңге дә,
Тарттырдым кишер, кыяр...
Мин тарттырган нәрсәләрне
Ашаса, фил дә туяр.

Тарттырдым мин борыч, суган,
Тарттырдым мин алманы.
Өебездә тарттырмаган
Бернәрсә дә калмады.

— Син тарттырдыңмы?— диеп, әби
Аһ-уһ килде, шаккатты...
...Әйе, әйе, үзем тарттым,
Колакны әби тартты.

*Разил Вәлиев*

## Без ничәү?

Бербөтен зур алманы без
Ике өлешкә бүлдек.
Һәммәбезгә дә җитсен ул,
Юк, болай булмый, дидек.

Тагын бүлдек без аларны
Тип-тигез кисәкләргә,
Инде җитә микән диеп
Керештек исәпләргә.

Җитми икән. Барысын да
Урталай бүлдек тагын.
Шуннан бөтенебезгә дә
Җиткәнен белдек аның.

Йә, исәпләп карагыз!
Барысы ничә кисәккә
Бүленде соң алмабыз?

*Нәҗип Мадьяров*

## Саныйм әле

Биш карлыгач тезелгән
Телефон чыбыгына.
Тагын дүртәү өстәлде,
Көткәндәй шуны гына.

Бераз сайрап утыргач
Очып китте өчәве.
Саныйм әле: чыбыкта
Калды икән ничәве?

*Хәкимҗан Халиков*

## Үзебезчә бүлдек

Иртән әни өчебезгә
Бирде ике мандарин.
«Үзегезчә бүлегез», — дип
Өстәп куйды аннары.

Берсен, тизрәк үссен диеп,
Энебезгә бирдек без.
Икенчесен сеңлем белән
Кыл урталай бүлдек без.

*Хәкимҗан Халиков*

## Мин ничә яшьтә?

Ничә яшьтә икәнемне
Әйтмим әле мин сезгә.
Башыгызны эшләтсәгез
Белерсез үзегез дә.

Минем исем Айдар инде,
Ансын белеп торасыз.
Ул исем ничә хәрефле?
Белмәсәгез сорарсыз.

Шул санга минем исемнең
Иҗек санын кушыгыз.
Шуннан яшем килеп чыгар,
Ә хәзергә хушыгыз.

*Мөҗәһит*

## Төшемә керде

Мин телевизор карыйм,
Шуңа беркая бармыйм.
Кирәклесен дә карыйм,
Кирәксезен дә карыйм.

— Әни, ашарга китер,
Карыным ачты никтер.
Кухняга чыга алмыйм,
Мин телевизор карыйм.

Кайчагында арыймын,
Арысам да туктамыймын.
Күзләрне уа-уа,
Йокыны куа-куа
Карыймын да карыймын.

Карый торгач өзмәстән,
Үзем һич тә сизмәстән,
Ахры, мәлҗеп җиткәнмен,
Кинәт йоклап киткәнмен.

Төш күрдем мин шулчакта.
...Телевизор почмакта:
— Туймасҗан син, кызган, ди.
Бертуктаусыз карагач,
Мин бик каты кызам, ди.
Сүндереп тор, ял иттер,
Юкса бик тиз тузам, ди.
Белмим, әллә куркудан
Уяндым мин йокыдан.
Карыйм телевизорга,
Яп-якты анда экран.
Бик тиз янына бардым,
Шнурны токтан алдым,
Эшләвеннән туктаттым,
Инде аны йоклаттым.
Үзем уйлыйм: юкса гел
Төшкә кереп йөдәтер.
Ахрысы, моннан ары
Телевизор карауны
Сирәгәйтү кирәктер.

*Мөҗәһит*

## Ничә көннән?

«Бер атнадан кайтам», — диеп,
Әти читкә киткән иде,
«Бер көн үтте, ике көн...» — дип,
Зилә шундый көткән иде,

Әти кайтты атнадан соң
Тагын ике көннән генә.
Ничә көннән кайткан
инде?
Ягез әле, кемнәр белә?

*Хәкимҗан Халиков*

## Шәһәр төзим

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкле урамнарда
Машина чабып торыр.

Шәһәрнең уртасыннан
Зур елга агып торыр.
Йөзеп арган көймәгә
Дулкыннар кагып торыр.

Бу шәһәрдә кошларга
Таш атмаслар малайлар,
Усал малайлар күреп
Шаккатмаслар агайлар.

Абыйлар һәм апалар
Бик-бик тату яшәрләр,
Бер-берсенә һәрвакыт
«Исәнме!» дип дәшәрләр.

Төзүче булыр әти,
Әни булыр тегүче.
Абый белән без икәү —
Машиналар йөртүче.

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкләр, агачларга
Тамчы сибелеп торыр.

Чәчәкләр биеп торыр,
Гел «рәхмәт!» диеп торыр.

*Рәшит Бәшәр*

## Чия

Пешкән чия — кызыл ут,
Чия җыйдым бер савыт.
Җиргә куйдым, тулгач ук,
Йөреп килсәм — савыт юк.

Үләннән алсам табып,
Савытым киткән авып,
Калган бары ун чия,
Ул чия кемгә тия?

Әни ашар өч чия.
Әти ашар өч чия,
Ә икесен — Гөлсинә,
Ничәсе миңа тия?

*Гөлфия Юнысова*

## Хисап мәсьәләләре

**Кушу**

Без... без... без идек,
Без биш кенә кыз идек.
Килеп керде Хәдичә,
Хәзер инде без ничә?

**Алу**

Без... без... без идек,
Без бит сигез кыз идек.
Китеп барды бишәвебез,
Хәзер калдык ничәү без?

**Тапкырлау**

Без... без... без идек,
Без ничәдер кыз идек.
Өч пар булып тезелдек,
Хәзер ничәү без инде?

**Бүлү**

Без... без... без идек,
Без... без... алты кыз идек.
Алты телем алма телдек,
Ничәшәр телем бүлдек?

*Бари Рәхмәт*

## Ничә сәгать кызынганбыз?

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Атна буе һәр көн без
Берәр сәгать кызындык.

Ничә сәгать кояшта
Кызынганбыз һәммәбез?..
Уйлыйк әле, әйдәгез.

*Хәкимҗан Халиков*

## Бармак уеннары

*Уенчыкларның исемнәрен әйтә-әйтә, балалар бармакларын бөгеп баралар.*

* Бабай алды барабан,
Әби алды бөтерчек,
Әти алды машина,
Әни алды сикергеч,
Ә мин алам бер зур туп,
Уйныйм, тупны сикертеп.

* Баш бармагым туп була,
Имән бармак — бөтерчек.
Урта бармак була шакмак,
Атсыз бармак — сикергеч.
Чәнти бармак — барабан,
Сана, әйдә, яңадан.

* Бу бармак — кыяр,
Бусы — кәбестә,
Бу бармак — кишер,
Бусы — чөгендер,
Ә бусы суган булды —
Менә кәрзинем тулды.
(*бармакларны йодрыклыйлар)*

* Баш бармак була бүре,
Имән бармагым — төлке,
Урта бармагым — керпе,
Атсыз бармагым — аю,
Чәнти бармагым — куян,
Куянны кая куям?

*Фәрсия Зиннурова*

***

## Төлке белән Аю

*(Мари халык әкияте)*

Бервакыт Төлке белән Аю юлда калач табып алганнар. Урман йортына кереп, калачны урталай бүлгәннәр: яртысы — Аюга, яртысы Төлкегә тигән.

Төлке үз өлешен шундук ашап бетергән. Ә Аю кабып кына караган да соңрак ашарга калдырган.

Йокларга яткан болар. Аю хырылдый башлауга, Төлке аның өлешен дә ашап куйган.

Төнлә Аю уянган. Калачын ашарга теләгән. Әмма аннан җилләр искән. Аюның бик каты ачуы килгән.

— Болай булгач, мин сине ашыйм, Төлке, — дигән.

— Гаеплемен, абзыкаем, синең алда. Ашасаң ашарсың инде. Әмма минем итем пешергәч тәмлерәк була, — ди икән Төлке.

— Мич кабызырга ут юк ич!

— Әнә бит ут, — дип, айга күрсәтә икән Төлке.

— Ул ут бик биектә ич, алып булмый.

— Биеген биек тә соң, әнә теге чыршы башына менсәң алып була! Мен, абзыкаем, курыкма, — дип үгетли моны Төлке.

Аю кулына чыра тота да чыршы башына үрмәли. Чыраны айга сузып карый, буе җитми.

— Ыграк үрел, абзыкаем! — дип өйрәтә Төлке тегене, җирдән торып, — әз генә үреләсең калды. Сикер, сикер, шундук җитәсең!

Аю Төлкене тыңлап сикергән икән, чыршы башыннан түбән тәгәрәгән. Әз генә үлми калган, ә Төлке табанын ялтыраткан.

## Аю койрыгы

*(Индонезия халыклары әкияте)*

Иртән торып, Тиен куак төбендә чикләвек ашап утыра икән. Шулчак агач арасыннан Юлбарыс килеп чыккан. «Бетте баш», — дип уйлаган Тиен һәм куркудан калтырый башлаган. Инде нишләргә? Авызына капкан чикләвекне шартлатып ваткан да кычкырып җибәргән бу:

— И тәмле дә соң Юлбарыс күзе!

Моны ишеткән Юлбарыс туктап калган. Аннары, әкрен генә артка чигенеп, яңадан агачлар арасына кереп югалган.

Урман буйлап качып барганда, Юлбарыска Аю очраган.

— Юлбарыс күзе ашаучы ерткычны белмисеңме син, дустым? — дип сораган ул Аюдан.

— Белмим, — дигән тегесе.

— Әйдә, бергә барып карыйбыз, — дигән Юлбарыс.

— Бармыйм мин, куркам, — дигән Аю.

— Курыкма, — дип юаткан аны Юлбарыс. — Әйдә, койрыкларыбызны бер-берсенә бәйләп куйыйк. Теге ерткыч минем өскә ташланса, син тартып алырсың.

Шулай ике койрыкны бергә бәйләгәннәр дә Тиен өненә таба юл тотканнар болар. Аю белән Юлбарыс килгәнне күргәч, Тиен урман яңгыратып кычкырып җибәргән:

— Карале, бу хәйләкәр Юлбарыс мине тагын алдамакчы бугай. Мин аңа иртәнге ашка ак Аю китерергә кушкан идем, ә ул соры Аю биреп котылмакчы була...

Моны ишеткәч, коты чыккан Аю агач арасына сикергән. Үзе исән калган, тик койрыгы гына өзелгән, ди, аның. Менә шуннан бирле аюлар кыска койрыклы булып калган.

Ә Тиен, бернигә исе китмичә, әле һаман өнендә чикләвек ашап утыра икән.

## Әтәч ни өчен өч вакыт кычкыра?

*(Әкият)*

Борын-борын заманда Әтәчнең йон-каурыйлары бик тә зиннәтле, салават күпере кебек гүзәл булган. Аңа карап, һәммәсенең күзе янган.

Ә Тавис кош ул чакта гади генә киенеп йөргән. Мактанчык Әтәч аннан көлгән. Шуннан Тавис бер хәйлә уйлаган һәм Әтәч янына юл алган.

Тавис Әтәчкә әйткән: «И генерал әфәнде, и гүзәл Әтәчкәй, ярдәм сорап килдем сиңа. Өйләнергә исәбем бар, киемеңне биреп торчы миңа. Әгәр анда озаграк торсам, таң атуга, мине чакырырсың. Тавышың бик көчле һәм матур. «Китереп бир!» — дип кычкырырсың. Иртә белән кайтмасам, өйлә җиткәч кычкырырсың, өйлә җиткәч күренмәсәм, кич җиткәчтен кычкырырсың».

Тавис тәмле теле белән юмалап сораган. Әтәч киемнәрен салып биргән, каршы килә алмаган.

Иртәгесен Әтәч читән өстенә очып кунган һәм: «Китереп бир! Китереп бир!» — дип кычкырган. Тавис китермәгән, күрәсең, ычкынган. Төш вакытында тагын кычкырган Әтәч, ә Тавис күренмәгән. Кич җиткәч тә кычкырган. Тавис юк та юк икән.

Шуннан бирле Әтәч көн саен Тависка: «Китереп бир!» — дип кычкыра. Тавис килми дә килми.

## Ашыгыч ярдәм

Айдар кошларны ярата. Кыш көннәрендә бакчадагы җимлеккә җим салырга бер дә онытмый. Ә җәй көннәрендә әнисенә тавык, чебеш, каз, үрдәкләрне карарга булыша.

Бүген ишегалдында тагын ике ят кош күрде ул. «Әтием күркәләр алып кайтам дигән иде, шушылардыр инде», — дип уйлады. Аның моңа кадәр бер дә күркә күргәне юк иде. «Тик

берсенең муены чабырган икән. Ашыгыч ярдәм кирәк», — дип, өйгә кереп китте. Өйдән көнбагыш мае һәм марля алып чыкты. «Хәзер дәвалыйбыз. Май белән сөртәбез дә марля белән бәйләп куябыз», — дип сөйләнде Айдар үз-үзенә. Әмма күркәләр аңа тоттырырга уйламадылар да. Айдарның килүен муеннарын сузып карап тордылар да, малай якынаюга, эре-эре атлап китеп бардылар. Ә теге чабырган кызыл муенлысы, кабарынып, «голдыр-голдыр» дип ачуланып, Айдарның кулын тешләп алды.

Айдар кулына көнбагыш мае сөртте. Аннан аңа марля урады. Күркә көлә иде.

*Заһирә Гомәрова*

## Бал кортлары һәм яңгыр

Кичә кичке якта яңгыр яуган иде. Нәҗия балалар бакчасыннан кайтышлый ярыйсы гына чыланды...

Шуңа күрә, бүген иртән тору белән үк, ул тәрәзәгә бакты. Көн бүген дә болытлы күренә. Юк инде, Нәҗия бүген алдатмас: үзе белән кечкенә кулчатырын[7] да алачак. Әнисе исә бакчадагы умарта ояларына ишарәләде:

— Бүген яңгыр булмас, кызым, кулчатырыңны алып торма, — диде. — Көндез яңгыр явасы булса, кортлар ояларыннан борыннарын да күрсәтмиләр. Ә бүген исә, әнә күр, алар ничек иртә күтәрелгәннәр, ничек дәртләнеп очалар.

Чын икән, ул көнне Нәҗиягә кулчатырның кирәге булмады, бер тамчы да яңгыр яумады. «Кара син аны, үзләре нәп-нәни кортлар, ә көннең нинди буласын әллә каян беләләр», — дип гаҗәпләнде Нәҗия...

*Альберт Хәсәнов*

[7] *Кулчатыр* — зонт.

## Алтын балык

Әтисе, Сәйдәшне ияртеп, балык тотарга китте.

— Әтием, — диде Сәйдәш, — безнең кармакка Алтын балык эләгерме?

— Алтын балык әкияттә генә була, — диде әтисе.

— Ә үзең, — дип эләктереп алды Сәйдәш, — әкият тормыштан алып языла, дисең.

— Элек, — диде әтисе, яхшылап аңлатырга тырышып, — матур, алтынсыман балыклар күп булган...

— Элек булган, ни өчен хәзер беткән? — дип төпченде Сәйдәш.

— Ул суның чисталыгана бәйле, улым. Нәзберек, затлы балыклар пычранган, тынчыган суда яши алмый. Шуңа күрә кайбер балыклар хәзер бөтенләй юкка чыккан.

— Алтын балык тамы?

— Алтын балык та.

— Киләчәктә «Алтын балык турында әкият» тә булмасмы?

— Әкияте булыр...

Әти кеше бераз уйланып торды да:

— Әгәр син, зур үскәч, күп итеп чәчәкләр, агачлар утыртсаң, олы абыйлар елга-күлләргә агулы калдык-постык, әшәке чүпчар ташламаса, алтын балыклар, бәлки, терелер, — дип җавап бирде.

— Ә мин чәчәкләрне хәзер үк утырта алам. Минем көчем күп, менә кара... — диде ул, ашыгып. Әтисенә беләкләрендәге мускулны күрсәтте. Шатлыгы хәрәкәтләренә, тавышына күчте.

— Әкрен, улым! Балык тотканда тавышланырга ярамый, — диде әтисе.

Алар күп кенә балык тотты.

Өйгә кайткач, чәчәк орлыкларын кайдан алу, кайда утырту турында да сөйләште алар. Кич белән бер-берсенә хәерле төн теләп йокларга яттылар.

...Төшендә Сәйдәш янына Алтын балык йөзеп килде. Дөресрәге, ул чын алтынсу төстә түгел. Җитмәсә, бик күңелсез иде.

Сәйдәш аңа үзе үстергән кашкарый чәчәкләрен бирде. Кашкарый чәчәкләре ал, кызыл, сары, зәңгәр, шәмәхә, алтынсу төстә иде.

Алтын балык чәчәкләрне алды. Сәйдәшкә рәхмәт әйтте. Һәм Сәйдәш бүләк иткән кашкарый чәчәкләреннән күз ачып йомганчы такыя үреп киде. Иң алга алтынсу төстәгеләрен куйды. Алтынсу төстәге кашкарыйлар ялык-йолык килә. Алардан төшкән нур балыкны да алтын төскә мана...

— Алтын балык терелде, Алтын балык терелде!.. — дип кычкырып җибәрде Сәйдәш, йокысыннан тора-торышка. Һәм тиз генә әтисе янына килде.

— Әти, әтием, мин Алтын балыкны коткара алам! — диде ул, үзенә нык ышанып. — Безгә кашкарый чәчәкләре утыртырга кирәк. Бүген үк, хәзер үк! Аның чәчәкләре алтынсу төстә булырга тиеш!..

Әтисе кечкенә Сәйдәшне, күтәреп, күкрәгенә кысты. Битләреннән үпте дә:

— Бик матур төш күргәнсең, ахры, улым! — диде.

*Эльмира Шәрифуллина*

## Тамчы

Корылыктан әлсерәгән иген кырлары өстендә яңгыр болыты күтәрелде. Тамчыкай иптәшләренә болай диде:

— Күрәсезме, игеннәр, безне сәламләп, башларын селкетәләр. Сусаганнар алар, корыганнар. Зарыгып, безне көтеп торганнар. Игеннәргә дым кирәк, югыйсә булырлар алар бик сирәк. Явыйк, явыйк, кырларны һәлакәттән коткарыйк!

Шыбыр-шыбыр яңгыр яварга кереште. Тамчыкай җиргә сикереп төште. Кайда ярдәм кирәк, шунда тизрәк! Тамчыкай ул бик зирәк, һәркемгә шулай булырга кирәк.

Җылы яңгыр явып китте. Кырга ямь керде, ашлыклар баш күтәрде.

Болыт үзенең тамчыларын сипте-сипте дә көнчыгышка таба китте. Җир өстенә хуш исләр бөркелде...

— Терелдек, терелдек, — дип, үләннәр шатланды.

Нинди шатлык! Нинди шатлык! Җиргә төшкән тамчылар төрлесе төрле якка юл алдылар: кайсылары үсемлек сабагына кереп калдылар, икенчеләре йөгерделәр ермакка, елгага, өченчеләре кире күтәрелде һавага.

*Гасыйм Лотфи*

## Кояш елый

Көзге көн. Кояшны болытлар каплаган. Салкын җил исә, агач ботакларын селкетә. Сары, кызыл яфраклар шыбыр-шыбыр җиргә коелалар.

Алия тәрәзә аша тышка карап тора. Кинәт болытлар арасыннан кояш күренде. Нәкъ шулчакта яңгырның эре бөртекләре, кояш нурларында ялтырап, җиргә сузылды. «Кояш елый, — диде Алия. — Агачларны кызганадыр. Әнә бит агачлар ялангачлар. Кояш аларны җылыта алмый. Агачларны болытлар каплаган. Кояш тизрәк җылытсын иде инде үзләрен».

Алиянең күзләренә мөлдерәп яшь тулды.

*Заһирә Гомәрова*

## Дачада

Айнур белән Алсу шәһәр уртасында яши. Биек йортның сигезенче катында. Балконга чыгасың да, туйганчы, урам күзәтәсең. Анда тыз-быз машиналар чаба. Трамвайлар йөгерә. Абыйлар, апалар, әбиләр, бабайлар каядыр ашыга. Алар йортлар артына китеп югалалар. Айнур белән Алсуның да шунда барасы килә.

Ә быелгы яз аларга шатлык алып килде. Әтиләре шәһәр кырыенда дача алды.

Дачалары каенлык уртасында аланда икән. Өй зәңгәр, яшел, ак буяуларга буялган. Идәне сап-сары.

— Йә, ничек, ошыймы сезгә дача? — дип сорады әтиләре.

— Әй-йе. Без монда хәзер җәй буе торабызмы?

— Теләсәгез, җәй буе да мөмкин.

Әниләре аш-су әзерли башлады. Әбиләре яшелчәләргә су сибәргә чыгып китте. Әтиләре баскычка юнәлде. Ул ике кулы белән баш очындагы тоткаларны эткән иде, түшәм ишек кебек өскә ачылды да китте. Ур-ра! Монда берсендә — диван, икенчесендә карават торган бүлмәләр бар икән ич. Айнур мәтәлчек атып алды.

Тиздән аш өлгерде, чәй кайнады. Яңа дачада беренче мәртәбә табын янына җыелдылар. Шатлыкны кайбер күршеләр дә уртаклашты. Алар Айнур белән Алсуга үзләре үстергән чәчәкләр бүләк иттеләр.

Әй кызык икән дачада!

*Тәүфикъ Әйди*

## Сәгать дигән серле ил

Ул илне сезнең һәркайсыгызның күргәне бар, әйеме?! Мин сезгә шул илнең серен ачмакчы булам.

Күрәсезме, бу илдә ике бертуган — Келт-келт белән Тек-тек яшиләр. Келт-келт кыскарак, Тек-тек озынрак. Шуңа күрә ул тизрәк йөри. Аннан соң, ул хәйләкәррәк тә. Келт-келт 1, 2, 3... дип санаганда, Тек-тек 5, 10, 15... дип саный. Келт-келт уникегә кадәр генә саный белә, Тек-тек — алтмышка кадәр.

Шулай да алар бик тату яшиләр. Чөнки бергә булганда гына төгәл вакытны күрсәтә алалар. Келт-келт сәгатьне, Тек-тек минутны күрсәтә.

*Илсөяр Иксанова*

## Хәтерсез Күке

Сезнең җәй көннәрендә урманга барганыгыз бармы? Барганыгыз булса, мөгаен, агачтан агачка кунып, «Күк-күү! Күк-күү!» дип кычкыручы Күкене күргәнсездер. Әгәр аның тавышына игътибар итсәгез — анда ниндидер сагыш, моң, өзгәләнү, чакыру авазлары ишетерсең. Нигә өзгәләнә, нигә сагышлана икән соң Күке? Урманның барча кошлары эчләренә сыймаган шатлыкларын тирә-юньгә җыр итеп тараткан чакта, ни өчен Күке болай моңлана икән?

Шушы соравыма җавап табарга теләп, беркөнне мин урманга киттем. Урман тып-тын иде. Җилләр, агач күләгәсенә сузылып ятып, мыш-мыш йоклый. Аюлар юкә балы белән тәмләп чәй эчеп утыралар. Куяннар, чәчәкле аланга җыелышып, сикерү ярышы уздырып яталар. Җырчы сандугачлар таң алдыннан бик каты сайрап арыганнар, хәзер, кипкән тамакларын чылатыр өчен, яфраклардан чык суы эчеп йөриләр. Бары тик күкеләр генә, әле бер агач башына, әле икенчесенә күчеп: «Күк-күү! Күк-күү!» — диләр. Шунда мин иң матур, иң төз, иң биек каен башына кунган Күке янына килдем дә:

— Әй Күке! Ни өчен болай моңаясың! Әйтергә яраса, миңа сереңне әйт әле.

Минем тавышымны ишетеп, Күке кычкыруыннан туктады. Канаты белән күз яшьләрен сыпырып алды. Аннары болай диде:

— Ничек инде мин моңаймыйм?! Эчем тулы сагыш бит минем. Сез, кешеләр, безнең сагышны аңламыйсыз. Безне башка кошлар оясына күкәй салган өчен гаеплисез. Балаларын үстерергә яратмый, дисез. Йә, кем инде үз баласын яратмасын?

— Алайса, нигә соң чит кошларның ояларына күкәй саласыз? — дидем мин.

— Хәтерсезлектән бу, — дип көрсенде Күке. — Хәтеребез бик начар безнең. Үз оябызны таба алмыйбыз. Аннары инде аптырыйбыз да башка кошлар оясына күкәй салабыз. Икенче күкәй салыр вакыт җиткәнче, теге кошның оясын да югалта-

быз. Менә бермәлне безнең утырыр вакытларыбыз җитә. Әле анда сугылабыз, әле монда бәреләбез. Бөтен урманны бетереп, оябызны эзлибез. Арып-талып бетәбез. Шулай эзли торгач, агач башында бер оя күреп алабыз. Сөенә-сөенә, шунда кереп утырабыз, ләкин безнең сөенечебез озакка бармый, бу ояга йә берәр Саескан, йә Карга килә дә: «Бу нинди чакырылмаган кунак? Минем өемдә нишләп утырасың?» — дип тавыш куптара.

Оятыңнан нишләргә белмичә, тизрәк моннан чыгып китү ягын карыйсың. Аннан инде икенче оя эзләп табасың, әмма аннан да сине куып җибәрәләр. Җитмәсә, әле кайбер кошлар сине урман алдында мәсхәрә итәләр. Оя ясарга иренәсең, балаларыңны теләсә кемгә ташлап калдырасың, диләр. Их, аңламыйлар безне, аңламыйлар. Кошлар гына түгел, кешеләр дә безне иң юньсез җан иясенә саныйлар. Ә безнең күңелебездә бернинди мәкер юк бит. Без: «Күк-кү! Күк-кү!» — дип, көннәр буе үзебезнең балаларыбызны чакырабыз. Тавышыбызны бер ишетмәсәләр, икенче ишетеп, янәбызга килерләр, дибез. Безнең дә үз балаларыбыз турында кайгыртасыбыз, аларның үскәннәрен, канат ныгытканнарын күреп сөенәсебез килә. Үз балаң турында кайгыртудан да ләззәтлерәк мәшәкать бармыни дөньяда!

Күк- кү! Күк- кү!

Шулай диде дә Күке очып китте. Озакламый ул икенче агачка кунып кычкыра башлады: «Күк-кү! Күк-кү!». Мин озак кына аның тавышын тыңлап тордым. Күңелгә әллә нинди сагыш, моң тулды. Үзем дә сизмәстән күзләремне сөртеп алдым. Хәзер инде миңа күкеләр турында начар уйлавым өчен оят иде.

*Фәнис Яруллин*

# «АРАЛАШУ» БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Бит күрке — күз, тел күрке — сүз.
* Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
* Сүз бирсәң — үтә.
* Ничек эндәшсәң, шулай ишетерсең.
* Аз сөйлә, күп бел.
* Сөйли белсәң, тыңлый да бел.
* Һәрбер сүзнең урыны бар.
* Үзең сөйли башлаганчы, кеше сүзен тыңлап бетер.
* Теле барның юлы бар.
* Суны кипкән җиргә сип, сүзне көткән җирдә әйт!
* Алтыда белгән ана телен алтмышта да онытмас.
* Китап — бакча, андагы язулар — шул бакчаның гөлләре.
* Китап укысаң — белемең артыр, укымасаң — белгәнең дә онытылыр.
* Тоз ашның түмен китерсә, мәкаль сүз ямен китерер.
* Мәзәк — күңел ачкычы, табышмак — зиһен ачкычы.

## ТАБЫШМАКЛАР

* Чыны бар, ялганы,
Яхшысы, яманы.
Агы бар, вагы бар,
Авызда тагы бар.
*(Сүз)*

* Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе.
Телгә аннан оста юк,
Аннан якын дус та юк.
*(Китап)*

* Күрешергә кулы юк,
Сөйләшергә теле юк.
Аның белән күрешмәгән,
Киңәшмәгән кеше юк.
*(Китап)*

* Бик күп телләрне белсә дә
Сөйләшми бер телдә дә.
Өйрәним дисәң — өйрәтә,
Карышмый беркемгә дә.
*(Сүзлек)*

* Әйткәч беләсе килә,
Белгәч көләсе килә.
*(Табышмак)*

* Һичбер кайчан сөйләшми ул,
Ләкин һәркем аңлый телен.
Олы дими, кече дими,
Өйрәтә ул безгә белем.
*(Китап)*

* Башта бар, аякта юк,
Кашта бар, колакта юк.
*(«ш» авазы)*

* Агач түгел — яфраклы,
Тун түгел — тегелгән,
Кеше түгел — сөйли.
*(Китап)*

* Киштә башында төпле төргәк,
Аңа һәр өйдә хөрмәт,
Ул һәркемгә дә кирәк.
*(Китап)*

* Урманда бар, кырда юк,
Мунчада бар, өйдә юк.
*(«м» авазы)*

* Яз белән көз нәрсә белән тәмамлана? («з» авазы)
* Җирнең уртасында нәрсә бар? («и» авазы)
* Иртә нәрсәдән башлана? («и» авазыннан)
* Урам башында ни бар? («у» авазы)

* Зонтик тоткан кыз, дисәң дә,
Зәйнәп — зәңгәр күз, дисәң дә,
Зәйтүнә — зур кыз, дисәң дә,
Бер аваз бар барысында.
Нинди аваз сүз башында,
Уртасында, ахырында?
*(«з» авазы)*

* «Әни»дә дә әйтәм,
«Әти»дә дә әйтәм,
«Әби»дә дә әйтәм,
Ә «бабай»га җитсәм,
Әйтә алмыйм бүтән.
*(«ә» авазы»)*

# ТЕЛ КӨРМӘКЛӘНДЕРГЕЧЛӘР

* Әрәмәдәге әрем әче. *(ә)*
* Башта башлап, баскыч башына бас. *(б)*
* Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра. *(с, з)*
* Кара карга кардан бара, канатларын кага-кага. *(к, р, г)*
* Кар аттым, кар аттым, ап-ак карны каралттым. *(к,р)*
* Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык, чык-чык, кошчык, очып чык. *(ч, к)*
* Тукый, тукый тукыган, тугыз талны чукыган. *(т, к)*
* Тау башында таллыкта тукраннар тукылдый. *(т)*
* Такта какма, капка как! Капка какма, тотка как! *(т, к)*
* Таулар биек таллардан, тал бөресе балланган. *(л)*
* Юлга егылгаласам да, елгага егылгалаганым юк. *(е, г)*
* Җәйнең ямьле көннәрендә җиләк җыя Җәмилә. *(җ)*

* Кичке сәгать болай суга:
Доң, доң, доң, доң!
Кече телем җитте унга,
Бик соң, бик соң!
Җәй урының, доң, доң!
*Фәнис Яруллин*

* Сокланам мин Сабирга,
Сабир сыман Сабырга:
Сабирдагы сабырлык
Сабыр хәйран калырлык.
*Хакимҗан Халиков*

* «Һау-һау! Һау-һау! Һау!» —
дисең,
Һаман нигә һаулыйсың?
Җитте, һау-һау, һаулама,
Китап укыйм — шаулама!
*Хәкимҗан Халиков*

* Көчле кеше
Очлы шөшле
Белән шушы
Төшне тиште.
*Мөҗәһит*

* Чүәк чигә чүәкче,
Чүлмәкче дә чүлмәген
Чүәкчедән күрмәкче,
Чүәк кебек чикмәкче.
*Хәкимҗан Халиков*

* Бака кебек бак та бак,
Бак та бак килә үрдәк.
Менә шулай була ул,
Бакадан алсаң үрнәк.
*Роберт Миңнуллин*

## ШИГЫРЬЛӘР

### Яхшы бел

Татарча да яхшы бел,
Урысча да яхшы бел.
Икесе дә — безнең өчен
Иң кирәкле затлы тел.

Татарчасы — туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң-анаң, әби-бабаң
Сине сөя торган тел.

Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!

*Шәйхи Маннур*

### Татар теле

Татар теле — минем туган телем,
Сөйләшүе рәхәт ул телдә.
Шул тел белән көйлим...
Шул тел белән сөйлим
Милләттәшем булган һәркемгә.

Дөньялар киң, анда илләр бик күп,
Туган илем минем бер генә.
Туган илемдә дә телләр бик күп,
Туган телем минем бер генә.

*Нәҗип Мадьяров*

### Туган тел

Әткәң-әнкәң телен белсәң
Адашмассың кайда да...
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, айга да

Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек бер генә.

*Газинур Морат*

## Уйнап алыйк әле

Тик утыру күңелсез бит,
Уен уйнап алыйк без.
Башны бераз эшләттереп,
Әйдә, уйлап карыйк без.

Бер сүз әйтәм, син шунда ук
Сүз киресен уйлап тап.
Мин әйтәмен:
«Чит җирдә», — дип,
Син әйтәсең: «Туган як».

Мин әйтәмен: «Ул куркак», — дип,
Син әйтәсең: «Юк, батыр».
Мин әйтәмен: «Юл сикәлтә»,
Син әйтәсең: «Юл такыр».

«Бу — ак», — дип бәхәсләшәмен,
Син әйтәсең: «Юк, кара!»
Хәзер мин ахырын әйтәм,
Син, әйдә, башлап кара.

*Гөлфия Юнысова*

## Бәхәс

Бәхәстәнме? Бәхәстән!
Нәсим белән Нәсимә,
Әй, даулаша, әй, шаулаша,
Теттереп бәхәсләшә.

— Синең сүзең дөрес түгел,
Бака ул квакает.
— Әйттең менә, әт-тә-тә,
Бакылдый, хәлдән таеп.

Бака бит ул ба-ка-ка,
Баткакта батып ята,
Әгәр аны куркытсаң,
Агулы суын ата.

Әгәр аңа тимәсәң,
Син килбәтсез, димәсәң,
Рәхәтләнеп бакылдый,
Үз телендә такылдый.

— Кирәге бар квакушаң,
Эшли алмый, эш кушсаң.
Ни арбага, ни чанага
Җигеп булмый, ичмасам.

— Син әйтәсең: квакуша —
Кем шундый исем куша?
Үз телеңне, ичмасам,
Тагын син дә бозмасаң!

Туган телең белмичә,
Сүзләр бозып ятканга,
Көләләр бит үзеңнән,
Кычкыралар: ба-ка-ка!

*Бикә Рәхимова*

## «Алма» түгел, «алам»

Ал алмалар юа әни,
Тезеп куя өстәлгә.
— Аша, улым, алма, — диеп,
Берсен сузды Рөстәмгә.

Хата сизде Рөстәм сүздә:
— Аша алма, дисеңме?
«Аша» дигәч, «алма» димә,
«Алам» булсын исеме.

*Сажидә Сөләйманова*

## Хаталарны төзәт

Агачларда шаулый яфрак,
Төсе — ап-ак.
Өстәлендә сөт һәм кымыз,
Алар — кызыл.

Ике карга очып бара:
Кызгылт-сары.
Басу тулып дулкынлана
Зәңгәр тары.

Күктә йөзә күксел кояш,
Яшел болыт.
Яр башында алсу үрдәк
Тора оеп.

*Гөлфия Юнысова*

## Әйтә үрдәк

Кытаклый тавык, сөенеп:
— Күкәй салдым,
күкәй салдым!
Үрдәк әйтә:
— Алай түгел,
Син бит йомырка салдың.

*Нәҗип Мадьяров*

## Кызык китап

Әни миңа китап алды,
Әй кызык инде.
Кулымнан да төшермимен,
Тиз тузар инде.

— Балам, кызык китап диеп,
Син алдыйсың бит.
Русча укыр өчен, телне
Аңламыйсың бит.

— Русча булса да бу китап,
Укуы рәхәт:
Сурәтләрнең һәммәсе дә
Башкортча бит, вәт!

*Гөлфия Юнысова*

## Китап

Һәр шәһәрдә, һәр авылда
Иртән, көндез, кичләрен
Китап бизи һәрбер өйдә
Укучының өстәлен.

Яхшы китап белән безнең
Һәркайсыбыз дуслаша.
Без белмәс идек үткәнне,
Яңаны, ул булмаса.

Кадерләп тота китапны
Укучы үз кулында.
Үрнәк ул — акыллы китап —
Безгә тормыш юлында.

*Сергей Михалковтан*

## Туган телгә өйрәттек

Безнең авылга шәһәрдән
Кайтты бер кылтык малай.
Урысча гына сөйләшә,
Бер дә сер бирми алай.

Без дә төшеп калган түгел:
Урысчаны аңлыйбыз.
Тик «телеңне белмибез» дип
Шаяртабыз, алдыйбыз.

Җәй эчендә Айратыбыз
Урысчасын ташлады.
Безнең белән туган телдә
Сөйләшә дә башлады.

Кылтыклыгы да югалды,
Эрелеге дә бетте.
Шулай итеп, безнең авыл
Аны чын кеше итте.

*Мөҗәһит*

## Ат ник көлә?

Авылга әбиләренә
кунакка кайткан Ирек.
—Привет, конь! —
дип исәнләшкән,
Җирән кашканы күреп.

Җирән кашка, башын, чайкап:
— Мих-ха-хай! — диеп көлгән.
— Ник көлә ул? — диеп, Ирек
сораган әбисеннән.

Әбисе, хәйләкәр генә
елмаеп, болай дигән:
— Үз телен оныткан, диеп
көләдер, улым, синнән...

*Шамил Маннапов*

## Кем булып эшли?

— Әтиең кем булып эшли?
— Директор минем әти,
Эше күп, йоклап ятмый.
— Әниең кайда эшли?
— Әниемме? Ул өйдә,
Королева ул бездә.

*Вәсимә Ураксина*

## Тел белү авыр түгел

Чит телләрне бер көндә
Өйрәнеп буласына
Тәки ышандым, баргач
Шул Уфа каласына.

«Килмим» — «килмәем» икән,
«Көлмим» — «көлмәем» икән.
«Сана» — була, ди, «һана»,
Ә «чана» — була «һана».

Бөтен сере шул гына,
Игътибарлы бул гына.
Башкортчаны белерсең,
Рәхәтләнеп кунакта

Сөйләшеп тә йөрерсең.
Әз генә бирсәң күңел,
Тел белү авыр түгел.
Ышанмасаң сүземә,

Башкортның радиосын
Тыңлап кара үзең дә.

*Мөҗәһит*

## Татарча белмәүче кәҗәләр

Шундый безнең Алиябез:
Үлеп әкият ярата.
Сөйли аны әнисе дә,
Сөйли аны Марат та.

Әкият иле Алиянең
Туган иле диярсең.
Бердәнбер кызың сорагач,
Белмәсәң дә сөйләрсең...

«Козлятушки, дитятушки,
Ваша мать пришла,
Вам молочка принесла...»

Кәҗә шулай җырлый, диеп
Сөйләп китә әнисе...
Урысчалап такмаклауга
Алия соң ни дисен?!

Тыңлап-тыңлап тора да ул
(Тыңлый белә ул үзе!)
Әнисе сөйләп бетергәч
Әйтеп куя үз сүзен:

— Бу кәҗәләр бер генә дә
Татарча белмиләрме?
Татарчаны белмәгәнгә
Урысча сөйлиләрме?

*Фирая Зыятдинова*

## Әкиятләр яратам

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр — батырлар.
Бар бит анда ак аюлар,
Көчле Камыр Батырлар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр — шаяннар.
Йөгерешә Җилаяклар,
Чакмый торган Чаяннар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр — хәйләле.
Чөнки анда зирәк Былтыр,
Тагын елак Шүрәле...

Серле, кызык әкиятләрне
Тыңларга бик яратам.
Әкият сөйли дә әтием,
Шундук йокларга ятам.

*Эльмира Шәрифуллина*

## ***Рольләргә бүлеп сөйләү өчен***

### Аю

— Кая юл тоттың, аю?
— Калага — чыршыларга.
— Чыршылар сиңа нигә?
— Яңа ел каршыларга.
— Ә соң кая куярсың?
— Урын булыр анысы.
— Урманда чыршы юкмы?
— Җәл шул урмандагысы.

*Григоре Виеру, молдаван шагыйре*

### Әйтче, кояш!

— Әйтче, кояш, синең нурлар
Һәммәсе ничәү икән?
— Нурларымның һәммәсен дә
Мин сезгә бүләк итәм!

— Әйтче, Кояш, нурларыңда
Җылына ничә кешең?
— Санарга минем вакыт юк,
Иркәләү — минем эшем!

*Григоре Виеру, молдаван шагыйре*

## Өйдә калам

— Әти, эшкә барасыңмы?
Иярт әле, мин дә барам.
— Юк, юк, эшкә түгел әле,
Башка җиргә барам, балам.

— Ә, клубка, киногамы?
Мин дә барам, әти, яме.
— Юк, юк, балам, клубка дип
Җыенуым түгел әле.

— Кая барсаң да ияргәм...
— Мин мәктәпкә барам, балам.
— Ә алайса, әти җаным,
Мин бүгенгә өйдә калам.

*Фәнис Яруллин*

## Каравылчылар

— Әй Муса абый,
Кая барасың?
— Каравылчы мин,
Барам фермага.

— Ә сиңа, Муйнак,
Ни калган анда?
— Һы, барам ич мин
Каравылчыны
Каравылларга.

*Нәҗип Мадьяров*

## Ай, кызым

— Мин дә керләр удым, әни,
Сабынлап юдым, әни!
— Ай, кызым, үскәнсең,
Бигрәк матур иткәнсең!

— Идәнне җыйдым, әни,
Сабынлап юдым, әни!
— Ай, кызым, үскәнсең,
Бигрәк матур иткәнсең!

— Бәрәңге дә юндым, әни,
Сабынлап юдым, әни!
— Ай, кызым, үскәнсең,
...Нишләдең?!

*Шәүкәт Галиев*

## Өй чебеше

— Чыгасыңмы урамга?
Бергә чана шуарбыз.
— Көн суык бит, туңарбыз.

— Тун киярсең өстеңә.
— Тунны песи ашаган.
Җиңен мичкә ташлаган.

— Ә пәлтәңә ни булган?
— Көя тишеп бетергән,
Иләк кебек иттергән.

— Әтиеңнең толыбын
Киеп чык син, булмаса:
Яхшы булыр туңмаска.

— Әти алып толыбын
Чыгып китте каядыр,
Белмим, кая барадыр?..

— Идрис түгел, чебеш син,
Өй чебеше икәнсең:
Песи алып китмәсен.
Хуш!

*Хәкимҗан Халиков*

## Әнкәсе белән улы

— Дөмбер-дөмбер кем йөри?
— Дөмбер-дөмбер җил йөри.
— Ник кага ул калайны?
— Чакыра бер малайны.
— Ә ул малай ник чыкмый?
— Малай дәресен укый.
— Дәресен укыр соңыннан...
— Юк, юк, улым... Җил тынган.

*Фәнис Яруллин*

## Җавап бир

Утырттым да Маратны,
Күзләремә караттым,
Сорау бирдем үзенә,
Җавап бир, дип, тиз генә.
— Күзләрең нигә кирәк?
— Күрергә...
— Аягың нигә кирәк?
— Йөрергә...
— Ә телең нәрсә эшли?
— Сөйләшә.
— Кулларың нәрсә эшли?
— Кашык, чәнечке тота да
Тәмле ашлар ашата.
— Ә авызың нәрсә эшли?
— Шикәр, конфет суыра...
— Ә чәчләрең нәрсә эшли?
— Баш өстендә тик тора.

*Энҗе Мөэминова*

## Үрдәк белән сөйләшү

— Үрдәк, зурмы бу тавыклар?
— Вак, вак.
— Ә кәҗәләр, ә сарыклар?
— Вак, вак.
— Сыерлар вак түгелдер ич?
— Вак, вак.
— Үз бәбкәләрең дә вакмы?
— Юк, юк.

*Нәҗип Мадьяров*

## Мәче нигә мыеклы?

— Әни, әни, әйт әле:
мәче нигә мыеклы?

— Тычканнарны бик ерактан
сизеп алсын өченгә.
Мыек түгел, антенна ул
Безнең елгыр мәчегә.

— Әни, әни, алай булгач,
мәче телевизормы?

*Марсель Галиев*

# КҮҢЕЛЛЕ ШИГЫРЬЛӘР

## Радиога салкын тигән

Энемнең тавышы беткән —
Көч-хәл белән сөйләшә.
Салкын тигән. Шуңа күрә
Мәтрүшкәле чәй эчә.

...Беркөн безнең радиога
Нидер булды — сөйләми.

Чыжылдый шунда...
Йөткерә —
Берничек тә көйләнми.
Нишләтергә инде моны,
Әйбәт сөйләсен өчен?

Энем әйтә: «Салкын тигән.
Мәтрүшкәле чәй эчсен!»

*Ләбиб Лерон*

## Юкка малай булганмын

Их, кыз буласым калган!
Белмәдем шул мин алдан.
Кызларга кадер-хөрмәт,
Эшләре бара, гөрләп:

Бәйрәм саен аларга
Чәчәк бүләк итәсең.
Исәнләшеп үтәсең,
Ишек ачып кертәсең,
Хәтта портфельләрен дә
Күтәрешеп йөртәсең.

Троллейбуста барганда,
Автобуста барганда
Алар утырып бара,
Ә син утырып кара!

Шунда ук күрәчәкләр,
Һәммәсе көләчәкләр,
Әдәпсез, диячәкләр,
Гадәтсез, диячәкләр.

Ә кызларга күңелле,
Йөриләр, килештереп.
Үзләрен булмый хәтта
Шаяртып, ирештереп.

Хәтта толымнарыннан
Тарттырмаган булалар,
Чирттермәгән булалар —
Бигрәк иркә шул алар.

Ә үзләрен кайда да
Чиратсыз уздырасың...
Юкка малай булганмын,
Калган ла кыз буласым!

Моннан соң мин, күрерсез,
Акыллы булачакмын:
Яңадан тусам әгәр,
Кыз булып туачакмын!

*Роберт Миңнуллин*

## «Мөгезле» әни

— Үгез була мөгезле,
Кәҗә була мөгезле.
«Мөгезле» әни белән
Таныштырыйммы сезне? —
Әнине күреп, энем
Шулай диде беркөнне.

Ул мөгезләрен әни
Үзе куя һәр көнне.
Үзе куя шул кичтән,
Аның каравы иртән
Әниемнән чибәр әни
Дөньяларда юк бүтән.

Ул чәчләре төшеп тора,
Бөдрәләнеп, иңенә.
Бигуди дигән мөгез
Куя әни чәченә.

*Йолдыз*

## Кем хаклы?

Аңламассың бу зурларны —
Алдыйлармы, чын сүзме? —
Төрлесе төрлечә дәшеп
Аптырата үземне.

Әти әйтә: «Зур улым», — ди,
Әни әйтә: «Бәбием».
Апа әйтә: «Үскәнем», — ди,
«Җимешем», — ди әбием.

Ә бабам әлеге эштә
Барыннан да уздыра —
Кайтып керсәм, «Нихәл, картлач», —
Дип, миңа кулын суза.

*Шәмсия Җиһангирова*

## Күз тигән

Нишләгән бу телевизор?
Күрсәтми, калган телдән.
Бик үтенгәч, төзәтергә
Бер абый — оста килгән.

«Көннәр буе ял бирмичә
Карагансыз сез, дигән,
Каникулда чакта Шомбай
Карый торгач... күз тигән.

Ял итәргә телидер бит
Сезнең шикелле ул да.
Шомбай мәктәптә чагында
Ял итсен, каникулда»

*Илдар Юзеев*

## Тун кигән Акбай

Салып аттым туфлиемне,
Салдым мин күлмәгемне.
Су буена комга яттым —
Кыздыр, кояш, тәнемне!

Гәзиттән башлык ясадым,
Эссе капмас башыма.
Акбаем да рәхәтләнеп
Ятты минем каршыма.

...Ул да инде — туны аша! —
Кызынам дип маташа.

*Ринат Мәннан*

## Ә үзләре...

Зурлар безгә тапшыру да,
Кино да каратмыйлар.
— Ярамый да ярамый! — дип,
Көн саен кабатлыйлар.

— Кинолар кичен, — диләр, —
Олылар өчен! — диләр.

Әгәр дә карый башласаң,
Безгә бармак яныйлар...
Безгә дигән мультфильмны
Үзләре бик карыйлар!

*Роберт Миңнуллин*

## Күлмәк белән сөйләшү

Ник тиз буяла икән
Минем күлмәк, аптырыйм.
Өйгә җиткән чагында,
— Ник буялдың? — дип сорыйм.

— Ялгыш кына, — ди күлмәк, —
Чынлап түгел инде, — ди, —
Әниең орышмаса
Ярар иде сине, — ди.

Җәллим мин сине, малай,
Аңлыйм мин сине, малай.
Менә күреп торырсың,
Буялмам бүтән алай.

— Бүтән буялма инде,
Буялма, күлмәк, димен.
Чиста малай буласым
Килмиме әллә минем?!

*Илгизәр Солтан*

## Өчпочмакмы, берпочмакмы?

Пешергән бүген әнисе
Бик тәмле өчпочмаклар,
Табын янында тып-тыныч,
Селкенә тик колаклар!

Ләйлә генә аптырашта,
Менә сиңа табышмак:
Бер ягын китеп капкан да,
Ашадым, ди, берпочмак.

Өлкәннәр аның сүзеннән
Рәхәтләнеп көлделәр.
«Күпме ашасаң да, — барыбер
Өчпочмак ул», — диделәр.

*Резеда Шәрипова*

## Нажиягә ни булды?

«Здрасьте», «привет» дип
Сөйләшкән Нажиягә
Әллә нәрсә булды әле,
Күчкәч гимназиягә.

Телефоннан да әйбәтләп
Башта сорый ул: «Бу кем?»
Аннан соң җавап кайтара:
«Әссәламегаләйкем!»
*Мөҗәһит*

**Карлыган мунча керә**

Әле март та бетмәгән,
Кар да китеп бетмәгән,
Бакчада карлыганнар
Уянып та җитмәгән.

Әти кайнап чыккан суны
Куакларга сиптерә.
Пары чыгып торган суны
Һәр ботакка җиткерә.

— Ник алай итәсең? — дим.
Әти мине шаярта:
— Карлыган, — ди, — синең кебек,
Мунчаны бик ярата.
*Вәсимә Хәйруллина*

**Ярамаган эш**

Аңламагач татарчаны,
Ачуым килде минем.
Шуңа кунак кызының мин
Чәченнән тарткан идем.

Әби мине тирги шуңа:
— Син, ди, аңларга тиеш:
Бу гамәлең синең, улым,
Бер дә ярамаган эш.

Телен дә чыгарды әле,
Телен тотмадым, ярый.
Исеме Гүзәл бит аның,
Ник ул мине аңламый?
*Илгизәр Солтан*

## Әләкләргә ярамый

— Син үзең дә тәртипсез,
Песиең дә тәртипсез.
(Тапкан әни әйтер сүз!)
Туздыргансыз өйне, — ди, —
Аударгансыз гөлне, — ди, —
Монда ята чүлмәк, — ди, —
Тегендә ауный күлмәк, — ди.—
Азынасыз бигрәк, — ди. —
Аерырга кирәк, — ди.
Бүлмә үзе тузгандыр,
Без гел аны күрмәдек,
Чүлмәк үзе аугандыр,
Без аңа да тимәдек.
Һич тәртипсез түгел без,
Без бит бары уйныйбыз,
Песи наян, мин шаян,

Шуңа өйгә сыймыйбыз.
Песи чапты, мин кудым,
Алны-артны карамый.
Кайсыбыз гөл аударганны
Ул да әйтми, мин дә әйтмим,
Әләкләргә ярамый.

*Клара Булатова*

## Машина ала белмисез

Ватык минем машиналар,
Нигә миңа андыйлар!
«Барыбер ватасың!» — диеп,
Яңаларын алмыйлар!

Йөрми минем машиналар,
Барсы да тәгәрмәчсез,
Шофёрсыз кабиналары,
Рульсез дә тәрәзәсез...

Мин аларны ватканмындыр,
Бәләкәй булган чакта,
Әле миңа бер генә яшь
Йә ике тулган чакта.
Хәзер үзегез дә мине:
«Өч яшьлек егет!» — дисез,

Егетләргә машинаны
Ала гына белмисез:
Үземнән дә зур булсын ул,
Мин ваталмаслык булсын!

Нихәтле такси урамда!
Алыгыз шуның берсен!

*Нурия Измайлова*

## Карак карга

Быел башлы суганны
Алмыйк диеп акчага,
Бик күп итеп утырттык
Үзебезнең бакчага.

Мин дә булышып йөрдем,
Көне буе эшләдем.
Беләм: суган яратсаң
Авыртмый ул тешләрең.

Яшел кыяклары чыккач
Пешерербез зур бәлеш.
Хыялланып эшләдек,
Җайлы барды безнең эш.

Иртән торып карасак,
Бу ни гаҗәп, бу ни хәл?
Бер суган да калмаган,
Танырлык түгел түтәл.

— Кем урлаган икән? — дип
Торган чакта, аптырап,
Баш очында бер карга
Әйләнә бит «кар-кар»лап.

Карасам, томшыгында
Безнең суган орлыгы.
И куамын карганы:
— Кит, карак,
мур кыргыры!

Әтием никтер тыныч,
Мыек астыннан көлә.
— Суганда, ди, витамин күп,
Моны карга да белә.

*Йолдыз*

## Казанга киләчәкмен

Казанга килгәч, урамда
Шаклар катып йөрим мин.
Бөтен нәрсә күз алдымда —
Бер әйбер дә күрмим мин.

Урам тулы халык анда,
Тыз да быз йөреп тора.
Шул йөрүдән башка, алар,
Белмим, нинди эш кыра?

Ничек күрмәк кирәк анда,
Күзләрең ич камаша.
Эзләп тә йөрисе түгел,
Монда икән тамаша.

Кая эш кырсыннар инде,
Тик йөриләр, буталып.
Бик тәмле туңдырма алдым,
Бер урында тукталып.

Әй йөрим соң урам буйлап,
Туңдырма ашап кына.
Нәкъ Казан малайларының
Үзенә охшап кына.

Ике дә уйлап тору юк,
Моннан соң беләчәкмен:
Укуымны бетергәч тә,
Казанга киләчәкмен.

*Мөҗәһит*

## Битем туза

Уянды да, җайлап торып,
Равил киемен киде.
Дәү әнисе кайчан күргән:
«Битең, кулың ю!» — диде.

Суга чыланырга һич тә
Малай теләми иде.
«Иртән юам, кич тә юам,
Битем туза ич!» — диде.

*Фирдәвес Бәширова*

## «Өйләнсәм», ни диярсең?

Беркөн кайткач, кызым әйтә:
— Дәү әни, син беләсеңме,
Мин бит бүген бакчада
Бер шәп малай очраттым:
Аптырамам акчага,
Квартиры бар, өч машина —
Син дә аны сөярсең,
Шул малайга иртәгә үк
«Өйләнсәм», ни диярсең?

Иртәгесен бакчасыннан
Кайтып керде, борчылып:
— «Өйләнмәскә»
булдым әле —
Чабып йөри сызгырып,

Чәч тә тарта, төртеп ега,
Бигрәк инде әдәпсез,
Бер дә харап елак тагын —
Үкерә бер сәбәпсез.

Шундый буламыни инде
Мин «өйләнәсе» малай?
Андыйның акчасына да
Исем китми бик алай,

Чуртымамы машинасы,
Үзе тәртипсез булгач,
Яхшысын табармын әле,
Яшем зур булып тулгач.

*Флёра Тарханова*

***

## Үрдәк беренчелекне алган

*(Әкият)*

Беркөнне Сыер белән Кәҗә янына Тавык белән Үрдәк килеп туктаганнар да яңа хәбәр белдергәннәр:

— Иртәгә йорт хайваннары һәм кошларның һөнәрләрен сынап карыйлар. Кем үзенең һөнәрен яхшы күрсәтә, шуңа бүләк биреләчәк, — дигәннәр.

Иң беренче булып Кәҗә акырырга тотынган:

— Мин шундый матур итеп җырлап күрсәтермен, бөтенесе хәйран калыр, — дигән.

— Ә мин йөгерү ярышында катнашырмын, — дигән Сыер.

— Минем җырлаганым бар инде, бу юлы биеп күрсәтергә кирәк, — дигән Тавык.

— Мин белмәгән эшкә тыгылмыйм. Сәхнәгә чыгам да бак-бак итеп бакылдап күрсәтәм, шул җитәр, — дигән Үрдәк.

Менә икенче көнне, боларның һөнәрләрен тикшерү өчен, комиссия килгән. Аю бабай, күзлеген киеп, бик игътибар белән күзәтеп торган. Төлке язып барган.

Кәҗәнең бакырганыннан бөтенесе шаркылдап көлгән.

Сыер, йөгерергә чыккач, абынып егылган. Тавык та биемәкче булган икән, чалыш атлап мәтәлеп киткән.

Ә Үрдәк сәхнәгә чыккан да үзенчә бакылдаган. Аңа барысы да гөр килеп кул чапканнар. Һәм, үз телендә матур итеп шигырь сөйләгәне өчен, аңа сулы ләгән бүләк иткәннәр.

## Дөресе анның шулай...

*(Нәни хикәя)*

Әтисе кызын балалар бакчасыннан алган. Сөйләшә-сөйләшә, өйләренә кайтып баралар.

— Кызым, бигрәк күп сорау бирәсең, һаман мине сөйләндерәсең, тәмам арыттың бит, — ди әтисе. — Менә хәзер мин сиңа сорау бирим әле. Син җавап бир. Рәхәтләнеп сөйлә.

— Нәрсә сөйлим? — ди кызчык.

— Бүген бакчада нинди уеннар уйнадыгыз? Шуны сөйлә, — ди әтисе кызына.

— Без бүген бакчада кулга-кул тотынып, түгәрәк ясап, сәйлән-бәйлән уйнадык, — ди кыз.

— «Сәйлән-бәйлән» түгел, «Әйлән-бәйлән» уены ул, кызым, — ди әтисе.

— Тәрбияче апа да « Әйлән-бәйлән» дип әйтә. Дөрес әйтми. Син дә ялгыш әйтәсең, — ди кыз.

— Менә сиңа?! Тәрбияче апаң да дөрес әйтми. Мин дә ялгыш әйтәм... Ничек инде алай? — ди әтисе.

— Шуны да белмисез. Үзегез зурлар. Ә без — кечкенәләр, сәйлән кебекләр. Шуңа күрә без «Сәйлән-бәйлән» уйнадык. Дөресе аның шулай, — ди кыз.

*Рөстәм Мингалим*

# IV БҮЛЕК

## «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»

*(«нәфис-нәфасәти үсеш» юнәлеше)*

***«ИҖАТ» БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ***

## МӘКАЛЬЛӘР, ӘЙТЕМНӘР

* Гөл кадерен былбыл белер, җәүһәр кадерен җәүһәрче белер.
* Берәү хөрмә сөя, берәү торма сөя.
* Зәвыкта бәхәс юк.
* Былбылны сайравыннан таныйлар.
* Былбылны бытбылдыкка алыштырмыйлар.
* Тәм тою да бер түгел, ямь тою да бер түгел.
* Тыйнаклык кешене бизи.
* Һәр ялтыраган алтын түгел.
* Бер йөрәктә туган җыр икенче йөрәкне кузгата.
* Сандугач булсаң — сайрый да бел.
* Театр күңелләрне уятыр!

## ТАБЫШМАКЛАР

* Бер ояда алты дус,
Алтысында алты төс.
Ләкин алар барысы да
Башкаралар бер үк эш.
Юк аларда энәләр,
Бар да чигү чигәләр.
*(Буяу карандашлары)*

* Яз җитүен белдерә,
Былбылга шатлык бирә.
Күп төсле кием кия,
Бакчаларга ямь бирә.
*(Гөл)*

* Бер өем бар — нәзек очы,
Таштыр тышы, буштыр эче.
*(Мәчет манарасы)*

* Җәеп нәни паласымны
Торгызамын намазымны.
*(Намазлык)*

* Җиде сөлгем җиде төстә,
Җидесен дә элдем күккә.
*(Салават күпере)*

* Чулпан да ул, Зөһрә дә,
Венера да кайчакта.
Шундый матур балкып тора,
Кояш уянган чакта.
*(Йолдыз)*

* Зәңгәр ашъяулык
Бөтен дөньяны каплаган.
*(Күк йөзе)*

## ШИГЫРЬЛӘР

### Матурлык минем белән

Зур, матур, биек йортлар,
Тәрәзәләрдә утлар...
Ишектән килеп керәм.
Кая гына барсам да,
Матурлык минем белән.

Алда күл, янда болын...
Уйнаклап йөри колын...
Мин дә тәгәрим, көләм,
Чөнки, кайда булсам да,
Матурлык минем белән.

*Мөдәррис Әгъләмов*

### Соклангыч дөнья

Соклангыч та соң бу дөнья —
Кояшы бар, ае бар...
Чәчәк җыеп йөри сыман
Аланлыкта каеннар.

Күбәләкләр, бөтерелеп,
Чәчәкләргә куналар...
Ак тузганак болытлары
Офыкларга юл ала.

*Ләбиб Лерон*

### Матурлык

Безнең авыл бик матур, —
Урман якын булганга,
Су буендагы талларга
Сандугачлар кунганга.

Безнең урам бик матур, —
Өйләр якты булганга,
Һәр көн саен тәрәзләргә
Кояш нуры кунганга.

Безнең өй дә бик матур,
Матур ул — мин булганга.
Ә мин нигә матур соң? —
Матур — җирдә туганга.

Тәрәзәне ачып шулай,
Мин елмаеп торам да
Йөгереп чыгам урамга, —
Матур җирдә уйнарга.

*Илгизәр Солтан*

## Табигать

Әй сөям мин табигатьнең гүзәл күренешләрен!
Ялтырап аккан суын, анда балык йөзешләрен.

Ул яшел урман, болыннар, бакчалар, чәчкәләрен,
Ул кояш, айны, аларның нур чәчкәннәрен.

Әллә ни сөйли алар — тыңлыйм да мин моңлангалыйм,
Тәмле, ләззәтле хыяллар берлә тик уйлангалыйм.

*Гыйффәт туташ*

## Мин елмаям

Мин елмаям, мин елмаям,
Мондый шатлык килде каян?

Җылы яктан кошлар кайта,
Умырзая чәчәк ата...
Шуңа күрә мин елмаям —
Күңелемдә шатлык арта.

Карлар эри, карлар эри,
Күңелемдә шатлык йөри;
Яз килә бит, яз килә —
Гел елмаясы килә.

*Энҗе Авзалова*

## Нәкъ әкият диярсең

Кышның бозлы таулары,
Шыгыр-шыгыр карлары,
Тәрәздәге бизәкләре,
Чыршыдагы шарлары —
Бар да матур, тылсымлы,
Нәкъ әкият диярсең,
Шушындый гүзәл дөньяны
Сөймәс җирдән сөярсең.

*Флёра Тарханова*

## Рәсем

Ямь-яшел таулар — өстә,
Ак чәчәкләр — уртада,
Кызыл җиләклек — аста.
Бутама син, бутама!

Сеңлем шушы рәсемне
Ясады әле генә.
Бик тә охшап тора ул
Илебез әләменә.
*Рәшит Бәшәр*

## Рәсем ясыйм

Көнбагыш чәчәге ясыйм,
Сары карандаш алдым.
Эшем бетте, исем китте:
Кояшны ясаганмын.
*Равил Фәйзуллин*

## Рәсем дәресендә

Тышта бүген берөзлексез
Кар аралаш яңгыр ява.
Соры болытлар иңендә
Томанланып тора һава.

Ә бездә — рәсем дәресе,
Ике күзем — альбомымда.
Җәйне ясыйм, матур җәйне,
Елак көзгә карамыйм да.

Ә җәйнең төсләре бүтән:
Яшел, зәңгәр, кызыл төсләр.
Ямь-яшел алмагачларда
Кып-кызыл алмалар пешкән.

Зәңгәр чәчәк, алсу җиләк,
Чия пешкән чиләк-чиләк...
Мин җәй ясыйм альбомымда,
Тәрәзәгә карамыйм да!
*Резеда Вәлиева*

## Чуар тавык

Бик шәп тавык ясадык без,
Вакыт һәм кәгазь табып.
Бераз гына буядык та,
Ул булды чуар тавык.

Апа да: «Чын тавык бу», — дип,
Тавыктан күзен алмый.
Тик нәни Нил сорау бирде:
— Ник ул йомырка салмый?

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Үрдәк

Үрдәк рәсемен ясыйм мин,
Кулымда карандашым.
Зур түгәрәк булыр гәүдә,
Ә кечкенәсе — башы.

Гәүдәсе һәм башы булгач,
Аннан ясыйм муенын.
Кишергә охшатып сызам
Үрдәкнең зур борынын.

Канатларын, аякларын
Бик ансат һәм тиз ясыйм.
Тирә-якка карар өчен,
Бит өстенә күз ясыйм.

Шуннан соң гына җибәрәм
Үрдәкне мин елгага —
Нәни дулкыннар чыгарып
Йөзеп китә ул алга.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Сыер

Башта ике түгәрәкне
Ак кәгазьгә төшердем.
Аннан аларны гәүдә һәм
Баш итеп килештердем.

Коточкыч итеп ясадым
Зур-зур ике мөгезен.
«Үгез булып чыкмасмы?» — дип
Куркып калдым мин үзем.

Усал үгез итмәс өчен,
Ярый юлын тиз таптым...
Сөтле җиленен ясадым,
Аннан койрык та тактым.

Күзләр, аяклар ясадым.—
Кабул итеп алыгыз.
Инде һәр көнне иртә-кич
Җылы сөтен савыгыз.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Төсләр

Күз төсе —
Соргылт төс,
Саргылт төс,
Коңгырт төс.

Язныкы
Ала төс.
Соңыннан
Кара төс.

Кышныкы —
Аклы төс.
Ялт иткән
Якты төс.

Яшел төс —
Җәйге төс.
Их, бигрәк
Ямьле төс.

*Нәҗип Мадьяров*

## Кара

Карга канаты ни төсле? —
Карга канаты кара.
Кара төсне белер өчен,
Кара каргага кара.

Чем-кара сыерчыклар да
Кайтканнар туган якка.
Күренми дә, җим чүплиләр
Сутлы кара туфракта.

*Гөлфия Юнысова*

## Ак кыш

Яратам мин ап-ак төсне.
Бөтен дөнья ап-ак төсле:

Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кар кунган.

Биек булып, ап-ак булып,
Урамга ак кар яуган.
Көне буе шау-гөр килеп
Шуабыз шул ак таудан.

Шундый якты, шундый нурлы —
Бөтен дөнья ак кына...
Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына.

*Роберт Миңнуллин*

## Кәләпүшем, кәләпүш

Йөзләремә килешәсен
Кайлардан гына белгән,
Туган көнгә дәү әтием
Кәләпүш алып килгән.

Кәләпүшемне кидем мин,
Көзге каршына килдем.
— Менә шушындый була ул —
Татар малае! — дидем.

Кәләпүшем, кәләпүш,
Энҗе-мәрҗәннәр чиккән.
Чиккән кәләпүш үземә
Бигрәк килешә икән.

Инде җырлый да беләм мин,
Инде бии дә беләм.
Сәхнәләрнең түрендә мин
Кәләпүшкәем белән.

Әнием дә бик сөенде,
Кочаклап алып сөйде.
Котлы булсын кәләпүшең,
Бигрәк килешә, диде!

Кәләпүшем, кәләпүш,
Укалыдыр читләре.
Шундый матур кәләпүшле
Малай булдым бит әле.

*Резеда Вәлиева*

## Түбәтәй

Әнием туган көнемә
Бүләк итте түбәтәй.
Шундый матур түбәтәем,
Үзем кебек бәләкәй.

Әнием ак сәйлән тезеп
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә түбәтәем —
Мин бүген бик бәхетле!

*Вәсимә Хәйруллина*

## Чигүле читекләрем

Аягымда чиккән читек,
Бизәге көлеп тора.
Нәкыш җепләрдән күңелгә
Җылы нур бөркеп тора.

Салават күпере төсе
Җемелди итекләрдә.
Останың кул җылыларын
Тоямын читекләрдә.

Биегән саен биетә
Каюлы читекләрем.
Үземә килешеп тора
Чигүле читекләрем.

*Лиана Әмирханова*

## Мәчет

Тора, ерактан күренеп,
Тора, нур чәчеп,

Тора, күзнең явын алып,
Үзенә дәшеп,

Авылыбыз уртасында
Матур, зур мәчет!

*Роберт Миңнуллин*

## Татар баласы

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә:
Нинди гүзәл татар кызы! —
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә:
Нинди матур татар улы! —
Күз тимәсен үзенә.

Үзе тыйнак, үзе горур,
Хак сүз булыр әйткәне.
Яратыр газиз Ватанны,
Сөяр әткәй-әнкәйне.

Дәү булгач та шулай калыр —
Татар баласы булып.
Әйтерләр:
— Татар кызы бу!
Диярләр:
— Татар улы!

*Ләбиб Лерон*

## Ислам дине

Исламның нигезләре биш —
Күп түгел алар, бик аз:
Иман, намаз, руза тоту,
Зәкят бирү һәм дә хаҗ.

Ислам динен тоткан кеше
Мөэмин-мөселман була.
Ходай кушкан хак дин белән
Дөньяда гамәл кыла.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## Сигез таҗлы чәчәк

Ясап куйдым бер чәчәк,
Сигез таҗлы ал чәчәк.
Һәр таҗыннан яхшылык
Һәркем табып алачак.

Берсе аның — мәрхәмәт,
Икенчесе — мәхәббәт,
Өченчесе — тыйнаклык,
Дүртенчесе — җыйнаклык,

Бишенчесе — ихласлык,
Алтынчысы — гаделлек,
Җиденчесе — тугрылык,
Сигезенче — гадилек.

Кайсы кирәк ал, дустым,
Мин тагын да ясармын.
Сигез таҗлы чәчәккә
Яхшы сүзләр язармын.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Азан әйтә бер малай

Биек мәчет манарасы,
Кыйбла якта ярымай.
— Аллаһу әкбәр!
— Аллаһу әкбәр!
Азан әйтә бер малай.

— Аллаһу әкбәр!
Азан әйтә
Бер малай манарада,
Нечкәреп китә күңелләр,
Горефләр яңарганда.

Азан әйтә, сузып-сузып,
Чын күңелдән тырышып,
Кечесе-олысы тыңлый
Моңлы азан тавышын.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Курчак театрында

Киң урамны тар итеп,
Без театрга киттек.
Якын булгач арасы,
Җәяү генә барасы.

Гади театр түгел —
Курчак театрына!
Төсле утлар балкыган
Могҗизалар кырына...

Театрның ишеген,
Елмаеп, кем ачты соң?..
Буратино бит инде,
Тотып алтын ачкычын.

Кәҗә белән Сарык та
Чыккан безнең каршыга.
Бөтен таныш курчаклар —
Көлеп тора барсы да.

Бармакларын тырпайтып,
Биеп йөри Шүрәле...
Алтын тарак чәчендә —
Су анасын күр әле!..

Аюлар да бүреләр
Тирәбездә йөриләр.
Этләре дә бик юаш,
Тешләмиләр, өрмиләр...

Хуш киләсез, балалар!
Хәзер башлыйбыз, диләр.
Бергә-бергә бик зур эш
Эшләп ташлыйбыз, диләр.

Сукты тылсым сәгате:
Утырдык, залга кереп.
Серле пәрдә артыннан
Курчаклар чыкты килеп...

Аннан нәрсә булганын
Сөйләп тормыйм калганын...
Үзең күреп кайт!
Бармы
Театрга барганың?..

*Лена Шагыйрьҗан*

## Безнең китапханәдә

Безнең китапханәбез
Җылы, кояшлы, иркен.
Дөрестән дә, эш беткәч,
Шунда киләбез һәр көн.

Гөлләр белән бизәлгән
Якты уку залы бар.
Ул рәсемле журналлар...
Ни телисең, бары бар.
Телисеңме ал, укы
Космонавтлар турында,

Телисеңме, дөнья гиз,
Утырып бер урында.
Монда һәркем бик тыйнак,
Беркем утырмый уйнап,

Утыралар шым гына,
Барын белеп, тын гына.
Йөреп тора зур сәгать,
Тик тормаучы шул гына:
— Келди-келди-келди, — ди, —
Кем күбрәк белде? — ди.

*Зәкия Туфайлова*

***

## Канатлы ай

Кич. Авыл тынлык куелыгына чумган. Үзе шундый җылы. Өйгә һич керәсе килми. Капка төбендәге утыргычта, кичке шәфәкъ матурлыгына хозурланып, әнисе белән нәни кыз Фирая сөйләшеп утыралар. Утыралар дигәч тә, утыргычта әнисе генә утыра, ә Фирая аның итәгенә менеп кунаклаган.

Күк гөмбәзендә, учлап сибелгән энҗе-мәрҗәннәрдәй, йолдызлар җемелди.

Аларның барысын да уздырып, түм-түгәрәк ай көмештәй нурларын җиргә сибә, гүя ул шулай Фираяны сөеп елмая. Айның ике ягында да аккош канатларыдай, нәфис кауры болытлар йөзеп йөри. Тулган, менә-менә канатланып очып китәрдәй тоела. Әнисенең итәгендә иркәләнеп утырган Фирая да, әлеге сихри күренештән әсәрләнеп, соклану тулган күзләрен күк гөмбәзеннән ала алмыйча:

— Әни, әни, әнием, кара әле! — ди. — Кара... әнә анда, күктә, аккоштай ак канатлы ай йөзә. — Талпына-талпына, нәни кулларын чәбәкли. — Канатлы ай!..

Әнисе дә айга карый.

— И-и-и кызым, рәхмәт төшкере! Искиткеч нурлы икән шул кичке ай. Гаҗәп икән. Кызлар шикелле елмая. Гомеремдә дә мондый айны күргәнем юк иде. Бәхеткә генә була күрсен мондый хозур, мондый матур күренеш, — дип, үз нәүбәтендә хыялый, күбәләктәй канатланган нәни кызына карап, нурлы айдай елмая.

Әйе шул, әниләр янында ай да канатлы.

*Нәкыйп Каштанов*

## Кара төс ни өчен кирәк?

Айдар рәсем ясарга ярата. Менә бүген дә ул, төсле карандашлар алып, өстәл янына килеп утырды. Әтисе аңа ап-ак кәгазь бирде.

Иң башта Айдар йорт ясап куйды. Йортның түбәсен ул кызылга, ә тәрәзәләрен зәңгәргә буяды. Аннары йорт янәшәсендә бакча ясады. Бакчада исә ямь-яшел агачлар, ә ямь-яшел агачларда кызарып пешкән алсу чияләр, алтын-сары алмалар пәйда булды. Аннан соң Айдар көмеш сулы елга ясады. Көмеш сулы елга буйлап, ап-ак кораб йөзеп килә иде.

Әмма шул мәлне йортны... кызыл телле ут — ялкын ялмап алды.

— Ни ясыйсың, улым? — диде аңа әтисе.

— Сугышны ясыйм, әти, — диде Айдар һәм буш калган урынга танклар, танклар артына исә кулларына автомат тоткан сугышчыларны ясап куйды. Боларның һәммәсен дә ул яшел, коңгырт төсләр белән чуарлады. Ак корабка да туп көпшәсе ясап куярга онытмады. Ә йортны ялмап алган ялкын телләрен Айдар бакчадагы агачларга күчерде.

— Улым, мин бит сиңа ап-ак кәгазь бирдем, ә син аны капкара иткәнсең, — дип, әтисе башта көлеп куйды. Аннары исә, җитдиләнеп:

— Сугышның, улым, бер генә төсе бар, — диде. — Кара төс ул... Шундый заман җитәр — сугышлар бөтенләй булмас! Менә шул чагында синең улың да кара төс белән кара карлыгачлар гына буяр!

*Марат Закир*

# «МУЗЫКА»
# БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ

## МӘКАЛЬ, ӘЙТЕМНӘР

* Җыр — кешенең юлдашы.
* Җыр белгәнгә җыр — һөнәр, җыр белү дә — зур һөнәр.
* Җыр — күңеллегә куаныч, күңелсезгә юаныч.
* Җырның канаты бар.
* Эчең пошса, музыка уйна; уйный белмәсәң, уйнаганны тыңла.
* Атам-анам биегән, күңел ачкан биюдән; уйнап-җырлап биемәгән — җебегән.
* Һәр заманның үз көе.

## ТАБЫШМАКЛАР

* Телләре бик күп булса да,
Һәркем аңлый, үз итә.
Елата да, җырлата да,
Кирәк икән — биетә.
*(Гармун)*

* Борынгы булсам да мине
Онытып бетермиләр,
Милли гармуныбыз диеп,
Сәхнәдән төшермиләр...
*(Тальян гармун)*

* Гармуннарның патшасы мин,
Телләрем йөздән артык.
Яшьләр кулында йөримен,
Тиз генә килмәс картлык.
*(Баян)*

* Алты-җиде генә булыр
Тәнемдәге уемнар.
Миннән башка үтми иде
Аулак өйләр, уеннар.
*(Курай)*

* Курайларның туганы мин,
Ләкин тавышым үзгә:
Колакларны ярып керә,
Өстәп куйсаң мөгез дә.
*(Сорнай)*

* Үзе кыллы, үзе телле,
Идәндә басып тора.
Уйнарга теләгән кеше
Иң беренче — утыра.
*(Пианино)*

* Иң озын муен миндә,
Иң кыска исем миндә.
Кылларымны чиерткәләп,
Көй чыгарырсың син дә.
*(Саз)*

* Уйнавы — дүрт кылда,
Тавышы — сокландыргыч!
Нәзек муенында
Дүрт нәни кара боргыч.
*(Скрипка)*

* Кечкенә генә өй,
Эче тулы көй.
*(Радиоалгыч)*

* Тартма эчендә кеше,
Җырлау-сөйләүдә эше.
*(Телевизор, диктор)*

* Сырлы, сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул.
*(Гармун)*

* Бу ясалма тәрәзәгә
Дөнья хәлләре сыя.
Кичләрен ул үз алдына
Бөтен гаиләне җыя.
*(Телевизор)*

* Бу сихерле нәни тартма
Мең төрле көй көйләтә,
Һава торышын әйтә ул,
Илбашларны сөйләтә.
*(Радиоалгыч)*

* Попугай түгел, җаны юк,
Әйткән сүзне кабатлый.
*(Магнитофон)*

* Эче буп-буш,
Тавышы дөньяга сыймый.
*(Барабан)*

* Барысы дүрт кыл анда,
Сызган чакта моңлана.
*(Скрипка)*

## Табышмак-шигырьләр

* Елга ул тик бер килә.
Ул килсә, җир гөр килә.
Яшел чыршы әйләнә
Якты заллар күркенә.
*(Яңа ел)*

* Бер карчык яши кара урманда.
Ничек курыкмый яши ул анда?
Аның үзеннән, күрсәң,
куркырлык.
Куркыныч карчык була — ...
*(Убырлы)*

* Килә, бары кыш җиткәч,
Иске ел үтеп киткәч.
Үзе белән һәрвакыт
Яңа ел алып килә.
Бүләк тулы капчыгын
Иңенә салып килә.
*(Кыш бабай)*

* Кыш бабайның юлдашы.
Аның белән гел бергә.
Шуңа аны җәй көне
Мөмкин түгел күрергә.
Җәй көне ул бөтенләй
Мөмкин хәтта эрергә,
Суга әверелергә.
*(Кар кызы)*

*Рафис Корбан*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Музыка

Күңелле музыка
Яңгырый зал якта.
Музыка көенә
Җырларга, биергә,
Төз атлап йөрергә
Өйрәтә Сара апа, —
Ул безне ярата...
*Бари Рәхмәт*

## Сәйдәш моңнары

Назлый Идел дулкыннарын
Кояш нурлары.
Кояш нурларыдай җылы
Сәйдәш моңнары.

Сандугач сайравы назлый
Урман, кырларны.
Сандугачны сокландыра
Сәйдәш моңнары.

Сәйдәш җырларына гашыйк
Хезмәт уллары.
Күңелләрдә мәңге яши
Сәйдәш моңнары.

*Мәхмүт Хөсәен*

## Курай

Абый белән икәүләп
Ясадык без бер курай.
Уйнап җибәрсәк курай,
Кушылып сайрый тургай.

Сайрады да сайрады,
Яратты көебезне.
Болыннан өйгә кадәр
Озата килде безне.

*Рәшит Бәшәр*

## Мин аннан үрнәк алам

Бабай уйный, мин биим,
Бии белмимен, димим.
Әйе шул, шулай шул,
Бии белмимен, димим.

Ул нинди көй уйнаса,
Аяк шул көйгә баса.
Әйе шул, шулай шул,
Аяк шул көйгә баса.

Гармунчы булгач бабам,
Мин аннан үрнәк алам.
Әйе шул, шулай шул,
Мин аннан үрнәк алам.

*Мөҗәһит*

## Курай

Курайда кырлар догасы,
Чишмә тавышлары бар.
Курайда туган як гаме,
Кеше сагышлары бар.

Иң элек курайда туа
Һәр аткан таңның көе.
Курай ул — тылсымлы әйбер,
Курай ул — моңның көе.

*Галимҗан Гыйльманов*

## Мандолина

Бер мандолинам бар минем,
Көн дә алып, аны көйлим;
Әкрен генә чиртәм кылын,
Эндәшә ул: тллин-тллин...

Шундый матур тавыш чыккач
Куанам, кызып китәм мин.
Матур-матур көйләр уйныйм:
Тллин-тллин, тллин-тллин.

*Әнәс Кари*

## Фейерверк

Әнә бер ракета
Һавага атыла.
Ә аннан меңләгән
Ут-чәчәк ачыла.

Тагын да, тагын да
Ракета чөелә.
Канәфер, розалар
Һавага өелә.

Ут-чәчәк балкышы —
Фейерверк-тамаша.

Соклану, куану,
Күзләрең камаша.
Могҗиза, әкият,
Бәйрәмнәр тылсымлы.
Күңелгә төшә күк
Ут-чәчәк очкыны.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Бииләр итек, читекләр

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин,
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.

Учларыңны шакылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.

Әй, бии итек, читекләр!
Әй, уйныйм мин, уйныйм мин,
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин!

*Шәүкәт Галиев*

## Әйлән-бәйлән

Сез дә безгә кушылыгыз —
Без шатлык таратабыз.
Тирә-якны яңгыратып
Җырларга яратабыз.
Әйлән-бәйлән,
　　әйлән-бәйлән,
Безнең белән,
　　безнең белән әйлән!
Җыр ул — канат,
Җыр ул — бәйрәм!

Без биибез тыпыр-тыпыр,
Без биибез тып та тып.
Бер башласак, бик тиз генә
Булмый безне туктатып.

Ягез, сез дә кушылыгыз,
Утырмагыз, торыгыз!
Җырлый-җырлый
　　　　биик әле,
Сез кул чабып торыгыз.

*Роберт Миңнуллин*

# «БӘЙРӘМНӘР КИРӘК БЕЗГӘ...»

## Сентябрь

Инде яланда
Көз җиле исә,
Мәктәп ишеге
Ачылды кичә.

Уңыш җыелды,
Һәм кошлар китте,
Чөнки көз ае —
Сентябрь җитте.

Урамнар тулып,
Йөкләр үтәләр,
Алар дәүләткә
Ашлык илтәләр.

Бар да ашыга,
Тизрәк илтик дип,
Илебезне бай,
Матур итик дип.

*Нур Гайсин*

## Түтәлләрдә үсте яшелчә...

Түтәлләрдә үсте бик
күп яшелчә:
Кыяр, кабак, чөгендер,
кишер, кәбестә.
Алар ничек үсә,
Нинди төстә?

— Катлы-катлы булып үсә,
Җир өстендә
Ул нәрсә?
— Кәбестә.

— Йодрык-йодрык булып үсә,
Алма кебек кызарып пешә,
Үзе бик матур, аны кем әйтер?
— Помидор.

— Ул җир астына төшкән,
Кып-кызыл булып пешкән,
Ашка тәм һәм төс бирер...
Аны кем белер?
— Чөгендер.

*Хәләф Гарданов*

## Чөгендер

Чөгендер, әй чөгендер,
Син яраткан сыемдыр,
Чия кебек төсләрең
Бизи өстәл өсләрен.

Телем-телем түгәрәк,
Куям сине телгәләп,
Өстәлебез түрдәрәк,
Сыйланабыз, бергәләп.

*Әдхәт Синугыл*

## Яшелчәләр бәхәсе

Көзгә таба бакчада
Яшелчәләр җитешә.
— Кайсыбыз иң яхшысы? —
Дип, алар бәхәсләшә.

— Мин иң кызыл арада, —
Помидор горурлана. !
— Без иң хуш исле гөлләр, —
дип,
Рәйханнар хозурлана.

Кыяр билгә таянган:
— Мин яшел, иң кетердек,
Хуҗабикә тәпәнен
Без тутырып бетердек.

Тырышудан шәмәхә
Төскә керә баклажан:
— Минем салат иң тәмле,
Кабып кара банкадан.

— Мин иң сары, —
ди шалкан, —
Тәмгә тәмле сары май.
— Ә миндә иң күп күлмәк, —
ди кәбестә, — мин иң бай!

— Миндә иң күп каротин,
Ашап кына кара син!
Үзем баллы, кетердим,
Кояш төсле кишер мин.

— Мин иң ачы, — ди суган, —
Сарымсак — минем туган.
Алга чыга чөгендер:
— Бу бәхәс ни өчендер?

Без барыбыз иң-иңнәр,
Бергә булсак, юк тиңнәр.
Без — тау-тау
ВИТАМИННАР.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Кыш килде

Урамнарга, бакчаларга,
Урман, кырлар өстенә
Ак мамыктай күбәләк кар
Төшә дә төшә генә.

Һава саф — рәхәт суларга,
Яп-якты бөтен урын,
Кыш бабай килде кунакка,
Җир киде йомшак тунын.

*Мостафа Ногман*

## Чыршы әйләнәсендә

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч булачак
Котлаулар да, бүләк тә!
Яңа елда чынга ашар
Безнең бөтен теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без beләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!

*Роберт Миңнуллин*

## Кыш бабай килгән

Безгә Кыш бабай килгән,
Яңа ел алып килгән.
Капчыгына күп итеп
Бүләкләр салып килгән.

Көттек сине, сагынып,
Исән-саумы, Кыш бабай.
Өләш бүләкләреңне,
Капчыгыңны чиш, бабай.

*Рафис Корбан*

## Кыш бабай

Әй! Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә якын дус бабай.
Көтеп алдык без сине,
Күңелләргә хуш бабай.

Ак туныңны кигәнсең,
Безне котлап килгәнсең.
Сине көтеп торганны
Әллә кайдан белгәнсең.

*Туфан Миңнуллин*

## Кыш бабай

Яшел чыршы тирәсендә
Җыелып бертугандай,
Әйлән-бәйлән уйный идек,
Килеп керде Кыш бабай.

Әй Кыш бабай, Кыш бабай,
Хуш киләсең, уз бире,
Кунак булып килер дип,
Күптән көттек без сине.

Рәхмәт, рәхмәт, күп бүләк
Китергәнсең безгә син,
Без нәни дусларыңны
Сөендерим дигәнсең.

Бәйрәмебез син килгәч
Матурланды тагын да,
Бик күңелле уйнавы
Яшел чыршы янында.

*Әнәс Кари*

## Исәнме, Кыш бабай!

Кыш бабай, Кыш бабай,
Исән-сау килдеңме?
Син бездә Яңа ел
Икәнен белдеңме?

Белдеңме син безнең
Сагынып көткәнне?
Үзең дә көттеңме
Яңа ел җиткәнне?

Без көттек бик күптән,
Яңа ел килә дип,
Сиңа дип сөйләргә
Шигырьләр өйрәндек.

Кулга-кул тотышып
Ясыйк та түгәрәк,
Әйдә, кил, Кыш бабай,
Әйләник, бергәләп.

Яңа ел сиңа да
Сөенеч китерсен.
Тагын бер ел үткәч,
Яңадан килерсең!

*Рафис Корбан*

## Чыршы

Төрле-төрле утлар яна,
Без уйныйбыз, әйләнеп.
Бигрәк матур, бигрәк ямьле
Безнең чыршы бәйрәме.

Җырлый-җырлый әйләнәбез,
Чыршы тора уртада.
Кунак булып, ак сакаллы
Бабай килгән бәйрәмгә.

Чыршыдагы җем-җем утлар
Сүнәләр дә яналар.
Без җырлыйбыз, шатланабыз,
Без — бәхетле балалар.

*Әхмәт Ерикәй*

## Бушлык

Өйнең эче яп-ялангач,
Белмимен әллә нигә.
Кайтып керәсе дә килми
Бүген бөтенләй өйгә.

Бөтен нәрсә үз урынында,
Тик җитешми әллә ни...
Әй, онытып торам икән:
Өйдә юк бүген әни.

*Фәнис Яруллин*

## Бүген бәйрәм

Байрак элдек без
Бүген урамга,
Безнең Армия
Көне булганга.

Әйдә, зур бәйрәм,
Шатлык белән кил,
Сине каршылый
Бөтен Туган ил.

Ватаныбызның
Чикләрен саклап,
Батыр абыйлар
Торалар сакта.

*Нур Гайсин*

## Батыр һөнәр

Батыр һөнәр бар җирдә —
Җирне, илне саклаучы.
Сине, мине — һәркемне
Дошманнардан яклаучы.

Генералмы, майормы,
Капитанмы йә сержант —
Барсының да исеме
Дөньяда бер ул — солдат.

Ватанны саклаучылар
Аямыйлар үз-үзен:
Беләкле, йөрәклеләр,
Ихтыярлы һәм түзем.

Саклап Ватанны, безне
Хәтәр сугыш утыннан,
Батыр һөнәр иясе
Китә туган йортыннан.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Әти бәйрәме көнне

Әти бәйрәме көнне
Без пешердек пилмән.
«Шундый тәмле булган —
Бөтен җире килгән».
*(Бусын әти әйтте.)*

«Челтәр-челтәр читләгән —
Камыры тишелмәгән,
Пилмән пешерүченең
Көче бушка китмәгән...»
*(Бусын әби әйтте.)*

«Кызым да бит булышты:
Борычлашты, тозлашты,
Сарымсагын, суганын
Кирәк кадәр салышты».
*(Бусын әни әйтте.)*

«Әнием камыр җәйде,
Итен турап чыгарды,
Әнием тырышмаса,
Шулай матур чыгармы?»
*(Бусын мин әйттем.)*

*Бикә Рәхимова*

## Әти дә көлеп торсын

Кояш көлә, мин елмаям,
Сигезенче март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй,
Бөтен нәрсә пакь булсын.

— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнне
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын.

*Зәкия Туфайлова*

## Әти белән бергәләп

Әниләрнең бәйрәмендә
Безнең өйдә бер гадәт:
Чәй табыны әзерлибез
Әти белән бергәләп.

Ашыгып, чәкчәк ясыйбыз,—
Пешеп килә бавырсак.
Йә, кайсына өлгерергә,
Бигрәкләр дә авыр чак.

Өйдәгеләр уянганда
Әзер инде һәммәсе,
Әти әйтә: «Булганы шул,
Ни диярсең, әнкәсе?»

Әнием бер безгә карый,
Бер безнең сыйга карый:
Бу кадәрле нигъмәтләрдән
Өстәл сынмаса ярый. —

Әй мактыйлар безнең сыйны:
— И тәмле соң, уңган соң! —
Әти белән мин пешергәч,
Нигә тәмле булмасын?!

*Газиз Нәбиуллин*

## Бүләк

Нәни кыз Гөлчәчәк
Салкын кыш көнендә
Чәчәкләр үстерә
Тәрәзә төбендә.

Су сибә аларга
Һәр иртә һәм кичен,
Беләмсез ул шулай
Тырыша ни өчен?

Тиздән бит әниләр
Бәйрәме җитәчәк,
Шул көнгә зур бүләк
Әзерли Гөлчәчәк.

*Данис Хәбибуллин*

## Бүген әниләр бәйрәме

Нигә бүген бөтен җирдә
Чәчәкләр балкый бездә,
Нигә кояш көлеп карый, —
Беләбез һәммәбез дә.

Бүген — әниләр бәйрәме,
Бүген җирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.

Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Җирдә барлык балалар.

Мин дә котлыйм, әнкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә.

*Резеда Вәлиева*

## Әнием

Әнием минем матур,
күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була,
ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
әни миңа елыша.

Битләре аның кайнар,
ә куллары йоп-йомшак.
Конфет та кирәк түгел,
кирәк түгел курчак та,
чөнки мин әниемне
алдым инде кочаклап.

*Ренат Харис*

## Минем әни иң әйбәт

Кемнең әнисе иң әйбәт?
Минем әни, әлбәттә.
Өйрәтә әни безне дә
Әйбәт, матур гадәткә.

Үзе бөтен эшкә оста,
Безне өйрәтә җайлап.
Мактый, күңелне күтәрә,
Иң кирәк сүзләр сайлап.

Иң чибәр әни минеке,
Толымнарын карачы.
Кояш кебек, нурлар сибә
Ягымлы күз карашы.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Дәү әни

Дөньяда иң җылы әби —
Безнең әби, беләбез.
Шуңа күрә энем белән
Куенына керәбез.

Дәү әнинең кочагында
Китәбез эреп кенә.
Яшәрбез әле, үскәч тә,
Кадерен белеп кенә.

*Йолдыз*

## Әбиемне яратам

Мин үзем шәһәрдә яшим,
Авылга кайтам җәен.
Чөнки ул авылда яши
Яраткан әбекәем.

Әбием анда ялгыз яши,
Мине сагынып көтә.
Мин кайткач, шатланып йөри,
Мине бик кунак итә.

Мин, үскәч, әбием белән
Авылда торачакмын.
Әбием картаеп киткәч,
Ярдәмче булачакмын.

*Гөлшат Зәйнашева*

## Минем әбием

Әбием күзлек кия,
Чәчләренә чал кунган.
Бер көн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.

Минем әби энемне
Бәй-бәй итә, пәп итә.
Ул йокыдан торганда,
Мәмие пешеп җитә.

Әбекәй, алтыным,
Минем иң якыным.
Яратам, яратам,
Яратам мин аны!

*Галимҗан Латыйп*

## Әбием килгән

Өйгә кайтсам, өй балкыган —
Өйгә нур иңгән!
Ерак җирне якын итеп,
Әбием килгән!

Үзен ничек сагынганны
Белгән ул, белгән!
«Күрим әле улымны!» — дип,
Әбием килгән!

*Фирая Зыятдинова*

## Карга боткасына сый җыйганда
*(Халык авыз иҗаты)*

Өйдәме, түтәй!
Җәтрәк бир күкәй.
Бирсәң безгә өч күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.
Май кирәк, ярма кирәк,
Карга туена бар да кирәк.

Тагын, булса, он чыгар,
Пешерербез без чумар.
Шикәр кирәк, тоз кирәк,
Чыгар, түтәй, тизрәк!
Синең кебек уңган түтәй
Бу дөньяда бик сирәк.

## Бәйрәмгә чакыру
*(Халык авыз иҗаты)*

Карга әйтә: кар, кар,
Туем җитте, бар, бар!
Ярма, күкәй алып бар,
Ипи-итең алып бар,
Карр, карр, карр!

## Карга боткасы

Яз җиттеме, безнең әби
Ясый «карга боткасы»,
Ботка белән сыйланалар
Бөтен авыл баласы.

Аның яме! Аның тәме
Телләреңне йотарлык!
Аның тәмен ел буена
Саклап кына тотарлык.

*Әзһәр Габиди*

## Карга боткасы

Җиребезгә язлар килгәч,
Кошлар кайткач ерактан,
«Карга боткасы» пешергән
Халкыбыз чын йөрәктән.
Бу бәйрәм безнең көннәргә
Килгән, гасырлар үтеп.
Каргалар да, без дә аны
Һәр ел алабыз көтеп.

Быел да менә пешердек:
Салдык тәмле ярмалар,
Сыйланыгыз, туган якны
Сагына белгән каргалар!
Изге йола, еллар кичеп,
Киләчәккә дә барсын.
Үз боткаларын ашарга,
Берүк, каргалар калсын!

*Йолдыз*

## Күкәй бәйрәме

Безнең якта бәйрәм бүген,
Бездә бүген тантана!
Өйдән-өйгә йөреп әнә
Күкәй җыя һәр бала.

Төсле күкәй, төсле күкәй!
Бик матуры бер генә!
Иң матуры — иң өлгергә,
Алыгыз, кем өлгерә?!

*Лиана Әмирханова*

## Нәүрүз мөбарәк булсын!

*(Халык авыз иҗаты)*

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

## Нәүрүз

Әнә яз яшелләнә,
Җир-анабыз гөлләнә,
Бозны тишә ак чәчәк,
Көнгә бага саф чәчәк!

Бүген көн тиң төннәргә,
Урын юк һич көнләргә,
Без дә тиң, без дә тигез!
— Мөбарәк Нәүрүз! — дибез.

*Әхмәт Гадел*

## Туган тел бәйрәме

Кунакка килдек мәктәпкә,
Туган көн бәйрәменә.
Туган көн кебек кадерле
Туган тел бәйрәменә.

Сөенмичә ни —
бәйрәм ич! —
Шигърият дигән илдән
Шагыйрә апалар белән
Шагыйрь абыйлар килгән.

Без киләсен белеп, дуслар
Алдан ук сөенгәннәр.
Туган көндәге шикелле,
Бик матур киенгәннәр.

Матур сүзне матур сүзгә
Сөйлибез, бәйләп кенә.
Әйләнсен һәрбер көнебез
Туган тел бәйрәменә!

*Лена Шагыйрьҗан*

## Һәйкәл

— Тукай туган Кушлавычта,
Исмен данлый һәйкәле,
Аңа кем соң һәйкәл куйган,
Энем, белсәң, әйт әле?

— Беләм, абый, зур
шагыйрьнең
Китабы гел кулымда,
Аның моңы, үлмәс җыры
Яши күңел кылымда.

Гасырларга барсын диеп,
Аңа һәйкәл куелган.
Халык мәхәббәтен салып,
Исме ташка уелган.

*Нур Гайсин*

## Май килә

Дөньяны яктыртып,
Кояшлы Май килә.
Йөзләрне балкытып,
Урамда Май көлә!

Һәммәбез сагынып
Көттек Май килүне —
Китерә ул безгә
Иң Бөек Җиңүне!

Бәйрәмнәр еш булмый —
Гел шатлан, гел елмай!
Май килә дөньяга —
Чәчәкле, җырлы Май!

Май килә бәйрәмле
Көннәргә бай булып.
Калыр ул хәтердә
Иң якты Май булып!

*Роберт Миңнуллин*

## Якты ай, яхшы ай

Җир буйлап йөгерә
Җылы ай, якты ай.
Чәчәкләр сибә ул
Бәйрәмле ямьле ай.

Байраклар, флаглар
Бәйрәмгә җыелган.
Бабайлар янына
Оныклар сыенган.

Бизәлгән, киенгән
Матурлык көннәре.
Җиңүле, горур май —
Батырлык көннәре.

Бабайлар күзендә
Энҗе яшь калтырый,
Малайлар күзендә
Горурлык ялтырый.

Мәйданга чакыра
Зур Җиңү бәйрәме.
Һәйкәлләр янында
Чәчәкләр бәйләме.

Яңгырый сафларда
Җиңүгә дан җыры.
Өзелмәс дәвамлы
Буыннар чылбыры.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Җиңү көнендә

Яз сулышы белән бергә
Бәйрәм йөри, авыл буйлап.
Күрше Сәрби әби генә
Яшен сөртә, авыр сулап.

Мин чәчәкләр җыям аңа,
Бүлмәсенә ямьнәр тулсын.
Җиңү белән бергә илгә
Улы кайткан кебек булсын...

*Резеда Вәлиева*

## Минем бабай

Минем бабам — капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.

Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,

Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан.

*Эльмира Шәрифуллина*

## Батыр булам

Бабаем медальләрендә
Кояш нурлары уйный.
Аның шикелле үк, мин дә
Батыр булырга уйлыйм.

Ләкин сугышны яратмыйм,
Килми аны күрәсем.
Килми минем япь-яшь килеш
Яу кырында үләсем.

Бабама охшыйсым килә,
Хыялым ерак китә.
Хезмәт батыры булырмын,
Тынычлыкка ни җитә?!

*Йолдыз*

## Рәхмәт әйтә сиңа кызың

Уеннарымны онытып,
Кулларыма чәчәк тотып
Киләм, бабай, яннарыңа.

Сөйләвеңнән кем дә туймый,
Мин дә сине тыңлый-тыңлый
Утырыйм әле алларыңа.

Сугышларда булгансың син,
Дошманнарны кугансың син,
Узган юлың ай-һай озын.

Илгә тугры калган өчен,
Батыр исеме алган өчен
Рәхмәт әйтә сиңа кызың.

*Энҗе Авзалова*

## Бабам истәлеге

Шактый еллар үтте инде
Бабаемның вафатына.
Юксынганда, мин еш кына
Медальләрен алам кулга.

Җансыз тимер медальләрдән
Дары исе аңкып тора.
Әйтерсең лә минем алда
Бабам үзе басып тора.

Бу медальләр сөйли миңа
Бабам үткән сугыш юлын.
Медальләрнең чыңнарыннан
Калтыранып куя кулым...

*Лиана Әмирханова*

## 1 июнь — Халыкара балаларны яклау көне

Шундый якты, шундый көләч
Беренче көне җәйнең,
Назлап кына сыйпап сөя,
Кочагыдай әнинең.

Балаларны яклау көне —
Шундый матур бәйрәм бар,
Мәйдан тулы бала-чага,
Балаларга урам тар.

Бәхетле безнең балачак,
Яклау-саклаулы булгач,
Чыңлап тора җырларыбыз,
Чәчкәгә, нурга тулгач.

*Вәсимә Ураксина*

## Сабантуй

Чәчәккә күмелгәч тугайлар,
Июньнең иң матур көнендә
Болынның иң матур җиренә
Килегез Сабантуй күрергә!

*Энҗе Мөэминова*

## Сабантуй

Ник безгә дә көрәшмәскә,
Мәйдан тотмаска әле.
Көрәшик, әйдә, бергәләп,
Бүген бит яз бәйрәме.

Сабан туенда көрәшеп,
Бил бирмәскә өйрәник.
«Без һәрвакыт әзер!» — дигәч,
Җиңелмәскә өйрәник.

Куәтебез ташып тора,
Һәркемдә — ярсу йөрәк.
...Без беләбез: әтиләргә
Лаеклы алмаш кирәк!

*Газинур Морат*

## Сабантуй

Сабантуймы, сабантуй —
Уеннар туе бит ул,
Тәм-томнар сые бит ул,
Җиңүләр уе бит ул.

Чаптар өстендә чабып,
Катыктан тәңкә табып,
Колга башына менеп,
Узышлыга йөгереп

Һәм татарча көрәшеп,
Аркан белән сөйрәшеп,
Ватмый, йомырка ташып,
Тапкырлыкта сынашып

Җиңсәң әгәр,
Сабантуй —
Эчкә шатлык
сыймас туй!

*Эльмира Шәрифуллина*

## Сабан туе батыры

Быел батыр кем дисәң,
Батыр калды Шәвәли.
Зур мәйданда берүзе
Басып калды Шәвәли!

Басып калды Шәвәли —
Екты ул барчасын да.
Батыр калды Шәвәли
Балалар бакчасында!

*Шәүкәт Галиев*

## Сабан туе

Күңелле Сабантуйлары.
Бүген бәйрәм, зур бәйрәм.
Матур җырлар
җырлый-җырлый
Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

Күбәләкләр безнең белән
Уйныйлар әйлән-бәйлән.
Сабантуй — күбәләкләр һәм
Кошлар өчен дә бәйрәм.

Без җырлыйбыз Сабантуйда,
Иң матур җырлар сайлап.
Безнең җырга зәңгәр күктән
Кошлар кушыла сайрап.

Әти-әниләребезгә
Җыйдык чәчәк бәйләме.
Матур булсын,
ямьле булсын
Сабан туе бәйрәме.

*Гөлшат Зәйнашева*

## Сабантуй бүген бездә!

Шатлыклар — күңелебездә,
Ал кояш — күгебездә!
Килегез, дуслар, кунакка —
Сабантуй бүген бездә!

Җилферди чиккән сөлгеләр!
Бүләкләр — күбебезгә!
Көрәшик тә, узышыйк та —
САБАНТУЙ БҮГЕН БЕЗДӘ!

*Роберт Миңнуллин*

## Туган көн

Әлә-лә, әллә-лә,
Нинди бәйрәм, кем белә?
— Бүген туган Сөмбелә.
Туган көнгә апа да,
Әби, бабай да килә.

Әбидән — чәкчәк,
Ападан — чәчәк.
Бабайдан — бал, җимеш.
Әнидән — бәлеш,
Әтидән — уенчык:

Олы туп, курчак.
Әй сөенә кызчык!

*Вәсимә Хәйруллина*

## Туган көн җыры

Җыелдык без менә
Бергә бүген дә,
Утырабыз синең
Туган көнеңдә.

Бәйрәм итик әле,
Туган көн булгач.
Безгә дә күңелле,
Син көлеп торгач.

Туган көннән дә шәп
Бәйрәм юк икән,
Нигә без дә бүген
Тумадык икән.

Киләсе елда да
Бәйрәм итәрбез.
Без түземле халык:
Бер ел көтәрбез.

*Роберт Миңнуллин*

## Тагын бер сүз

Кар өстеннән җан-фәрманга
Йөгерә кояш нуры...
Йөгерә сезнең өйгә ул,
Ялгышмыйча, туп-туры.

Кояш нуры да белгән бит
Синең туган көнеңне.
— Алып бар, нур, ул кызыйга
Минем дә, дим, сүземне.

Котлыйм аны чын күңелдән
Туган көне белән мин.
Тагын, тагын бер сүзне әйт:
«Син бик-бик матур!» — диген.

*Илгизәр Солтан*

## Чыпчык

Килеп кунды тәрәзәгә,
Шакылдата шык та шык.
Минем туган көн икәнен
Каян белгән бу чыпчык?

Әни белән кунакларга
Ясый идек пәрәмәч.
Бер пәрәмәч артык бөктем,
Чыпчык кунакка килгәч.

*Вәсимә Хәйруллина*

## Бабай туган көн

Төрле-төрле бүләк алып,
Барча дуслар килгәннәр.
Бабай туган көн булганга,
Бәйрәмчә киенгәннәр.

Прәннек, конфетлар куеп,
Чәй әзерләгән әби.
Шарт-шорт чикләвек ваталар
Ләмига, Үзбәк, Нәби.

Курай уйный минем бабам,
Ә башкалар бииләр.
— Тагын, тагын килсен иде
Бабай туган көн! — диләр.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Иң матуры — мин!

Бүген минем туган көн.
Булсын иде ул һәр көн!
Матур бүләк алып килде
Мине котларга һәркем.

Уенчыклар җанлы түгел,
Еламыйлар, көлмиләр.
Иң матуры — мин үзем бит,
Никтер шуны белмиләр.

Аю, куянны ошаттым,
Сокланамын этемә.
Хәзер бүлмәм охшап калды
Уенчык кибетенә.

Ә әнием беләчәк,
Хәзер йөгереп киләчәк.
Ул гына аңлаячак:
Иң матурлар арсыннан
Тик мине сайлаячак.

*Йолдыз*

## Әхмәтнең укыйсы килә

Алты яшь тик әле Әхмәткә,
Бик йөрисе килә мәктәпкә.
«Кайчан җиде яшькә җитәм? — ди, —
Тиз-тиз генә үссәм икән», — ди.

«Улым, ашыкма, — ди әнисе. —
Кечкенә бит, яшь бит әле син.
Бер елдан соң йөри башларсың».
«Ә бер ел ул, әни, кайчан соң?

Иртәгәме? Берсекөнгәме?
Көннәр салкынайгач, көзгәме?
Әйт тә әйт!» — ди Әхмәт. Йә, ничек
Җавап бирсен инде әнисе?!

«Илдар тәпи йөри башлагач
Укырсың, — ди, җавап тапмагач. —
Бер ел үтәр, бәбкәм, шулчакта
Озатырмын сине мәктәпкә».

«Илдар! Илдар! Тор инде,
Тизрәк тәпи йөр инде».

*Бари Рәхмәт*

## Мәктәпкә барасы бар

Туйганчы уйнар идем дә,
Минем шул вакытым тар,
Иртәгә «биш»ле алырга
Мәктәпкә барасы бар.
Әтәчебез сизәр микән —
Бик иртә торасы бар.

Сез дә озак йокламагыз —
Мәктәпкә барасы бар.
Киләчәктә Туган илдә
Зур юллар саласы бар.
Ә хәзергә, соңламыйча,
Мәктәпкә барасы бар.

*Гәрәй Рәхим*

## Минем дустым — Әлифба

Мин иртә белән мәктәпкә
барам,
Беренче китап минем
кулымда.
Буран булса да, мин
юлны табам,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.

Шат күңел белән мәктәпкә
керәм,
Сабак укырга, белем
алырга.
Мин хәрефләрне әле аз
беләм,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.

Хәрефләр белгәч, сүзләр
язармын,
Каләмем кулда, дәфтәрем
алда.
Яшә, диярмен, туган
Ватаным,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.

Мин үсә-үсә буйга
җитәрмен,
Бәлки, юлларым китәр
еракка.
Таулар үтәрмен, диңгез
кичәрмен,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.

*Нәби Дәүли*

## Беренче көн

Бүген иртә уяндык,
Көнгә карап куандык.
Их, сикердек, шатландык,
Кош кебек канатландык.

Сентябрьнең бере ич,
Бүген уку көне ич.
Сикерешеп тордык без,
Бит-кулларны юдык без.

Ашап-эчеп киендек,
Шау-гөр килдек, сөендек.
Китап-дәфтәрләр салдык,
Матур сумканы алдык.

Бик күңелле сөйләшеп,
Шаулашып та гөрләшеп,
Иң беренче мәртәбә
Җыйналдык без мәктәпкә.

*Мөхәммәт Әхмәтгалиев*

## Бакча белән хушлашу

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде күбебез.
Бакча белән хушлашабыз,
Бүген соңгы көнебез.

Тик елыйсы килә минем,
Инде нихәл итәсе? —
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.

Тәрбияче апа елый...
Бу дөнья кызык кына:
Китәсе килми моннан да,
Мәктәп тә кызыктыра!

Күңелле дә, күңелсез дә...
Хәлемне белмиләр шул.
Китмәс идем, зур балалар
Бакчага йөрмиләр шул.

Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына.
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!

*Роберт Миңнуллин*

## Мәктәпкә!

Чәчәкләр тотып кулга,
Без чыктык матур юлга.

Һәркем белә, әлбәттә,
Без барабыз мәктәпкә!

Безне котлый әтиләр:
— Бик дәү үстегез! — диләр.

Өйрәтәләр әниләр:
— Әйбәт булыгыз! — диләр.

Дәү әти, дәү әниләр:
— Хәерле юл, хуш! — диләр.

*Бари Рәхмәт*

## Сара мәктәпкә бара

— Карасана, кара, Сара укырга бара!..

Әлеге яңалык иң әүвәле нәни оныклары белән ишегалдына чыккан әбиләрне, гәп сатып утырган апаларны хәйранга калдырды: «Күрче, зинһар, кай арада үсеп җиткән диген син аны!»

Ә инде Сара үзе күренгәч, комлы әрҗә эчендә уйнап утырган бала-чагалар да гаҗәпләнүдән авызларын ачып тынып калдылар.

Ул иртәдә Сара, чыннан да, карап туймаслык иде. Өстендә күз явын алырлык ак алъяпкыч, аякларында сыек саргылт төстәге өр-яңа сандаллар. Чәчләренә күк йөзе кебек җете зәңгәр «күбәләк» кунган. Янында кулына чәчәк бәйләме тоткан әнисе белән әтисе.

Сара комлы әрҗә эчендә җыелган дус-ишләре янына килмичә булдыра алмады.

— Мин бүтән сезнең белән уйный алмам инде... Мәктәпкә укырга барам...

Көннең икенче яртысында әбиләр, апалар үзләренең оныкларын янә ишегалдына алып чыктылар. Комлы әрҗә тирәсе яңадан бала-чагаларның чыр-чуы, шау-шуы белән тулды. Бу юлы инде дөньяларын онытып мәш килеп уйнаучылар арасында өс-башын алыштырып чыккан Сара да бар иде.

*Мәхмүт Хәсәнов*

## Эчтәлек

Аңлатма язуы....................................................................................3

### I кисәк. Балдай татлы балачак

### «Бәллүр бишек»

*2 яшькә кадәрге балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**......................................................16
Бишек җырлары, такмаклар.....................................................16
**Әкиятләр, хикәяләр**...................................................................17
Кәҗә бәтиләре һәм Бүре. *Татар халык әкияте*...............................17
Шалкан. *Рус халык әкияте*...........................................................18
Чуар тавык. *Рус халык әкияте*.......................................................19
Зилә бакчага бара. *З. Хөснияр буенча*.........................................19
Җиләккә барганда. *Җ. Тәрҗеманов*..............................................20
Мияубикә. *К. Ушинскийдан*...........................................................21
Настяның курчагы. *Л.Толстойдан*.................................................21
**Шигырьләр**...................................................................................22
Без чәбәкәй итәбез. *Н. Измайлова*...............................................22
Үчти-үчти. *Р. Харис*.........................................................................22
Бәллү. *Дәрдемәнд*...........................................................................22
Булатны йоклатканда. *Мөҗәһит*....................................................23
Ай, нәни. *Ә. Гадел*...........................................................................23
Бәлли-бәү. *Җ. Тәрҗеманов*............................................................23
Мияу! *Р. Миңнуллин*........................................................................24
Бәти. *Р. Корбан*................................................................................24
Чебиләр. *М. Хөсәен*..........................................................................24
Туп. *Ә. Бикчәнтәева*..........................................................................24
Тәп-тәп бас. *Х. Исмәгыйлев*............................................................25
Бии-бии үс, әйдә. *Ә. Бикчәнтәева*...................................................25
Беренче адымнар. *Ә. Кари*..............................................................25
Минем кызым – курчагым. *Җ. Тәрҗеманов*.....................................26
Чәбәкәй. *Х. Халиков*..........................................................................26

### «Мин бит әле бик нәни»

*2–3 яшьлек балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**......................................................28
Җырлар, юаткычлар, эндәшләр.................................................28
**Әкиятләр, хикәяләр**...................................................................30

Калач. *Татар халык әкияте*......30
Теремкәй. *Рус халык әкияте*......31
Йокы бабай. *Җ. Тәрҗеманов*......33
Карлар ява. *Г. Бакир*......34
Кар бабай. *С. Летовадан*......35
Нурбәк әкияте. *Батулла*......35
Варя белән Песнәк. *Л. Толстойдан*......37
Казлар. *К. Ушинский (А. Әхмәт тәрҗемәсе)*......37
**Шигырьләр**......38
Әтәч. *М. Җәлил*......38
Лап-лап. *Р. Харис*......38
Чәбәк-чәбәк. *Р. Харис*......39
Ул зу-у-у-ур үскән. *З. Туфайлова*......39
Туп-туп тубыбыз. *Ә. Бикчәнтәева*......39
Аюым. *Җ. Дәрзаман*......40
Беренче адым. *Ә. Бикчәнтәева*......40
Бәлли-бәү. *Р. Харис*......41
Гөлдергү. *Н. Каштан*......41
Син – минем нәнием. *Э. Шәрифуллина*......42
Йоклар алдыннан. *Н. Измайлова*......42
Су. *Б. Рәхмәт*......42
Ике. *С. Сөләйманова*......43
Йокла, курчак. *Г. Таһирова*......43
Гали белән кәҗә. *Г. Тукай*......44
Мыраубикә. *Д. Гарифуллин*......44
Маэмай. *Җ. Тәрҗеманов*......44
Кикрикүк. *Җ. Тәрҗеманов*......44
Әтәчем. *Б. Рәхмәт*......45
Чебиләр. *Ә. Кари*......45
Тавык. *Ә. Кари*......45
Кызыл Әтәч. *С. Сөләйманова*......46
Безнең сыер. *Ә. Кари*......46
Маэмай. *М. Җәлил*......46
Йә, алар кемнәр икән? *Д. Гарифуллин*......47
Яңгыр. *В. Хәйруллина*......47
Беренче кар. *Ә. Ерикәй*......47
Яз. *Ш. Галиев*......48
Кәккүк. *Ә. Кари*......48

**«Үсә-үсә зур булам»**

*3–4 яшьлек балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**.....50
Җырлар, такмаклар, эндәшләр, бармак уеннары.....50
**Әкиятләр, хикәяләр**.....52
Аю белән Бабай. *Татар халык әкияте*.....52
Кыз һәм икмәк. *Балалар матбугатыннан*.....52
Аю белән хатын. *Татар халык әкияте*.....53
Мәче белән Аю. *Татар халык әкияте*.....54
Кем нәрсә ярата? *Татар халык әкияте*.....54
Төлке белән Каз. *Татар халык әкияте*.....55
Төлке, Куян һәм Әтәч. *Рус халык әкияте*.....55
Өч аю. *Л. Толстойдан*.....58
Кызыл калфак. *Ш. Перро. (З. Садыйкова тәрҗемәсе)*.....60
Рөстәм. *Д. Аппакова*.....61
Сания инде зур үсте. *Г. Бакир*.....62
Бәби әйтә. *М. Әмир*.....62
Кечкенә Ринат. *Р. Гыйззәтуллин*.....63
Айсылу. *Р. Гыйззәтуллин*.....64
Яңа чана. *Р. Ишморатова*.....65
Песнәк белән Әнисә. *Г. Лотфи*.....66
Сания бакчага бара. *Г. Бакир*.....66
Минеке, тимә! *А. Әхмәт*.....67
Куян кызы. *А. Алиш*.....68
Елак Әтәч. *Батулла*.....69
Юынмый торган Балык. *Ә. Гаффар*. .....70
Чукмар белән Тукмар. *А. Алиш*.....70
Мактанчык бака. *И. Шәймөхәммәтов*.....71
Дару. *К. Ушинский* (*Ф. Басыйров тәрҗемәсе*).....72
Әтәч үзенең гаиләсе белән. *К. Ушинскийдан*.....72
Бергә җайсыз, аерым күңелсез. *К. Ушинскийдан*.....73
**Шигырьләр**.....74
Күз. *Ә. Ерикәй*.....74
Яратам. *Ш. Маннур*.....74
Минем бакчам. *Ә. Бикчәнтәева*.....74
Көзге яңгыр. *М. Фәйзуллина*.....74

Бәтиләр. *Ә. Бикчәнтәева*......75
Чишмә. *Ә. Исхак*......75
Безнең сыер. *Н. Каштан*......75
Беренче рәхмәт. *Ә. Исхак*......76
Шофёр булам. *З. Туфайлова.*......76
Ул шуңа кечкенә. *З. Гомәрова*......76
Үз телендә сөйләшә. *Э. Мөэминова.*......77
Ботка. *Р. Харис*......77
Минем сеңлем. *Р. Вәлиева*......78
Энесенә ул апа. *М. Мазунов*......78
Түз инде. *Р. Корбан*......79
Ләлә чана шуа. *Б. Рәхмәт.*......79
Ләйлә. *Һ. Такташ.*......79
Салкын, саф һава. *Ә. Бикчәнтәева*......80
Кыш бабай. *Б. Рәхмәт*......80
Кыш бабай. *Ә. Рәшит*......80
Минем бүләк. *З. Гомәрова.*......80
Куянкай. *Н. Исәнбәт*......81
Үзен бик чиста йөртә. *Җ. Тәрҗеманов*......81
Әтәч. *Г. Лотфи.*......81
Кәҗә. *М. Мазунов.*......81
Яз. *Б. Рәхмәт*......82
Тышта яз. *Ә. Ерикәй.*......82
«Әни» сүзе. *З. Туфайлова*......82
Уңган сыерчык. *Х. Вахит*......82
Тавыклар белән Таһир. *Д. Гарифуллин*......83
Зиләнең курчагы. *Х. Халиков*......83
Йокла инде, курчагым. *Ә. Бикчәнтәева*......83
Тәти кул. *М. Фәйзуллина*......83
Алмаз. *Җ. Дәрзаман.*......84
Сүз тыңлаучан булыгыз. *Р. Вәлиева*......84
Башмак кигәндә. *Р. Харис*......84
Курчак. *Ә. Кари*......85
Ике кыз. *Ә. Кари*......85
Әнигә булышам. *Г. Нәбиуллин*......85
Ап-ак иткән. *Ф. Яруллин*......86
Әни белән сөйләшү. *А.Барто (Ә. Юныс тәрҗемәсе).*......86

**«Гөрләп үсәбез, без бәхетлеләр...»**
*4–5 яшьлек балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**.......................................................................88
Җырлар, такмаклар, мавыктыргычлар, эндәшләр, бармак уеннары.......................................................................................................88
**Әкиятләр, хикәяләр**.............................................................................90
Йомры күмәч. *Рус халык әкияте*..........................................................90
Торна белән Төлке. *Әкият*.....................................................................92
Ата каз. *Татар халык әкияте*...............................................................92
Балыкчы Аю. *Татар халык әкияте*......................................................93
Ябалак. *Әкият*...........................................................................................94
Ике ялкау. *Татар халык әкияте*...........................................................94
Тавык, Тычкан һәм Көртлек. *Татар халык әкияте*.........................95
Карт белән Төлке. *Татар халык әкияте*.............................................96
Конфет ашап, тамак туямы? *Корея халкы әкияте*............................97
Комсызлык бәласе. *Венгр халык әкияте*............................................98
Күбәләкләр ничек килеп чыккан? *Филиппин халык әкияте*...........99
Әтәч һәм Бөркет. *Тибет халкы әкияте*..............................................99
Бөдрә чәчле кыз. *Чукот халык әкияте*.............................................100
Тавык белән Сарык. *Болгар халык әкияте (Р. Гариф тәрҗемәсе)*.......................................................................101
Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау. *Абхаз халык әкияте*.......................101
Керпе туны. *Хәйдәр*...............................................................................102
Шифалы сөт. *С. Сәүбәнова*...................................................................103
Кыңгырау чәчәк. *Р. Вәлиева*...............................................................104
Чуар тавык *Г. Гомәр*..............................................................................105
Аю Әппәс. *Батулла*.................................................................................106
Бикбатыр белән Биккуркак. *А. Алиш*..............................................107
Койрык. *Ә. Гаффар*................................................................................108
Җил белән Кояш. *Г. Тукай*...................................................................109
Комсыз эт. *К. Насыйри*..........................................................................109
Кырмыска белән күгәрчен. *Л. Толстой*.............................................110
Зирәк чәүкә. *Л. Толстойдан*.................................................................110
Төлке белән Кысла. *Л. Толстой (Ә. Еники тәрҗемәсе)*..............110
Куян белән Керпе *К. Ушинский (Ш. Шириазданов тәрҗемәсе)*.....................................................................................................111
Хайваннар бәхәсе. *К. Ушинский (Ш. Шириазданов тәрҗемәсе)*.....................................................................................................111

Тавык һәм үрдәк бәбкәләре *К. Ушинский (Ш. Шириазданов тәрҗемәсе)*..........111
Шапшакларны бака ялый. *Батулла*..........112
Балалар бакчасында. *Ә. Хәсәнов*..........113
Эшче абый. *А. Алиш*..........113
Ботка. *Ф. Садриев*..........114
Бер әби. *В. Осеева (А. Лутфуллина тәрҗемәсе)*..........116
Тәмле сүз. *Ә. Бикчәнтәева*..........116
Куян күчтәнәче, яки тешсез малай. *З. Хөснияр*..........118
Әби белән онык. *Мәҗит Гафури (А. Лутфуллина тәрҗемәсе)*..........118
Начарлык. *В. Осеева (А. Лутфуллина тәрҗемәсе)*..........119
**Шигырьләр**..........120
Көз. *Г. Тукай*..........120
Бу кайчак була? *Г. Тукай*..........120
Көз. *К. Нәҗми*..........120
Яфрак бәйрәме. *Л. Лерон*..........120
Бу кайчак, туган? *Г. Тукай*..........121
Кыш. *Җ. Тәрҗеманов*..........121
Кыш. *Ә. Кари*..........122
Буран. *Г. Толымбай*..........122
Шуабыз. *Н. Мадьяров*..........123
Кошлар туйдырам. *Ә. Кари*..........123
Кыш бабай. *М. Фәйзуллина*..........123
Солдатлар. *К. Булатова*..........124
Туган илнең улы мин. *Р. Миңнуллин*..........124
Бу кайсы вакыт? *Г. Тукай*..........124
Яз җитә. *Ф. Кәрим*..........125
Яз килә. *Н. Гайсин*..........125
Яз. *Р. Вәлиева*..........125
Апрель. *С. Маршактан*..........126
Сыерчыклар. *Ә. Бикчәнтәева*..........126
Минем әнием. *Ә. Бикчәнтәева*..........126
Әниләр бәйрәме. *С. Сөләйманова*..........127
Дәү әнигә күчтәнәч. *Ш. Галиев*..........127
Оекбаш. *Р. Корбан*..........128
Кишер суы. *А. Барто (Ә. Юныс тәрҗемәсе)*..........128
Бакчага килгәч. *Б. Рәхмәт*..........128

Йомшак су, йөгерек су. *Җ. Тәрҗеманов*....................................129
Уенчыклар. *Б. Рәхмәт*...........................................................129
Гөлсия. *Н. Гайсин*...............................................................130
Һаҗирә апа. *М. Садри*..........................................................130
Аның өчен оялам. *З. Туфайлова*............................................130
Уяталар. *Р. Вәлиева*............................................................131
Юмартлар. *Р. Харис*............................................................131
Нәни ташчылар. *З. Туфайлова*...............................................131
Светофор – тәмлетамак?! *Л. Лерон*.......................................132
Пескәем. *М. Хөсәен*.............................................................132
Светофор. *Р. Бәшәр*.............................................................133
Чебиләр сөенделәр. *Я. Игәнәй*...............................................133
Тиен. *Ә. Кари*.....................................................................134
Бәләкәй көчек. *М. Әлимбаев (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе)*.................................................................................134
Бу кайчак була? *Г. Тукай*......................................................134
Хәерле иртә. *Х. Халиков* .......................................................135
Тыныч йокы! *Ш. Галиев*.........................................................135
Кояшлы ил. *Ә. Рәшит*............................................................136

**«Без инде хәзер зурлар»**

*5–6 яшьлек балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**...................................................138
Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр, эндәшләр, әйтешләр.............................................................138
**Әкиятләр, хикәяләр, легендалар**..........................................140
Кем көчле? *Татар халык әкияте*...........................................140
Батыр әтәч. *Татар халык әкияте*..........................................141
Күгәрченнәр ни өчен гөрләшеп яшиләр, һәм гөрләмеш уены каян килеп чыккан? *Легенда*..................................................144
Куркак юлдаш. *Татар халык әкияте*.....................................145
Ике кыз. *Татар халык әкияте*...............................................145
Ни өчен Эт белән Песи бер-берсенә дошман булганнар? *Легенда*..............................................................................149
Өч кыз. *Татар халык әкияте*.................................................150
Шүрәле. *Татар халык әкияте*................................................152
Карга ни өчен исемен әйтеп бетерми? *Башкорт халык әкияте*......152

Башак. *Украин халык әкияте*............................................................153
Итагатьле мәче. *Литва халкы әкияте*................................................155
Бүре аларны нигә ашаган? *Болгар халык әкияте*.............................156
Хәйләкәр Әтәч. *Болгар халык әкияте*...............................................157
Күңелле Чыпчык белән күңелсез Карга. *Калмык халык әкияте* .....158
Суалчан кунакка бара. *Ә. Гаффар*......................................................159
Каз белән Аккош. *А. Алиш*.................................................................160
Мактанчык алма. *С. Сәүбәнова*..........................................................161
Ялкау карга баласы. *Р. Вәлиева*..........................................................162
Әбү булган аягы. *Батулла*...................................................................164
Алпамыш шәһәргә килде. *И. Дәүләтша*............................................165
Керпе. *С. Сәүбәнова*. ........................................................................166
Ак песи. *Г. Мөхәммәтшин*..................................................................167
Ялкау өчен ботка суынган. *И. Туктар*................................................168
Әбиләрдә кунакта. *А. Алиш*................................................................169
Ирек, Алмас һәм Җәлил. *Н. Фәттах*....................................................171
Велосипедлы Мөнир. *Н. Фәттах*..........................................................173
Иртәнге нурлар. *К. Ушинский (Ф. Басыйров тәрҗемәсе)*............175
Сыер. *К. Ушинский (А. Әхмәт тәрҗемәсе)*.......................................175
Сөт елгасы. *Я. Тайц (К. Котдусова тәрҗемәсе)*..............................176
Канатларың булса... *Р. Мингалим*.......................................................176
Агачлар да авырый. *З. Әхмәров*..........................................................177
Йорт салалар. *Г. Бакир*........................................................................178
Актырнак белән Назбикә. *Җ. Дәрзаман*............................................180
Көн җылынды. *М. Хәсәнов*..................................................................181
Кое чыпчыгы. *Н. Кәримова*..................................................................182
Татлы җәй. *Ф. Зариф*............................................................................184
Бал дәвалый. *А. Хәсәнов*.....................................................................186
**Шигырьләр** ...........................................................................................187
Көз. *Х. Халиков*......................................................................................187
Көзге табын. *Ф. Яруллин*.......................................................................187
Без игенчеләр булдык. *Р. Вәлиева*.......................................................188
Октябрь. *М. Мазунов*..............................................................................190
Банан тәмле буламы? *Ә. Рәшит*...........................................................191
Кар яуды. *Г. Латыйп*...............................................................................191
Кыш килде. *Г. Зәйнашева*......................................................................192
Балалар ярдәм итә. *Г. Лотфи*.................................................................192

Кыш бабай бүләкләре. *Ә. Кари*......................................................193
Бүләк. *Йолдыз*...................................................................................193
Яшел чыршы, яшь чыршы. *Э. Шәрифуллина*...................................193
Почмакта торам. *Р. Миңнуллин*.......................................................194
Яз килә. *Б. Рәхмәт*..............................................................................195
Яз. *Н. Баян*...........................................................................................195
Минем кунагым. *Ә. Кари* ...................................................................195
Бәйрәм бүген. *Р. Корбан*.....................................................................196
Нәүрүз. *Р. Миңнуллин*........................................................................197
Тукай абый. *З. Туфайлова*...................................................................197
Бала белән Күбәләк. *Г. Тукай*............................................................197
Бал корты. *М. Фәйзуллина*..................................................................198
Ныграк авыртыр иде. *Р. Корбан*........................................................199
Оныткан. *Х. Халиков*...........................................................................199
Керпе белән Бала. *Р. Вәлиева*.............................................................199
Безнең дусларыбыз. *М. Хөсәен*..........................................................200
Авыл малае белән шәһәр малае. *Р. Миңнуллин*................................201
Энә. *Н. Думбадзе (Р. Вәлиева тәрҗемәсе)*.........................................201
Якшәмбе көн балыкта. *А. Тимиркаев (Р. Вәлиева тәрҗемәсе)*......202
Елга. *А.Барто (З. Мансур тәрҗемәсе)*.................................................202
Миннән дә зур үсәрсез. *З. Туфайлова*...............................................202
Кунаклар. *Ш. Галиев*............................................................................203
Берүзем. *А. Барто (Р. Вәлиева тәрҗемәсе)*.........................................203
Ярый әле. *Г. Гыйльманов*.....................................................................204
Шофёр буласым килә. *Э. Шәрифуллина*............................................204
Өлкән группага күчкәч. *М. Фәйзуллина*............................................205
Туган тел. *Ш. Галиев*...........................................................................205
Якын дус. *Җ. Тәрҗеманов*....................................................................205
Кадерлә син китапны. *Х. Шабанов*.....................................................206
Безнең гаилә. *Г. Тукай*..........................................................................206
Иң матур сүз. *Н. Исәнбәт*.....................................................................206

**«Мәктәпкә илтә юллар»**
*6–7 яшьлек балалар өчен*

**Татар халык авыз иҗаты**................................................................208
Җырлар, такмаклар, әйтенүләр.............................................................208
Санамышлар.............................................................................................209
Календарь йола җырлары.......................................................................209

Тел көрмәкләндергечләр.................................................................210
Алдавыч әкиятләр..........................................................................210
Ай белән Кояш. *Татар халык әкияте*..........................................211
Ялкау малай. *Татар халык әкияте*................................................212
Зөһрә йолдыз. *Легенда*.................................................................212
Кәкре каенга терәткән. *Татар халык әкияте*...............................214
Алтын бөртекләр. *Татар халык әкияте*.......................................215
Ни өчен бакалар бакылдык булып калганнар? *Легенда*...............216
Ни өчен, Чәберчек килмичә, боз китми икән? *Легенда*...............217
Бүләк кемгә? *Татар халык әкияте*................................................218
Кола ат. *Әкият*...............................................................................219
Казлар-аккошлар. *Рус халык әкияте*...........................................220
Куянның ирене нигә ярык? *Эстон халык әкияте*.........................222
Сандугач. *Украин халык әкияте*...................................................223
Тату туганнар. *Корея халкы әкияте*..............................................224
Икмәк. *Төрекмән халык әкияте*....................................................225
Пингвин баласы. *Инглиз халык әкияте*.......................................226
Тычкан белән Чыпчык. *Удмурт халык әкияте (Р. Вәлиев тәрҗемәсе)*..................................................................................227
Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар. *А. Алиш*...............228
Тузганак. *С. Гыйльметдинова*........................................................230
Һәркемнең үз эше. *Н. Исәнбәт* .....................................................231
Кыш бабай бүләк өләшә. *А. Хәсән* ...............................................232
Кар кызы. *В. Даль (Т. Шакирова тәрҗемәсе)*...............................234
Чыбык ашату. *Батулла* ..................................................................236
Иң бәхетле көн. *Ф. Яруллин буенча*..............................................237
Ташбака белән Куян. *Г. Тукай*......................................................239
Җил белән Кояш. *К. Ушинский (Т. Шакирова тәрҗемәсе)*..................................................................................239
Сабыр итә бел. *К. Ушинскийдан (Ш. Шириазданов тәрҗемәсе)*..................................................................................240
Дуслар. *С. Әдһәмова*......................................................................241
Чишмә. *Ф. Зариф*...........................................................................245
Чәчәк. *С. Сәүбәнова*.......................................................................247
Гөлгүзәл. *С. Гаффарова*..................................................................248
Кыңгырау чәчәкләр. *Ә. Гаффар*....................................................249
Кояштагы тап. *Ф. Яруллин*............................................................251
Өч угыл. *Дәрдемәнд*.......................................................................253

Тәрбияле бала. *Р. Фәхреддин*..........253
Хәрәмләшү. *Н. Каштан*..........254
Кадерле бүләк. *Г. Сабитов*..........256
Ай-һай. *А. Әхмәт*..........257
Куян. *Г. Хәсәнов*..........259
Песнәк. *Р. Хафизова*..........259
Ак песи. *Р. Вәлиева*..........260
Солтания белән күбәләк. *Н. Каштан*..........262
Витаминлы аш. *Х. Халиков*..........263
Тылсымлы сүз. *В. Осеева (А. Лутфуллина тәрҗемәсе)*..........266
Кем хуҗа? *В. Осеева (Ф. Гайнанова тәрҗемәсе)*..........269
Туган көндә. *Р. Вәлиева*..........269
Җанлы эшләпә. *Николай Носов (Т. Шакирова тәрҗемәсе)*..........270
Туган илем. *М. Пришвин (Х. Фәйзрахманова тәрҗемәсе)*..........272
**Шигырьләр**..........274
Мәктәп. *Н. Думави*..........274
Көз җитте. *М. Җәлил*..........274
Чыршы. *Г. Тукай*..........274
Күңелсез көз. *С. Сүнчәләй*..........275
Ашлар солтаны. *Р. Вәлиева*..........275
Уңыш җыелды. *Н. Гайсин*..........277
Кырдан кайткач. *Х. Халиков*..........277
Беренче кар. *Н. Думави*..........277
Кыш килде. *Б. Рәхмәт*..........278
Кыш килде. *Г. Латыйп*..........278
Җепшек көндә. *Җ. Дәрзаман*..........278
Ак бабай. *Г. Тукай*..........279
Һай, Кыш бабай. *Җ. Тәрҗеманов.*..........279
Бер яшькә үстем. *Н. Гайсин*..........280
Җәлил турында җыр. *Р. Корбан*..........280
Яз килә. *М. Мазунов*..........281
Әниләр бәйрәмендә. *Ф. Яруллин*..........281
Иң матур җыр. *Җ. Тәрҗеманов.*..........282
Әти кайтыр эштән... *Я. Игәнәй*..........282
Кайгырту. *Ш. Җиһангирова*..........283
Энҗе-мәрҗән калфагым. *Р. Вәлиева*..........283
Тылсымлы түбәтәй. *Йолдыз*..........284
Бүген. *Р. Бәшәр*..........285

Намаз. *Р. Бәшәр*......................................................................................285
Бәйрәм бүген. *Г. Тукай*............................................................................286
Китап һәм балалар. *М. Гафури*...................................................................286
Әлифбам. *Ә. Бикчәнтәева*..........................................................................287
Кояш – безнең дустыбыз. *Р. Корбан*.........................................................287
Туган тел. *Г. Тукай*....................................................................................288
Туган телем. Э. *Мөэминова*.......................................................................288
Татар теле. *М. Гафури*...............................................................................288
Нәүрүз килә. Р. *Хафизова*.........................................................................289
Тукай көне. *М. Әгъләмов*...........................................................................289
Моңсу бәйрәм. *Э. Мөэминова.*....................................................................290
Татарстан байрагы. *Ф. Яруллин*.................................................................290
Туган җир. *Р. Вәлиева*...............................................................................291
Карга бичара. *Юозас Некрошюс (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе)*........................................................................................................291
Сандугачлы Ак инеш. *Р. Бәшәр*.................................................................292
Кызыл китап. *Р. Фәйзуллин*.......................................................................292
Дуслашасым килә! *В. Романов (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе)*........................................................................................................293
Мин җырларга яратам. *Р. Сарби (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе*..........................................................................................................294
Май. *С. Маршактан*...................................................................................294
Июнь. *С. Маршактан*..................................................................................294
Катя. *А. Барто. (М. Хөсәен тәрҗемәсе)*.....................................................294
Кабырчык. *А. Барто (Г. Латыйп тәрҗемәсе)*..............................................295
Казлар, казлар. *К. Тәхау*............................................................................295
Песи һәм Чыпчык. *А. Нигъмәтуллин*..........................................................296
Карак песи. *Х. Халиков*..............................................................................296
Светофор. *Р. Миңнуллин*............................................................................297
Малайлар сөйләшә. *Р. Миңнуллин*..............................................................298
Сөембикә манарасы. *Л. Шагыйрьҗан*.........................................................298
Казан. *Х. Туфан*.........................................................................................299
Биктырыш «Әлифба» укый. *А. Хәлим*........................................................299
Хуш, сөекле бакчабыз. *Ә. Бикчәнтәева*.......................................................300

# II КИСӘК
## «Җирдә миңа ни кирәк?»
### I бүлек
### Хәрәкәттә – бәрәкәт
*(«Физик үсеш» юнәлеше)*

«Сәламәтлек» белем бирү өлкәсе


Мәкальләр, әйтемнәр........................................304
Табышмаклар........................................304
Армыйм да мин, талмыйм да! *М. Хөсәен*........................................306
Хәрәкәттә – бәрәкәт. *Х. Халиков* ........................................306
Зарядкага бас. *Г. Юнысова*........................................307
Хәрәкәттә – бәрәкәт. *Г. Морат*........................................307
Физкультура. *Г. Морат* ........................................307
Ял ит инде. *Х. Халиков*........................................308
Тот яхшы тәрбиядә. *З. Гомәрова*........................................308
Көмеш чишмә. *Д. Гарифуллин*........................................309
Чишмәгә бардык. *Г. Гыйльманов*........................................309
Чисталык яратабыз. *М. Фәйзуллина*........................................309
Песине дә юабыз. *Б. Рәхимова*........................................310
Бармаклар. *Г. Юнысова* ........................................310
Муен. *Г. Юнысова.*........................................310
Тешләр. *Г. Юнысова*........................................311
Чисталык сөябез. *Ә. Ерикәй*........................................311
Аш вакыты. *Б. Рәхмәт*........................................312
Сөт эчәбез. *Р. Вәлиева*........................................312
Чәчәкләр ясыйм. *С. Сөләйманова*........................................312
Без ашыйбыз бишбармак. *А. Хәлим*........................................313
Шифа чәе. *В. Хәйруллина*........................................314
Аппетиты юк. *В. Хәйруллина*........................................314
Әбиләрдә кунакта. *Ш. Галиев*........................................314
Табиблар янымызда. *В. Хәйруллина*........................................315
Татлы чир. *В. Хәйруллина*........................................316
Ватмасын. *В. Казыйханов*........................................316
Чама бел. *В. Казыйханов*........................................316
Яшьтән өйрән тәртипкә! *Ф. Тарханова* ........................................317
Курчагымны өйрәтәм. *Я. Игәнәй*........................................317
Ләйсән инде зур булган. *З. Насыйбуллин*........................................317

Йомшак кыш яратабыз. *Мөҗәһит*..................................................318
Бер дә ял итми калам. *М. Фәйзуллина*...........................................318
Өстәл янында. *Ә. Бикчәнтәева*........................................................319
Табын әдәпләре. *К. Насыйри*...........................................................320
Ашау әдәпләре. *Р. Фәхреддин*..........................................................320
Ботка нигә тәмле? С. Сәүбәнова........................................................321
Киемнәр кая киткән? *Әкият*..............................................................322
Әкияттәге кебек. *Э. Шәрифуллина*...................................................325
Шифалы табиблар. *В. Монасыйпов*..................................................326

**«Физкультура»**
**белем бирү өлкәсе**

Табышмаклар.......................................................................................328
Санамышлар........................................................................................329
**Уеннар**.................................................................................................332
Кояш һәм яңгыр....................................................................................332
Куышу..................................................................................................332
Йонлач көчек........................................................................................333
Төлке һәм куяннар................................................................................333
Черки...................................................................................................333
Коңгызлар............................................................................................334
Кечкенә туплар.....................................................................................334
Атлар һәм көтүче..................................................................................335
Курыкмыйм..........................................................................................335
Бүләкләр...............................................................................................335
Такыя үрәм...........................................................................................336
Тургай, чыпчык.....................................................................................336
Мин качам, син тот................................................................................337
Ачкычлар..............................................................................................337
Тилгән һәм тавык .................................................................................337
Аю.......................................................................................................338
Чәчәкләр, җилләр..................................................................................338
Сикергечләр.........................................................................................339
Тырыш кырмыскалар............................................................................339
Әйт, күгәрчен........................................................................................339
Яулык алыш ........................................................................................340
Башмакчы.............................................................................................340
Бүген кемнең туган көне?......................................................................341
**Физкультминутлар**..............................................................................342

## II бүлек
## Һәрвакыт булсын кояш
*(«Социаль-шәхси үсеш» юнәлеше)*
«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе


Мәкальләр, әйтемнәр.......................................................................360
Табышмаклар....................................................................................361
Әссәламегаләйкем! *Г. Садә*............................................................362
Тылсымлы сүзләр. *Йолдыз*.............................................................362
Якты сүз. *Х. Халиков* ......................................................................363
Хәерле көн. *В. Хәйруллина*..............................................................363
Әйдә, танышабыз. *В. Хәйруллина*...................................................363
Үсәсем килә минем. *Л. Әмирханова*................................................364
Үсәсем бар. *Ф. Зыятдинова*.............................................................364
Кечкенә. *Ш. Җиһангирова*...............................................................365
Үстем. *Д. Гарифуллин*......................................................................365
Иртә. *И. Иксанова*............................................................................365
Әни дә мин, бала да мин. *Ә. Габиди*...............................................366
Бу – мин! *В. Ураксина*......................................................................366
Туган. *В. Хәйруллина*.......................................................................366
Минем гаиләм. *З. Туфайлова*...........................................................367
Әтием белән бергә. *Ә. Бикчәнтәева*................................................367
Хәзер инде өчәү без. *Х. Халиков*.....................................................367
Олы кунаклар. *В. Хәйруллина.*.........................................................368
Энем бар. *Р. Мингалим*....................................................................368
Энемә. *Йолдыз*..................................................................................369
Мин бит татар егете. *Р. Бәшәр.*.......................................................369
Дәү әнием. *Ә. Бикчәнтәева*..............................................................370
Зиратка бардык. *Х. Халиков*............................................................370
Гөлсия. *Н. Гайсин*............................................................................370
Йоклар алдыннан. *Р. Мәннан*...........................................................371
Үпкәләп булмый әбигә. *Н. Мадьяров*..............................................371
Иңнәремдә – фәрештә. *Э. Шәрифуллина*.........................................371
Рамазан аенда. *Йолдыз*.....................................................................372
Булышабыз. *Мөҗәһит*......................................................................372
Курчаклар. *Б. Рәхмәт*.......................................................................372
Минем эш. *Йолдыз*...........................................................................373
Сөйләшсәләр безнеңчә... *Х. Халиков*..............................................373

Ул бакчаны ярата. *Г. Лотфи*..........373
Кунакка килегез! *Йолдыз*..........374
Татарстан җирләре. *Ә. Синегулов*..........374
Мин яратам сине, Татарстан. *Р. Рәкыйпов*..........374
Казанда гына калам. *Мөҗәһит*..........375
Сәлам, Галәм! *Йолдыз*..........375
Дусларың гына булсын. *Р. Мингалим*..........375
Хат. *Г. Юнысова*..........376
Дуслык җыры. *Л. Әмирханова*..........376
Булатларга кунакка! *Р. Миңнуллин*..........377
Хикмәтле чиләк. *Н. Каштан*..........378
Кечкенә Миләш. *Г. Таһирова*..........379
Ярдәм. *Н. Каштан*..........380
Гап-гади Инсаф. *Г. Мөхәммәтшин*..........382
Бүләк. *Г. Гыйльманов*..........382

**«Хезмәт»**
**белем бирү өлкәсе**

Мәкальләр, әйтемнәр..........386
Табышмаклар..........387
Бармак уены. *Ф. Зиннурова*..........388
Эшкә өндәү. *Г. Тукай*..........389
Кызыклы шәкерт. *Г. Тукай*..........389
Игенчеләр гаиләсе. *Р. Миңнуллин*..........389
Безнең бабай. *М. Мазунов*..........390
Иртәнге кояш. *З. Туфайлова*..........390
Ике көрәк. *М. Фәйзуллина*..........390
Таяклы помидор. *В. Хәйруллина*..........391
Булышам. *Р. Мәннан*..........391
Кишер чәчтек. *Я. Игәнәй*..........392
Әниемә булышам. *Н. Мадьяров*..........392
Ялт иттерде бүлмәне. *Ф. Тарханова*..........393
Теләсәң, эш табыла. *М. Фәйзуллина*..........393
Кем кем була? *Л. Шәех*..........393
Эш табыла кемгә дә. *Э. Мөэминова*..........394
Мин әтигә охшаган. *Я. Игәнәй*..........394
Кем булырга? *Г. Юнысова*..........395
Әтием – җир докторы. *Мөҗәһит*..........395

Гөлсем апа. *Ә. Бикчәнтәева*..............................................................396
Минем әнием – тегүче. *Ә. Кари*...........................................................396
Архитектор. *В. Хәйруллина*...................................................................396
Әти йорт төзи. *Ә. Ерикәй*......................................................................397
Доктор апа. *Г. Нәбиуллин*......................................................................397
Дәү әнием – бакчачы. *Х. Халиков*............................................................398
Чирле кран. *В. Хәйруллина*....................................................................398
Фокусчы. *Э. Мөэминовадан*.....................................................................399
Нәни чакта һәм зур үскәч. *Ә. Бикчәнтәева* ..................................399
Фотомодель булам. *В. Ураксина*..........................................................400
Теш табибында. *Йолдыз*......................................................................400
Һәркем эштә. *Г. Тукай*............................................................................401
Кем тизрәк үскән? *Н. Каштан*.............................................................401
Супермалай. *Л. Лерон*...........................................................................403
Ничек аңларга? *Э. Шәрифуллина*.......................................................403

## «Иминлек»
## белем бирү өлкәсе

Мәкальләр, әйтемнәр..................................................................................406
Табышмаклар..............................................................................................406
Үрли дә үрли генә. *Ә. Бикчәнтәева* .................................................407
Гөмбәләр. *М. Фәйзуллина*.......................................................................407
Кошларга. *Г. Тукай*...................................................................................408
Песи, песи, пескәем... *Д. Гарифуллин*.................................................408
Батыр кызчык. *Б. Рәхимова*..................................................................409
Сансыз малай. *Б. Рәхимова*..................................................................409
Акбай шулай ди... *Р. Миңнуллин*.........................................................410
Авыру урман. *Р. Бәшәр*...........................................................................410
Тәкый һәм пәке. *Х. Халиков*...................................................................411
Песинең зары. *С. Шакир*.........................................................................411
Ятим тургай. *Х. Халиков*........................................................................412
Машинада балалар. *З. Гомәрова*..........................................................412
Светофор. *И. Иксанова*..........................................................................412
Светофорның өч сүзе. *Ш. Галиев*........................................................413
Светофор. *Г. Юнысова*............................................................................413
Велосипедыңа өйрәт. *К. Низамова*........................................................414
Алга утырсаң... *Р. Мәннан*.....................................................................414
Светофор. *Йолдыз*....................................................................................414

Уйныйсы килә. *З. Гомәрова*..............................................................415
Кызык итте... *Ф. Сафин*........................................................................416
Шомырт нигә елый?.. *Р. Төхфәтуллин.буенча* ..............................417

## III бүлек
## «Дөнья матур, дөнья киң»
## («Танып белү-сөйләм үсеше» юнәлеше)
## «Танып белү» белем бирү өлкәсе

Мәкальләр, әйтемнәр...............................................................................420
Табышмаклар..........................................................................................420
Табигать күренешләре.............................................................................420
Үсемлекләр.............................................................................................421
Җәнлекләр, кош-корт, бөҗәкләр... ...........................................................422
Үсемлекләр дөньясы................................................................................424
Йорт-җир, көнкүреш әйберләре, кием-салым, савыт-саба,
аш-су.......................................................................................................425
Табигать кочагында *Р. Фәйзуллин*............................................................426
Яз. *Г. Рәхманколый*....................................................................................426
Фасыллар. *Г. Шаһиев*..................................................................................427
Булмагандыр буявы. *В. Ахунҗанов*.............................................................427
Кар астыннан чыкты яз. *Н. Мадьяров*..........................................................428
Җилкәй, исмә. *В. Ахунҗанов*.......................................................................428
Нәрсә ул җил? *Р. Мәннан*...........................................................................428
Яңгыр ява. *И. Юзеев*...................................................................................429
Яшенле яңгыр. *Г. Рәхим*..............................................................................429
Кырау. *Р. Шәрипова*....................................................................................430
Томан. *Н. Мадьяров*....................................................................................430
Давыл. *Ф. Җамалетдинова*...........................................................................430
Өермә. *Л. Шәех*..........................................................................................431
Ай белән кояш очрашкач. *Р. Шәрипова*........................................................432
Саташкан табигать. *Р. Шәрипова* .............................................................432
Чүмеч йолдыз. *Г. Гыйльманов*.......................................................................432
Яңа һәм иске ай. *М. Фәйзуллина*..................................................................433
Алмалар ничек кызарган? *Н. Мадьяров*.......................................................433
Балан. *Н. Мадьяров*......................................................................................434
Чыршының күлмәкләре. *М. Фәйзуллина* ......................................................434
Ап-ак икән эзләрем. *Л. Шагыйрьҗан*............................................................435
Маратка нәрсә җитми? *Р. Фәйзуллин*............................................................435

Җәнлекләр. *М. Фәйзуллина*..........................................................435
Кәгазь. *Р. Фәйзуллин*....................................................................436
Күгәрчен *Н. Гайсин*.........................................................................436
Сыерчыклар. *Л. Лерон*.....................................................................437
Файдалы чәүкәләр. *А. Жамалиев*....................................................437
Чыпчык. *Ф. Яруллин*.........................................................................437
Нәни дусларым. *Л. Әмирханова*......................................................438
Беләсезме? *М. Фәйзуллина*..............................................................438
Яу-яу. *Р. Мингалим*...........................................................................438
Гүзәл. *М. Сөндекле*............................................................................439
Урманда. *З. Гомәрова*.......................................................................439
Миләш. *Р. Фәйзуллин*........................................................................439
Әбием сүзләре. *Җ. Дәрзаман*............................................................440
Мәк чәчәге. *С. Шакир*........................................................................440
Күбәләк. *Ф. Кәрим*.............................................................................440
Бездән үрнәк алыгыз. *Мөҗәһит*......................................................441
Сыер. *М . Фәйзуллина*.......................................................................441
Замана бозавы. *А. Нигъмәтуллин*...................................................441
Танышмак өчен табышмак. *Ш. Галиев*............................................442
Ат. *Э. Мостафин*.................................................................................442
Безнең ишегалдында. *Л. Шәех*........................................................443
Куяннарым. *Н. Мадьяров*..................................................................444
Песи. *В. Хәйруллина*..........................................................................444
Атна. *Р. Корбан*...................................................................................444
Бер атнада ничә көн? *Г. Зәйнашева*..................................................445
Тәүлек. *Ә. Кари*..................................................................................445
Бу кайвакыт? Әйт, балам! *Л. Лерон*.................................................446
Көн һәм төн. *Г. Юнысова*..................................................................446
Кайсы ай бу? *Н. Каштан*....................................................................447
Нигә кирәк шкафлар? *Г. Юнысова*..................................................448
Пешкән, әллә пешмәгән. *М. Фәйзуллина*.........................................449
Куркыныч уй. *Йолдыз*.......................................................................449
Минем дусларым. *Р. Вәлиева*............................................................449
Тылсымчы. *Г. Юнысова*....................................................................450
Без – төзүчеләр. *Х. Халиков*.............................................................450
Тегермән. *Р. Вәлиев*..........................................................................451
Без ничәү? *Н. Мадъяров*....................................................................451
Саныйм әле. *Х. Халиков*...................................................................452

Үзебезчә бүлдек. *Х. Халиков*..........452
Мин ничә яшьтә? *Мөҗәһит*..........452
Төшемә керде. *Мөҗәһит*..........453
Ничә көннән? *Х. Халиков*..........453
Шәһәр төзим. *Р. Бәшәр*..........454
Чия. *Г. Юнысова*..........454
Хисап мәсьәләләре. *Б. Рәхмәт*..........455
Ничә сәгать кызынганбыз? *Х. Халиков*..........455
Бармак уеннары. *Ф. Зиннурова*..........456
Төлке белән Аю. *Мари халык әкияте (Р. Вәлиева тәрҗемәсе)*..........457
Аю койрыгы. *Индонезия халыклары әкияте (Р. Вәлиева тәрҗемәсе)*..........458
Әтәч ни өчен өч вакыт кычкыра? *Әкият*..........459
Ашыгыч ярдәм. *З. Гомәрова*..........459
Бал кортлары һәм яңгыр. *А. Хәсәнов*..........460
Алтын балык *Э. Шәрифуллина*..........461
Тамчы *Г. Лотфи*..........462
Кояш елый *З. Гомәрова*..........463
Дачада. *Т. Әйди*..........463
Сәгать дигән серле ил. *И. Иксанова*..........464
Хәтерсез Күке. *Ф Яруллин*..........465

## «Аралашу»
## белем бирү өлкәсе

Мәкальләр, әйтемнәр..........468
Табышмаклар..........468
Тел көрмәкләндергечләр..........470
**Шигырьләр**..........471
Яхшы бел. *Ш. Маннур*..........471
Татар теле. *Н. Мадьяров*..........471
Туган тел. *Г. Морат*..........471
Уйнап алыйк әле. *Г. Юнысова*..........472
Бәхәс. *Б. Рәхимова*..........472
«Алма» түгел, «алам». *С. Сөләйманова*..........473
Хаталарны төзәт. *Г. Юнысова.*..........473
Әйтә үрдәк. *Н. Мадьяров*..........474
Кызык китап. *Г. Юнысова*..........474

Китап. *С. Михалковтан*..................................................................474
Туган телгә өйрәттек. *Мөҗәһит*..................................................475
Ат ник көлә? *Ш. Маннапов*..........................................................475
Кем булып эшли? *В. Ураксина*......................................................475
Тел белү авыр түгел. *Мөҗәһит*.....................................................476
Татарча белмәүче кәҗәләр. *Ф. Зыятдинова* ..................................476
Әкиятләр яратам. *Э. Шәрифуллина* ...............................................477
Аю. *Г. Виеру (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе)*.........................477
Әйтче, Кояш! *Г. Виеру (Русчадан Р. Миңнуллин тәрҗемәсе)*........477
Өйдә калам. *Ф. Яруллин*...............................................................478
Каравылчылар. *Н. Мадьяров*........................................................478
Ай, кызым. *Ш. Галиев*..................................................................478
Өй чебеше. *Х. Халиков*................................................................479
Әнкәсе белән улы. *Ф. Яруллин* ....................................................479
Җавап бир. *Э. Мөэминова*............................................................480
Үрдәк белән сөйләшү. *Н. Мадьяров*..............................................480
Мәче нигә мыеклы? *М. Галиев*......................................................480
**Күңелле шигырьләр**.....................................................................481
Радиога салкын тигән. *Л. Лерон*...................................................481
Юкка малай булганмын. *Р. Миңнуллин*..........................................481
«Мөгезле» әни. *Йолдыз*.................................................................482
Кем хаклы? *Ш. Җиһангирова*.........................................................482
Күз тигән. *И. Юзеев*.....................................................................482
Тун кигән Акбай. *Р. Мәннан* ........................................................483
Ә үзләре... *Р. Миңнуллин*...............................................................483
Күлмәк белән сөйләшү. *И.Солтан*...................................................484
Өчпочмакмы, берпочмакмы? *Р. Шәрипова* ....................................484
Нажиягә ни булды? *Мөҗәһит*.........................................................484
Карлыган мунча керә. *В. Хәйруллина*............................................485
Ярамаган эш. *И. Солтан*...............................................................485
Әләкләргә ярамый. *К. Булатова* ....................................................486
Машина ала белмисез. *Н. Измайлова*.............................................486
Карак карга. *Йолдыз*.....................................................................487
Казанга киләчәкмен. *Мөҗәһит*.......................................................487
Битем туза. *Ф.Бәширова*...............................................................488
«Өйләнсәм», ни диярсең? *Ф. Тарханова*.........................................488
Үрдәк беренчелекне алган. *Әкият*..................................................489
Дөресе аның шулай... *Нәни хикәя. Р. Мингалим*.............................489

**IV бүлек**
**«Салават күпере»**
*(«Нәфис-нәфасәти үсеш» юнәлеше)*
**«Иҗат» белем бирү өлкәсе**

Мәкальләр, әйтемнәр....................................................................492
Табышмаклар................................................................................492
**Шигырьләр**...................................................................................493
Матурлык минем белән. *М. Әгъләмов*............................................493
Соклангыч дөнья. *Л. Лерон*...........................................................493
Матурлык. *И. Солтан*...................................................................493
Табигать. *Гыйффәт туташ*.............................................................494
Мин елмаям. *Э. Авзалова*..............................................................494
Нәкъ әкият диярсең. *Ф. Тарханова* ...............................................494
Рәсем. *Р. Бәшәр*...........................................................................495
Рәсем ясыйм. *Р. Фәйзуллин*..........................................................495
Рәсем дәресендә. *Р. Вәлиева*..........................................................495
Чуар тавык. *М. Фәйзуллина*...........................................................496
Үрдәк. *М. Фәйзуллина*...................................................................496
Сыер. *М. Фәйзуллина*....................................................................496
Төсләр. *Н. Мадьяров*.....................................................................497
Кара. *Г. Юнысова*..........................................................................497
Ак кыш. *Р. Миңнуллин*.................................................................497
Кәләпүшем, кәләпүш. *Р. Вәлиева*..................................................498
Түбәтәй. *В. Хәйруллина*................................................................498
Чигүле читекләрем. *Л. Әмирханова*...............................................498
Мәчет. *Р. Миңнуллин*....................................................................499
Татар баласы. *Л. Лерон*.................................................................499
Ислам дине. *М. Фәйзуллина*..........................................................500
Сигез таҗлы чәчәк. *В. Хәйруллина*................................................500
Азан әйтә бер малай. *В. Хәйруллина*..............................................500
Курчак театрында. *Л. Шагыйрьҗан*...............................................501
Безнең китапханәдә. *З. Туфайлова*.................................................502
Канатлы ай. *Н. Каштанов*...............................................................503
Кара төс ни өчен кирәк? *М. Закир*.................................................504

**«Музыка» белем бирү өлкәсе**

Мәкаль, әйтемнәр...........................................................................506
Табышмаклар................................................................................506

Табышмак-шигырьләр....................................................................508
**Шигырьләр**..............................................................................508
Музыка. *Б. Рәхмәт*.....................................................................508
Сәйдәш моңнары. *М. Хөсәен*...................................................509
Курай. *Р. Бәшәр*..........................................................................509
Мин аннан үрнәк алам. *Мөжәһит*.............................................509
Курай. *Г. Гыйльманов*................................................................510
Мандолина. *Ә. Кари*..................................................................510
Фейерверк. *В. Хәйруллина*........................................................510
Бииләр итек, читекләр. *Ш. Галиев* ..........................................511
Әйлән-бәйлән. *Р. Миңнуллин*.....................................................511
**«Бәйрәмнәр кирәк безгә»**..........................................................512
Сентябрь. *Н. Гайсин*...................................................................512
Түтәлләрдә үсте яшелчә... *Х. Гарданов*.....................................512
Чөгендер. *Ә. Синугыл*................................................................512
Яшелчәләр бәхәсе. *В. Хәйруллина* ..........................................513
Кыш килде. *М. Ногман*..............................................................513
Чыршы әйләнәсендә. *Р. Миңнуллин*...........................................514
Кыш бабай килгән. *Р. Корбан*...................................................514
Кыш бабай. *Т. Миңнуллин* ........................................................514
Кыш бабай. *Ә. Кари*...................................................................515
Исәнме, Кыш бабай! *Р. Корбан*.................................................515
Чыршы. *Ә. Ерикәй*......................................................................516
Бушлык. *Ф. Яруллин*..................................................................516
Бүген бәйрәм. *Н. Гайсин*...........................................................516
Батыр һөнәр. *В. Хәйруллина*.....................................................517
Әти бәйрәме көнне. *Б. Рәхимова*...............................................517
Әти дә көлеп торсын. *З. Туфайлова*.........................................517
Әти белән бергәләп. *Г. Нәбиуллин*............................................518
Бүләк. *Д. Хәбибуллин*................................................................518
Бүген әниләр бәйрәме. *Р. Вәлиева*............................................519
Әнием. *Р. Харис*.........................................................................519
Минем әни иң әйбәт. *В. Хәйруллина*..........................................519
Дәү әни. *Йолдыз*.........................................................................520
Әбиемне яратам. *Г. Зәйнашева*..................................................520
Минем әбием. *Г. Латыйп*............................................................520
Әбием килгән. *Ф. Зыятдинова*....................................................521
Карга боткасына сый җыйганда. *Халык авыз иҗаты*....................521

Бәйрәмгә чакыру. *Халык авыз иҗаты*..........521
Карга боткасы. *Ә. Габиди*..........521
Карга боткасы. *Йолдыз*..........522
Күкәй бәйрәме. *Л. Әмирханова*..........522
Нәүрүз мөбарәк булсын! *Халык авыз иҗаты*..........522
Нәүрүз. *Ә. Гадел*..........522
Туган тел бәйрәме. *Л. Шагыйрьҗан*..........523
Һәйкәл. *Н. Гайсин*..........523
Май килә. *Р. Миңнуллин*..........523
Якты ай, яхшы ай. *В. Хәйруллина*..........524
Җиңү көнендә. *Р. Вәлиева*..........524
Минем бабай. *Э. Шәрифуллина*..........525
Батыр булам. *Йолдыз*..........525
Рәхмәт әйтә сиңа кызың. *Э. Авзалова*..........525
Бабам истәлеге. *Л. Әмирханова*..........526
1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне. *В. Ураксина*..........526
Сабантуй. *Э. Мөэминова*..........526
Сабантуй. *Г. Морат*..........527
Сабантуй. *Э. Шәрифуллина*..........527
Сабан туе батыры. *Ш. Галиев*..........527
Сабан туе. *Г. Зәйнашева*..........528
Сабантуй бүген бездә. *Р. Миңнуллин*..........528
Туган көн. *В. Хәйруллина*..........528
Туган көн җыры. *Р. Миңнуллин*..........529
Тагын бер сүз. *И. Солтан*..........529
Чыпчык. *В. Хәйруллина*..........529
Бабай туган көн. *Җ. Тәрҗеманов*..........530
Иң матуры – мин! *Йолдыз*..........530
Әхмәтнең укыйсы килә. *Б. Рәхмәт*..........531
Мәктәпкә барасы бар. *Г. Рәхим*..........531
Минем дустым – Әлифба. *Н. Дәүли*..........532
Беренче көн. *М. Әхмәтгалиев*..........532
Бакча белән хушлашу. *Р. Миңнуллин*..........533
Мәктәпкә! *Б. Рәхмәт*..........533
Сара мәктәпкә бара. *М. Хәсәнов*..........534

**Искәрмәләр өчен**

Составитель
**Закирова Кафия Валиевна**

# На поляне детства

Хрестоматия
для воспитателей детских садов и родителей
*(на татарском языке)*

Төзүчесе
**Закирова Кафия Вәлиевна**

# Балачак аланы

Балалар бакчасы тәрбиячеләре
һәм әти-әниләр өчен хрестоматия

*Фәнни редактор* Д. М. Мостафин
*Рецензентлары* Г. Х. Манюрова, Н. Р. Фәләхова,
В. В. Шәйхетдинова, А. В. Абдурахманова
*Корректоры* Г. Г. Мөһәмәтҗанова
*Рәссамы* Л. С. Золондинова
*Компьютерда биткә салучы* Г. И. Гатауллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.11.2011.
Формат 60x90 1/16.Офсет кәгазе.
Офсет басма. Басма табагы 35.
Тиражы 5000 д. Заказ № 78.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристов урамы, 2.